ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.1990



## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: *420066, Казань, Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.*

Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1990

1

(807)

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Н. АРСЛАНОВ. Яңа шигырьләр . . . . . . 3
А. РАСИХ. Ишан оныгы. *Роман-истәлек* . . 8
Р. МИНГАЛИМ. Үзгәреш. *Шигырьләр* . . . 69
Г. КАШАПОВ. Кайгы. *Шигырьләр* . . . . 72

ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ

Д. ГЫЙСМЕТДИНОВ. Тамгалы бүрәнә. *Хикәя* 74

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

ЗӨЛФӘТ. Зөлфәт турында Зөлфәт . . . . . 82
З. ХӘКИМ. Айлы төн. *Шигырьләр* . . . . . 82

ӘДӘБИ МИРАС

И. НУРУЛЛИН. Кайту . . . . . . . . . . 85
Г. ИСХАКЫЙ. Сөннәтче бабай. *Хикәя* . . . 89
Г. ИСХАКЫЙ. Ике йөз елдан соң инкыйраз 110

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. БӘШИРОВ. Тургайсыз яшәп буламы? . . 143
С. ХАФИЗОВ. Политика һәм шигырь . . . . 149
Д. ИБӘТУЛЛИНА. Беренче буразналар *(Әмирхан Еникинең башлангыч чор иҗаты)* . . . 157

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН. Думавиның дөньяви уйлары 160

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТОБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Америка татарлары тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . 167

Бер сорауга бер җавап . . . . . . . . 172

Г. ЗӘБИРОВ. Ата Салих белән әңгәмәләр . . 173

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Бишенче дәрес . . . . . . . . . . . . 181

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . 184

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . . . 187
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60.
баш редактор урынбасары —
53-07-09.
җаваплы секретарь — 53-07-09.

*бүлекләр:*

проза, поэзия, очерк — 53-07-61.
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.
техредактор,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа А. РАСИХА «Внук ишана». Стихи Н. АРСЛАНОВА, Р. МИНГАЛИМА, Г. КАШАПОВА.
«На конкурс»: рассказ Д. ГИСМУТДИНОВА «Бревно с клеймом».
«Творчество молодых»: стихи З. ХАКИМА.
В рубрике «Литературное наследие» опубликованы рассказ и повесть классика татарской литературы ГАЯЗА ИСХАКИ.
«Литературная критика»: статьи Ф. БАШИРОВА «Жизнь без жаворонка?»; С. ХАФИЗОВА «Политика и поэзия»; Д. ИБАТУЛЛИНОЙ «Первые борозды» о начальном этапе творчества А. Еники.
«К истории культуры»: статья Я. АБДУЛЛИНА «Мировоззрение Н. Думави».
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: статья А. КАРИМУЛЛИНА «Из истории американских татар».
Очерк-воспоминание Г. ЗАБИРОВА о выдающемся туркменском поэте Ата Салихе.
Уроки татарского языка.
Навыки чтения на основе арабской графики.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках — историко-архитектурный памятник в Булгаре — Малый минарет.
Портрет известного татарского писателя Салиха Баттала.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 03.11.1989 ел. Басарга кул куелды 27.12.1989 ел. ПФ 05394. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 81049. Заказ Б-483. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Нури Арсланов

### Мавыктыргыч

Ни әйтсәң дә, узган елдан быел яхшы,—
Татып карау бүгенгенең сыен яхшы.
Җирләнеп — куыш корып «ял» итүдән,
Тынгы бирмәс ыгы-зыгы, кыен яхшы.

Язмышның кара ягы, ак ягы бар,
Тормышның ансат, кыен чаклары бар:
Тәгәрмәчтә әйләнсәң дә тиен кебек,
Яшәүнең мавыктыргыч яклары бар!

*1989.*

### Булмагандыр

Гаҗәп сәер яшәдем мин җирдә:
Язмыш миннән көлде, мин — аннан,
Шуңа ахры көн күрмәдем бер дә,—
Булмагандыр миндәй кыйналган...

Карый идем өстән, тик биектән
Дөньядагы ыгы-зыгыга.
Баксаң, нәкъ шул үзе көрәш икән:
Ир шунда я ега, я егыла...

Мин җаваплы идем тууыма,
Мин җаваплы идем хәятка:
Ничек инде дөнья кууына
Битараф бул, Илне ярат та!

Дәррәү төшә идем җиргә күктән
Ишеткәндә көрәш быргысын,
Без идек ул — походларны үткән,—
Уйлап тормый киресен, тугрысын.

---

Нури АРСЛАНОВ *(1912) — шагыйрь, тәрҗемәче, татар, рус телләрендә дөнья күргән күп санлы шигырь китаплары авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Әйе, тынгы белмәдем мин бер дә:
Язмыш миннән көлде, мин — аннан.
Карамагыз, дуслар, күңелем күргә,—
Булмагандыр миндәй кыйналган!..

*1988.*

## Сынык күңелдән

Болыт булып каплап торган
Күгемне чылбырлылар —
Аяз көннәргә омтылган
Күңлемне сындырдылар...

Киң-иркен Ил дә тар булган,
Без алалмадык тын да,—
Берни дә килмәде кулдан,
Әверелде ялган чынга.

Ясадылар тоташ зират
Илемне чылбырлылар,—
Шул чылбырлар мине кыйнап
Билемне сындырдылар!..

Килде гамь өстенә гамьнәр,
Ил — лагерь, анда коллар...
Йосыф та Йосыф пәйгамбәр
Булмаган икән мордар.

Узды ил буйлап көз итеп
Язымны чылбырлылар:
Шул чыңнар үзәккә үтеп
Сазымны сындырдылар...

Шул чылбыр тавышларында
Килә миллионнар зары...
Шуңа язым, кышларым да
Зәгъфыран төсле сары...

*1988.*

## Кузгала боз

Кузгалабыз, кузгала боз,—
Боз кәрваны Иделдә:
Яз җиткәнгә куанабыз!
Шатлыгым зур минем дә.

Идел уяна йокыдан
Зәңгәр күзләрен ачып.
Өстә кояш, үз йортына
Соклана, ярга басып.

Җылына боз асларында
Туңып яткан Иделем,—
Ни кичмәде башларыңнан,
И Туган илем минем!..

Кузгала боз, и ага боз!—
Җитә Әстерханнарга.
Бәйрәмнәр каршы алабыз
Сыйлы дәстерханнарда!

*1989.*

## Кар Кызына

Бизәнгән дә чыршы, туңган да,
Тирә-ягы тулган нурларга:
Ява йолдыз алтын сил төсле,
Ява кар — саф көмеш җир өсте.
Оча күккә бәллүр чаналар,—
Акбүзатлар Айга чабалар!
Салкыннан кыш үзе шыгырдый,
Куанычтан тәннәр чымырдый!

Бара торгач чаттан борылдым,—
Кинәт алда син пәйда булдың.
Көлеп әйттем: — Мин Кыш Бабаең,
Син Кар Кызы бул, яме, Аем!
Җитәкләшеп йөрик, таң атсын,
Мамыктай кыш безне яратсын.
Синең белән рәхәт, көләч син,
Көләчләргә бүләк өләш син!
Яңа елда балкы, Кояш бул,
Кояш төсле якты, гел яшь бул!

*1988.*

## Алтын арба

Язон белән сәйях булып китәм
Диңгезләргә, ерак илләргә,
Җилкәннәрне киереп, шаулап үтәм,
Күкрәк ачып көчле җилләргә.

Орфей төсле җырлап көндез-кичен,
Чиртәм изге лира кылларын:
Кешеләрне көләч итәр өчен
Багышлана минем җырларым!

Гераклны алам иптәш итеп,—
Аусын өчен юлда киртәләр,
Күңелләрдә кара төннәр бетеп,
Балкысын дип якты иртәләр.

Изге йөкләр төяп үтәр өчен,
Ярый әле, шөкер аллага,
Шигъри толпарымның сизәм көчен,—
Һәр көн җигәм алтын арбама!

*1988.*

## Үзем генә утырып уйланганда

Барган чакта Буа кырларыннан
Бер-бер артлы үсә калкулык:
— Элек монда баһадирлар булган!—
Ди карт миңа, юкны бар кылып.

Гильгамешлар[1], имеш, илләр кичеп,
Алпамышка[2] килгән юлларда
Башмакларын каккан, диләр, чишеп,
Шуннан калган, ди, бу курганнар...

Шулаймы ул, юкмы? Ачык итеп
Кем әйтала җиһан тарихын?
Алай да мин, гасырларны үтеп,
Узганнарга килә карыйсым.

Гаҗәпмени әгәр таулар ашса,
Үз илләрен ташлап, төркиләр?
Океан кичеп Америка ачса,
Дәүләтләшсә Майя, Инкиләр?

Борынгыдан төрки «Гильгамеш»лар
Мирас булып Бабиль, Айсурга[3]
Килгән икән диләр. Ә язмышлар
Уйнамаган дисең кай чорда?!

Сәер хисләр! Күңел уйга талган,
Мин борынгы гүя үзем дә...
Күр, Буада күпме курган калган
Бабайларның серле эзендә!..

*1988.*

---

[1] Гильгамеш — Ассирия патшасы Ашшурбанипал китапханәсендә табылган борынгы поэма каһарманы. Аны төрки әсәр дип уйлыйлар.
[2] Алпамыш — төрки-татар әкиятләре батыры.
[3] Бабиль, Айсур — Вавилон, Ассирия.

## Бер маньяк янында

*...Вагондагы 76 тоткыннан, аз дигәндә, 20 се: «Бу хаксызлыкларны Сталин белми», дип шау-шу куптара иде.*

*Е. Гинзбург, «Текә маршрут».*

Китми, диләр, эт күнексә бәйгә,
Чылбырыннан азат итсәң дә,—
Тугры кала икән кайбер бәндә
«Хуҗасына», Себер китсә дә...

Әнә утыра, елын тутырып кайткан,
Төрмәләрдә ниләр күрмәгән!..
Төн илендә ул боз булып каткан,
Ач-ялангач йөргән, үлмәгән.

Диварында тиран рәсеме тора,
Трубкасын капкан, елмайган.
Өй хуҗасы авыр сулап кына:
«Истәлек, ди, узган еллардан...»

Фанатик шул наркоманга охшаш,
Манкорт бүреген басып кигән дә,
Ачулана культны иткәнгә фаш,—
Палачына үзенең тигәнгә.

Әйе, АНЫҢ белән бронь кидек,
Уңышларга ирешеп узышта.
Көрәшләрдә АНЫҢ белән идек,
Җиңеп чыктык Бөек сугышта...

Ләкин болар корбан миллионнарның
Аклыймы соң кара язмышын,
Юып ташлыймы соң кайнар канын,
Каплыймы соң Ватан каргышын?!

Хикмәт белән җүләрлеккә, диләр,
Тик бер генә адым ара бар;
Шул адымнан тапталмады кемнәр:
Төзәлмәслек булды яралар!..

Китмәгәндәй бәйгә күнеккән эт
Бушатсаң да муен чылбырын.
Син утырасың, мескен, белгән кебек
Язмыш серен, тарих чынлыгын.

*1989.*

## Аера күрмә

Язмыш! Игелек күрсәтмәдең бер дә...
Ярый әле бәндәң күнеккән:
Бәхетсез дә яшәп була җирдә,
Тик аера күрмә өметтән.

*1988.*

## Урам-бакчада

Түш тибрәтеп яшь хатыннар уза,
Үкчәләре шакый асфальтны:
Картлыгымнан тузан гына туза,—
Кара инде күңел-алчакны!

Кыен түгел чәнчеп телгә алу,
Гаепләве минем ишене.
Тик гаепнең зуры — «Аяк чалу»,
Яки «тәнре ясау» кешене.

Андый эштән, шөкер, ерак йөрдем,
Уйлап утырам урам-бакчада:
Ни әйтсәң дә, үтте минем гомерем
Ихлас биреп аннан башкага.

Кызлар уза, бөдрәләрен җилпеп,
Үкчәләре җанга без генә...
Шулар инде, җирне Җәннәт итеп,
Өмет белән имли безне дә.

*1989.*

# Эч пошканда

Сәфәр чыгар идем — тәнем таштай авыр,
Ат иярләп менәр идем — атым явыр...[1]
Үтте гомер... Ирештемме максатыма?—
Сулкылдап йөрәгемдә сызлый тамыр.

Дусларның үлмәгәннән үлгәне күп,
Борчуларны күрмәгәннән күргәнем күп,
Әбелхәят суы алдым дип алдандым:
Савытыңа тулган үзән суларын түк...

Берәүләр алып торды гел мазаны,—
Мин яшәдем булыр әле дип азагы:
Бирделәр хәятымнан өлеш итеп,
Өмет белән яшәгәнгә бу җәзаны.

Алтмыш елым үткән икән арман[2] белән,
Калдым иске туарылган арбам белән...
Монда, язмыш, салган идең җәһәннәмгә,
Анда да җәннәтеңә бармам, беләм!..

Зарлана икән бу дип уйламагыз,
Шулай да язмыш белән уйнамагыз,—
Күргәнне әйтеп булмый күрмәдем дип...
Газап чиксәк, соңгармадык туйга да без!

*1988.*

[1] Авыр — аркасынияр суккан ат.
[2] Арман — өметкә ирешә алмау.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Атилла Расих**

# ИШАН ОНЫГЫ

РОМАН-ИСТӘЛЕК

*(«Елларны чигерсәм» исемле әсәрнең беренче китабы)*

1



Термез шәһәреннән Казанга 1934 елның июль аенда, юкә чәчәк аткан чакта кайтып төштем. Казан ифрат сагындырган. Мондагы һәрбер нәрсә — ишегалдындагы агачлар да, чарлактагы бәләкәй бүлмәбез дә, каршыдагы базар кибетләре дә (әнием турында әйткән дә юк инде) — барысы-барысы үзләренең күренешләре белән үк миңа ял рәхәте бирәләр. Теләгем — хәзер инде укырга керү. Ярар, бераз дөнья күрдем, читят җирләрдә «лаеш шулпасы» эчеп бактым. Хәзер күптәнге теләгемне тормышка ашыру эшенә керешергә вакыттыр. Укырга, укырга, укырга!

Минем әле генә ачылган авиация институтына керергә теләгем зур. Гомумән, мәктәп елларында, төгәл фәннәрне якын иттем һәм ул өлкәдә үземне сәләтле бер кеше дип саный идем. Инде Казанда авиация институты ачылгач, минем иң изге теләгем шул институтка укырга керү булды. Нигә бәхетемне сынап карамаска!? Минем урта белемем бар ич.

Казанга исән-сау әйләнеп кайтуыма чиксез шатланган әниемнең хуплавы белән канатланып, тиз арада кирәкле документларны барлыйм, анкета тутырам һәм, кайтуыма атна-ун көн дә узмый, үзем керергә җыенган институтка йөгерәм.

Институтка нинди хыяллар белән ашкынып баруымны, тетрәнеп аның авыр ишеген ачуымны, калтыранган кул белән папкадан документлар чыгаруымны, аларны кабул итү комиссиясе секретарена тапшыруымны ничек тә төгәл, җанлы һәм ышанырлык итеп язып булмас кебек. Мин артык дулкынланам. Алырлармы, студент дигән гүзәл исемне йөртүче булырмынмы тиздән?

Әмма миңа уку йортына керү насыйп түгел икән. Чөнки бу өметләр, секретарь өстәле янында ук сүнеп, һавага очты. Кабул итү комиссиясенең кырыс карашлы, өстенә юнг-штурм костюмы кигән секретаре, анкетамны карап чыкты да, бик гади генә итеп:

— Без мондый кешеләрне алмыйбыз,— диде.

---

Атилла РАСИХ *(1915) — язучы, галим, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» һәм башка роман, повестьлар авторы. Казанда яши.*

Журнал варианты.

— Ни өчен?— дидем мин, тәмам аяктан кала язып.
— Чыгыш бит сезнең... үзегез беләсез.— диде ул, бер ягы белән генә елмаеп.
Мин тәмам коелып төштем. Документларымны папкага ничек салганымны да тоймастан, йөгерә-атлый бүлмәдән чыгып киттем. Юк, булмады! Миңа институтларда укырга язмаган икән. Янадан эшкә керергә туры килер. Урта Азиягә киткәнче токарь булып Вахитов исемендәге сабын кайнату заводында эшли идем. Без яшәгән Арча кырыннан ул заводка эшкә йөрүләре шактый авыр, ара ерак, трамвайлар бик начар йөри. Мин шул хәлләрне искә алам. Шуңа күрә үзебезгә якынрак булган трамвай паркына урнашырга кирәк, дигән фикергә киләм.
Мин трампаркка кереп эшли башладым. Тик шулай да күңел тыныч түгел. Укыйсы килә. Ни өчен соң әле минем укырга хакым юк? Ни өчен, ни өчен? Әллә башкалардан кимме мин? Шулай гомере буе этисе өчен җәзаланырга тиеш микәнни аның улы?
Җитмәсә, трампаркта эшем дә бик көйсез бара. Станокның иң начары янына бастырдылар. Эш кораллары да... ташка үлчим.
Әмма шулай да көннәр бер-бер артлы уза тора. Һәм шул көннәрнең берсендә, һич уйламаганда-көтмәгәндә, минем сүнгән өмет йолдызым кабат җемелдәп яктыра башлады.
Шулай, эшкә керешүемә атна-ун көн үтмәгәндер, көндезге ашка дип өйгә кайтсам, ни күрим, тимер караватымда бер егет йоклап ята. Димәк, безгә ниндидер бик якын кеше килгән. Ул бик алҗыган булган, йокысызлыктан интеккән, ахры. Чөнки көпә-көндез нинди йоклау инде ул? Әнием исә, ничектер серле итеп елмаеп, миннән сорый:
— Йә, кем бу, таныйсыңмы?
Аптырап, иңбашларымны гына җыерам. Егет уянып миңа кулын сузгач кына, аның кем икәнлеге беленә: бу — миңа күптәннән таныш Шәүкәт Корбангалиев икән. Шәүкәт — Троицк егете, бергә уйнап үскән малай, дигәндәй, этиләр үзара аралашкан, йөрешкән, укытучы Вәли абзый улы. Без күрешмичә яшәгән елларда ул үскән, җитлеккән, авыл хуҗалыгы техникумын тәмамларга өлгергән, бер совхозда ике ел агроном булып эшләгән, хәзер исә Казанга авыл хуҗалыгы институтына укырга килгән.
Безнең җитди сөйләшү, көн тәмамлангач, кичкырын башланды. Ул мин юкта әнием белән барысы турында да сөйләшкән, минем хәл-әхвәлләрнең торышын белә икән. Шәүкәт сүзне миңа укырга кирәклеген, хәзер минем нәкъ укый торган вакытым икәнлеген аңлатудан башлады.
— Беләм,— дидем.— Әгәр мине укырга алмыйлар икән, нишләмәк кирәк? Әтинең алты ел Троицкида мулла булып торуы аркасында мине сыйнфый дошман дип саныйлар икән, мин нишли алам?
Шәүкәткә, түкми-чәчми, барын да сөйлим. Шәүкәт минем аһзарымны тыныч кына тыңлап торды. Шуннан соң әйтте:
— Беләсеңме нәрсә, Атилла,— диде (миңа өйдә дә, Троицк кешеләре дә шулай, исемемнең азагындагы «а»ны нечкәртеп «ә»гә охшатып дәшәләр иде).— Бер дә ут йотма. Документларыңны әзерлә, аларны институтка үзем илтеп бирәм. Без синең белән икебез дә авыл хуҗалыгы институтына керәбез. Честный слова, алмый калмаслар...
— Ә минем чыгыш мәсьәләсе?— дидем мин.
— Син аны яшер, әйтмә. Анкетага хезмәткәр баласы, дип куй. Әллә кайдагы Троицк кешеләрен кем белсен!
Нинди генә юллар белән булса да институтка эләгү минем өчен бик мавыктыргыч теләк иде. Ләкин шулай да алдашу дигән нәрсәгә җинаять эшләү дип карыйм. Мин:

— Бәлки шулай кирәктер дә, тик элек укыганнар онытылган инде,— дигән булдым.— Кайчаннан бирле инде кулга дәреслек алган юк. Барыбер имтихан бирә алмам дип уйлыйм.

— Бирәсең, диде Шәүкәт зур ышаныч белән.— Тик документларыңны иртәгә үк институтка тапшырырга кирәк. Чөнки анда абитуриентлар өчен әзерлек курслары ачылган. Алар укый башлаганнар инде. Шунда керәбез. Белдеңме?

— Белмим инде, нишләргә дә белмим,— дидем икеләнеп. Минем нинди дә булса берәр техник вузга керәсем килә иде. ФЗУда уку һәм заводта токарь булып эшләү чорында мин инде техникага тәмам гашыйк кеше хәленә күтәрелгән идем. Өстәвенә, уйлап табучылык белән дә «җенләнүем» машиналарга, механизмнарга булган мәхәббәтемне көчәйтте генә.

Уйга калдым. Ләкин бит мине берәү дә техник вузга чакырып тормый. Ә монда, Шәүкәтнең әйтүенә караганда, авыл хуҗалыгы институтына эләгүем бик мөмкин. Бу турыда әни белән дә киңәштем. Ахыр чиктә минем төп максатым югары белем алу түгелмени? Авыл хуҗалыгы белгече булу ни дә, төгәл фәннәр буенча белгеч булу ни?! Иң мөһиме — белем алу ич!

Шулай итеп, мин йомшадым. Карышып торуны кирәк санамадым. Әгәр сәләтле кеше икәнмен, теләсә кайда да сынатмам, ә инде һөнәремә мәхәббәт дигән нәрсә дә өстәлсә, эшләр мантымый калмас. Шулай фикер йөрттем дә, Шәүкәтнең киңәшен дөрес табып, документларымны яңадан барлап чыктым. Яңабаштан анкета тутырдым, өр-яңа үтенеч яздым.

Кешегә сылтап гөнаһлы буласым килми, төп гаеп үземдә. Социаль чыгышымны анкетада яшердем мин. Авыз бер тапкыр пеште бит инде, җитәр, дип акландым.

Һәм бу эшемнең җәзасын тугыз ай институтта укыганнан соң татыдым...

Мин чиксез бәхетле идем. Иң олы максатыма ирештем. Хәзер барлык көчемә яшьлек дәртемне кушып, ашкынуларымны өстәп, укырга да укырга тиешмен, дип юана идем. Тик, кызганычка каршы, минем өчен бу бәхетле көннәр санаулы булган икән.

Шатлыклы, чәчкәле Май бәйрәменнән соң бер атна узмагандыр, мине дәрес вакытында институт директорына чакырдылар. Күңелем нидер сизенеп, шунда ук йөрәгем дерт итеп куйды. Бу чакырылу, һәрхәлдә, хәерлегә түгел иде. Күрәсең, Киров үтерелгәннән соң илдәге авыр атмосфера, партия җитәкчелегенең «Террорга террор белән җавап бирербез!» дигән сүзе күңелләргә шом салган, ниндидер авыр тетрәнүләр вәгъдә иткән...

Институт директоры булып ул вакытта Соловьев фамилияле керәшен татары эшли иде. Урта буйлы, чибәр генә, түгәрәк кысалы күзлек киеп йөри торган, урта яшьләрдәге бер кеше иде ул. Әле күптән түгел генә Май бәйрәме мөнәсәбәте белән студентлар сафы алдында безгә нотык сөйләде. Өстендә кара пальто, башында кепка, кулында трость. Ул, ялтыр резин галошларына туфрак чәчрәтеп, таяк очы белән җиргә бәрә-бәрә сөйли.

— Әгәр сугыш башланса,— ди ул,— без барыбыз да иптәш Ворошилов яклы булырбыз!

Әнә ул, мине чакырткан кеше, хәзер кәгазьләр актарып, үзенең яландай зур яшел постау ябылган өстәле артында утыра. Озакламый ул миңа үзенең үтергеч сүзен әйтәчәк.

— Мондарак кил,— диде ул, мине сискәндереп. Аның күзләрендә нәфрәттән башка берни дә юк кебек иде. Мин аңа таба атлыйм. Хәзер инде күңел түремдә тычкан уты кадәр генә дә өмет яктысы калмаган. Чөнки күз кырыем белән Соловьев алдында яткан анкетамны шәйлим.

— Әйт әле, синең әтиең кем булган?— диде ул шул ук кырыслык белән.

— Укытучы,— дим мин, чөнки чыннан да, минем әти гомеренең күбрәк өлешен укытучылыкта уздырган.

Директор авыз чите белән генә мәсхәрәле елмаеп куйды. Миңа бик ачык сизелә: ул җиңү тантанасы кичерә.

— Ә егерме икенче елдан егерме сигезенче елга кадәр?

— Мулла,— дип куйдым мин шыпырт кына.

— Ә нигә анкетаңа хезмәткәр дип яздың?

— Дөресен язсам, институтка алмассыз дип курыктым.

Директор минем язмышымны бик тиз хәл итте:

— Совет хөкүмәтен алдаганың өчен сине институттан сөрәчәкбез. Сиңа тотылган расходларны кайтарып алу өчен, судка бирәчәкбез.

Шуның белән безнең аңлашу тәмам булды, башны аска иеп, кабинеттан чыгып киттем. Барысы да берничә минут эчендә җимерелеп төште. Барлык ашкынулар, татлы хыяллар, гүзәл планнар...

Кечкенәдән үк укырга, укырга кирәк, дигән тәрбия алган идем шул. Әти дә, әни дә минем, укып, илгә бик файдалы, зур кеше булуымны телиләр иде. Инде миңа юллар ябык, ябык, ябык! Нишләргә соң миңа? Башымда чиксез зур кайгы булып оеган кан, шаулап, чыжылдап, бөтен миләремне пешереп, каядыр өскә үрләде.

Институтның якты, иркен коридорына чыктым да, кая барырга, инде нишләргә белмәүдән аптырап, капкадай зур, якты тәрәзә төбенә килеп сөялдем. Юк, миңа урамдагы хәрәкәт күренми, минем колакларыма тирә-юньдәге шат кешеләрнең көлешү-сөйләшүләре ишетелми. Минем бөтен барлыгымны хәсрәт сөреме баскан.

Шулай да таркалган зиһенемне бераздан җыя алдым булса кирәк. Һәрхәлдә, үземә бер таяныч табарлык хәлгә килдем. Институттан куылсам да, югары мәктәптә уку насыйп булмаса да мин бит әле исән, мине бит әле үтермәделәр. Мин бит әле яшим, мин бит әле яңадан станок янына баса алам, рәхәтләнеп эшли алам.

Шулай уйлап, күңелемнән барысына кул селтәдем дә, коридор буйлап алга таба киттем.

Белдерүләр тактасы янында ике студент нидер укып тора. Алар миңа борылып карангалыйлар. Күзләрендә исә аптырау, шом. Узышлый, күзгә әле генә эленгән приказ чалына. Анда минем турыда, явыз ният белән чыгышымны яшергән өчен институттан куылуым, судка биреләчәгем турында язылган. Мин хәзер үк, хәзер үк, өч-дүрт баскычны бер атлап, аска, урам ишегенә таба төшеп китәргә риза... Тик иптәшләрем утырган ботаника кафедрасына керми булмый. Минем анда портфелем калды. Аны миңа, институтка керү имтиханын уңышлы бирүем белән котлап, барлы-юклы акчасына әнием сатып алган иде. Ул — минем өчен бик кадерле бүләк. Әле генә үзем гербарийлар карап утырган аудиториягә керәм. Анда, өстәлләр тирәсендә, студентлар кайнаша. Мин килеп керү белән аудиториядә авыр, котсыз тынлык урнашты. Иптәшләрем, эшләрен ташлап, кайсы аптырау, кайсы кызгану аша миңа текәлгәннәр. Алар минем һәр хәрәкәтемне бизмәнгә салып үлчиләр кебек. Тиз генә өстәл тартмасыннан портфелемне алам да коридорга ташланам. Сизәм, кемдер артымнан килә. Быков Гога икән. Дус егет. Ул тирә-юнендә карана, кеше юклыгыннан файдаланып, миңа якынлаша:

— Атилла, мин бу хәлгә бик хафада...

Ул ашыгып читкә китте. Яныма, шундый ук саклык белән, икенче дустым Газиз Нуриев килеп җитә. Ул — Минзәлә егете. Беренче айларда, әле укуда шактый аксаганда, ярдәмен күп күрдем аның.

— Агайне, Атилла,— ди ул.— Мин... просто ни әйтергә дә белмим инде...

Ул, әйтер сүз таба алмаудан гаҗиз булып, тукталып тора, аның каратутлы матур йөзе кызарган, күзләрендә яшь элпәсе.

Мин, институт белән мәңгегә саубуллашып, урамга чыгам. Һава искиткеч матур, көн аяз, институт бинасына каршы бакчада кошлар чыр-чуы. Ләкин боларның берсе дә миңа куаныч, өмет бирми.

Ул көнне, мин институттан куылып кайтып кергәндә, әни өйдә иде. Дәфтәр тикшереп утыра. Ул — укытучы. 18 нче татар мәктәбендә башлангыч класс балаларын укыта. Үзе дә, читтән торып, педагогия институтында укый. Күрәсең, минем хәсрәтем йөземә бәреп чыккан булгандыр, әнием, шундук эшеннән аерылып, сорау белән миңа текәлде. Минем исә аны әз генә дә борчыйсым килми иде. Әмма булдыра алмадым. Портфелемне өстәлгә ташладым да караватыма йөзтүбән сузылып яттым. «Мине институттан куып чыгардылар»,— дидем. Бер мизгел тынлык булып торды. Әнием үзенең көчләрен туплады булса кирәк, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән: «Кайгырма, улым, бирешмә, балакаем»,— диде.

Кадерлем, бәгырем минем, бердәнберем, газиз әнием! Синең чандыр, юка гәүдәңә табигать ничек шундый зур көчләр сыйдырган? Бу минутта, бәлки, башка ана булса, еларга яки мескенләнергә керешер иде. Ләкин минем әни андыйлардан түгел. Ул — көчле, тормыш чыбыркылауларына каршы тора алган, буранга каршы барудан курыкмый торган кеше.

Әни әле моннан ике ел гына элек, Шәле дигән сәер исемле татар авылыннан кайтып, Яңа бистәдәге татар мәктәбенә урнашты. Ул чакта Шәле Татарстандагы иң караңгы авылларның берсе иде дисәм дә, шәт, ялгышмам. Аның халкы ифрат усал. Ирләре генә түгел, анда хатын-кызлар да оятсыз сүзләр кыстырып сөйләшә. Кеше үтереш, суеш анда еш кабатлана торган бер хәл. Әни шундый авылда укытты. Алай гына да түгел, ул анда шул шомлы авыр көннәрдә колхоз төзү эшендә, тырышып, актив катнашып йөрде. Шундый авыр хезмәттә дә ул мине бер генә минутка да онытмады, авызыннан өзеп, миңа даими рәвештә акча җибәрде, әз генә мөмкинлек чыкса да, шәфкатьле ярдәм кулын сузу өчен, мине күреп, өс-башымны карау өчен, Казанга кайтып китә торган булды.

Инде Шәледән Казанга бөтенләйгә кайткач, ул бер генә көнен дә әрәм итмәскә тырышып, укуын дәвам иттерде.

Тормыш ифрат авыр. Үзенең «гөнаһларын» яшереп, ерак Кыргызстан таулары арасындагы бер колхозда хисапчы булып эшләп яткан әтидән бернинди дә ярдәм юк, әниемнең эш хакы бик аз. Икмәк карточка белән генә бирелә. Ашаган төп ризык — бәрәңге. Аны үсемлек маенда кыздырып ашыйбыз, ит исә — артык тансык ризык, әллә нигә бер эләгә.

Әйе, без фәкыйрь яшәдек. Әни, авылга эшкә китү белән, миңа кул сәгате алып бирү өчен тырышты. Аны кибеткә авыл хуҗалыгы продукты тапшырган кешеләргә бирелә торган талонга гына саталар иде. Әни шул талоннар сатып алу эшенә дә керешеп карады. Мәгәр теләгенә һич ирешә алмады.

Без Вахитов заводы янында бер фатирда яшәгәндә әниемнең аягына брезент итек киеп кыш уздырганын яхшы хәтерлим. Аның, кышкы суыкларда мәктәбеннән кайткач, сызланып, тезләрен уып, мич авызы каршында утырган чакларын онытасым юк. Бу итекне безгә Урта Азиядән кунакка кайткан, әнинең олы абыйсы Шакир абый бүләк иткән иде.

Кыскасы, безнең эшләр «байларски» ук булмады. Ләкин, шуңа да карамастан, без әниле-уллы үзебезне моңарчы бик бәхетле сизеп яши идек. Нигә дип без бәхетсез булыйк: тормыш — илдәгечә, без һаман үсәбез, укыйбыз, куйган максатка таба тауга үрмәлибез!

Тик бу бәхет бүген, югарыда әйтелгәнчә, боздан ясалган бина-

дай чытырдап җимерелде. Хәзер инде эшкә урнашу турында баш ватарга кирәк иде.

Мин үземә кулай эш эзләргә керештем. Универсаль токарьлар һәр җирдә кирәк, һәр җирдә белдерү очратырга була. Ләкин күңелгә ятышлы урынны табуы читен. Мин Казан заводларын айкыйм. СК-4 заводы артык ерак, трамвайлар һаман начар йөри. Вахитов заводында эшләгәндә дә житәрлек газап кичерде кеше. Аерата икенче сменада эшләгәндә өйгә кайтулары авыр. Онытылмый, көне буе аягүрә торып аяклар тала, Шамов больницасы тавыннан менгәндә алар бүрәнәдәй авыраялар. Шул кадәр ничек йөрмәк кирәк? СК-4 чуттан сызып ташлана. Инде трампарк. Ул безгә бик якын, тик андагы станоклар әйткәнемчә, ватык арбадай, эш кораллары ярым хөрти. Мин, йөри торгач, Державин бакчасы каршында Агамали углы исемендәге язу машиналары заводын сайладым. Ләкин миңа анда да озак эшләргә туры килмәде. Уенчыктай кеп-кечкенә револьвер станоклар минем өчен бөтенләй кулай түгел. Зур станокларда иркенләп эшләргә өйрәнгән кеше өчен бу авыр гына түгел, хәтта газаплы да икән. Мин тагын эшсез. Төшенке күңел белән йөрим. Җитмәсә, эш эзләп йөргән көннәрдә әниемне дә институттан чыгардылар. Без хәзер, аңа эшләгән җиреннән дә ул-бу булмагае дип, тагын куркуда яшибез.

Менә шундый авыр, борчулы көннәрдә урамда, очраклы рәвештә, Фәйзи Гыйззәтуллин дигән егеткә юлыктым. Һәм бу очрашу минем барлык планнарымны кинәт үзгәртеп җибәрде. Шуның аркасында мин, хәзергә эшкә урнашмаска, тагы бер тапкыр бәхет сынап карарга булдым.

## 2

Фәйзи Гыйззәтуллинны мин бик күптәннән белә идем. Әле егерме алтынчы елларда ук, мин Троицк шәһәрендә яшәгәндә, аны күргәли идем. Ничек, нинди шартларда танышканымны хәтерләмим. Ләкин төптән юан, сары чәчле, сипкелле йөзле, татардан бигрәк рус кешесенә охшаган, миннән дүрт-биш яшькә олырак бу үсмернең күпер башы Сабир абзыйларда яшәвен, дөм ятим икәнлеген белә идем.

Катлаулы, сикәлтәле еллар башланып, без Казанга күчеп килгәч, ФЗУда укыганда, аны тагы очраттым. Ул Вахитов исемендәге сабын заводының кайсыдыр цехында эшли һәм завод каршындагы ВТУЗда укый, имеш.

Фәйзи матур әдәбият белән дә кызыксына икән. Аның шигырьләр язгалавы, завод газетасы оештырган әдәбият түгәрәгенә йөрүе безнең араны тиз якынлаштырды. Дөресен әйткәндә, мин аның шигырьләрен бигүк өнәми идем. Ләкин күп тиражлы газета редакторы, ул вакытларда «Гудок», «Сөрем» дигән пьесалары белән танылган драматург Хан Җәмил һәм безнең түгәрәккә Язучылар союзы тарафыннан шеф буларак беркетелгән Абдулла Алиш Фәйзигә һәм аның иҗатына зур хөрмәт күрсәтәләр, аның шигырьләрендә мин күрмәгән нииндидер әйбәт үзенчәлекләр, тирән фикерләр табалар. Ә Фәйзи исә, якташ буларак, мине якын итә.

Эш эзләп йөргән көннәрнең берсендә мин моны Казанның үзәгендә, трамвай көткәндә очраттым. Сүз хәл-әхвәлләргә кагылгач, аңа үземнең кайгыны әйтми кала алмадым, югары уку йортына керүдән өмет өзелүен, яңадан заводка кайтырга туры киләчәген сөйләдем.

Фәйзинең бу минутта соры күзләрендә бераз аптырау, хәтта көлемсерәү билгеләре дә күрдем мин. Кинәт:

— Тиз бирешкәнсең син, Атилла!— диде ул.

— Нишлисең, башыңа төшкәч! Башка бернинди дә чара эзләп таба алмадым инде...

— Мин дә нәкъ синең хәлгә калган кеше идем,— диде ул.— Тик синең кебек кауш:ап калмадым. И җиңеп чыктым. Үземнең укырга хаклы кеше икәнлегемне исбат иттем.

Ул миңа башыннан кичкәннәрне сөйләп бирде. Минем өчен исә Фәйзинең әйткәннәре һич көтелмәгән бер яңалык булды. Ятимлектә үскән, ерак кардәшендә йомышчы малай сыйфатында диярлек тәрбияләнгән, хәзер исә заводта алдынгы эшчеләрдән саналган кешенең, җитмәсә әле, эшеннән аерылмыйча, югары мәктәптә укучының минем хәлгә калуы үзе үк башка сыймаслык бер нәрсә.

Аның этисе, сәнәкчеләр фетнәсендә катнашып, заманында совет органнары тарафыннан хөкем ителеп, атылган кеше булган икән[1]. Бу вакыйгадан соң, анасы ишле балаларын төрле якларда яшәгән туган-тумачаларына асрамага таратырга мәҗбүр булган. Фәйзинең Троицкига барып чыгуының сәбәбе шуннан икән.

Фәйзи дә ВТУЗга кергәндә минем кебек үк үзенең алама чыгышын яшергән һәм, фаш ителгәч, уку йортыннан сөрелгән.

— Тик мин синең кебек кул селтәмәдем. Миңа диплом яклап инженер исемен алырга нибарысы алты ай вакыт калган иде,— диде ул.— Нишләп әле мин үз мәнфәгатем өчен көрәшмәскә тиеш? Менә шулай, Атилла, син дә тик ятма.

— Нишлим икән соң?

— Мин, мәсәлән, туп-туры Мәскәүгә, Совконтрольгә киттем. Мария Ильинична Ульянованың үзе янына кердем. Барын да яшермичә сөйләдем. Ленинның сеңлесе гозеремне аңлады, мине ВТУЗга восстановить итеп кайтарды. Менә син дә тот та туп-туры Мәскәүгә бар. Бирешмә.

Фәйзинең бу сүзләре минем күңелне күтәреп җибәрде. Чыннан да! Хаклыдыр ул! Барысы да югалып бетмәгәндер әле.

Өйгә кайту белән, бу яңалыкны әнигә сөйләдем. Минем бу теләкләрем аркасында туган мәсьәләләрне хәл итү һәм, гомумән, бу эшне ничегрәк оештырганда яхшырак буласын мәслихәтләшү өчен шул ук көнне бездән ике чат кына арырак, Достоевский урамында яшәгән Габдрахман абыйларга киттек. Габдрахман абый исә Наркомпроста эшли, ул — әниемнең кече абыйсы.

Сөйләшү нәтиҗәсендә шундый фикергә килендe. Мин Мәскәүдә безнең бик якын танышыбыз, заманында Троицкида яшәгән, хәзер башкаладагы татар мәктәбендә укытучы Мәрьям Черкасова апага барып төшәм. Инде алар өйдә юк икән, безнең Мәскәүдә Нәфисә Юманкулова да бар бит әле. Ул әтинең бер туган сеңлесе Гайшә апаның, үги булса да, кызы. Һәрхәлдә, мине үзенең фатирына кертми калмас.

Ә акча мәсьәләсендә болай хәл кылынды. Хәзер Татарстан районнарында Наркомпрос үзенә буйсынган оешмаларда җиһаз исәп-хисабы уздыра. Түләүле эш. Габдрахман абый минем өчен шул эшкә алыначак, ә гамәлдә эшне, районга китеп, мин башкарачакмын. Ниһаять, бу эш тә башкарылды. Акча булды.

Юлга җыена башладым. Сәяхәтемнең бик җитди икәнлеген яхшы аңлыйм. Иң мөһиме — Мәскәүгә кирәкле документлар алып бару. Минем язмышымны җиңеләйтә алырлык бер генә рәсми кәгазь дә онытылып калырга тиеш түгел. Анда баргач, хатлар язып, Казаннан документ соратып йөрерлек булмасын.

[1] Соңыннан миңа шагыйрь Сибгат Хәким Фәйзинең Күлле Киме кешесе икәнлеген әйтте. (Автор)

Әшне әтиемнең 30 нчы ел башында «Фән һәм дин» журналында басылып чыккан «Соңга калган бер тавыш» исемле мәкаләсен портфелемә салып куюдан башладым. Анда әтинең муллалыгын ташлавы һәм моның сәбәпләре турында ачык язылган. Аннан соң мин әниемнең әти белән аерылышуы турында загс таныклыгының күчермәсен алдым. Әлбәттә, бу аерылышу фактик гамәл түгел иде. Ничарадан бичара дигәндәй, әниемә эшкә урнашу мөмкинлеге булсын өчен эшләгән бер эш иде. Үземнең моңарчы заводта токарь булып эшләгәнлегемә, рационализатор, ударник булганлыгыма белешмәләр дә алдым. Завод каршындагы әдәбият түгәрәгендә актив катнашуымны, «Вахитовчы» газетасында еш кына басылуымны, хәтта соңрак повесть язып, шул повестьтан бер өзекнең газетада басылып чыгуын онытмадым. Газетаның ул санын әйбәтләп портфелемә салып куйдым. «Чаян»да беренче тапкыр А. Расих псевдонимы белән бирелгән хикәямне дә кыстырдым. Шулай документлар җыеп юлга әзерләнгән көннәрдә, һич көтмәгәндә, хәбәрсез-нисез, Үзгәннән әти кайтып төште. Әйе, әти. Минем Троицкида чакта ук татар мәктәбенең алтынчы классыннан сөрелүем, инде институтка кергәндә анкетаны алдап тутырырга мәҗбүр булуым һәм, соңыннан, фаш ителеп, укудан куылуым — аның аркасында. Ләкин мин моның өчен этиемә әз генә дә кинә сакламадым. Моны үземнең шәхси бәхетсезлегем дип карадым. Әтиемнең холкы үтә йомшак, ул — тормышка җитәрлек әзерлек белән кермәгән һәм, шуның аркасында, бер хата артыннан икенчесен ясаган, хаталары өчен тормыш тарафыннан рәхимсез рәвештә кыйналган бер кеше. Ләкин шул ук вакытта ифрат шәфкатьле, тәрбияле, мөлаем. Мин, вакыты-вакыты белән аның булдыксызлыгына, әледән-әле кирәксез эшләр эшләп ташлавына әниемә ияреп рәнҗесәм дә, аны кызгана, хәтта ярата идем. Өстәп тагы шуны әйтергә кирәк, әти сәнгатьне бик ярата. Хәер, ул бу өлкәдә дә эзлекле кеше түгел иде. Хәтеремдә, ул бер пьеса язарга кереште. Гаҗәп мавыктыргыч булырга тиеш иде ул әсәр. Мәгәр әти ул хезмәтен очлап чыга алмады, тиздән суынды, ташлады. Шулай ук, гомере буена дигәндәй, русчадан «Стакан воды» дигән гыйльми бер әсәр тәрҗемә итеп утырды. Ләкин анысын да тәгәлләмәде. Бер сүз белән әйткәндә, ул — гамәл кешесе булудан бигрәк, хис кешесе иде.

Шулай итеп, әти безнең янга бөтенләйгә кайтты. Гаиләбез шактый күңелсез көннәрдә түгәрәкләнде. Әтинең тышкы кыяфәте безнең өчен бик сәер тоелды. Ул, кыргыз арасында яшәп, тәмам шундагы халык вәкиленә әйләнгән диярсең. Үзе белән йөнтәч кырпулы бүрек, салпыраеп торган, ялангай зур, буяу тимәгән тире тун алып кайткан, сакал-мыегы үскән, үзе бөтенләй ябыгып беткән. Үзгәреш тышкы кыяфәтендә генә дә түгел, ул кыргызлардан кайбер сәер гадәтләр дә иярткән. Мәсәлән, без аның беренче көнне үк чәй чүбен җилкә аша гына идәнгә ташлавына игътибар иттек. Әти үзе дә, ялгышын сизеп, уңайсызланып көлеп җибәрде.

Әйе, аның бөтенләйгә Казанга, безнең янга кайтуы иде бу. Сагынудан тәмам тәкатьсез калгач, эшеннән чыгып, Казанда да миңа бер урын табылыр әле дип өметләнеп, юлга чыккан.

Әтинең өйгә кайтуы минем өчен күңелле бер вакыйга булса да, ул миңа ни киңәш-табыш җәһәтеннән, ни матди яктан ярдәм күрсәтә алмады. Габдрахман абый миңа киңәшләр бирүче булды. Беренче киңәше аның шул иде: эшне инстанция буенча алып барырга кирәк. «Башта Наркомзем каршындагы вузлар идарәсенә кер,— диде ул,— үтенечеңне шунда бир. Инде алар уңай җавап бирмәсәләр, Совконтрольгә, Мария Ильинична Ульяновага керерсең».

Ниһаять, барлык әзерлек тәгәлләнде. Барып төшәргә адреслар бар, документлар тәртиптә, чалбар эчендә әни тегеп биргән бәләкәй

кесәгә акча салынган. Июль башы иде. Мин, гомеремдә беренче тапкыр үземә җитди вазифалар йөкләп, бетмәс-төкәнмәс өмет һәм ышаныч белән, Мәскәүгә чыгып киттем.

## 3

Менә ул башкала! Казан вокзалыннан киң мәйданга чыккач, Мәскәү урамындагы ыгы-зыгылы хәрәкәткә, һушыңны алырлык гүзәл, мәһабәт биналарга хәйран калып, тәмам онытылып карап торам. Күзгә ташланган манзара мине бөтен барлыгым белән йотты. Бу шау-шулы, баш әйләндергеч каланы күреп, бирегә нигә килгәнемне дә бермәл онытып тордым. Бераздан күңел бу яңалыкка күнегә төште булса кирәк, хәзер үк, эш сәгате узганчы ук, авыл хуҗалыгы комиссариатына барырга кирәк. Кулымдагы төенчегемә, аннан портфелемә күз салам, аларның авырлыгын чамалыйм. Авыр түгел, төенчектә әни хәстәрләгән ашамлык, ә портфельдә — җанымнан да кадерле документлар гына. Үз җаның үзеңә авыр тоела мыни?!

Карар кылынды. Мин постта торучы милиционердан ничек барырга кирәклеген сорашам. Мәскәү транспорты Казанныкы кебек чыгымчы атны хәтерләтми. Монда тәртип. Әле, җитмәсә, май урталарында гына, Мәскәүдә метрополитен ачылды, дип шаулады газеталар. Лазарь Моисеевич Каганович исемендәге дөньяда иң камил, иң зиннәтле, иң шәп метро турында күп сүзләр булды. Хәер, Мәскәүгә килеп төшү белән үк бу төр транспортка юлыкмадым мин. Барасы җирем бөтенләй ерак түгел икән. Хәтта җәяүләп кенә дә барырга булыр иде. Ничек булса булды — трамвайдан төшеп, Җир эшләре наркоматының көрән төстәге җиде катлы бинасы алдына килеп бастым. Иа, хода! Булса да булыр икән шундый зур йорт. Мин вестибюльгә узам, стенага эленгән такталардагы исемлектән вузлар идарәсен эзлим. Гомеремдә беренче тапкыр лифт дигән нәрсәгә утырам, аннан төшеп, коридорларда адашып йөрим. Бер этажга югарырак менелгән. Мин лифтта тагын аска төшәм. Әллә тагын узылган инде? Сорашам. Йөгерә-атлый тагын баскычтан менеп китәм. Менә ул мин эзләгән ишек. Керергә кыймыйча торам. Ниләр көтә мине? Шулай да ишек төбендә таптанып тик тору әйбәт түгел. Ишектән берсе керә, икенчесе чыга. Кешеләр миңа аптырабрак күз ташлый. Күрәсең, бу нинди әкәмәт егет тагын, диләрдер инде.

Мин, батырчылык итеп, кыю гына эчкә уздым. Иркен бүлмә, уң почмакта машинистка үзенең язу машинасын тыкылдата, сул яктагы өстәл артында кәгазьләргә чумган бер чибәр генә апа күренә. Мин шуның янына килеп басам. Төенемне идәнгә куеп, портфелемне ачарга җыенам. Менә ул матур апа, кәгазьләреннән аерылып, миңа күз ташлады. Минем кыяфәт аңа да шактый сәер тоелгандыр, ахры; апаны тагын да ямьләндереп, йөзендәге сәерсенүе елмаю шәүләсе белән нурлана.

— Сез нинди йомыш белән?

Минем телем тотлыга. Юл буена ятлап килгән сүзләремне онытам. Ахырда, һич булмаганча, рус телен ватып-сындырып, үземнең Казаннан килүемне, институттан нахакка чыгарылуымны, дөреслекне эзләп Мәскәүгә юл тотуымны аңлатам. Мин апа алдына, үземнең үтенечемне, үтенечкә теркәлгән документларны салам.

Үтенечне бик озак уйлап, хаталары булмасын дип кат-кат тикшереп һәм тикшертеп язган идем. Апа шуны укый. Аннан матур зәңгәр күзләрен миңа төбәп тора. Тоям, без аның белән шушы бер мизгелдә үк дуслашырга өлгердек. Мин моны аның мөлаем карашыннан, нурлы күзләреннән күрәм.

— Идарә каршында конфликт комиссиясе атнага ике тапкыр утырыш ясый. Тикшереләсе гаризалар бик күп. Башта ук кисәтеп куярга тиешмен, сезгә бераз сабыр итәргә туры киләчәк.

Күрәсең, бу сүзләрдән соң минем сөмсерем коела төшкәндер, ул, хәлемне аңлап, сорап куя:

— Мәскәүдә тукталырга урыныгыз бармы соң?

Мин үземне кулга алам, сер сынатмыйм:

— Бар, хәтта ике...

Шуның белән минем бирелдәге эш бетте дә булса кирәк.

— Белешү өчен кайчан керергә булыр?

— Шулай да, иртәгә кереп чыгыгыз.

Мин бөтенләй бушап калган портфельгә төенчегемне дыңгычлап салам, чибәр апаның җылы каршы алуын әйбәт фал санап, күтәренке күңел белән саубуллашырга да онытткан хәлдә, чыгып китәм. Исәп хәзер Мәрьям апаларның квартирын табу, бераз тамак ялгагач, Мәскәү каласын карарга чыгып китү.

Мин шундый хыяллар һәм ифрат күтәренке күңел белән Кузнецкий күпере артында булырга тиешле Мало-татарский тыкрыкны эзли киттем. Трамвайларны алыштыра-алыштыра, сораштыргалап бара торгач, ул урам табылды. Әмма минем өметләрем тагын челпәрәмә килде. Хыялларым бушка гына булган икән. Мәрьям апалар әле моннан бер атна гына элек, ишекләрен биклэп, Уфага киткәннәр. Кайчан кайтачаклары да мәгълүм түгел, сентябрь башларында гына кайтып керүләре дә ихтимал икән.

Мәрьям апаның күршесе, татар хатыны, миңа шуларны аңлата. Ләкин моннан ни файда! Мин шактый төшенке күңел белән бу өйдән чыгып китәм. Инде өмет Нәфисә апаны эзләп табуда. Бу апаны әйбәт хәтерлим дип әйтә алмыйм, аның буен-сынын да күз алдыма китерә алмыйм. Хәлбуки, без әнием, әтием белән, егерме икенче елны булса кирәк, Чиләбегә барып аларда бер кич кундык. Истә калганы бары шул: ялангай зур, шәрә, салкын бүлмәләр, биек гипс сыннар белән бизәлгән стена кәрнизләре, котсыз тәртипсезлек, юылмаган пычрак савыт-саба. Шул бүлмәдә шау-гөр килгән бер төркем ач бала-чага.

Нәфисә апаның әтисе Ибраһим Юманкулов* бик җитди совет работникларыннан булса кирәк. Хәтерем ялгышмаса, ул күн фуражкадан, күн тужуркадан, биленә наган тагып йөри иде. Хатыны үлгәч, ул нинди сәбәпләр аркасында ишан кызына өйләнергә булгандыр — ул кадәресен белмим. Бик ихтимал, чыннан да, йомшак табигатьле, ап-ак йөзле, иркә Гайшә апага гашыйк булгандыр ул. Мин Мәскәүгә бару ихтыяҗы чыкканга кадәр алар турында бөтенләй оныткан да идем. (Гайшә апа да, Ибраһим абый да күптән гүр иярәре инде. Балалары үсеп, таралып беткәннәр. Әле, әниемнең сөйләвe буенча, Мәскәүдә аларның олы кызлары Нәфисә апа яшәгәнлеген күптән түгел генә белдем.)

Менә хәзер мин ул апаның үзенә, куныш чыгарга урын эзләп барам. Нәфисә апаның квартиры Мәскәүнең әллә кай җәһәннәмендә, имеш. Мин арып-талып аңа барып кергәндә көн караңгыланган, кояш баеган иде инде.

Чандыр гына, ап-ак йөзле Нәфисә апа мине бик аптырап, әмма алай артык ачылмыйча гына каршылады. Мине ул, әлбәттә, оныткан иде. Миңа үземнең кем булуымны тәфсилләп аңлатырга туры килде. Бераздан ул ачыла төште, чәйнектәге чәен җылытып, табынга чакырды. Ләкин бу кунакчыллык та артык озак дәвам итмәде. Хәер, монда

* Мин соңыннан И. Юманкуловның заманында Уфадагы атаклы Галия мәдрәсәсендә укыткканлыгын белдем.

мин үзем дә гаепле идем. Мин, яшь кешегә хас булганча беркатлыланып, үземнең Мәскәүгә ни өчен килүемне әйтеп ташладым. Нәфисә апаның нәзек матур кашлары шундук җыерылды, коңгырт күзләре кырысланды. Ул, күрәсең, сыйнфый сизгерлекнең ихтыяҗын күптән күңеленә сеңдергән һәм шуны дөньяда иң ышанычлы бердәнбер корал иткән кешеләрдән иде.

Ул миңа, бик нык сыйнфый позициядә торган хәлдә, авыр сүзләр ыргыта башлады. Этине дә, бабайны да, гомумән, эти ягындагы безнең барлык нәсел-нәсәпне хурларга кереште. Тел төбеннән шул аңлашыла: шул ук нәселдән булгач, мин дә ышанычлы кешеләрдән түгелмендер, чөнки «алма агачыннан ерак төшми».

Иртәгесен мин йокыдан уянуга, Нәфисә апа йортлар идарәсеннән бирегә кереп чыгулары турында әйтте. Ниндидер ят бер кешенең узган төндә Нәфисә апага килеп кунып калуын идарәгә тапшырганнар, имеш. Пропискага кермәгән кешенең бер кичтән дә артык кунарга хакы юклыгын әйтеп, бик каты кисәткәннәр...

Чәй эчеп тормадым, портфелемне алдым да, саубуллашмый гына чыгып киттем.

Менә мин зур, ят шәһәрнең урамнарында япа-ялгыз калган кеше. Минем хәзер монда ни танышым, ни керер урыным юк. Әйе, мин максатсыз-нисез урамнар гизәм. Башыма төрле уйлар килә. Тукта, мин бит берәр кунакханәгә урнаша алам, һич югында колхозчы өенә. Ләкин андый мөмкинлек булмавына тиз ышанам. Бер кунакханәдә дә миңа урын әзерләп куючы юк икән. Өйлә вакыты җиткәндә, хәлдән таеп, ачыгудан күз алларым караңгылана башлаган хәлдә, Столешников тыкрыгындагы бер «закусочный»да тамак ялгап алам. Шул вакыт бүген үк Наркомземга кереп чыгарга кирәклеге искә төшә. Фатир кайгысы хәзер икенче планда кала. Бәлки, кунар урын турында өтәләнүнең кирәге дә юктыр, дип уйлыйм мин. Хәер, көтәргә туры килсә дә, ул кадәр төшенкелеккә бирелергә кирәкми. Җәй вакыты, көннәр матур тора. Комиссия эшне тиз арада карый калса, мин бит бер-ике төнне урамда, инде бик кирәк икән, берәр вокзалда уздыра алам.

Мин Орликов тыкрыгына ашыгам. Чибәр апа үзенең искиткеч матур, тылсымлы күзләрен тутырып карый да: «Юк шул әле, кадерлем,— ди.— Мин сезнең документларны комиссия секретарена тапшыра алмадым әле. Ул һаман командировкада». Наркоматның бетмәс-төкәнмәс коридорлары буйлап йөрим. Паркет идән дә, тезелеп киткән бер төрле ишекләр дә — барысы да көрән төстә. Коридор, бик озак баргач, сулга борылып китә. Һәр этажда бер үк күренеш. Борылышларда — мәйданчыклар, аларда — буфет. Тәмле аш исләре борынны кытыклый. Юк, вокзалда төн уздырып булмастыр, дип уйлыйм мин. Әле теге комиссия секретаре командировкадан кайчан кайта да, минем эшне кайчан карыйлар. У-у, минем эш озакка сузылырга охшый. Бәлки, берәр кешегә акча түләп тору исәбенә фатирга урнашыргадыр.

Мин тагын Мало-татарский тыкрыгында. Бу — Мәскәүнең татар ягы. Тирә-ягыма карана-карана, тар тротуар буйлап атлыйм. Менә зур таш бина. Аның ишегенә өстенә кадакланган калайдан укып, бу бинада татар китапханәсе урнашканлыгын беләм. Байтак еллардан соң, аның әзербайҗан бае Әсәдуллаев йорты икәнлеген, революциядән соңгы беренче елларда Мәскәү юксылларын совет властеның тирәсендә оештыруда Мулланур Вахитовка күп хезмәт күрсәткән урын булганлыгын беләчәкмен. Ләкин ул кадәресен мин хәзергә белмим. Миндә торак кайгысы.

Китапханәгә, бәлки, берәр киңәш бирүче табылыр, дип, йөгерәатлый баскычтан өскә менәм. Бөкрерәк китапханәче агай белән шул турыда сүз башлыйм. Юк инде, Мәскәүгә нигә килүемнең сәбәбен әйтте юк хәзер. Нәфисәападан бик шәп сабак алдым. Мин бирегә



*Айдар Үтәгәнов рәсеме.*

укырга килгән кеше, ә тулай торак юк. Менә шул, бетте-китте.

— Сез болай итеп карагыз, энекәш,— ди абзый.— Бездән чыгыгыз да, шул ук рәттәге дүртенче өйгә керегез. Ул ике катлы, сары төстә булыр. Анда татарлар яши. Уфа татарлары. Бәлки, шуларның берәрсе кертер кунып чыгарга.

Уктай атылып урамга чыгам. Мин абзый әйткән өйдә. Беренче катта, ишектән керү белән, ярым караңгы коридор. Киң коридорның ике ягында да өстәлләр тезелгән, ә өстәлләрдә чыжлап примуслар яна. Минем нинди максат белән монда керүемне ишеткәч тә хатыннар шаулаша башлый: «Юк-юк, бездә алай куна кертүче юк, безнең үзебезнең дә рәхәтләнеп аяк сузып яткан юк. Күрмисезмени, нинди тыгызлыкта яшәп ятканны?» — диләр.

Аргы караңгы почмактан бер апа яңа хәбәр сөйләп ала. Янәсе, кешене һич белер хәл юк, ул яхшы ният белән йөриме, әллә аның күңелендә явызлыктан гайре нәрсә юкмы. Шулай менә...

Мин портфелемнән паспортымны чыгарам. Менә, ышанмасагыз — карагыз, мин андый кеше түгел. «И-и, балакаем,— дип суза тегә апа,— фәлән кешегә дә бирәү шулай паспортын, документларын күрсәтеп куна кергән дә, иртәгесен, җаным, ул киткәч, камудларын ачып карасалар, кыйммәтле әйберләрдән җилләр искән, ди!» Хатыннар сөйләшәләр, көлешәләр, гайбәт саталар. Миңа хәзер әйләнеп тә карауучы юк. Чыжлап примуслар шаулый. Мин онытылдым. Юк, эшләр инде мондый тәс алгач, булмады дигән сүз. Мин тагын урамда, өй борынча кереп, кунып чыгар урын эзлим. Ләкин беркемнең дә үз тынычлыгын бозасы килми. Нindидер билгесез ят егетне кем өенә кертсен!

Нишләргә инде? Мин кыска тыкрыкның барлык өендә булдым, һәр ишекне шакыдым, әмма мине өендә кундырырга теләүче табылмады. Үзем дә сизмәстән, байтак каңгырап йөргәннән соң, яңадан Уфа татарлары яши торган ике катлы сары агач өй янына килеп чыкканымны абайладым. Башыма сәер бер уй килде. Туктале, минем портфельдә паспорт кына түгел ләбаса. Апаларны тәгаен үземнең начар кеше булмавыма ышандырып булыр.

Мин инде тагын үземә таныш коридорда. Хәзер инде примусларның күбесе сүндерелгән. Коридорда бары бер-ике апа гына кайнаша.

— **Карагыз әле,— дим мин, йомры гына, кара кашлы, чибәр апа** янына килеп.— Сез миннән бик шикләнәсез. Шулай бит? Мине әллә кемгә хисаплыйсыз. Менә бу газетаны карагыз әле. Анда кем портреты? Миңа охшамаганмы?

Мин апага үземнең фоторәсем төшерелгән «Вахитовчы» газетасын сузам. Анда повестемның өзеге басылган.

Апа рәсемгә карый, елмая.

— Миңа бер генә кич булса да кунып чыгарга кирәк, апа,— дим мин.— Иртәгә, бәлки, ничек булса да җаен табып урнашырмын.

— Әйдә инде, алайса, энем,— ди миһербанлы апа,— минем бер буш торган тапчаным бар. Шунда кунарсың.

Бу апаның исеме Хәдичә иде. Утыз еллар чамасы вакыт узгач, мин аны шул ук квартирада очратачакмын әле. Язучылар съездына Мәскәүгә барган җирдән, аларга сугылып, аның инде картайган, ләкин әле һаман мөлаем йөзен тагы күрәчәкмен. Тагын бер тапкыр рәхмәтемне әйтәчәкмен, кочтәнәч бирәчәкмен.

Вакыйганың кызыклы ягы тагын шунда: миңа вакытында үзенең яхшылыгын күрсәткән Хәдичә апаның татар арасында Мәскәү комиссары дип йөртелгән Мулланур Вахитовның иң якын көрәштәшләреннән берсе булган мәрхүм Минһаҗ Хөсәен улы Әхтәмевнең хатыны икәнлеген белдем. Бусы инде утыз ел вакыт узгач билгеле булды.

Ниндидер хатын-кызның өзгәләнеп елавына йокымнан уяндым. Артык арыганлыктан, кичә Хәдичә апаның бәләкәй фанер стеналы бүлмәсендәге агач тапчанга сузылып яту белән, йокыга талганмын. Апа белән сөйләшергә дә, аның гаиләсе хакында сорашырга да туры килмәде. Әле мине уянырга мәҗбүр иткән елаучы кеше Хәдичә апаның кече кызы икән. Ул — сызымчы. Эшләрен кич алып кайткан да, иртәнге якта шуны төгәлләргә утыргач, бәхетсезлеккә каршы, сызымына тушь савыты аударган.

Мин, торып киенәм дә, шыпырт кына алгы якка чыгам. Олы якта ыгы-зыгы. Хуҗаларның әле хәзергә күзләренә ул-бу чалынырлык түгел. Шулай да, портфелемне алып, чыгып китим дип ишеккә таба атлыйм. Хәдичә апаның аптырый төшеп:

— Син кая болай, энем?— дигән сүзләрен ишетәм.— Чәй эчеп китәр иең...

— Юк, бик зур рәхмәт. Мин ашыгам.

— Син кайтырсыңдыр бит әле?

Ирексездән тукталып калам. Хәдичә апаның тел төбен аңлыйм кебек. Мин бит бары бер кичкә генә кунарга керәм, дидем.

— Кайтам, кайтам. Кунарга урын тапсам да, тапмасам да кайтам. Шунда исәп-хисапны өзәрбез.

— Безнекеннән яхшырак урын тапмасаң, кунарга дип үзебезгә кайт, тартынып торма, энем...

Мин, рәхмәт әйтеп, ярым караңгы коридор аша ишеккә таба ашыгам. Примуслар чыжлый, коридордагы хатын-кыз, мине күргәч, тынып кала, сөзеп карап озата.

Ни әйтсәң дә, җайлы вакытка туры килде минем сәфәрем. Узган ел гына карточка системасын бетерделәр. Кибетләрдә икмәк ирекле сатыла, ашханәләр, кафеләр һәр урамда гөрләп эшләп тора. Акчаң бар икән, кер дә тамак туйдыр, синнән беркем бернинди карточка-талон сорамый. Якындагы ашханәдә тамак ялгап алам да Орликов тыкрыгына китәм. Ләкин әлеге комиссия секретаре һаман командировкадан кайтып җитмәгән. Ашкынып баруларым юкка булды. Кинәт үзәккә үтә торган бушлык, өметсезлек тойгысы күңелемне кимерә башлады. Киттем Мәскәү урамнары буйлап. Мәскәүнең метросында әле булганым юк иде. Хәйраннар калып, зиннәтле җир асты сарай-станцияләрендә йөрим. Көлеп, елкылдап торган, үзләреннән үзләре ачыла торган ишекле вагоннарда рәхәт кенә тирбәлеп барам. Станция саен төшәм, кулны артка куеп тамаша кылам, тагын вагонга утырам, тагын төшәм, тагын карыйм. Күңел тынычлангандай булды.

Мин шулай, метродан чыга алмыйча, бик озак йөрдем. Мәскәү урамына чыкканда өйлә вакыты җиткән иде инде. Бер кафеда аяк өсте генә тамак туйдыргач, Кызыл мәйдан ягына юл тоттым.

— Ленин!— дидем мин, үземнең моңарчы мавзолейга кермәвемә үземне табалап. Ә анда, мавзолейдан алып тарих музеена кадәр, чиратта халык тора. Ашыгып, чиратның ахырын эзли киттем. Ул музейдан да арырак, бакча коймасы буена кадәр сузылган булып чыкты. Ниһаять, чираттагы соңгы кешегә җитеп, аның артына басам.

Ленин! Менә нинди кеше икән ул! Кечкенә генә гәүдәле, киң маңгайлы, җирән чәчле. Ак матур кулларын күкрәгенә куйган, күзләрен мәңгегә йомган, ята. Даһи юлбашчының электр утында яктыртылган йөзен, гәүдәсен игътибар белән карап, кешеләр артыннан әкрен генә атлыйм. Баш очыннан кердек, аяк очыннан әйләнеп узабыз. Минем барлык теләгем — бөек кешенең чалымнарын күреп истә калдыру. Мавзолейдан чыккач та әле, тәэсирләремнән аерыла алмыйча, урамнарда байтак вакыт йөрдем. Менә шул кешенең теләкләре тормышка

ашу аркасында мин хәзер Мәскәүдә йөрим, дип уйлыйм.

Ә көндәлдә кинәт кенә шундый бер вакыйга пәйда була... Мин беренче классларда авыр укысам да, соңыннан ачылып киттем. Мәктәптә инде беренче укучылардан санала идем. Ләкин аңа карап тормадылар, көннәрдән бер көнне мине һәм минем кебек башка, тавыштан мәхрүм ителгән кешеләрнең балаларын, чит элемент, дип, мәктәптән чыгардылар. Алтынчы класста уку башланган чак иде бу. Без, мәктәптән куылган балалар, Ленин почмагы дип аталган бүлмәгә җыелдык. Анда укытучылар юк иде. Күрәсең, шуннан файдаланыпмы, кайбер балалар, тойгыларына хуҗа була алмыйча, елый-елый, Ленинга карап-карап, язмышларын каһәрләргә тотындылар...

Мин үземнең рәсем дәфтәрләремә Ленин бабай портретын бер генә тапкыр ясамадым. Инде менә институтка кергәч тә, минем кебекләргә мәктәп ишекләре ябылгач та, күңелемдә бу кешегә нинди дә кинә саклау, үпкәләү кебек нәрсә тоймадым. Казандагы Ленин музееның истәлекләр дәфтәренә мин, беренче курста укыган чакта, юкка гына «Без синең юлдан мәңге барырбыз».— дип язмадым бит.

Ә кем гаепле соң минем якты ниятләремнең челпәрәмә килүенә? Әтиемме? Ләкин нинди нигезләрем, дәлилләрем бар соң аны үземнең бәхетсезлегемдә гаепләргә?! Ул, моңарчы укытучы булган кеше, егерме беренче елгы ачлыктан соң мулла булган. Шуның өченме? Алай дисәң, имамлык аша да халыкка хезмәт итеп була, дигән тәрбия алган кеше бит ул. Кешенең нәсел-нәсәбен гаилә башының ялгышы өчен җәзалау дөресмени? Аннары шул кадәресен дә әйтергә кирәк: ул бит, еллар узу белән, күзләре ачылу, карашлары үзгәрү белән, гаебен төзәткән. Минем документларым арасында Троицкида чыга торган «Вперед» газетасының егерме сигезенче елгы бер саны ята. Анда «Мулла порвал с религией» дигән кечкенә хәбәр-мәкалә басылган. Әти анда, ачыктан-ачык игълан итеп, үзенең муллалыгын ташлавы турында яза. Шул җитмәгәнмени? Ә-ә, сыйнфый дошман сарык тиресе ябынган бүре дә була бит дисезме? Моны кешенең гамәленә карап бик ансат белергә мөмкин. Бары кеше дигән затка кешегә караган кебек карарга гына кирәк.

Хәер, минем әти ягы күзгә артык нык ташланып торган як шул. Әтием — мәшһүр Зәйнулла ишанның уртанчы улы. Шәйхе Зәйнулла ибне Хәйбулла Нәкышбәнди. Исеме һәм титуллары гына да ни тора! Мин шулай уйладым.

Әлбәттә, Мәскәү урамнарында үземнең язмышымны кайгыртып йөргәндә, хәзер никадәр сәер тоелмасын, мин Зәйнулла бабам турында анык берни дә белми идем. Миңа аны исән чагында күрергә туры килмәде. Әти дә, үзе хакында сөйләргә яратмаган кебек, бабам турында бөтенләй сөйләми иде дисәм дә ялган булмас.

Бабай турындагы кайбер мәгълүматларны мин укып һәм кешеләрдән ишетеп кенә белдем. Менә алар:

Л. Климовичның 1936 нчы елны «Огиз-Гоизда» басылып чыккан «Ислам в царской России» исемле китабында бабай турында шактый мәгълүмат бар. Анда Зәйнулла ишанның башкортлар арасында беренче тапкыр зекер әйтүне кертКәнлеген һәм шуның аркасында дошманнары аның өстеннән ересь (дингә каршы көферлек) тарата дип донос язып төрмәгә утыртулары, аннан сигез елга сөргенгә җибәрүләре турында язылa. 1881 нче елны гына аңа сөргеннән кайтырга рөхсәт бирелүе, сөргеннән котылгач, икенче тапкыр хаҗга китүе, аннан кайткач, Аккуҗа дигән авылдан Троицк шәһәренә күчеп, андагы җәмигъ мәчеткә имам булуы турында сөйләнә.

Бабам турында укыган икенче чыганак — Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашның «Яшьлек эзләре буйлап» дигән, 1964 елны Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан автобиографик әсәр.

Автор анда бабамның бик начар, әхлаксыз кеше булуы турында яза. Янәсе, Зәйнулла ишан ифрат комсыз булган, аңа сәдака җыю гына җитмәгән, ул үзе ышәгән бистәдә кибетләр ачып, табышлы сәүдә кылып акча җыйган. Шул ишан аркасында Троицк шәһәре дини реакция үзәгенә, әйләнгән Кечкенә гәүдәле Зәйнулла ишан Рәсүлевнең зур күләгәсе казах, башкорт далаларына чын гыйлем-мәгърифәт чәчәргә һәм, гомумән, прогрессив хәрәкәткә бик комачаулаган.

С. Кудаш, Зәйнулла ишанны «фаш итү» өчен, хәтта Шәехзадә Бабич әсәрләреннән дә мисал китерә. «Бабич әйтмешли, карт ишан Зәйнулла ул әфьюн вә мәгъҗүн сандыгы», ди. Әмма мин үзем яраткан бу зур талант иясенең андый шигъри юлларын беркайда да очратканым юк. Ә укыганым шул... Хәер, бу турыда соңрак.

Сәйфи ага үзенең әсәрендә, Зәйнулла ишанның реакцион зат икәнлеген нигезләү өчен, Мәҗит Гафуридан да файдаланырга тырыша. Мәгълүм ки, заманында Мәҗит Гафури Рәсүлия мәдрәсәсендә бераз вакыт укыган. Әмма шагыйрьнең ишанга карата язган әсәре хәзергә беркемгә дә билгеле түгел.

Басма чыганакларның тагын берсе истә калган. Кызганычка каршы, мин аның нинди журналда һәм ничәнче елда басылганлыгын анык хәтерләмим. Тик шул кадәресе исемдә: ул егерменче елларда басылды. Анда автор Зәйнулла ишанны, ул патша шпионы иде, дип игълан итә. Бу мөһер, бабайга сугылган булса да, мине бик нык тетрәтте. Мин үз вакытында, алтмышынчы еллар азагында, Оренбурда булуымнан файдаланып, андагы архивның жандарм идарәсе папкаларында бу нәрсәне ачыклау өчен озак казындым. Хәзер мин бабамның берниндн шпионлык хезмәтен үтәмәгән кеше икәнлеген раслый алам. Киресенчә, аның артыннан жандармерия тарафыннан яшерен күзәтү куелганлыгын исбатлап торган документларны күрдем мин анда.

Юк, бабам турындагы материаллар гел тискәре характерда гына түгел. Менә минем алдымда 1917 елда «Вакыт» типографиясендә басылган 105 битлек бер китап ята. Аның тышына «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» дип язылган. Китап бабамның вафатыннан соң бик ашыгыч рәвештә басылган. Китапны чыгаручы, аңа кереш сүз язучы кеше — атаклы прогрессив галим, тарихчы Риза Фәхретдинев. Ул «Сүз башында» түбәндәгеләрне яза:

«Русия мөселманнарының олуг адәмнәреннән вә файдалы хадимнәреннән булган шәех Зәйнулла хәзрәтләре ошбу 1335* — 1917 нче елның 2 нче февраль (22 нче шәһре рабигыл ахыр) дә Троицк шәһәрендә, үз йортында, әһле әүляды вә әкрабасы хозурында мәңгелек булган ахирәт йортына сәфәр итте, үзенең әтбагларыны мөхлисләрен кайгы вә хәсрәтләргә гарык кылды.

Шушы кадәр озын гомерне михраб берлә мөнбәр, мәсҗет берлә мәктәп вә мәдрәсә һәм дә китап уртасында үткәргән кеше хакында аллаһы тәгалә хәзрәтендә өметебез зур.

«Асарь»га дәрҗ итәр өчен дип хөрмәтле Муса хаҗи (Зәйнулла бабайның якын туганы һәм дусты. **А. Р.**) җәнабларыннан шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәлен үтенеп яздырып алган идем. Бу тәрҗемәи хәлне, әлбәттә, «Асарь»га дәрҗ итәчәкмен. Шәех Зәйнулла хәзрәт хакында башкалардан ишеткән вә үзем белгән нәрсәләр дә күп. Иншә алла, шул нәрсәләрнең һәрберене шунда әлхаль кылсам кирәк»,— ди. Аннан тагы шулай дип яза: «Зәйнулла хәзрәт тәрҗемәсен язар өчен мәйдан бик иркен, мәүзуг бик күп, мөляхәзә вә мөхакәмә урыннары күз күреме кадәр киң. Ләкин без Муса әфәнде рисаләсенә әсас игътибар итәбез. Хакыйкать хәлдә Зәйнулла хәзрәт хакында

* Миләди ел исәбе белән 1917 ел.

язылган нәрсәләрнең иң дөресе Муса әфәнде язган нәрсәләр булыр, иншә алла.

Ризаэтдин бән Фәхретдин. Оренбург. 10 февраль. 1917 нче ел».

Риза Фәхретдинов әйткән Муса хаҗи мәкаләсендә Зәйнулла бән Хәбибулланың чыгышы белән башкорт Куакан ыруыннан булуы әйтелә. 1833 нче елда туган. Туган җире — Троицк өязе, Тунгатор волосте, Шәрип авылы. Шәҗәрәсе: Зәйнулла — Хәбибулла — Рәсүл — Муса — Бәйрәмкул — Гашикъ — Солтанай — Морад — Тупай — Уразгали — Яңшы — Ятаби.

Зәйнулла унике яшенә кадәр авылындагы мәдрәсәдә укый, аннан, Малай Муйнак авылына китеп, әлшәех Якуп хәзрәт мәдрәсәсендә белем алуын дәвам иттерә. 1851 нче елда Троицкига китә һәм анда дамелла Әхмәт бән Халид әл-Мәнгәри мәдрәсәсендә дәрес ала. Анда, сәләтле булуы аркасында, җиде ел эчендә тиешле программаны уңышлы тәмамлап, 1858 нче елда Верхнеуралда типтәр авылы Акхуҗага китеп, мәдрәсәдә дәрес бирә, 1859 нчы елда закон буенча имамлык итә башлый. Алтмыш алтынчы елда ул чәй сәүдәсенә керешеп карый, ләкин файда күрү урынына бурычка бата. Зәйнулланың барлык хыялы изге урыннарны зиярәт итү була. Бәхетенә каршы дип әйтимме, казахның Җәббас ыруыннан булган Ершыбай атлы бер бае вафат булып, аның өчен хаҗ кылуны Зәйнулла хәзрәттән үтенәләр. Бәдәл* хаҗ өчен кулына мең сум акча төшкәч, ул 1869 елның 18 августында Истанбулга китә. Анда Әлшәех Әхмәт Зиялетдин бән Мостафа Көмешханәви хәзрәтеннән дәрес ала. Шәех Көмешханәви аңа челләханәгә кереп ураза тотарга, анда һәркөн йөз мең тапкыр зекер әйтергә боера. Зәйнулла, кырык көн буена ябылып, ураза тота, зекер әйтә, кыскасы, шәехнең боерыгын тулысынча үти. Шушы сынауларны уңышлы башкарганнан соң — бу сәфәрдә аның белән Муса хаҗи да була — ул Хиҗазга китә. Алар Мәдинә әлрәсул галия исламга рамазан шәрифнең өченче көнендә барып җитәләр.

Зөлкагдәнең егермесендә Зәйнулла Мәдинәдән дөядә Мәккәгә китә һәм зөлхиҗҗәнең икенче көнендә анда була. Хаҗны башкарып, пароход белән Истанбулга кайта. Анда Көмешханәви аңа Нәкышбәнди тәрикәсендә мөритләр булдырырга фәрман бирә, шул юнәлештә дәрес бирү өчен иҗазәтнамә (диплом) белән тәэмин итә. Кыскасы, аңа ишанлык дәрәҗәсе шулай бирелә.

1870 елның июнь башында илгә кайтып, сентябрь айларында ишан үзенең миссиясен башкарырга керешә. Тиз арада яраннар һәм иярүчеләр пәйда була. Абруй арта, хәтта башка шәехләрнең мөритләре дә Зәйнулла хәзрәткә күчә башлый. Бу хәлне автор Зәйнулла хәзрәтнең галимлеге һәм кешелеклеге белән аңлата. Ләкин, абруй арткан саен, күрәлмаучылар саны да күбәя, узгандагы гөнаһларны искә төшерүчеләр дә табыла. Ниһаять, Зәйнулла ишан өстеннән донослар ява башлый, төрле гайбәт тарала. Доносларның бер ише Сәлимгәрәй мөфтигә җибәрелә, шул ук вакытта эшне икенче канал буенча да йөртәләр — губернаторга язалар. Янәсе, ул халыкны патшага каршы котырта.

1872 елны Зәйнулла хәзрәт Уфага Духовный собраниягә чакыртыла. Анда ишаннан сорау алып, ахырда кул куйдырып кайтарып җибәрәләр. Ләкин юлда, Златоустка җиткәч, губернатор әмере белән ул кулга алына һәм, алты айдан соң хөкем карары чыгарылып, этап белән Вологда шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Юлда Уфа, Казан, Нижний, Мәскәү шәһәрләрен үтәләр. Вологда губернаторы моны Никольский шәһәренә озата. Шушы шәһәрдә ул полиция күзәтүе астында өч ел яши. Хәзрәтнең карт анасы, балалары Акхуҗада кала, хатыннары үз янына килә.

*Бәдәл — кеше өчен ялланып хаҗга бару.

1876 елны, ишанның үтенече буенча, аңа Кострома шәһәренә күчәргә рөхсәт бирелә. Ул шундагы Татар бистәсендә биш ел яши. 1881 елны, губернатор Кржижановский рөхсәте белән, сөргеннән котылып Акхуҗага кайта.

Зәйнулла хәзрәт, тоткынлыктан котылу хөрмәтеннән, үзе өчен изге урыннарны янә зиярәт кылырга була. 1882 елны, Муса хаҗи белән берлектә, тагын хаҗга сәфәр китә.

1884 елны, Троицк шәһәрендә бишенче җәмигъ мәчет салдыручы Хәбибулла Габбасов хаҗиның һәм мәхәллә халкының теләге буенча, шәех Зәйнулла хәзрәтнең Акхуҗадан Троицкига күчеп килүен үтенә. Хәзрәт бу үтенечне кабул итә һәм, халыкның рөхсәте белән, 23 апрельдә Троицк шәһәренә күчеп килә. Мәдрәсәләр, кунакханәләр төзелә. Троицкиның абруе тагы да арта. Шул көннән башлап, Зәйнулла ишан үлгәнче Троицкида яши.

Шул ук китаптан башкалар язган мәгълүматларга да тукталыйк. Әйтик, Габдулла Газиз Зәйнулла хәзрәтне сөргенгә озатканда полицмейстер Вәликәй Дәүләтшиннең олау бирмәвен яза. Ләкин юлда халык аны атлар белән авылдан авылга озата. (Моның шулай булганлыгын миңа язучы Әмирхан Еникинең әтисе Нигъмәтҗан абзый да сөйләгән иде. **А. Р.**)

Ишан кулга алынганнан соң, халык төркем-төркем булып төрмәгә ябырыла. Бу хәл губернаторны аерата шикләндерә, чөнки аңа язылган доноста ишанның дошманнары: «Ул бик хәвефле кеше, төрек тарафдары, төреккә акча җыя, гаскәр туплый»,— дип язалар.

Габдулла Газиз ысул җәдитнең таралуында ишанның хезмәте гаять зур булганлыгын әйтә. «Ишан хәзрәт билгеләгән мәҗлесләргә керү һәркем өчен ачык,— ди.— Ул үзенең тәэсир итү көче белән меңнәрчә аталарны эчү бәласеннән коткарды, бик күп гаиләләрне бәдбәхетлектән азат итте. Ул күп авыруларны дәвалады, әгәр үзенең кулыннан килмәсә, авыруны докторга җибәрде. Зекер алырга кергән шәкертләргә, сезнең зекерегез — дәресләрегез, дип җавап кайтарды. Тормыштан ул хәбардар булган һәм бернинди файдалы яңалыкка каршы килмәгән».

«Вакыт»та (№ 2171) басылган тәрҗемәләрдән:

«Зәйнулла хәзрәт эчке Россиядәге мәшһүр затларның иң олысы һәм абруйлысы... Гасырыбыз аның кадәр мәшһүр һәм абруйлы зат күрмәгәндер диелсә, ялгыш булмастыр... Троицкидагы Зәйнулла хәзрәт эчке Россиядә иң мәшһүр вә иң атаклылардандыр. Заманында аның сүзе һәркемгә закон-шәригать иде... Вөҗданы кушса, шуны ачыктан-ачык сөйләде вә язып таратты... Бәгъзе әтрафында җыелган бер төркем риякяр халыкның сүзенә ышанып бәгъзе хаталар кылса да... бу кара эч белән эшләнмәде... Ахыры гомеренә кадәр һәркем аны олуг бер шәех, могтәбәр бер галим санап хөрмәт итте. Зәйнулла хәзрәт Казахстанга дин вә мәдәният таралуга гаять бөек хезмәт кылды. Зәйнулла хәзрәтнең берничә басылган әсәре дә бар. Болар, гыйльми җәһәттән бөек бер әһәмияткә ия булмасалар да, үз заманында сөелеп укылды һәм тиешле вазифасын үтәде. Болар арасында Зәйнулла хәзрәтнең Троицк голәмәсе арасында ысул җәдитнең дөреслегенә биргән фәтвасы һәм страхованиенең кирәклеге хакындагы фәтвасы иҗтимагый җәһәттән дә вакытында бик зур урын тоттылар. «Троицки голәмәсе һәм ысул җәдит» исемле рисалә «Вакыт» идарәсе тарафыннан кабат-кабат бастырылды».

«Тормыш» газетасы да шундый ук сүзләр яза. «Кояш» газетасы Зәйнулла ишан турында мәкаләне түбәндәге сүзләр белән тәмамлый:

«Киң холыклы, мөтә вазыйг, юмарт куллы, хуш мәҗлесле мәрхүм үзенең соңгы гомерендә дә мәдрәсәне онытмады. Аның матди җәһәтен тәэмин итү мәсьәләсен кузгатып, мәзкүр мәдрәсәгә башлап үзе ун мең сум һидия итте. Ходаның рәхмәтендә булсын».

Имам Кәшшаф Тәрҗемани «Кояш»та болай дип яза:

«Зәйнулла хәзрәтнең милләтебезгә олуг хезмәтләреннән берсе аның ысул җәдидә мәктәпләрне тәрвиҗ вә химая кылуы иде. Ысул җәдидә Казан вә Оренбург кеби зур шәһәрләрдә вә гомумән Русиядә үзенә бик аз тарафдар тапкан, исламиятнең Мәккәдәге кебек гаммә тарафыннан ифкар вә тард (тибәрелгән, куылган. **А. Р.**) кылына торган вакытларында, мәрхүм хәзрәт сәясында ул инде Троицкида үзенә камил гражданлык хокукы алган иде... Дин исеменнән ысул җәдидә хилафына хәрәкәт иткән кешеләргә каршы Исмәгыйль Гаспринский җәнабларының Зәйнулла хәзрәтне калкан итеп язган мәкаләләре әле дә хәтеремдә бар.

Шулай ук остаз Галимҗан хәзрәт үзе башлап тәэсис иткән ысул җәдидә мәдрәсәсенә (сүз Казандагы Мөхәммәдия мәдрәсәсе турында. **А. Р.**) зур вә яңа бина торгызганда беренче нигез ташыны Зәйнулла хәзрәттән салдырып, Казанда да ысул җәдидәнең дини рәсмиятен тасдыйк иттергән иде. Зәйнулла хәзрәтнең фәзаиленнән берсе аның остаз Шиһабетдин Әл-Мәрҗани хәзрәтләренә тәрфигъләк итүе иде. Күп муллалар Мәрҗани хәзрәтләренә тәгаен вә аның мәсләкләренә халыкны тәнфир иткән заманнарда мәрхүм хәзрәт мәҗлесендә һәрвакыт аны тәсвиб кылып вә китапларны карау белән тәүсыя итеп сөйләр булган. Бу хәлне бән берничә дәфга күрдем» (1917, 5 февраль, № 1076).

«Йолдыз» редакторы Һади Максудов яза:

«...мәрхүм шәригать исламиягә бәни адәмне кысарга һәм тыгызларга килгән мәҗбүри бер карарнамә дип карамый иде, бәлки һидаять вә ислах илә галәмнең дөнья вә ахирәт, рәхәт вә сәгадәт арттыру өчен килгән нәсихәтнамә дип карый иде, шуның өчен күп муллалар һәм файдалы эшне мөмкин кадәр харамга чыгарырга тырышкан вакытта хәзрәт халәлгә чыгара иде, ислам бәни адәмне җәберләр өчен килмәгән, бәлки аңа һәр җәһәттән ярдәм итәр өчен килгән, ди торган иде. Ысул җәдидә белән укытуның файдалы булачагын бик тиз аңлаган иде. Шул сәбәптән ысул җәдит тәртибе хосусында мәрхүм Исмәгыйль Гаспринский җәнабларына тәкълид кылуны лязим табып, 1895 сәнәдә ике мөгаллимен Бакчасарай шәһәренә җибәргән иде. 1897 елдан башлап үз мәдрәсәсендә ысул җәдит белән укытуны башландырган иде. Хәзрәтнең бу эшенә, бәлки, бик күп мөритләрнең кәефе киткәндер, ләкин ул мөритләренә үзе табигъ булырга тырышмый иде, бәлгакес һәр хакыйкатьдә мөритләрен үзенә табигъ итәргә тырыша иде».

Рәхимҗан Атнабаевның «Тормыш» (1917 ел, 1 март, 600 сан) газетасында язганыннан:

«Ул сөрген мөддәте эчендә бик фәкыйрь хәлләрдә калган, тарлыкның бик ачы читенлекләрен татыган, фәкыйрьлекнең, гаҗизлекнең хәятларын сынаган, төрле кешеләр белән янәшә булырга тугры килдегеннән мөгамәлә ысулларын өйрәнгән, шуларның барысы бергә җыелып хәзрәтнең әхлагына бик тәэсир иткәннәр, аңар аллага иман, нәфескә игътимад, яхшылыкка тәшәккер дәресләрен укытканнар... анда хәзрәт күп калын китаплар укып чыккан вә шуның аркасында сөргеннән кайтканда көтмәгәнчә галим булып чыккан...»

«Әл-дин вә әдәп» тән:

«Хәзрәтнең үлү хәбәренең иртәгесендә җомга көн җомгача мәдрәсәи Мөхәммәдия дәресханәсендә мәдрәсәнең шәкертләре вә хәлфә нәзыйрлары, шәһәрнең байтак имамлары вә гаяннан бер кадәр кеше җәмигъ газем булып берничә мәртәбә коръән хәтем итеп хәзрәтнең рухына догалар кылынды. Соңра Галимҗан хәзрәт әсәрле рәвештә хәзрәтнең кыскача тәрҗемәи хәлен сөйләде... аннан җеназа намазы укылды... Шул җомга көн бәгъзе Казан имамнары укып, бөтен Казан мәчетләрендә ахшам соңында намазлар да укылды... Зәйнулла хәзрәтнең һәркөн сәгать тугыздан ишеге ачылып, күрергә килүче хаҗәтле кешеләр хозурына керерләр вә мәҗлеслә-

рендә булырлар, мәҗлес өйләгәчә дәвам итәр иде. Йөзләп кеше кабул салонында даим булыр, кереп чыгучылар көненә берничә йөзләргә ирешер иде. Һәркемне ачык йөз берлә каршылар, хәл-әхвәл сорашыр, хаҗәтләрен дә ида кылырга тырышыр иде. Ханәсенең диварлары түшәмгәчә китаплар өелгән булып гаҗәп рәвештә хафизалы. Шул кадәр күп китапның кайсы кай урында икәнен белер, бер китап хаҗәт булса, бер сүз карарга кирәк булса, «Ул китап фәлән шүрлектә, фәлән урында, бу сүз дә фәләнчә сәхифәсендә булыр»,— дип, китапны шкафтан эзләү мәшәкатен калдырмый иде. Егерме ел элек күргән нәрсәсен онытмас. Кирәкле китапларны һаман эзләп сорашып алып торадыр иде... китап өчен акча кызганмады. (Мөхәммәт Нәҗип Түнтәри, 6 — 7 саннар, 29. 1.17).

Мин кайбер күчермәләр ясаган китаптагы башка мәкаләләрдә дә Зәйнулла бабай турында бер үк диярлек нәрсәләр кабатлана. Шуңа күрә мин барысына да тукталуны кирәк санамыйм. Һәрхәлдә, китерелгән мисаллардан мин бабамның кем икәнлеген, ниндирәк кеше булганлыгын төсмерли алам. Миңа шул җиткән.

Өстәп бары шуны гына әйтә алам: аның турында байтак кына хикәят-вакыйгалар, легендалар ишеткәнем булды. Мәсәлән, Габдулла Мусич Рәсүлевтән (исеме аталган Муса хаҗи улы) ул үзе күргән вакыйганы ишеткәнем бар.

...Ишан хәзрәт акылына зыян килгән кешеләрне дә дәвалаган. Көннәрдән бер көнне бер рус бае ишанга үзенең акылдан шашкан улын алып килә. Габдулла абый болай сөйли: ««Мин ул вакытта хәзрәт янында идем, аңа кунакларны кабул итүдә булышлык күрсәттем. Хәзрәт, авыруның рус икәнлеген белгәч, башта бик каты каршы килде. Русның хәзрәт аягына ятып үтенүенә дә игътибар итмәде. Ләкин соңыннан минем дә алар исеменнән үтенүемне ишеткәч, йомшады. Арбага бәйләп салынган авыруны алып керергә кушты. Хәзрәт аны каршысына утыртып өшкерде, дарулар бирде, минем аша егетне ничек дәваларга кирәклеген аңлатты. Ә бер елдан соң теге авыру, тәмам савыккан хәлдә, ишанга рәхмәтләр әйтергә килде».

Бабам турында сүз барганда аның мәдрәсәсендә Мәҗит Гафуриның укуын да искә төшергән идем. Әйе, аны мәдрәсәдә фанатик шәкертләр кыйнаган, анда бик алама бер хәлфә дә булган. Әмма Зәйнулла бабай турында шагыйрьнең хурлап язган сүзен кем күрсәтә алыр иде икән?

Инде Шәехзадә Бабичның ишан хәзрәткә карата язган шигыре турында. Талантлы татар-башкорт шагыйре Бабичны мин кече яшьтән үк яратып укыйм. Әмма аның бабама карата эпиграмма язуын укыганым юк. Хәер, ул ишанның олы улы Габдрахман Рәсүлигә эпиграмма язган. Ул анда:

> Габдрахманыр Рәсүл, сиңа ишанлык зур мирас,
> Булсаң ишан, әфьюн урнына гыйлем, әхлак өләш,

— дип яза. Мин бу юллардан авторның «ишан — гыйлем, әхлак өләшүче иде» дигән карашыннан башка нәрсә күрмим.

Татар-башкорт-казах шагыйре мәшһүр Акмулланың Зәйнулла бабайның якын дусты булганлыгы мәгълүм. Миңа бабамның бу ирек сөюче шагыйрьне якын күргәнлеге, һәрдаим аңа химая кылуы да билгеле. Акмулла үзенең соңгы сәфәренә чыгар алдыннан Зәйнулла хәзрәт аңа ат бүләк итә, шагыйрь үзе арба ясый, ниндидер явыз җаннар тарафыннан шагыйрь үтерелгәч, бабам аны җирли, үзе язып, кабер ташы куйдыра.

Бабам турында, ул Тибет медицинасын яхшы үзләштергән кеше иде, дигән сүзләрне ишеткәнем бар. Аның турында халык арасында заманында төрле риваятьләр дә ишетергә туры килде. Мәсәлән, кулга алынгач, аның аякларына богау сала алмый интеккәннәр; имеш, богау

үзеннән-үзе чишелеп торган. Бабай гипноз көченә ия булган, имеш.

Кыскасы, мин Мәскәү урамнарында комиссия җавабын көтеп йөрим һәм уйланам. Нәсел-нәсәбем турында уйланмый хәлем юк. Ул елларда кеше үзенең яшәргә хаклыгын раслау, йә инкарь итәр өчен ерексездән ата-бабасына мөрәҗәгать иткән. Кем белә, бәлки мин, нәсел-нәсәбем буенча җаваплы кеше буларак, кирәкмәс, булмас эш артыннан йөримдер. Бәлки, мөһер сугылган кеше буларак, уку йортыннан сөрелүем белән килешергә, илдә барган, бөек, зур эшкә шулай өлеш кертергә, бу шулай булырга тиеш, дигән карарга килергә тиештер?

Ләкин моңа күңелемнең кайсыдыр почмагында каршылык кузгала, мин дә бит адәм баласы, минем дә хокукларым нәкъ башкаларныкы кебек булырга тиеш, дип дәгъвалый иде.

Мин хәзер Зәйнулла бабамның прогрессив карашлы, халыкка хезмәт итү юлыннан барган бер шәхес булуын аңлыйм. Хәер, бер мин генә түгел, Башкортстан галимнәре дә аның нәкъ шундый кеше булуын таныйлар. «Совет Башкортстаны» газетасының 1986 елгы бер санында алар нәкъ шул хакта язып чыктылар. Ләкин бу бит бүген... Ә ул көннәрдә, Мәскәү урамында йөргәндә, күңелемдә зур рәнҗү бар иде минем...

## 5

Иртүк торам да, хуҗалар чәйгә утырганчы, тизрәк өйдән чыгып китәм. Бүген Мәскәүдә дүртенче тәүлегемне уздырам. Бүген дә кичәгедәй: «Бернинди дә яңалык юк шул, кадерлем», — дияр микән чибәр апа? А, юк, бүген ул мине аерата якын күреп, аерата сөйкемле елмаеп каршылады: «Ниһаять, секретарь кайтты, сезнең кәгазьләрне тапшырдым», — диде.

Йөрәгемнең ашкынып тибүен тоям. Минем язмыш озакламый хәл кылыначак. Сулышым кысыла; хәлсезләнеп, әлеге апа каршысында тик басып торам. Бераздан сорыйм. Нәтиҗәне белү өчен кайчан килергә соң? Апа куе буялган кызыл, матур иреннәре астындагы ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп тагын елмая: «Ашыкмагыз, — ди. — Әле сезнең документлар чират көтәчәк. Секретарь аларны карарга тиеш, аннан комиссия членнарына бирелер, шуннан соң инде комиссия карар чыгарачак. Ашыкмагыз. Мәскәү белән танышыгыз. Третьяковкада булганыгыз бар идеме? «Күләгәләр могҗизасы» кинотеатрына барыгыз, әгәр театрал икәнсез — Большойга керегез, хәер, алар хәзер гастрольдә булсалар кирәк...»

Ул, эшеннән аерылып, озаклап миңа карап тора. Елмая. Күрәсең, минем үзенә гашыйк булуымны тоя торгандыр. Әйе, тәгаен тоя, минем уңайсызлануымны да тоя торгандыр...

Мин тагын Мәскәү урамнары кочагында. Чыннан да, Третьяковка картиналар галереясына барырга кирәк, дип уйлыйм. Ниятләндем — киттем. Менә мин бөек рәссамнар иҗат иткән сурәтләр дөньясында. Монда йөрүләре бик күңелле, дөньяң бөтенләй онытыла. Сәгать ярымнар чамасы тамаша кылып, картинадан картинага күчкәннән соң, тәмам хәлдән таеп аяктан егылыр дәрәҗәгә җиттем. Җитмәсә, иртәнге ашым да такы-токы булган иде. Бер стакан чәй дә, йөз грамм кильки белән икмәк. Андый гына азык минем кебек егерменче яшьне куган егеткә җитәрлекме соң?...

Урамга чыгам да, якындагы ашханәгә кереп, тамак туйганчы аш ашыйм. Инде нишләргә? Тукта, минем финанс хәлләрем ничегрәк икән соң? Ашка акча түләгәндә янчыгым артык юкаргандай тоелган иде. Кул юу бүлмәсендә, яшеренеп кенә, акча саныйм. Йөземнең агарып китүе, битемнән кан качуы үземә дә сизелә. Йа хода, минем акча бөтенләй бетә язган лабаса! Ничек яшәрмен мин, ничек туенырмын. Алда әле ми-

нениләр көтә? Ничә көн Мәскәүдә ятачагымны кем белгән?! Бәлки, өйгә телеграмма сугаргадыр? Юк, бусы мөмкин эш түгел, мондый кагыйдәне мин белмим. Бары шуны беләм: өйдә дә акча, кем әйтмешли, чебен чукындырырлык кына.

Калган акчамны икегә бүләм. Аның бер өлеше — Хәдичә апага. Рәхмәт төшкере, бер сүз дә дәшмичә, сабыр гына көтә бит. Тәгаен, ул минем бик мөһим эш майтарып йөрүемне тоядыр. Миннән, урынны кайчан бушатасың, дип тә сорамый, кайчан акча бирергә уйлыйсың дип тә әйтми. Ә минем акчам...

Миңа бит әле юлга, билетка да акча калдырырга кирәк. Янчыгымны яңадан кесәдән чыгарып, аның бер бүлегенә билетка дигән акчаны санап салам. Калган акчаны яңадан икегә бүләм. Моның бер өлеше — туену өчен. Тик мин аны, Мәскәүдә булачак көннәр санына карап, тиенен тиенгә аерып куярга тиеш. Ләкин ничә көн торырга тиеш соң әле мин биредә? Бу кадәресен берничек тә билгели алмыйм. Шуңа күрә, бүген үк яңадан җир эшләре комиссариатына кереп, эшнең торышын ахырынача белешергә булдым. Теге сөйкемле апа, һәрхәлдә, әйтә алыр; һәрхәлдә, минем кебек еракгtан килгән кешеләрнең эше ничә көндә әйләнеп чыкканын әйтер. Анысы шулай, тик мин үзем дә хәзер акча хәлләрен чамаларга тиеш. Бик-бик кысып тотканда ничә көнгә җиткереп булыр икән аны?

Мин акчаны, ачтан үлмәслек чыгымга исәп тотып, көндәлек хисапка бүләм. Кильки һәм арыш ипие ашап кына торып буламы? Бик була. Димәк, шуннан чыгып исәп-хисап ясыйбыз. Болай ярыйсы чыга. Акча унбиш көн яшәрлек. Ә ул арада җавап бирелми калмас. Яшибез болай булгач!

Тынычлана төштем. Тирә-юнемне күзәтеп утырам. Сквер рәшәткәсе яныннан ук чыңлап трамвайлар уза. Урамнан бер-бер артлы автобуслар, йөк машиналары йөгерешә. Мәскәү урамнарындагы хәрәкәт бер генә минутка да өзелми. Якында гына иске өйләрне сүтәләр, ә урамның теге ягында искитмәле зур таш бина салына.

Мин шуларны күзәтәм. Аннан, ялыга төшкәч, бакча эчендә берән-сәрән күренгән кешеләрне карап утырам. Күрше эскәмиядә олыгайган юан абзый газета укый. Аның башында зур козыреклы кепка, өстендә шактый таушалган җәйге соры пальто. Пенсионер-фәлән дер. Ә арырак — газонның теге ягында — яшь бер хатын, бала арбасын тирбәтә-тирбәтә, китап укып утыра. Бала... Балачак...

Үзем дә сизмәстән, мин тагы уйлар, истәлекләр дөньясына чумам. Үземнең балалык елларымны хәтерлим.

Беренче тапкыр мин үземне кайчан белә башладым соң әле? Бу унтугызынчы елның җәе иде булса кирәк. Без — әти, әни, мин — Троицк шәһәренең Амур дип аталган ягындагы өсте агач, асты таш өебезнең подвалында утырабыз. Үрдән, вокзал ягыннан очкан туп снарядлары гөрселдәп шартлый. Мин әниемә сыенам. Ә дымсу, тузанлы подвалда бер без генә түгел, кеше күп; алар, снаряд шартлаган саен, нидер сөйләнәләр, кычкырып куялар, укыналар. Ләхәүлә, аллам, үзең сакла, диләр.

Ә инде шул шомлы төннең иртәгесе көнендә күргәннәрем хәтердә аеруча нык саклаңган. Төнлә подвалда ниләр булган, кайчан өйгә кергәнбез — монысын анык кына әйтә алмыйм, бәлки, мине йоклаган килеш алып кергәннәрдер. Әмма ачык хәтердә: иртән күземне ачып җибәрүгә, өебезнең алгы бүлмәсендә мин ят рус кешеләрен күреп аптырашка калдым. Алар гимнастеркалардан, ыштырлы ботинкалардан иде. Болар төнлә безнең шәһәрне тупка тоткан Колчак гаскәрләре икән. Безнең калага таң аткач килеп кергәннәр; ә хәзер алар, аерым өйләргә таралып, ял итәләр.

Караваттан төшеп, зал якка йөгереп чыктым да тәрәзәгә ташландым. Урамдагы күренеш хәйран калырлык. Безнең урам бик киң

Кала як урамнары белән чагыштырырлык та түгел, үзе ком белән капланган, буп-буш, бер генә агач заты да үсми анда. Шул киң урамга туплар тезеп куйганнар. Аларның дәһшәтле, кара-яшел еландай өскә караган көпшәләренә күн түбәтәй кидертелгән.

Алгы бүлмәне үзләренең капчыклары, винтовкалары һәм махорка төтене, мылтык мае исе белән тутырган, идәнгә сузылып яткан солдатлар мине аерата бер кызыксыну белән каршы алдылар. Аларның күпчелеге сары мыеклы булып истә калган. Менә алар минем белән шаяртып сөйләшәләр, миңа нидер әйтәләр, миннән нидер сорыйлар. Ләкин мин аларның сүзләрен аңламыйм. Берсе русча сөйләшергә өйрәтә башлый. Берәүсе миңа алюмин кашык бирә: бүләк, янәсе. Шул солдатлар өйрәткән җыр әле дә хәтердә саклана. Ул болай:

Цыганочка Аза, чего тебе надо?
Ничего не надо, кроме шоколада.

Бу аклар ягындагы солдатлар бездә берничә көн торганнан соң киттеләр. Кызыл гаскәр аларны Троицкидан тиз өреп чыгарды.

Тагы бер күренеш хәтердә. Мин, әти-әни белән, бабамның элекке дачасында. Дача шәһәрдән ун-унбиш чакрым ераклыкта. Без шул дачада кунакта. Әйе, хуҗалар түгел, кунак сыйфатында без монда. Чөнки ул дачада хәзер ятим балалар яши. Балаларның тәрбиячесе Суфия апа — әниемнең дусты, элегрәк алар бер мәктәптә укыткан-нар. Без шул Суфия апага кунакка килдек.

Дача өе искиткеч матур, иркен, аның ике ягында да балконнар бар. Бу ике катлы өйнең түбәсе калай, яшелгә буялган, тышкы стеналары такта белән коршалган. Эчтә әллә ничә бүлмә, бик иркен зал.

Без әнием белән балконда җәйге иртәнең хозурлыгын карап торабыз. Тирә-ягыбызда куе агачлык, кошлар сайрый. Кинәт әнием мине күтәрә дә:

— Бу якка карале, улым,— ди,— күрәсеңме, әнә һөд-һөд!..

Минем андый кош күргәнем юк иде әле. Кош өй кыегы янындагы агач ботагында. Үзе бүрекле, шундый сәер, томшыгы без кебек очлы, ә кошның өсте аклы-каралы таплар төшкән кызгылт-сары. «Һөд-һөд, һөд-һөд»,— дип сайрый кош. Юкка гына шул исемне бирмәгәннәр икән үзенә...

Без өчәү — әти, әни, мин — дачадагы бакчада йөрибез. Дүрткел итеп казылган тирән чокыр янына килеп чыгабыз. Бу чокырның сәерлеге шунда: ул юка гына кара туфрак катламы астындагы тоташ ап-ак балчыктан тора. Ап-ак, саф, сөт кебек балчык ул. Әти чокыр төбеннән йодрыгы зурлыгында балчык каерып алды да: «Йә, нәрсә ясап бирим, улым, үзеңә?» — дип сорады. Мин беләм: әти теләсә нәрсә ясап бирә ала. Тик нәрсә ясатырга икән соң бу ак балчыктан? Озак уйламастан: «Өй яса, әти!» — дидем. Хәтеремдә: ул өй бик матур булачак иде. Бер катлы өй, түбәсе каен тузы белән ябылган, тәрәзәләрендә чын пыяла. Баганалы болдыры да бар. Кыскасы, барлык шартын җиткереп эшләргә тырыша әти. Мәгәр өйне дачада гына төгәлли алмады, эшен без өйгә кайткач та дәвам иттерде. Мин аның яныннан китмим. Исем-акылларым китеп, аның осталыгына сокланып торам. Тик, кызганычка каршы, әтием ул өйне очлап чыга алмады. Әйе, мин үсә төшкәч аңладым: әтиемә эштә, аның һәр гамәлендә эзлеклелек, түземлелек җитми иде. Әйе, ул — эш кешесе түгел, хис һәм хыял кешесе. Ул, чалкан яткан килеш, түшәмгә карап, сәгатьләр буе хыялланып, нидер уйлап ята ала. Әгәр андый вакытта аңа берәр кеше текәп караса, ул уңайсызланып елмая, борын аша гына «һе» дип көлемсерәгәндәй итә һәм, күрәсең, тагын үзенең татлы хыялларына чума.

Зәйнулла бабай, әтием мәдрәсәне тәмамлау белән, улым русча

да укысын дип, аны берзаман Петербургка җибәрә. Ләкин эти, беренче авырлыклардан соң ук, русча укудан гайрәте чигеп, яңадан Троицкига кайта. Бабам аны тиз генә кайтып җитәргә мөмкин булмаган ерак җиргә — Истанбулга укырга җибәрергә мәҗбүр. Эти шунда өч ел укып, төрек гимназиясен бетереп кайта.

Читкәрәк чыгып киттем булса кирәк. Мин бит әле үзем турында, үземнең балалык елларым турында сүз башлаган идем.

Гаҗәп, ни өчендер мин сабый чагымның иртәнге чорын артык начар хәтерлим. Аның кайбер кыйпылчыклары гына исемдә сакланган.

Мин эти-әниемә бердәнбер бала булып үстем. Әниемнең сөйләвенә караганда, минем сеңлем дә булырга тиеш икән, ләкин ул, тугач, озак яшәмәгән. Гадәттә, бердәнбер баланы бик иркә булып үсә диләр. Әнием мине кечкенә чагымда, чыннан да, бик иркәли иде, битләремнән үбә, миңа «иркә таем» дип дәшә иде. Эти исә бик сирәк иркәли, ничектер ул мине иркәләргә ояла сыман, алай да ара-тирә аркамнан сыйпап куя. Үзе белән урамга алып чыкканда миңа һәрвакыт балачакта ук ит тарту машинасында бер буыны өзелгән имән бармагын тоттыра.

Алар миңа беркайчан да кул тигермәделәр. Әмма артык узындырмадылар да. Мин җәй башында ук аяк киемнәремне салып ташлыйм, җәйне яланаяк уздырам, чәчем кышын да, җәен дә машинка белән алдырылган булыр. Мәктәптән кайткач, үзем теләгән кадәр «шайтан чабам». Этинең йә әнинең мине эзләп урамга чыкканнарын хәтерләмим. Җәен өстә бер кат ситсы күлмәк, тездән әз генә түбән кыска балаклы чалбар. Башта — түбәтәй яки кепка. Өс киемнәремнең барысын да, хәтта кепканы да әни үзе тегә. Язгы пычракларда аякларның «чебиләве», әниемнең елата-елата минем аякларны ләгәндә юган чаклары әле дә истән чыкмый.

Егерме беренче елгы ачлык Троицкида да авыр узды. Халык ачыкты, шешенүчеләр күп булды, күпчелек кеше алабута икмәге ашады. Кеше ашаучылар тотылган икән, дигән хәбәрләр дә таралды.

Әйе, тагын америкалылар ачкан кухняга йөрү истә. Ул бездән шактый ерак, теге очта, чиркәү тирәсендә. Без шунда чират торып, какао, татлы дөге боткасы алабыз.

Минем эти-әни хәрби коммунизм чорында совет мәктәпләрендә укыттылар. Шул көннәрдән истә калган бер күренеш. Бездә бер ят кунак утыра. Этинең күптәнге танышы, читтән килгән кеше булса кирәк. Эти аңа укытучылар өчен шәһәр күләмендә уздырылган бер җыелыш турында сөйли. Шунда үзәктән килгән комиссар укытучыларны партиягә керергә өндәгән икән. «Юк инде,— ди эти,— безне алай тиз генә кармакка эләктерә алмассыз, дидек тегеңә. Татар мөгаллимнәреннән беркем дә язылмады. Мөмкинме соң! Әле бер власть, әле икенчесе хакимлек иткән заманда большевиклар кыйбласына табынып, алар арбасына җигелү мөмкинме? Алла сакласын!..»

Мин, әлбәттә, ул вакытта булган хәлләрнең барын да төгәл хәтердә саклый алмаганмын. Әмма ачлык елны этиемнең дә, әниемнең дә мәктәптә эшләмәгәнлеген беләм. Мәктәпләр эшләмәде ул елны. Әни өйдә хуҗалык эшләре белән генә шөгыльләнде, ә эти исә, башкорт ягына китеп, үзебездән арткан кием-салым, өй кирәк-яракларын икмәккә алыштырып йөри башлады. Ул агачтан махсус сандык ясады, аңа чана табаннары беркетте. Ул башта Аргаяш станциясенә кадәр поездда бара, аннан башкорт авылларына җәяүләп китә.

Эти сәфәрдә чакта без әнием белән идәненә киез җәелгән кечкенә бүлмәбездә утырабыз. Керосин юк, булса да, теге кем әйтмешли, күзгә кырып салырлык кына. Шуңа күрә халык лампа урынына куян тизәгеннән файдалана. Ул, туң майга батырып ут төрткәч, филтә вазифасын үти. Май, төтәмичә генә янып, сыек яктылык бирә. Әнием шул яктылыкка китабын бик якын куеп, миңа кызыклы роман-

нар укый. Китап төрекчә булса, аны шундук тәрҗемә итә. Шулай да минем хәтердә күбрәк сакланганы мондый вакытларда әниемнең тегү-чигү, ямау-ялгау белән шөгыльләнүе. Бервакыт ул кепка тегү белән мавыкты. Ул заманнарда җиде өлгеле кепка модада иде. Бусы инде, ачлыкның газаплы кышы узып, яз кергәч булса кирәк. Әйе, әнием кепка тегә. Әйткәнемчә, ул кепка җиде өлгеле, нәкъ түбә уртасында аның күннән ясалган төймәсе дә бар. Төймә ясау миңа ышанып тапшырыла. Ул эш ифрат кызыклы. Башта күннән бармак башы зурлыгында түгәрәкләр кисәсең, аннары нәкъ уртасына энә чәнчеп аны ут өстендә бераз вакыт тотасың. Күн куырыла башлый, түгәрәкнең читчите, бөрешеп, эчкә кайтарыла һәм кечкенә генә бик матур төймә хасил була.

Гомумән, әнием тегү-чигүгә бик оста. Күрәсең, бу эш аңа канәгатьләнү бирә. Әле мин үсмер егет булгач та, ул миңа күлмәк-чалбарны үзе тегеп кидерде. Ә теге кепкалар тегү НЭП чорында аерата кызды.

Минем барлык дус-иш ул чак сәүдәгә кереште. Һәрберсендә — муенга асылмалы агач тартма, һәрберсе бик эшлекле кыяфәттә табыш турында сүз йөртә. Берише — папирос, икенчеләре — шырпы йә булмаса көнбагыш, кабак орлыгы белән сату итә. Минем дә күрше малайлары кебек сәүдә итәсем килә. Әнидән бик-бик үтенеп, миңа «товар» бирүен сорыйм. Әни моны теләми. Ләкин соңыннан минем ялынуларыма каршы тора алмый, риза була. Кечкенә генә бер катыргы тартма табабыз; муенга асар өчен аңа бау бәйлибез. Әнием үзенең кадерләп саклаган дәфтәр-карандашларыннан, каләм-бозгычларыннан миңа өлеш чыгара. Һәм мин, куанычымнан авызымны җыя алмаган хәлдә, Кала якка базарга йөгерәм.

— Башта бәяләрен сораш, улым,— дип кала әни.

Базар Кала якта, күперне чыккач та. Анда иркен мәйдан, шунда — һәр көн кайнап торган шәһәр базары. Мәйданның күпергә якынрак өлешендә авыл сәүдәсе, биредә — җәен кавын-карбыз, бәрәңге, шалкан, мал-туар, кышын — күбрәк ашлык һәм печән сатыла. Мәйданның шәһәргә якын очында вак такта кибетләр тезелеп киткән. Нэпман кибетләре. Ә бу кибетләр белән авыл сәүдәсе арасында базарның иң кайнар җире — «талчок». Менә шунда инде минем сәүдә итү урыным. Мин, иптәшләрем кебек бик батырланып кычкыра-кычкыра, үз товарымны тәкъдим итәм. Кызыксыналар, хәтта әйләндереп алалар. Кайберсе хәтта дәфтәрләрне тотып, мактый-мактый тел шартлата, карар өчен күршесенә дә бирә. Күрәм, мине сарып алган апалар, абыйлар, әле генә мине: «Нәни сәүдәгәр, менә нинди булырга кирәк ул!» — дип мактаган кешеләр: «Бик кыйммәт сорыйсың шул, балакай»,— дип, таралыша башладылар. Мин шунда гына тартмамдагы әйберләрнең нык кимегәнлеген тоям, ни әйтергә дә белми өнсез калам. Ни арада булды соң бу хәл? Юкса минем «товар»ны кулдан-кулга йөртеп караганнан соң кире салганнар кебек иде бит. Әллә инде «күз буу» дигәннәре шул микән?

Минем сәүдәгәрлек кәсебем күз яшьләре белән тәгәлләнде. Берничә тиен иске бакыр акча тотып, үкси-үкси өйгә кайтудан башка юл калмады. Җитмәсә, әнием өйдә, елаудан шешенеп беткән улын кызганасы һәм рәхимсез каракларны хурлыйсы урында, миннән көлеп тора.

Шулай итеп, мин сәүдә эшләренә икенче тыгылмас булдым.

### 6

Безнең гаиләдә хәзер биш кеше: әти, әни, әниемнең әнисе — дәү әни, безнең хезмәтче кыз — Мәгъмүрә апа һәм мин. Без Зәйнулла бабайдан әтигә мирас булып калган йортта. Мәгъмүриянең (татарлар

Амур ягын шулай атый) иң зур урамындагы өебездә яшибез. Аста — фатир керүчеләр. Өйалды иркен, аның бер почмагында җылы бәдрәф, эчке якта кечкенә генә чолан. Мин шул чоланда ике тапкыр авырып ятканымны хәтерлим. Беренчесе — сөннәткә утыртылганнан соң, икенчесе — кызамык чыккач.

Өебезнең без яшәгән икенче каты — өч бүлмәле. Урам якка караганы — зал. Аның идәненә кызыл төстәге калын хәтфә келәм җәелгән, уртада — зур өстәл, тәрәзә араларында идәннән түшәмгә җиткән көзге, почмакларда кышын-җәен өзлексез чәчәк ата торган роза гөлләре, стена буенда затлы утыргычлар, сырты залга чыгып торган мич янында зур иркен сандык. Онытылмасын: таза бүрәнә стеналарда — шәмаилләр һәм ике фазан кошы сыны, ә түшәмдә — өстәл турысында — кырыклы лампа. Бу лампаны әти, утыргычка басып, бәйрәм кичәләрендә, йә кунаклар киләсе кичтә генә яндыра.

Алгы ике бүлмәдә әллә ни җиһаз юк безнең. Ишектән кергәч тә — уң кул якта — йокы бүлмәсе, анда караватлар, бер кечкенә өстәл, артсыз утыргычлар, ә зал алды бүлмәсендә — мич, тимер караваt, түгәрәк көрси өстәл. Тагын йокы бүлмәсенең стенасында — келәм һәм Габдулла Тукаев портреты. Кечкенә бүлмәнең идәненә ак киез җәелгән.

Безнең булган байлык-мөлкәтебез, башлыча, Зәйнулла бабай калдырган мирас.

Мин дәү әни белән залда йоклыйм. Дәү әни мич янындагы сандыкта, ә мин — идәндә. Хәер, кышкы озын төннәрдә куркыныч төшләр белән сатышып уянган һәм йоклый алмый азапланып яткан чакларда, әтиләр йоклый торган алгы бүлмәгә чыгып, сораусыз-нисез әни белән әти арасына кереп ятам.

Дәү әнием соргылт күзле, йомры гына гәүдәле; күңелле итеп, чистайлыларга хас йомшак мишәр шивәсендә сөйләшә, ачык һәм елдам карчык. Гомеренең иң күп өлешен, ишле бала белән яшьли тол калып, ятимлектә уздырган кеше ул.

Сүзне аның турында башлагач, аның гаиләсенә кагылып, башта аның олы улы — гаилә терәге — Шакир абыйга тукталмый булмый. Шакир абый зур карчыга борынлы, әниемнеке кебек коңгырт кара күзле, ачрак озынча яңаклы, уртадан түбән буйлы, ифрат сөйкемле, нәзакәтле кеше. Бала чактан ук кагылып-сугылып яшәвенә һәм «мәптек»кә өч-дүрт кыш кына йөрүенә карамастан, үзлегеннән укып белем һәм әйбәт кешелек сыйфатлары үзләштергән, тырыш, акыллы кеше. Әниемнең әтисе, ягъни минем Хәйдәр бабай үлгәч, Шакир абыйга унөч яшь тулыр-тулмастан, аны дәү әни ерак туган тиешле Кизил сәүдәгәре Гали Дербышевка малайлыкка биреп җибәрә. Шакир абый мнңа байның туган тиешле кеше исәпләнүенә карамастан, соң дәрәҗәдә рәхимсез булуын бер тапкыр гына сөйләмәде. Гали бай, ачуы чыкса, бөтенләй котырынып, Шакир абыйны кыйный торган булган. Менә шундый типке, рәнҗетелү-изелү астында байга хезмәт итә Шакир абый. Күрәсең, шушы хәл аңарда байларга карата нәфрәт уяткандыр инде. Бишенче ел революциясе көннәрендә үк ул баена каршы баш күтәрүне оештыра. Ахырдан, шул ук Гали Дербышевта малайлыкта хезмәт иткән энесе Габдрахманны ияртә дә, исәп-хисап ясауны сорап, бай янына керә. «Юк, бернинди акча да бирмим мин сезгә», — ди Гали абзый. Ничектер, туганлык хисләре уянган бер минутта, бай Шакир абыйга иске куен сәгате биргән була. Шакир абый шул сәгатьне Гали абзый алдына сала. «Бүләгеңне кире кайтарам, инде дә аны ихластан биргәнсең икән, шул сәгать урынына безгә юллык акча бир», — ди. Бай йомшара төшә, боларга Казанга җитеп егылырлык акча бирә.

Шакир абый белән Габдрахман абый, шулай итеп, Кизилны ташлап Казанга китәләр. Анда Шакир абый Болгар кунакханәсе

астындагы Бәхтиевләр магазинына приказчик булып урнаша, ә Габдрахман абый якындагы бер хәрчәүнәгә половойлыкка яллана.

Бишенче елгы революцион хәрәкәт Шакир абыйның күңеленә бик нык сеңгән була. Ирек өчен булган көрәш дәрте Казанга килгәч тә кимеми, ул монда да приказчиклар өчен профсоюзлар төзеп дәртләнеп йөри. Бәлки әле аңа Казандагы революционерларның тәэсире дә булгандыр. Һәрхәлдә, ул Казанда да тынгысыз була. Ниһаять, уникенче елны, үзе белән бер төркем приказчик ияртеп, байга бойкот йөзеннән эш ташлап, Троицкига китеп бара. Ул Троицк миллионеры Яушевларның сәүдә йортына урнаша.

Сөйләвенә караганда, тормыш Троицкида чагыштырмача җиңел була. Аның миңа: «Унике сумга бүлмә алып фатирга кердем, шул хак исәбенә хуҗабикә керләремне уз урын-җирне карый һәм һәркөнне өч тапкыр кайнар аш ашата иде» — дип сөйләгәне бар.

Россия белән Казахстан далалары чигенә урнашкан, яртылаш диярлек татардан торган Троицк шәһәрендә дә Шакир абый тик ятмый. Ул, шәһәрнең алдынгы яшьләре белән берлектә, үзешчән ансамбльләр, аннан театр труппасы оештыра. Аның шул чакта төшкән фотолары миндә әле дә саклана. Аның белән бергә спектакльләрдә катнашып йөргән кешеләрдән, мәсәлән, Ш. Урманаевның (заманында ул Казандагы академия театрының администраторы булган кеше) Шакир абыйның талантлы артист булуын һәм баш рольләрне башкарганлыгын сөйләгәне бар.

Шакир абый озак кына буйдак булып яшәде. Ул, Троицкига килеп ныклап шунда төпләнгәннән соң, 1913 елны үз янына Чистайдан дәү әни белән минем әниемне дә алдырта. Әни ул вакытта Буби кызлар мәктәбен тәмамлаган була. Ул, Троицкига килү белән, шундагы кызлар мәктәбендә укытучы булып урнаша.

Мин белгәндә дәү әни белән Шакир абый шәһәрнең Кала ягында яшиләр иде. Беренче булып истә калган хатирә унсигезенче елларга туры килә булса кирәк. Без, әнием белән, Шакир абыйларда кунакта. Шакир абый караватка яткан килеш кенә тәмәке тарта. Миңа бу эш гаҗәп күңелле тоела. Аның миңа да папирос суыртуын даулый башлыйм. Ул, ярамый, ди. Ә ярамыймы? Мин җәнҗал куптарып, акырып җыларга тотынам, тәмәкесен тартып алыр өчен кулларымны сузам. «Мә, алайса» — ди Шакир абый, папиросын минем авызга төртә. Шатланып, ифрат тәмле тоелган папиросны суырам һәм тончыгып йөткерергә, укшырга, шундук тагын да катырак еларга керешәм. Шакир абый көлә, дәү әни белән әнием Шакир абыйны орышалар.

Әнием миңа бик яшьли мөстәкыйльлек тәрбиясе сеңдерде. Оясында ни булса, очканында да шул дигәндәй, әнием үзе ятимлек һәм фәкыйрьлектә үсеп, бик иртә тормыш йөген тарта башлаганга күрә, мондый хәлне табигый дип исәпләгәндер, миңа да бу кагыйдәне сеңдерергә тырышкандыр, дип уйлыйм.

Әни мине тиешенчә киендерә, кулыма дәү әниләргә дигән күчтәнәчне тоттыра һәм, юлда сак булырга кирәклеген кабат-кабат тукып, мине озатып кала.

Мин Амурның комлы урамнарын ашыкмый гына узам, күпер башы Сабир абзыйның такта кибетенә тукталып, киштәдәге әйберләргә үрелеп карап торам. Хуҗаның: «Ни кирәк, малай?» — дип соравы гына юлымны дәвам иттерергә бер сәбәп була. Мин күпергә таба юнәләм. Ә ул күпер искиткеч зур, биек, озын.

Шундый зур күпер аша чыгу минем өчен ифрат күңелле бер сәяхәт. Мин, әледән-әле тукталып, әллә кайда, аста агып яткан елгага озаклап карап торам. Анда ташбашлар өерләре белән йөзеп йөри. Су күпер баганалары янында чоңгыллар ясый, субайларга бака ефәкләре чорный. Мин, күпер таянсасының терәүләре арасына

башымны тыгам да, дөньямны онытып, шуларны карап торам. Кайчагында, белгән кеше очрап, мине айнытып җибәрә:

— Нишләп йөрисең монда, Атиллә?

— Дәү әниләргә кунакка барам,— дим мин горур гына.

Кайчак артымнан сукранып әйтелгән сүзләр дә ишетелә: «И ходаем, гөнаһысыннан курыкмыйча, бот буе баланы ничек ялгызын гына чыгарып җибәрәләр икән?!»

Мин, сул якны шактый вакыт күзәтеп ялыккач, күпернең уң ягына йөгереп чыгам. Монда, биек яр өстендә, Амурның мәһабәт чиркәве калкып тора. Шул инде, үзенең адәм биеклегендәге кыңгырауларын даң-доң кагып, Амур халкын йокыдан уята, мөселман әһелен сукрандыра. Амурның чиркәү ягы — рус төбәге. Чиркәү тирәсендә тимер түбәле төзек зур өйләр тезелгән. Без бу тирәгә зурлар белән генә килергә җөрьәт итәбез. Юкса, рус малайлары безне күрү белән сугыша башлыйлар.

Елганың сул ягында иркен базар мәйданы җәелеп ята. Әле мине кызыксындырган нәрсә — такта кибетләр рәте. Алар һәркөн иртәдән кичкә кадәр ачык. Татар сәүдәгәрләре — җомга, руслар якшәмбе көн генә кибетләрен ябып торалар.

Бу бәләкәй кибетләрдә ниләр генә сатылмый! Әлбәттә, минем һушымны алганы — уенчыклар. Мин шуларны күздән кичерми китә алмыйм. Йа, хода! Уенчыкларның ниндие генә юк бу кибетләрдә: кәкре муенлы алмачуар атлар, кургашын «пугач»лар, ялтыр көпшәле пистолетлар. Мин беләм, ул «пугач»ларның ядрәсе балчыктан катырылган, атканда утлар чәчрәтеп шартлый. Инде пистолетны кәгазь пистоннар белән корасың. Ул да ярыйсы шартлый. Тагын бу кибетләрдә дәфтәр битләренә, альбомнарга күчерелә торган, күзләреңнең явын алырлык матур чәчәк сурәтләре төшерелгән кәгазьләр дә сатыла. Беләм, аны йөзе белән чылатып дәфтәр битенә каплыйсың да, кәгазен юеш бармак белән ышкып каезлый башлыйсың. Берзаман кәгазь уалып бетә, ә кәгазь астындагы искиткеч матур чәчәк синең дәфтәр битендә мәңгегә истәлек булып кала.

Базар мәйданы олы тамашалар урыны вазифасын да үти. Анык кына хәтерлим, җәйнең кайсыдыр аенда анда ярминкә уздырыла, шул вакыт читтән килгән кешеләр, зур чатырлар корып, цирк тамашалары күрсәтәләр, карусель эшли. Бервакыт анда күкләргә ашкан биек колгалар утырттылар, арасына тимерчыбык тарттырып куйдылар. Күп тә үтмәде, шул тимерчыбыкта йөрүче үзенең хикмәтләрен халыкка күрсәтте. Ул кеше үзбәк иде булса кирәк. Башына чалма чорнаган, күлмәк-ыштаннан, кулына озын колга тоткан бер кеше иде ул. Халык дәрьясы, тынын кысып, хәйран калып, тавышланырга да кыймастан аны күзәтте. Менә, ниһаять, безнең шатлыгыбызга каршы, ул өскә, ике колга арасындагы чыбык өстенә менеп басты. Менә ул шунда йөри. Бер алга бара, бер чигенә. Мин, дәһшәтләнеп, теге кеше егылып төшмәсен тагы дип, тетрәнеп, тамашаны күзәтәм...

Базардан чыгам да, аннары шәһәр үзәгенә таба юл алам. Юлымда очраган сәер киемле рус абыйларга һәм апаларга тукталып карап та торгалыйм.

Дәү әни мине: «Улым килгән, улым!» — дип шатланып каршы ала, безнең өй хәлләрен сораша. Мин аларда дәү әниемнең хас мин килер дип саклаган тәмле-томлысын ашап чәй эчәм. Аннан кинәт минем өйгә кайтасым килә башлый. Чөнки миңа монда күңелсез. Дәү әни үзенең эше белән мәшгуль, сөйләшәсе сүз сөйләшендә уйнарга берниндә дә иптәш юк. Шакир абый өйдә булса, әлбәттә миңа күңеллерәк, чөнки ул минем белән көрәшкән булып шаяра. Ләкин анысы да бик озак дәвам итми, ул йә чыгып китә, йә караватына ятып газета укырга керешә.

Мин әле искә алган вакытларда Шакир абыйның кайда ни эшләгәнен төгәл генә әйтә алмыйм. Әмма шунысы ачык, ул артистлыгын ташламаган иде. Чөнки хәрби коммунизм азагында, үзен гомергә сәхнә эшенә багышлап, татар труппасы белән ул Урта Азиягә китеп барды. Дәү әни бездә калды, ачлык елында бездә яшәде.

Шакир абый шул китүеннән Урта Азиядә бик озак гомер сөрде. Труппа таркалу аркасында булса кирәк, артистлыгын ташлап, элекке һөнәре буенча совет сәүдә оешмаларында эшләде. Соңарып кына өйләнде. Бөек Ватан сугышы алдыннан гына Казанга кайтты.

Бездә берничә ел яшәгән Мәгъмүрә апа турында да җылы сүз әйтәсе килә. Ул бик ягымлы, мин белгәндә инде җиткән кыз иде. Тыгыз бәдәнле, каратутлы, кара күзле, эшләп үскән авыл кызы. Куе кара чәчен уртадан шомартып тарап ачкан, юан чәч толымын алга, калку күкрәгенә төшергән. Әни аны булдыра алганча матур киендерә иде. Алар өй эшләренең авырлыгын бергәләп күтәрәләр. Кер юумы, бәйрәм алдыннан пешеренүме, кунак җыйганда әзерләнүләрме — барысы да бергә эшләнә. Аларның андый вакытта бергә бик дус булып киңәшеп, тирләп-пешеп, тырышып эшләүләрен бик ачык хәтерлим. Шуңа күрә, минемчә, Мәгъмүрә апаны асрау кыз дип әйтү дә минем өчен читен; дөресен генә әйткәндә, бездә тәрбияләнүче бер ятимә иде ул.

Мәгъмүрә апа, ачлык елы узгач, кияүгә чыкты. Аның кияве солдат шинеле кигән буйчан, ачык бер яшь кеше булып истә калган. Туйның булу-булмавын хәтерләмим. Юравымча, Мәгъмүрә апа бездән киткәч кияүгә чыккан булса кирәк. Мин бары, алар өйләнешкәннән соң, әнием белән аларда бер булуыбызны гына хәтерлим. Минем аптыравыма каршы, аларның фатиры көндезен дә караңгы иде. Мәгъмүрә апалар тәрәзәләре капланган нинди дер ташландык өйдә торганнар, ахры, ул вакыт. Ихтимал, ул егете белән яшерен генә кавышкандыр.

## 7

Ачлык елыннан соң беренче җәйдә әтиемне Троицкидан шактый ерак бер башкорт авылына мәктәп директоры итеп билгеләделәр. Авылның исеме хәтеремдә анык сакланмаган, бары шуны гына әйтә алам: аның исеме күл белән бәйләнешле иде. Чуаркүл атлы булмады микән ул авыл дип кенә гөман кылам.

Хәтеремдә, без анда нинди дер хәлле кешенең өендә, шулар гаиләсендә бераз яшәдек. Хуҗаның атлары күп иде. Һәр көн малайлар шул атларны берничә тапкыр күлгә су эчерергә алып баралар. Истә калганы тагын шул: көннәрдән бер көнне,— күрәсең, үзем даулаганмындыр,— мине дә атка атландырдылар. Билгеле, ияр-фәләнсез, аска капчык-мазар салдылар микән — анысын да белмим. Атка менеп утырганнан соң булган беренче тәэсир әле дә истә. Читтән караганда ат өстендә бару бик җайлы күренсә дә, бу һич тә дөреслеккә туры килми икән. Чөнки атның чыгып торган сырты шул кадәр авырттыра, ирексездән әле бер, әле икенче якка авышасың. Беренче көнне үк булмагандыр, берничә көннән соң булса кирәк, малайлар мине дә үзләре белән ат эчертергә күлгә алып барырга булдылар. Мин бик шат инде моңа. Кая ул! Малайлар белән атка атланып бар әле!

Ләкин минем шатлык озакка сузылмады. Авылдан чыгу белән малайлар атларын чаптыра башладылар. Минем ат та, дулап, кошаяклап сикереп чабарга тотынды. Мин исә, тигезлегемне саклый алмыйча, җиргә очып төштем. Бәхетсезлеккә каршы, ат өеренең ур-

тасына килеп эләккән идем. Атлар минем аша сикерә. Билгеле инде, әгәр бер ат миңа басып узса, минем кечкенә гәүдәм сытылып беткән булыр иде. Әмма, искитмәле хәл, бер ат та басмады миңа, бары бер атның тояк очы гына аркамны сыдырып узды. Мине өйгә кем, ничек алып кайтканын хәзер анык кына әйтә алмыйм. Ләкин, күптәнге төш кебек, әти-әнинең минем өчен кайгырулары истә. Авырып ятканымны да тонык кына хәтерлим. Әти дә, әни дә алай башбаштакланырга ярамаганын, тәртипле, акыллы булырга кирәклеген миңа шактый аңлаттылар.

Без шулай яңа авыл, яңа тормыш шартларына күнегә башлау белән, әтиләрем анык бер фикергә килеп, шушы авылда төпләнеп калырга булганнардыр дип уйлыйм. Ә авыл, чыннан да, гүзәл, аның тирә-юнендәге каенлыкларын, ямь-яшел бәбкә үләне белән өретелгән урамнарын, авылга ямь биреп торган һәм шактый төзек агач өйләрен һич яратмаслык түгел.

Әти, Троицкида калган әйберләрне һәм дәү әнине алып кайту өчен, тиздән өйгә кайтып китте. Без исә әнием белән авылда, әлеге хуҗа өендә калдык.

Әти Троицкига кайткач ниләр кичергәндер, аның туган абыйсы Габдрахман Рәсүлев белән сөйләшүләре, аңлашулары ни рәвештә баргандыр — анысын белмим. Байтак еллар узганнан соң әниемнең сөйләгәннәреннән белгәнем шул: әти анда, абыйсының киңәшен тотып, гомергә төзәтелмәслек бер хата ясый.

Кыскача әйткәндә, вакыйга шуннан гыйбарәт: әти Троицкига кайтып төшкәндә, Кала яктагы алтынчы мәхәллә имамы үлгән була. Шулай итеп, алты мәхәлләнең берсе мулласыз калган. Әтинең абыйсы — ул вакытта абруйлы мөхтәсип, үзе белән көрешергә кергән әтине шул мәчеткә мулла булырга үгетли башлый.

Шулай итеп, без көннәрдән бер көнне дәү әнине ияртеп кайтасы әтиебез урынына мулла указы тоткан әтиебезне каршы алдык. Мин әле кечкенә бала, бу хәлнең минем барыр юлларымда нинди зур киртә булып торачагын ул чакны аңламыйм. Ләкин бу яңалыкның әнием өчен нинди тетрәндергеч бер нәрсә булуын шул вакытта ук төшендем. Бу эшкә әнием башта теше-тырнагы белән каршы торды, әмма соңыннан мәҗбүрән риза булды.

Кыскасы, без яңадан әтиемнең туган шәһәренә әйләнеп кайттык. Амур якта яшәү әтигә Кала яктагы мәчеткә йөрүне авырлаштырганга күрә, без үз өебезгә фатирчы кертеп, Кала якка күчәбез.

Әти хәзер, ак чапан, ак чалма киеп, безнең фатирдан бер чат кына арадагы биек манаралы мәһабәт таш мәчеткә намазга йөри. Әни — остабикә, мин — мәхдүм.

Әйткәнемчә, мин ул вакытта әле бөтенләй кечкенә җиде яшьлек бер бала идем. Һәм, күрәсең, барысы да шулай булырга тиеш дип уйланылгандыр. Хәер, алай дип тә булмый. Эшнең алай ук тормаганлыгын мәктәпкә кереп укый башлау белән төсмерләдем. Әтинең безнең тормышка кискен борылыш кертүе, кабатлап әйтәм, минем бөтен киләчәгемне, барыр юлларымны, минем генә дә түгел, әниемнең дә, хәтта үзенең дә тормыш юлын үзгәртте, авырайтты. Әйе, бу шиксез шулай. Әмма кем белә, әтинең бу эше аркасында минем хафалы юллар узуым бәлки файдага да киткәндер? Бәлки шул сикәлтәле юллар гына мине кеше, әдип иткәндер? Мин кайчак шулай дип юанам...

Алай дисәң, минем бу «сират күперләре»н уза алмыйча егылып калуым да ихтимал иде бит. Әнә, Габдрахман абзый Рәсүлевның кызы — минем яшьтәш, Наилә — шушы авыр юлларны җиңә алмыйча, акылыннан язмадымыни? Ул әле дә Уфада психиатрия шифаханәсендә ята бит. Ә нинди сөйкемле һәм, әйтер идем, һәр җәһәттән сәләтле бер кыз иде бит ул!..

Узылган юллар турында уйлансам, күңелгә төрлесе килә. Бүгенге тормыш кешелеккә арзанга төшмәде шул. Ул күп югалтулар, күп корбаннар бәрабәренә ялганды. Һәм бу югалтуларның, корбаннарның һәр ике ягы да жәл. Революция, Маркс әйтсән, юынтык су белән бергә, гөнаһсыз бәбиләрнең дә байтагын чүплеккә чыгарып ташлады.

Мин тагын үземнең балалык елларыма әйләнеп кайтыйм әле. Безнең Кала ягындагы хәзерге фатирыбыз — шәһәрнең татар халкы күбрәк булган очында. Безнең тирә-юньдә руслар бөтенләй юк диярлек. Безнең рәттә ике катлы, төзек каралтылы өйләр тезелеп киткән. Аларның күбесе — касапчы, сәүдәгәр яки ям чаптыручы булган кешеләрнең йорты. Хәер, безгә каршы якта гына берничә бәләкәй өй дә бар. Ул өйләрдә вак һөнәрчеләр, ломовойлар, «шурум-бурум»чы вак «талчок»чылар, һөнәрсез яки кул хезмәте белән көн күрүчеләр яши.

Безнең хәзерге фатирыбыз Амурдагы үз өебездән бер җире белән дә аерылмый дип әйтерлек — иркен, матур. Өй хуҗасы — Шакир абзый. Элекке сәүдәгәр, элек үзе яшәгән авыл кушаматы белән «Логовой Шакир» дип йөртелә торган җитмеш биш яшьлек карт. Безнең өйнең аскы катында руслашкан яһүдләр тора. Шакир абзыйлар үзләре капканың сул ягындагы бер катлы җыйнак кына флигельдә яшиләр. Безнең фатирның да, хуҗа яшәгән өйнең дә тәрәзәләре урам ягына караган. Иркен такыр ишегалды түрендә — тимер түбәле биек лапас, шул лапас астында ук амбар һәм мал-туар өчен аран. Шул ук лапасның уң кул ягында хуҗалар яши торган өйгә тоташтырып салынган кухня өе һәм мунча.

Яңа урынга күчү белән, мин үземә иптәшләр эзли башладым. Уйнарга иптәшем булмаганда мин бөтенләй төшенкелеккә бирелә. Хәтфә келәмгә ятып, еламсырый-еламсырый, әнигә: «Миңа күңелсез»,— дип зарланганнарым әле дә исемдә. Мондый вакытларда әни: «Бар, урамга чык, улым, үзеңә иптәш тап, уйна»,— ди.

Әкренләп яңа урында да иптәшләр табылды. Аларның берсе — Шакир абзыйның кечкенә улы Вәли. Ул ябык чырайлы, соргылт күзле, нәкъ этисенә охшаган малай. Аның сеңлесе Рокыя — бәләкәй генә, йомры гына кара күзле кыз. Вәли этисенә охшаса, Рокыя — нәкъ әнисе. Шакир абзыйның хатыны Шәрифкамал исемле. Мин, әле кечкенә булсам да, беренче танышуда ук Шакир абзый белән Шәрифкамал апаның яшь аермасына игътибар иттем. Өй хуҗабыз Шакир абзый җитмештән узган, картлыктан шактый коргаксыган кеше булса да, шактый җитез, һич тик торуны белми торган бабай. Аның мыегы җептәй тар калдырып кырылган, сакалы ияк очында гына. Ул җомга намазыннан бер вакытта да калмый. Көндәлек намазга да йөргәли. Аз сүзле, кыркурак табигатьле. Әйткәнемчә, ифрат хезмәт сөючән карт. Мин иртә торып ишегалдына чыкканда, җәен-кышын ул инде ишегалдында камил тәртип урнаштырган була. Бөтен җир себерелгән, мал-туар асты тазартылган. Бу эшләрне Шакир абзый иртәнге чәйгә кадәр үк башкара.

Шәрифкамал апа исә яшь, чибәр, тулы бәдәнле, кара күзле, колач, әмма оялчан бер хатын. Ул этидән йөзен яшерә. Аңа күп булса утызлар тирәсе булыр, тыныч, күкрәк тавышы белән сөйләшә. Шәрифкамал апа — Шакир абзыйның икенче җәмәгате. Беренчесе моннан ун еллар элек үлгән, ә анысыннан туган балалары күптән инде башка чыгып аерым гомер итәләр. Алгарак китеп булса да әйтәм, Шакир абзый белән Шәрифкамал апа арасындагы тигезсез никахның, мин белгәндә берниндидә кыек яклары күренмәсә дә, азагы күңелсез беткән. Байтак еллардан соң ишеттем мин бу хәбәрне. Утызынчы елларда Шәрифкамал апага бер яшь кенә җилле егет ияләшкән. Шул беркатлы татар хатынын тәмам юлдан яздырган. Шәриф-

камал апа шул егеткә гашыйк булып, картайган ирен генә түгел, хәтта балаларын да ташлап, ябышып чыккан...

Безгә каршы, урам аша, фәкыйрьрәк кешеләр яши иде. Мин шундагы Алтыбармак Закир улы Ибрай белән таныштым. Закир абзый үзе итекче, ифрат оятсыз, аерата минем алда, ике сүзнең берендә оятсыз сүзләр кыстырып сөйләшә. Аның кече улы Ибрай миннән олырак, какча йөзле, соры күзле, миннән көчлерәк тә, хәйләкәррәк тә. Без һәркөнне иртән дусларча уйный башлыйбыз, әмма һәркөн кичен, кагыйдә буларак, сугышып аерылышабыз. Мин еш кына канаган борын, тырналган бит белән өйгә елап кайтам. Өйдә, мин аны барыбер үтерәм дип елый-елый әтәчләнеп, Ибрайны каргыйм, аңа яныйм. Әни безнең эшкә тыгылмый. Ярый-ярый, шулай итәрсең, улым, дип кенә куя. Әмма иртәгесен мин тагын урамның теге ягында Ибрайны күреп куанам, аның белән, кичәге кебек үк дөньябызны онытып, уен кора башлыйбыз.

Бездән бер йорт аша гына Әкрәм исемле сузан, ябык бер егет яши. Мин аның турында язмый кала алмыйм, чөнки ул мине бала чакны ук хәйранга калдырган кеше. Аның әтисе касапчы, ягъни мал суйдыручы. Әкрәм Троицкидагы татар-башкорт педагогия техникумында укый. Бераз тотлыгып сөйләшә, шуңа күрә булса кирәк, техникумның өченче курсыннан китәргә мәҗбүр булган. Хәер, монысы соңрак. Әле мине шаккатырган вакытта ул укый иде. Әйе, ул безгә дә кергәли, әти белән бик җитди нәрсәләр, минем буй җитмәслек хәлләр турында сөйләшеп утыра. Аннан, әни әзерләгән чәйдән баш тартып, бик күп рәхмәтләр укып чыгып та китә.

Көннәрдән бер көнне ул, урамда бергә уйнап йөргән иптәшләрем белән, мине үзенә ияртеп өенә алып керде. Менә без аның кечкенә генә бүлмәсендә. Монда ниләр генә юк! Әллә нинди катлаулы аппаратлар, батареялар, сәгать механизмнары, машиналар. Кыскасы, аның өстәлендәге моңарчы мин күрмәгән хикмәтле нәрсәләрнең барысы да бар кебек иде.

Әкрәм безне өстәленә якынрак китерде, барыбызга да кулга-кул тотынышырга кушты. Иң кырыйга туры килгән бер малайга сәгать гере сыман бер тимер тоттырды. Аннан соң нәрсәгәдер басты-тоташтырды, безнең аша моңарчы без тәмен беркайчан да татымаган көчле дулкын ага башлады. Безгә бик куркыныч та, көлке дә. Аның кызыгы шунда, без кулларыбызны бер-беребездән һич ычкындыра алмыйбыз.

Бераздан безнең кыланышны көлә-көлә күзәткән Әкрәм көлүеннән туктады. Бик җитдиләнеп:

— Кызык булдымы? — диде. — Менә моны, энекәшләрем, элек-т-трический ток, диләр.

Без исә, мондый «могҗизаны» беренче тапкыр күрүче малайлар, тәмам тетрәнгән дә, сәерсенгән дә бер хәлдә өнсез калдык.

— Электр тогы диләр моны, т-тишек борыннар! — дип кабатлады Әкрәм.

Шунда гына беренче тапкыр электрның тәмен татып карадым мин. Бераздан шул ук Әкрәмнең тар бүлмәсендә беренче тапкыр детекторлы, наушниклы радиоалгыч белән дә таныштым. Бик мөмкин, Әкрәм шәһәребездә беренче кеше буларак радиоалгыч ясаган егеттер, бәлки. Бераз алгарак китеп, тагын хәбәр итә алам. Бик күп еллар узгач, инде Бөек Ватан сугышы алдыннан, мин Әкрәмне Мәскәүдә очраттым. Ул хәзер әллә ничә патент хуҗасы, хәрби заводлар консультанты, танылган уйлап табучы иде.

— Син бит бары өч курс техникум бетергән кеше, Әкрәм, ничек соң югары белемле инженерларга консультация бирә аласың? — дип сорадым мин аңардан.

Ул миңа:

— Беләсеңме, Атилла, мин интуиция белән эш итәм,— диде.

Мин Әкрәмгә ышанам. Халкыбыз арасыннан чыккан искитмәле талантларны үз гомеремдә аз очратмадым. Татар халкы мондый кешеләргә ифрат бай. Ул күрше халыкларга да гомере буена талант өләшеп торды дияр идем мин.

Әлбәттә, малай чакны Әкрәм минем уйларымны озак били алмады. Мин үземне һәркөн кыйный торган Ибрайлар белән дә озак аралаша алмадым. Чөнки, ни әйтсәң дә, мин алар арасында «ала карга» идем.

Озакламый миңа яңа иптәшләр табылды. Башта шуны әйтергә тиешмен: минем әти бик үзенчәлекле мулла иде. Хәер, ул заманда җәдитче дин әһелләре белән гади татар интеллигенциясе арасында кискен аерма да юк иде. Безнең гаилә укытучылар, заманында милли әдәбиятка да хезмәт күрсәткән кешеләр белән бик нык аралашты. Ул кешеләр атнага бер тапкыр диярлек бездә булалар. Кышкы озын кичләрдә чәй эчеп, лото уйнап, әңгәмә сатып, төрле кызыклы вакыйгалар, шәкерт мәзәкләре сөйләп утыралар. Әтиләр дә, безне өйдә калдырып, еш кына шулай танышларына кичке чәйгә китәләр, соң гына кайталар.

Менә шулай безнең гаилә белән аралашучылар арасында көннәрдән бер көнне Фәез абый Черкасов һәм аның хатыны Сәхип апа пәйда булды. Фәез абый зур колаклы, кара тутлы, калын мыеклы кеше иде. Ул ифрат күңелле, «мәҗлес күрке» дип аталучылардан. Фәез абый күбрәк шәкерт тормышыннан бик көлке мәзәкләр, вакыйгалар сөйләп, мәҗлестәгеләрнең эчләрен катырып көлдерә. Сәхип апа да алдынгы хатыннардан, заманында үзешчән спектакльләрдә катнашкан, бик ачык, күңелле апа. Әниләр миңа кунаклар янында залда утырырга рөхсәт итмәгәч, шыпырт кына залга чыгып, өстәл астында ятканым әле дә исемдә...

Фәез абыйлар безнең урамда яшиләр иде, аларның фатиры бездән ике чат ераклыкта гына. Аларның Рашат һәм Морат исемле уллары, Рауза һәм Ләлә исемле кызлары бар. Мин Фәез абыйның уллары белән тиз якынайдым, еш кына аларга барып йөри башладым. Белмим, үземнән өч яшькә олырак булса да, ни өчендер Рашат белән дуслашып киттем. Морат — Рашатның энесе — минем хөрмәтемне ул кадәр үк яулый алмады. Ул ничектер миңа үзе белән артык мавыгучан, иркә һәм һавалырак булып тоелды. Рашат исә әтисе кебек уен-көлке яратучан, сурәт ясарга, әллә нинди хикмәтле фокуслар күрсәтергә, төрле уенчыклар уйлап чыгарырга сәләтле, кирәгендә коры да, нык та була белә. Ул уң кулы белән яза, сул кулы белән рәсем ясый. Сурәт төшерү белән минем кызыксынуым шул Рашаттан башланды дип әйтергә була. Рашаттан йоккан сурәт ясау эше исә тормыш юлымда миңа шактый күп ярдәм дә күрсәтте.

## 8

Гадәтемчә, һәр көн иртүк торам да, Хәдичә апаларның күзенә артык чалынмас өчен шыпырт кына киенеп, урамга чыгып китәм. Әле иртә. Җәйге Мәскәү иртәсе, әмма җәйге иртә рәхәтен тоймыйм, күңелдә бары бер генә мәсьәлә казыктай басып тора: хәл ителмәде микән минем язмыш? Йа, хода, әгәр тикшергән булсалар, миңа студентлык хокукын кайтарсалар, миннән дә бәхетлерәк кеше була алыр иде микән бу дөньяда? Мин шулай уйланам. Ләкин шундук бөтен тәнемне чымырдатып умыртка сөяге буенча йөгерешкән салкын күңелемә дәһшәт булып үрмәли башлый. Ә андый хокукка мине лаек дип тапмасалар? Чыгышны яшергәнсең бит, кабахәт җан, син моның өчен тиешле җәзасын да алырга тиеш, дисәләр?

Күңелем җир эшләре наркоматына ашкына. Бөтен бер кварталны биләгән көрән таш бинада минем язмыш хәл кылыначак. Минем тизрәк шунда барып җитәсем, барысын да тизрәк беләсем килә. Әйе, иртәрәк икән әле. Хезмәт көне Мәскәүдә сәгать тугызда гына башлана. Юлымда очраган ашханәгә керәм дә, ике стакан чәй һәм өч телем икмәк алам. Өстәл янына урнашып, гадәттәгечә, портфелемнән кәгазьгә бик әйбәт төрелгән тозлы балыкларымны алып өстәлгә куям, тәмләп чәй эчәргә керешәм. Ризыкның фәкыйрьлеге ят күзгә бик чалынмасын өчен, залга аркам белән утырам. Ашыкмыйча гына, иплəп тәмләп ашыйм, стакан төбендә шикәр эреми калмасын дип, чәйне бераз эчкәч, кашык белән бик озаклап болгатам.

Иртәнге ашым, мин ни кадәр сузарга тырышсам да, бик тиз тәгәлләнә. Ашыкмый гына урамнар гизәм. Киләчәк тормышым турында уйланам. Казанны искә алам. Аннан уйларым тагы үткән көннәргә таба юл саба.

Балалык елларымда хәтергә бик нык уелып калган вакыйгаларның берсе Казанга бару булды, бу — егерме икенче елның җәе. Без әнием белән икәү Казанга киттек.

Безнең ул сәяхәт, тулырак әйтсәң, бер Казан белән генә чикләнмәде. Без Казаннан, пароходка утырып, Чистай шәһәренә дә бардык. Әниемнең туган шәһәрендә берничә көн булгач, яңадан Казанга әйләнеп кайттык. Казанда шактый вакыт торганнан соң гына Троицкига юл тоттык.

Йомры таш түшәлгән Казан урамнары үзләренең чыңгылдык трамвайлары, Ташаягы һәм тагын урамнарга таралган алма, кура җиләге исләре белән хәтердә калган. Без үзебезнең якташ Фатыйха апа Аитоваларга төштек. Искиткеч матур һәм батыр хатын Фатыйха апа — Троицк бае Мөхәммәтвәли Яушев кызы. Ул бик яшьли үзеннән олы, тол калган Казан бае Сөләйман Аитовка кияүгә чыга. Мәгәр бай алдына, ни эшләсә дә, үзенә ирек бирүен шарт итеп куя. Тиздән Фатыйха апаның әтисе үлә, кызына шактый мул мирас кала. Фатыйха апа шул акчага Казанның данлыклы җәдит кызлар мәктәбен ачып җибәрә.

Билгеле, бу эшләр бик күптән, революциягә кадәр үк булган. Без аларда чакта Фатыйха апаның, берсеннән-берсе чибәр улларын карап, шуларның уңышлары белән юанып яшәгән вакыты иде.

Тагын истә калганы — әнием белән Муса Бигиевләргә бару. Бу кеше атаклы дин галиме, теолог, заманында Тукайның якыннарыннан, унынчы елларда Петербургта мулла булган кеше. Аның хатыны Әсма апа — әниемнең туганнан туган апасы Гарифә апаның сеңелесе.

Муса җизниләрнең хәзер Казанда булуын ишеткәч, әлбәттә, аларны күрми китә алмаган инде әни. Ул мине дә үзе белән ияртеп алып барды. Бу вакыйганың истә калуы бәлки Муса Бигиевнең тышкы кыяфәте аркасында булгандыр дип уйлыйм. Аның дин кешесе, мулла булуын әнием миңа башта ук әйткән иде. Мин исә үзем белгән чалмалы мулла күрермен дип фараз иткәнмендер. Хәлбуки, мин күргән кеше бөтенләй башкача булып чыкты. Муса Бигиевне, мулла дип атаудан да элегрәк, интеллигент дип әйтергә булыр иде. Таралмаган җитү чәч, калын мыек, тар балаклы чалбар. Менә шундый булып истә калган ул заманында дингә реформа кертергә тырышучы кеше.

Казанда чакта Ибраһим абыйларга бару вакыйгасы да истә. Бу кеше — әнинең әнисе ягыннан туганнан туган кардәше. Ибраһим Камалов заманында Чистай шәһәренең алдынгы яшьләреннән саналган, революцион хәрәкәттә шактый актив катнашкан. Шул кадәресен дә әйтәсе килә, аның хатыны — язучы Гаяз Исхакыйның аерган җәмәгате. Шул хатыныннан Ибраһим абыйның Микаил, Исраил исемле уллары, Суфия исемле бер кызы бар. Микаил туберкулездан үлде. Исраил Бөек Ватан сугышында һәлак булды. Суфия апа инженер булып озак

еллар химия заводларының берсендә. Казанда эшләде. Болары инде соңгы чорларга бәйләнештәге хәлләр. Ә теге вакыттан истә калганнары түбәндәгеләр. Ибраһим абый миңа бер скрипка бүләк итте. Вакыйгалар тәртибен бозып булса да, ул скрипкага тулырак тукталмый булмый. Чөнки соңыннан скрипка дигән борынгы уен коралы тормышымда билгеле бер роль уйнады. һәрхәлдә, минем хыянәтсез гомерлек дустым булды.

Әйе, чандыр гәүдәле, сакал-мыек йөртмәсә дә карт чырайлы, ифрат җитди кыяфәтле, ләкин сабыр һәм хәлим, бәләкәй генә Ибраһим абый бүләк иткән скрипка зурларныкы. Мин аны ияк астына кыстырып, смычок белән кылларына сызгаласам да, ямьсез быгырдау авазларыннан башка җүнле тавыш чыгара алмадым. Скрипкадан тәмам гайрәтем чикте һәм мин аны, өйгә кайткач та, футлярына салып, шкаф өстенә олактырдым. Ул шунда, тузан җыеп, берничә ел ятты.

Бәлки ул гомер буе да шунда ятар иде, тик бер гарьләндергеч вакыйга үҗәтлегемне кузгатты, шулчак скрипка искә төште. Болай булды ул. Баштан ук аңлатыйм. Кала якта яши башлагач, мин дус-ишләргә көннән-көн байый бардым. Рашатлардан соң яңа дусларымның берсе Рәфкать Гыйззәтуллин дигән малай булды. Аның этисе Рәхмәтулла абзый кечкенә генә кибет тота, кызыл мал белән сәүдә итә, ләкин ифрат дәрәҗәдә китап сөюче бер кеше. Ул — этинең дусларыннан. Безгә ара-тирә кергәләп, эти белән озаклап сөйләшеп утыра. Сүз күбрәк китап, дөнья хәлләре, дин, әхлак турында бара. Без дә аларда булгалыйбыз. Хәтеремдә, шул Рәхмәтулла абзый этигә бик калын «Камусе төрки» исемле энциклопедия бүләк итте. Ә аның олы улы, миңа яшьтәш Рәфкать, туган көнемә каты тышлы кечкенә генә альбом китерде. Аның беренче битенә «Гатиллага» дип язылган, аннан «Ай төн өчен, кояш көн өчен, синең болай тырышулар, беләсеңме кем өчен?» дип өстәлгән.

Шулай итеп, без Рәфкать белән дуслашып киттек. Йөрешә башладык. Көннәрдән бер көнне, аларга баргач, дустымның кулында бәләкәй генә скрипка күрәм. Алай гына да түгел, ул шул скрипкасында көйгә охшаш бер нәрсә дә безелдәтә. Бу искитмәле бер хәл иде! Мин, ни маташып, берни чыгара алмадым, ә ул?..

Кулларымны сузып скрипкага үреләм. Рәфкатьтән скрипкасын тоттырып каравын үтенәм. Кем белә, бәлки бу скрипкада көй чыгара алырмын. Ләкин Рәфкатьнең күзләрендә масаюдан башка берни дә күрмим. Юк, тотып карарга да бирми, янәсе, син тота белмисең, ватарсың. Бу сүзләр инде бар түземемне юкка чыгара. Кипкән чырадай кабынып, алардан чыгып китәм. Өйгә кайтам да, сүзсез-нисез, шкаф башыннан тузанга баткан скрипкамны алам, тешкә тия торган котсыз тавышлар чыгарып, көйсез кылларны пычкылый башлыйм.

Менә шулай мин, берәр елдан соң, скрипкада уйный башладым.

Казанда беренче тапкыр булуымның хәтергә бик нык сеңеп калган истәлеге — тагы Тукай каберенә баруыбыз.

Без әнием белән Фатыйха апаларда ятабыз әле. Көннәрдән бер көнне моңарчы күренмәгән, пеләш башлы, зур, авыр гәүдәле ниндидер бер кеше әниемне алырга килде. Аларның хәзер Тукай каберенә барырга җыенуларын ишетеп калам. Аңлап та өлгермәдем, алар өйдән чыгып, капка төбендәге тарантаска утырып элдерттеләр.

Әһ-һә, барысы да аңлашылды! Мине калдырып, Тукай каберенә киттегезмени әле сез? Монысы булмас инде! Күзем ачылганнан бирле Тукай шигырьләрен ишетәм. Әнием, син үзең бит миндә бөек шагыйрьгә карата мәхәббәт уяткан кеше, үзең бит аның портретын кадерләп стенага элеп куючы. Ә инде шул кешенең каберенә минсез генә барырга уйлыйсыңмыни?

Яшен ташыдай атылып урамга чыгам да, әниләр киткән якка таба

чабам. Артларыннан кууымны ишетсеннәр өчен, барлык көчемә кычкырам, елыйм. Ниһаять, әнием тавышымны ишетте булса кирәк. Артка борылып карады да, пеләшкә нидер әйтте. Ләкин күрәм: теге хәерсезнең атны туктатырга уенда да юк. Тагын да катырак йөгерәм, тагын да катырак кычкырып елыйм. Күрәм, әнием чәбәләнә, тәгаен тегенең атны туктатуын таләп итә.

Пеләш баш атын туктатырга мәҗбүр булды.

Хәзер, чамалап, теге такыр башлы кешенең кем икәнлеген әйтә алам. Ул — заманында татар сәхнәсендә байтак әсәрләре куелган, хәтта «Койрыклы йолдыз» исемле әсәрен экранлаштырган, чыгышы белән Троицк кешесе, драматург Әхмәт Таҗетдин булырга тиеш.

Без Троицкидан киткәнче, миңа Казанда тагын бер тапкыр булырга туры килде. Бу юлы без өчәү идек. Эти дә безнең белән булды. Без бу баруда да Фатыйха апаларга килеп төштек. Егерме дүртенче ел иде, ахры. Казан истәлекләреннән бары җырчы Әлмөхәммәдев һәм композитор Солтан Габәши генә истә калган.

Менә ул — атаклы җырчы — рояльдә уйный, җырлап та күрсәтә булса кирәк. Анысы хәтеремдә ачык сакланмаган, әмма әнигә ниндидер мөнәсәбәт белән әйткән сүзләре хәтердә. Ул:

— Безнең һөнәр сәясәткә бөтенләй бәйләнешле түгел,— ди. Аның шулай, мактана төшеп дип әйтер идем, әниемә аңлатуы ни өчендер хәтергә бик нык сеңеп калган.

Икенче килүдә дә, беренчесендәге кебек, без Чистайда да булдык.

Күлле Киме авылына да кайттык. Без шул авылда мәктәп директоры булып эшләүче Габдрахман абыйларда кунакта булдык. Алдарак Габдрахман абыйның әниемнең кече абыйсы икәнлеге әйтелгән иде инде. Бернинди махсус мәктәп бетермәгән, бары тик курсларда йөреп һәм үзлегеннән укып белем алган, тырышлыгы, зирәклеге аркасында камилләшеп җитлеккән бу кеше хәзер шул Казан артындагы Күлле Киме исемле авылда хатыны, балалары белән яшәп ята.

Минем элек тә башкорт авылларын, казах кышлауларын күргәнем бар иде. Ләкин бу татар авылыннан алган беренче тәэсирләремне беркайчан да онытасым юк.

Күлле Кименең ямь-яшел каз үләне белән өретелгән киң урамнары, кичләрен, күләгәләр озынайгач, киндер тукмаучы хатын-кызның урамның бер очыннан икенче очына таба ишетелгән үзенчәлекле музыкаль шакы-шокысы күңелгә кереп калган.

Күлле Кимедән без Казанга кайтып киттек һәм, шунда бераз кунак булганнан соң, үз шәһәребезгә юл тоттык. Габдрахман абыйны озакламый Арчага кантон мәгариф бүлегенә инспектор итеп алганнарын хатларыннан белдек. Сәүдә апа исә, Габдрахман абыйның хатыны, Арча урта мәктәбенә укытучы булып урнашкан.

Хәер, ул гаилә турында вакыты җиткәч, сүз булыр әле. Хәзер тагын Троицк хәлләренә кайтыйк.

Әйе, без этинең яңа эшенә дә, үзебезнең яңа халәткә дә, хәтта яңа квартирага да тора-бара иякләштек, күнектек. Әни дә, күрәсең, барысына да кул селтәп, эчке ризасызлыкларын җиңеп, чып-чын остабикә булып уйный башлады. Ул хәзер сирәк-мирәк булса да намаз укыштыра, өйдә мәүлид кичәләре уздыра, вәгазь сөйли. Әнием турында уйлаганда мин вакытында алдынгы татар яшьләре арасында булган, Тукайларга, Фатих Әмирханнарга мөхлис татар кызының хәзерге халәтенә нинди авыр кичерешләр, каршылыклар аша төшүен ачык күзаллыйм. Адәм баласы котылгысыз шартларның барысына да ахыр чиктә җайлаша, үзенең рухи тигезлеген таба.

Без күе сөтле ала сыер сатып алдык. Аны эти яки мин ашатабыз, эчертәбез, мин көтүдән алып кайтам. Бераздан эти сөт аерткыч сатып алды. Аны, хуҗаларның рөхсәте белән, Шакир абзыйларның кухня өйләренә урнаштырдык. Безгә сөт аертырга күрше-күлән хатыннары

йөри башлады. Минә шулай яшибез. Эти, ап-ак чапан-чалмасын киеп, мәчеткә йөри, мин Кала як үзәгендәге татар мәктәбендә укыйм. Юлда очраган мәчет картларын, бик тәүфыйклы булып, кулны күкрәккә куеп, «әссәләмөгаләйкем» дип сәламлим. Өйдә пәйгамбәрләр тарихын укыйм, дәрес әзерлим; бушагач, нәкъ элеккечә, «шайтан чабам», киного бик еш йөрим. Гомумән, тормыш көйле, үз җае белән бара бирә...

9

Мәскәүгә килүемә алтынчы көн китте. Хәдичә апа да, аның кызлары да минем ни өчен шулай озакка килүемнең сәбәбен төшенәләр кебек. Миңа «Кайчан китәсең инде?» — дип бер генә сүз әйтмәсәләр дә, сизеп торам, минем нииндидер җитди эш артыннан йөрүемне төсмерлиләр. Тик мин, нәкъ элеккечә, иртүк торам да, урам гизәргә чыгып китәм. Җир эшләре комиссариатына көненә икешәр тапкыр сугылам. Сөйкемле секретарь апа минем болай йөрүемә һич тә үпкәләми кебек. Тәгаен без аның белән, күңел күзләре аша гына булса да, үзара ныклы дуслык урнаштырдык. Ул мине һәрвакыт якты чырай белән каршы ала, елмаеп карый. Аның гүзәл йөзе күңелемә тынычлык һәм ышаныч бирә. Ләкин мин аның йөзенә озаклап карарга оялам. Ул миңа матур зәңгәр күзләрен тутырып текәлсә, йөземә кызыллык йөгергәнен тоям, тез буыннарым йомшара башлый һәм мин тизрәк бүлмәдән чыгып китү ягын карыйм.

Бүген дә иртәнге якта ул мине, гадәттәгечә, үз итеп каршы алды. Аннан өстәл тартмасын ачты да:

— Сезнең документлар арасында комиссия членнары аңламаган, сезнең телдәге бер журнал бар. Сез шундагы материалны тиз генә русчага тәрҗемә итеп китерегез,— диде.

Миңа уңайсыз булып китте. Ничек соң мин бу турыда Казанда ук уйламаганмын? Апа минем документларым арасында тагын берәз казынды да:

— Менә бу газетада да кирәкле нәрсә бар, ахры. Аны да тәрҗемә итәргә кирәк булыр,— дип өстәде.

— Ярар, тырышырмын,— дигән булам. Әмма уйга калдым. Ничек барып чыгар икән соң бу эш? Нишләмәк кирәк, хәзер үк кайтам да эшкә керешәм.

Бәхеткә каршы, өйдә берәү дә юк иде. Кызлар эштә, ә Хәдичә апа кухня ягында кайнаша. Мин, «Фән һәм дин» журналын һәм әлеге дә баягы газетаны өстәлгә ачып салдым да, кулыма кәгазь-карандаш алдым. Тәрҗемә итәлергә тиешле нәрсәләр — әтиемнең «Соңга калган бер тавыш» исемле мәкаләсе һәм күптиражлы «Вахитовчы» газетасындагы минем повестьтан өзек.

Ашкынып эшкә керештем. Тик тәрҗемәмнең беренче юлларында ук сөрлегә башлавымны тойдым. Җөмләләр ямьсез, ятышсыз хәтта мәгънәсез килеп чыгалар. Ирексездән тукталып, уйга калам. Гаҗәп бер эш икән бу бер телдән икенче телгә күчерү! Мин үземне азмыкүпме рус телен беләм дип уйлап йөрүчеләрдән идем. Янәсе, дүртенче класстан алып рус мәктәбендә укыдым, заводта рус арасында эшләдем, инде килеп миңа бер ел буе рус гаиләсендә һәр көн русча сөйләшеп яшәргә туры килде, матур әдәбиятны укыганны әйткән дә юк. Шулай да тел белүем чамалы икән ләбаса!

Ләкин бирешмим. Барлык көчемне җигеп, татарчадан русчага күчерә бирәм. Әйдә, ямьсез чыкса чыксын, тик аңларга теләгән кешегә аңлашырлык булсын.

Төштән соң гына эшемне бетереп, язганнарымны яңадан укырга керештем. Иа хода, бу бит бернинди дә киртәгә сыймый торган кәлҗемә булып чыккан! Бөтенләй кара хәсрәткә баттым. Бармый болай! Тәр-

җеменә рус телен шәп белүче берәр кешегә күрсәтеп төзәттерми мөмкин түгел.

Әти үзенең мәкаләсендә ничек мулла булып китүен һәм нинди сәбәпләр аркасында соңыннан бу эшен ташлавын яза. Бу мәкаләне кемгә генә биреп төзәттерсәм, үземә зыян китермәм икән, дип уйлыйм. Шундук уйларым мине ерак Троицкига алып китә...

Троицк! Мин аны туган шәһәрем дип беләм. Аннан бик еракта туган булсам да, мин бары шул шәһәрне генә беләм. Сабыйлык елларымнан бирле бары аны гына хәтерлим. Троицк! Синең турыда уйлаган саен, синең комлы урамнарың, эссе җәйләрең, дулап котырып ага торган ташуларың, зәмһәрир суыкларың белән истә калган кышларың күз алдына килеп баса. Троицк исемен ишетү белән, аның тирә-юне. Урал тавының тамырларыннан шәһәр читендә калкып торган таш кыялары, шәһәр артыннан ук шул кыяларга ышыкланган иркен айдалалары һәм җил уңаена чайкалган чиксез кылган дәрьялары күз алдыма килә.

Шәһәрнең кыл уртасыннан, Увелька елгасы ага, ә Көньяк читендә Уй елгасы җәйрәп ята. Бабай тавы дип аталган таш кыялар турысында, шәһәр читендә, Уй үзенең сеңлесе Увелька белән кушыла. Тырпаеп торган текә таш диварлар арасындагы елгалар кушылган урын — без малай-шалайның яраткан җире. Анда ниндидер серлелек, тирәнлек. Уй шушы урында, сеңлесе Увельканы җитәкләп, Тобол елгасына таба ашыга.

Без һәр җәйдә «казахка чыгабыз». Ягъни, җәен ял итеп яту өчен, берәр бай казахтан ак тирмә кордырабыз, хуҗадан кымыз, сөт, ит сатып алабыз, шулай җәйне иркен сахрада үткәрәбез.

Әмма болай гына казах даласының бөтен гүзәллеген күреп булмый икән әле. Мин моны әтием белән Убаган буйларында сәяхәт кылганда аңладым.

Әтиемнең олы абыйсы Габдрахман абзыйларга ул җәйне Казаннан Фатыйха апаның кече улы Якуп Аитов кунакка килде. Бу — ифрат чибәр, уңҗиде-унсигез яшьләрендәге кунак егетенә абзыйның улы, җиткән егет Рәүф абый казах далаларын күрсәтергә булган. Ләкин, бу ике егеткә генә ат ышанып, аларның үзләрен генә әллә ничә йөз чакрымга җибәреп буламы соң? Якнарында абруйлы бер олы кешенең булуы сәяхәтне җиңеләйтәчәк тә бит әле. Шулай уйланган булырга тиеш. Нәтиҗәдә, Рәүф абый юл чыгарга әтине дә чакыра. Әти исә мине дә алып баруны шарт итеп куя.

Һәм без, җәйге матур көннәрнең берсендә, абзыйларның бурлы айгырын җигеп, Уй елгасы аръягына, көньяк-көнчыгышка таба юл тоттык.

Дала ул гел бер төрле күренешләрдән генә тормый. Юлда безгә калку курганнар да очрый, монда камышлы ярлар белән каеп алынган түгәрәк күлләр дә күренгәли. Ә ул күлләрдә чиксез күп киек кошлар кайнаша: үрдәкләр, казлар, торналар. Мондый күлләр турысыннан узганда егетләр арбадан сикерешеп төшәләр. Тиз генә ау мылтыкларын алып, күлгә таба йөгерәләр. Аларның йөзләрендә, күзләрендә — сунарчы комарлыгы. Без, атны туктатып, аучыларны күзәтәбез. Әти арбаның уң ягында, дилбегә тоткан, мин исә аның янында зур төенчек кочаклап утырам. Әтинең йөзендә кинаяле елмаю. Ул егетләрнең берни дә кыйрата алмавын алдан ук белә. Менә ничә тапкыр инде алар шулай, өтәләнеп, йөктән мылтыкларын тартып алдылар. Менә ничә тапкыр инде бик җитди кыяфәттә киек кошларга таба йөгерделәр. Ләкин аларның бары ату тавышлары гына даланы яңгыратып алды. Шуның белән вәссәләм. Андый вакытта үрдәкләр фырылдап күккә күтәрелә, торналар, казлар әллә ни арада юкка чыга.

Без тагын юлыбызны дәвам иттерәбез. Юлда безгә симез дүдәкләр очрый. Алар далада утлап, җим чүпләп йөриләр. Бик матур, горур

кош ул дүдәк. Аларны казахлар атта куып, чукмар белән бәреп егалар. Чөнки бу дала кошлары авыр гәүдәләрен күтәреп очканчы байтак араны йөгереп барырга, «канат кыздырырга» тиеш булалар.

Ә тургайлар, һавада асылынган килеш, һаман безне җырлап озаталар. Аларның сайравы күңелгә рәхәтлек бирә. Рухны күтәрә, бөтен тирә-юньгә бәйрәм тантанасы кертә.

Бер тапкыр без ялан далада диңгездәй зур бер күл күрдек. Ләкин ул күлгә барып җитә алмадык. Юкса ул буй җитәрлек якын булып күренде үзе. Мираж, дип аңлатты әти. Шулай далада, һич көтмәгәндә, хәтта гүзәл шәһәрләр дә «пәйда» була икән.

Барачак урыныбызга без бер көндә генә барып җитә алмадык. Ике тапкыр казах җәйләвендә кунып ял иттек. Атны да ял иттердек. Хәтердә, кайсы гына җәйләүгә якынлашмыйк, безне нәзек, озынча, үзләре бозау хәтле, бүре аулый торган бурзайлар һау-һаулап каршы ала иде. Алар бик көчле, бик зур, хәтта арбага сикерәләр. Кешене өстерәп төшерергә дә күп сорамаслар. Әмма этләр артыннан таягын тоткан казах ялчысы килеп җитә. Ул безне өзгәләп ташларга әзер торган этләрдән аралый, каты кычкырып, бурзайларны куып җибәрә. Үзе ат башы янында йөгерә-атлый, безне ак тирмә артына кадәр озата бара. Ә ак тирмәдә — хуҗа, утагасы, җәйләүнең иң олы бае.

Кунарга тукталу белән, бездән ат кайгысы китә. Аны бик әйбәт караячаклар, ашатачаклар, вакыты җиткәч эчертәчәкләр. Без тирмәгә керәбез, мал-җан аманлыгын белешкәннән соң, утырып, озаклап дога кылабыз. Ул арада кулларны юып алу өчен комган белән ләгән дә килеп җитә. Аны бер кешедән икенче кешегә күчереп йөртәләр. Идәндәге келәмгә ашъяулык җәелә. Сап-сары агачаяклар килә, зур агач табакка саба дип аталган ысланган күн капчыктан кымыз коела, эскәтергә бавырсак сибелә.

Табында сүзне, башлыча, утагасы алып бара. Казах халкы сүзгә оста. Утагасы, ашыкмыйча гына, күргән-белгәннәрен, ишеткәннәрен хикәят кыла. Сүзгә башкалар да кушылгалый, өсти, хуҗаны куәтли, хуплый, ләкин чамасын белеп кенә, мәҗлеснең игътибарын утагасыннан артыграк җәлеп итмәү шарты белән генә катыша.

Инде менә караңгы төшә башлады, ләкин әле һаман сүз бетми, ә тирмә каршысында өчаякка утыртылган зур чуен казанда күптән инде ит пешә. Мин беләм, без килеп төшү белән сарык суелды, хәзер инде ул казанда. Тирмә эчендә асылмалы лампа яндырыла. Караңгы төшкәндә җәйләү тирәсенә мал-туар тупланган була инде. Колакка ат пошкырган, ат кешнәгән, үгез мөгрәгән, сарыкларның «кәһ-кәһ» йөткергән тавышлары ишетелеп китә. Соң инде хәзер, төнлек ябылган, ишекнең киез каплагычы да төшерелгән. Тик олылар, һаман кымыз белән юанып, табын янында гәп коралар. Нилэр турында шундый озак сүз дәвам итә — ул кадәресе минем өчен кызык түгел, олыларның нилэр белән кызыксынуы миңа бик аңлашылмый. Минем үтереп ашыйсым килә. Ә ит әле табынга һаман куелмый.

Ниһаять! Менә ул олы-олы калҗалар өелгән зур калай табакны табын уртасына куялар. Хуҗа, ашыкмыйча гына, чалбар кесәсеннән үткен пәкесен чыгарып, аның ни дәрәҗәдә үткен булуын белергә теләгәндәй, баш бармагы белән аның йөзен капшый башлый, табакны үзенә таба тартып «пысмылла...ын...» әйткәннән соң, ит турарга керешә. Башта иң өстә яткан сарык башы эшкәртелә. Башның уң колагын төбеннән кисеп, утагасы миңа тоттыра. Аннан, башның итле урыннарын турап, аны шәп-шәрә ак сөяккә калдыра да, ит калҗаларын эшкәртә башлый.

Ит турый белү — үзенә күрә бер сәнгать. Аны һәркем булдыра алмый.

Әйе, табактагы пар бөркеп торган тәмле ит калҗалары артканнан арта бара. Хуҗа бу минутта иткә кызыгып текәлгән кешеләрне дә

исеннән чыгармый. Ит тураган арада майлырак калҗаларны учына сала да, берәм-берәм могтәбәррәк кунакны согындыра. Согындыру инде ул — уч тулы итне кунакның авызына салу, ә тегесенең җылы итне чәйнәми-нитми йотып җибәрүе дигән сүз.

Табындагы ит ашалып беткәч, калган сөяк-санакны хуҗа, берәмберәм исемен атап, ишек янында тезләнеп йә чүгәләп утырган ялчы-көтүчеләргә, фәкыйрь туган-тумачаларына ыргыта башлый. Бу эш тә башкарылгач, табынга аякларда өреле тәмле шулпа килә. Ул шулпаны йөретеп эчәсең, ягъни бераз чөмергәч, аякны күршеңә бирәсең.

Инде корсаклар тулган, карын тук, мине тәкатьсез рәвештә йокы баса. Мин башымны әтиемнең тезенә куеп йокларга чамалыйм. Әмма көтмәгәндә бик еракта бүре улаганы ишетелә. Ерткыч нәзек тавыш белән, елагандай, башын күккә күтәреп улый икән. Бу тавыш кешедә дә, терлектә дә үлем дәһшәте уята. Мөгезле эре терлек үкерә, гасабиланып алгы аягы белән җир тырный башлый, атлар пошкыра, сарыклар тетрәнеп бер-берсенә елыша, бөтен җәйләү хәрәкәткә килә.

Рәүф абый белән Якуп абый урыннарыннан сикереп торалар да, мылтыкларын алып, тирмәдән чыгып китәләр. Бераздан аларның берпер артлы мылтыктан атканнары ишетелә. Бу тавыштан да мал куркып тайпыла, ләкин аның каравы бүре тына, аның җан өшеткеч улавы артык ишетелми башлый.

Хәер, казахта бүрене мылтыктан атып ауламыйлар. Сөйләүләренә караганда, атта куып җитеп, кистән белән бәреп үтерәләр аны. Моны боз каткач эшлиләр. Тайгак бозда бүре артык җитез кылана алмый, ә дагалы атларда аны куып җиттү берни түгел икән.

Без тагын юлда. Безне тагын иксез-чиксез айдала, тургайлар җыры, ерак-еракларда күренгән казах җәйләүләре һәм чалт аяз күк йөзе озатып бара. Менә, ниһаять, барасы урыныбызга җиттек. Бу — Вәли хаҗиның җәйләве. Вәли хаҗиларга дип атап баруыбызның берәр сәбәбе булгандыр. Ихтимал, бу бай казах, Габдрахман абзыйларда булып, аны кунакка чакырып киткәндер.

Вәли хаҗи, әйткәнемчә, бик бай казах. Сөйләүләреннән хәтерлим, байның елкы малы гына да биш йөз баштан артык. Бу атлар арасында нинди генә төстәгеләре юк иде! Троицк мал-туарга никадәр генә бай булмасын, аның базарларына нинди генә мал килмәсен, минем моңарчы бу кадәр күп төстәге атларны күргәнем юк иде. Вәли хаҗи атлары арасында нәкъ юлбарыс төсендәгеләр, алтын-сарылары, ап-ак яллы җираннәре бар иде. Инде күп күрелгән бурлы, җирән, кара, туры, алмачуар төстәге атлар турында әйткән дә юк.

Вәли хаҗи дөм сукыр, симез, шадра бер карт булып чыкты. Ләкин ул, сукыр булуына карамастан, барысына да баш булып, зур хуҗалыгын идарә итеп, барысын да исәпләп һәм исендә тотып, күзлеләрдән күбрәк күреп хуҗалык сөрә икән.

Ул Троицк кунакларына үзенең хаҗга ничек баруын, юлда күргән кызыклы маҗараларын сөйләде. Хәзер инде ул сөйләгәннәрнең барысы да истә калмаган, шулай да хаҗ юлындагы кеше талаучы бандитлар турында сөйләве әле дә исемдә.

Без Вәли хаҗиларда атнага якын кунак булдык. Мин, Рәүф һәм Якуп абыйларга ияреп, берничә тапкыр якындагы күлгә ауга бардым.

Өйгә кайтып китәр көнне, хуҗаның фәрманы буенча, тирмә каршысына ук бер йөнтәс колын алып килделәр. Бу ярым кыргый ат малаен әле генә өердән аерып, корык белән тотканнар икән. Әтиемне дә, мине дә шул колын янына чакырып чыгардылар. Сукыр бай үзе дә чыкты һәм миңа колынның колагын тешләргә кушты. Күзләрен алартып, алгы аягы белән мине тибеп очырырга күп сорамаячак колынга якынлашырга кыймыйча, сорау белән әтиемә текәлдем.

— Тешлә, улым,— диде әти,— бу колынны Вәли хаҗи сиңа бүләк итә.

Мин әле ул чакны бу кыргый кара-туры айгырчык белән киләчәктә нинди мажаралар кичерәчәгемне күз алдыма да китерә алмый идем...

## 10

Башта ансат кына тоелган тәрҗемә миңа бик кыйммәткә төште. Аны төзәтердәй кеше таба алмыйча иза чиктем. Хикмәт шунда: ул кеше ике телне дә бик яхшы белергә тиеш бит әле. Төп нөсхәгә карап төзәтмәгәндә тәрҗемәнең бөтенләй кире мәгънә алуы да ихтимал. Андый кеше, эзли торгач, табылды булса кирәк. Асадуллаев йорты дип аталган атаклы таш бинадагы татар китапханәсенең хезмәткәре, кайчандыр миңа фатир табуда да киңәшләре белән ярдәм иткән бөкрерәк абзый бер адрес бирде. Мин хәзер шуны эзли киттем. Артык еракта яшәми икән. Тапкан кешем чәчләре агара башлаган бик җитди, интеллигент кыяфәтле, сөйләшкәндә рус сүзләрен мул кыстырып җибәрә торган бер мишәр икән. Ул мине сабыр гына тыңлады һәм, шатлыгыма каршы, үтенечемне кире какмады. Шундук, журналга карап, мин язганнарны төзәтә башлады. (Бик күп еллар узгач, минем «Ике буйдак» исемле романымны русчага үз тәкъдиме белән тәрҗемә итеп, Мәскәүдә бастыручы кеше шул зыялы агайның кызы Разия ханым Фәизова булыр дип кем уйлаган?!)

Эш беткәч, абзыйга рәхмәтләр әйтеп, кулъязманы акка күчерү өчен, тизрәк Хәдичә апаларга йөгердем. Әле эш аны акка күчерү белән генә дә бетми иде. Чөнки ярдәм иткән абзый, бу тәрҗемә нотариус тарафыннан расланмаса, документ булып исәпләнмәс, диде. Бәхеткә каршы, конторада гарәп хәрефендә язылган күчермәләрне раслап утырган, борын очына Чеховныкыдай күзлек элгән ап-ак чәчле абзый безнең тәрҗемәгә артык бәйләнмәде. Аның, гарәп телен белсә дә, татарча бер авыз сүз дә белмәвен мин шундук аңлап алдым.

Ниһаять, эш бетте. Тәрҗемәне журнал битләре арасына кыстырып, чибәр апага илттем. Һәм тагын зарыгып көтү, өмет, ышаныч белән тулы сәгатьләр башланды.

Мин, өйдә утырырга уңайсызланып, урамга чыгып китәм. Янәсе, эш бар. Аяклар талганчы йөрим, тәмам хәлдән язгач, берәр бакчага кереп эскәмиягә түнәм. Баштан төрлесе уза. Хатирәләр үзләреннәнүзләре яңара башлый. Күзалдыма тагын узган көннәр, төрле вакыйгалар килеп баса...

Лотфый җизни һәм аның ишле гаиләсе искә төшә. Алар бәхет эзләп Троицкига егерме дүртенче елны килделәр. Моңарчы Тоболда яшәгәннәр. Лотфый Җәүһәрев әнигә, димәк, миңа да инде, җизни тиешле. Чөнки аның үлгән хатыны әниемнең бик яраткан апасы — Фатих Әмирхан хөрмәт иткән Бәдриҗиһан. Җизнинең балалары барысы да әниемнең апасыннан. Бәдриҗиһан ападан. Күрәсең, шуңадыр, әни ул ятимнәрне ифрат якын күрә, аларга булдыра алган барлык яхшылыкны күрсәтергә тырыша.

Балаларның олысы Нәкыйп исемле. Ул ундүрт яшьләрендә. Сөрмәле зәңгәр күзле, яшенә караганда кечерәк буйлы, бик уңган һәм акыллы.

Лотфый җизнинең икенче улы — Фәрит. Минем белән яшьтәш малай. Тупасрак кыяфәтле, калын иренле, әз генә дә абыйсына охшамаган. Үзе салмаграк, ифрат беркатлы. Аның тагын күзгә ташланган ягы — тел катылыгы. Әгәр туганнарының теле күп вакытлар читтә йөрү аркасында шактый татарчалашкан булса, моның әз генә дә үзгәрмәгән, туган авылы Каргалыдагы килеш калган. Ул әнине дә мишәрчәләтеп: «Заутунапа»,— ди.

Фәрит белән Нәкыйп абый арасында Ләлә апа бар әле тагын.

Бу гаиләдә иң кечкенә бала — Ханнә. Әнием аның турында: «Нәкъ Бәдриҗиһан апам инде»,— дия торган иде. Искиткеч матур, моңлы зәңгәр күз, чалымнары дөрес булган озынча йөз, шәфкатьле һәм мөлаем табигатьле. Бик матур һәм моңлы итеп җырлый.

Лотфый җизни үзе халыкта «эт каешы» дип атала торган кешеләрдән. Дуамал, саран, ләкин эшләсә кулында ут уйната торган булдыклы кеше. Алар, Троицкига күчеп килү белән, шәһәр уртасыннан квартир табып шунда урнаштылар. Лотфый җизни базар тирәсендә әвеш-тәвеш китереп көн күрә башлады.

Лотфый җизнинең балалары ятимлек һәм фәкыйрьлек аркасында әрсез булып үстеләр. Әтиләре иртә-таңнан базарга чыгып китә, Әминә апа аш-су әзерләү, өй җыештыру белән мәшгуль, ә балалар үз иркендә. Нәкыйп абыйның да, Фәритнең дә, муеннарына тартма асып, папирос, шырпы сатканнары, кайчак капчык күтәреп, стаканлап көнбагыш орлыгы белән кәсеп иткәннәре хәтердә.

Ятимнәр мәрхүмә әниләрен сагынып яшиләр иде. Чыннан да, әниемнең истәлекләренә караганда, ул Бәдриҗиһан апа бик мөлаем, ягымлы хатын булган. Алай гына да түгел, заманасының алдынгы хатын-кызларыннан саналган. Аны әдип Фатих Әмирхан ифрат хөрмәт иткән. Уемча, әнигә мәгърифәткә ашкынуда, әдәбиятка мәхәббәт тудыруда аның йогынтысы аз булмаган.

Лотфый җизни Троицкида шулай вак сәүдә, маклерлык белән шөгыльләнеп, күбрәк очракта алдап, азрак алданып, әмма шулай да көч-хәл белән генә очын-очка ялгап яши дә, соңыннан егерме алтынчы елны бөтен гаиләсе белән үзенең туган авылы Каргалыга кайтып, муллалык эшенә керешә.

Шулай итеп, Лотфый җизнинең вак сәүдәгәрлек карьерасы бетә, ул могтәбәр Каргалы мулласына әверелә. Ләкин бу дәрәҗә дә аңа озакка бирелмәгән икән. Коллективлашу, сыйнфый көрәш дип аталган чор килә. Лотфый җизни гаиләсе раскулачиваниегә эләгә. Ул үзе качып котыла, ләкин гаиләсен, Әминә апаны күкрәк баласы Гаввяз белән, Нәкыйп абыйны, Лалә апаны, Фәрит белән Ханнәне сөрелүчеләр белән берлектә Кама буйлап Пермь ягына алып китәләр.

«Безгә азыкны өч көнлек кенә алырга кушканнар иде,— дип сөйләде миңа соңыннан Лалә апа,— тик баржаны тартып барган кечкенә буксир, без төшәсе ярга тукталганчы, өч көн генә бармады. Ашарыбызга бетте, баржа буйлап хәер эстәргә мәҗбүр булдык. Ләкин тоткынлыктагы кешеләрнең хәерчегә бирерлек нинди артык ризыгы булсын!» Шулай итеп, бу ярдәмчесез алты кеше, ачлыктан тәмам бетәшеп, көчкә Пермьгә барып егыла. Аннан товар поездларында Себер тайгасына кадәр озын-озак газаплы юл башлана. Боларны, поезддан төшкәч, урманга алып китәләр, тимер чыбык белән камалган бер мәйданга кертеп, шунда урнашырга кушалар. Халык җир казып куышлар әзерләргә керешә, бараклар сала башлый, урман кисә, такта яра. Ниһаять, кешеләр түбә асларына урнашкач, читкә озату өчен урман кисү эшенә керешәләр. Лалә апа болай сөйли: «Кыш кергәндә без барак һәм землянкаларда идек инде. Урман кисәбез, әкренләп мондагы тормышка күнегелә, инде язмыштан узмыш юк дип, булганына риза булып яшибез. Шул чакны мин комендатның үземә күзе төшкәнлеген аңладым. Бераздан бу миңа кул сузудан да тартынмый башлады. Минем мондый хурлыкка түзәр тәкатем калмады, мин ничек кенә булса да лагерьдан качарга булдым.

Бу хәтәр эшкә без иптәш кызым белән икәү бик нык әзерләндек, чаңгылар булдырдык, ризык хәстәрләдек. Шуннан, көннәр бераз җылына төшкәч, бер караңгы төндә качтык. Лагерь территориясе читтә, тайгада булганга күрә, сакланмый иде. Күрәсең, моннан качу мөмкин эш түгел, дип уйлаганнар. Тирә-юньдәге иң якын авылга — туксан километр.

Барасы юлыбызны баштан ук ачыклап, билгеләп куйган идек инде. Туксан километр дип тормадык, исеме ишетелгән шул авылга таба киттек. Һәркөн аяктан егылганчы бардык, төннәрен кар эскертләренә күмелеп йокладык. Арттан килүче булмады. Шулай итеп, мең бәла белән, үзебез билгеләгән бер татар авылын эзләп таптык. Бәхеткә каршы, ул авыл кешеләре өчен качаклар каршылау, аларны туган якларына озату яңа эш түгел икән. Беренче барып егылган өйдә үк безне җылыттылар, ашаттылар, эчерттеләр. Хәтта, күрше-күләннән җыеп, юлга акча да юнәттеләр. Кеше мәрхәмәтле. Акны карадан, гадел эшне гаделсезлектән аера белә».

Шуннан Лалә апа туп-туры әтисенең туганнары яшәгән Урта Азия якларына барып чыга. Җизнәсе аңа документ рәтләп бирә. Шулай ул, бер казах студентына кияүгә чыгып, «мөһерсезләр» сафына баса, медицина институтына кереп, аны тәмамлап чыга.

Лалә апаның калган туганнары да шулай берәм-берәм лагерьдан качалар. Тик үги әниләре Әминә апа гына юлда авырып егыла, туган-үскән якларына кайтып җитә алмыйча вафат була.

Лотфый җизнигә килгәндә, ул Урал заводларының берсендә эшләп, соңыннан Үзбәкстандагы якыннары кулында гүр иясе була.

Мин алдарак Бәдриҗиһан апа турында тулырак сөйләргә җыенган идем. Уйлавымча, бу эшне башкарганга кадәр әниемнең яшьлек елларын да искә төшерергә кирәктер. Чөнки әниемнең балалык еллары Бәдриҗиһан апа белән бергә бер ояда, бер мохиттә уза.

Әни минем өчен генә дип язган бер истәлегендә үзенең 1893 елның 18 августында фәкыйрь генә вак һөнәрче гаиләсендә тууын аңлата. Аның әтисе, минем Хәйдәр бабам, вакытында мәдрәсәдә укыган, шактый белемле булуына карамастан, кул хезмәте белән яшәүне артык күргән, голәмәдән аерылып, тормышын үз кул көче белән уздыра башлаган. Аның куллары һәр эшкә ятышлы була. Шулай да күбрәк пыяла кую белән шөгыльләнә. Шуңа күрә аны Пыялачы Хәйдәр дип йөртәләр. Ул көзге дә коя белгән, мич тә чыгарган.

Кызганычка каршы, бабай бик яшьли үлеп китә. Минем дәү әнием кулында биш ятим бала кала. Аларның иң олысы Шакир әтисе үлгәндә — унбиштә, иң кечесе, минем әнием, алты яшьтә генә булгандыр. Хәйдәр бабай вафат булганнан соң, мохтаҗлыкны җиңеләйтү өчен, дәү әни кул арасына керердәй балаларын, югарыда әйтелгәнчә, туганнарына озатырга тырышкан. Әниемнең олы апасы, Рабига апаны бер бай туганына асраулыкка бирә. Инде әйтелеп узганча, Шакир абыйны унике яшьлек энесе Габдрахман белән малайлыкка Кизилга озата. Дәү әнинең кулында хәзер кече кызлары Бәдриҗиһан белән минем әнием Зәйтүнә генә кала.

## 11

Әниемнең Бәдриҗиһан апасын һәрвакыт сагынып искә алуын мин бик яхшы хәтерлим. Әниемнең сөйләүләреннән аның кече апасы ифрат акыллы, тотнаклы һәм искиткеч уңган бер кыз булып күз алдыма килеп баса. Берсе ун яшьлек, икенчесе алты яшьлек кыз туганнар, ятим калгач, һаман бергә, олысы кечесен карап, кечесе олысын хөрмәт итеп, апасының сүзен тыңлап, бергә үсәләр.

Әнием истәлекләрендә үзләренең тормыш шартларын болай яза: «Мин туган өй таш мәчеткә каршырак Зариф Бадамшиннарның ишегалды түрендәге капкага таба өч тәрәзә караган, тәбәнәк булса да, бик калын бүрәнәләрдән салынган өч бүлмәле бер өй иде. Мин белгәндә залда түр буена сәке ясалган. Аның өстендә ике сандык. Сандыклар өстенә түшәк, юрган куелган. Идәндә җиз самавыр. Ишек катындагы

бүлмәдә шактый биек сәке. Без аны «эти сәкесе» дип йөртәбез. Шул ук бүлмәнең икенче почмагында тәбәнәк «әни сәкесе». Анда әни камыр баса иде. Шулай ук ян сәке ясалган. Ул сәкедә без, балалар, тезелешеп йоклыйбыз. Урын-җир юк хөкемендә. Мендәрләр көндез сәке кырындагы кечкенә сандыкка өелә, бик сәләмә тышлылары киштәгә, мич башына куела».

Әнием тагын болай яза: «Әтинең әнисе, Гайшә әби, балалар укыткан. Аның ире Садыйк бабай үлгәндә безнең әтигә нибарысы алтыҗиде яшьләр генә булган.

Гайшә әби ике бала белән тол калган. Тормыш авыр булганлыктан, әби һәм бабай үлгәч, Курса авылына Хәсән хәзрәт Уразгильдиевләргә барып торган. Хәсән хәзрәт әбинең ата-бер, ана башка туган агасы булган. Әбинең аларда күпме яшәгән булуын мин анык белмим. Ләкин ул, аннан кайткач, Чистайда балалар укыта башлаган. Гайшә әби кечерәк кенә буйлы, таза гына, бик гайрәтле, матур карчык булган. Анда кечерәк малайлар һәм зур кызлар укыган.»

Хәйдәр бабай ике тапкыр өйләнгән. Беренче хатыны Мәфтүхә үлгәч, ул минем дәү әнием Шәмсеҗиһанга өйләнә. Аннан ун бала була. Аларның бишесе вафат. Дәү әнием белән егерме ел гомер сөргәннән соң, Хәйдәр бабай да үлә. Дәү әни биш бала белән тол кала.

Әниемнең әтисе белән бертуган апасы Фатыйма исемле булган. Аның чибәрлеген күреп хәйран калган Чистай ишаны Закир, кызның фәкыйрьлегенә карамастан, Фатыйманы ундүрт яшендә үк үзенә икенче хатынлыкка ала. Бу вакытта көндәшенең олы кызы Фатыйманың үзеннән олырак була.

Фатыйма, ишан инде шактый карт булуына карамастан, аңа берсеннән-берсе чибәр сигез кыз, бер ул табып бирә.

Закир ишанның барлык балалары да заманының иң күренекле яки бай кешеләре белән никахлашканнар. Олы кызы Әминә Түнтәр мулласы Нәҗип хәзрәткә чыккан. Икенче кызы Камилә Фатих Әмирханның абзасы, Чистай мулласы Нәҗип хәзрәт хатыны булган. Улы Ибраһим Теләнче Тамак бае Хәлфин кызына өйләнгән. Өченче кызы Гарифә Курсави Хәсән хәзрәт улы Гариф муллага барган. Дүртенче кызы Җәүһирә Усадагы чәй төрдерүче Мансуров улы Миргалимгә чыга. Әсма исемле кызы дин теоретигы булып танылган Пермь мулласы Муса Бигиев белән никахлаша. Кызларның Шәмсениса исемлесе бай Акчуриннар килене була. Ишанның иң кече кызы Гөлсем — шулай ук Акчуриннар килене.

Әйткәнемчә, Закир ишанның барлык кызлары да чибәр, таза гәүдәле, белемле һәм тәрбияле булалар. Мин дә аларның берничәсен күреп белә идем. Камилә, Җәүһирә, Гөлсем апалар минем хәтеремдә яхшы сакланган. Гөлсем апа аерата чибәр хатын иде. Озынча йөз, сөрмәле кара эре күзләр. Әнә шул инде Балкан сугышы чорында, тагы ике иптәш кызын ияртеп, Төркиягә китә. Истанбул шифаханәләрендә болгарларга каршы сугышта яраланган төрек солдатларына шәфкать туташы сыйфатында ярдәм күрсәтә. Моны мин соңыннан Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» еннән укып беләчәкмен.

Әни үзенең истәлекләрендә «туганым абыстайның» (ишан хатыны Фатыйманың) үзләренә, бик фәкыйрь булгач, түбәнсетеп каравын да яза. Безгә карата рәхимсез иде, әнине дә, безне дә гел орышып тора иде, ди. Дәү әни аларга барып керләрен, идәннәрен юган, кунак килгәндә аш-су һәм барлык башка эшләрен башкарган. Әниемнең олы апасы Рабига апа яшьли шуларда асраулыкта булган. Әмма аны кияүгә биргәндә туйны дәү әни туганнары оештырган.

Рабига апа бәхетсез булган. Ишанның азгын улы Ибраһим аны кочлагән. Шуңа күрә, җинаятьне яшерү өчен, аны тизрәк кияүгә озатырга ашыкканнар. Юравымча, бу эштә аны тизрәк олактырырга Закир ишан үзе дә катнашкандыр. Һәрхәлдә, Рабига апа кияүгә (алдан

сөйләшү, бәлки әле акча төртү дә булгандыр) барып кына кайткан. Чөнки Рабига апа, Ибраһимнан булган баласы тугач та, иреннән аерыла.

Мин югарыда ишанның олы кызы Әминә Түнтәр мулласы Нәҗип хәзрәт хатыны булган дигән идем. Аларның балалары булмаган. Рабига апаның улы тугач, алар: «Үз ятимебез, төсе дә үзебезгә охшаган, баланы Түнтәргә илтегез».— дип киткәннәр.

Рабига апаны шулай баласын Түнтәргә озатырга мәҗбүр итәләр. Хәзер кыскача хәбәр итүе, әлбәттә, ансат ул. Ләкин бу кичерешләрнең нинди тирән, газаплы, авыр фаҗигә икәнлеген әйтеп тә, язып та бетереп булмый. Ятимлектә үскән никадәр хисле татар кызының бозык, әхлаксыз исерекбаш Ибраһимнан алдануы, аның өстенә, кемнән генә туса да, үзенең беренче газиз баласын чит кешегә тапшырырга мәҗбүр ителүе җиңел хәлмени? Ләкин Рабига боларның барысын да башыннан кичерергә тиеш була. Соңыннан, үз теләге беләнме, әллә шулай ук мәҗбүрәнме, баласын озата барган җиреннән, Рабига Түнтәрдә, Могыйн атлы юаш кына фәкыйрь бер хәлфәгә кияүгә чыга.

Тагын әниемнең хәл-әхвәлләренә әйләнеп кайтыйк әле. Хәйдәр бабай үлгәч, иренең исән чагындагы теләген үтәп, дәү әни аны җәдит мәктәбенә бирә. Ул заманда андый мәктәпләрдә парталар юк әле. Укучы идәнгә утырып, китапларын тәбәнәк эскәмиягә куеп укый. Шундый мәктәптә белем ала башлый әни.

Дәү әни өйнең алгы ягына фатирчы кертергә мәҗбүр. Ләкин мондый чара да ятим гаиләне бөлгенлектән коткармый. Җитмәсә, ишегалды хуҗасы Зариф Бадамшин йорт урыны өчен болардан елына ун сум акча таләп итә. Өйне сатарга мәҗбүр булалар. Хәйдәр бабайның төсе итеп, шул акчага самавыр сатып алалар һәм, кечкенә генә фатирга күчеп, шунда яши башлыйлар. Ләкин алай да барып чыкмый әле, очны очка ялгап булмый. Ул арада Чистайдан башта Шакир абыйны, аннан Габдрахман абыйны малайлыкка алып киткән Гали Дербишев килеп чыга. Аның хатыны саташып авырый башлаган, байның шуны туган авылына китерүе икән. Гали абзый, өй карап торырсыз дип, дәү әни белән әнине Кизил шәһәренә алып китә. Ә Бәдриҗиһан апа икенче мәхәллә мулласында асраулыкта кала.

Шулай итеп, әни белән дәү әни Гали абзыйларда өй хезмәтчеләре сыйфатында яшиләр. Монда тагын бераз чигенеш ясап, әнинең абыйлары Шакир һәм Габдрахман хәлләренә тукталырга кирәк. Байда хезмәт итүнең шарты мондый булган: дүрт ел тамак ялына бушлай хезмәт итәргә. Аннан соң, әгәр яхшы хезмәт итсәләр, хак тәгаенләнәчәк. Башта үсмерләр йорт малае хезмәтен үтәргә тиеш, ягъни кибеткә чәй, мал ташырга, идән себерергә, утын ярырга, ат карарга, сыер абзары көрәргә. Өс-башка — байдан калган иске-москы.

Ләкин, бу очракта бәхеткә каршы дип әйтергә кирәктер, дәү әниләргә Кизилда артык озак яшәргә туры килми. Көннәрдән бер көнне Гали абзыйның дивана хатыны дулап Кизилга килеп төшә. Чистайдан бер тол хатын ияртеп китте, дигән хәбәрне ишеткәч, ирем өйләнгән дип коты алынган икән аның.

Әниләр кышны ничек кирәк алай уздыралар, язын өйләренә Чистайга кайтып китәләр.

Өй хәзер — чүплек башында булса да — үзләренеке; җитмәсә, асраулыкта иза чиккән Бәдриҗиһан апа да гаиләгә кире кайта. Дәү әни сәүдәгәрләргә заказ буенча бүрек эче тегә, хәлле туган-тумачага барып керләрен, идәнен юа, кунак-китем булганда пешекчелек итә. Кызларына калган ашлар, сынык-санак та кайткалый мондый эштә. Дәү әнинең туган абыйсы, вак сәүдәгәр Баһау абзый да мәрхәмәт күрсәтә, ярдәменнән калдырмый. Ул атна саен диярлек ятимнәргә бер сум акча арттыра. Ул арада Шакир абый өчен Кизилдән ай саен дүрт сум акча килә башлый. Күрше-күлән арасында, бай булмасалар да, әйбәт, шәфкатьле ке-

шеләр күп. Әни үзенең истәлекләрендә, күршеләр икмәк пешергәндә куәстә калган камырдан кырып, безнең өчен хас «питрәч» (кечкенә ипи) пешереп кертәләр иде, дип яза.

Урам якка куш тәрәзә караган бәләкәй өйләрендә әниләр тату гына, ачыкмыйча гомер сөрә башлыйлар.

1907 нче елның җәендә Шакир абый әнисен һәм сеңелләрен Казанга чакыртып китерә. Дәвамлы булмаса да, Казанда яшәү чоры әнием өчен аның киләчәк тормышында гаять зур роль уйный.



## 12

Әле һаман минем язмыш хәл кылынмый. Үтенечне тапшырганга бер атнадан артык вакыт узды, ләкин комиссия ашыгырга уйламый. Агриппина Евграфовна (секретарь апаның исеме шулай икән), караласы гаризалары бик күп шул, нишлик, сезгә чират килеп җитми бит, ди.

Бүген дә, эш көне башлануга, шунда бардым. Хәлнең торышын белешкәч тә чыгып китим дисәм, Агриппина Евграфовна ничектер серле бер караш ташлап, сабыр итәргә, бераз көтәргә кушты. Андый-мондый күңелсезлек килеп чыкмадымы тагын дип, тәшвишләнеп, аңа сорау белән текәләм. Күрәсең, борчылуым йөземә бик ачык чыкты булса кирәк. Ул:

— Тынычланыгыз, әллә ни юк. Менә, утырыгыз әле, — диде. Мин, өстәл янындагы утыргычның читенә утырып, аның гүзәл йөзенә текәлгәч, ул сөйләп китте:

— Комиссия әгъзалары белешергә куштылар... Сез ни өчен үзегезнең телдәге материалларның берсен генә тәрҗемә итеп китердегез. Ә икенчесен, газетадагысын, сезнең портретыгыз да төшерелгәнен игътибарсыз калдыргансыз.

— Мин анысын тәрҗемә итү кирәксез дип белдем. Чөнки анда басылганнар комиссия өчен бөтенләй кызыксыз.

— Шулай да анда ниләр язылган соң? Ул, минемчә, сезнең турындагы мәкалә.

Агриппина Евграфовна, матур тигез тешләрен балкытып елмайган хәлдә, миннән җавап көтте.

— Юк,— дидем мин.— Ул минем турыдагы мәкалә түгел. Ул — минем повестьтән өзек кенә.

— Ә-ә, сез язучы да мыни әле?

Агриппина апа тагын күңеллерәк итеп елмайды. Аның озын керфекле, нурлы зәп-зәңгәр күзләрендә миңа карата хәзер кызыксыну гына түгел, хәтта хөрмәт хисләре дә чагыла иде кебек.

— Әйе, язгалыйм,— дидем мин, башны ия төшеп һәм бу хатынның күңел түренә үк үтеп керә торган үткен карашыннан куркынып.

— Күптән язасызмы?

— Ничек дип әйтим. Балачактан бирле маташам.

Ул миңа сәер бер кызыксыну белән карап ала. Мин саубулашып чыгып китәм.

Әйе, сүз әдәбиятка кагыла калса, мин бу апага бик күп нәрсәләр турында сөйли алыр идем. Аңа үземнең әдәбият белән татлы мавыгуымның беренче сәбәпчесе кем икәнлеген дә, тагын башка бик күп нәрсәләр турында да озаклап сөйли алыр идем. Ләкин бу, минемчә, аның өчен бөтенләй кирәксез, аңлаешсыз нәрсә. Кызыксынуы да болай гына, бары үз гүзәллегенең көчен сынау өчен генәдер...

Мин, көндәгечә, якындагы скверга кереп, таныш эскәмиягә утырам. Әдәбиятка бәйле рәвештә, күз алдымнан әдәби каһарманнар уза. Бөек Тукай турында уйлыйм. Аннары күңелемдә әнием гәүдәләнә. Ни өчен шулай? Билгеле, әниемнең Тукайны шагыйрь буларак яратканы

өчен генә түгел, ул аны шәхес буларак та белгән, якын күргән. Хәер, моны әниемнең үзеннән сөйләтү яхшырактыр. Әни үзенең истәлекләрендә болай яза:

«1907 елның җәендә без Казанга күчеп киттек. Өйгә фатирчы керттек булса кирәк, хәтеремдә юк. Без Казанда Заводской урамда дүрт бүлмәле фатирга урнаштык. Абыйлар приказчик булып эшли. Без апам белән русско-татарская школага укырга йөри башладык».

Укысалар да, әниләр Казанда эшсез генә утырмыйлар. Укудан кайту белән, тегү-чигүгә утыралар, кибетчеләргә күлмәк тегәләр, мендәр тышлары чигәләр. Әнием һәм аның апасы Бәдриҗиһан, шундый алдынгы мәктәптә уку аркасында, беренче тапкыр театр белән дә танышалар. Укытучылары Әминә апа аларны, өченче класс укучыларына ияртеп, рус театрына алып бара. Чистай кызлары спектакль күреп хәйран калалар. «Шуннан соң,— дип яза әнием,— без, театрга алып бар, дип, Шакир абыйның үзегенә үтә башладык.»

Бераздан соң әниләр арзанлырак фатирга, Мещанский (хәзерге Нариман) урамындагы Алат Хәким өенә күчәләр. Моннан инде Фатих Әмирхан җитәкләгән «Әл-ислах» редакциясе дә ерак түгел, ул хәзерге Тукай урамында гына.

Әниләр һәр көн иптәш кызлары белән йөрергә чыкканда шул редакция урнашкан өй яныннан узалар. Көннәрдән бер көнне алар, батырчылык итеп, редакция ишеген ачалар, анда Фатих Әмирхан белән танышалар һәм үзләрен Габдулла Тукаев белән таныштыруларын үтенәләр.

Мин тагын әниемнең истәлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк дип уйлыйм. Ул болай яза: «1908 елның март башларында булса кирәк, бер якшәмбе көнне безгә апам белән, хәзерге Тукай һәм Татарстан урамнары почмагында яшәүче танышларыбызга барышлый, редакция яныннан үтеп китәргә туры килде. Редакция тәрәзәсе ачык, Фатих абый тәрәзә янында утыра. Без аның белән исәнләшкәч, ул: «Кая барасыз? Озак тормагыз, тиздән монда Тукай киләчәк»,— диде.

Без, гадәттә, мәктәптән кайтуга эшкә утыра идек. Абыйлар эшләгән Бәхтиевләр магазинына канва белән күлмәк, мендәр тышлары чигә идек. Шуңа күрә бер минут та эшсез тормыйча, кая гына барсак та, эшләребезне үзебез белән алып бара идек. Без әле барган җиребездә дә Бәдриҗиһан апа, чәй эчкәч тә, эшкә утырды. Мин, Тукай килмәде микән дип белешү өчен, хуҗа хатыны Фатыйма апага әкрен генә: «Әни бер җиргә керергә йомыш кушкан иде, шунда барып кайтам»,— дип, урамга йөгердем. Капкадан чыгуыма, Фатих абыйның сеңлесе Гөлсем очрады. «Ярый әле килеп чыктың, сезне эзләп кая керергә белми тора идем, Тукай килгәнлеген Фатих абый әйтергә кушты»,— ди.

Мин апа янына кире йөгереп кердем. Әни бик тиз өйгә кайтырга кушты, дип аны алып чыктым. Юкса Фатыйма апа безнең өчен таба ашлары пешерә башлаган икән. Әгәр ашап утырсак, Тукайның китеп баруы ихтимал. Апа тиз генә эшләрен җыештырды да, хуҗа апаның үпкәләвенә карамастан, без чыгып киттек.

Без Аппаковларга барып керүгә (идарә шунда иде) зал яктан Фатих абзыйның энесе Ибраһим абый килеп чыга. «Әйдәгез, кызлар, күптән күрсәтегез дип йөдәткән Тукай белән күрештерәм үзегезне»,— ди. Үзенең култыгын тәкъдим итә. Мин аңа барып тотындым, Гөлсем — миңа, апага — Фатыйма Аппакова. Мин Ибраһим абыйга: «Анда тагын кемнәр бар?»— дим. Ул: «Фатих, Тукай, «Әл-ислах»ның рәсми редакторы Вафа Бәхтияров»,— диюгә, Фатыйма, «И-и, кеше күп икән, кермим»,— дип читкә китте. Апа да: «Вафа ага булгач, оят шул»,— дип куйды. Гөлсем дә минем кулдан ычкынды. Мин Ибраһим абыйның беләгеннән кулымны алдым. Шулай барыбыз да аптырашта калдык. Ибраһим абый бездән көлә: «Вафа нишләп олы кеше булсын, аның мыегы минекеннән дә кыскарак»,— ди.

Без, батырчылык итеп керү өчен, тагын Ибраһим абыйга тотынабыз. Ләкин Фатыйма киреләнә башлый. Мин аны орышам. Чөнки барысы да аңа карыйлар. Ибраһим абый тагын көлә. Соңыннан түземе калмады. Алайса, мин кереп китәм, хушыгыз, ди. Мин, барлык кыюлыгымны җыеп: «Кызлар, кермәсәгез, мин керәм,— дидем.— Соңыннан үпкәләмәгез, үкенмәгез».

Бу сүзләр үзенең тәэсирен ясады булса кирәк. Кызлар, тезелешеп, Ибраһим артыннан эчкә керделәр. Мин туп-туры Фатих абый янына уздым».

«Әл-ислах» редакциясе зур гына бер залга урнашкан була. Элек монда Муса Бигиев яшәгән. Урамга таба — өч, ишегалдына ике тәрәзә карый. Урам як тәрәзәләренең берсе каршысына, ишектән кергәч тә уң якта, карават куелган. Фатих Әмирхан караватка утырган. Аның алдында кечерәк кенә өстәл.

«Мин иң элек Фатих абый белән күрештем,— дип дәвам итә әни.— Фатих абый: «Кызлар, шагыйрь Габдулла Тукаев белән таныш булыгыз»,— диде. Безне үзенең уң ягындагы урындыкта утырган кешегә исемнәребезне әйтеп тәкъдим итте.

Тукай кара пинжәк, юллы ак күлмәк, кара галстуктан, үзе яланбаш иде. Чәче озын да, артык кыска да түгел. Ул күрешкәндә безгә бер генә караш ташлады; аннан, кулларыбызга текәлеп кенә: «Исән-сау йөрисезме»,— дип куйды... Мин күзләремне һич аннан аермыйм. Фатих абый безне кәрт уйнарга чакыра. Тик без кыймыйбыз. Фатих абый бик рәхимсез кыйлана, аңа һаман яхшы кәртләр эләгә. Тукай кәрт алган саен: «Шул инде, бәхетсез кешегә һәрвакыт кире килеп тора, җүнле кәрте дә керми бит»,— дип зарлана. Ә мин аны кызганам, аның өчен йөрәгем әрни. Мин, уенны бүлеп, кәртләрне барыбызга да бүлдерергә карар кылганда гына алгы яктан әни тавышы колагыма чалынды. Коелып төштем. Апа — миңа, мин апага карашабыз. Фатих абыйдан рөхсәт сорап, ул никадәр утырыгыз әле дисә дә, без чыгып китәбез. Тукайның: «Ник утырмадыгыз?»— дигән сүзләре колагыма керә. Эш узгач, безнең кабалану урынсыз икәнлеген аңладык. Чөнки әни күрше бүлмәдә яшәүче Муса җизнигә килгән икән. Ул шунда кереп китте. Без исә, Тукайлар янына яңадан керергә уңайсызланып, тиз генә өйгә кайтып киттек.

Юлда барганда апам, әни сизмәсә дип, безнең капка төбендә һәрвакыт хәер эстәп утыручы карчыкка биш тиен бирергә нәзер дә әйтеп өлгерде.

Бу минем Габдулла Тукаев белән беренче тапкыр очрашуым булды.

Тукай белән без икенче тапкыр Рабига һәм Бәдриҗиһан апаларым белән Екатерининский (хәзерге Тукай) урамыннан барганда очраштык. Рабига апа безгә кунакка килгән иде ул вакыт. Безнең яннан гөрләп трамвай узды. Рабига апам: «Трамвай тәрәзәсеннән бер урыс башын селкеп узды,— ди.— Сезгә түгелме?» Бәдриҗиһан апамның күзләре үткен, ул карау белән: «Тукай»,— диде. Мин, ачык күрмәсәм дә, сәламләп баш идем. Трамвай ул арада, дугасыннан чатыр-чотыр утлар чәчрәтеп чаттан борылды да, күздән югалды. Бу вакыйганы искә алуым шуннан: озак та үтми, шагыйрьнең «...гә» исемле шигыре басылып чыкты.

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген,
Ул шуңар да шатлана бит, чын җүләр түгел диген!

Күргәнең бармы әле корьәндәге мәдхияни?
Ул синең васфында: «Ля шәркыйя, ля гарбия»,— ди!

Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла сатып.

(Монда мин, шигырьнең әнием турында булганлыгы аңлашылсын өчен, шуны искә төшерергә тиеш: Коръәндә «Зәйтүнәтен ля шәркыйя, ля гарбия» дигән сүзләр бар. Тукай бу шигырендә шуңа ишарә ясый. А. Р.)

— Шул ук Екатерининский урамында Тукайны мин тагын бер тапкыр күрдем,— дип дәвам итә әнием.— Бәдриҗиһан апам белән «Әльислах» редакциясе янынннан узып бара идек, тәрәзәдән Фатих абыйны һәм идарәдә утырган кешеләрне күреп калдык. Кеше күп булганлыктан, керергә кыймадык. Ләкин күп тә үтмәде, апам: «Әнә, Тукаев килә»,— диде. Ул арада Тукай үзе дә килеп җитте. Безнең белән, гадәтенчә, кыяр-кыймас кына исәнләште. Мин, аның янына барып, кул биреп күрештем. Апам да килеп күреште. Шагыйрь ашыккан сыман күренде. Ләкин мин аның юлын кисеп: «Кая барасыз?»— дип сүз башладым.

— Редакциягә. Фатих анда микән, сез булмадыгызмы?— диде ул.

— Тәрәзәдән күрдек. Кеше күп булганга күрә, кермәдек.

Һәм мин аның ниләр эшләп йөрүен төпченә башладым. Ул исә әдәби кичәләр оештырып йөрүләрен, шунда хор өчен кирәкле материаллар әзерләвен әйтте. «Сез килерсезме?»— диде. Барырга киңәш итте. Үзе сөйләшкәндә түбәнгә карый, миңа йөзенә карамаганда гына күз ташлый. Мөмкин кадәр карашларның очрашмавын тели, күрәсең, һәм дә тизрәк китәргә ашкына. Мин, аның кулыннан тоткан килеш, байтак вакыт сөйләшеп тордым. Яз көне булганга, аяк асты пычрак иде. Мин сөйләгәндә ул аягы белән сулы балчыкны изгәләп тора. Бу лыбырдыкның сүзе озынга китте, дигәндәй, миннән тизрәк ычкынырга тели кебек үзе. Мин, бәлки, аның сөйләшәсе килмидер дип, бәлки кеше-кара күрүеннән хурланадыр, дип уйладым. Җитмәсә, аннан аерылгач, апам мине орышырга тотынды. «Кешене шул кадәр аптыратмасаң, беләсең бит, ул эш кешесе. Эше ашыгычтыр, синең белән сөйләшәсе генә килеп тормас. Ә син бер артына, биш алдына төшәсең. Шул хәтле чекрәя-чекрәя күзләренә кермәсәң, күреп туймассыңмы әллә? Котым калмады. Бу инде «Габдулла әфәнде, мин сезне сөям», дип әйтәме дип торам».

Апамның мондый сүзләренә ачуым чыкты. Нишләп мин алай әйтим? Ул бит миңа абыем кебек кеше. Аның миңа карау ихтималы да юк. Олы кеше, караса, сиңа карар. Мин аны бары тик хөрмәт итеп кенә сөйләшәсем килә, якыннан таныш буласым килә, дидем.

Кайчак, минем ачуымны китерү өчен, апам болай җырлый иде:

Күк күгәрчен күктә уйный, башлары әйләнмәсә;
Бик сөйсәң дә баралмассың, чәчләрең бәйләнмәсә.

Яки:

Карар инде, карар инде, карап туялмас инде,
Ни кадәрле карасаң да, ул синә булмас инде.

Бик дустанә сөйләшкәндә апам, эчке серләрен әйтеп, үзенең Фатих абый белән булуын, минем Тукай белән булуымны хыялланып куя иде. Андый чакларда үзебезнең хыялдан үзебез оялып, кеше сизмәсен тагын дигәндәй, як-ягыбызга карана идек. Аннары тагын:

Бүген күргән өч егетнең җем-җем итә кигәне,
Фатих алма, Ибрай хөрмә, Тукай кура җиләге.

— дип тә җибәрә идек.

Габдулла Тукай белән без тагын әдәбият кичәсендә күрештек. Ялгышмасам, ул кичә мәдрәсә ташлап чыккан шәкертләр файдасына ясалды.

Фатих абый безгә контрамарка бирергә һәм үзе янына, беренче рәткә утыртырга вәгъдә итте. Кичәгә барганда ак күлмәк, ак калфаклардан барырга кушты.

Кичә бик күңелле барды. Тукай үзенең «Утырышу» шигырен укыды. Кулында бөгәрләп тоткан бер кәгазь бар иде. Тавышы бик каты да,

йомшак та түгел — уртача, яхшы итеп, интонация белән укый. Бик озак кул чапканнан соң гына, чыгып, тагын бер шигырен укыды. Сәгыйть Рәмиевнең нәрсә укыганын хәтерләмим. Шәкертләр хор белән «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?»не җырладылар.

Антракт булды. Мин тиз генә биш тиенлек конфетти барып алдым да, сәхнәгә чыгуларын көтеп тордым. Тукай костюмнан, галстуктан иде, башында кара хәтфә кәләпүш. Кызларның һәммәсе дә калфактан, ирләргә кәләпүштән килү шарт итеп куелган иде. Минем күлмәгем ак булса да, калфагым кызыл хәтфәдән, ак төслесен таба алмадым.

Алдан Тукай килеп чыкты. Кулымдагы конфеттидән күп кенә алып аңа сиптем. Бөтен чәче, кәләпүше матур кәгазьләр белән бизәлде. Соңра Сәгыйть Рәмиевкә өлеш чыгардым да, калганнарын тагын Тукайга сибеп, аның кулын кысып, муаффәкыйять белән тәбрик итә башладым. Ул көлеп баш иде, рәхмәт әйтте. Аннан бераз кырыйгарак китеп сөйләшә башладык.

Залда музыка танцы көйләрен уйный, кызлар, егетләр бии. Кызларның күкрәкләрендә чәчәк, егетләр әллә нинди күк тасмалы бантлар таккан. Югарыдан серпантин тасмалары төшерәләр, биючеләр шуңа уралып бииләр. Без шул кызыкны карап сөйләшәбез.

— Ничек, кичә сезгә ошыймы?— ди Тукай.

— Бик ошый. Монда килгәч, мәктәбебез белән бер мәртәбә Большой театрда гына булдым. Мондый әдәбият кичәләрен күргәнем булмаганга, моннан артыгын күз алдыма китерә дә алмыйм.

— Сез танцевать итмисезме, теләмисезме?— дип сорый.

— Әле яңа гына танцыга өйрәнә башладым. Белмим. Мин, өйрәнгәч, сезнең белән генә танцевать итәргә телим. Бергә танцевать итәрбез, яме?

— Мин дә әле яңа өйрәнә башладым. Мин дә сезнең белән генә танцевать итәрмен,— ди ул, үзе көлә.

«Кем белән килдегез?»— дип сорады. «Апам белән килдем, кайтканда бергә кайтырбыз, халык киткәндә сез дә кайтасыздыр бит?»— дидем. Тукай ризалык белдерде. Шуннан соң ул тәмәке тарту бүлмәсенә кереп китте. Мин почта уены өчен кәгазь алдым да Фатих абый янына барып утырдым. Бер ягымда Фатих абый, икенче ягымда — Гани байның энесе диделәр — Мәхмүт бай утыра. Бик күп энҗе белән чиккән кәләпүш кигән, күзенә бик калын итеп сөрмә тарткан, калын, озын таза гәүдәле. Шул кеше күзләрен чекрәйтеп карый башлагач, тиз генә урынымнан торып, икенче креслога күчтем. Фатих абый көлә. Үзеңә шундый матур итеп карап торган кеше яныннан ник шудың, ди. Ул да дикъкать иткән икән.

Кичә тәмам булды. Мин, ни хәтле эзләсәм дә, Тукайны таба алмадым. Апам: «Әйдә инде, кешедән калабыз ич»,— дигәч, безне көтеп торган Ибраһим абый, Солтан Рахманколый, Фатыйма, Гөлсемнәр белән кайтып киттек».

13

Әни үзенең истәлегендә, мәгълүм кичәдән кайткач, шагыйрьнең сүзендә тормавы аркасында туган кичерешләрне дә яза. Ул Тукайның үзенә карата мөнәсәбәте турында шик-шөбһәләргә бирелә. Җитмәсә, иптәш кызлары болай да дөрләп торган күңел ялкыннарына: «Бик исе китәдер инде синә Тукайның»,— дип, май сибәләр. Аннан әнием: «Г. Тукай турында шундый уйда булуым, ул үзен шулай олы тоткан-да, кыз башым белән аның янында шул хәтле кыю йөрүем оят бит. Ул һәрвакыт миннән көләдер, иптәшләренә дә әйтеп, бергә көләләрдер кебек тоелды. Чынлап шулайдыр. Мин «бергә кайтырбыз» дигәч тә күренмәде бит. Безнең Болгар номеры яныннан узачакны белә бит.

Ул йә безне көтми китте, йә китсен дип, чыкмый торды дип тә уйладым»,— дип яза.

Ләкин бераздан яралар төзәлә. Тукайның шигырьләре әниемне кызыксындырганнан-кызыксындыра бара. Алар, Бәдриҗиһан апасы белән, Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» дигән шигырен бик ошаталар. Ничек итеп шуны укыйсы, ятлыйсы икән! Тукайның үзен күреп тә булмый, уңайсыз да. Бу әрсез кызлар тәмам сагыз икән, дияр.

Шулай да кызлар әлеге кичәдә катнашкан Фәхрелислам Агеевтан сорап карарга булалар. Нәтиҗәдә, хәбәр Тукайга ишетелә. Һәм ул кеше аша үзенең шигырен кызларга бүләк итеп җибәрә. Әниемнең күңеленә җылылык йөгерә.

Ләкин әниемә яраткан шагыйре белән озаклап очрашырга мөмкинлек тиздән киселә. Казандагы тормышның авырлыгы, кыйммәтчелек, дәү әнине «Чистайга кайтырга кирәк» дигән фикергә китерә. Ни әйтсәң дә анда азык-төлек арзанрак; аннан, кечкенә генә булса да, куышлары бар. Ә монда егетләр иртәдән кичкә кадәр байга хезмәт итәләр, кызлар исә көн-төн канва чигәләр, алай да очын-очка ялгау читен. Шулай итеп, 1908 елның җәй башында әниләр Чистайга китәргә әзерләнә башлый. Кызлар соңгы тапкыр, бәлки-бәлки дигән өмет белән, «Әл-ислах» редакциясенә баралар. Бәхеткә каршы, Тукай редакциягә килгән чак була. Фатих Әмирхан янында кеше күп булу сәбәпле, кызлар ишектән генә редакция хезмәткәре Таһирны чакырып, Тукайның үзләре янына чыгып керүен үтенәләр.

«Тукай чыкты,— дип яза әни,— күрештек. Бергәләп урамга чыктык. Үзебезнең бүген Чистайга бөтенләйгә китәчәгебезне, монда бары аны соңгы тапкыр күрергә генә килгәнебезне әйттек.

Әлбәттә, бу хәбәрне ишеткәннән соң шагыйрьнең күңелсезләнүен күз алдына китерү читен түгел. Шагыйрь, башын аска иеп: «Бик җәл»,— ди. Сөйләшәләр. Ләкин әңгәмә ничектер барып чыкмый. «Казан ошадымы соң?»,— дип сорый Тукай. «Безгә бик ошады да, тик әниебез китәргә тели ич»,— шулай диләр кызлар. «Укуыгыз әрәм була»,— ди Тукай. «Нишләмәк кирәк, бәлки әле укуны Чистайда дәвам иттерербез»,— диләр кызлар. Әнием Тукайның күңелсез кыяфәттә булуын, бәлки, сәламәтсезлек аркасындадыр дип, кабат-кабат аның исәнлеге турында сораша. Хәтта аның сул күзендәге ак тап турында да сорарга җөрьәт итә. «Чәчәктән ул»,— ди Тукай, тагын да күңелсезләнә төшеп. Кызлар шагыйрьгә хат язып торырга булалар. Адресын сорыйлар. «Мин сезне озатырга төшәрмен, шунда адресны да бирермен»,— ди Габдулла. Кызлар китәләр. Тукай фуражкасын селкеп кала.

Бу әниемнең яраткан шагыйрен соңгы тапкыр күрүе була. Чөнки Тукай бу юлы да сүзендә тормый. Әни пристаньдә көтә, ул күренми. Чистайга кайткач, әнием шагыйрь белән бөтенләй бәйләнешен югалта. Тукай турында бары матбугат аша һәм имеш-мимешләр аркылы гына мәгълүмат алырга кала.

Әниләр Чистайга кайтып бераз вакыт үткәч, бер газетада «Кызык гыйшык» исемле шигырь басыла.

Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай,
Шәһрене күптән барып җиткән бугай...

Гаҗәп хәл! Стиле Тукайныкы, әмма имзасы — «Мәҗнүн». Әниемнең апасы Бәдриҗиһан: «Моны Агеев язгандыр»,— ди. «Әйе, шулай булырга тиеш»,— ди әнием дә, чөнки ул Бәдриҗиһан апасының Фәхрелислам белән дус икәнлеген белә. Бәдриҗиһан Агеевка рәсемен дә бүләк иткән ич. Әнием ул вакытта шигырьнең Тукай тарафыннан үзенә карата язылганлыгын башына да китерми. Әйе, Тукайның әниемә булган мәхәббәте кайнар, сәер һәм яшерен була.

Шагыйрьнең: «Шигырь язсам да ялган кул куям»,— дигән сүзләрен һич искә алмыйлар ул вакыт кызлар.

«Мин бу шигырь үзем турында язылган дип уйламадым. Элекке фикерләрем гел кирегә чишелеп килгәнгә күрә, тагын бер тапкыр ялгышудан курыктым»,— дип яза әнием үзенең истәлегендә.— Үземчә, ул миңа укуга дәртле, шат күңелле милләттәшем дип, агаларча, дусларча гына карады. Мин бик яшь идем шул ул чак...»

1909 елны Бәдриҗиһанны әле яңа гына мәдрәсә тәмамлаган Лотфый Җәүһәревкә кияүгә бирәләр. Шул көннән башлап, әнием иң якын дустыннан аерылып, рухи ялгызлыкта кала. Әниемне дә кияүгә чыгарга сорыйлар. Ләкин дәү әни, ул яшь әле, Зәйтүнәм дә китсә, мин бөтенләй ялгыз калам, дип, аны кияүгә бирми.

Август айларында Казаннан Чистайга «Сәйяр» труппасы килә. Шунда Тукай труппа башлыгы Габдулла Кариевка бер амәнәт тапшыра: Чистайда минем ике таныш кызым бар, шуларга контрамаркалар җибәр, ди. Әни үзенең истәлегендә бу вакыйганы түбәндәгечә тасвир итә: «Беркөн шулай эчем пошып өйдә утырганда, Казаннан «Сәйяр» труппасы килгәнлеген ишеттем. Шундук Баһау абзыйларга киттем. Бу вакыт Баһау абзый үзе үлгән, аның улы Ибраһим өйләнгән иде. Мин аларга баруга, Ибраһим эшеннән кайтты. Мин аның энисе Камәр җиңгине, әйдә, театрга барыйк, дип йөдәткән чак иде бу. Ибраһим исә, кайтып керүгә, әле мине күргәнче үк, энесенә алгы бүлмәдән:

— Исмәгыйль, хәзер үк Шәмси апаларга бар. Казаннан артистлар килгән, Тукай аларга Зәйтүнәләр өчен ике билет бирергә кушкан,— дип кычкырды. Мин тиз генә алгы бүлмәгә чыктым, билетлар алдым, әйдә, бергә барыйк, дип, тагын җиңгине йөдәтә башладым. Ул бармыйм, ди, назлана. Ибраһим исә барса хатыны белән генә бара инде, чөнки хатыны миннән көнләшә. Шуңа күрә мин Ибраһим белән җунләп сөйләшмим дә хәзер.

Миңа спектакльгә ул вакыт кодача тиешле бер апа белән барырга туры килде. Театрга баргач, миңа, билгеле, билет өчен кемгәдер рәхмәт әйтергә кирәк иде. Ләкин кемгә, ничек әйтергә — моны ачык белмим. Залда хатын-кыз аз, утырган җиремдә дер калтырап, Чистай карагруһлары үземне тотып кыйнамасалар ярар иде дип, котым очып урырам».

Кышын әни укырга йөри башлый. Ләкин ишан улы, миллионер Хәлфин кияве үзенә укырга йөрүче кызларны күбрәк өй эшен эшләтү белән мәшгуль. Бай әле китапханәсен тәртипкә китерә, кызларга китап ташырга куша, йә башка йомыш таба. Ул гына да түгел, хәрчәүнә ачып кәсепкә керешә; ә дәресне, бик эшем кешесе булып кыйланып, телефон аша гына биреп маташа. Кыскасы, укуның рәте-чираты юк. Шулай азапланып йөргәндә, көннәрдән бер көнне әнинең туганнан туган апасы Гарифә Курсадан Чистайга кунакка кайтып төшә. Ул әниемнең вакыты бушка узганлыгын белгәч, үзләренә чакыра башлый.

Шулай итеп, әнием Югары Курсаның имамы һәм мөдәррисе Гариф җизнәсеннән сабак ала башлый. Шул ук вакытта Гарифә апасының кызлар мәктәбендә дәрес бирә. Әни ул мәктәпне болай тасвир итә: «Мәктәп Гарифә апаларның түбән өендә. Анда ике бүлмә. Мин аларның алдагысында укытам. Сәке. Сәкедә дүрт эскәмия. Һәр эскәмия янында өчәр кыз тезләнеп утыра. Зур мич арасына сыер бозаулагач — бозау, сарык бәрәнләгәч — сарык бәрәннәре кертеп ябалар. Кызлар берәр көлтә күтәреп килә. Без укытырга төшкәндә зуррак кызлар мич яга торган булалар. Дустым Сафия (Гарифә апа кызы, ул киләчәктә язучы М. Гали хатыны булачак. А. Р.) белән без — вак кызларны, Гарифә апа үзе олыларны укыта. Кичен җизни ястүдән кайткач, үзебез аңардан дәрес алабыз. Коръән, хәдис, гарәпчә сарыф, нәхү укыйбыз. Җизни үзе коръәнхафиз, Мысырда укып кайткан кеше».

Шулай итеп, әнием күңелсез башланган кыш айларын Курса авылында дәвам иттерә. Хезмәте тамак ялына була.

Шулай кыш уза, әни тагын Чистаена кайтып китә.

Өйдә көннәр буе канва чигә, әбигә булыша. Аны, кияүгә димләп, тагын йөдәтәләр. Әни, елап, бу хакта абыйларына Казанга хат арты хат җибәрә. Шакир абыйдан «Зәйтүнәне көчләү булмасын»,— дигән хат килгәннән соң гына, үгетләү-кысулар туктала.

Шул җәйдә Тукайга бәйләнешле тагын бер вакыйга була. Әнием аны болай яза: «1910 елның җәй айлары иде. Ачык тәрәзә янында канва чигеп утырам. Капка төбендә сагыз ч[illegible] суга баручы тау асты Мәрьям апа миңа кычкыра: «Зәйтүнә, әнә сезгә әллә нинди урыслар килә». Үрелеп карасам, Ибраһим абый бер кеше ияртеп килә. Болар бераздан, рөхсәт сорап, өйгә керделәр. Ибраһим абый мине Габдулла Кариев белән таныштыра. Кариевнең мине эзләп килүенең сәбәбе шунда, спектакль кую өчен бер хатын-кызлары җитми икән. Зәйтүнә туташ катнаша алмас микән, янәсе.

Кунакларны самавыр куеп чәй эчердем. Мин үзем уйнап карарга каршы түгел, әнине Ибраһим абый күндерә алса, риза мин, дидем. «Яшь хатын» драмасында миңа карт хатын ролен ятларга кушып, кунаклар чәйдән соң китеп бардылар. Икенче көнне Ибраһим абый килеп сөйләшкәч, әни яраткан энесенә каршы килә алмады. Бары бер шарт куйды: «Зәйтүнәне егетләр янында, зинһар, ялгызын калдыра күрмә»...

...Минем уйнавымны яраттылар. Спектакльдән соң мине Кариев озата барды. Безгә кайткач, чәй эчтек, сөйләшеп утырдык. Кариев шунда миңа: «Тукайдан сезгә күп сәлам,— диде.— Тукай да Чистайга килергә булып калды, иртәгә үзе белән телефон аша сөйләшәм».

Мин аңардан Тукайны бик ныклап безгә чакыруын үтендем, үземнең бик күрәсем килгәнлеген әйттем. «Номерга урнашу кыен булса, үзебезгә килсен, безнең өй кунак ярата»,— дидем. Ул:

— Тукайның сезнең хакта язган әсәрләрен күргәнегез бармы?— дип сорады.

— Юк. Кайсы шигыре минем хакта?

Кариев Тукайның бер җыентыгын ача да шундагы «...гә» дигән шигырьне күрсәтә.

— Шигырьне язгач та миңа укыды, бу кем турында, дип сорады. Мин бит коръәнхафиз, сезне белмәсәм дә, Зәйтүнә исемле берәр туташ турындадыр дигәч, бик шатланды.

Кариев миннән: «Боларны әйткәнгә миңа ачуланмыйсызмы?»— дип сорады. Мин бик шат идем. «Сезгә рәхмәт кенә әйтәм»,— дип, Тукайны Чистайга чакырып, тагын бер тапкыр үтендем.

Икенче, өченче көнне мин Кариевтән, Тукай кайчан килә соң, дип сорасам да, ул, сөйләшә алмадым әле, дип кенә җавап бирде.

Кариев миңа ул очрашуында, «Һәдияне Һәдия» дип язып, Тукайның фоторәсемен бүләк итте. Үз рәсемен дә бирде. Ялгышмасам, мин дә бер рәсememне бирдем бугай.

Көзен мин тагын Курсага укытырга киттем. Берникадәр вакыттан соң миңа Чистайдан бер якын кешем хат яза. Анда: «Фатих абый сине язучы Тукаевка димләп хат язган. Без, үзенә яз, дип синең адресны җибәрдек»,— диелгән иде. Шуннан соң мин Казаннан Фатих абыйдан хат алдым. Тәассефкә каршы, ул хатта мине башка кеше соратуы гына язылган иде. Башта бик сагынып сәлам язган, аннары — без Казанда чакны Фатих абыйлар белән кулларга сугып «песием-песием» уйный идек — шуны искә алган. Кулларыңның сугылудан кызаруы беттеме әле, дигән. Үземнең хәл-әхвәлем, ничек вакыт уздыруым, нинди хисләр белән яшәвемне белешкәч, мине Вафа Бәхтияровның үзенә соратуын әйткән. Шуннан соң гына хатның бер почмагына бөкләп: «Тукай да сине онытмый»,— дип язып куйган. Үзенең бер дә онытмавын әйткән.

Фатих абыйдан мондый хат килгәннән соң, минем кәефем бик

нык кырылды. Әллә хатны ялгыш укыдыммы дип тә уйладым. Бер җавап та бирмәдем. Бары үзем белән бергә укыткан Сафия дустыма, бер кемгә дә әйтмәячәгенә ант иттереп. Вафага сораган җирен укыттым.

Ул җәйне мин Казанга бара алмадым, җәйне олы апам Рабигаларда — Түнтәрдә узырдым».

Әнием шул мәгълүм хат килгәч, Курсада икенче елын укыткан-да, Бубида кызлар дарелмөгаллимәте барлыгын ишетә һәм бай хәлле кешеләрнең кызлары шунда укыганлыгын белә. Үзенең әле укытучы буларак белемгә мохтаҗлыгын сизгән хәлдә, ул шул Буби мәктәбендә, һич югында, аның курсларында ике-өч ай гына булса да укып кайту турында хыяллана башлый. Ләкин мондый хыялны тормышка ашыру өчен иң элек акча кирәк шул. Әнием, өметен өзеп, Курсада балалар укытуын дәвам иттерергә мәҗбүр. Ул кышта да аңа хезмәт хакы түләнми. Бары язгы каникулга Чистайга кайтып китәр алдыннан гына биш сум акча төртәләр. Дәү әнинең мондый хәлгә бик хәтере кала һәм ул әниемне Курсага бүтән җибәрмәс була. Әни шулай Чистайда кала. Ләкин укуын дәвам иттерү теләге аның күңеленнән бер генә минутка да китми. Ул кемнәндер, татар байлары ятимә кызларның кайберсен үз исәпләренә Бубига җибәреп укыталар икән, дигән хәбәр ишетә. Шунда ук Казанга кызлар мәктәбе тотучы бай хатыны Фатыйха Аитовага үзен Бубига җибәрүен үтенеп хат яза. Ләкин: «Башта үзең килеп безнең мәктәптә укытып кара, аннан соң җибәрербез»,— дигән җавап ала. Юк, әнием моңа риза түгел, әгәр ул үзен белемле укытучы дип сизсә, Бубига барып уку турында хыялланмас та иде. Ниһаять, ул Казанга, абыйларына, укырга җибәрүләрен үтенеп, тәфсилле озын хат яза. Көннәрдән бер көнне Шакир абыйдан җавап килә. Анда ул дәү әнигә: «Без барыбер Чистайга кире кайтмабыз инде, өйне сат та Зәйтүнәне Бубига илтеп куй. Без үзебез дә укый алмадык, ичмаса Зәйтүнә белемле булсын»,— дип яза. Әниемнең абыйлары дәү әнигә фатир хакы түләү өчен ай саен акча җибәреп торырга булалар.

Дәү әни улларының сүзен тыңлый, өйне сата, әниемне үзе Бубига илтә китә.

«Бубига алданрак баруның сәбәбе, укулар башланганчы тиешенчә әзерләнеп, зуррак класска кереп булмасмы, дигән теләктән чыгып эшләнгән эш иде»,— дип яза әнием үзенең истәлегендә. Ул бу теләгенә ирешә дә. Укулар башланганчы бик нык әзерләнеп, сигез класслы мәктәпнең алтынчы классына имтихан тота. «Дәрес, мин төрекчә госманлыны бер дә белми идем,— дип яза әни,— хәлбуки, Бубида күп фәннәр шул телдә укыла».

Әниемнең тырышлыгы аркасында бу каршылык та чигенә. Ул төннәр буе йокламыйча дәрес әзерли. Аңа укуда укытучылар гына түгел, укучы кызлар да ярдәм итә. Алар хосусый фатирларда төркем-төркем булып яшиләр. Бергә дәрес әзерлиләр, уйныйлар, хәтта спектакль куялар. Көннәрдән бер көнне җиденче класс укучыларыннан берсе әнием турында мулла абыстайга: «Ул күп фәннән безнең җиденче класс кызларыннан да күбрәк белә»,— дип хәбәр сала. Мулла абыстай дигәне — безнеңчә мәктәп директоры. Ул әнине үз янына чакырта да: «Син безнең төп фәннәрне җиденче класс кызлары кадәр беләсең икән, шуңа күрә, сынап карау өчен, сине җиденче класска күчерәм»,— ди. Тагын болай ди: «Син бик тырыш күренәсең, җиденчедә укыганда сигезенчедә үтелә торган фәннәрнең дә кайберсе белән шөгыльләнерсең, шулай итеп, әгәр булдыра алсаң, җәйгә кадәр бәлки сигезенче классны да тәмамлап чыгарсың».

Әни истәлегендә: «Ураза керде,— дип яза,— мин сәхәргә хәтле дә, сәхәрдән соң да йокламыйм, укыйм да укыйм. Фатир хуҗасы Зәйнәп әбинең килене бар; шулар, мине кызганып, мунчада самавыр кайнатып, ризык калдырып, шунда бикләп куялар».

Шулай итеп, әнием, үзенең зирәклеге һәм тырышлыгы аркасында, өч еллык программаны бер кышта үзләштереп, шәһадәтнамә алуга ирешә, Чистайга кайтып китә.

Табигать язгы уяну шатлыгын кичергән апрель көннәрендә Казаннан «Тукай вафат» дигән дәһшәтле хәбәр килеп төшә. Әниемнең үзенә сүз бирик.

«1913 елның язында, Тукай үлгәнен ишеткәч, бик еладым, бик борчылдым. Әкрен генә йөткерә башладым, ябыктым. Әни мине, Гөлсем апага ияртеп, профессорга күрен дип, Казанга җибәрде. Фатих абый янына бардым. Әйе, иң элек, килгәч тә, зиратка чаптым. Тукайның кабере — кергәч тә капканың уң ягында. Зур гына бер калайга «Шагыйрь Габдулла Тукаев» дип язылган. Мин кабер янында коръән укып бик озак елап утырдым.

Врачка күрендем. Чистайга кайтып кәҗә сөте эчәргә кушты. Гөлсем апаны Сембергә озаткач, тагы Чистайга юл тоттым. Миңа бик күңелсез, бер нәрсәдән дә ямь таба алмыйм... Июльме, август башларымы — Габдрахман абый, безне алып китәргә дип, Петропавелдан кайтты. Шакир абый хәзер Троицкида, әйбәт кенә урнашкан. Габдрахман абый исә безне шунда алып китәргә тиеш. Без әни белән, Чистайны бөтенләйгә ташлап, пароходта Пермьгә, ә аннан инде Троицк ягына сәфәр чыктык. Бәдриҗиһан апа ике баласы белән елап безне озатып калды. Миңа аңардан аерылу бик, бик авыр. Без дус идек, бергә үстек. Мин яраткан апамны башка күрә алмадым. Җизни элек Тобольскида яшәде. Аннан алар, җизнинең аталары чакыргач, Каргалыга күчеп кайттылар. Апам анда балалар укытты.

Шулай алар егерме беренче ачлык дәһшәтләренә кадәр шунда торалар. Ачлык елны апам приют балалары белән Себергә киткән җиреннән, тиф чире йоктырып, Томскида үлеп кала. Шул ук елны холерадан Рабига апам да вафат була. Һәр апамның алтышар баласы ятим кала...»

## 14

Агриппина Евграфовна:

— Шушы көннәрдә сезне комиссия членнары чакырыр,— диде.

— Нигә?— дидем мин. Апа, ачылып, гадәтенчә матур итеп елмайды:

— Менә сезне күрү өчен, нindирәк кеше икән бу егет, игътибарга лаекмы, юкмы, шуны белү өчен,— диде. Мин, ни әйтергә дә белмичә, җилкәләремне җыерып кына уңайсызланып калдым. Шул дәрәҗәдә үк мөһим микәнни соң алар өчен минем тышкы кыяфәтем? Бу уемны сизенгәндәй, апа шәрехләргә ашыкты. «Алар андый вакытны документларда язылмаган кайбер мәгълүматлар белән дә кызыксыналар,— диде.— Сез моңа әзер булып торыгыз. Җавап биргәндә бик уйлап кына сөйләгез. Эмоциягә ирек бирмәгез. Аңладыгызмы?»

Апа тагын нурлы күзләрен җемелдәтеп миңа карап алды. Мин бүген дә буш кул белән урамга чыгып киттем.

Еш кына, үткән көннәрне искә алсам, шундый нәтиҗә ясыйм: Балалык чоры — җаныңны артык каты авырттыра торган сикәлтәләргә дучар ителмәсә генә — хәтердә якты, нурлы, рәхәт вакыт булып саклана икән. Ә минем өчен бу чор артык озак булмады. Ул миңа нәкъ унөч яшь тулганда тәгәлләнде. Моны, бәлки, тулырак итеп сөйләргә, йомгакны башыннан сүтәргә кирәктер.

Мин Кала ягындагы, татар совет мәктәбенең дүртенче классында укыйм. Безнең укытучыбыз Хәдичә апа — тупасрак киң битле, ләкин кешегә ягымлы хатын — миңа карата ифрат игътибарлы. Бәлки, минем әниемнең мәктәпкә еш килгәләве моңа сәбәптер. Ләкин, ни булса шул, класста уку миңа рәхәт. Бик алдынгылардан булмасам да, ярый-

сы гына барам. Мин үземне мәктәптә иркен тотам, минем яраткан укытучым бар, дусларым, иптәшләрем мине тиң күрә.

Мин бәләкәй чакта ук, әйткәнемчә, киногa хирыс булдым. Ул хирыслык үскәннән үсә барды. Дөрес, егерменче елларда экраннарда безнең совет фильмнары бик сирәк күрсәтелде. Кинотеатрларда күбрәк чит ил артистлары катнашындагы күп серияле фильмнар белән җенләнәбез. Комик артистларның кыланышын карап, эчләребез катканчы көләбез. Мин андый кызыклы фильмнарның берсен дә калдырмыйм. Чөнки аларны карау минем өчен үзе бер бәйрәм. Афишада шундый картина барганлыгын белсәм, ничек тә әнидән ун тиен ялынып алам.

Бу — егерменче елларның уртасы — шактый арзанчылык хөкем сөрә. Әтием мулла булырга, ныклы эш хакы бирсәгез генә риза, дип кергән. Аңа мәхәллә аена утыз сум түли. Мондый арзанчылыкта ул акчага шактый иркен яшәргә була. Әмма халык эшсезлектән интегә. Акчаның кадере бик югары. Әгәр кәсебең булмаса, аның бер тиенен дә таба алмыйсың. Акча табу өчен нинди генә юллар уйлап чыгармый кеше дигәнең. Бер ишесе — кешелек горурлыгын югалтканы — хәер эсти. Булдыра алганы урамнарда кәмит, фокус күрсәтеп, йә башка шаккатыргыч табышлы мәзәк ясап, тамашачының тиенен суырырга омтыла. Вак һөнәрчелек, иске-москы җыю, утын яру, вакытлы эш, көнлекчелек, тагын әллә ниләр белән шөгыльләнә. Караклык, кеше талау да аз түгел.

Хәтердә, бервакыт шәһәрдә Муллатай дигән кеше талаучы пәйда булды. Ул төнлә үзенең шул төп кәсебе белән шөгыльләнә, имеш. Муллатайның даны яңгыраган көннәрнең берсе иде. Без Фәез абыйларга кунакка барган җирдән озакка тоткарландык. Кайтыр ара алай ук ерак түгел. Чалт аяз салкын төн. Ләкин шул кышкы чиллә төнендә, Фәез абыйлардан чыгу белән, безгә бер кеше иярде. Аның өстендә кайры тун, тун өстеннән җилбәгәй җибәрелгән брезент яңгырлык. Аның аяк астындагы кар аерата шомлы шыгырдый. Ә барыннан да куркынычрагы — кешенең кулында җепкә бәйләнгән чукмар. Без бер-беребезгә сыенып атлыйбыз, ул арттан бер сүз дәшмәстән бара. Ниһаять, без бер чат араны хәвефсез уздык, икенче чат башында — безнең капка. Күрәм, әтием дә, әнием дә бик куркалар.

Аллага шөкер, менә безнең сары капка. Ул, гадәттәгечә, эчтән бастырык белән бикләнгән. Әти яңгыр торбасына таба ашыга. Өйдән чыгып капканы ачсыннар өчен, шуны кагарга кирәк. Әти гасабиланып калай торбаны дөбердәтә. Бәлки, әтием ул кадәр тетрәнмәс тә иде, теге чукмар өстерәгән абзый тукталып ук калды бит.

Капканы Суфия апа ачарга тиеш. Җитмәсә, анысы да кымшанмый. Күрәсең, йокысыннан айный алмый ятадыр. Ә теге кеше туктаган, ай яктысында ап-ачык күренә, кашларын җимереп, һаман безне күзәтә. Ниһаять, алгы бүлмәдә ут алынды, Суфия апа без кайтканны белде, чыгып, бастырыкны эшерде, без исә, кабаланып, ишегалдына уздык, котылдык. Кем белә, бәлки, бу котылу да түгелдер, бәлки, беркем безгә янамагандыр да. Ихтимал, теге чукмарлы кеше, мулланың котын алыйм әле, дип, юри ияргәндер.

Биредә вакыйгага Суфия апа исеме килеп керде. Аның турында сүз әйтми китү килешмәс. Суфия апа — әниемнең олы апасы Рабиганың уртанчы кызы. Ул миннән җиде-сигез яшькә олы. Аны егерме дүртенче елның җәендә әни Урсай авылыннан Троицкига, бездә торырга чакыртып алды. Ябык, чандыр гәүдәле, чәчләрен уртадан ачып тараган, чәч толымнарын иңбашына төшереп салган оялчан авыл кызының безгә килеп төшкәч, чәй эчкәндә аска гына карап: «Рәхмәт инде, җизни, мине үзегезгә алдырдың»,— дип әйткәне әле дә колакта.

Югарыда бер әйтелеп узылганча, Суфия апаның әнисе Рабига

ачлык елында холерадан вафат була. Мөгыйн җизни башка хатынга өйләнә. Нәкъ ачлык ел алдыннан Троицкидан әниләрен сагынып кайтып киткән Суфия апаның апасы Һаҗәр дә ачлыктан үлеп китә. Шулай итеп, алар алты баладан бары икесе генә торып калалар.

Суфия апа, безгә килеп төшкәч тә, гадәтенчә аскарак караган хәлдә, кулларын тез өстендә кушырып, үзләренең ачлык елында күргәннәрен сөйләде. Мин, аның сөйләгәннәренә таянып, Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» ендә ачлык ни дәрәҗәдә дөрес, реалистик планда язылганлыгын тоям. Троицкида да ачлык адәм балаларына күп газаплар китерде. Алабута икмәге ашатты, ачлыктан үлүчеләр дә булды, әмма ул Идел буендагы кебек дәһшәтле булмады.

Сүз Суфия апа турында бара бит. Безгә килеп төшү белән, әни аны татар мәктәбенә укырга бирде. Урсайда уку аңа бик чамалы тигән булса кирәк, ул үзеннән кечерәк балалар белән, хәтта миннән дә түбәнрәк сыйныфта укыды.

Троицкидагы базар мал-туар һәм ризык белән ташып торуына карамастан, эшсезлек аркасында, кул хезмәте белән яшәгән кешеләр өчен тормыш җиңелдән түгел иде. Мин аны шуннан да чамалыйм: нәкъ безнең каршыда гына иркен ишегалды түрендәге бер бәләкәй флигельдә ишле гаиләсе белән Дәүләтгәрәй абзыйлар яши. Аның кечкенә генә, һәрвакыт нидер эшләп торучы Мәймүнә атлы хатыны, биш баласы бар. Дәүләтгәрәй абзый үзе бик матур, мәһабәт ир. Озын буй, көрән сакал-мыек, ачык, ягымлы йөз. Аның берәр эштә даими эшләвен мин белмим. Ул гаиләсен көнлекчелек хезмәте белән туйдыра.

Без аның иң кечкенә улы, миңа яшьтәш Рәхимҗан белән дуслашып киттек. Мин еш кына аларда булам. Шунда Дәүләтгәрәй абзый үзенең бик озак еллар иза чиккән солдат хезмәте турында да сөйли. Әле дә аның кайбер сөйләгән нәрсәләре хәтердә.

— Элек безнең кебекләргә көн юк иде,— дип сөйли иде ул.— Байлар безне кешегә дә санамый иде. Син сәлам бирәсең, ә ул сиңа акаеп кына карый. Кызык итте бу переворот шуларны!

Әйткәнемчә, ул солдатта патшага хезмәт иткән. Патша армиясендә офицерларның татар солдатларына ничек начар, түбәнсетеп карауларын ул еш искә ала. Аның үзен дә һич юкка «татарская морда» дип яңаклый торган булганнар. «Мине,— ди Дәүләтгәрәй абзый,— бервакыт взводный, чиратсыз наряд биреп часка бастырды да, мылтык урынына бастырык күтәреп торырга мәҗбүр итте».

Дәүләтгәрәй абзый безгә дә кергәли, кирәгендә мал суюны башкара, кайбер башка эшләрдә дә булыша. Җәй көннәрендә алар бер елны Бабай тавы ягындагы җилем кайнату эшендә булдылар. Җәй буе шунда яшәделәр. Без исә шул якка сәйранга чыккан араларда аларның алачыгына сугылмый калмыйбыз. Мәймүнә апаның сыек кына итеп кайнаткан ирисен кабып чәй эчәбез, аларның салкынча куышында ял итәбез. Мин шул көннәрдән бирле бер хәлне күреп хәйран калам. Кеше ни кадәр ярлы булса, шул кадәр юмарт була икән. Гаҗәп бу!

Сәйранга чыгабыз дигәннән, вокзал артындагы урманчыкка чыккан чаклар да хәтергә килә. НЭП чорының азакларында Троицкиның бер иш хәллерәк кешеләре «Ярдәм» исемле авыл хуҗалыгы артеле оештырып маташты.

Шунда бардык бервакыт. Менә без җәйнең иң матур аяз көнендә әти, әни һәм мин, тагын миңа таныш булмаган әллә кемнәр белән аланда, чирәмгә палас җәеп, аякларны сузып, табын тирәсендә утырабыз. Безнең янга олы гына гәүдәле, табак битле, сакал-мыексыз, ләкин минем күзлектән шактый олы яшьтәге бер абзый килә. Табын тирәсендә утыручылар аны аерата бер хөрмәт белән каршы алдылар.

Зурлар аны табын уртасына чакырдылар, хәл-әхвәл сораштылар, бераздан гармунда уйнап, җырлап күрсәтүен үтенә башладылар. Бу

кеше атаклы җырчы Мирфәйзә булып чыкты. Заманында аңардан Тукай да көлеп язган.

Мин Мирфәйзә атлы җырчының Троицкида яшәгәнлеген ишеткән идем инде. Ләкин аның ничек җырлавын белми идем. Күзләремне шарландырып, колакларымны торгызып, бу мәшһүр кешегә текәлдем. Мирфәйзә кулына кечкенә генә кыңгыраулы гармунын ала һәм уйнап җырлый башлый. Мин аптырап калам. Әлбәттә, аның матур тавыш белән җырлавына түгел, ә шундый олы бәдәнле үгездәй таза агайның хатын-кызларныкы кебек чәрелдек тавыш чыгаруына гаҗәпләнәм. Менә ни өчен «Мирфәйзә» дигәннәр икән аңа!

Шул ук «Ярдәм» ширкәтендә шәһәрнең абруйлы кешеләреннән Габдрахман ага Әхмәрев тә әгъза булып тора иде. Габдрахман ага ияк очында гына калдырылган матур түгәрәк сакаллы, кыска мыеклы, озынча ак йөзле, башына үзбәк түбәтәе кигән ифрат ягымлы кеше булып истә калган. Ул революциягә кадәр безнең шәһәрдә кызлар мәктәбе ачкан, җәмәгать эшләренә дә бик актив катнашкан, милләтне күтәрүдә зур тырышлык күрсәтеп йөргән зыялыларның берсе.

Габдрахман абзыйларның бала-чагалары бик ишле иде. Ләкин минем белән аерата дуслашып киткәне бу балалардан иң кечесе — Үзбәк булды. Мин, билгеле, Үзбәкнең кече абыйсы Чыңгызны да бик яхшы беләм, аның рәссамлыкка укып йөргән чакларын да хәтерлим. Чыңгыз чит шәһәрдә укыды, ул мине каникул вакытларында үзенең осталыгы белән шаклар катыра иде. Ябык кына, кызлар кебек нәфис, чибәр Чыңгыз беркайчан да үзенең рәсем блокнотын кулыннан төшерми. Урамдамы, ишегалдындамы — үзенә сәер тоелган берәр нәрсә күрсә, ул хәзер шуны ясап куя. Һәм ясаган сурәтләре искитмәле матур була.

Үзбәк минем яшьтәш. Ифрат хискә бирелүчән һәм шул ук вакытта дуамал, усал. Тойгыларына хуҗа була алмаган минутларында теләсә нинди ахмаклыклар ясап ташларга сәләтле, хәтта зәһәр рәхимсезлекләргә дә бара торган малай. Хәтердә калган: бервакыт ул, минем чехоткадан үләсем килә, дип, сарайдагы ларлар өстенә кунган тузаннарны ялап йөрде. Ә берчак, сарай түбәсе астына оялаган күгәрчен балаларының башын өзеп, кемгәдер булган ачуын басты. Хәтеремдә: бервакыт без, дөнья белән танышып йөри торгач, фатирыбыз чарлагына эләктек. Минем бәхетсезлеккә каршы, андагы тузан арасыннан бер туп снаряды табылды. Үзбәк шул снаряд өчен мине аз җәберләмәде. Мин инде ул вакытларда үземә булган кырын карашны, мәхдүм буларак, тоя идем. Үзбәк дус исә, шуңа кинаяләп: «Ул снарядны совет властена каршы көрәшү өчен сез юри саклаган, моны тиешле урынга хәбәр итми булмас»,— дип, мине куркыта башлады.

Ә инде Чыңгыз турында мин тагын шуларны әйтергә тиеш. Ул үзенең эзлеклелеге һәм көчле таланты аркасында соңыннан рәссам булып дан казанды. Үзбәкстанда үз мәктәбен тудырган күренекле рәссам буларак, СССР дәүләт премиясе лауреаты дәрәҗәсен алды. Аның Ташкент опера театрын бизәгән паннолары әле дә тамашачыларны сокландыра. Чыңгыз үз халкын, татар халкын да онытмый. Ул, Казандагы опера һәм балет театрының фойе залларындагы диварларны гүзәл сыннар белән бизәп, үз туган туфрагының күркәмлеген арттырды.

Балалык чорына әйләнеп кайтыйк. Мин дә инде ул вакыт тузга язмаган, фантазия җимеше булган пьесалар яза идем. Яза идем һәм без аны уйный идек. Кем белә, иҗат эшемнең башы итеп, бәлки, шуны санарга кирәктер.

Әдәбият, бигрәк тә Тукай һәм Бабич белән мин күптән мавыга идем инде.

Әниемнең чиксез мәхәббәте аркасында булса кирәк, Тукай минем

күңелемә бик яшьли кереп сеңде. Соңрак Шәехзадә Бабич та минем сөйгән шагыйрьләремнең берсенә әйләнде. Үсә төшкәч, Гаяз Исхакыйны, Галимҗан Ибраһимовны бик яратып укый башладым.

Көннәрдән бер көнне, беренче баскыч мәктәпне тәмамлап, бишенче сыйныфка күчтем. Бу мәктәптә бишенче класс булмау аркасындадырмы, әллә башка сәбәпләр беләнме — мине бишенче класска элек бабамның Рәсүлия мәдрәсәсе булган, хәзер татар совет мәктәбе урнашкан җидееллыкка бирделәр.

## 15

Менә мин хәзер шул татар мәктәбенең бишенче классында укыйм. Көз үтеп, кышкы салкыннар да башланды. Мәктәпкә без, Кала якта яшәүче балалар, бергәләшеп йөрибез. Елга бозы аша Амур ягының чүплегенә чыгабыз, аннан кыеклап мәктәпкә таба юл тотабыз. Минем өстә сары кайры тун, башта колакчынлы бүрек, аякта киез итек. Шулай да Увелька буенча искән ачы җил куенга керә, бит очларын, иякне өшетә. Аркада киндер букча; букча эчендә китап-дәфтәр, кечкенә шешәгә салынган сөт, ике телем икмәк. Мин шулай укырга йөрим.

Әйтергә кирәк, бик дәртләнеп йөрим. Чөнки, яңа мәктәпкә күчү белән, мин укуда бик шәп алдыра башладым. Укытучыларым мине башка укучыларга үрнәк итеп куялар. Миндә моңарчы һич күренмәгән ораторлык куәсе ачылып китте. Хәтеремдә, хәтта бервакыт әти-әниләр җыелышында миңа доклад сөйләргә куштылар һәм мин бу эшне, әйтүләренә караганда, шактый шома башкарганмын.

Мин — активист. Стена газеталары чыгаруда булсын, бәйрәм көннәренә лозунглар язуда булсын — мин беренче. Драмтүгәрәктә катнашам. Мин шагыйрь дә әле җитмәсә, бер шигырь язып, стена газетасында бастырдым. Кыскасы, бик дәртләнеп, укуның тәмен, ләззәтен табып яшим.

Әтием үз вазифаларын җиренә җиткереп башкара. Мәхәллә картларын мәчеттә намаз укыта, вәгазь сөйли, хөтбә укый. Өйдә, яшеренеп кенә, мич каршында тәмәке тарта. Ләкин ул, мәхәллә халкына никадәр ярарга тырышмасын, бер иш кеше аны барыбер өнәми. Кемнәрнеңдер аны «коммунист мулла, урыс мулла» дип сүккәннәре безгә дә ишетелгәләп тора.

Аның совет укытучылары белән аралашуын яратмыйлар, вәгазь-хөтбәләрен китапка карап сөйлисе урында үзе язган кәгазьгә карап сөйләвен дә өнәмиләр. Күрәсең, аның тәмәке тартуы да халыкка сизелә. Ничек сизелмәсен, тәмәкене тартканга кадәр кибеттән алырга кирәк бит әле. Кайчагында кибеткә әти мине дә җибәрә. Мин аңа «Пушка» папиросы алып кайтам, үземә уңайсыз, әтием өчен дә уңайсызланам, кибетченең миңа хәйләкәр көлемсерәп каравы, кемгә бу, дип соравы ошамый.

Көннәрдән бер көнне без үз өебезгә, Амур якка күчендек. Моның сәбәбен анык кына әйтә алмыйм. Бәлки, хуҗа без түләгән акчага гына риза булмагандыр, бәлки инде әтигә муллалыкның хәтәр бер эш булуын, озак гомерле булмаячагын аңлатканнардыр, бәлки, үз өебез була торып, фатирда яшәүнең мәгънәсезлеген тойганнардыр, белмим. Хәзер мәктәп миңа бөтенләй якынайды, монда яңа дус-иш тә табылды.

Менә язга да килеп җиттек. Карлар эреп, үрдән — вокзал ягыннан — гөрләвекләр ага башлаган көннәрдә бездә зур яңалык булды. Кайчандыр казах бае Вәли хаҗи миңа колагын тешләтеп бүләк иткән атны безгә китереп тапшырдылар. Йөнтәс, кыргый туры тайчык хәзер бөтенләй үсеп беткән, ябага йонын койган, шомарып-тазарып

киткән, кыска гына муенлы бер айгыр кисәгенә әйләнгән. Ләкин ул һаман кыргый, йөгәннең ни икәнен әле яңа гына аңлаган хайван.

Әти ат белән булаша башлады. Арба, чана сатып алды, сбруй җүнәтте. Инде карт әти өй салдырганда ук хәстәрен күреп эшләткән менә дигән такта сайгаклы аранда бу кыргый казах атына җылы урын да табылды.

Ат — аранда. Ул әле бер тапкыр да тәртә арасына кермәгән. Аны күрше-күлән егетләре башта камытка, ыңгырчакка ияләштерделәр. Аннан тәртә арасына керттеләр. Айгыр дулый, тыпырчына, тибешә, тешләрен ыржайтып, үзен ирексезләүчеләргә үрелә. Инде бер дә булмаса, арткы аякларына баса. Ләкин шулай да аны кешеләр җиңде, ат буйсынырга мәҗбүр булды. Бераздан ул атланып йөрүгә дә, тәртә арасына кереп җигелүгә дә күнегә башлады. Инде гөрләвекләр тоташ ага башлап, урамнарны тубыктан быкырдык пычрак баскач, рәхимсез агайлар минем туры айгырымны җиргә егып печтеләр. Мескен айгыр, гомерендә бер генә тапкыр булса да нәсел калдыру куанычыннан авыз итмәгән хәлдә, үзенең ирлеген югалтты. Ул суырылып, ябыгып калды, тәмам йончыды, юашланды. Миңа, аның өстенә менеп, урамнар буенча чабарга куштылар. Чапканда да әле мин пычраграк урамнардан барырга тиеш: чөнки, яра тизрәк төзәлсен өчен, пычракның ярага эләгүе бик мөһим, имеш.

Өске урам буйлап атны камчылый-камчылый чабам; янәсе, мин аңа яхшылык эшлим. Мескен ат тәмам алҗып, артык атларлыгы калмагач, туктап калды. Ул бөтен гәүдәсе белән сулый, тилмереп, миңа таба башын суза. Мин, аттан төшеп, аны тезгененнән тоткан килеш кенә алып кайтам.

Берәр атнадан соң ат бөтенләй рәтләнде. Ул инде миңа ияләшеп килә. Мин аның астын тазартам, печән салам, солы бирәм. Инешкә алып төшеп су эчерәм.

Бер көнне без әти белән, ат җигеп, Кала якка чыгып кердек. Арба безнең тимер хутлы, бик җиңел, әмма әрҗәсез, шуңа күрә, аның өстенә көрпә салынса да, утырып баруы шактый җайсыз. Алай да мин горур, чөнки дилбегә минем кулда, бик әтәчләнеп, кирәккә дә кирәкмәскә дә кычкырып атны кызулатам. Әти мине тыеп бара, сабыр, сабыр, улым, ди.

Бераздан соң, мәктәптән бушаган чакларда, әтине Кала якка мәчеткә дә озатып куя башладым. Базарга да әти белән атта чыгабыз. Минем хәзер эш худта, минем атым бар!

Без шулай яшибез, ә укулар бара. Мин әле һаман алдынгы укучылардан саналам. Ләкин мин «тәти шәкерт» түгел, мин башкалардан бер дә ким шайтан чапмыйм, башкалардан ким котырмыйм.

Ләкин минем, шулай әйтергә яраса, мәдәни шөгыльләрем дә житәрлек. Пьесалар язам. Берсеннән-берсе маҗараларга баерак пьесалар. Безнең ишегалды түрендә ябык лапас. Ул ике катлы. Без шуның өске катында сәхнә сыман калку сәке ясадык. Хәзер инде иптәшләр белән спектакльләр куябыз. Күрше-күлән балалары бездә. Нинди генә хикмәтле нәрсәләр күрми алар безнең уенда!

Нәкъ шул чорда кызларга да күз төшерә башладым, ахры. Хәер, моны мәхәббәт дип атап була микән әле? Бу — булачак мәхәббәт кичерешләренең яралгысыдыр, мөгаен. Безнең класста Хәдичә атлы бик җыйнак бер кыз укый. Ул ап-ак йөзле, коңгырт күзле, шактый чибәр, пөхтә киенә. Өстендә көрән күлмәк, кара алъяпкыч, ә аякларында уенчыктай матур күн итекләр. Хәдичәнең күпермә чәче дулкынланып тора. Бер күзе чак кына сизелерлек кылый, ләкин бу кимчелеге аның йөзен бозмый; хәтта, мин әйтер идем, аңа ниндидер шук кыяфәт, серлелек төсмерен бирә кебек.

Шул Хәдичә үзе беренче булып миңа игътибар итте. Ул тәнәфес вакытларында, һич ихтыяҗы булмаса да, минем белән сүз башлый,

миңа карап елмая, кулларымнан тотып, уенга өстери. Хәтта бер көнне, мин мәктәпкә килгәч, әнием белән коридорда сөйләшеп торганда үзе әрсезләнеп безнең белән сүзгә тыгылды. Алай гына да түгел әле, ул әни алдында ук, сиздермәстән, минем аяк очына басып алды. Бу әлбәттә, аның миңа булган игътибар билгесе иде. Бурлаттай кызардым, әни тәгаен сизде инде бу эшне, дип уйладым. Күңелемдә моңарчы һич булмаган яңа, сәер, татлы һәм газаплы тойгылар уянды. Еш кына, онытылып, аның турында уйлана торган булып киттем.

Яңа тойгылар, яңа шөгыльләр белән узган көннәрнең берсендә аяз күгемә яшен ташы атылды. Бу яңакка чалтырату белән бер булды. Минем яшь, әле чыныкмаган зәгыйфь күңелемә бу хәл бик каты рухи җәрәхәт ясап китте. Бу хәл мине укуда, гомумән, бөтен тормышымда таудан түбәнгә атып бәрү кебегрәк бер нәрсә булды. Билгеле, бүгенге күзлектән караганда, аек акыл белән бүгенге бизмәннәргә салып үлчәсәң, әллә ни булмады да кебек. Ләкин ул чакны мин бу кимсетелүне ифрат авыр кичердем.

Вакыйга безнең мәктәпкә яңа укытучы килүеннән башланды. Ул кеше әле яңа гына Казаннан кайтып төшкән, гимназистлар формасы кигән яшь егет иде. Исеме Зәйни. Зәйни абый Казанда укып яткан җиреннән авырып киткән һәм үзенең туган шәһәренә — Троицкига кайтырга мәҗбүр булган. Ул зифа буйлы, бетчәлерәк йөзле, яшь булуына карамастан, гадәттән тыш җитди бер кеше иде.

Гаҗәп хәл, Зәйни абый беренче тапкыр дәрескә керүе белән үк мине кан дошманы урынына күреп яратмый башлады. Һәр дәресендә минем мулла малае булуымны, гәзитчәрәк әйтсәк, ассызыклап атап, миңа карата нинди генә булса да берәр кимсетү сүзе кулланмый калмый иде.

Моңарчы укытучыларның үзен иркәләвенә, алдынгы укучы буларак үрнәк итеп куюларына күнеккән малайга бу хәл шул дәрәҗәдә тетрәткеч тоелды ки, мин Зәйни абыйның сүзеннән генә түгел, гүя карашыннан ук котым алынып бөтенләй коелып төшә торган булдым. Мин аның дәресләрен әзерли алмый башладым, чөнки ни генә кылсам да, миңа начар билге куячак. Ә ул исә, нәкъ шуны сизенгәндәй, беренче булып мине аякка бастыра, мин тәмам югалып, җир тишекләренә кереп китәргә әзер бер халәттә, ык-мык итеп калтыранып торам. Ул минем ни өчен аның фәнен тырышып укымавымны сыйнфый көрәш күзлегеннән аңлата.

Бераздан канатларым сынып-сыгылып төште, күңелдә дәрт-омтылыш дигән нәрсә бетте.

Бу вакыйгаларга бик күп еллар узды инде. Ләкин минем күз алдымда Зәйни абыйның бетчәле бите, миңа ачы нәфрәт белән текәлгән күзләре әле дә җанлана. Ул хәзер инде күптән гүр иясе. Озак еллар Троицк шәһәрендә укыткан, әйбәт педагог буларак абруй казанган, орденнар алган.

Мин аның яшьлек чорында Казаннан ни дәрәҗәдә сыйнфый көрәш пафосы белән сугарылып кайтуын, һәрбер күренешкә сыйнфый күзлектән карарга кирәк дигән кагыйдәне ничек ялгыш аңлавын бүген төшенәм. Юк, мин аны гаепләмим. Ул үз дәверенең бер җимеше булган. Бу яшь кешене әлеге чирне йоктырып кайтуының сәер ягы тагын шунда: ул үз вакытында Троицкиның иң алдынгы, кешелекле укытучыларыннан берсе булган Лотфулла мөгаллим улы иде.

Бәхеткә каршы, дип әйтим инде, миңа Зәйни абыйның дәресләрен икенче уку елында тыңларга туры килмәде. Җәй узып көз кергәч, мине алтынчы класска кертмәделәр. Сайлау хокукыннан мәхрүм кеше баласы буларак, минем мәктәптән сөрелүемне игълан иттеләр.

*Ахыры киләсе санда*

# Рөстәм Мингалим

## Үзгәреш

*Абау, матур зәңгәр чәчәк —*
*сөрми калган җирләрдә...*

(Халык җырыннан)

Үзгәреш, дип аны мин дә
кычкыра алыр идем.
Шатланып та канатланып,
и, оран салыр идем.
Күңел курка кычкырырга,
хәтерли үткәннәрне...
Шау-гөр килеп, куллар чабып,
үзгәреш көткәннәрне.
Килде дә ул үзгәрешләр
йөреп үтте лә инде.

Безнең юллар, мәйданнарны
сөреп үтте лә инде.
Акылларны сөреп үтте,
екты милли капканы.
Каберләрне, мәчетләрне
буразналар каплады...
Сөрде телне, сөрде илне,
хәзер безнең көйләр дә —
зәңгәр чәчәк кебек кенә
сөрми калган җирләрдә.

## Ул чор безне ничек каршылар

*Сугыш фаҗигаләре,*
*шәхес культы корбаннары аша*
*узган гомерләрне уйлап*
*әйтелгән шигырь.*

Без кечкәндә тормыш диңгезен,
су түгел шул анда, кан иде.
Кан исенә дөнья исерде,
чигәләрдә пуля биеде,
гали затлар ауды чүплеккә,
телдән, аңнан язып адаштык.
Йә милләтне милләт дөмбәсләп,
аңга китерергә маташты...

Без кечкәндә тормыш диңгезен,
ямьсезләнеп беттек имгәнеп.

Гарип уйлар-сүзләр кычкырдык,
озак шулай аңга килмәдек...

...Тормыш диңгезендә әйләнмә,
хәлебезне шунда шәйләдек:
кан өстендә тордык әйләнеп,
ярый әле шуны шәйләдек...

Инде, бәлки, аңга килербез,
бәлки алгы ярга җитәрбез...
Ул чор безне ничек каршылар,
Һәм кан исе бездән бетәрме?

---

Ростәм МИНГАЛИМ *(1937) — шагыйрь, драматург. Татар һәм рус телләрендә дөнья күргән унбишләп китап авторы. Казанда яши.*

## Сыгылып төшкән алмалык

Сиңа гына дигән сүзләр иде,
һаман шуны сөйләп булмады.
Узды вакыт сызып гомерләрне,
без сөйләшер сәгать тулмады.

Бар иде лә икәү сөйләшәсе,
син үзең дә моны аңладың.
Мәңгелеккә охшаш бу вакытка
һаман бергә сыя алмадык...

Сөйләшмичә калган
безнең сүзләр —
сыгылыплар төшкән алмалык.
Мең аңлашыр идек, бер сөйләшеп,
Тик... Сөйләшер вакыт калмады.

## Менә шулай, дускай...

(БЕР СӨЙЛӘШҮДӘН ӨЗЕК)

Ул рус көен уйнап тора иде,
моң дәрьясы иде — дүрт ягы.
Нинди уйлар килмәс кыз балага!?
...Скрипка елап туктады.
Күз тимәсен, кызым, кулларыңа,
яман күзләр булу хак, дидем.
Инде уйна берне үзебезчә,
бик тыңлыйсым килгән чак, дидем.
«Былбылым»ны уйна?
...Уйнамады...
Менә шулай, дускай!? Ни дисең?
— Ни дим? — диде дусым,—
димәк, шулай,
әнә минем хәлне кара син.
Сагынасы булган бу Казанны
һәм авылда яшәп каласы.
Әнкәй мәрхүм сүзе хак иде шул,
мине җиңде хатын киңәше...
Урамчарак әйтсәк, зверь инде,
элегрәк... Хәзер шәп яшим...
Өч малаем бар дип йөргән идем,
булмадылар миңа берсе дә.
Минем хисабыма үстеләр дә
өчесе дә күчте күршегә...
Хет берсе дә минем телне белми,
җанны шулар ничек белсеннәр?
Инде киләчәктә берсен-берсе
танысалар ярый, мескеннәр.
Югалттылар менә этиләрен,
әбиләрен... Бабаларын да...
Әллә югалтырга күнеккәннәр
югалтырлар микән барын да?

Аналарын гына сатыйм, дисәм,
ул карчыкны хәзер кем алсын!?
Үзем, әйтик, яшьне табармын да,
баласы да булыр, аннан соң?
Без дәвамсыз буын ахры, яшьти,
хет утырып ела, хет ятып:
баласызлар ялгыз — баласызга,
балалылар ялгыз — югалтып...

Синең кызны була кичереп тә,
кыз барыбер инде — ир ягы.
Ә малайлар?!

— Әй, малайлар булып
карадык ла килеп дөньяга.
Моң-зарларны
монда калдырыйк та
китик әле, дускай, икәү без.
...Кая барасыз дип сорасалар,
белмибез дик, ә бит беләбез.

## Соңгы мәсьәлә

Мәсьәләне бер-бер артлы
каршыма тезде тормыш.
Шуны чиш тә яшәрсең, ди,
чишәсең, ди, йә, тырыш.
Теш белән дә, баш белән дә
җитәрлек чиштем лә мин.
Уйлар йөртеп, иң сыгылып,
иллегә төштем лә мин.
Шунда да яңа мәсьәлә —
хет сөен, хет аптыра!
Учымда тотам кызымны,
никтер ул елап тора.
Бу елак кеше булганчы,
мин туфрак буласы бар.
Ләкин мин туфрак булганчы,
ул кеше буласы бар,—
Алынмам моны чишәргә,
куркыта нәрсәгәдер.
Син, тормыш, үзең чиш инде,
Бу соңгы мәсьәләдер.

*1988—1989 еллар.*

# Газиз Кашапов

## Кайгы

*Было горе, будет горе,*
*Горю нет конца.*

Анна Ахматова.

Бу язның аяз кичендә
Күзәтеп йөрим Айны.
Ә Җирнең тарафларында
И кайгы, кайгы, кайгы...

Фәләстыйннар ут эчендә
Илле ел иза чигә.
Ливанда суеш, кан коеш,
Бу низаг, низаг нигә?

Әфганның таулары биек,
Бөркетләр оя кора.
Бүлгәләш, Талаш, Үтереш
Туктаусыз чыгып тора.

Әрмәндә Җирнең күкрәге
Янар тау кебек ярсый.
Шәһәрләр булган урынга
Зыярәт кылып бар син...

Грузиннар иле аһ ора,
Тончыга газдан халык.
Кайгыны санап чыкканчы
Бетәрсең арып-талып.

Бу язның аяз кичендә
Күзәтеп йөрим айны.
Ә Җирнең тарафларында
И кайгы, кайгы, кайгы...

## Исеңдәме?..

Исеңдәме?
Озатып калдың мине,
Алтын кебек чакта көзге урман.
Шул чакларны эзләп йөрим хәзер,
Урман эче күз ачкысыз буран.

Исеңдәме?
«Сөям, — дидем, — сине»,
Баш очында сары яфрак иде.
Шул сарылар сукты микән әллә,
Тойгыларым кайнар уттан көйде.

---

*Газиз КАШАПОВ (1942) — прозаик. «Сәмум җиле», «Убыруг» һ. б. повестьлар, роман авторы. Чаллыда яши.*

Исендәме?
«Мин — синеке», — диден,
Өскә яуды яңгыр тамчылары.
Шул тамчылар юды микән әллә,
Бакча тулы гөлнең барчаларын.

Исендәме?
«Көт — көтәрмен», — дидек,
Озын юллар булды урау-урау.
Шул юлларны эзләп йөрим хәзер,
Урман эче күз ачкысыз буран.

## Икәү

Хыялларның ниндиләрен генә
Юрамадык, иркәм?
Без кич саен йолдызларга мендек
Синең белән икәү.

Сагышларның ниндиләрен генә
Татымадык икән?
Без назлардан һич тә туялмадык
Синең белән икәү.

Шатлыкларның ниндиләрен генә
Кичермәдек, иркәм?
Без җир шарын коча белә идек
Синең белән икәү.

Бүген синнән аерылып гүя,
Мәңгелеккә китәм...
Без анда да очрашырбыз, ахры,
Синең белән икәү.



## Дамир Гыйсметдинов

# ТАМГАЛЫ БҮРӘНӘ

хикәя



Сишәмбе көн иртән, «Җомга» көен эчтән генә сузып, экономист Хәлим ашыкмый гына кәнсәләргә таба атлады. Көн кояшлы, матур, Хәлимнең дә күңеле тыныч сыман иде. Сәкинәсе иртән кыстый-кыстый ашаткан кабартмаларны искә төшергән бу мизгелдә ул үзенең соң булса да уңышлы өйләнүенә янә бер кат сөенеп куйды.

Менә дигән таң йолдызын кулга төшерде шул Хәлим!

Әлбәттә, аның йолдызына үрелеп караучылар аз булмады. Хәлимгә җиңелдән бирелмәде бу бәхет. Кадалып китсеннәр, аларны бүген искә төшереп, шундый күркәм иртәнең тәмен югалтырга ярыймы соң?!

Әнә яңа клуб салалар. Өч ел да узмады, нигезен коеп чыкты колхозның уңган төзүчеләре. Ә бүрәнәләре... Шәп! Кайдан тарттырдылар икән мондый төп-төз шәмнәрне? Хәлим түзмәде, шыңгырдап торган бүрәнәләргә типкәләп карады. Бу шигъри минутларда ул шаулап утырган нарат урманын күз алдына китерде... Җиләс урман, кошлар чут-чут сайрый. Яшь наратлар арасында алар Сәкинә белән икесе...

Чү! Бу нәрсә? Әйтерсең лә, Хәлимнең башына имән күсәге белән тондырдылар. Озын гына бүрәнәнең урта бер җиренә нindидер юньсезе, пәке белән уеп, «СӘКИНӘ + СӘЛИМ» дип язып куйган! Хәлим аптырап җиргә чүгәләде, калтыранган куллары белән шул ике сүзне капшады. «Нишләп соң әле «Сәлим»?!— дип сыкранды ул. «Хәлим» булырга тиеш бит, «Хәлим»!

Әгәр дә төзелеш авыл советы һәм колхоз идарәсе расалаган график буенча барса, бирелә инде күптән ташчылар, балта осталары булып, Хәлимнең җан өзгеч тавышын ишетеп, һичшиксез, врач чакырырга йөгерерләр иде. Бәлкем бу очракта безнең хикәя дә башкачарак борылып, Хәлимне борчыган табышмак тизрәк чишелгән булыр иде. Кем белә?... Уй-фикерләре тәмам чуалган экономист тамгалы бүрәнәгә ачу белән тагын бер типте дә юлын дәвам итте.

...Әйтергә кирәк, төрле төбәкләрдә төрле исемнәр очрый, әмма кайбер авылларда яңа туган бәбиләр бер-берсенә имезлек суырулары белән генә түгел, исемнәре белән дә охшаш. Күрәсең, һәр чорның, һәр авылның үзенә хас бер гадәте буладыр инде. Әле кайчандыр рәттән Котбетдиннәр, Шәрифҗаннар, Гөлҗамаллар, Сәлимҗаннар иде, ә бүген шул ук урамнарда өчәр-дүртәр Марсельләр, Айдарлар, Тимурлар,

Альбертлар, Алсулар, Әлбинәләр яши. Шуңадыр, мөгаен, авыл халкы аларга тизрәк кушамат тагып, үзенчә аралашу җаен гадиләштереп җибәрә. Төрле буыннарны, әлбәттә, исем генә түгел, башка нәрсәләр дә аерып тора. Әйтик, Котбетдиннәр көрәк белән тир түгеп казыган нигезләрне, коеларны, балта белән төзегән агач йортларны бүгенге Марсельләр ансат кына бульдозер белән ишеп-күмеп, таш йортлар, колонкалар төзеп чыга. Гөлҗамаллар кул арбасы янсә атка төяп ташыган утын-печәннәрне бүгенге Әлбинәләр трактор-машина белән генә кайтарта...

Исем мәсьәләсенә килгәндә, Хәлим туган елларда алар авылында, күрәсең, Сәлимнәр модада булган. Ике урамлы авылда — дүрт Сәлим. Шул вакытта Хәлимнең дә, Сәкинәнең дә әти-әнисе, туфраклары җиңел булсын, мода артыннан кумаганнар икән. Бөтен авылга бер Хәлим дә бер Сәкинә. Шуңа күрә дә, бүрәнәгә уйган сүзләр Хәлимнең йөрәгенә хәнҗәр кадагандай тәэсир итте. Кайсы Сәлим аның фәрештәсенә ашерен гыйшык тотып йөри? Чү, бар иде бит авылда шундый берәү! Гармунчы, тел бистәсе, «Ыспай Сәлим» дип йөртәләр иде үзен. Сәкинә кебек сылу чәчәккә күз атып кына калмады, Хәлимнең бәхетенә аяк чалып, нервысында озак уйнады. Аллага шөкер, холкы йомшак булса да, бу очракта Хәлим каты торды. Бәлкем шуңадыр, Ыспай Сәлим Төньякка бәхет эзләргә чыгып китте. Инде биш еллаптыр, кайтып күренгәне дә юк, хәбәре дә ишетелми. Димәк, сүз башка Сәлим турында бара...

Шушы авыр уйлары белән Хәлим, ниһаять, эш кабинеты бусагасын узып, өстәл артына кереп утырды. Исәп-хисап машиналарын кабызып җибәрде, әмма эш бармады. Саннар сикерешә, күздән югалып интектерде. Үзенең ярдәмчесен шундый мөшкел хәлдә күреп, баш экономист аңа җайлап кына эндәште:

— Хәлим тугankай, чирлисең мәллә?

— Нәрсәдер бар кебек шул, Сәлим Сабитович...

Шушы исемне кабатлауга, Хәлимнең күз алдына бүрәнәдә пәке тотып утырган Сәлим Сабитович килеп басты.

— ...Матур, яшь хатыннар сырхау ирләрне яратмыйлар, туганкай, тешеңне кысып булса да түз, сер бирмә. Ә бүгенгә кайтып дәвалан...

Хәлим, тышаулаган ат сыман, аякларын көч-хәл белән сөйрәп, урамга чыкты. Тә-әк. Сәлим Сабитович... Авылда баш экономистны хатын-кызларга битараф түгел дип сөйлиләр иде.

Чынлап та, Сәлим Сабитович бу мәсьәләдә махы бирә торган ирегетләрдән түгел. Әле хәзер дә, санаторийлардан кайтып, атна-ун көн узмас борын, аның исеменә кәнсәләргә «Җаныем» дигән открыткалар килеп кенә тора. Хатыны Сабира апа көнләшүдән гарык булып, иренең мондый шаяруларына күптән кул селтәгәнгә күрә генә, Сәлим Сабитович гаиләсендә савыт-саба шылтырамый, аның абруена тап төшми иде. Тик, Хәлимнең фикер йөртүенчә, баш экономист үз хисләрен пәке белән бүрәнәгә уеп йөрмәс. Андый кеше түгел ул! Тәҗрибәле буларак, ул андый эшләрне астыртын гына, әз-мазар калдырмыйча гына башкарыр иде...

«Инде өченчесенә килик»,— дип, Хәлим үзенең якын дусты, бергә уйнап үскән, бергә укыган, бергә армиядә хезмәт итеп кайткан күзлекле Сәлимне исенә төшерүгә, ничектер уңайсызланып куйды. Гомере буе хатыны колы булып, телевизор белән гәзиттән гайре берни белән дә кызыксынмаган дусты аңарда бернинди шик уятмады.

Аскы очта тагын бер көндәш — студент Сәлим бар иде. Әле бөтенләй борын асты кипмәгән малай. Унны бетереп, Чабаксарда институтта укып йөри. Авылда инде ярты еллап күренгәне юк. Әнисе Хәдичә түти әле кичә генә борчылып сөйләп торды: «Улым бик авыр игызам бирә, ысатамат, ди... Шуны бирсәм өйләнәм, әни!— ди...»

Әлбәттә, Хәлим бүрәнәдәге язуны үз бакчасына ыргытылган таш итеп кенә кабул итмәде. Бу фани дөньяда Сәкинә белән Сәлим исемле гашыйклар, әлбәттә, тагын да бардыр. Әйтик, чыкканнар ди шулар җәйге урманга, аңлашканнар, ди. Ниндидер Сәлим, изге тойгысын мәңгеләштерү йөзеннән, токкан да уйган агачка ике сүз... Әйе, шулай диик. Беркатлылык бу! Тузга язмаган фикер. Бүрәнәләр анда күптән ята, ә теге шомлы язу әле яңа гына уелган. Димәк, авылда кемдер минем хәләл җефетемә күптән түгел генә гыйшык тотып, янып йөри башлаган!

Мәсьәләне шулай тирәнтен уйлый торгач, кәефе кырылган ир, үзе дә сизмәстән, янә теге төзелешкә килеп төртелде. Кеше-фәлән юк. Инде өч ел буена нигезеннән артык күтәрелә алмаган төзелештә колхоз җитәкчеләре каравылчы тотуны артык чыгым дип исәплиләр иде. Хәлим бүрәнә янына килеп чүгәләде. Бу юлы ул аны җентекләп тикшереп чыкты. Эзләнә торгач, бүрәнәнең урта бер җирендәге ботак тишегеннән тәмәке төпчеге килеп чыкты. «Әһә, Казан тәмәке фабрикасы, «Беломорканал»! Хәлим төпчекне, криминалистларга гына хас булган пөхтәлек белән, Сәкинәсе биргән чиста кулъяулыкка төреп, кесәсенә салып куйды. Эзләнә торгач, кайсыдыр ярыктан «Беломор» кабы да килеп чыкты. Иң кыйммәтлесе — шул капка ашыгып кына сырлаган сүзләр иде: «С! Иртәгә шул ук урында 12 дә. С.»

...Төш вакыты бетеп килгәндә, ул вагон бушаткан кеше сыман арып-талып, өйгә кайтып керде.

Сәкинәсе көндәгечә аш-су әзерләп маташа иде.

— Әтисе, ни булды, алтынкаем?

Хәлим, ничек тә булса хәлен сиздермәскә тырышып, өйгә узды һәм диванга кереп ауды.

Сәкинә төрле үләннәр кайнатып, дару-фәлән табып, ире янында мәш килде. Хәлим моңсу күзләре белән Сәкинәсенең чибәр йөзенә, буй-сынына, үз-үзен тотышына сокланып, «Ышанырга мөмкин түгел!»— дип уфтанып ятты.

Иртән кояш чыкканда ул инде урамда иде. Бу юлы да аяклары аны бүрәнәләр өеменә алып килде. Тик... Бүген биредә эш кызу бара иде.

— Сәлам, кардәшләр! Нәрсә кинәт куптыгыз?

Хәлимнең соравына ташчы Сабир теш арасыннан гына җавап бирде:

— Комиссия килә, имеш. Тапканнар вакыт. Ә сиңа монда нәрсә кирәк?

Хәлим бүрәнәләрне күзәтә-күзәтә:

— Юк ла, минем көтү куып кайтуым...— диде һәм аяк табанына шырпы кадалган сыман, сикереп куйды. Тамгалы бүрәнә урынында юк иде! Ул шундук Сабирны туктатып әйтте:

— Ун метрлы бүрәнәгезне сукканнар бит, беләсезме!?

— Моннан егерме метрлысын да сугарга булдыралар,— диде Сабир тыныч кына.

— Ә Сәгыйдулла кайда соң?

— Аның көтү куасы юк. Синең кебек ач иртәдән колхоз милке өчен янып йөрергә җүләр түгел ич ул!

Хәлимнең уйлары бөтенләй башка якта иде. Кайчан да булса исенә төшәр иде микән, әмма бу мизгелдә ул узган ел үзенең колхоз отчет җыелышында халык контролеры итеп сайлануын исенә төшерде. Башка вакытта колхозның бер бүрәнәсен генә түгел, машинасы белән суксалар да исе китмәс иде. Әмма бүген аңарда халык милкенә кул сузучыга, ягъни тамгалы бүрәнәне урлаучыга карата тирән нәфрәт кузгалды.

Шул нәфрәтен көчкә тыя-тыя, ул прораб Сәгыйдулланың өенә барып керде. Җылы түшәктә изрәп яткан прораб экономист Хәлим-

нең әтәчләр кычкырмас борын тавыш куптаруын, әлбәттә, алкышлап каршыламады.

— Син йокы симертәсең, ә анда клуб төзелешеннән менә дигән бер бүрәнәне урлап киткәннәр!

Сәгыйдулла шешенгән күзләрен уды.

— Шулаймыни? Бер бүрәнә диген, ә... Һм... Ә син, нәрсә, милициягә эшкә күчтеңме әллә?

— Минме? Мин бит!..

— Син бит, син бит! Бар, бар, яшь әзтабар, кайтып хатыныңны кара, аны урлап китмәсеннәр!

Сәгыйдулла чуар юрган астына кереп чумды.

Колхоз милкенә шулай битараф каравы белән Хәлимнең җен ачуларын чыгарды прораб. Чуар юрган идәнгә очты.

— Мин, беләсең килсә, халык контроле вәкиле! Былтыр үзегез сайлап куйдыгыз!

Сәгыйдулла тагын юрганны үзенә таба тартты.

— Сайлаганнар сайрап йөрсен, минем анда ни эшем бар?

— Төзелешкә комиссия килә бит, оятсыз! Хет шул хакка уян!

— Комиссия килә дә китә ул, ә эш кала бирә...

Чуар юрган прорабны көмешкә-суган исе аңкып торган авызыннан каплап куйгач, халык контроле вәкиле, вөҗдан турындагы диалогның уңышсыз тәгәлләнүенә тәмам инанып, урамга чыгып китте: «Бөтенесен аякка бастырам, барыбер бүрәнәне таптырам!» — дип каткат кабатлады ул.

Комсомол комитеты секретаре Марсель иртәнге гимнастика ясап маташа иде. Әле егерме биш тә тулмаган бу егет һөнәре белән гади электромонтер гына булуына карамастан, озын-озын лекцияләр, докладлар сөйләп, авылда гына түгел, районда билгеле бер оратор булып исәпләнә иде. Шуңа күрә авыл халкы аны «нотык Марселе» дип йөртә. Хәлим килеп кергәндә нотык маһире ике потлы герне җилкәсендә уйната иде.

— Хәерле иртә, Марсель энекәш!— дип дәште Хәлим комсомол секретарена һәм, сәлам алганны да көтмичә, сорауны кабыргасы белән куйды: — Сезнең прожекторыгыздан берәр файда бармы? Ул теге кыңгыр эшләрне яктыртамы, юкмы?

Марсель ике потлы герне җиргә төшерде һәм шушы сорауны гына көткән кеше кебек җавапны бик тиз тотты:

— Ничек яктыртмасын, Хәлим абый, әлбәттә, яктырта. Ындырдагысы да, кырдагысы да, фермадагысы да. Ул прожекторларны мин бит үзем лично карап торам. Прожектор бит ул бик мөһим...

— Мин бит, Марсель, ындыр прожекторы димим. Кыңгыр эшләрне яктыртучы «Комсомол прожекторы» эшлиме, дим! Менә, мәсәлән, клуб төзелешеннән шәм кебек бер бүрәнәне сугып киткәннәр. Клуб бит ул сезнең өчен — яшьләр, комсомоллар өчен төзелә торган изге нәрсә. Шул бүрәнә мәсьәләсен күтәрә аламы прожекторыгыз, юкмы?

Бу сүзләрдән соң нотык Марселе эчен тота-тота көлде.

— Ничек инде безнең «Прожектор»дагы ике кеше, хәтерем ялгышмаса, унынчы класста укучы чебеш кебек ике кыз, бүрәнә тикле бүрәнә күтәрсеннәр, Хәлим абый. Авыр ул!

— Мин сезгә бүрәнә күтәрергә димим бит! Бүрәнә урлау мәсьәләсен дим. Ягъни, Марсель энекәш, сүз халык милкенә кул сузу турында бара!

— Менә-менә! Нәкъ кендегенә бастың! Югыйсә, бездә мәсьәләне тегеләй дә, болай да боргалыйлар. Мәсьәлә ул, мәсьәлә! Мәсьәлә күтәрү ул, Хәлим абый, гер күтәрү белән бер!

Нотык Марселе янә ике потлы герне өскә чөеп, җилкәсендә уйната башлады.

— Аңлашылды. Син дә комсомол секретаре исемен күтәреп йөрисең, таш йөрәк. Их!— Хәлим кул селтәде дә профсоюз башлыгы Харисның өенә юл тотты. Иртәнге чәйдән күтәрелгән профком председателе бүрәнә югалу турындагы хәбәрне игътибар белән тыңлады, хәтта чын күңелдән кайгырды булса кирәк.

— Тик, Хәлим туган, эш биредә профком вәкаләтләреннән узып киткән бит. Син мәсьәләне сәер куясың. Үзең халык контроле вәкиле, ә үзең профсоюз җитәкчесенә килгәнсең. Бу очракта мин сиңа килсәм, дөресрәк булыр иде түгелме соң? Бусы — бер. Икенчедән, колхозда хуҗа бар бит. Адресын әйтергәме, әллә үзең дә...

Хәлим янә кул селтәп китеп барды. Аның уйлавынча, колхозда тагын абруйлы ике кеше — партоешма секретаре белән председатель генә бу эшкә кирәкле бәя биреп, чара күрергә булдыра ала иде.

Партоешма секретаре район үзәгенә чыгып киткән икән. Шуңа күрә Хәлим кәнсәләргә килде. Гомердә булмаганны, ул туп-туры председатель Искәндәр Кәримовичның кабинетына шакып-нитеп тормыйча бәреп керде.

Председатель чамадан тыш батырайган экономистны күреп:

— Нәрсә булды? Әллә кассаны басканнармы?— дип кычкырды.

— Кассаны бассалар бернәрсә булмас, анда барыбер акча юк...

Председатель кызып китте:

— Акча юк! Булдыксыз экономистлар белән эшләп, нинди керем булсын! Начар эшлисез!

— Керем юк та юк инде ул, Искәндәр Кәримович. Колхоз милкен болай сакласак, гафу итегез, бөтенләй ыштансыз калуыбыз бар.

— Син, давай, турыдан, вакыт юк. Нәрсә булган?

— Клуб төзелешеннән бер бүрәнәгә «аю мае» сөрткәннәр. Мөгаен, прораб Сәгыйдулла сатып эчкәндер.

Председательнең битен бер мизгелдә канәгатьсезлек билгесе каплады.

— Син, агайне, белер-белмәс: «Урлаганнар, сатып эчкәннәр»,— дип тавыш куптарырга ашыкма әле. Айдан төшмәгәнсеңдер бит?

Председатель тәмәке кабызып җибәрде.

— Айдан төшкәнсең икән, аңлатып бирәм,— диде ул, ярсуын баса төшеп.— Урлау кайдан килә? Эчүчелектән. Айнык баштан кеше контордан бер карандаш чәлдерергә дә кыймый. Шулай бит? Эчсә — бүрәнә түгел, комбайнны да абзарына куып кайта.

Хәлим талпынып куйды.

— Соң мин дә бит шул турыда...

— Ә бездә, иптәш Кәбиров, исегезгә төшерәм, икенче ел инде аеклык зонасы. Эчмибез дә, урламыйбыз да. Әле кичә генә районга шул хакта шатлыклы хәбәр җибәрдек. Ә син биредә тузга язмаганны сөйләп торасың. Бар, эшеңне әйбәтләп башкар, керем турында уйлан! Кассада эш хакы бирергә акча юк. Менә синнән халык нәрсә көтә! Уңышлар телим...

— Рәхмәт,— дип мыгырдады Хәлим.— Безнең авылда барысы да «Беломор» тарта икән...

Председатель, аңламыйча, экономистка сораулы караш ташлады:

— Нәрсә, нәрсә?

Хәлим уңайсызланып:

— Гафу итегез, мин сезнең турыда түгел...— диде һәм кабинеттан чыгып китте.

Колхозның акча әрҗәсендә сукыр бер тиен дә шылтырамавын председатель бары тик үзенең булдыксыз исәп-хисапчыларыннан, экономистларыннан күрә иде. Бөтен районга мактанырлык тәртипне өстәлгә йодрык белән төеп, бер җыелыш карары белән аеклык урнаштыра алган мәһшүр җитәкче җәмгыять сейфын хәләл акча белән тутыруны бик вак, пүчтәк эш дип карый иде. «Миннән — тәртип, сез-

дән — акча! Кайда безнең керемнәр?!» — дип, Искәндәр Кәримович киңәшмә саен бухгалтер һәм экономистларның бугазларына баса иде. Әмма бу көч сарыф итү, буш әрҗәгә йодрык белән суккан сыман, бернинди уңай нәтиҗә дә бирми. Шуңа күрә баш бухгалтер председательнең эш хакын, премиясен вакытында кертеп бирүдән артык чара күрә алмый... Хәер, бусы да колхоз башлыгының тузган нервларын шактый гына тынычландыра иде.

Шулай да Хәлимнең уйлары бүген колхозның буш әрҗәсе турында түгел, юкка чыккан тамгалы бүрәнә тирәсендә чуала.

Ул үзен диңгездә япа-ялгыз йөргән сыман хис итте. Тотынырга бүрәнә түгел, нибары бер салам бөртеге — «Беломор» кабына язган сәлам хаты гына йөзеп йөри иде бу иксез-чиксез дәрьяда. Тә-әк... Вакыты билгеле. Очрашу урынын санап чыгарга мөмкин. Авыл шәһәр түгел. Шәһәрдә генә ул чат саен утыргыч, ышык урын — көпә-көндез кавышалар, оялмыйча үбешәләр. Авылда әле бу мәсьәләдә һаман искечә. Очрашу урыннары санаулы — тау астындагы чишмә, иске клуб артындагы имән, авыл читендәге ташландык җил тегермәне.

Әбәткә кайтканда Хәлим янә төзелешкә сугылып чыгарга булды. Инде бу юлы бернинди сюрприз көтмәгән экономист анда... тамгалы бүрәнәне күреп алды! Аның үткен күзе тамганың зуррак хәрефләр белән салынуын күрде. Димәк, башка бүрәнә! Хәлим: «Балта табып, юнып ташлыйм мәллә», дип уйлап торганда, мәйданга прораб үзе килеп чыкты. Ул уйга чумган экономистны күреп:

— Нәрсә, халык контроле күзе күпне күрә, тагын бүрәнә санымсыңмы?

Хәлим сөйләшеп тормады, кул селтәп кайтып китте.

Төнге уникегә хәтле ул кымшанмыйча ятты. Янында Сәкинәсе тыныч кына йоклый иде. Стенадагы сәгать уникене суккач, ул әкрен генә торып киенде һәм, өйнең ишеген өстән бикләп, иске тегермән янына юл тотты. Җайлы урын табып, колакларын тырпайтып, көтә башлады. Күп көтәргә туры килмәде. Тегермән янына әкрен генә җиңел машина килеп туктады.

— Утыңны кабызма! — дип боерды таныш тавыш. Бу колхоз председателе Искәндәр Кәримович иде.

— Аңладым, шеф, — дип җавап бирде тагын бер таныш тавыш. Монысы Сәгыйдулла иде. — Балык, тавык, ярты савыт.

— Ярар, әйдә, озак маташма. Хәзер үзең беләсең. Заманасы ул түгел. Аеклык зонасы... Әле монысын кайдан юнәттең?

— Комиссия килә дигәч, бер бүрәнәне дачникларга...

— Ярар, «Сабантуйга китте», диеп акт язарсың. Югыйсә, бүген миңа безнең мәхлук Хәлим: «Колхоз милкен урлаганнар», — дип, бу уңайдан гауга куптара башлаган иде.

— Мине дә йокыдан күтәрде ул бүген. «Мин — халык контроле вәкиле, кайда бүрәнә?» — дип бугазга баса бит. Күзен әйт әле син аның. Шул хәтле бүрәнә арасыннан берсе җитмәвен сизеп алган бит! Кем-кем, ә аңардан көтмәгән идем! Аптыраш. Югыйсә, ул хатынынан гайре беркемне дә күрми-белми иде бит...

— Андый хатының булса, Сәгыйдулла, синең дә күзеңә башка нәрсә күренмәс иде, — дип җавап бирде председатель, стаканын бушатып.

— Миңа дисә, хет алтын булсын. Хатын-кыз ул, минемчә, ир-егеткә өреп торучы бер эт. Тыныч тормышны гаилә сазлыгына батырырга мин җүләр түгел әле!

— Юкны сөйлисең. Аның Сәкинәсе артыннан нинди генә егетләр йөрмәде! Ыспай Сәлим үзе генә ни тора иде! Гармунчы, ут кебек егет. Хәтерлисеңме?

— Хәтерләмичә. Бик яхшы беләм, Искәндәр Кәримович. Ул булмаса — балык, тавык, ярты савыт каян килер иде безгә.

— Аңламадым. Ыспай Сәлимнең бу яртыга нинди катнашы бар?

— Искәндәр Кәримович, ул бит хәзер күршедәге Карун леспромхозында эшли.

— Кит аннан!

— Билләһи газим, менә шушы стакан белән ант итәм!

Прораб, стаканны «голт-голт» иттереп, бер секундта бушатып куйды.

— Ышандырдың, сал тагын. Димәк, бүрәнәләр шуннан кайта?

— Бездә урман юк бит инде. Кәримыч.

— Ә кем булып эшли соң ул анда? Күбрәк салдың бугай. Иртәгә районда киңәшмә...

— Норма. Ә Сәлим Хәлимович үз урынында зур кеше. Начальник. Тәэминатчы. Кыскасы, безгә кирәк кеше. Тот, Кәримыч, тот, безнең исәнлеккә. Актлар язып-сызып торыш юк. Ул миңа барган саен бер-ике бүрәнәне артык төяттереп җибәрә. Соңгы тапкыр ике шәм сыман бүрәнәне үзе лично салдырды. «Берсен Сабан туе колгасына бастырырсыз»,— диде. Бәһасе — бер тавык та ике савыт.

Председатель икенче стаканны әйләндереп куйды.

— Синең бөтен җирдә бер такса. Менә әйтеп бетермәдем. Шушы Ыспай Сәлим озак йөрде теге Мәхлук Хәлимнең булачак хатыны артыннан. Нәрсәдер барып чыкмады. Китеп барды. Хәзер туган якларда, димәк. Авылда ник күренми соң ул зимагур?

— Монда нәрсә бар аңа? Тегендә акча, тавык, савыт. Минем кебек кунакчыл прораблар бетмәгән бит, Кәримыч. Чират торалар. Сабан туена чакырдым мин аны. «Бәлкем кайтып әйләнермен, бер бәхетле кешене күрәсем бар иде»,— дип сөйләнде.

Әллә төнге салкынча җилдән, әллә ишеткән шомлы хәбәрдән Хәлим туңа-калтырый башлады. Озакламый савытларын бушатып, председатель белән прораб машинага утырып китеп тә бардылар. Хәлим дә, оешып каткан буыннарын угалый-угалый, өенә таба атлады.

Авыл йоклый иде. Болытлар арасыннан күренгәләп киткән ай тирә-юньгә тонык нурын сибә. Их, ай, ай! Күпне күргән сүзсез шаһит! Әгәр җирдә кылынган кыек хәлләрне пакь кеше кебек кичерә белсә... Оятыннан кызарып, күптән кояшка әверелер иде ул.

Хәлим, бикләгән ишеген ачып, өйгә керде. Сәкинәсе тыныч кына йоклап ята иде...

Иртән ул таныш маршрут белән төзелешкә барды. Тамаша! Тамгалы колга юкка чыккан иде! Тирә-юньдә кеше-фәлән күренмәде. Экономист, нәрсә уйларга белмичә, тиз-тиз атлап төзелештән китеп барды. Аяклары аны үзе дә сизмәстән кәнсәләргә китерде. Идарә нишләптер бикле булып чыкты. Сәгать тугызлар иде. Каравылчы Дәүли абый бакча эчендә нидер төзәтеп маташа.

— Дәүли абзый, исәнме!— дип дәште Хәлим.— Нишләп контора бикле бүген?

Дәүли абзый билен тотып ыңгыраша-ыңгыраша турайды һәм Хәлимне күреп:

— Ә-ә, син икән. Бүген, энекәш, сабан туе бит. Халык шунда...

Хәлим, сабан туйларында батыр калып дан тоткан кеше булмаса да, бу бәйрәмне аеруча ярата, көтеп ала иде. Тик бүген, шул каһәр суккан колга-бүрәнә артыннан йөреп, сабан туе буласын бөтенләй оныткан икән ләбаса! Тизрәк Сәкинәсен алып, мәйданга төшәргә кирәк.

Ә мәйдан шаулый-гөрли. Озын шома колга тирәсенә инде халык җыйналып, яше-карты өскә үрмәләргә тырыша. Чү! Колга дигәннән... Шул бит! Әнә, нәкъ бүләкләр элгән җирендә таныш тамгасы да бар. Шактый зур хәрефләр белән һаман да шул Сәлим һәм Сәкинәнең мөнәсәбәтләре турында әллә кайдан кычкырып торган

тамга иде бу. Һәрхәлдә Хәлимгә бу шулай тоела иде. Ул бу тамганы биш чакрымнан да күреп алыр сыман иде.

— Туктап тор, Сәкинә!— диде ул һәм колга төбенә килеп басты.— Йәгез әле, егетләр, мин дә сынап карыйм бәхетне...

Хәлим, бөтен дөньясын онытып, затлы чалбар-күлмәген дә алыштырмыйча, шома колгага үрмәли башлады. Азаплана торгач, колганың очына якынлашты. Гомерендә берниндә уенда катнашмаган, турникта ике тапкыр да күтәрелә алмаган Хәлимнең колгадагы бүләккә менеп җитүен күреп, авыл халкы дәррәү кул чапты. Әмма колгага үрмәләүченең бүләккә бер дә исе китмәде. Ул кесәсеннән пәке чыгарып «С» хәрефенә тагын бер кәкре таяк өстәп куйды. «Сәлим + Сәкинә» шул ук минутта «Хәлим + Сәкинә»гә әйләнде.

— Йә, ал инде бүләкне, нәрсә маташасың!— дип кычкырдылар астан. Тик Хәлим үз эшен эшләп өлгергән иде, аска таба шуды. Йөзләгән күз аның җиргә төшүен тын гына карап торды.

Түбәтәй кигән судья Хәниф, Хәлимнең кулын кысып,аптыравыннан булса кирәк, аңа русча эндәште:

— Не понял юмора земляк...

Хәлим озак уйлап тормады.

— Аңларсың, энекәш, әле аңлар көннәрең алда,— дип, хатынын эзләп китте.

Сәкинәсе аны елмаеп каршы алды:

— Карале, алтынкаем, син бит бик батыр кеше икәнсең, белмәгән идем,— диде.

Мәйдан буйлап күпме йөргәннәрдер, анысын төгәл әйтеп булмас, тик сабан туе таралыр алдыннан гына Сәкинә белән Хәлимгә шактый үзгәргән, олыгаеп корсак үстереп җибәргән Ыспай Сәлим белән борыны кызарган прораб Сәгыйдулла очрадылар.

— Исәнмесез, якташлар! — диде Сәлим эшләпәсен мушкетерларча болгап.— Таһир белән Зөһрәгә бездән кайнар сәлам!

Исәнләшеп, бераз сөйләшеп торгач, Сәлим кесәсеннән «Беломор» алып көйрәтеп җибәрде һәм Хәлимгә кулын сузды.

— Маладис, шундый биек шома колгага менә алгач, син кыю кеше икәнсең. Юкка гына Сәкинә сине сайламаган...

— Шул-шул, ир сайлау — бүрәнә сайлау түгел шул!— диде Хәлим, боларның икесенә берьюлы төрттереп.

Сәлим белән Сәгыйдулла авызларын ачып катып калдылар. Хәлим, Сәкинәсен кочаклап, мәйданга таба китеп барды.

Колга башында сабан туе җырлары тибрәлә иде.

# ЗӨЛФӘТ ТУРЫНДА ЗӨЛФӘТ

*«Абау! Бигрәкләр дә хозур! Җан кебек инде!»— дип соклана безнең халык. «Кеше җаны бар монда!»— дип әйтергә теләүдәндер инде бу...*

*Зөлфәт Хәким язган шигырьләрдә нәкъ менә шул җан җылысы бар. Шагыйрь, җырчы, музыкант буларак, ул Сүзнең кадерен, моңның бәһасен белә, хиснең кыйммәтен тоя.*

*Минем үземне нәкъ шундый шигырьләр төн йокысыннан калдыра.*

*Чөнки Зөлфәт Хәкимнең җанындагы борчулар миңа күчә, аның сагышы, аның шатлыгы минем дә күңелемне алгысыта.*

*Ихлас җанлы бу шагыйрьне Шигърият алласы үзенең мәрхәмәтеннән ташламас дип чын күңелемнән ышанам.*

*Хәер, иң әлек аның шигырьләрен үзегез укып карагыз әле.*

**ЗӨЛФӘТ,**
Татарстан комсомолының М. Җәлил
исемендәге премиясе лауреаты.

## Зөлфәт Хәким

### Айлы төн

Шаулама! Чү! Куркытырсың!

...Төнгә муенын сузган
Кое сиртмәсенә кунып,
Ай үзен карый судан.

Боза күрмә бу тынлыкны,
Атлама бер адым да.
Күрәсеңме:
Ай бизәнә
Ерак сәфәр алдыннан.

### Әби

Ачы еллар тозы утыргандыр,
Шуңа шундый аның күзләре.
Битләрендә җыерчыклар түгел,—
Нужа камчысының эзләре.

Өй янында гарип тал агачы
Тыңлап арыгач кошлар авазын,
Кояш баю белән, пыш-пыш кына
Укыйдыр күк кичке намазын.

Ә таң аткач — җәен, кышын, язын
Җилләр искәч тагын җанлана.
Әллә авыртудан шыгырдый ул,
Әллә тормышыннан зарлана.

Аерылышу газаплары
Төн йокысы бирмиләр,
Көзге җилләр тәрәзәмне
Дер селкетеп тиргиләр.

Тәрәзәмне киереп ачып
Каршы әйтердәй булам.
...Дөнья давылын күмәр күк
Минем җандагы буран.

## 1937

Сагайды йорт...
Авыр тынлык...
Шәүлә урам чатында.
Бу тирәдә нидер йөри,
Кемдер бар өй артында.

Үлем килеп керде өйгә,
Эт өрүдән туктагач...
Тора... кииеме бик таныш:
Галифе һәм күн плащ.

## ТатАЭСта уйлаган уй

Кайбер эшләре Кешенең
Күренсә дә изге булып,
Бу Җирдә кылынган хәлләр
Мәңгелектә калмас микән
Бер коточкыч мизгел булып...

Һаман буран Җирдә, һаман давыл...
Хәтта дөнья инде чайкала.
Мәңгелек дау игълан иткән төсле,
Өметләрдән тыны капкан килеш,
Безнең өнсез еллар чаң кага.

❀

Ышанмыйм мин үлем барлыгына,
Жирем ачкач соңгы кочагын,
Чыдамам мин аның тарлыгына,
Мәңгелеккә чыгып очармын.

Мин кайтырмын Җиргә ерак юлдан
Бу заманның җырын җырларга.
Мәңгелеккә китү мөмкин, мөмкин!—
Рәхмәт укыйм үткән елларга.

Көчем бетсә мин иңәрмен җиргә —
Ял итәргә тормыш шавыннан.
Бу — хәл җыю булыр минем өчен,
Мәңгелеккә очар алдыннан.

Үлемсезлекләрнең тирән серен
Беләм сыман бары мин генә.
Риза түгел үлем барлыгына!
Мин дөньяга килдем мәңгегә!

❀

Тере тәнгә пычак кадагандай
Җир тетрәтеп субай кагалар.
Җан өшеткеч «прогресс» тавышыннан
Качып бетте хәтта каргалар.

Исерек ирдән поскан хатын сыман,
Читтәрәк бер авыл сагайган,
Урамында үскән каеннары
Күздән түгел, куркып саргайган.

Менә төйнәлер дә тимер йодрык,
Кыйнап ташлар шушы авылны,
Чалышайган басу капкалары
Каршы алыр соңгы давылны.

Комсызлыктан ярсып, сукыраеп,
Болгый «прогресс» үткен хәнҗәрен.
Оча алмый калган кош шикелле
Тора авыл көтеп әҗәлен.


## Аттылар ана этне

Җирдә мәрхәмәт барына
Өзәрсең дә өметне:
Этләр өере җыя дип,
Аттылар ана этне.

Үтерделәр җан иясен,
Ана булмасын өчен.
Аттылар... китеп бардылар,
Канатып кышның кичен.

Елады җил, ята-ята
Канлы карның өстенә.
Йолдызлар чыкмады куркып,—
Күктә кара төс кенә.

Очты җаны бичараның,
Кермәде ул ояга —
Очты төннең үзәгенә,
Үпкәләп бу дөньяга...



# КАЙТУ

Язмышы, политик карашлары никадәрле четерекле булмасын, атаклы прозаик, драматург, публицист һәм, революциягә кадәрге демократик тәнкыйтьнең раславынча, яңа татар әдәбиятына нигез салучылардан күренеклесе буларак, Гаяз Исхакый татар халкы тарихының аерылмас бер кисәге хисапланырга хаклы.

Г. Исхакый Казан губернасының Чистай өязе Яуширмә авылында мулла гаиләсендә туган. Атасы кул астында укырга-язарга өйрәнгәч, аны Чистай мәдрәсәсенә бирәләр. Аннары ул Казанга күчеп китә. Монда Күл буе мәдрәсәсен тәмамлап, бер ел хәлфә булып торгач, 1898 елда Гаяз рус класслары өчен укытучылар әзерли торган Татар укытучылар мәктәбенә керә һәм Х. Ямашев, Г. Коләхмәтовлар белән бергә дүрт ел буе укып, аны тәмамлап чыга. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә бер ел эшләгәч, сукырайган әтисенең үтенүе һәм кушуы буенча, авылына кайтып мулла була.

Г. Исхакый бик яшьли яза башлаган. 1905 елгы революциягә кадәр үк инде ул дистәгә якын хикәя һәм повесть, ике пьеса һәм «Теләнче кызы» исемле романның беренче кисәген иҗат иткән һәм күбесен дөньяга чыгарган була. Язучының башлангыч иҗат чорында «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902) исемле хыялый-публицистик повесть үзенчәлекле урын тота дияргә мөмкин. Бу әсәрдә автор милли үсеш, үзгәреш һәм иҗтимагый прогрессны тәэмин итә торган биш шарт (арадан берсе — рус мәдәниятен үзләштерү) турында сүз алып бара. Повестьның татар иҗтимагый фикерен һәм әдәбиятын алга җибәрүдә гаять зур роль уйнаганлыгы турында замандашлары, шул исәптән, Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан да язып чыгалар.

Укытучылар мәктәбен радикаль фикер-карашка килеп тәмамлаган Г. Исхакый 1905 елгы революциянең беренче көннәреннән үк самодержавиегә каршы көрәш эченә кереп китә. Татар эсерлар төркеменең башлыгы буларак революцион-демократик позициядә

ныk басып торган хәлдә, ул крестьяннар арасында эш алып бара, аннары «Таң йолдызы» исемле газета барлыкка китереп, «Мөселман иттифакы» партиясенә каршы көрәш шартларында массаларны сәяси яктан тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Берничә мәртәбә кулга алынып, төрмәдә утыра, 1907 елда Архангель губернасына өч елга сөргенгә җибәрелә. 1908 елда, яшь төрекләр революциясе булганны ишетеп, Төркиягә кача. 1911 елда ул яшерен рәвештә Петербургка кайта һәм, кулга алынып, сөргеннең калган өлешен тутырыр өчен яңадан Архангель губернасына озатыла. Сөргеннән аны Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңае белән игълан ителгән амнистия азат итә.

Бу елларда Г. Исхакый шулай ук күп, тиз һәм ал-ялны белми иҗат иткән. Кеше почмакларында язган ул, төрмәләрдә, конспиратив квартираларда һәм сөрелгән җирләрендә эшләгән. Беренче рус революциясе елларына караган әсәрләре арасында «Солдат» һәм «Зиндан» дигән повестьлар, «Теләнче кызы» романының дәвамы һәм «Тартышу» исемле пьеса бар. Бу әсәрләргә, публицистик пафостан кала, социаль каршылыкларга игътибар һәм тормышны сыйнфый принциптан чыгып сурәтләү хас.

1909-1913 елларда Г. Исхакыйның иҗаты аеруча җимешле була. Бу чорда ул шактый өлешен классика төренә кертерлек күп хикәя, повесть, роман һәм пьесалар яза. Шундыйларга беренче чиратта «Тормышмы бу?» һәм «Мулла бабай» романнарын, «Кияү», «Сөнәтче бабай» һәм «Бер тоткынның саташуы» повестьларын, «Фамилия сәгадәте» исемле хикәяләр җыентыгын кертергә мөмкин. Моңа татар театр труппалары тарафыннан куелып, сәхнәдә зур уңыш белән барган «Җәмгыять», «Кыямәт», «Мөгаллимә» һәм «Зөләйха» кебек пьесаларын да өстик. Болар — шул заман татар җәмгыятен чын мәгънәсендә сәнгатьчә тикшерә һәм анализлый торган әсәрләр. Аларда консерватив руханиларның, шәкерт һәм мөгаллимнәрнең, ярлы һәм урта хәлле крестьяннарның, кулакларның яңа, оригиналь типлары белән беррәттән, төрле социаль катлауларга караган менә дигән хатын-кыз образлары да урын ала. Исхакыйның реализмы яңа югарылыкка күтәрелә. Геройларның рухи дөньясына керүдә һәм психологик анализда ул яңа биеклекләр яулый.

Г. Исхакыйны XX йөз башы татар әдәбиятының әйдәп баручыларыннан иткән факторларның берсе рус классик әдәбияты булды. Ориентациянең Көнчыгыштан Көнбатышка, төгәлрәк әйтсәк, төрек әдәбиятыннан руска таба авышырга тиешлеген аңлап алып, ул бик яшьли рус әдәбиятын өйрәнә һәм пропагандалый башлый. Егерме яшендә ул Пушкинның «Капитан кызы» һәм Гогольнең «Борынгы алпавытлар» повестьларын татарчага тәрҗемә итә. Соңрак Исхакый И. С. Тургеневка, Л. Н. Толстойга һәм А. М. Горькийга табына башлый. 1909 елда Төркиядә укыган лекциясендә ул рус әдәбиятын «хөррият вә тәрәккый тарафдары, зәгыйфь вә фәкыйрьләрнең мөдафигы[1]», дип атаган. Аннары болай дигән: «рус әдәбиятының һәм, хосусан, гавампәрвәр[2] әдәбиятның татарларга тәэсире ихтилалчылар[3] җитештерүдән бигрәк, милли, фикри инкыйлапларны[4] әзерләүдән гыйбарәт булды».

Реализмы һәм халыкчанлыгы сәбәпле Г. Исхакый иҗаты, Тукай шигърияте кебек үк, татар халкының киң катлауларына кадәр барып җитте. Аның даны милли чикләрне дә атлап чыкты. Россиянең рус булмаган әдипләре арасында беренчеләрдән булып ул башкала журналларында һәм җыентыкларында басыла башлый. Бүтән авторлардан кала, аның турында үзәк матбугатта академик В. А. Гордлевский һәм Н. И. Ашмарин кебек галимнәр дә язып чыгалар. Г. Исхакый иҗатының бәясен А. М. Горький да яхшы аңлаган. Алар күп еллар буе хат алышканнар. Берлин профессоры М. Һартманның «Төркиядән гайре сәяси хатлар» дигән китабында (Лейпциг, 1910) һәм «Рашен ревью» исемле инглиз журналында (1914, № 1) шактый күп сәхифә Г. Исхакыйга багышланган.

Революция алды елларында Г. Исхакый әдәби әсәрләр язудан тукталмаса да, эшчәнлеге күбрәк вакытлы матбугат һәм публицистикага таба авышты. Башта Петербургта, аннары Мәскәүдә ул охранкага шактый мәшәкать тудырган радикаль юнәлешле «Ил» һәм «Сүз» газеталары чыгара.

Февраль революциясен Г. Исхакый шатланып каршы ала һәм эсерлар рухындагы сәяси көрәшкә баш-аягы белән чума. Ләкин Октябрьне һәм Советлар властен ул кабул итә алмады, чөнки барлык эсерлар һәм меньшевиклар кебек үк, артта калган «чабаталы» Россия (бигрәк тә аның милли төбәкләре) социалистик революциягә әле өлгереп җитмәгән, дип ышана иде.

Г. Исхакыйның эмиграциядәге тормышы һәм эшчәнлеге турында без хәзергә аз беләбез, чыганаклары күрсәтелмичә генә таратылган имеш-мимешләр белән генә чикләнеп торабыз.

Хәер, соңгы вакытларда яңа мәгълүматлар килеп тора, аның чит илләрдәге тормышы да ачыклана бара. 1919 елда солых конференциясенә дип киткән Г. Исхакый кире кайтмый, күпмедер вакыттан соң Берлинга барып урнаша. Анда 1929 елга кадәр яшәгәч, Польшага күчеп китә. 1939 елда бер яктан Гитлер, икенче яктан Совет армияләре килеп кергәч, ул Төркиягә барып төпләнә һәм 1954 елның җәендә шунда вафат була.

1. Мөдафиг — яклаучы. 2. Гавампәрвәр — демократик. 3. Ихтилалчы — революционер. 4. Инкыйлап — алмашыну, революция.

Гаязның тагын ниндидер Бәйсезлек комитеты рәисе буларак, Финляндиядән Япониягә чаклы татар мөһаҗирләре, ягъни, күчеп китүчеләре булган төбәкләрне йөреп чыкканлыгы, халыкны оештыру, милли рухта тәрбияләү (телләрен, диннәрен, гореф-гадәтләрен онытмасыннар!) буенча күп эш башкарганы, Европада «Милли юл» журналын чыгарганы, ерак шәрыкътә «Милли байрак» исемле газетаны нигезләгәне мәгълүм. Боларны әле җентекләп өйрәнәсе бар. Әмма Г. Исхакыйга ягылган кара тапларның кайберләрен хәзер үк юып төшерергә мөмкин. Аның, мәсәлән, немец фашистлары белән хезмәттәшлек итмәгәнлеге, татар әсирләреннән легионнар оештыруда катнашмаганлыгы, икенче бөтендөнья сугышы елларында бөтенләй Германиядә булмавы сәбәпле, катнаша да алмаганлыгы турында кистереп әйтергә мөмкин.

Без, әлбәттә, Г. Исхакыйны һәр җәһәттән акларга, турайтырга, шомартырга җыенмыйбыз. Васыяте дип йөртелә торган шәхси хатыннан күренгәнчә, соңгы көннәренә чаклы ул илдә урнашкан иҗтимагый-политик хәл белән дә, милли мәсьәләнең практик рәвештә хәл ителеше белән дә килешә алмаган.

Хәер, татар халкы һәм аның әдәбияты тарихын чын мәгънәсендә фәнни һәм, димәк, дөрес яктырту зарурияте яктылыгында караганда, Г. Исхакыйның чит илдә ничек яшәве, ни эшләве зур әһәмияткә ия түгел. Аңа карап кына әдәби мирасының идея-художество дәрәҗәсе төшми дә, күтәрелми дә. Ә бу мирастан тыш XX йөз башы татар әдәбиятының язма тарихы, беренче бүлеге умырып алынган китапны хәтерләтеп, чын мәгънәсендә фән була алмый.

* * *

Г. Исхакыйның укучыга тәкъдим ителә торган ике әсәреннән берсе — «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле фантастик-публицистик повесть 1902 елның ноябрендә язылып бетеп, җайга таба Петербургта цензура аша узып, 1904 елны Казанда басылып чыккан. Кабат басылганы күренми.

Әсәрнең эчтәлегенә тукталып тормастан, ике нәрсәгә генә укучының игътибарын юнәлтмәкче булам.

Беренчесе — повестьның татар әдәбияты тарихында тоткан урыны. Рус әдәбияты һәм Гогольнең «Шинеле» турындагы мәгълүм сүзләргә охшатып, XX йөз башы татар әдәбияты Исхакыйның «Инкыйраз»ыннан чыкты, дип әйтә алабыз. Бу чор әдәбияты белән азмы-күпме таныш булган укучы үзе дә күрер: Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ. б. классикларыбызның шигырь һәм хикәяләрендә, повесть һәм пьесаларында, мәкалә һәм фельетоннарында күтәрелгән һәм сәнгатьчә хәл ителгән тема һәм мәсьәләләрнең барысы да «Инкыйраз»да бар. Повестьтагы тип һәм образларның, деталь һәм тәгъбирләрнең кайберләре шул дәвер әдип һәм шагыйрьләренең әсәрләренә хәтта үзгәрмичә, сүзгә-сүз барып кергәннәр. «Инкыйраз»ның әһәмиятен замандашлары да шактый дөрес аңлаганнар. Тукай, мәсәлән, «Кем ул?» исемле шигырендә Г. Исхакыйның башкарган хезмәтләрен санап килә дә болай дип куя:

*Кичән көнләрне уйга алдыран кем,*
*Вә безә «инкыйраз»ы аңдыран кем?*

«Мөридләр каберстанындин бер аваз» дигән шигырендәге моңарчы төшереп калдырыла торган ике юллык та кызыклы:

*Дәрсе гыйбрәт вирде безә «Инкыйраз» нам бер әсәр,*
*Аһ буны язан кеше инсан икәндер, белмәдем.*

Ф. Әмирханның русча язылган автобиографиясендә түбәндәге сүзләр бар: «Бу әсәрдә ялкынлы автор бөтен татар тормышын рәхимсез рәвештә тәнкыйть итә. Ул миңа бик тә көчле тәэсир ясады».

Икенчесе — беренче һәм шул ук вакытта соңгы басманың сыйфаты мәсьәләсе.

Повестьны укыганда укучы күп нокталар белән билгеләнгән урыннарны еш очратыр. Болар цензор сызып ташлаган кисәкләрне аңлата. Моның шулай икәнен без тагын Гаязның русча язылган автобиографиясеннән беләбез. Ул анда цензураның әсәрдән күп урыннарны чыгарып ташлаганы, моңа җен ачулары чыкканы, авырып, түшәктә яткан чагында хәтта, Петербургка барып, мәгълүм Смирновны үтерү уе белән янганлыгын яза.

Соң нинди урыннарны сызып ташлаган цензура? Әсәрнең кульъязмасы сакланмаганга күрә, бу сорауга төгәл җавап биреп булмый. Шулай да чамаларга мөмкин. Укучы күрер: ике йөз елдан соң татар милләтенең юкка чыгуын яки чыгачагын автор шактый күп сәбәпләр белән аңлата. Әмма сәер хәл: шулар арасында милли-колониаль изү, шуның бер күренеше булган христианлаштыру, ассимиляцияләү кебек сәбәпләр юк. Ямашев һәм Колах-

мәтов белән берлектә Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлап, революцион-демократик позициягә баскан Г. Исхакыйның бу мәсьәләне белмәве һәм «Инкыйраз»да күтәрмәве мөмкин түгел. Менә ни өчен без кыскартылган урыннар, һәрхәлдә, аларның күпчелеге, һичшиксез, самодержавиенең милли-колониаль политикасы белән тегеләйме-болаймы бәйле дип әйтә алабыз. Хәер, әсәрдә сүз сөрешеннән дә моны чамаларга мөмкин.

«Сөннәтче бабай» повесте 1911 елның 23 январь һәм 7 май аралыгында Истанбулда язылган. Беренче кат сигез томлык әсәрләр җыелмасының икенче томында «Шәкерт абый» хикәясе белән берлектә басылып чыккан (1912). Моннан соң кабат басылганлыгы күренми.

Повесть турында җентекләп сөйләргә хаҗәт юк. Шулай да, хөрмәтле укучы бер нәрсәгә игътибар итсә, зарар булмас иде.

«Сөннәтче бабай»— чын мәгънәсендә милли һәм халыкчан әсәр. Ул татар авылының үзенә генә хас фикерләү рәвешен, хис-тойгы һәм гореф-гадәтләрен тирәнтен белеп язылган. Сөннәтче бабай — татар авылында гына туарга мөмкин булган тип.

Шул ук вакытта повестьта Гоголь рухын, Гоголь чалымнарын, Гоголь принципларын күрми мөмкин түгел. «Кечкенә» кешенең драмасын зур итеп күтәрү, тормышның «вактәяк» ләреннән тирән мәгънә чыгару, күз яше аралаш көлү — болар, һичшиксез, «натураль мәктәп» башлыгыннан килә. Әсәрнең гаять көчле язылган финалына гына игътибар итегез.

Бер җан, бер тән булып яшәгән карчыгы үлеп киткәч, Сөннәтче бабай өйләнергә карар итә, ләкин бәхетсезлегенә, уңмаган, ялкау, затсыз карчыкка туры килеп, тормышы чыгырыннан чыга. Әмма ул түзә, өенең сыер абзарына әверелүенә дә, өс-башының катып бетүенә дә, карчык пешергән ашларның авызга алгысыз булуына да түзә, хатын булучыга каты бәрелми. Ләкин сөннәт пәкесе белән тегенең бәрәңге әрчеп утырганын күргәч, түзми, тилереп китә, кычкыра, елый, карчыкны өеннән куа башлый. Шактый дулаганнан соң һуштан язып егыла, ә берничә көннән соң Сөннәтче бабайны алдан үзе казып куйган каберенә күмеп кайталар...

Соң нинди изге пәке булды бу? Берәр нәрсәнең билге-символы түгелме ул? Сөннәтче бабайның җаннан артык күреп саклый торган шәҗәрәсе нәрсә аңлата? Гап-гади кешенең гап-гади трагикомедиясенә нинди олы мәгънә яшеренгән? Бу сорауларга хөрмәтле укучы, әсәрне укып, әйдә, үзе җавап эзләсен.

**Ибраһим НУРУЛЛИН.**

**Гаяз Исхакый**

# СӨННӘТЧЕ БАБАЙ

**хикәя**



Авылның картлары, ир уртасылары, яшьләре — һәммәсе дә үзләре белә башлаганнан бирле аны «Сөннәтче бабай» дип таныйлар. «Сөннәтче бабай» дип йөриләр иде. Угыллары, кызлары җиткән карчыклар да, яңа төшкән яшь киленчәкләр дә аны «Сөннәтче бабай» итеп таныганнар, алар да бу көнгә яшь киленләр кеби, урак өстендә кызу-кызу урак урганда да, көз көннәрендә, төшмәенчә башны әйләндерә торган гөбе язганда да, бәйрәм алдында ашыга-ашыга өй юганда да, егълаган угылларын туктатыр өчен, «Сөннәтче бабай килә!» дип куркытканнар иде.

Аның яшен белгән кеше юк иде. Яше күпме, дип уйлаган кеше дә юк иде. Һәм дә, әллә ничек, бөтен авыл халкы шул Сөннәтче бабай берлән яше арасында мөнәсәбәт барлыгын уйлый алмый иде. «Сөннәтче бабай сиксән яшендә, туксан яшендә»,— дигән сүз аларның колагына ят килер кеби. «Ата таш, ана таш»,— дигән шикелле мөнәсәбәт булыр кеби тоела иде.

«Сөннәтче бабай» — Сөннәтче бабай иде. Ул авылның өч сайлануында да староста булып торып, хаҗга барып кайткан Аш-аяк Шәрәфи бабайның да «Сөннәтче бабае» булган кеби, авыл хәзрәтенең, тимер юллар, пароходлар берлән үтеп барып, Казан шәһәрендә укый торган мәхдүменең дә Сөннәтче бабасы иде. Авылның бу ел төшкән яшь киленнәренә дә ялгыз калып уйлап ятканда, яисә эштән соң каенанасыннан яшеренеп иске чүпрәкләрдән искеләр хәзерләгәндә дә, углы булуыны уйлап бетерүе берлән, Сөннәтче бабай хәтеренә төшә, углы булуы берлән сөннәт ясавы Сөннәтче бабайдан һич аерылмый иде.

Кечкенә кызлар курчак уйнаганда курчакларның туе иттереп, кодалар, кодагыйлар чакырып маташканда, иске чүпрәкләрдән ямьсез генә иттереп, һәрвакыт бер курчакны «Сөннәтче бабай» атыйлар, сөннәт туйлары ясап, аның исеменнән әллә никадәр сүзләр сөйләнәләр, ир балаларны еглаттыралар иде. Бөтен авыл сөннәт дигән сүзне ишеткәндә, шул картаеп, искереп беткән Сөннәтче бабайны хәтеренә китерә, сөннәт туе хакында сүз ишетсә, аның кайда булганын да уйламаенча, мотлакан[1] «Сөннәтче бабай булган»,— дип утыртып куя иде.

Аның яше югалган кеби, исеме дә югалган иде. Көлдергечрәк картлар, эшләр бетеп кырдан кергәч, җомга көннәрне, кояш җылысында җыелышып, сөйләшеп ятканда: «Сөннәтче бабайның метрикәсен кәҗә ашаган икән. Аның исеме югалгач, Газраил фәрештә аны оныткан икән дә, шуның өчен авылда ике зур холерада ул исән калган икән»,— диләр иде. Газраилнең «онытуы» сүзе дөрес булса булыр, ләкин Сөннәтче бабайның исеме югалган икән хәбәре ялган иде.

1. Мотлакан — һичшиксез.

Аның исеме бар иде. Исеме генә түгел, аның бөтен нәселен язган, аның бабаларын, бабаларының бабаларын язган «сөннәтче шәҗәрәсе» бар иде. Ул шул шәҗәрәсе белән, үзенең сөннәт кисәргә мирас тарикы барлыгын читтән килгән һәрбер шарлатан алдында исбат итә алырлык булса да, авыл халкы аның үткен чалгы пәкесе берлән сап-сары агач черегенә шәҗәрәсеннән дә нык ышанганга, ул шәҗәрәнең кирәге дә булганы юк иде.

Авылның кырыенда сан буенча икенче исәпләнә торган Сөннәтче бабайның йорты да, дөресен әйткәндә, өе дә, үзе кеби, бөтен авылның өйләреннән аерым иде. Ул, авылның сатучысы Әхмәдинең кызылга буяган өенә охшамаган кеби, авылның иң фәкыйрьләреннән хисаплана торган капка каравылчысы Садрыйныкына да охшамаган иде. Ул Сөннәтче бабайның өе иде. Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде. Авыл тарихын белми торган вакытта такта берлән ябылган түбәсе, вакыт үтә-үтә, каралып бетеп, анда-монда кәкрәеп торулары берлән Сөннәтче бабайның битенә бөтенләй охшый иде. Түбәсенең кырыйларына солы, бодай, алабута катышыннан үскән үләннәр дә, берсе анда таба, берсе монда таба карап, Сөннәтче бабайның рәтләп таралмаган сакалын хәтергә китерә иде. Өйнең сулга да, уңга да таба кәкрәйгән диварлары Сөннәтче бабайның төрле тарафка таба бөкрәйгән аркасын искә төшерә иде. Аның пыяласыннан күп рамлы тәрәзәләре үзенең яшәргән[1] пыялалары берлән бабайның һәрвакыт яшьле күзләренә бик охшый иде. Өйнең берәм-берәм агачларын таратудан саклап тора торган, өстән сылаган күк балчык та Сөннәтче бабайның да шул картайган тәнен бер кеше иттереп җыеп йөрту вазифасын кыйла торган киемнәренә төсенисе берлән дә бик охшаган иде. Монда һәр нәрсә Сөннәтче бабайга охшаган, Сөннәтче бабай үзе дә һәр нәрсәгә охшаган иде. Кем белсен, бәлки Сөннәтче бабай, чыннан да, шул өйнең балчыгы белән бер балчыктан яратылгандыр. «Мал иясенә охшамаса, харам була»,— диләр. Аның дөреслеген белмим, ләкин мал иясенә охшамаса, мал берлән иясе арасында аерма бетә. Менә монда да кай җирдә Сөннәтче бабайның үзе башлануы, кай җирдә аның әйберенең чиге булуы әллә кайчан хәтерләрдән себерелгән иде; әллә кайчан бу чик баганалары авып беткән иде. Дөресе генә, Сөннәтче бабай шул Сөннәтче бабай үзе генә түгел иде: ул шул киемнәре берлән, шул буе берлән, шул үткен чалгы пәкесе берлән, шул әллә ничә кат кәгазьгә төргән черегe берлән бергә Сөннәтче бабай иде. Бөтен авыл халкы шуны шулай уйлый, бөтен авыл халкы шуның шулай икәнлегенә ышана иде. Шуның өчен авылдагы ике зур утта да Сөннәтче бабайның йорты янмый калуын да Сөннәтче бабайның аерым бер эш иттереп сөйләнмиләр. Сөннәтче бабайның өе янмый калды, аны ут онытты, фәлән дә димиләр иде. «Газраил дәфтәреннән югалды»га шуларның һәммәсен бергә кертәләр иде.

Сөннәтче бабайның Сөннәтче бабайлыгы моның берлән генә тәмам булмый иде. Аның тагын берничә кисәге, кәбестә теле белән сөйләсәң, тагын берничә яфрагы бар иде. Аның өенең алдында юкагачлар берлән бастырып тоттырган кечкенә бакчасы да, бер карагандa, һаваланган дай, күкрәген чыгарып, кукыраеп тора кеби, бер карагандa, картайганнан арып билен тота алмыйча, бөкрәеп торган кеби күренгән миләш агачы да бар иде. Күзгә таба аның кып-кызыл миләш сабаклары кызыл ахак кебек салынып, сөялеп, яшь кызларның муенын, кулын, колагын бизәкли торган төймәләр, алкалар кебек, Сөннәтче бабайның өен бизи иде. Аның искелектән туеп беткән йөзенә көләчлек биреп, битенә кызыл йөгертә иде. Сөннәтче бабай шул үзе берлән картайган миләш агачының телен белгән

1. Яшәргән — яшелләнгән.

кебек, һәр көн иртә берлән чыгып, агачка таба карый, һәр көнне аның белән сөйләшергә тотына:

— Нихәл, суык булмадымы? Кырау төшмәдеме? Чәчәкләреңне өшетмәдеме? — дип сорый иде. Миләш тә, шуны гына көткән кебек, офицер алдында басып тора торган солдатның офицерыннан сәламенә каршы кычкырып: «Исәнлегеңне телим!» — дигән кебек, әллә кайдан килгән җил белән шаулап җавап бирә. Сөннәтче бабай да аның сыгылып-сыгылып килә торган ботакларын, чәчәкләрен тотып карап, туңмаганына, өшемәгәненә ышанып, агачның тамырларын карарга, «Җире корымадымы? Су кирәкмиме?» — дип, туфракны кулы белән изәргә тотына иде. Ул күп вакыт су сибәргәме, юкмы дип, уйлап тора-тора да, «майдан ботка бозылмас», дип чиләкне күтәреп, артындагы инешкә төшә дә, анда үзе ясаган басмадан су алып менеп, миләшенең төбенә сибә иде. Аннан соң салыныбрак төшкән ботакларны бер-бер җеп белән бәйләп куя, иелгәнрәкләрен агачлар белән терәтә, миләш вакытында урамга якынракларын бакчага таба борып куя иде. Ләкин монысы кирәкмәс бер эш кенә, Сөннәтче бабайның картлыгыннан килгән артык бер саклану гына иде. Аның миләшләреерактан караганда малайларны никадәр кызыктырса да, урамның теге ягыннан үтеп барганда ук, үзенең әчеле-төчеле тәме белән никадәр аларның авызыннан су агызса да, килеп басып алырга берсенең дә көче җитми иде. Түбән оч, югары оч бакчаларында кыярга рәхәт йөзе күрсәтми торган Гата малае Касыйм да, юлаучы Камалинең күршеләрендә йомыркаларына көн күрсәтми торган ирдәүкә кызы Мәрфуга да шул миләшләргә таба тугры килә алмый иде. Сөннәтче бабай дигән сүз аларның күңеленә әллә нинди бер курку төшерә, аларның күз алдына шул Сөннәтче бабайны, карт Сөннәтче бабайны пәкесе, череге белән китереп бастыра; аның авызыннан Сөннәтче бабай һич сөйләми торган бер тавышта: «Кисеп алырмын»,— дигән сүзне ишеттерә иде. Шул «Кисеп алырмын»нан Касыйм куркып кача, никадәр ирдәүкә булса да, киселәчәк артык бернәрсәсе дә булмаган Мәрфуга да якын килми иде.

Миләштән башка да бабайның байлыгы юк түгел иде: аның өй артында канау белән әйләндереп алган, суга кадәр сузылган йорты[1] бар иде. Читтән караганда, никадәр кечкенә төсле күренсә дә, бу йортның бер почмагы уҗым кыры, бер почмагы сабан ашлыгы кыры, суга якын җире печәнлеккә бүленгәнгә, башка — урта җире, шалкан, кыяр, кәбестә, чөгендер, борчак, бәрәңге түтәлләрен дә эченә ала иде. Шул ферма, урам ягыннан кечкенә генә җил капка берлән авылга чыккан кеби, пөхтә генә такта ишек тар гына, матур гына басма белән суга таба да сузылган иде. Шул су ягындагы ишектән Сөннәтче бабай түтәлләрен, ашлыгын сугара, урам ягындагы капкадан шул ашлыкларны чит дөньяга чыгара, географиячә әйтсәк, чит мәмләкәтләргә җибәрә иде. Җәйнең һәрвакытында аның шул бакчасы һәрвакыт ямь-яшел тора, илдәге корылык аның арышын саргайтмый, җәйге эсселек аның карабодаен көйдерми иде. Һәр елны кояшка карап тора торган каш[2] җирендә аның бодае уңа, уйсу җиргә чәчкән аның солысы кара туткыллы булып, гөрләп үсә, карабодае, миләш кебек, сабаклары белән тулы була; арышы, сары ука кебек, башын күтәрә алмаенча сузылып ята. Аның кыяры, шалканы, кишере хакында сөйләмә дә инде — алар бөтен авылның авызыннан суын агыза, бөтен авылны кызыктыра иде.

Сөннәтче бабайның кош-корты да юк түгел иде. Ләкин болары, ни өчендер Сөннәтче бабайныкы дип сөйләнмиенчә, аның карчыгы

1. Йорт (диал.) — ишегалды. 2. Каш (диал.) — калкулык, кашлак. 3. Җилем (диал.) — җилен.

Гөлйөзем әбинең исеме берлән йөри иде. Мәсәлән, аның бүрекле тавыгы, кызыл әтәче — «Гөлйөзем әби тавыгы», «Гөлйөзем әби әтәче»,— дип йөртелә; аның зур җилемле, һавалы мөгезле, көтүнең иң артыннан килә торган кәҗәсе дә: «Гөлйөзем әби кәҗәсе»,— дип сөйләнә иде.

Бу тавыклар, әтәчләр, кәҗәләр — һәммәсе дә «Сөннәтче бабай» кебек карт булсалар да, Сөннәтче бабай күрше картларыннан аерылган кеби, алар да күрше тавыкларыннан, әтәчләреннән аерылсалар да, һәммәсе дә холыклары, табигатьләре берлән Сөннәтче бабайга бик охшасалар да, күрше-колан, ни өчендер, бу мәсьәләдә Сөннәтче бабайның хакын кабул итмәенчә, Гөлйөзем әбигә нисбәт биргәннәр иде. Кем белсен, өй, бакча, миләш Сөннәтче бабайга никадәр охшаса, тавык, әтәч, кәҗә, бәлки, Гөлйөзем әбигә шулкадәр охшагандыр. Шулай дигәч тә, сез Гөлйөзем әби берлән Сөннәтче бабай арасында аерма бар иде, берсе кара туткыллы, берсе сарырак; берсе каты табигатьле, берсе йомшак, берсе матур, берсе ямьсез иде дип, бер хата фикер чыгармагыз. Боларның төсләрендә, йөзләрендә, кыланышларында, табигатьләрендә дә һич аерма юк иде. Дөресе гена, болар хәзер ике кеше түгел, икедән кушып ясалган бер кеше иде. Боларның берсен күреп, икенчесен күрмәгән кеше, иттифакый[1], күрмәгәнен икенче авылда яисә кара урманның ялтыраган аланында җиләк җыйганда күрсә, мотлакан, моның кем икәнлеген таныячак иде.

Боларның төсләре генә түгел, уйлары да берләшеп беткән иде. Мәсәлән, Сөннәтче бабай: «Карчык, түтәлләргә сибәргә вакыт түгелме?..» — диярга өлгерә алмый, Гөлйөзем әби чиләкне күтәреп чыга башлый иде. Көз җитеп, сөннәт туйлары итә башларга вакыт җитеп, Гөлйөзем әби: «Карт, сөннәтләр җитә...» — диярга өлгерми, Сөннәтче бабай тәһарәт төзеп, чалгы пәкесен кайрарга тотына иде. Алай булса да, болар үзләре бер-берсен аералар иде. Гөлйөзем әби бервакытта да Сөннәтче бабайга «карчык» дип дәшми, бабай да онытып җибәреп, карчыгына «картым» дип эндәшми иде.

Ул гына түгел, болар арасында эштә дә аерма бар иде: кәҗә саву, тавыклар ашату, йомырка җыю, самавыр кую Гөлйөзем әбинең эше булган кеби, миләшкә су сибү, йортны себерү, канауларны төзәтү дә Сөннәтче бабайның гына эше иде. Оныткансын икән әле, өй җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде. Ул һәркөнне әллә ничә мәртәбә идәнне себерә, һәр атна кич ком берлән сап-сары итеп самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларын ямар өчен салган балчык өстеннән акбур берлән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде.

Өйләрендә әллә никадәр җиһазлар булмаса да, җәмәгатьләре шул карт-карчык берлән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән бушамый иде, ул кайвакытлар мич ягып күмәч сала, кыстыбый пешерә, бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде. Өйдәге бөтен әйберләр, җиһазларда һич артык нәрсә булмаса да, болар арасында берсе дә кыйммәтле, кыйммәтсезлек белән аерылмаса да, өч нәрсә боларга һич охшамаган, бөтенләй башка дәрәҗәдә иде: аның берсе Сөннәтче бабайның мирас юлы берлән сөннәтчелеккә хакы барлыгын исбат итә торган шәҗәрәсе, икенчесе сөннәт кисә торган чалгы пәкесе, өченчесе сөннәткә сибә торган, шешәгә тутырган сары черега иде. Боларның өчесе дә өйнең иң кадерле җирендә, Гөлйөзем әбинең кыз чакларыннан калган һәфтияге[2], бөтиләре[3] саклана торган түрдәге шүрлектә, кечкенә сандыкта тора иде. Боларның һичберсе дә гади көндә алынмый, һичберсе

---

1. Иттифакый — очраклы рәвештә. 2. Һәфтияк — Коръәннең җидедән бер өлеше. 3. Бөти — бәхетсезлектән саклаучы догалык.

андый-мондый эшкә тотылмый иде. Хосусан, шәҗәрәнең кыйммәте әби белән бабайның алдында бик зур иде. Ул һәрвакыт карындыкка төрелгән көенчә берничә кат кәгазьгә сарылып, чүпрәкләр берлән бәйләнеп куелган иде. Аның эчендә ни язылганын Сөннәтче бабай укый белмәсә дә, шул кәгазьнең бик зур кәгазь икәнен белә, әллә нидә бер зур кунак-фәләнгә күрсәтергә тугры килсә, ул шәҗәрәнең бер җирендәге исемгә бармагы берлән төртеп:

— Менә бусы — Сәлман Фарси, разыйя аллаһы ганһе[1], менә монысы мин,— дия иде. Ул шул сүзне әйткәндә бераз һаваланып та киткән кеби була, теге кешегә гади кеше берлән эш итмәгәненә, Сәлман Фарси[2] нәселеннән бер кеше берлән эш иткәнене белдерер өчен кеби:

— Сәлман Фарси хәзрәтләре безнең бабамыз булган,— дип куя иде. Андан соң ул шәҗәрәнең тарихын сөйләргә тотына иде. Сөйләгәндә, гади сүз сөйләмәгәнене белгәнгә, сүз араларында салаватлар әйтә, «разыйиллаһи гыйна, рәхмәтуллаһы галәйһи»ләр берлә бизәкли иде.

Бабай ул шәҗәрәне этисеннән мирас тарикынча алган иде. Шундан соң аңар үзенең исемен яздырыр өчен мәрхүм, алла рәхмәтендә булсын, «Түнтәр (Гали ишан) хәзрәт»кә барган иде.

Сөннәтче бабай шул вакыйганы менә ничек сөйли иде:

— Кышның көне иде. Әти мәрхүм, алла рәхмәт итсен, вафат булды. Үләр алдыннан мин берничә ел әти берлән читкә сөннәткә чыгып йөрсәм дә, иҗазәт[3] ала алмаган иде. Менә бер көнне тегермәндән кайтсам, әти: «Углым, хәзрәтне алып кил, хәлем начар»,— диде. Мин хәзрәткә киттем. Хәзрәт мәрхүм, алла рәхмәтендә булсын, ул вакытта Кәбир хәзрәт иде. «Хәзрәт бабай, әти авырый»,— дигәч, «машалла!» диде дә, мәдрәсәдән чыгып, чанама утырды. Өйдә этине телсез таптык. Хәзрәт йасин укырга тотынды. Әти һаман телгә килмәде. Йасиннан соң хәл җыйган кеби булды. Бик авырлык берлән кулын күтәреп, шүрлектәге сандыкны күрсәтте. Аннан ары күзен миңа борды. Хәзрәт:

— Сиңа сөннәтче бабай булырга иҗазәт бирә,— диде. Хәзрәт шул сүзне әйтеп өлгерә алмады, әти тагы: «Аллаһ!» — дип әйтеп, җан бирде. Алла рәхмәт итсен, бик яхшы күмдек. Гүр садакасына бер зур сарык бирдем, фидиясенә[4], өй тумасы кашка кырыкмыш иде, шуны бирдем; кырыгына кабер өстенә йөрергә алты тәкәдән теккән тунын бирдем. Менә көн үтте, кыш үтте, җәй булды, көз булды — сөннәт вакыты җитте. Мин тәһарәт алып, әтинең пәкесен алып, сөннәткә чыктым. Малайлар минем арттан йөри башладылар. Алар: «Корбан-колый сөннәтче бабай»,— булган дип, көлә башладылар. Ул вакытта әле яшь идем. Бер өйгә кердем. Үзем берлән үскән Гадиләнең өе икән. Угылы сөннәтлек булган, яхшы каршы алдылар, белен берлән чәй эчерделәр, ләкин: «Бер ел әле сөннәткә бирмәскә телибез, балабыз үссен дип уйлыйбыз»,— диделәр. Икенче җирдә тагы шулай. Мин бөтен авылдан бер малай да таба алмадым. Үткән ел бай ел булганга, сөннәтлек малай күп иде. Мин уйладым да, яңа тун киеп, кияү булып кергән казакины киеп, мәрхүм Кәбир хәзрәткә киттем. Хәзрәт мине өенә алып керде. Кергәч тә, тулы ният[5] бирдем. Хәзрәт, дога кылып, сорашырга тотынды. Хәзрәткә бәйнә-бәйнә хәсрәтемне сөйләдем. Хәзрәт уйлап-уйлап торды да:

— Син, Корбанколый, Түнтәр Гали ишанга бар, андан иҗазәт ал,— диде.

---

1. Разыйя аллаһы ганһе — алла аңардан рази булсын. 2. Сәлман эл-Фарси — Мөхәммәт пәйгамбәрнең сәхабәләреннән. Фарсы халкыннан булып, сугыш гыйлемен яхшы белүче саналган. 3. Иҗазәт — рөхсәт. 4. Фидия — үлгән кешенең гөнаһын йолып алу өчен бирелгән садака; 5. Ният — ният садакасы.

— Хәзрәт, ул кая соң? — дидем.

Хәзрәт: «Фәлән җирдә, фәлән җирдә»,— дип сөйләп бирде.

Шул ара да булмады, авылга әллә кайдан, сөннәтче дип, бер карт килде. Миңа, балабыз кечкенә, дигән бөтен кешеләр сөннәткә бирә башладылар. Атам мирасының әллә кемнәргә китүенә ачуым килде. Атны җигеп, хәзрәткә дип бер савыт кәрәзле бал алып, юлга чыктым. Унике көн бардым. Мәнә хәзрәтнең авылына барып җиттем. Иртә намазга кердем. Ул халык, ул халык! Сакаллы шәкертләр берлән мәчет тулган. Намаз бетте. Хәзрәтнең намаздан чыкканын көтеп торып, күрештем. Хәзрәткә серне аңлаттым, үзебезнең хәзрәттән алган хатны бирдем.

— Өйлә намазына тәһарәт төзеп кил,— диде. Килдем. Дерелдәп кенә намаз укыдым. Коръәннән соң хәзрәт мине чакырды, иманны сорады, җавап бирдем. Намазны сорады, җавап бирдем. Шәҗәрәне сорады, әтинең, бабайның исемен әйттем. Шуннан соң хәзрәт кул күтәреп дога кылды. Шундагы бер зур шәкерткә:

— Шуның шәҗәрәсен күчереп, исемен яз,— диде. Шатлыгымнан язган шәкерткә бер талир тәңкә бирдем. Унике көн барган җиремне уналты көн кайттым. «Мәнә җиңел генә түгел, шулай алдым»,— ди иде дә шәҗәрәне күрсәтә иде. Шәҗәрәне укый белгән кеше башыннан әллә никадәр аятьләр, салаватлар укыганның соңында «Корбанколый бине Уразколый, Уразколый бине Миңлеколый, Миңлеколый бине Габдулла, Габдулла бине Мөхәммәтсалих, Мөхәммәтсалих бине менла Морад баба (*), менла Морад баба бине хан Гәрәй, хан Гәрәй бине хәзрәт Аксак Тимер, Аксак Тимер бине хәзрәт Гали, хәзрәт Гали бине Сәетбаттал, Сәетбаттал бине хәзрәт Хәнәфи, хәзрәт Хәнәфи бине Мөхәммәт, Мөхәммәт бине Габдессәлам, Габдессәлам бине Мамай, Мамай бине ибн Габбас, ибн Габбас бине Габделмоталлап, Габделмоталлап бине Һашим, Һашим бине Хәсән, Хәсән бине хәзрәт Билал, хәзрәт Билал бине Сәлман Фарси разийя аллаһы ганһе» дип бетергән бер шәҗәрә күрә иде. Укучы Сәлман Фарси бабай арасындагы шул мең дә өч йөз елның шул кадәр тиз кичеп, биш-алты буында Сәлман Фарсига барып җитүендә дә, шунда кергән тарихи исемнәрнең тугрылыгында да шөбһәләнми иде.

Пәке, шәҗәрәгә караганда шәфкатьсезрәк булса да, ул бик мөкаддәс иде. Бабай аны да салаватсыз тотмый, аны да күрсәткәндә атасыннан калганын сөйләп кенә калмаенча, аның да шул буыннардан үтеп, хәзрәт Сәлман Фарсидан килгәненә кадәр барып җитә, аңар хәзрәте рәсүлнең үз кулы белән бирелүен дә әйтеп куя иде. Пәкене караган кешенең күңеленә: «Ул вакытта чалгы бар иде микәнни»,— дигән фикер килми, бабайның башына да андый шөбһә килми иде. Замана бозылмаган иде. Халык бер-берсенә ышана, язылган сүзләргә Коръән кеби игътикад[1] итә иде.

---

Көннәр кыскара башлап, кичләр суыгая башлагач, киленнәр киндер әвернәләрен чормадан төшереп кора башлагач, кызлар, киергеләрен киереп, балтыр чүпрәкләре, челтәрле якалар чигә башлагач, Сөннәтче бабайларда да хәл үзгәрә, аларның өйләре дә әллә нинди зур эшкә хәзерләнә башлый иде. Шул көн якынлашуы сизелә

(+) Менла Морад бабай — Кырым ханнары Гәрәйнең угылларыннан. Ни сәбәптәндер, Русиянең уртасына күчеп килеп, гыйлем юлында хезмәт иткән. Чистай вә Бөгелмә өязләрендә зур исеме бар. Шонталы авылында Чистай өязендә күмелгән +.

Бу — автор искәрмәсе. Ул югарыдагы шәҗәрәнең Әмирхановлар шәҗәрәсенә пародия икәнлеген сиздерер өчен бирелгән. Фатих Әмирханнар шәҗәрәсе кыскача болай: Гәрәй мирза-Җәлмәт-Әхмәт-Кадермәт-Морад хәзрәт-Исмәгыйль-Габделмәннан-Әмирхан-Хөсәен-Зариф-Фатих.

1. Игътикад — ышану; 2. Әвернә — җайланма, станок.

башлагач та. Гөлйөзем әби керләр чайкый, өенең идәннәрен юа, самавырын тагы көзге кебек иттереп ачып куя, шул көнгә дип, җәйли җыйган каймагыннан гөбе яза иде. Менә көтәр көн килеп җитә, көннәр салкынланып җитеп, чебеннәр, күбәләкләр үлеп бетә иде. Сөннәтче бабай, иртә намазга иртә үк барып утырып, ниятләрен укый, намаз беткәч, ишрак[1] намазын да бетереп, хәзрәткә кереп: «Безгә фатиха биреп чыкмассыз микән? Карчык самавыр куеп торырмын дип әйт дигән иде»,— дип, хәзрәтне ашка чакыра; хәзрәт тә, чакырыласын аллә кайдан белеп торганга, вәгъдә бирә. Сөннәтче бабай сүз беткәч кенә: «Хәзрәт, остазбикә берлән»,— дип, тагы ныгытып әйтеп, «Алай булса сез, хәзрәт, тәһарәт яңартыгыз да, барыгыз, мин карчыктан кайтып сөенче алыйм»,— дип, кызы-кызу кайтып китә, кайнаган самавыр, яккан мич берлән көтә торган карчыгына хәбәрне сөйләп, үзе киенергә тотына иде. Ул бу көнне үзе кияү булып кергән вакытында бикәч бүләге иттереп бирелгән, чиккән якалы күлмәген, аның өстеннән бу хәзрәттән элгәрееге хәзрәт биргән кыска җиңле, алды теткәләнгән булса да, арты өр-яңа тора торган әдрәс казакиен, башына хәзрәтнең кияүгә чыккан кызының углын сөннәткә утырткач биргән чигелгән кәләпүшен кия иде. Ул шул киемдә матураеп, шул көндә яшәреп китә иде. Ул шул көенчә хәзрәтләрне көтәргә капка төбенә чыга, күзен кытыклый торган көзге кояшның йодәтүеннән сакланыр өчен күз өстенә кулын куеп, хәзрәтләргә таба карарга тотына иде. Хәзрәтләр капкадан чыгу берлән ул: «Карчык, карчык!» — дип, Гөлйөзем әбигә кычкыра, Гөлйөзем әби дә мичтәге коймагын алга тартып, самавырына тагы бер күмер салып, каршы чыга иде. Хәзрәтнең сәламенә каршы Сөннәтче бабай сәламне алгач та, Гөлйөзем әби: «Әй рәхмәт, хәзрәтем, остазбикәне алып килә! Кил, остазбикәм!» — дип, остазбикәсен аркасыннан кага, «Әй канатым, рәхмәт! Олуг башыңны кече итеп килүең өчен аллаһы тәгала җиде оҗмахның ишеген ачык кылсын! Безнең ярлы йортыбызга аяк баскан өчен аллаһы тәгалә хәзрәтләре алтын-көмештән сарайлар бирсен!» — дия иде. Абыстай да, хәзрәт тә: «Амин!» — дип, өйгә керәләр иде. Гадәтнең тышында, абыстай, Сөннәтче бабайдан качмыйча, хәзрәт берлән бергә утыра иде, шул гадәткә, шәригатькә сыймый торган эшне тәэвил[2] итәр өчен, хәзрәт догадан соң да:

— Әййү, Сөннәтче бабай, гадәтем остазбикәне алып йөрү булмаса да, Гөлйөзем әби күңеле өчен алып килдем. Сездән качмаса да, гаепләмәгез инде,— дия иде. Шул сүзне ул утыз елдан бирле әйткән кебек, Гөлйөзем әби дә шул сүзгә каршы:

— Ай рәхмәт, хәзрәтем! Ай рәхмәт! Бөтен илдән аерып, безне үз итүегезгә рәхмәт! Сәлман Фарси хәзрәт шәфәгатьчегез[3] булсын!— дия иде. Шул «Сәлман Фарси» дигән сүзне әйткәндә Сөннәтче бабай тагы бераз үсеп киткән кеби була, аның күзенә нур керә, аның йөзе тагы яшәрә төшә иде. Хәзрәт әчә торган чәйдән бүләк итеп китергән чирек чәйне Сөннәтче бабайга: «Үлгән углым Габдрахман өлеше»,— дип суза, абыстай да Гөлйөзем әбигә: «Үлгән кызым өлеше»,— дип, чиккән күкрәкне[4] төртә иде. Тагы дога башлана. Гөлйөзем әби:

— Аллаһы тәгалә сезгә оҗмах хөлләләре кидерсен, кыямәт көнне йөзегезне ак кылсын! — дип, дога кыла иде дә чәй мәҗлесе башлана иде. Гөлйөзем әбинең мичендә пәрәмәчләр, коймаклар кызу-кызу четерди башлый иде. Хәзрәт тә, абыстай да, кыстатмыйча әчәләр, ашыйлар, тәмле сүзгә кереп китеп, чынаякны санарга онытalar, самавырда су беткәч кенә: «Туйдык, туйдык инде»,— дип тарсынсалар да, Гөлйөзем әби тагын кайнаган су берлән самавырны

1. Ишрак намазы — иртән кояш күтәрелгәч укыла торган намаз. 2. Тәэвил — аңлату, ачыклау; 3. Шәфәгатьче — арадашчы, аклаучы. 4. Күкрәк — күлмәк астыннан күкрәккә киеп калдырыла торган чигүле материя.

яңарткач, тагы эчәләр иде. Өченче мәртәбә самавырны яңартырга хәзрәт тә каршы килә иде, остазбикә дә разый булмый иде. Гөлйөзем әби: «Минем, хәзрәткәем, эчәсем килә, мин дә сезнең мәҗлесегез берлән шәриф («мөшәррәф»[1] дигән сүзне шулай әйтә иде) буласым килә».— дигәч, хәзрәт тә дәшми, остазбикә дә разый була; тагы самавыр килә, тагы Гөлйөзем әби берлән бергә чәй эчелә, тагын су бетерелә иде. Дүртенче самавырга хәзрәт кенә түгел, абыстай да каршы килә, Гөлйөзем әби дә, тиресләнмәенчә, чәй урынын җыеп ала иде дә, Сөннәтче бабай: «Хәзрәт, әрвахлар өчен...» — дип, сүзен әйтеп бетерә алмаенча туктый иде. Хәзрәт тә шундый вакытта укыла торган кыска аятьләрне укымыйча, «инна фәтәхна»ны бөтенләй укып чыга, бик озын иттереп, гарәпчә, фарсы катыштырып, дога кыла иде. Сөннәтче бабай, хәзрәт дога кылып беткәч тә, әллә кайчан хәзерләп куйган, мич буендагы зур биш тиенне хәзрәтнең кулына, биш тиен дип язылса да, хәзер бер тиен ярымга йөри торган зур акчаны да остазбикәнең кулына баса иде. Акчалар кызган булса да, хәзрәт тә, абыстай да кулыннан төшермичә дога кылалар иде. Догадан соң хәзрәт, гадәте буенча: «Аллаһы тәгалә озын гомер бирсен, дәүләтегезне киң кылсын!» — дияргә өлгерми, Гөлйөзем әби, әллә каян чыгарып, хәзрәткә зур ике тиен, абыстайга бер тиенне төртеп: «Патша хезмәтендә үлгән углым өчен,» — дип, сүзне бетерә иде. Тагы дога башлана иде. Шуның артыннан Гөлйөзем әби: «Гаеп итмәгез инде, сыйлый алмадым»,— дия иде. Хәзрәт: «Бик рәхмәт, бик сыйладың»,— дип тора башлагач, Гөлйөзем әби: «Аш хәзерли алмадым инде, хәзрәт, аз гына шурпам бар, шуны ашап китегез инде»,— дия иде. Шуның артыннан тавык итендә пешкән шурпа китерә иде. Ул бетәргә өлгерә алмый — каз аягы, бүтәкәсеннән пешкән, чыгыр-чыгыр кайнап тора торган шурпалы бәлеш ашьяулыкка куела иде. Шул арада ишегалдына чыгып, Сөннәтче бабай да зур аякларда сосла күтәреп кереп: «Бәлки, хәзрәт, яратырсыз»,— дип, хәзрәтләр өчен ясаган сосласын суза иде. Бәлеш ашала, сосла эчелә иде. Бәлешнең эче бетеп, төбе киселергә җиткәч, хәзрәт тә, абыстай да: «Кисмә, кисмә!» — дисәләр дә, кискәч, төбеннән дә берәр кисәк ашыйлар иде. Ул бетеп өлгерми, Гөлйөзем әби: «Хәзрәт, менә безгә доганы аз кыласың, быел бер үрдәгем качып салды, үрдәкләрем аз булды»,— дип, пешкән үрдәк чыгара иде. Хәзрәт: «Сез безне бигрәк сыйладыгыз»,— дия, абыстай да: «Туйдык инде, кирәкмәс, бозма»,— дия иде. Ләкин бозылгачтан үрдәктән дә кечкенә мәхдүмгә дип алып куелган боттан башка, бер нәрсә дә калмый иде. Үрдәктән соң Гөлйөзем әби: «Бер нәрсә дә хәзерли алмадык»,— дип, йомырка бәлеше чыгара иде. Тагы: «Кисмә, кисмә!» — дигән сүзгә карамаенча, ул да киселә, ашалып бетә иде. Шуннан соң Гөлйөзем әби: «Гаепләмәгез инде, хәзрәт»,— дип гозер үтенергә тотына, Сөннәтче бабай да, әллә кая югалып, шактый гына зур карбыз күтәреп керә иде. Хәзрәт, абыстай тагы: «Урыныбыз калмады инде»,— дисәләр дә, ашый башлагач, карбызны мактый-мактый, урын калмаганлыгы онытыла иде. Шуннан соң Гөлйөзем әби, никадәр самавыр китерергә теләсә дә, хәзрәт разый булмый, ул шул арада капка төбенә ашка алырга килгән кешене күрсәтеп: «Остабикә калсын, без, Корбанколый агай берлән бергә китик инде»,— дия иде. Корбанколый дигән сүзне хәзрәт үзенә кан алдырганда гына, мәхдүмгә сөннәт кистергәндә генә әйткәнгә, Сөннәтче бабай тагын кәефләнә, Гөлйөзем әби тагы шатлана иде. Шуннан соң Сөннәтче бабай: «Алай булса, хәзрәт, безгә фатиха бир инде, бу көн баш көн, башламакчы булам»,— дия иде. Хәзрәт тә кулын күтәреп дога кыла иде дә Сөннәтче бабай берлән чыгып китә иде. Гадәттә, абыстай,

1. Мөшәррәф — бәхетле булу. * Коръәннең «Фәтех» исемле 48 сүрәсе әнә шул сүзләр белән башлана. Хәзрәт сүрәне тулысынча яттан укып чыккан була.

Гөлйөзем әби янында калып, тагы бераз чәй эчә, тамагы туйган булса да, калдык-постык пәрәмәчләр, коймаклар, бәлешләрдән тагы бераз авыз итә иде.

Шул көнне өйләдән соң Сөннәтче бабай һаман шул кунакча киеменнән, череген салават әйтеп кәгазьгә төреп, пәкесен күкрәк кесәсенә тыгып, күрше Мифтах малаен янына алып, эшкә чыгып китә иде. Иң әүвәл, хәзрәтнең углы булса, хәзрәткә, аның углы булмаса, мөәзингә, аның да булмаса, илдәге хаҗига, анда да булмаса, намаз карты Гобәй бабайга, анда да булмаса, башка бирәр намазлы-ниязлы картның йортына бара иде. Аталары күтәреп чыгара торган, чыкмас өчен тыпырчына, тырмаша торган зуррак малайларны өйрәтер өчен ул кесәсеннән чыгарып, бер алма бирә, аның берлән сөйләшеп, аңа чыбыркы ишеп бирергә вәгъдә итә иде. Шулай итеп аны ышандырып җиткергәч, аңар: «Кызыл ыштан, тәти ыштан тегәбез, минә үлчик әле»,— дип яткыра да, янындагыларга тотарга кушып, салават әйтеп, «бисмиллаһи, аллаһыәкбәр!» — дип кисеп ала да, акырабакыра торган малайның җәрәхәтенә череген сибеп, чыгарырга куша иде. Шул эшне эшләп беткәч, кулын юып, тагы салават әйтеп, пәкесен, череген куеп, хәзерләнеп торган чәй янына менеп утыра, элгәреге сөннәтләр хакында сөйләп чәй эчә иде. Сөннәт садакасын алып, гадәттәге бер икмәкне якындагы малайга күтәртеп, ул күңел тынычлыгы белән өйгә кайтып китә, бу көнгә шуның берлән эшне туктата иде. Ул шул көнне үзен бөтенләй егетләрчә хис итә, бөтенләй башка кеше булып китә иде. Йокысын да тыныч йоклый, вак-төяк төш тә күрми, күрсә дә, бабаларыннан Сәлман Фарси хәзрәтне яки Сәед-Баттал газине генә күрә иде.

Иртәгесен ул иртүк чыгып китә, көн буе дүрт-биш җирдә сөннәт кисеп, биш-алты икмәк күтәреп кайта иде. Ашлык булган елларда зур авылда шул хезмәт бер-ике атнага бара иде. Шул вакытта Гөлйөзем әбинең өе икмәк берлән, Сөннәтче бабайның кесәсе зур бакыр акча берлән тула иде. Сөннәт беткәч, бабай, хәл белер өчен, тагы әүвәлге йортка бара, тагы, акырып-бакырып, чыкмаска теләгән малайларны чыгартып карап: «Менә тәти булган, улым»,— дип, акырган балага тагы череген сибеп, тагы чәй эчеп, тагы икмәк алып китә иде. Шулай итеп, тагы бер мәртәбә йөреп чыга иде.

Сөннәтче бабай шул эшен тәһарәтле көенчә кылганга, һәрвакыт салават, бисмилла берлән эш башлаганга, балаларның җәрәхәтләре тиз бетәшә, тиз төзәлә иде. Кайвакытларда гына ярага әйләнеп китсә дә, чебен-черки чыкканчы төзәлми калмый иде. Иң актык сөннәт беткәч, Сөннәтче бабай зиярәт өстенә барып Корьән укый, хәзрәткә кереп садака бирә, остазбикәгә дип җимеш илтә иде. Шуннан соң, күршедән ат алып, сөннәт булган йортларда сөннәт ашлыгы җыеп йөри, капчык-капчык карабодай, борай, арыш, солы төяп өйгә кайта, өйалдының бөтен үсекләрен ашлык, он берлән тутыра иде. Җыелган икмәкне сатып, карчыгына күлмәк, алъяпмалык, үзенә күлмәк-ыштан, рамазан никадәр ерак булса да, «санаулы көн үтәр» дип, мәчеттә авыз ачтырырга дип ике кадак хөрмә алып, мөәзингә бирә иде. Шуннан соң ул тагы иске торышы берлән, тагы киләсе елның сөннәт вакытын көтү өмете берлән яши иде.

Шулай итеп еллар үтә, яшьләр өйләнә, яңа балалар, яңа сөннәтләр җитә, алар үтә; алар артыннан килә торган буынның баласы-чагасына рәт җитә иде. Яшьләр картая, картлар үлә, еллар үтә иде. Ләкин бу үткән еллар аның яшен картайтмаган кеби, аның битенә яңа җыерчыклар да чыгармый вә аның билен тагы бөкрәйтми иде. Ул, дөнья үтүен сизмәгән кеби, һаман элгәреге Сөннәтче бабай булып тора иде.

Тыйб[1] гыйлеменнән мәгълүм: кешенең тәнендәге канының куелыгы вә сыеклыгы, ул канның агуы елның фасыллары берлән бик зур мөнәсәбәте бар. Кыш көннәрендә инсаннарның[2] каннары бөрешкән, куеланган хәлдә була. Ул тамырлар буенча акыртын гына, һаваланып кына ага. Кыш көнендә бер-бер әгъза киселсә, яисә тамыр өзелсә, кан, касәдән авыр-авыр чыга торган куе каймак кеби, акыртын гына ага, җәрәхәт тиз бетәшә. Көннәр озая башлап, кояш күбрәк җылыта башлагач, урамнарда сулар җыела башлагач, адәм тәнендәге кан да, кояш җылысында эрегән кар кеби, языла башлый. Көн җылынган саен ул сыегая, сыегая килә. Май числосында ул тәмле, татлы язгы сөт кеби була. Шуның өчен ул вакытта кешеләр үзләрен яшәргән кеби хис итәләр, аркаларыннан бик зур йөкне ташлаган кеби, җиңеләеп калалар. Бу вакыт кан, үзеннәнүзе, кыш буе җыелган бозык, начар каннарны куа башлый. Җәй җитеп көн кызуланган саен кан сыекланганнан сыеклана бара. Кеше тәнендә торасы килмәгән кебек, адәмнең эчендә кайный, ялгышлык берлән кул-баш киселсә, бик күп кан әрәм була. Һавалар суыгая башлап, яшел үләннәр кырау күргәч, кан тагы, савыт өстенә утыра торган каймак кеби, акыртын гына утыра, куера башлый. Кыш якынлашкан саен аның куеруы арта, шуның өчен гыйльме тыйб ияләре кан алдыру, мөгез салдыруның вакытларын елның фасылы берлән тәгаен итәләр. Һичбер вакытта, аерым бер авыруы булмаса, канның сыекланган вакытында тамырын кисеп, адәмнең шашкан, чыгарга көтеп кенә торган канын әрәм итмиләр. Шуның кеби үк, кыш көнендә, куерган, утырган канны йокысыннан уятып, ага торган юлын бозмыйлар, аның буасын ермыйлар. Алар кан алдыру өчен кыш буе җыелган начар, бозык каннарны, канын үзеннән чыгарып иркәләнеп калырга теләгән яз көнен ихтыяр итәләр. Шул яз көнендә, көнләр җылынып җиткәч кенә тамырдан кан алалар, мөгез салалар.

Ел фасылларының кан агуына, канның куелыгы, сыеклыгына тәэсире булган кеби, айның, көннең дә тәэсире юк түгел. Айның тулысында кан тулы булганга, кан алу өчен куркынычсыз түгел. Канны туктату авыр булып, теләр-теләмәс күп кан чыгу ихтималы бар. Айның башында яшь тамырга өйрәнеп бетмәгән каннар чыгып китүләре ихтималы булганга, таза канның чыгып, карт канның калу шөбһәсе бар. Шуның өчен канны алдыруны тулы ай кителә башлагач муафыйк күргәннәр. Айның унтугызынчы-егерме беренче көннәрен бигрәк мәслихәткә санаганнар.

Көннең исеме берлән, көннең вакыты берлән дә канның агуының, әлбәттә, мөнәсәбәте бар. Ләкин көннәр һәммәсе дә аллаһы тәгаләнең көне булганга, бу мөнәсәбәтләрне тәгаен әйтергә тыйб галимнәре ирешә алмаганнар. Аллаһы тәгалә бу серне алардан яшергән. Шулай булса да, көннәр өчен дә сәбәпләр мәгълүм булмаса да, сишәмбе вә якшәмбе көннәрен артык күргәннәр.

Безнең Сөннәтче бабай Сәлман Фарси хәзрәтләреннән мирас тарикы берлән сөннәтчелекне алса да, Әбугалисина хәзрәтләре тарафыннан тыйб гыйлеме, гыйльме симия вә гыйльме кимиягә иҗазәт алмаганга, әлбәттә, тыйб гыйлеменең бу кадәр нечкәлекләрен белми иде. Ләкин исәпсез-хисапсыз еллар хәзрәтләр, муллалар, мөәзиннәр берлән катнашу, аларга исәпсез-хисапсыз мәртәбә мөгез утырту, иксез-чиксез аларның каннарын алу аңар зур тәҗрибә биргән вә шул кагыйдәләргә аны да алыштырган иде. Ул да һичбер вакыт көз кан алмый, кыш мөгез салмый иде. Ул да һичбер вакыт

1. Тыйб — медицина. 2. Инсан — кеше.

айның тулысында мөгезне истигъмаль[1] итми, җәйнең кызуында кан балтасын тамырга сукмый иде. Ул да һичбер вакытта баш көндә яисә шимбә көнендә кан эшенә тотынмый иде. Ул, кан өчен вакытын, көнен исәпләп, аен, сәгатен саклап тора иде.

Менә шул көн җитә башлагач, хәзрәт мәхдүм аркылы яисә хезмәтче аркылы Сөннәтче бабайга: «Буш көн (сишәмбе көн) кан алырга керсен»,— дип хәбәр иттерә иде. Сөннәтче бабай мөгезләрен җылы суда кат-кат юа, кан тамырына чаба торган балтасын үткәрә, мөгез астына суга торган пәкесен ныграк очлый иде. Ул шул көн җиткәч, тагы кияү булып кергәндәге күлмәген, Кәбир хәзрәттән калган әдрәс камзулын, мәхдүмәдән килгән кәләпүшен киеп, ап-ак чүпрәккә төргән мөгез салу әйберләрен күтәреп, иртәнге чәйне эчкәч тә, хәзрәткә китә иде. Хәзрәт аны үзе каршы ала, остазбикә тасларга җылы суларны үзе хәзерли иде. Хәзрәт, тәһарәт алып, кан алу хакындагы хәдисләрне укып, салават әйтеп килеп утыра иде. Сөннәтче бабай, тагы бисмилла әйтеп, салават әйтеп, хәзрәтнең арт чигәсенә бик йомшак кына иттереп кыра иде дә, тагы бер салават, тагы бер бисмилла әйтеп, пәкесенең очы берлән чиртергә тотына иде. Каннар агып, хәзрәтнең муенына төшә башлагач, ул, мөгезне куеп, башындагы тишектән һаваны суыра да, шуның тишегенә ябар өчен бәйләтелгән сарык имчәген юешләтеп, тишекне ябып куя иде дә, икенче чигәгә чиртергә тотына, аны да шул юл берлән эшләп, мөгез утырта да, шуларның тулганын көтеп тора иде. Шул вакытта хәзрәт Сөннәтче бабайдан элгәреге заман хәзрәтләре хакында сораша; ул да элгәреге Кәбир хәзрәт, Сафа хәзрәтләрнең кан алдырулары хакында бер мәртәбә тәбәррек[2] Кәбир хәзрәтнең, кан алдыргач, һушы китү кыйссасын, шуннан абыстай мәрхүмәнең хәзрәтенә кан алырга рөхсәт бирмәвен сөйли иде. Һәрвакыт, шул хәбәр сөйләнеп бетүгә, мөгезләр кан белән тула иде дә, тагы бисмилла, салават әйтеп, Сөннәтче бабай мөгезләрне акыртын гына алып, әүвәлдән хәзерләнгән савытка сала да, катык кеби каткан кара канга карап: «Сөбханалла, хәзрәт, күз тимәсен, каныгыз бик бозылган, капкара!»— дия иде. Сөннәтче бабай тагы мөгезне утыртыр өчен урынын карый, теге җәрәхәтләрнең кайсы-берсе бетәшкән булса, тагы чалгы пәкесенең очы берлән аркылы-торкылыга чиртә иде дә, тагы мөгезне утырта, тагы иске заман кешеләре хакында сүзгә керешә иде. Монысында да кан кара чыкса, Сөннәтче бабай: «Машалла, хәзрәт!»— дип, тагы хәзрәтнең каны бозылуы хакында сөйли, хәзрәт тә шул бозык канын чыгарып бетерер өчен, тамырдан кан алдырырга уйлый башлый, ләкин һәрвакыт шул мәсьәләгә килгәч: «Мөгез салдыру сөннәт[3] булса да, кан алдыру бидгать[4] түгелме?»— дип, пәйгамбәрләребезнең кан алдыру турында ачык риваять күргәне юкка шөбһәләнеп, торып, шүрлектән китап алып, китап карарга тотына, шуның хакында риваять тапканчы маташып, шуннан соң гына разый була иде. Сөннәтче бабай сул яки уң кулының терсәгенең бөкли торган җиреннән кара тамырын табып, тагы: «Бисмилла!»— дип, салават әйтеп, балтасы берлән чаба, кан чәчрәп чыгып, фонтан булып, түшәмгә таба ата башлагач та, җиз таска хәзрәтнең кулын бора, үзе тагын чыккан бер канның суынып, каралып катканын күргән саен: «Машалла, машалла, хәзрәт, каның бик бозылган икән, капкара!»— дип хәзрәткә сөйли; хәзрәт, шул бозылган каннан котылыр өчен, һаман агыздырганнан агыздыра иде. Гадәттә, ике-өч чүмеч кадәр агызсалар да, кайсы елларны хәзрәтнең каны бик бозылып киткәнгә, күбрәк тә агызалар, агарга куйган җиз тас тулгач кына, тамырны ныклап бәйләп туктаталар иде,

1. Истигъмаль — куллану; 2. Тәбәррек — хәерле, рәхмәтле; 3. Сөннәт — пәйгамбәр кылган эш-гамәлләр; 4. Бидгать — сөннәткә каршы эшләр.

шуннан соң хәзрәт юынырга тотына. Сөннәтче бабай каннарны күтәреп чыгып, мәхшәр көнне, азып-тузып, ияләрен эзләп йөрмәсеннәр өчен, һәр елны күмелә торган, бала-чага маташмый торган почмакка чокыр казый иде дә, салават әйтеп күмә иде. Шуннан соң абыстай хәзерләгән самавыр янында чәй эчәләр иде. Сөннәтче бабай хәзрәткә, канны йомшартыр өчен пешкән коймак ашарга, канны сыеклатыр өчен лимон берлән чәй эчәргә мәслихәт итә иде. Замана башка булганга, халык ул вакыт таза булганга, хәзрәткә шул кан алдыру начар тәэсир итми иде. Ләкин күп вакытта шул кан алу аңа әллә нинди файдалы булып, җиңеләйтеп тә җибәрми иде. Әүвәл көннәрне бераз башы әйләнеп йөрсә дә, ул бик тиз элгәреге хәленә керә, аз гына да куәте кимегәнен сизми иде. Кан алганнан соң һушы китеп егылулар-фәләннәр хәзрәт берлән һич булмый иде. Чәйдән соң Сөннәтче бабай дога кылып торып, чәйгә рәхмәт укый, хәзрәт тә мәшәкатьләнүенә рәхмәт укып, Сөннәтче бабайга бирәр бүләк бирә иде. Сөннәтче бабайның мәшәкатьләнүе «бә ризаи аллаһы тәгалә»[1] булган кеби, хәзрәтнең дә бирүе «бә ризаи аллаһы тәгалә» иде. Бу бирүләр-алулар хәзерге, безнең замандагы кеби, докторга яисә акушеркага бирү кеби эш хакы түләү түгел, бүләк бирү иде. Шуның өчен хәзрәт күп вакыт Сөннәтче бабайга акча бирмәенчә, йә бер-ике генә юган күлмәк бирә, яисә моннан дүрт кенә ел элек алган читеген тоттыра, яисә Әхмәт хаҗи бүләк иттереп, хаҗ мөбарәктән алып кайткан мисвәк шәрифне[2] бирә иде. Сөннәтче бабай боларның һәммәсен бик зур разыйлык берлән алса да, мисвәк шәрифкә аның кәефе тагы да күбрәк килә иде. Ул аны Гөлйөзем әбигә кайтып мактанган кеби, бик саклап кына тота, аны мич янындагы иң кадерле җиргә куя иде. Сөннәтче бабайның бу бәйрәме дә үтеп китә, ул тагы иске киемнәрен киеп, иске тормыш берлән яши башлый иде. Ул вакытта җәдиде-кадиме, гәзите-мәзите, думасы-бумасы юк; ул вакытта мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе, тел мәсьәләсе, меллалар, яшьләр мәсьәләсе юк иде. Һәр кешенең вазифасы бер-берсенекеннән аерылган иде. Яңа эш, яңа хәбәр юк иде. Аның юклыгы да хис ителми, аның кирәклеге дә сизелми иде. Тормыш һәммә җирдә бер форма алган, шул формасында бара, шул алга китешендә, җәйге җилсез көнне ашъяулык кеби, тип-тигез ага торган Идел кеби ага иде. Аңа каршы торган буа юк, аның агымын тирескә[3] сөрергә теләгән һавалы җил дә юк иде. Тын иде, тыныч иде, тынычлыкның очы юк иде.

---

Шул тынлыкта гомер үтеп килгәндә, шул тынлыкның очы-төбе күренмәгәндә, бер көнне иртә берлән хәзрәт йоклап ятканда, Сөннәтче бабай ишекне кагып, хәзрәтне уятты. Калтыраган, каушаган тавыш берлән бабай:

— Хәзрәт, хәзрәт, карчык авырып китте, ясин укырга рәхим итмәссеңме? — диде. Хәзрәт, Сөннәтче бабайны юатып: «Иншалла, кичәр, суык тигәндер»,— дисә дә, күңеленнән, чыннан да, куркып китте. Тиз генә тәһарәтләнеп, бабай берлән китте. Гөлйөзем әбине яктан якка бәрелә-сугыла торган, «алла, алла!» — дип, ыңгыраша торган рәвешендә тапты. Бик ихлас берлән ясин укыды, бик озын иттереп дога кылды, Сөннәтче бабайны тагы юатып чыгып китте. Кайтып җитү берлән самавыр берлән көтеп тора торган остазбикәгә хәлне сөйләгәч, ул да курыкты. Ул, чәйне эчәр-эчмәс, хаҗ

---

1. Бә ризаи аллаһы тәгалә — алла ризалыгы өчен. 2. Мисвәк шәриф — хуш исле теш чистарткыч. 3. Тирескә — кирегә.

шәрифтән килгән савытка пешкән коймак салып, хәл белергә китте. Күрше Гадилә әби берлән бергә самавыр куеп, мәтрүшкә дә эчертте. Үзе дә дога кылып, өшкереп, Гөлйөзем әбине рәтләп яткырды. Өйлә тәһарәте берлән хәзрәт зәгъфәрән берлән аять шифа да язып җибәрде. Күрше хатыннары берлән абыстай Гөлйөзем әбине тәһарәтләндереп, аны да эчерде. Ләкин Гөлйөзем әби җиңеләймәде. Ул икенде[1] намазын тәямем[2] берлән генә, хәзрәтнең рөхсәт вә фәтвасы берлән, утырып кына укый алса да, ахшам намазын бөтенләй кыла алмады. Ул, башын күтәрә алмыйча, кайвакыт иссез, хәлсез булып киткәнгә, Сөннәтче бабай башына җыелган бозык каннарны чыгарыр өчен, кан алмакчы да булды. Ләкин шундый зур эшне эшләүдә көне-ае тугры килмәенчә, гөнаһлы булмас өчен ахшамнан соң хәзрәтне күреп сорады. Җәйнең эссе ае булганга, хәзрәт баштан ук: «Ярамый, канның сыекланган чагы»,— дип рөхсәт бирмәде. Бабай бик йөдәткәнгә: «Тагы бер-бер риваять булмасмы, китапта бер-бер кыйль вә кал[3] булмасмы, яравына риваять юкмы»,— дип, бик озак китап караса да, алдыруның файдасына һичбер дәлил таба алмады.

Хәзрәт ясту намазына тәһарәт алып бетерергә өлгермәде, Сөннәтче бабай килеп, еглаган тавыш берлән:

— Хәзрәт, бик авырайды, телдән калды,— диде. Хәзрәт аның авыраюында, телдән калуында үзен гаепле иткән кеби булганга, тизтиз итеп киенде. Абыстай да тагы бераз зәмзәм, кипкән инҗир, имбир алып, аның артыннан калмады.

Ясинны хәзрәт никадәр ихлас берлән укыса да, абыстай да никадәр ихлас берлән шул дарулары белән даруларга тырышса да, Гөлйөзем әби берсен дә каба алмады. Ул, кечкә-кечкә бер-ике тамчы зәмзәм суыннан башка берсен дә каба алмады. Күршенең Мәрфуга әбигә, Гадилә әбигә төнләргә калдырып, хәзрәт берлән абыстай кайтып киттеләр.

Ләкин иртә берлән, таң атар-атмас, Сөннәтче бабай килеп, хәзрәтләрне уятып:

— Карчык дөньяны куйды,— диде.

Сөннәтче бабай шул сүзне әйткәндә һәм дә иртә берлән мәчеттә дә, намаздан соң халыкка: «Җәмагать, карчык дөньяны ташлаган иде, кабер казырга ярдәм итешсәгез лә»,— дигәндә тавышында, кыйланышында әллә нинди кайгылылык беленмәде. Кыйланышларында хәтта бер бәйрәмгә хәзерләнү кеби әллә нәрсә сизелде.

Бөтен авыл кабер казырга китте. Бөтен авыл хатыны Гөлйөзем әбинең өстенә җыелдылар. Иртәнге чәйне эчкәч үк, абыстай да китап сөйләргә китте. Бик озын иттереп, үлем хакында, кабер газабы хакында, оҗмах, тәмуг хакында китап сөйләгәннең соңында, Гөлйөзем әбигә үзе кәфен кисте. Карт мөәзин хатыны, су куеп, үзе Гөлйөзем әбине юды. Хаҗ җиреннән килгән Мәрьям ана чәчен (хөрмә агачының мунчаласын) зәмзәм суына үзе манып биреп, кәфенне тектерде.

Җеназа да өлгерде. Бөтен авылның картлары тәһлилгә[4] җыелды. Гөлйөзем әбинең әллә кайчан хәзерләп куелган унике тастымалы тәһлилгә өләшелде; кәфенне бәйләргә куелган кызыл башлы өч сөлгесе хәзрәтләргә бирелде. Сандыктан чыккан илле баш берәр тиен ярымлыклар, егерме биш баш өч тиенлекләр җыелганнарга таратылды. Мәсҗет янына җыелган дүрт-биш йөз кеше җеназасын укып озатты. Җомгага кадәр күмелеп бетеп, хәзрәтләр Сөннәтче ба-

---

1. Икенде намазы — көн уртасындагы намаз; 2. Тәямем — сусыз гына; 3. Кыйль вә кал — төрле-төрле сүз; 4. Тәһлил — күмү йоласының бер өлеше: «Ля иләһы иллял-лаһ» — (бер алладан башка алла юк), сүзләрен кабатлап, тәсбих тарту.

байның өендә актык фатиханы да кылдылар. Җомга намазыннан соң хәзрәт бөтен мәсҗеттән һәүл[1] намазы да укытты. Сөннәтче бабай барысында да бик нык кыйлынып, үзенең кайгылылыгыны артык сиздермәде, йә сизелмәде. Җомгадан чыгуга, ул хәзрәтләр белән ашка да барды. Анда да шактый ашады, эчте. Менә өенә кайтып китте. Әллә никадәр күрше карчыклары берлән тулган канәфер мае исле өе, аны, бердән башына суккан кеби кабул итте. Ул, ишекне ачып керү берлән, шул канәфер мае исе борынга керү берлән, карчыгының, Гөлйөзем әбинең, шул үзе берлән илле, алтмыш, җитмеш ел яшәгән карчыгының юклыгын, аның тагы бер мәртәбә кайтмый торган җиргә киткәнлеген, аның үлгәнен белде. Ул шундагы сандык өстенә утырып, бик озак дога кылырга тотынды. Аның карт йөзеннән мөлдер-мөлдер яшь агарга тотынды. Ул, бик озак дога кылып, «Ярабби, карчыгымны гафу ит, гөнаһларын кичер!»— дип, йөзен сыйпады. Шуның белән ул үзенең күз яшьләрен дә тәмамларга теләсә дә, яшьләр туктамады. Ул, аның үлүенә ышанмаган кеби, өйнең бөтен җирләрен карап бетерде, беркемне дә белә алмады. Бакчасына чыкты. Анда да бер әсәр, галәмәт күрмәде.

Ул, шуларның һәммәсенә ышанып, өенә кереп утырырга өлгермәде, ишекнең тышкы ягында әллә нәрсә тырмаша башлады. Ул: «Гөлйөзем әбинең рухы килде»,— дип, куркып китеп, ишекне ачты. Үзләренең соры мәчеләре килеп керде. Ул, «мияу-мияу»,— диде. Сөннәтче бабай мәченең шул кычкыруында аермачык: «Әби кайда?»— дигән сүзне аңлады. Сөннәтче бабайның каткан күзеннән тагы яшь агарга тотынды. Ул, мәче белән сөйләшергә тотынып:

— Әбиең үлде, үлде. Оҗмахка китте, дога кыйл,— диде. Мәче, әллә нәрсә аңлаган кебек, тагы «Мияу-у»,— диде. Сөннәтче бабайга карчыгы төсе шул мәче бик якын кеби тоелды. Ул аның савытына сөт салды. Ләкин мәче берәр генә кабып караса да, ашамады.

Сөннәтче бабай мәченең дә кайгырганын күреп, шуннан котлары очып йортка чыкты. Аның күзенә берсе артлы берсе тезелеп, ана үрдәкнең командасы астында менеп килә торган үрдәкләр күренде. Ул аларны ашатыр өчен, өй алдына ярма алып чыгып сипмәкче булды. Моны күргәч, үрдәкләр тагы «бак, бак!..»— диярга тотындылар. Сөннәтче бабай боларның бакылдавында да: «Әби кайда?»— дигән сүзне аңлады. Шул уйдан котылыр өчен ул капка төбенә таба чыгарга өлгермәде, хәзрәтнең углы килеп, аны чәй эчәргә чакырып алып китте.

Анда да бер буйдан Гөлйөзем әби сөйләнсә дә, остазбикәнең тәмле чәен эчеп, татлы ашларын ашап, Сөннәтче бабай азрак күңелен юатты.

Ул, икенде намазын укып, өенә кайтты. Зур мөгезле карт кәҗә аны кычкырып каршы алды. Ул аның мөгез арасын кашыды, аны сөйде. Ләкин кәҗә җилеменә сөт тутырып кайтканга, «Савыгыз!»— дип, әбисенә кычкыра башлады. Сөннәтче бабай тагы чыдый алмады, тагы күзеннән яшь акты. Менә күрше килене килеп, кәҗәне саварга тотынды. Кәҗә саудырмаска теләмәсә дә, бик ямьсез тавыш белән: «Минем сөтемне урлыйлар, минем сөтемне талыйлар, әби, кил!»— дигән кеби, кычкырудан туктамады.

Сөннәтче бабай ахшам намазына барыр өчен тәһарәт алырга комган эзләргә тотынды. Комганының җирендә булмавы тагы карчыгын аның исенә төшерде. Ястүгә кадәр ул ялгыз коръән укып, дога кылып үткәрде. Ястү намазын укып, гомерендә җәймәгән урын-

1. Һәүл — мәет күмелгән көн кич укыла торган намаз.

ны үзе җәеп ятты. Ләкин түшәк, ястык аңа ят күренде, ул урын каты тоелды. Өе, шул Сөннәтче бабай өйләнгәннән бирле тора торган өе, үзенеке түгел, кешенеке кеби сизелде. Ул, белгән бөтен догаларын укып, йокларга теләде. Тагы янында карчыгы юклыгы аны уятты. Ул бик озак уйлады, үзенең яшьлегеннән алып, бу көнгә кадәр уйлады. Көн буе йөреп арган тән аруына баш авыруы да катышты. Ул йокыга китә башлады. Менә кәҗә кычкырды. Аның кычкыруында бабай тагы әбине сагынуын аңлады. Тагы йокы качты, тагы уйлар, тагы кайгылар...

Менә таң якынлашты. Сөннәтче бабай йокыга киттеме, юкмы, анысы мәгълүм түгел,— ул ап-ак күлмәктән, көлеп кенә Гөлйөзем әбинең: «Карт, намаздан каласың!»— дигән тавышын ишетте, төсен күрде. Ул, сикереп торып: «Әлһәмделиллаһ, әһле җәннәтдән икән»,— дип, ян-янга карарга тотынды. Чыннан да, намаз вакыты бик җиткәнен сизеп, торып тәһарәт алып, намазга китте. Намаздан соң хәзрәткә төшен сөйләде. Хәзрәт:

— Оҗмах әһлендин икән,— дип тагы бабайны кәефләндерде. Ләкин өйгә кайткач, ул тагы ялгызлык хис итте, тагы аны шул киң, зур өй кыса, изә башлады. Ул, өендә утыра алмыйча, капка төбендә, күршеләр янында, бакчада тора башлады. Шул ялгызлыкның изүенә хәйлә таба алмады.

Бер төнне Сөннәтче бабай әллә нинди ямьсез төшләр күреп, уянып китте. Бөтен тәненең туңганлыгын күреп, юрганына тагы бөтәрләнебрәк ятты. Ләкин ни кыйлса да, аркасын җылыта алмады. Ул әйләнде, бәйләнде, урынын төзәтте, ләкин аркасы җылынмады. Әүвәл йокыга киткән кеби булды, тагы аркасы туңып уянды. Тагы калыкты, тагы уянды. Менә аркасының туңганын белеп, ярты йокы, ярты уяу көенчә: «Карчык, карчык!.. Арканы җылыт!»— диде. Үзенең тавышын үзе ишетеп, уянып китте. Шул тавыштан куркып, йокысы качты. Тагы күңеленә Гөлйөзем әбинең үлүе, аның һәрвакыт Сөннәтче бабайның аркасын җылытып йоклатуы исенә төште. Шул рәхәт көннәрне исенә төшереп, аның аркасы тагы туңа башлады. Ул тагы Гөлйөзем әби хакында уйларга тотынды. Уйлыйуйлый ничектер, «тагы өйләнергә», дигән фикер башына килеп керде. Элгәре ул шул фикерне башыннан ташламакчы булса да, ләкин уе, бизгәк кеби, аны ташламады. Арканың туңуы шул фикергә куәт бирде. Ул минут саен куәтләнә: «Өйләнергә кирәк, өйләнергә кирәк!»— дип уйлый башлады. Бик озак йоклый алмыйча уйлап торганның соңында ул өйләнү фикеренә килде. Килде генә түгел, шул уйдан аерыла алмады. Ул, бер күрше малаенда күргән уенчыкны аталарыннан таптыра торган тирес бала кеби, шул уе берлән бөтенләй томаланды. Ул шул карардан соң яшәреп киткән кеби булды. Аның искедәге киткән яшьлек көчләре кайткан кеби булды. Ул, урынына ятып, шул өйләнүләрне уйлый башлады. Үзенең әүвәлге өйләнүе, бикәчкә билбауның очын яшереп баруы ишек бавына кызыл яулык бирүләре, җилән ябынган яшь бикәч белән бергә ашка йөрүләре, туйлары, уеннары — һәммәсе бөтен ваклыкларына кадәр күз алдыннан үтте. Ул тагы шуларның ләззәтен яңартып ләззәтләнде. Шул вакыттагы шатлыкларны хәтердән үткәреп, тагы рәхәтләнде. Менә ул тагы өйләнә, тагы аңар шул вакыттагы кеби кызык, күңелле була...

Шул уй белән ул җанланып, аркасы туңганын да хәтердән чыгарып, вакытыннан иртә тәһарәт алып, намазга китте. Намаздан соң хәзрәт берлән сөйли-сөйли, хәзрәтләргә кадәр барып җитте. Чәй янында шул сүздән туктамады. Хәзрәткә, абыстайга элгәре шул яше онытылган бабайның «өйләнәм» дип йөрүе көлке кеби тоелса да, Сөннәтче бабайның шул уе берлән саташканын күреп, каршы килүдә мәгънә юклыгын сизеп, яткан ягына сыйпарга тотындылар.

Сөннәтче бабай тәмам яшьләр кеби, авылдагы тол хатыннарны санарга тотынды. Бик файдалы, кыйммәтле кияү кеби, әллә никадәр тол хатынларны яратмаенча үтеп китүе хәзрәт берлән абыстайның элгәре бераз исен дә китерде. «Әллә гакылдан бераз яздымы?» — дигән фикергә дә төшерде. Ләкин башка хәрәкәтләре берлән бик гакыллы күренүе тагы аларны ул фикердән кайтарды. Сөннәтче бабай яучы булырга хәзрәтне яисә остазбикәне кушса да, бабайның күңеле бик югарыдан булганга, төрле хәйләләр табып, хәтта хәзрәт иске әүлияларның үзләре өчен үзләре яучы булуларын сөйләп, үзенә баруны мәслихәт итте.

Бабай да шул сүзне колагына элеп, белгән догаларын укып, күңеленә ни яраган иске мөәзин хатынына таба китте. Мөәзин хатыны — абыстайның җиткән угыллары барлыгын да хәтеренә китермәенчә, туп-туры барып керде. Сөннәтче бабайны күргәч тә, мөәзин хатынының угылларының угыллары чыр-чу килеп: «Кисә, кисә!» — дип, качыштылар. Алар артыннан кызлары да: «Кисә, кисә!» — дип, почмакларга постылар. Мөәзин хатынының ялгыз гына калуын ганимәт белеп[1] Сөннәтче бабай тугрыдан-тугры сүз салды. Карт остазбикә элгәре исе китсә дә, Сөннәтче бабайны азрак акылга җиңеләйгәндер, ахры, дип, «утыр, утыр», дип, сүзне башкага борырга теләде. Ләкин карт һаман үз сүзеннән кайтмаганга, «әлхәмделиллаһе, фәкыйрь түгелмен, арышым да бар, кәҗәм дә бик сөтле, быел сөннәт тә шактый күп, дип, үзенең яхшы якларын сөйләп торганга, моның чынлап йөрүен аңлады һәм дә, «рәхмәт» — диде дә, ничек иттереп, болаймы, әллә башкачамы әйтергә аптырап торып:

— Минем ул фикерем юк. Ирем мәрхүмгә вәгъдә бирдем. Балаларым да үсте. Менә шуларның балаларын тәрбия кыйлып гомер үткәрәм инде,— диде. Сөннәтче бабай үзенең тагы Сәлман Фарси нәселеннән икәнен дә сөйләнсә дә, ул да тәэсир итмәде. Сөннәтче бабай ясалган чәйне дә эчмәенчә, чыгып китте. Чыккан вакытта күңелендә бер төрле хурлану, ачу килү хисе булса да, шул остазбикәнең сүз кайтаруы Сөннәтче бабайның бәгъзе планнарын бозса да, урамда уйлый-уйлый, ул фикер белән дә килешеп, түбән очта тегермәнче Фәхринең хатынына китте. Илле-илле бишләрдәге тегермәнче хатынының йортта чебешләр ашаткан җиренә тугры килеп, хәл-әхвәл сорашып, янына утырды; сүзне бик озаклап, читтән китереп тормаенча, тугрыдан-тугры:

— Миңлезифа, мин сиңа яучылыкка килдем,— диде. Шул сүзне ишеткәндә теге хатынның тавыкларны, әтәчләрне куарга тоткан чыбыгы кулыннан төште. Шуны гына көтеп торган тавыклар, әтәчләр ябырылып алып, чебешләрнең азыгын ашарга тотындылар. Теге аптырап, катып торганның соңында бабайның туктамый сөйләгән сүзләреннән элгәре аның җиңеләюенә хөкем итте. Бара-тора ул фикердән дә кайтты; ләкин ни дип җавап бирергә дә, ничек кайтарып җибәрергә дә сүз таба алмады. Уйлый төшәргә вакыт күбрәк ясар өчен: «Утыр, хәзер киләм»,— дип, лапас астына җәйгән урынга күрсәтте, үзе, базга төшеп, каймаклы катык алып чыгып, бабайның алдына куйды. Бабайның, ашый-ашый сүзен дә дәвам итүен күреп, карчык ничек шул ямьсез сүзне бетерергә юл эзләргә тотынды. Ул мөәзин хатыны кеби:

— Углым, кызым җиткән: ир тәрбия кыйлырлык хәлем юк,— диде. Сөннәтче бабай моңар тагы, анда тормыш тормыш түгел — оҗмах икәнлекне сөйләсә дә, ахырдан гына, үзенең Сәлман Фарси нәселеннән икәнлеген аңлатып, кыямәт көнне Сәлман Фарсиның шәфәгате берлән оҗмахка керү мәгълүм икәнлеген белдерсә дә, карчык, әйткән сүзеннән кайтмады.

---

1. Ганимәт белү — кадерен белү, бушка уздырмау.

Сөннәтче бабайның шактый ачуы килеп чыгып китте. Ул хәзер ары яктагы кызында тора торган сөлекче карчыкны сорарга китте. Ләкин сөлекче карчыкның тасма тел кызы бабайның сүзен ишеткәч үк, бабайны кадерсезләп-кадерсезләп тиргәргә тотынды. Аннан да бабай бер җылы сүз ишетә алмаенча, күптән түгел генә иреннән аерылып кайткан кырыклы-иллеле бер хатынның әнисенә туры китте. Хатынның килене, артык тамактан котылыр өчен, Сөннәтче бабайның сүзен бик җөпләсә дә, әнисе каршы бер сүз дә әйтмәсә дә, карчык үзе якын да килмәде.

Сөннәтче бабай юл буенда тугры килгән тагын берничә җиргә кереп, һәммә җирдән җылы сүз ала алмыйча, өметсез өенә кайтты. Иртәгесен дә шуның артыннан йөрсә дә, тагы өметле сүз ишетмәде. Ләкин боларның берсе дә бабайның эссесен сүндермәде. Киресенчә, аңарда шул фикерне куәтләндерде. Ул күрше авыллардан сораштыргалый башлады. Күрше карчыкларына, картларына үзенә карчык табарга үтенде. Менә, килеп-килеп, карчыклар димләргә тотындылар. Кайсы ул авылда, кайсы бу авылда; бик һәйбәт, бик яшь, фәлән, дип мактадылар. Биш-алты сөаль белән бу карчыкларның һәммәсенең дә торырга урыны юк, фәкыйрь, карт, зәгыйфь, эшкә ярамаган икәнлекләрен аңларга мөмкин булса да, Сөннәтче бабай өйләнү уе аркасында андый эшләрне онытып бетергәнгә, андый кирәкмәс эш белән вакыт үткәрмәде — карчыкларның һәммәсен ятатты, һәммәсенә разый булды. Ләкин берсе әллә нигә күңеленә күбрәк охшаган төсле булды.

Баш коданың сүзе белән килүендә дә шөбһә булмаганга, ул былтыргы сөннәттән калган ике капчык арышны сатып, күршедән ат алып, теге әдрәс камзулны киеп, күрше авылга да китте. Карчык күңелгә бик үк тулып бетмәсә дә, «Ит юкта үпкә тансык» дигәнчә, бабай разый булды. Хәзрәтләр дә чакырылды, никах та укылды. Моннан соңгысын бабай никадәр әүвәлге туена охшатырга теләсә дә, охшамады: карчык берлән сөйләргә сүз табылмады; табылса, әллә нигә ул кадәр кызык булмады. Сәлман Фарсины карчык аңламады. Карчыкның җеп җөрләвеннән бабай бер ләззәт ала алмады. Карчыкның кардәшләренә кунакка бару да әүвәлге кеби күңелле чыкмады, кич үткәрүнең дә мәгънәсе әлгәрегечә булмады. Бабай шуларны аңласа да: «Менә үз өемә килгәч, Гөлйөзем әби күк булыр, аның үлгәне сизелмәс тә»,— дип күңелен юатты.

Иртәгесен карчыкның агач сандыгын, бер комганын арба артына бәйләп, карчыкның тавык йонынннан ясалган ястыгын аска салып, карчыкның янына утырып, бабай туй төшерде. Бөтен шартлары тулсын өчен ул, тавык суеп биреп, карчыгына аш хәзерләргә кушты. Үзе кибеттән дөгесен, җимешен алып кайтып, хәзрәтләрдән икендегә кадәр фатиха кылып чыгарга вәгъдә алды.

Вакыт җитте. Хәзрәтләр килде. Аш өлгерде. Коръәннән соң бабай бүлмәдән алып шурпа бирде. Шурпаның өстендә йөзеп йөри торган пешмәгән суганнар бабайга әллә нинди мәхәббәтсез кеби тоелды. Хәзрәтләрнең сүзе берлән ул үзе дә утырды. Менә аш башланды. Гөлйөзем әбинең шурпасын табактан төбенә кадәр ашый торган хәзрәтләр, берәр капкач, кашыкны куйдылар. Бабай шөбһәләнде, бисмилла әйтеп ашны капты. Тозсыз, борычсыз, чи суганлы, «идел суы илле батман» иттереп пешерелгән шул аш аз-аз гына костырмады. Ул, халыкны кыстап, тагы бер-ике капса да, артык өнди дә, кашыгын суза да алмады. Аш алыштырылды, бәлеш чыкты, өсте ачылды. Кирпеч төсле каткан ярмага мөәзин никадәр шурпа сипсә дә, ул эремәде. Төбенә кадәр ашалып бетмәгәнгә, мөәзин төпне кисмәде дә. Менә тутырган тавык: ул, туп эченә төртеп, дошман гаскәренә атып, аның крепостен ватарга ясалган кеби катырылган, киселгәч, йомыркалары беләү кеби ялтырап торалар; тозлы-

лыктан авызга кабарлык түгел. Ул гына булса ярар иде, эче арчылып бетмәгән, кабырга төбендә әллә никадәр канлы былчырак нәрсәләр калган. Сөннәтче бабай кайнап торган самавырын күрсә дә, тагы мыскыл булмас өчен:

— Хәзрәтләр, шуның берлән тәмам,— диде.

Сөннәтче бабай хәзрәтләрнең: «Алла хәерле гомер бирсен, тигезлек берлән гомер үткәрергә язсын!»— дигән догаларын ишетсә дә, күңеленнән Гөлйөзем әби китмәде. Ул, шул тәмсез ашлар, шул халык алдында мыскыл иткән карчык — Гөлйөзем әбинең бәддогасы дип ышанганга, өенә кире кайтмаенча, зияраткә китте. Бик озак коръән укыды, бик озак дога кылды. Күңеле бераз урынына утырып, ул өенә кайтты. Баягы ашларның буш табак-савытлары янында, кайнаган самавыр алдында карчыгын җимешләп чәй эчкән көенчә тапты. Ул, аның янына утырып, чәй эчә башлады. Аның бер сум алтмыш тиенгә алган чәеннән дегет исе, әллә нәрсә тәме сизенеп, ул аз гына сикереп тормады:

— Ник бу кадәр тәмсез? Ашың килешмәгән иде, хәзрәтләр бер дә ашамадылар. Минем мәрхүм карчык заманында бер тамчы аш калмый иде,— диде.

Карчык, бик зур эш белән мәшгуль кеби, чәй эчүендә дәвам итте. Картка каршы бер сүз дәшмәенчә, кәҗә сөте алып кереп, чәенә салып эчә башлады. Сөннәтче бабайның әллә ничә еллардан бирле өйрәнгән гадәтләренә илтифат итмәенчә, үзе теләгәнчә кылана торган шул затсыз карчык аны җирәндерде. Ул «намаз җитте» дип, тәһарәткә су сорап алды. Ни күзе белән күрсен, комганында ләкшәләр[1] йөзеп йөри. Ул тагын ачуланып, тешен кысып:

— Казанны пакь тотмаган өйдә бәрәкәт булмый,— дип, пакьләргә кушып, намазга китте. Кич берлән ул тагы карчыгын кәҗә сөте берлән бәлеш төпләре ашаган вакытта очратты. Моңар ачуы килү бетмәде — ул, самавыр янына бик зур бер табак бәрәңге китереп куеп ашарга тотынды. Бабай шул ашау казаныннан әллә никадәр җирәнде. Икенче чәйнеккә чәйне үзе пешереп, берәр чынаяк чәй эчеп ятты. Ләкин карчыкның мыш-мыш йоклавыннан җирәнеп, ул таң алдына кадәр йокыга китә алмады. Аның туңуы да онытылды.

Ике атна вакыт үтмәде — Гөлйөзем әбинең тарихы онытылган көннән бирле керткән тәртипләре бозылды. Аның заманасында сары гәрәбә кеби ялтырый торган идәннәре мәдрәсә әчелеге хәлен алды. «Аглийский пыяла»дан ясалган кеби ялтырый торган тәрилкәләр уңмаган хатынның алъяпкычы төсенә керде. Әби заманасында йөзендә аллы-гөлле кояш уйный торган самавыры казан төбе кеби катты. Чынаякларның тоткалары, чәйнекнең капкачлары маңка малайның борыны төсле булды. Әби заманасында пөхтә итеп җыелып куелган мендәрләр урынында карчыкның сәләмәләре өстерәлә башлады. Көз якынлашкан булса да, әллә кайдан әллә никадәр чебен тулды. Алар «жу-у!..» итеп торып, чәйгә, ашка төшеп, бабайны җирәндергән кеби, бөтен диварларны, салфетларны былчыратырга тотындылар. Сөннәтче бабай селкенчәк Фәхриләр өендә генә очраткан сасы ис бөтен өйне тутырды.

Йорт эчендә дә элгәреге низам вә интизам[2] бетте. Әби заманасында йомыркасы бар чакта кырылдап хәбәр бирә торган, салып бетергәннең соңында бик озынлап кыткылдап белдерә торган Каракolak, Чуар, оя төбе тавыклары да кайсы качып сала башлады, кайсы читкә китте. Һәркөнне кич берлән көтү кергәндә өйдә була торган үрдәкләр, казлар да су буенда торып куна башладылар.

---

1. Ләкшә — токмач. 2. Низам вә интизам — тәртип һәм рәтлелек.

Кәҗә дә, әби берлән бабайны ун ел ашаткан, ун ел кәҗә тәкәләре, кәҗә бәрәнләре үстергән кәҗә дә, үзгәрде: аның да сөте азайды, сыекланды. Бөтен кышка җитәр дип торган бәрәңгенең дә яртысы кыш кермәс борын бетте. Бөтен кышка дип, бабайның хәзерләгән утыны эләгеп кенә калды.

Шуларның һичберсе дә Сөннәтче бабайга яхшы тәэсир итмәде. Ул карчык белән оршышмаса да, талашмаса да, шул аз вакытта элгәреге, тарихсыз үткәргән гомереннән картайды. Аның биле тагы бөкерәйде, чәченең агы әллә нинди ямьсез акка әверелде. Ул озын-озын «уф, уф...» иттереп сулый башлады. Ләкин шуларның барысы да карчыгы Гөлйөзем әбинең хәтерен калдырган өчен аллаһе тәгалә тарафыннан җибәрелгән бәла дип ышанганга, шул казага сабыр итте. Бөтен гомерен өендә, йортында үткәргән Сөннәтче бабай ике атнада өеннән, йортыннан бизде: ярты вакытын мәсҗеттә, ярты вакытын урамда уздыра башлады; мөмкин кадәр өйдә ашамаска, эчмәскә, өйдә утырмаска тырыша башлады. Ул оясын былчыраткан каз кеби, иртәдән кичкә кадәр өенә керергә курыккан кеби, өе тирәсендә әйләнә башлады. Аның бөтен рәхәте, тынычлыгы бетте. Ул һәркөнне, күңелен юатыр өчен, карчыгының каберенә барып, коръән укырга тотынды. Кабер янында бик озак утырып, һәркөнне, карчыгы берлән бергә үткәргән гомерен уйларга тотынды. Һәркөнне карчыгы бу көн генә үлгән кеби булып, еглаенча кайта алмады.

Менә бер көнне карчыгының зиярәте азрак басылган кеби булды. Иртәгесен бабай балта, көрәк алып килеп, яңа чирәм берлән өстен япты. Тагы бер көнне барганда әбинең зиярәте янында бер бозау ятканын күреп, бабай кабер тирәсен тотарга уйлады. Һәркөнне өйдән акыртын гына агачлар, такталар ташып, зиярәт тирәсен чәүрде (чәүрәде)[1]. Ләкин ахырына җиткәндә генә бер-ике такта җитмәгәнгә, бетмәенчә калды. Бабай иртәгесен күп уйлап тормаенча, җилкапкасыннан сүтеп алып, эшләп бетерде. Шул койманың кадакларын дүртәр-бишәр мәртәбә какты. Алай да эш беткәч, уйлап торып, өстенә агач утыртырга кирәген төшенде. Бакчасындагы кеше буйлык, түгәрәкләнеп килә торган каенын утыртырга уйлап, элгәре ике көн бик һәйбәт иттереп урын хәзерләде. Аннан соң каенын тамырын кисмәенчә алыр өчен, еракгган китереп казып алырга берике көн вакыт үткәрде. Ул да бетте, агач та утыртты. Агач, утыртып беткәч тә, акыртын гына искән җил берлән иелеп-сугылып, моң гына тавыш чыгара башлады. Бабай шуны күреп, шатланып китте; агачның зикерен[2] ишеткән кеби, моңаеп, тыңлап утырды. Шуннан соң һәркөнне кич берлән агачка су китереп сибүне гадәт итте.

Менә бер көнне бабайның моңаеп кына су сибеп кайтканын остазбикә күреп, малай йөгертеп, чәй эчәргә борып кертте. Ул, остазбикәдән оялган кеби, тагы бөкрәебрәк кенә килеп керде. Остазбикәнең тәмле чәе, һәйбәт әче күмәче, балы аңар тагы карчыгын исенә төшерде. Ул, әллә ничә көн чәй эчмәгән кеше кеби, бик тәмләп, тәмләп эчте. Эчә-эчә бераз кәефе дә килде. Ләкин шул чәй, шул эчелгән самавыр, шул ялтырап торган чынаяклар тагы аңар карчыгын исенә төшерде. Остазбикә дә, хәзрәт тә, бабайның ярты гомерен зиярәттә үткәргәнен, бабайның карчыгыннан разый түгеллеген белгәнгә, элгәре Гөлйөзем әбине сөйләп, картның җәрәхәтен ачмаска теләсәләр дә, остазбикә әллә ничек:

— Карчык исәнме, нишләп тора? — диде.

Сөннәтче бабай, иң авырта торган җиренә суккан кеше кеби,

1. Чәүрде — (бу сүз сүзлекләрдә очрамый); 2. Зикер — искә алу.

бердән, чырайларын сытты, кашын чытты. Әллә нәрсәгә бик зур көч сарыф кыла башлады. Ләкин картның күзеннән яшь ага башлады. Бабай кычкырып елап җибәрде:

— Сөйләмә, остазбикә, карчык бәддогасы...— дип елап кайгысын тиште. Берәм-берәм бөтен кайгысын сөйләп бетергәч, бабай азрак җиңеләеп китте. Ахырдан, хәзрәт берлән, быелның сөннәте турысында да сөйләште. Бик ихлас белән кызыгынчы, йөзенче мәртәбә үлем хәлләреннән Мөнкир, Нәнкир[1] килүләреннән, кабер газабыннан, оҗмах нигъмәтләреннән сорашты. Ахырдан гына, куркып кына:

— Хәзрәт, терек кешегә кабер казырга ярыймы? — дип, хәзрәттән фәтва сорады. Хәзрәт әллә нинди бер әүлияның үз каберен үзе казуын сөйләгәч, бик зур бер мәсьәлә хәл кылган кеби, шатланып кайтып китте.

Иртәгесен ул, карчыгының аяк очында җир табып, акыртын гына эшкә башлады. Шуннан соң һәр көнне килеп карчыгына коръән укып, каенына су сибеп бетергәч тә, бисмилла-салават әйтеп, казырга башлады. Акыртын гына иттереп, тәмле нәрсә ашаганда аз кабып ашаган кеше кеби иттереп, аз-аз гына казыды. Ләкин, никадәр аз казыса да, көн үткән саен тирәнләп, сары балчыкка килеп җитте. Яәҗүҗ, мәәҗүҗдән[2] бабай бик курыкканга, сары-сары балчыктан тирәнгә төште. Менә эш ләхеткә җитте...

Ул өйлә намазыннан соң тәһарәте кыстар төсле кеби тоелганга, өйгә кайтып тәһарәтләнеп барырга уйлап, өйгә таба борылды. Күрше йортка көзге ат көтүе бирергә җыелган җыен янына килеп сәлам биреп, мәчет картлары берлән сөйләшеп, акыртын гына өенә юнәлде. Ишекне ачты. Түр башында карчыгының бәрәңге әрчеп утырганын күрде. Күзе карчыкның кулындагы былчыранып беткән пәкегә төште. Аның кулында сөннәт пәкесе икәнен күреп, әлгәре катып калды, ахырдан ул җенләнгән кебек булды: кычкырырга, бакырырга тотынды, кулы берлән бәреп җибәреп, пәкене алды, үзе кычкырып еларга тотынды. Аңар әллә кайдан көч керде, кычкырып тиргәргә, кулы берлән бутанырга башлады:

— Чык өемнән, бәдбәхет, чык өемнән! Сәлман Фарси пәкесе, Сәлман Фарси пәкесе! Ни диермен? Кыямәт көнне ни җавап бирермен?! — дип еларга, карчыкның кулына очраган сандыгын, комганын, ястыгын йортка ыргытырга тотынды. Тагы кычкырды, тагы бакырды, тагы елады. Елан чаккан кеше кеби, кая барырга белмәде, елап урамга чыкты. Күршедәге халыкка: «Җәмәгать, җәмәгать!»— дип, бик каты иттереп кычкыра башлады. Бөтен җыен ут-фәлән бар дип, бабайга таба ашыкты. Бабай:

— Менә, җәмәгать, хәзрәт Сәлман Фарси пәкесе!.. Җитмеш мең мөселманның сөннәткә утыртылган пәкесе!.. Хәзрәт Аксак Тимердән калган пәке ул!..

Ул шул сүзне әйткәндә өенә төртеп күрсәтте:

— Шул пәке берлән, хәзрәт Сәлман Фарси пәкесе берлән бәрәңге әрчи!..— диде дә тагы еларга тотынды. Халык бабайны төрлечә бастырырга теләсә дә, бабай һаман кызганнан-кызды. Ул бөтенләй тилергән кеби булды, ул өенә таба барып, йортындагы карчыгын күреп:

— Кит, шайтан!.. Гөнаһ шомлыгы, иблис сидеге, пәри ташландыгы, күземә күренмә!.. Талак син, талак син!..— дип кычкырды. Халык тагын бабайны бастырырга теләсә дә, ул кычкырып еларга тотынды. Тагын әйләнеп карап, карчыкның йорт уртасында торганын күреп, тиздән сикереп торып:

---

1. Мөнкир, Нәнкир — үлгән кешедән сорау алучы фәрештәләр. 2. Яәҗүҗ, мәәҗүҗ — мифик вәхши кабиләләр.

— Әле китмәде шайтан, дәҗҗал! Яэҗүҗ, мәэҗүҗ кыйла! — дип, барып казык алып сугарга күтәрде. Бер кеше, бабайны кочаклап алып, сугудан саклый алды. Карчык урамга чыгып качты. Бабай аның артыннан ястыгын, сандыгын, комганын, туп уйнаган малай кеби, берсе арты берсен ыргыта башлады. Ул тагы еглады, тагы:

— Сәлман Фарси, шәфәгать кыл! Карчыгым бәддогасы, карчыгым бәддогасы!..— дип, халыкка кайгысын аңлатырга тотынды.

Ләкин теге карчык тагы өйгә керергә өлгерә алмады — ул тагы сикереп торып, казыкны күтәрде. Бу юлы сугарга да өлгерде, ләкин карчык качарга өлгерде. Ул тагы кызды, тагы кычкыра башлады. Кулындагы пәкесен кысып, тагы әллә ниләр сөйләргә тотынды. Картлар аны бастырыр өчен төрле сүзләр сөйләргә тотындылар. Ул берсен дә ишетмәде.

Менә бердән аның кып-кызыл бите агарды. Ул калтырана башлады. Ап-ак булып, авызыннан күбеге агып, һушсыз булып егылды. Хәзрәт килеп коръән укыганнан соң, аның һушы килсә дә, теле ачылмады. Пәкене никадәр алырга теләсәләр дә, кулыннан ычкындырмады, ул, күзе белән әллә нәрсә эзләнә башлады, кунакларга әллә нәрсәләр әйтергә теләде, ләкин әйтә алмады. Өченче көнне хәзрәт коръән укып бетереп, янында утырып торганда: «Эти, эти, кунаклар килде!» — дип, этисен чакырып мәхдүм килеп керде. Бабайның күзе нурланды; ул көлгән кеби булды, әллә нәрсә әйтергә теләгәне беленде, күзе берлән мәхдүмне чакырган кеби булды. Мәхдүм акыртын гына этисе янына килде. Бабай, тагы, күзенә әллә нинди мәгънәләр чыгарып, кулын селкетә башлады. Мең бәла берлән кулын күтәреп мәхдүмгә таба төртте. Һәммә кешегә мәхдүмгә пәкесен, үзенчә, иң кыйммәтле булган мирасыннан — Сәлман Фарси пәкесен бирергә теләвен аңлатты. Мәхдүм аптырап калды: хәзрәт алырга кушты. Алды. Бабайның йөзенә көләчлек чыкты. Ул әллә нигә шатланган кеби булды. Тагы бик авыраеп: «Аллаһ!..» — диде дә үлде...

Үзе казыган кабергә иртәгесен аны бөтен авыл җыелып күмде. Күрше карты аның өстенә дә каен илтеп утыртты. Ике каен берберсе берлән бәреләбәрелә, сөйләшә-сөйләшә үсә башладылар.

Көзге яңгырлы җилдә өйнең сылаганы изрәп, ул да җимерелде. Усал сыерлар, канауны җимереп, бакчага кереп йөргәнгә, түтәлләр, бакчалар да кешелектән чыкты. Кызыл миләшләрне җыяр өчен бөтен урам малайлары миләшнең ботакларын сындырып бетергәнгә, ул да икенче елны яфрак ярмады. Корыды.

Бер-ике, өч елдан Сөннәтче бабайның йорты урынында тормыш галәмәтеннән бернәрсә дә калмады. Ләкин зиярәттәге ике картайган, черегән, беткән картларның өстенә ап-ак тузлы, ямь-яшел ике яшь каен үсте. Алар зурайды, биекләнде, түгәрәкләнде; тавышлы, тынлы, кешеләр аңламый торган тормыш берлән яши башладылар.

Бер тормыш бетте, бер тормыш башланды...

Текстны әзерләделәр: **Р. ХАРРАСОВА, И. НУРУЛЛИН.**

# ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ[1]




ке йөз елдан соң инкыйраз»ны язудан максудым милләтебезнең шул китешеннән үземнең разый түгеллегемне күрсәтеп, бу китешнең очы инкыйраз идекен белдерүдер. Бәгъзе[2] кешеләр милләтемезнең шул китешен бик файдалыга санап, шул китештән бик зур өмидләр дә көтәләр. Әмма мин һич андый өмидләр көтәрлек «төпле» бер эш күргәнем юкка, хәзер дә халкымыз арасында сөйләнә торган сүзләргә, эшләнә торган эшләргә вакытлы килгән «бизгәк» дип кенә карыйм. Һәм дә ул сүзләрне сөйләүчеләр, эшләүчеләрнең күбрәк әһәмияте сүздә генә булганга, боларга бер төрле замана модасы төсле генә караганга, бу кычкырышларга «курчак уены» дип кенә исем бирәм. Һәм, минемчә, һәммәсе курчак уеныдыр. Курчак уеныннан бер мәгънәле эш килеп чыкмадыгы кеби, табигый, безнең дә бу «төпсез» эшемездән бер нәрсә чыкмас дип уйлыйм. Бәлки минем бу фикерем хатадыр. Бәлки бөтенләй көлкедер. Ләкин ни булса да, хакыйкатькә бик якындыр, йә хакыйкать үктер. Бу китапта минем милләткә карашым ничек икәнлеге тәмам күрендеге кеби, китмешемезне үзгәртсәк, минем бу өмидсезлегем урынына «өмид» тууы да мөмкин икәнлеге ачык белгертелгәндер. Китабым бик ачы лисан[3] берлән язылмыштыр. Хосусан, халкымыз гыйндендә[4] иң мөкатдәс саналган «голәма»[5] сыйныфына бик каты тукынылмыштыр. Монысы хакында бер төрле игътизар[6] — фәлән язмакчы булып, бу мөкатдимәне каралларга башласам да, үз гыйндемдә иң зарарлы, иң тәрәккыйгә манигъ[7] булулары сабит[8] булган шул сыйныфтан тәнәззел[9] итеп үтенүгә, бердән, вөҗданым разый булмадыгы кеби, икенчедән, каләмем итагать[10] кыйлмады. Фәкать бу хосуста укучыларыма гына бер сүз әйтәсем бардыр. Минем «голәма» сыйныфына каты-каты һөҗүмнәрем аларга үземнең бер гарзы шәхсиям[11] өчен дошманлыгым-фәләнлегемнән түгелдер. Бәлки милләтнең тәрәккыйгә манигъларын эзләгәндә, кайсы яктан караганда да шул «голәма» сыйныфының иң алда кылычын тотып «җәһаләт»не[12] саклавын күрдекемнән, мотлакан[13] аларның вөҗүдләре[14] зарарлы идеке фикере калебемдә бик нык урнаштыгыннан, үзем белгән нәрсәне шундый «тәрәккый милләт» кебек мөкатдәс эшләрдә сакларга, бердән, табигъ[15] булдыгым дин ислам манигъ булдыгыннан,— икенчедән, начарны яхшы, каракны тугъры, зарарлыны зарарсыз итеп күрсәтергә вөҗданым риза булмадыгыннан, һич ригаясез[16]-нисез бары кадәре һәммәсен күрсәттем. Бәгъзе кешеләр, бигрәк «голәма» тарафдарлары бу сүзләремне минем аларны белмәвемә, аларның һәр көнне кылып тора торган яхшылыкларын күрмәвемә хәмел кыйлу[17] ихтималы бардыр. Ләкин бу хатадыр һәм бик зур хатадыр. Үзебезнең өй тарихымыз забыт[18] кыйла башлаганнан бирле атам-анам тарафы мулла була килмеш улдыгы кебек, үзем дә шундый «голәма» кайный торган «Казан»да укыдыгымнан

---

1. Инкыйраз — бетү; 2. Бәгъзе — кайбер; 3. Лисан — тел; 4. Гыйндендә — күзендә, карашында; 5. Голәма — галимнәр мәгънәсендәге бу сүз руханиларга да атама итеп кулланылган; 6. Игътизар — аклану; 7. Манигъ — каршы торучы, киртә; 8. Сабит — шиксез, ачык; 9. Тәнәззел — түбән төшү; 10. Итагать — табыну, буйсыну; 11. Гарзы шәхсия — үзен күрсәтү; 12. Җәһаләт — наданлык; 13. Мотлакан — һичсүзсез, абсолют; 14. Вөҗүд — бар булу; 15. Табигъ — ияруче, буйсынучы; 16. Ригая — хөрмәт, яхшылык; 17. Хәмел кыйлу — йөкләү, юрау; 18. Забыт — кулга кертү, саклау, тоту; 19. Хазир — әзер булып җиткән; 20. Әсарәт — йогынты; 21. Хоббенәфес — үзен ярату; 22. Мөстәгыйть — булдыклы, сәләтле; 23. Мәгъмүр — төзек; 24. Мөсбит — исбат ителгән; 25. Кагыйдәи көллия — гомуми кагыйдә.

башка тормышымда да алар берлә катышуым бик күп булганга, алар хакында минем язган сүзләрем бик белеп, бик озын тәҗрибәләрдән соң язылганга, хата булу ихтималы бик ерактыр. Мин һәр эштә «голәма»ның манигъ тәрәккый икәнен күргәч, милләтне тәрәккый иттерәсемез килсә, аны башка милләтләр арасына кертәсемез килсә, манигъ булган «голәма» сыйныфының сүзенә илтифат кылмаска, үзебезнең штан алудан башлап, кыз бирү, угыл өйләндерү, самавыр тәзәттерү эшләребезгә кадәр катышуларын бетерергә тиешлекне һәм аларның сыйныфларына бер артыклык (привилегия) бирмәенчә, кешесенә күрә генә эш йөртеп, алар хакындагы хазир[19] гавамымызның фикерен үзгәртү кирәкле уена җиттем. Минемчә, хәзер тәрәккый өчен иң кирәкле эш үземезне шул голәманың тәхет әсарәтеннән[20] коткарып, һәр хәрәкәтемездә хөр булмакдыр. Шуннан соң безнең эшләремез рәткә китсә китәр. Әмма ул «голәма»ның кәкре-бөкре фикере белән, хоббенәфесе[21] белән ерракка китә алмавымыз һәммә кешегә мәгълүм бер эштер. Испания кебек дөньяның иң бай, мәдәнияткә иң мөстәгыйть[22] кыйтгасының бу көнге дәрәҗәдә калуына, Бохара кебек шул кадәр мәгъмүр[23] бер мәмләкәтнең иң түбән, иң начар дәрәҗәдә булуына «голәма»ның кәкре-бөкре черек фикерләрен үзләренә юл күрсәтүче дип тануларыннан башка бер сәбәп юктыр. Һәр диндә, һәр халыкта «дин голәмасы» исемендәге халыкның манигъ тәрәккый икәнлеге мөсбит[24] бер хакыйкать булгач, безнең голәмамыз гына ул кагыйдәи көллиядән[25] чыкмаячаклардыр. Шуның өчен без хәзер аларның сүзләренә илтифат кылмаенча хәрәкәт итик, без аларны приговор биреп, үлегемезне күмәр, туганымызга исем кушар өчен билгеләгәнмез. Һәм аларга шуннан үтәрлек бер хак бирергә хакымыз да юктыр. Бирсәк тә, үземезгә аннан зарардан башка нәрсә булмаячактыр.

Манигы тәрәккыйнең икенчесе — мәдрәсәләремезнең, мәктәпләремезнең юклыгы һәм дә барларында укыла торган гыйлемнәрнең эшкә яраксыз бер чепухалар булуы, вә мәдрәсә-мәктәп эшләренә әһәмият бирмәвемездер. Моның да сәбәбе баягы «голәма»ларга ышануымыздан һәм дә аларның шул эшне эшләргә сәләхиятле түгеллеген белә торып, шул кадәр мөкатдәс эшләрне аларга тапшыруымыздандыр. Тәрбия ни? Уку ни? Укыту ни? икәнлеген белмәгән кешеләргә шул эшне тапшыру һәм көлке, һәм кайгылыдыр. Бу мәсьәләне уйлаганда һәрвакыт минем хәтеремә русларның иң бөек мөхәррирләреннән, иң зур психологларыннан Тургеневның: «Все это было бы смешно, когда не было бы грустно!»[26] дигән сүзе исемә төшә дә, бу эш хакында шуннан да мәгънәле сүз әйтергә таба алмаенча, телемдә шул шигырьчекне әйләндерергә тотынам. Мин бу мәсьәлә хакында еглыйм да, көләм дә. Ләкин һич берсеннән файда чыкмадыгы кебек, миннән соң килә торган әрбаб хәмияткә[27] еларга да, көләргә дә бер эш булсын өченме, мәсьәлә һич үзгәртелгәнлеге юклыгыннан башка, аның хакында уйланганы да бик аздыр.

Өченче манигы тәрәккый — һәм дә иң сизелә торган манигы тәрәккый — милләтемездәге хезмәткә ярарлык кешеләрнең һәм хезмәт итә торганнарның, бик фәкыйрь сыйныфтан чыгып, үзләренең тамакларын туйдыру өчен, милләткә хезмәт итәр урнында, иң сәфил[28] кешеләрнең тәхте әсарәтендә изелүләредер. Бусы бик аяныч вакыйга һәм бик кәефсез хәлдер. Хәзерге күзгә күренгән әрбабе каләмнең[29]

---

26. «Все это было бы смешно, когда не было бы грустно — Моңсу булмаса, болар көлке булыр иде»,— М. Ю. Лермонтовның «А. О. Смирновой» дигән шигыреннән алынган өзек. 27. Әрбаб хәмият — яклау, саклау әһелләре. 28. Сәфил — түбән. 29. Әрбабе каләм — каләм әһеле, язучылар. 30. Затән — асылыннан. 31. Русия уртасындагы мөселманнар тарихча «болгар» халкыннан булып, татарлар боларга килеп кушылган гына булганга, бу китапта «болгар» исеме белән йөртәчәкмен (Гаяз Исхакый искәрмәсе — редакция).

һичберсе юк ки мөстәкыйлән хәрәкәт итә алсын. һәммәсе үз тамагын туйдырыр өчен, үзенең урынын саклар өчен, шундый кешеләрнең башмакчысы булырга ярамаган кешеләрнең кулларында уенчык булып йөриләр. Иң каефсез ягы боларны бу әсарәттән кортырлык бер җайның күренмәве һәм дә булганы бер шул әсарәткә төшә баруыдыр. Милләтнең алдан бара торган кешеләре һәм халыкка караңгы юлда ут күрсәтә торган затлары, үзләренең утларын сукырларның күзләренә, каефләренә зарар итмәс өчен, я бөтенләй күрсәтмәенчә, халыкны караңгылыкта калдыралар, яисә тычкан уты төсле генә якты биреп, халыкны караңгы төндә адаштыралар гынадыр. Бу мәсъәлә затән[30] иң әһәмиятле, иң зур фикер сарыф кылына торган эштер. Ләкин бу эш, безнең болгарларның[31] бәхетсезлегенә, башка милләтләрнең хилафына булгандыр. Башка халыкларда күбрәк әрбаб хәмият, бигрәк әрбаб каләм зур байлардан вә зур дәрәҗәле затлардан чыкмыштыр. Әмма бездә бер артык сүз ычкындырса, шуның җәзасы ничә айлар ач йөрергә мәҗбүр була торган, яисә шул сүз өчен бөтен халыкның күзеннән төшеп, үзенең кечкенә бер эшенең дә артка китүенә сәбәп була торган сыйныфтан килмештер.

Дүртенче манигы тәрәккый — безнең рус мәктәпләрендә укымавымыз, бу көнгә кадәр үземезнең мәдрәсәләремез юк икәннеген белмәвемез, һәм дә үземезнең бик надан, к.. юу кагыйдәләреннән бик аз үтә алуымызны икърар кылмавымыздыр. Бу эш безнең китешемезгә бу вакытка кадәр бик зур зарар иттеге кеби, киләчәктә дә манигъ булачактыр. Чөнки халкымыз арасында иң аңлаган дигәннәремез дә бу көнгә кадәр хөкүмәт мәктәпләрендә укудан качалар һәм качыралар. Мин бу эшнең бер дә сәбәбен белмәсәм дә, бик кайгырам. Минемчә, бик кайгырырга тиеш мәсьәлә һәм тизрәк шуның манигъларын бетерергә тырышырга кирәкле мәсьәләдер. Безнең Русия идарәсенә табигъ булганымызга өч йөз илле ел булса да, шул озын гомердә руслардан файдадан башка һич нәрсә күрмәсәк тә, бу көнгә кадәр безнең Русия идарәсенә табигъ икәнлегемезне белмәгәнләремезнең саны чиксез булдыгы кебек, руслардан әллә нинди куркып, аларның һәммә эшләренә шикләнеп караучыларның исәбе-хисабы юктыр. Бу безнең милләтемезнең китеше өчен һәм ватанымызның файдасы өчен бик зарарлы эштер. Шуның өчен бу эшне бетерергә хөкүмәт тә, әлбәттә, бик нык бил баглап тырышырга тиештер. Ул болгарлар арасында рус лисанын[32] тарату, рус әдәбиятына мәйдан бирү һәм дә болгар әдәбиятына юл ачу берлән була торган эштер. Болгар әдәбияты болгарларның иң аңлаган кешеләренең калепләреннән чыкканга, аларның күңелләрендә русларга ышану тәмам урнашканга, алардан һич куркырга ярамыйдыр. Бу әдәбият руслар берлән болгарларны якынлаштыруында, бик күп кеше тарафыннан укылып, бик күп кешенең фикеренең тиз ачылуында сәбәп булуында шөбһә юктыр.

Бишенче манигы тәрәккый — эшләгән эшләремезнең һәммәсенең төпсез, әссасыз[33] булуыдыр. Безнең һәммә эшемез бу ел булса, киләсе елга юктыр.

Моның сәбәбе — бәгъзе кешеләремез, димагымызның[34] шундый косур[35] берлән яратылуыннан дисәләр дә, минемчә, монда да эшкә өйрәнмәгәнлегемезнең бик күп зарары бардыр. Бу безнең һәр хәрәкәтемездә күренә торган авырудыр ки, мотлак моның дәвасын табып, бу бәладән котылырга тиештер. Бер авылда ачылган мәктәп бер сәнә дәвам итә, икенче сәнәсендә бөтенләй ташлана, бер мәктәпкә кергән шәкерт бер ел укый да, икенче сәнә чыгып, бер эшкә тотынган була, икенче елны ансын да ташлый; бу эшләр һәммәсе безнең күз алдымызда һәр көнне күренеп тора торган бер эштер. Тагы бездә бер эш бар — һәммә кеше бик зур эшләмәкче була, әгәр ул эштән ул теләгән кадәр үк зур эш чыкмаячагын белсә, хәзер ташлый, тагы бик зур файда күрелер төсле булган эшкә тотына, аны да күрә дә,аны да ташлый.

Әмма акыртын гына эшләп, озын гомердә бер әсаслы нәрсә чыгаруны без яратмыймыз да, теләмимез дә. Безгә булса тиз булсын һәм файдалы булсын. Без бер ел русча укып университет правасы алырга тырышамыз, ике ел укысак, бер-бер мәхкәмәдә[36] унбиш сумлык писарь булып, милләткә бик зур хезмәт иткән кеше кебек, бик вакарь берлән генә хәрәкәт итә башлыймыз. Менә шул эшләрнең һәммәсен мин инкыйраз галәмәтләре дип уйлыйм. Шул сәбәптән мин һәммәмезгә шул эшләрне рәтләргә тиеш дим һәм аңлаган кешеләргә фарыз[37] дәрәҗәсендә үк дим. Әгәр дә тәрәккый итик дисәк, һәммәмез милләтнең иң кирәкле эшләренә тотыныйк һәм шундый кешеләргә ярдәм итешик. Барымыз, аңлаганнарымыз бергә бер юл берлән хәрәкәт итик, һәммәмезнең теләгәнемез бер, һәммәмезнең эстәгәнемез бердер. Тырышыйк, авырлыклар күтәрик, бер нәрсәмезне дә кызганмыйк, менә шуннан соң милләт милләт төсле булса булыр. Югыйсә чәй янында варенье белән азрак исереп, милләтнең истикъбальләрен[38] сөйләүдән берни чыкмый. Агачтан җимеш алыр өчен, аны орлыктан чәчеп, һәр көнне никадәр хезмәт сарыф кылып, ничә еллар тырышканнан соң гына максудка ирешәләр. Без дә шулай итик. Бүген чәчеп, иртәгә алма җыярга тубал күтәреп чыкмыйк. Һәм алмасы булмаса, агачны бәреп-сугып бетермик, тагы хезмәт сарыф кыларга тотыныйк: бара-тора вакыты җиткәч, алмасы да булыр, файда да булыр. Бу китапта язылган сүзләр теләсә бик ачы булсын, теләсә бик төче булсын, минем калебемнән кайнап-кайнап чыккан мәгънәләрдер. Әчеләре дә күз яше беткәннән соң, еглый-еглый арганнан соң, ни белән дә күңелне тәгъбир[39] кыйлырга мөмкин булмагач, көлке белән тәгъбир кыйлынган хакыйкатьтер. Һәм дә ул көлгән гыйбарәтләрне чыгарырга элгәре бик күп яшьләр сарыф кылынганга, алары үз гыйндемдә төчеләреннән дә кыйммәтледер. Һәм дә төчеләреннән дә тәэсирле булырга тиештер.

*Мөхәммәт Гаяз*

> Иншә алла әл-рәхман.
> Алла насыйп итсә, Шаһмөхәммәт Ишмукаев никях мәҗлесенә кәрәм кыйлуыгызны үтенәдер. Чаһәршинбә көн иләдән чыгуга, әмма сәгать икедә никях укылыр. 12 сентябрь, 1800 сәнә,

дип таралган дәгъвәтнамә мөҗибенчә,[40] Шаһмөхәммәт байларга чаһәршинбә көн никях мәҗлесенә халык җыела башлаган иде. Шаһмөхәммәт байларның өендә дә туй яраклары, мәҗлес кирәкләре хәзерләнгән иде. Менә хәзрәтләр күренде. Әлмөхәммәт хәзрәт, Әхмәтша хәзрәт, Вәлиулла хәзрәт, Зәки хәзрәт, Җәмал мөәзин, Хәким кари, Мәрдән суфи бер-бере артлы бай өенә таба киләләр иде. «Туйлар мөбәрәк булсын, Шаһмөхәммәт!» «Әйе, шулай булсын инде»,— дигән догалар берлән хәзрәтләр эчкә керделәр. Аннан да атлы килеп чыга, моннан да килеп чыга иде, күренгәне бере Шаһмөхәммәт байларга килеп сәлам биреп, «Туйлар мөбәрәк булсын!»— сүзләре берлән эчкә юналәләр иде.

Кунаклар килеп бетә язган иде. Бары Фәхри кода, Шаһмәрдән ишан берлән Гали бай гына калганнар иде. Озак үтмәде, камчат бүректән Фәхри кода, саури читек, саури кәвеш, яшел чапан, яшел чалмадан Шаһмәрдән ишан да баягы «Туйлар мөбәрәк булсын!»ны әйтеп, эчкә кереп киттеләр. Пар тимер-күк атларда озакламаенча Гали бай килде.

Шаһмөхәммәт байларның йортларыннан арткан ат берлән генә

32. Лисан — тел. 33. Әсас — нигез. 34. Димаг — ми. 35. Косур — кимчелек. 36. Мәхкәмә — суд. 37. Фарыз — эшләнергә тиешле (эш). 38. Истикъбаль — киләчәк. 39. Тәгъбир — әйтеп бирү. 40. Мөҗип — сәбәп.

дә урам бөтеннәй тулган иде. Капка төбендә карарга килгән кешенең дә исәбе-хисабы юк иде. Кодалар килеп беткәч, Ишмукаев үзе өйгә кереп китте.

Өч катлы таш өйнең һәммә җирендә мәҗлес хәзерләнгән иде. Шаһмөхәммәт бай залны бер кат күздән кичерде. Ике табын хәзрәтләр, ике табын кодалар берлән зал шыгрым тулган иде. Гостинный, түбән өй, чарлакны һәммәсен карады, күп кешеләр берлән исәнләште, күп кешедән: «Туйлар мөбәрәк булсын!»— сүзен ишетте. Кирәкле кешеләр беткән төсле күренде. Һәм дөресе дә беткән иде. Шаһмөхәммәт, карап бетергәч: «Хәзрәтләр! Эш тәмам инде»,— диде.

Мәхәллә хәзрәте Әхмәтша мулла да тамагын кырып; «әһәһә» дип: «Соң инде укыйкмы, Фәхри агай?»— диде. Фәһри: «Әйе, хәзрәт, укыйсыз инде, Шаһмөхәммәт кызы Айсылуны минем углым Бикбауга никях укыйсыз»,— диде. Фәхри бай бу сүзләрне әйткәндә бөтен мәҗлес акыртын гына елмайганнар иде. Шаһмөхәммәт: «Ун мең мөһер, һәммәсе тәмам»,— диде. Бу сүз соңыннан хәзрәт, шаһит-фәлән дигән сүзләрне сорамаенча ук, гүя, аңарга кадәр кыз да, кияү дә ризалыкларын барып әйткәннәр кебек, Шаһмәрдән ишанга күзенең бер очы берлән карап, башын бөкте. Ишан хәзрәт: «Үзегез укыңыз, мулла Әхмәтша, үзеңез!»— дигәч, Әхмәтша хәзрәт тагын бер «Әһәңәһә» дип, «Әлхәмделилля» дип башлады, бикләгән бер сүзен дә калдырмады, коръән газыймдан «Вә ин хифтөм әля тәгъдилү»* аятен калдырса да, «мәсна вә сөляса, вә рабиг*»ны бик сузып-сузып, үзенә бер дәрт берлән укыды, никях та бетте.

Фәхри кода берлән Шаһмөхәммәт бай да хәзрәтләр табынында кулларына акча тотып, алды-артлы әйләнеп чыктылар. Биргән сәдакалар Шаһмөхәммәт байның, Фәхри коданың йөзләрен кызартырлык түгел иде — хәзрәтләргә иллешәр (!!), мөәзиннәр, кариларга да егерме биш сум иде. Мәҗлес башланды, кашык, тәлинкә кузгалды, бөтен өйдә чыкыт-чыкыт кашык, тәлинкә тавышы иде. Озак үтмәде, бу моңлы тавыш та бетте. Акрын-акрын ашлар килә башлады. Килгән аш саен Шаһмәрдән ишан яисә хәзрәтләрдән берсе тарафыннан: «Бәрәкалла, ашны бик зур хәстәрләгән икәнсез, мулла Шаһмөхәммәт»,— дигән сүз үзенә бер төрле тавыш берлән әйтелә иде. Ләкин бу сүз Шаһмөхәммәт байның да, Фәхри коданың да күңеленә электрик төсле тәэсир итеп, ике кода да тиреләренә сыймас дәрәҗәдә кәефләнәләр иде. Хәзрәтләр дә белми әйтмиләр лә инде! Укыган кешегә һәммәсе билгеле, кодаларның бу кадәр кәефе киләсен белмәсәләр яки бөтенләй әйтмәсләр иде, яисә кәеф таба торган икенче сүз табырлар иде. Мәсәлән, бер дә булмаса: «Мулла Шаһмөхәммәт үзеңә аллаһетәгалә вә тәбарәкә яшь кызлар алырга язсын, абыстаң әле сөйләп тора иде, әһә-һә, яхшы инде, тынычлык берлә торырга язсын!»— диярләр иде. Мәҗлес бик зур корылган иде. Казан ашларының һәммә төрлесе булдыгы шикелле, кондитер ашы берлән дә дөнья тулган иде. Аш артыннан аш килеп, ахырында ширбәт килде. Һәммә кеше бер-берсенә карап, елмаешып, кесәләрен актара башладылар. Бөтен мәҗлесләрдә акча тавышы купты, шотыр-шатыр иткән кәгазь тавышы берлән сирәк-сорак чылтыраган алтын тавышлары бөтен өйне тотты. Озакламады, һәммә тәлинкә өем-өем акчалар берлән хатын-кыз ягына юнәлә башлады. Фатихадан соң хәзрәтләр баягыча кодаларның тәненә тәэсир кылырлык, ата күркәдән зур иттереп кабартырлык сүзләр әйтеп чыгып киттеләр.

Кунаклар таралуы бик хозур булды, һәммә кеше үз танышы берлән көлешә-көлешә, Айсылу белән Бикбауга мәхәббәт теләп чыгалар

---

* «Вә ин хифтөм әля тәгъдилү»— гаделлек кылудан курыксагыз. «Мәсна вә сөляса, вә рабиг»— икәү һәм өчәү, һәм дүртәү (шәригатьнең ике, өч һәм хәтта дүрт хатын алырга рөхсәт итүе күздә тотыла.)

иде. Хәзрәтләрдән андый сүз ишетелми иде. Алар аның урынына, «ихсанлы[41] кеше, ихсанлы кеше» дип, кесәләрендәге акчаларны капшыйкапшый сөйләшеп чыгалар иде.

Ләкин ишегалдына чыккач та китәргә булмады, чөнки Шаһмөхәммәт кода кучерларга өчәр тәңкә акча, бирәр булки, бирәр яулык өләшә иде. Дөрес, аны элгәрерәк өләшеп бетерергә мөмкин иде. Шаһмөхәммәт бай һәммә кунак алдында акча кызганмаганын күрсәтер өчен шулай иткән иде. Озак үтмәде, Шаһмөхәммәт бай, эшне бетереп, кунаклар янына килде. Күзләре ут кебек уйный. Һәммә кешенең йөзенә караганда: «Менә абзаң ни эшли!»— дигән төсле иттереп карый иде. Шаһмөхәммәтнең бу эше дә тәбриксез калмады, ишан хәзрәт: «Һиммәтеңә рәхмәт, мулла Шаһмөхәммәт!»— диде. Шаһмөхәммәт, «әһә-һә» дип, хәзрәтенең ни әйткәнен аңламыенча, «Шулай булсын инде, хәзрәт, шулай»,— диде. Акыртынлап кунаклар тарала башлады. Кунаклар арасыннан: «Байлык ни эшләтә!! Курчак туена* никадәр расход!! Ике яктан кырык мең, кеше үз кызын биргәндә дә алай расход тота алмый, ай, байлык яхшы нәрсә соң»,— дигән сүзләр ишетелә иде. Әман[42] йа раббым, кырык мең тәңкә! Курчак туена кырык мең теңкә?! Кем әйтеп, кем ышаныр бу сүзгә? Ләкин ышансаң-ышанмасаң да, бу курчак туе иде. Һәм чыккан расход та кырык мең иде. Сез: «Бу эшләр ни өчен? Ник курчак туена кырык мең?! Бу эштән кемгә файда булды? Әллә гомум милләткә бер-бер файда бармы? Ник болай иткәннәр?»— диярсез. Мин тагы: «Бу туй курчак туе иде, чыккан расходы кырык мең иде»дән башка җавап белмим. «Кырык мең!! Кырык мең!! Бер файдасыз кырык мең!!»— дисезме? Без элгәре үзебезгә кәеф килерди җирләрдән кырык меңнәрне кызганмый идек (Бу туй үзе зур дәлил).

Күпме расход чыкса да чыкты, туй үтте. Шаһмөхәммәт бай берлән Фәхри дә читтә: «Менә акчаны кызганмыйлар, курчак туена кырык мең тотканнар»,— дигән зур ядкяр калдырдылар. Ләкин озак үтмәде, бу сүз аларны мактар өчен булмаенча, яманлар өчен әйтелә башлады. Сөекле укучы бәлки бу эшкә гаҗәпкә дә калыр, хакы да бар. Ләкин һәрхәлдә бу эш мөхәррирнең үз хыялы түгелдер, вакыйгадыр. Һәм гаҗәплегендә дә гаепле мөхәррир түгел, бәлки вакыйганың үзе. Һәм дә сезнең бу эшкә егерменче гасыр күзе белән каравыңыздыр. Безнең эшләремез арасында унтугызынчы гасырда эшләнгән эшнең егерменче гасырда көлке булуы ис китә торган бер эш түгелдер, безнең һәммә эшемез шулай, унсигезенче гасырда эшләгәнемез унтугызынчы гасырда көлкегә калмыш, унтугызынчы гасырдагы эшемез — егерменче гасырда; егерменче гасырдагы эшләремез дә егерме беренче гасыр кешеләренә көлке булуында да шөбһәм ерактыр.

Һәр нә булса булды, туй бетте. Күп вакыт үтмәде, әлеге Шаһмөхәммәт бай да, Фәхри кода да, баягы кырык меңне икенче мәртәбә күрә алмаенча, дөресе генә, кирәкләренә тотарга да таба алмаенча вафат булдылар. Сез инде нигә ул кадәр үз хәлләрен белмәенчә, киләчәкләрен уйламаенча кыланганнар диярсез. Эшләгән эшләремезнең ни өчен, ник икәнлеген белмәенчә кыйлануымыз болгарларның искедән калган табигатедер. Әгәр бу табигать бездә булмаса иде, белмим, без хәзер нинди милләт булыр идек икән? Бабайларның «үткән эшкә салават» дигән сүзләре белән күңелемезне юатыйк та эшемезгә тотыныйк. Унтугызынчы гасырда бер курчак туе кырык мең булдыгы шикелле, җанлы курчаклар туе да кырык мең белән калмаенча, сиксән меңгә бик еш җитә иде. Заманасына күрә гадәте, гадәтенә күрә кешесе, кешесенә күрә гакылы, уе, күрәсең, инде. Югыйсә безнең заманда ул кырык меңнәр (!!), сиксән меңнәр (!!) курчак туена тотарга түгел, үзе-

41. Ихсан — ярдәм итеп бирү. 42. Әман — иминлек, тынычлык.

* XIX гасыр ахырларында кайбер татар байлары, байлыгын күрсәтергә сылтау итеп курчакны курчакка өйләндергәннәр, ягъни курчак туе ясаганнар.

мез өчен иң кирәкле, милләтемезнең җаны диярлек дәрәҗәдә булган мәдрәсәләр, мәктәпләр салыр өчен дә юктыр.

Еллар үтә бара, халык арасында мода үзгәрде. Байларымызның камчат бүрекләре кечерәйде, бикәләремезнең ак калфаклары кыскарды. Әмма расход көннән-көн арта иде, мода кирәкләре дә, белмим, сәгате саен үзгәрә иде. Сез ул вакытта: «Голәмалар ни эшли иде? Халыкка бу эшләрнең ярамавын, болай кылансак, киләчәктә милләтемезнең бетү ихтималын сөйләп, мондый эшләрдән тыелырга вәгазь кылмыйлар идеме?»— диярсез. Мин әйткән идем ләбаса Фәхри белән Шаһмөхәммәткә вә аның төслелләргә «бәрәкалла һимматеңә» диләр иде дип. Ләкин озак үтмәенчә, голәма арасында икенче мәсьәлә чыкты — дин мәсьәләсе. Ул да: «Безнең болгар йортында ястү (ясигъ) намазы фарызмы, түгелме? Вакыт керәме, юкмы?»— мәсьәләсе иде. Бөтен болгар голәмасы шуның белән мәшгуль булдылар. Һичбер мәҗлестә шул мәсьәлә чыкмый калмады. Һәм дә һәр почмактан «ля нөсәлләм ләм ләйҗүз, мәмнугъ» дигән сүзләр ишетелгән кеби, әфьюнле баштан акыллы вә ныклы дәлилләр дә агып кына тора иде. Бу мәсьәлә көннән-көн халык арасында җәелә иде. Көннән-көн ике тарафның да сүзләргә сүзләре күбәя иде.

Ниһаять, һәр мәҗлес салада казна җыены хәлен алды. Йомшаграк кешеләр һичбер мәҗлестән башларын авырттырмаенча чыга алмыйлар иде. Бер мулла бер көнне бер тарафта булса, икенче көнне икенче тарафта була иде. Алай булса да, бер мәсләксез, сәбәпсез түгел иде. Вак салган көнне ястү тиеш түгел ягында, әфьюн салган көнне мотлакан кирәк, хәтта, кирәк түгел, дигән кешеләрне тәкфир[43] кыйла иде, йә билгакес[44] иде. Шаһмөхәммәт белән Фәхри булмасалар да, алар төсле-ләр тагы бар иде. Алар голәмалар арасында чыккан бу икенче курчак туена бик кәефләре килә иде. Расходы курчак туе төсле үк түгел, кызыгы һаман кызык. Шуның өчен бу байгуралар бик еш мәҗлес ясыйлар һәм муллаларның сазлы күлдә чыккан бакалар тавышына охшашлы кычкырышларын , низагъларын бик кәефләнеп, коруне вәсата[45] патшаларының җарияләре җырлагандагы кеби, башларын селкә-селкә тыңлап торалар иде. Ниһаять, бу эш бик зур иде. Бәлки моңарга тотылган расходлар да курчак туеннан ким булмагандыр. Голәмалар арасында низагъ купты, дошманлык артты. Һәр тараф рисаләләр яздылар һәм ике як та, үзләренең — хак, тегеләрнеке — хата, дип кенә калмаенча, кяфергә, иманга барып җиттеләр. Сез тагы бу тавышлар, бу низаглар, бу расходлардан гомумгә ни файда килде дисезме? Тагы шул сөаленезне китерденез. Әйттем түгелме соң, без андый эшләремездә гомум милләт файдасын, яки башка бер файданы күзәтмимез, ул безнең бабайларның иске гадәте, дидем ич, тагы ни кирәк инде?

Бу вакытларда халык арасында мәсҗет бина кылына башлаган, мәдрәсәләр ачылып, дәрес әйтелә, сабак укыла башлаган иде. Ләкин мәдрәсәләремез, мәктәпләремездә ни өчен, ник укылдыгы игътибарга алынмадыгы өчен, шәкертләремезнең гомеренең күбесе үзләренә кирәкмәс нәрсәләр уку берлән әрәм була иде. Милләтнең рәфаһ[46] хәле өчен иң лязим[47] булган әхлак, хөсен[48] мөгамәләгә һич әһәмият бирелмәдеге өчен, шәкертләремез бер милләтнең башчысы булу түгел, хакыйкать бер эшкә ярамый торган кеше булып чыгалар иде. Бу кешеләр үзләренең тәрбияләре җитмәгәнне белмәү белән генә калмаенча, мәдрәсәләр, мәктәпләрдә дә тәрбия кылган булып милләтнең балаларын кешелектән мәхрүм кылалар иде. Шул кешеләр зәһре белән милләтемезнең күпме кешеләре, бөтен нәрсә хакында ялган уй берлән торып, дөнья вә ахирәткә үзләренә бер төрле нәзар[49] кылып, хәтта үлеп тә киталәр иде. Һәрвакыт дөрес әйтүдән яхшы эш юк. Бу муллалар хакында да дөрес әйтергә кирәк. Йөздән туксан бише мин әйткәнчә кешеләр булса да, бер-никадәр инсаннар, заманасына ярарлык тугры фикерле кешеләр дә

булганнар. Ләкин бунлар бик аз булдыкларыннанмы яисә үз фикерләрен сөйләргә батырчылыклары булмавыннанмы, халык арасында кирәге кадәр үз фикерләрен тарата алмаганнар. Кәсеп бу вакытта заманасына күрә ярый иде. Бу турыда голәмалар ни кадәр «Алла рәззак,[50] садака бирергә кирәк, кәсеп белән табармын димә, кяфер булырсың», кебек кәсептән ихлас кайтара торган сүзләрне «китап әйтә» дип, ялгыш халыкка сөйләсәләр дә, бабайларымыздан калган сату итү, алыш-биреш итүне бетерә алмаганнар иде. Шуның өчен болгар сатучылары Азиянең һәммә тарафларына китеп-китеп зур сатулар итәләр иде. Ләкин боларның сатуларының файдалы булуы ни өчен, ник икәнлеген белеп эш йөртүдән түгел иде. Бәлки Азия халкы белән катышып сату итәргә кеше булмаудан һәм ватандашларымыз русларның әсарат тәхетендә изелеп ятулары сәбәбеннән, андый эшләрне эшләү бик аз гынасының көченнән килүеннән иде.

Һөнәр дә заманына күрә ярарлык дәрәҗәдә иде. Хәтта болгарлар тарафыннан никадәр заводлар, фабрикалар да ачылмыш иде. Һәм бу фабрикалар, заводлар рус фабрикаларыннан ким эшләмиләр иде. Иген игү, ашлык чәчү, мал асрау заманына күрә ярый иде, ягъни бу эшләрне эшләүдә алга киткән булмасалар да, русларга караганда артка да калмаганнар иде. Замана үтә бара, халык арасында тәбәдделләр[51] күренә башлады. Русларның яңа низам белән ачылган мәктәпләре балаларны икенче төрле фикер белән тәрбия кыла башладылар. Һәм озак үтмәде, русларда һәр сыйныфның үзенә күрә мәктәпләре тәэсис ителде. Рус милләтенә икенче рух бирелде, рус дигән гонван[52] мөкатдәс саела* башлады. Озакламады, һәр эштә яңа фикерле, яңа мәгълүматлы руслар мәйданга чыкты. Болар кирәк тиҗарәттә,[53] кирәк башка кәсепләрдә үзләренә кирәкле гыйлемне белдекләре өчен, болгарларның кәсепләренә бик зур зарар иттеләр.

Чөнки болар үзләренең эшләренең ник, ни өчен икәнен белеп эшлиләр иде. Әмма безнең мәдрәсәләремез һаман шул иде. Фикеремез һаман шул иде. Дөньяга нәзарымыз һаман шул иде!!!

Русларның бу эшләрен күреп, алар артыннан бара башламадык. Бәлки бабаларымыз гадәтен югалтмыйк, дип кирәкмәс гадәтләремезгә чормалып яттык. Голәмаларымыз бәгъзеләремезнең, руслардан гыйбрәт алып, үзләренә кирәкле фән тәхсил кылуларын күреп яки хөкүмәт мәктәпләрендә укуларын белеп, «замана бозылды, бу эшләр һәммәсе ахырзаман галәмәте», дип кычкыра башладылар. Һәм бу сүзләрнең һәммәсен дә дин исеменнән әйттекләреннән халкымызның бик күбесе бу эшләргә, ягъни хөкүмәт мәктәпләрендә тәхсил кылуларына дингә мохалиф эш дип каралуына сәбәп булдылар. Озак үтмәде, болгарлар өчен русча тәхсил кылырга мәктәпләр ачылды. Халыкта тагы яңа фикерләр йөри башлады. Шәһәр халкы, авыл халкы, голәмасы — наданы моңарга каршы килделәр. Һәммә мәҗлестә тавыш, һәммә мәҗлестә шуның хакында низаг иде, халык арасында тагы дин мәсьәләсе чыкты. Голәма арасында дин нoктаи нәзарыннан русча уку хәраммы, мәкруһмы,[54] мөбахмы[55] мәсьәләсе өченче курчак туе булды. Бу мәктәпләрдә ни укылганын белмәенчә, бәгъзесенең авызыннан хәрам, бәгъзесенең авызыннан көфер дигән сүзләр чаткы кебек оча иде (голәмалар арасында мөбах, фарыз дигәннәре дә бар иде). Шул хосуста халык арасында ялган хәбәрләр тарала башлады. Кечкенә бер сүз, мәсафа[56] ераклангач саен үсә-үсә, коточкыч була иде. Мәктәпләрдә дин укыталар, һәммә кешегә русча уку лязим булачак, имеш, мәдрәсәләр ябылачак, мәсҗетләр ябылачак! Балаларны көчләп алып, русча укытачаклар!!! Фәлән

---

43. Тәкфир — кяфер ясау. 44. Билгакес — киресенчә. 45. Коруне вәсата — урта гасырлар. 46. Рәфаһ — муллык. 47. Лязим — тиеш, зарур. 48. Хөсен — матур. 49. Нәзар — караш. 50. Рәззак — ризык бирүче. 51. Тәбәддел — үзгәреш. 52. Гонван — атама. 53. Тиҗарәт — сәүдә.

* Саелу — саналу.

шәһәрдә бер кешенең улы русча укыган икән!...... Фәлән муллага килгән рус та, сезнең дин ни, безнең дин ни, барыбер бит, дигән ди, әман йараб, бу ни куркыныч хәбәрләр?!! Минә әле күрше хатыны да кунакка барган җиреннән балаларны төяп киткәнне ишетеп кайткан!! Галәви ишан, ахыры яхшы булмас, ди! Һәммә өйдә күз яше, һәммә өйдә хәсрәт... Шәһәрләрдә халык сату итү, кәсеп итүне ташлады. Сала халкы, шәһәрләр ни эшләр икән, дип һәр көн хәбәр көтәләр, һәр көн хәбәр алалар. Әман йа раббым! Тагын кара хәбәрләр!!! Бер солдат хезмәттән кайткан, баяры бер кенәгә күрсәткән ди, анда бервакыт һәммә халык бер диндә булыр, дип язылган ди. Ахырзаман! Ахырзаман!!

Шәһәрләрдә мәсҗетләргә җыела башладылар. Салаларда җыен ясадылар. «Прашиние бирик! Прашиние! Падишаһның үзенә бирик. Ас, кис, без үз динемезне ташламыйбыз. Приговор, депутат, Петрбург!» һәммә кешенең авызында кайный иде. Озакламадылар, Русиядә булган һәр мәхкәмәгә (волостной судтан сенатка кадәр) прошение яудыра башладылар. Һәммә җирдә бер тавыш, һәммә җирдә бер сүз иде. «Ас, кис, үз динемезне ташламыйбыз!» — һәр прошениедә язылган иде. Хөкүмәт бу эштән гаҗәпкә калды. Халык арасыннан бу фетнәне бетерергә кеше җибәреп, хөкүмәтнең һичбер андый фикере юклыгын бәян кылдырды. Халыкта икенче тавыш чыкты. «Русча укылмасын! Динемезне ташламыйммыз! Ас, кис!..» Яңадан прошение! Яңадан депутат! Хөкүмәт тагы: «Русча укыган кеше укый, укымаганга көчләү юк! Ул да сезгә файда өчен, эшегез, кенәгез рус белән булгач, русча белү кирәк иҗ»,— дип халыкны йомшартты. Озак үтмәде, тагы хәбәрләр. Әман раббым! Тагы нинди куркынычлы хәбәрләр!

Фәлән авыл да чиркәү салырга приговор сораган! Фәлән авылда учитель алынган, фәлән авылда училище салынган! Тагы күз яшьләре! Тагы аһлар!.. Тагы хәсрәтләр! Хәтта мич башындагы картлар, карчыклар да бу хәбәрне ишетте. Алар да кайгырды. Һиҗрәт![57] Моннан китү! Монда ничек торырга кирәк!?! «Ас, кис, динемезне ташламыйбыз!..» Аннан да приговор, моннан да приговор: яңадан прошение! Яңадан фетнә! Һәммә халык нишләрен белмәенчә, әйберләр сата, юлга хәзерләнә башлады. Аннан берсе китәргә план язып чыгара, моннан берсе Мәдинәдәге булмаган Габдулла шәех исеменнән хәзер күчү фарыз икәнлеген язып тарата. Тегеннән берсе Истанбулда тормышның җиңеллеген, солтан тарафыннан фәлән нәрсә бирелә, фәлән нәрсә бирелә, дип үзеннән үрдәк очыра иде. Анда бер мәҗнүн төш күргән! Икенче җирдә бер карчык үлгән вакытында улына кулы белән кыйбла тарафына изәгән!!! Һәммәсе китәргә дәлил иде. Голәмаларның бәгъзесе, рус мәктәпләрендә тәхсил кылган кешеләргә һич курку юклыгын, һичбер вакыт дингә тиелмәячәген сөйләп, халыкка нәсихәт бирсәләр дә, икенче кешеләр тарафыннан бу сүзләр күңел каралудан гына сөйләгәнлекне риваять кылынадыр иде. Ниһаять, халыкның бик күбесе юлга хәзерләнде. Малларын-туарларын саттылар, җиһазларын, әсбабларын тараттылар, өем-өем кеше сәфәргә китә башлады — һиҗрәт кыла башлады. Авылларда күз яшьләре белән, кыямәт купкан кебек, кайсы туганын, кайсы баласын, кайсы кеше атасын озата иде. Һәр көнне китүче, һәр көнне күз яше, һәр көнне аерылулар, һәр көнне моңлы-моңлы җыр тавышлары, мәсҗетләрдә тәкбир тавышлары кыямәт көне кебек күренә иде. «Кая баралар?! Кая китәләр?! Ник китәләр?! Бу мәшәкатьләрне ник күрәләр. Боларга бу мәшәкатьләрне күтәрү хәтта калебкә бер рәхәтлек тә бирә иде. Һәммәсе дин өчен дөнья ташлау дип, бик шатланып әйтәләр иде. Хөкүмәт боларның бу эшләренә каршы килмәде. Булдыра алган кадәр кешеләр җибәреп вәгазь әйттерде. Ләкин фетнә көннән-көн зурайды. Көннән-көн халык арасында төрле хәбәрләр таралды. Күчүчеләрнең

---

54. Мәкрүһ — күңел теләмәгән. 55. Мөбәх — хәләл дә, харам да түгел. 56. Мәсафа — ара.
57. Һиҗрәт — күчеп китү.

саны көннән-көн артты. Русиянең һәммә тарафында бер хәбәр, һәммә җирендә бер фетнә иде. Күчүчеләр күчтеләр. Монда калганнар да әйберләрен сатып китәргә хәзерләнә башладылар. Һәммә кеше киткәннәрнең хәленнән интегеп хәбәр көтәләр иде. Менә хатлар! Менә хәбәрләр! Изге җирдән изге хәбәрдер?! Изге хәбәр! Изге!

Киткәннәрнең кайсы Дәрбәнттә, кайсы Батумда, кайсысы Севастополь, Одеста, кайсысы Бакуда фәкыйрьлектә, мохтаҗлыкта кая барырга белмәенчә калганнар. Китәргә дә акча юк! Кайтырга да акча юк! Кая барсыннар бу бичаралар?! Нишләсеннәр?! Боларга ни гакыл?!! Җирләренә кайтсыннармы? Җирләре кая? Анда кайтып ни эшләсеннәр? Ат юк җигәргә, тун юк кияргә! Өй юк керергә, җир юк сөрергә, ни эшләсеннәр?!

Болары болай, икенчеләре ничек? Чын мөһаҗирләр ничек? Төркиягә чыгып кала алганнардан да шул хәбәр!

Истанбулга чыккач, иң әүвәл карантин! Карантин! Ул ниткән карантин?! Моннан дин өчен күчә торган кешеләргә!! Без күчүчеләр, безгә карантин кирәкмәс, без дин өчен күчәбез! Безгә җир бирегез. Ат бирегез! Үгез бирегез! (кайсылар хәтта җимеш бакчасы бирегез дип язган иде) сүзләре берлән төрек докторларына гозерләр, прошениеләр биргәннәр. Бер айдан соң карантин да беткән, боларның да акчалары беткән, инде ни эшләсеннәр соң?! Боларга җир кая? Бакча кая? Атлар кая? Үгезләр кая? Теге язуда һәммәсе язылган иде. «Чиновник булырга теләгән кешеләргә, кереп укысалар, укыган өчен жалование дә бирелә»,— дип язылган иде ич! Һәммәсе дөрес түгелмени?!! Һәммәсе ялганмы?!! Тагын әле аның өстенә төрекләр: монда ник күчәсез, дип җөдәтәләр. «Дин өчен, анда русча укыта башладылар. Әллә нинди безгә кирәкмәгән нәрсәләр укыталар»,— дигәч тә, бер дә кызганмаенча шаркылдашып көләләр. Тагы мыскыл итеп, өстиләр: «Дин өчен түгел, бәлки наданлык өчен монда килгәнсез»,— диләр.

Кайсылары: «Карендәшләр, сез файда итәргә дип безгә чыксаңыз, кәсеп итеңез! Менә сезгә Көтәһия вилаятеннән* җир! (Көтәһия — Анатолиядә* бер шәһәр). Сезгә хәзерләп куйган бакчалар юк! Иң яхшысы — Россиягә яңадан кайтыңыз. Үз кәсебеңез берлән тора башлаңыз, динеңезгә бер кеше дә тимәс. Русча укыту сезгә зарар түгел ул! Укытсалар, бик укыңыз! Укытмасалар да, укырга тырышыңыз!! Әгәр сез безгә, безне укытмыйлар, дип килсәңез иде, без сезне кызганыр идек. Сез, безне укыталар, дип монда ислам динендә фарыз булган гыйлемнән качып китәсез! Үзеңез мөһаҗир фи сәбил алла[58] дисез. Бу һиҗрәт түгел, бу наданлык кына»,— дип вәгазь әйтәләр иде. Бу вәгазьләр Россиядә вакытта булса иде, бәлки тыңлаган булырлар иде. Хәер, Россиядә дә мондый вәгазьләрне ишеткәннәр иде дә аларны күңел караланганнан гына әйткән кешеләр сүзенә багышлаганнар иде. Дөресе — боларны котырткан кешеләрнең күңелләре каралган икән!! Татар гакылы артыннан йөри, диләр, бик дөрес сүз. Болар да хәзер һәммәсе һиҗрәт түгел, үз җирләрендә тору фарыз икәнлеген белделәр, әмма соңрак.

Монда калган карендәш-кабиләсе баерагы бер аягына кәвеш, бер аягына төрек ботинкасы киеп булса да кайттылар.

Әмма фәкыйрьләре мәңге горбәттә, мәңге фәкыйрьлектә калдылар, туган җирләрен, карендәш-кабиләсен күрер өчен зар елап, фәкыйрьлектә үлеп беттеләр.

Монда калганнары да, әйберләрен сатып, мал-туарларын таратып китәргә хәзерләндекләреннән, аларга да элгәреге дәүләтне җыю, элгәреге малны кайтару бик җиңел булмады. Нә исә болар

*Анатолия — Төркиянең Азия өлеше.
*Вилаят — губерна.
58. Мөҗаһир фи сәбил алла — алла юлы өчен күчеп китүче.

үз җирләреннән кузгалмадыкларыннан, еллар да яхшы килү сәбәпле, акыртын гына искечә тора башладылар. Алай булса да, бу фетнә һәр кешенең күңелендә бер җәрәхәт калдырганга, бик озак еллар онытылмады. Тагы акыртын гына искечә тора башладылар. Яңа эш юк иде, гәрчә Казанда матбагалар булып, һәр лисанда китап бастырырга, әдәбият нәшер итәргә рөхсәт булса да, дин китапларыннан башка, Сәйфелмөлек, Йосыф китабы вә башка — нә кешегә, нә дөньясына, нә ахирәтенә файда бирми торган китаплар басылса да, кирәкле фән китаплары, әдәби хикәяләр, милли театр уеннары һич күзгә-башка күренми иде. Халык та «Әлхәмделилля, тынычлык» дип яткан иде белән ята иде. Менә тагы яңа хәбәрләр! «Яңа укыту чыккан, ди! Ысулы җәдидме, ди?.. Ысулы язитме, ди? Иске китапларны укытмыйлар, ди. Үзләре китап чыгаралар, ди!!! Әй, раббым! Тагы нинди эшләр! Ит үзеннән кортлый, диләр, бик дөрес, үз арабыздан чыккан бит! Ул нинди эш ул! Болай укыту ярамый дип әйтәләр, ди! Әбҗәдне[59] бөтенләй калдырганнар, ди! Иҗек тә укымыйлар, ди! Аккош баласы төсле «Тый сөнтә, тый сөнтә»[60] дип сайрап торучы балалар булмаса, мәдрәсәләрдә, мәктәпләрдә ни ямь булыр? Белмим инде, белмим. Ахырзаман бигрәк якындыр, ахрысы, берсе бетә, икенчесе килеп чыга! Моны кем уйлаган инде? Йа, шәехем, мәдәд[61] ! Йа, шәехем, мәдәд!.. Голәмалар ни карыйлар? Ник халыкка сөйләмиләр? Бу нинди эш бу! Әле бер китапта «ля»ны* калдырганнар, ди! Урыска тарту шул инде! Урыска! Голәмалар арасында тагы тавыш! Тагы низаг! Болай укыту ярыймы-юкмы? Әлбәттә, ярамый! Болай укытылса, бөтен кеше язу таныр, бөтен кеше укый белер, төрки телендә кирәкле китаплар булса, укыган кеше һәммәсе, мулладан сорамаенча, үз хаҗәтен белер! Аннан ары муллаларга ни кала?! Ни сөйләсә, аны дөрес сөйләргә кирәк! Әле хәзер муллалар: «Ай ахмак, китапта шулай әйткән!»— дисәләр, бөтен мәҗлес авызын ача алмый иде! Инде бетте! Голәмага кадәр бетте! Һәммә кеше укыгач, һәммә кеше белгәч, ул нигә ярый?! Ахырзаман галәмәте! Ахырзаман!» тавышы һәр җирдә ишетелә иде. Бу вакыйга әүвәлгеләргә караганда да зур булды. Чөнки бу үз арабыздан чыкканга күрә, бик күп кеше болай укытуны яратмасалар да, яратучылар да бик күп иде. Озак үтмәде, шәһәрләрдә ысулы җәдид мәктәпләре ачыла башлады. Голәма арасында сүз күбәйде. Кара халыкта «Арышның поты ничә тиен? Тире бәһәсе кыйммәтме?» урынына «Ысул җәдид нишли әле? Фәлән хәзрәт аларны бик сүккән дип әйтәләр, дөресме?»— сүзләре ишетелә башлады. Халык арасында дүртенче курчак туе әүвәлгеләрдән дә ким булмады. Курчак уйнаучы сакаллы балалар (байлар) тагы бу эшкә катыштылар. Һәр кеше үзенә бер төрле сүз сөйли иде. Тагы, бәхетсезлеккә, гәзитә дә шуны яза башлады. Халык арасында тагы: «Гәҗитче ни яза? Бик мактыймы инде ысулы җәдидне?»— сүзләре ишетелә башлады. Голәма арасында тагы низаг! Тагы кычкырыш! Кяфер! Кяфер!!! Ысулы җәдид харам! Гәҗитчегә ышанырга ярамый, ул ни белә? Фәлән ишан әле бер ысулы җәдид кешесен пароходта күргән ди, җир түгәрәк дип әйтәдер, ди. Аңарга инде кем ышансын?! Берсен-берсе рәд кылып китаплар чыга башлады. Һәммәсе дингә татбикъ[62] кылган булып, нә динне белмәенчә, нә ысулы җәдид нидән гыйбарәт икәнлеген белмәенчә, рисаләләр яза башладылар. Табигатьтә бер кагыйдә бар: бер яңа эш чыкса, ул мотлакан үсә. Шул кагыйдәнең дөреслегеннәнме, ысулы җәдид көннән-көн алга бара иде. Бу эшләргә караганда бер вакытны бөтен халык арасында шулай низам белән укылу таратылып, без-

59 Әбҗәд — гарәп язуын өйрәнер өчен ясалган сүз. 60. Тый сөнтә — гарәп хәрефләрен кычкырып өйрәнү — аваз белән атау. 61. Мәдәд — ярдәм. *Ля — инкяр кушымчасы. Аны ташлап калдыргач, тыелган нәрсә рөхсәт ителгән була.

нең болгар милләте дә башка милләт төсле булу өметен уйлатуда иде. Ләкин, безнең бәхетсезлеккә, болар арасында төрле низаглар чыкты: милли файдадан битәр, шәхси файдалар карала башланды. Төрлечә тарикъларга[63] бүленә башлады. Һәр кеше үзе белгәнчә, дөресен әйтсәм, үзе белмәгәнчә мәктәп өчен китаплар чыгара башлады. Бу китапларны үз мәктәбендә һәм якыннарының мәктәбендә укыттыра башладылар. Бу китаплар күбесе ысулы тәгълимгә муафыйк булмаганга, ысулы җәдид исеменә бәднам[64] бирә башладылар. Казанда, Оренбургта, Троицкида, Уфада, Чистапульдә, Каргалыда, Семипалатта, хәтта Әстерханда да ысулы җәдид мәктәпләре ачылды. Карияләрдә дә мәктәпләр күренә башлады. Яңа укыту һәммә җирдә акыртын гына тарала башлады. Һәр нә кадәр укытулар төрлечә булса да һәм ысулы тәгълимгә муафыйк булмаса да, әлеге нух заманыннан калган ысулга караганда файдалыгында шөбһә юк иде. Һәммә җирләрдә мөгаллимнәр кирәк була башлады. Халыкта «уку-укыту» сүзләре еш-еш сөйләнә башланды. Мөгаллимнәр өчен дарелмөгаллимин кирәклеге вә иске мәдрәсәләрнең эшкә ярамавы да ачык фикерле кешеләр арасында кат-кат сөйләнә башлады. Халык арасында «хәмият»[65], «инсаният»[66], дигән сүзләр ишетелә башлады. «Тәрҗеман» газетасының һәр номерында мәгариф вә тәрәккый милләт өчен чаралар эзләү лязем идеке, мәгарифсез милләт җансыз кеше кеби булдыгы ачык-ачык иттереп, кайвакыт бик ачы, кайвакыт төче гыйбарәләр белән мәкаләләр күренә башлады. Мәктәпләргә мөгаллимнәр хәзерләү лязем улдыгыннан, анда-монда ысул күргән кешеләрдән, күбрәк җирдә «ысул» дигән сүзне ишеткән кешеләрдән мөгаллимлеккә өйрәнә башладылар. Бу эшләрдә дә байларның бик зур катышы булды. Бик күбесе моңардан курчак туйлары ясатып, килгән кешеләрдән иң әүвәл үзенең кылган эшләрен: «Әлхәмделилля, мин мактанмыйм, менә Ирсай авылына мөгаллим җибәрдем. Борнай авылына барган идем, муллаларына әйттем: Әй хәзрәт! Сез шулай өйрәтәсезмени! Сезнең халык шуны беләмени! Укыткан балаларыгыз кая? Әй, дин караклары!» — дип әйттем дигән сүзеннән соң, милләт өчен бәгъзесе: «Иң лязем эш — тәҗвидне бик яхшы белү!» Бәгъзесе остазлар, хәлфәләр: «Башка олуг кешеләргә (байларга) тәгъзим кылуны өйрәтү иң тиеш», идекне тыңлаучыны, теләсә нинди кеше булсын, үзенең рече (хотбә) белән тәмам туйдырып чыгаралар иде.

Бәгъзе аңлаган кешеләр, безгә хәзер ничек булса укырга, укытырга кирәк, ни булса да укысын! Ни белсә дә белсен, рус мәктәпләрендә укырга кирәк! Үз мәктәпләремез юк: алардан качмаска кирәк! Барыбер качып котыла алмыймыз. Милләтемезне инкыйраздан (!) коткарасымыз килсә, мотлакан, рус мәктәпләрендә уку тиеш! Без хәзер гомуми эшләремездә үз файдаларымызны бик тикшермәскә кирәк! Милләтемез өчен һәммәмез бар куәтемез берлән тырышырга кирәк! Ихсан байның сүзе берлән милләт алга китмәгән шикелле, Гали мулла сүзеннән дә милләткә һич файда юк! Эшкә тотынырга кирәк, эшкә! Аңлаган булып сөйләп йөримез: милләт димез, тәрәккый димез! Мәдәният, мәгариф димез, боларның берсен дә аңламый әйтәмезме, әллә аңласак та, хәзер безнең заманда шул сүзләрне әйтү мода булганга күрә генә әйтәмезме? Бәгъзе кешеләр мода булганга күрә әйтәләр! Ләкин аңлаганнарыңыздан милләт намына эшкә тотынуыңызны үтенәм! Аз булса да эшлә, эшләгән эш бер вакыт файдага ярый, болай сөйләүдә ни файда бар? Ул варенье белән чәй янында сөйләүдән генә нә милләт тәрәккый итә, нә милләт-

62. Татбикъ — чагыштыру. 63. Тарикъ — тоткан юл. 64. Бәднам — начар исем. 65. Хәмият — башкаларның зарар китерүеннән саклану. 66. Инсаният — кешелек.

нең бер-бер кирәге бетә! Әгәр без милләтемезнең хакыйкатьтә артка калуын аңлаган булсак, җиң сызганып эшкә тотыныйк! Әгәр аңламаган булсак, сезгә әйтәм, дусларым: бу көенчә барсак, милләтемез бетәчәк, бетәчәк!.. Милләтемезнең рухын саклар өчен нә мәдрәсәләремез бар, нә мәктәпләремез бар! Нә милли театрларымыз бар! Нә үз телемездә үз мәгыйшәтемездән[67] язылган хикәяләремез бар?!! Боларның һич берсе булмагач, ничек бу милләтнең истикъбале[68] парлак[69] дия аламыз?!! Яки эшкә тотыну!!! Яки инкыйраз!! Сез, туганнар, аңлаганнар! Иң әүвәл үземезне кеше ясарга тырышыйк, моның соңында һәммәмез дә милләтнең иң кирәкле тарафларын карап, милләткә хезмәткә тотыныйк, бу хезмәтләр үземезгә исем алыр өчен генә булмасын, милләт файдасы өчен булсын. Вак-төяк җөзьи[70] эшләргә әһәмият биреп, милләтемезне иң кирәкле эшләреннән мәхрүм калдырмыйк! Әйткән идем лә исә: укыйк, укыйк, дип. Тагы шул сүземне әйтәм. Безгә хәзер үз мәктәпләремез, мәдрәсәләремез биргән мәгълүмат кына җитәрлек түгел. Шуның өчен рус мәктәбендә укыйк. Бик күп кешеләремез кеби, «ярар иде дә булмый инде» дип, үземезне яки балаларымызны наданлыкта, ялган фикерләр, ялган уйлар, ялган хәмиятләр берлән чолгап калдырмыйк! Рус мәктәбендә укып күңел карала дигән сүзне сезгә әйтергә оят инде! Әүвәлдә русча гына укыган мирза балаларын мисалга китермәгез! Алар милләт-фәлән дигән сүзне аңлап укыганнар түгел. Белмим, «күңел каралу — ялган уйлар, дөньяга ялган карашлар бетү булса, ул каралу түгел, агару»,— дигән кебек сүзләр сөйләсәләр дә, мондый кешенең сүзенә бик үк игътибар кылмыйлар иде. Мәдрәсәләрдә тәртип берлән тору, тәртип берлән тәхсип кылу мөдәррисләр арасында да бик мөзакәрә[71] кылына башлады. Бик күбесе болай укуда бер мәгънә юклыгын аңлаганга, тәртипне бик кабул итәргә телиләр иде. Ләкин шул, мөдәррисләр вакытлы гына керер, фәненә күрә мөдәррис булыр сүзләрен ишеткәч, ниндәй аңлаган мөдәрриснең дә йөрәге шу итеп китә иде. Чөнки күз алдына үзенең зур чалма киеп, башны бер яккарак салындырып, кулына калын катыргылы китап тотып, «дәрескә» дип, бик зур эш иттереп баруы килә иде дә, ислах кылынса, андый кыяфәтләрнең бер дә кадере калмавын уйлап, ничек булса да аңарга гына шул элгәрегечә калдырып ислах кылдырырга тели иде. Шуның өчен үзенең киңәшчеләренә: «Мелла Салих, алай мәслихәт булмас! Сезнеңчә ничек соң? Шәмсетдин агай, мин мәслихәт дисәгез, разый, ләкин шәкертләр ул вакытта әдәпсезрәк булыр»,— диләр иде. (Мондый кешеләр үзләрен бик зур, һәммә кеше кадерләргә, олыларга тиеш заты галиләр дип белгәнгә, шәкертләрнең ул тәкъдирдә боларны мөдәррис итеп кенә күрүләрен бер дә күтәрә алмыйлар иде). Үзләре сүз арасында «милләт»кә хезмәт итү хакында бик озын сүзләр сөйләсәләр дә, бу тугрыда эчләреннән генә: «Милләткә ни булса да булыр, үземнең дәрәҗәмне бөтенләй үк төшереп җибәрәсем килми»,— дип уйлыйлар иде. Мәдрәсәләрдә дә вакыт үтә-үтә аз гына булса да үзгәрүләр күренә башлады. Гәрчә тәгълим-тәгаллемдә[72] тәртип кабул ителде дияр дәрәҗәдә булмаса да, шәкертләр өчен урыннар иркенәйтелә башланды. Мәдрәсәне пакь тотуда бидгать булса да, бидгать хәсәнәдән[73] саела башлады. Һаваның барлыгына, булса, бозылуына ышанып үк бетмәсәләр дә, кеше әзрәк булса, сулышка иркен булуын инкяр кылмый башладылар. Бәгъзе мәдрәсәләрдә дәрес тәртипләре дә ислах кылынган иде. Ягъни, элгәреге тәртипләр алыштырылган иде. Ләкин элгәреге тәртип ысулы тәгълимнең бер кагыйдәсенә туры килмәсә, яңа программ, яңа тәр-

---

67. Мәгыйшәт — тереклек итү, тормыш. 68. Истикбаль — киләчәк. 69. Парлак — балкулы, яхшы. 70. Җөзьи — вак, өлешчә. 71. Мөзакәрә — фикер алышу.

тип икенчесенә килми иде. Бу мәдрәсәләрне «мәдрәсә» дисәк тә, ифтира[74] була, «мәктәп» дисәк тә ифтира була. Белмим инде, «гаҗизханә» дисәк, ничек булыр. Минемчә, бу исем дөресрәк булырга кирәк! Чөнки монда укый торган кешеләргә безнең халкымыз рәзил[75], фәкыйрь, бәхетсез кешеләр дип карыйлар. Һәр ни булса булды, безнең тарафымызда миллятне алга җибәрер өчен һичбер эш булмаса да, мәдрәсә шәкертләре арасында яңа фикерләр туа башлады. Русча укуның өйгә кайтканда пароходта очраган марҗа белән сөйләшер өчен генә кирәк түгел икәнлеге аңлашылды. Гәзитә уку, яңа китаплар уку, төрекчә тарих, төрек романнары уку күзе ачыграк кешеләр арасында гадәт булып китте. Мондый шәкертләр үзләренең кеше икәнлекләрен, һичбер кешедән курыкмый, теләсә ни эшләргә ихтыярлары бар икәнлеген белделәр. Алай булса да коруне вәсата[76] гадәте булган «фатиха», «бәддога» дигән сүз боларны тимер чылбыр төсле мәдрәсә сасыларын иснәргә бәйләп тота иде. Акрын-акрын русча уку шәкерт арасында җәелде. Җәйләрдә рус авылларына барып, яки бер-бер шәһәргә барып уку гадәт төсле булды. Һәр шәкерт гәзитә аңларлык русча белүне бик зур сәгадәткә саный башлады.

Бу елларда тагы бер бәхетсезлек килеп чыкты. Русиядә гомуми тәхрир нөфүс («перепись») мәсьәләсе халык арасында тагы бик зур низаг куптарды. Ләкин бу елларда халкымыз арасында шактый аңлаган кешеләр күп булгангамы, бу мәсьәлә элеккесе кебек үк куркынычлы булмады һәм тиз басылды. Мәйданга яңа әдәбият чыга башлады. «Тәрҗеман» гәзитәсе, урыс гәзитәсе, төрек гәзитәләре уку халык арасында бер мода булды. Яңа рухта яңа әсәрләр халыкка тәэсир кыла башлады. Фәнни рисаләләр, гыйбрәтле милли хикәяләр, халыкны уятыр өчен язылган китаплар гомум[77]да мәкъбуль[78] була башлады. Тагы яңа өметләр туа башлады. Русиянең һәр җирендә җәмгыяте хәйрияләр ачыла башлады. Фәкыйрьләр карау, аларга ярдәм итү исламият мәйданга чыкканнан бирле мәгълүм мәсьәлә булса да, бездә унтугызынчы гасырның ахырында гына аңланылды. Бөтенләй аңламый калуга караганда, бусы да ярый әле. Билфигыль[79] эш булмаса да, шактый гына эшләргә юл ачылган иде. Халкымызның уку ягы бу дәрәҗәдә булса да, ягъни, фи әл-җөмлә[80], алга китүгә булса да, тиҗарәт[81] җәһәте бик каты тәнәззел[82] иткән иде. Бик күп фирмалар банкрот булган... Әлгәреге сәүдәгәрлек табигате бетмәсә дә, бик кечкенә эш берлән генә кәсеп итә башлаганнар иде. Кызыл мал берлән сату итү, вак-төяк галантерийный әйберләр берлән сәүдә бетмәгән булса да, күбесе лимон, әфлисун, алма, карбыз, иске-москы берлән сату итүдән уза алмыйлар иде. Банкрот булу халык арасында гадәт булганга, безнең болгар сәүдәгәрләренә һәммә җирдә ышаныч беткән иде. Шуның өстенә бу калган сәүдәгәрләрдә дә «Ник? Ни өчен?» икәнлекне белеп эш йөртү гадәт булмаганнан, боларның да тиз көннән исемнәре югалачагы билгеле иде. Иң кайгылысы шул иде: халкымыз әхлак җәһәтеннән бик бозылган иде. Казан халкы бөтенләй әтлеккә салынган иде. Көндезләрен вак төяк сату иткән булып маташалар да, кичләрендә гостиницалар, пивной вә фәхеш урыннарында кичләр үткәрәләр иде. Исереклек шул дәрәҗәдә тәрәккый иткән иде!!! Әйтеп бетерерлек түгел. Зина, фәхеш тә иң кабахәт дәрәҗәдә патшалык сөрүдә

72. **Тәгълим-тәгаллем — укыту-уку.** 73. **Бидгать хәсәнә — пәйгамбәрдән соң чыккан дини эшләрнең яхшысы.** 74. **Ифтира — яла ягу.** 75. **Рәзил — түбән.** 76. **Коруне вәсата — урта гасырлар.** 77. **Гомум — масса.** 78. **Мәкъбуль — кабул ителгән.** 79. **Билфигыль — чыннан да.** 80. **Фи әл-җөмлә — гомумән алганда.** 81. **Тиҗарәт — сәүдә.** 82. **Тәнәззел — төшү.** 83. **Гоҗеб — масаю.**

иде. Һәр җирдә башы ачык ислам кызлары, мөселман хатыннары күзгә күренә иде, бу эшләрнең бу кадәр артуына сәбәп тә халкымыз арасында эчү вә исереклекнең артуы иде. Ирләремез көне-төне кәсеп иткән акчаларын хатыннарына, балаларына алып кайтыр урында фәхешханәләрдә яки мәйханәләрдә вакытларын үткәрдекләреннән, хатыннары тамак туйдырыр өчен булса да, теләр-теләмәс фәхеш юлына кереп китәләр иде. Икенче — асрау тоту шәһәрләр гадәтедер. Бу асрауларның бик сирәге генә бай яки бай углының кулыннан котылалар иде. Һәм бәгъзе кешеләремез арасында фәкыйрь кешеләрне акчага кызыктырып, кызларын харап итү дә бик таралмыш иде. Шул сәбәпләр өчен Казан хатын-кызы арасында, бөтен гомерен әрәм итеп, ир ләззәте, бала ләззәте татымаенча, үзләренең бөтен исемнәрен югалтып, дөньяның иң кабәхәт җирләрендә җеназалары күтәрелүчеләре дә бик күп иде. Әхлак җәһәтеннән башка якта бик күп кимчелекләр бар иде. Мәсәлән, чибәррәк бер кеше Казанның Печән базарыннан бер мәртәбә чыкса, икенче мәртәбә я чыга ала, я юк иде. Яхшы дигәннәре мин яхшы дип гоҗеб[83] берлән тулган иде, усал дигәннәре, мин барыбер инде усал исемен күтәргән, дип усаллыгын арттыра гына бара иде. Боларның һичберсенә сүз әйтеп аңлатуның чарасы юк иде. Чөнки һәммәсе (үзе язу танымаган булса да) үзен бер галим, бер әдип, бер философ дип белә иде. Һәммә эшләргә катышырга җитәрлек гыйлемем дә бар, акылым да бар, дип, һәммәсе эченнән генә: «Менә абзаң нинди!» — дип күкрәкләрен кагалар иде. Боларда тагы бер кызык игътикад[84] бар иде — кеше нинди начарлык кылса да, намаз уку берлән кичерелә, нинди начарлык та русча белүдән артык күрелә иде. Чөнки русча белмәгәннәргә үз араларында «агай-эне» диләр иде, шул исем тегеләрнең бөтен гөнаһларын кичерә иде. Бәлки һәр надан милләттә шундый кимчелек бардыр — без әле бөтен дөнья хәлен карамаганга, аларның табигатьләренә, килешләренә, кыланышларына карамаенча, үз хәлемезне генә тикшерәмез, гомумән караганда, бу гасырда милләтемез бик тәнәззел иткән иде. Европа белән катышу, хосусан, руслар берлән муанәсәт[85] артса да, алардан әхлаксызлык, исрафчанлык, вөҗдансызлыктан башка әхлак өйрәнә алмаганнар иде. Чөнки боларның иң сәфилләре[86], иң начарлары белән катышалар иде. Дөрес, чибәррәкләре белән катышучылары да бар иде. Мәсәлән, мирзалар. Аларның күбесе рус мәктәпләрендә укыган һәм русларның гали[87] фикерле кешеләрнең әсәрләрен күргәннәр иде. Шулай булса да, белмим, алар үзләренең болгарлыкларын онытканнар иде, әллә үзләрен үк онытканнар иде. Бу гасырда болардан зарардан башка һичбер файда булмады, болар үзләрен башка милләт кешесе кебек күреп, милләттәшләренә татар дип әйтүдән башка бер яңа эш тә чыгара алмадылар. Һәрвакыт, милләт хакында сүз киткәндә, кайсысы «безнең татардан», кайсысы «татардан буламы соң» дип, кул гына селтиләр иде. Гүя ки, милләтнең бу кадәр артка калуы боларга башка болгарлардан калган ла!.. Дөресен әйткәндә, халыкның алга китмәвенә сәбәп болар «татар» дигән болгарлар түгел иде, бәлки татар дип үз милләтеннән үзләре качкан «татарлар» иде. Чөнки болар, рус мәктәпләрендә укыгач, үз милләтемезнең кайсы төше җитми, алга китәр өчен ниләр кирәк, шуларны уйлап, сырхау милләтемезнең авыруын белсәләр дә, һичбер дару бирмиләр иде. Күбесе болгар милләте тәрәккыйне кабил[88] дип тә белми иде, дөресен генә әйтсәк, бу кешеләр русча уку, фөнүн җәдидә[89] белү, яңа әдәбият күрүгә замана модасы дип кенә карыйлар иде. Кәмаләт нәфес[90] өчен, яки милләткә файда итәр өчен генә түгел иде. Әмма голәмага килсәк, бу гасырда алардан да бер

84. Игътикад — ышану. 85. Муанәсәт — якынаю, аралышып яшәү. 86. Сәфил — түбән. 87. Гали — бөек, югары.

нәрсә дә чыкмады. Яңа тарикат[91], яңа ишанлыклар, дөньяга яңа ялган карашлар, гавамны алдарга иблис үзе белмәгән хәйләләр чыкса да, болардан да милләткә килгән файда түгел, гомум милләткә — ишан хәзрәтнең корсагы берлән мәхдүм[92] әфәндене... нән артмый иде. Дөрес, файда иткән галимнәр, файда иткән мирзалар да бар иде. Ләкин алар йөзгә бер түгел, меңгә бер иде. Бу гасырда голум исламия[93] тәхсил[94] кылып, русча укыган кешеләр яки төрек-гарәп әдәбияты берлән күзләре ачылган кешеләрнең үзләреннән зур файдалары күренде. Унтугызынчы гасырның ахырында күренгән яңа мәктәпләр, яңа китаплар аларның сәмәраи гайрәтләредер[95]. Әлгәре болгарлар арасында шундый, «яңа фикерле» дигән бер сыйныф килеп чыкмаган булса иде, бу вакытка кадәр яткан ягымыз белән ятар идек. Рәхмәт бу кешеләргә! Болгар дигән бер халык бар икәнлеген үземезгә белгерттеләр. Үземезнең кайсы җирләремездә кимчелекләремез бар, шуларны күземезгә күрсәтә башладылар. Үз милләтемезне терелтү өчен чаралар эзли башладылар. Үзләрен-үзләре фида кылдылар, рәхәтләрен югалттылар. Бөтен милләтемезнең оятсыз кешеләреннән төрле кабахәт сүзләр берлән сүгелүне дә күтәрделәр вә, төрле ялган ифтираларга разый булып, милләт юлында кылган хезмәтләренә рәхмәт, ял сорамаенча, һаман эшләрендә булдылар. Күзләреннән яшьләр чыгарып, халыкка безнең милләтемезнең бу китеше өметле түгел, ләкин, милләтемез монкарыйз[96] булмасын, халкымыз бетмәсен дисәк, милләтемезнең кирәкләрен карау тиеш идекен көн-төн зурысына, кечкенәсенә сөйләделәр. Ләкин ни файда? Гоҗебле[97] болгарлар яшь-яшь, сакал чыкмаган, якасының карасы берлән күлмәк ялавы күренмәгән, башында чалмасы юк, кәкрәймәгән муенлы, янында сасы тир исе чыкмаган бер егетнең сүзен ни эшләп ишетсеннәр дә, аның сүзеннән нинди гайрәт алсыннар?!!

Шулай итеп, бу гасыр да үтеп китте. Егерменче гасыр башланды. Бу гасыр безгә ни бирә? Бу гасырда безнең болгарлар ни эшли, дип уйлый башладылар. Фикерле сыйныфына кергән кешеләр бу гасыр безнең өчен тәрәккый гасыры булса иде, дип догалар кылалар иде. Һәм дә үзе дә, бу гасырның башында ук тәрәккый галәмәтләре күренә башлады. Унтугызынчы гасырда башланган әдәбият нәшере бу гасырда акрын-акрын тәрәккый итә башлады. Милли хикәя көннән-көн күбәя башлады. Аннан да, моннан да яңа эшләр, гыйбрәтле хикәяләр күренә башлады. Фикерләр арасында театр, милли театр кирәклеге сөйләнә башлады. Байлар арасында да милләткә кирәкле кешеләр хәзерләү тиеш икәнлеге беленә башлады. Рус мәктәпләрендә укыган кешеләргә кыек күз белән карау азая башлады. Бохариларның ялган фикерләренә, әфьюн берлән черегән башларыннан чыккан сүзләренә Коръән аяте кебек карау бетә башлады. Хәтта милләтемезнең бу кадәр артка калуына сәбәп шулар идеке сөйләнә башланды. Һәр яктан тәрәккый хәбәрләре колакларны шыңгырдата башлады. Оренбург, Троицк, Уфа, хәтта Казан кук шәһәрләрдә сала муллаларын сугыштыру өчен яки авылдагы Әхмәтҗан агайнең кызын остазбикә итәр өчен салган мәсҗетенә караганда, кечкенә генә булса да мәктәп салуның файдалы икәнлеге беленә башланды. Мәдрәсәләрне ислах[98] кылу яңа бер мәсьәлә булып халык арасында кабарды. Мең-мең шөкерләр булсын, әфьюнле башлы муллалар ахирәткә юнәлә башладылар. (Аллаһе тәгалә урыннарын оҗмах кылсын). «Тәрҗеман» гәзитәсе һәр номерында тагы әһәмиятле бәндләр[99] нәшер кыла башлады.

---

88. Кабил — кабул итә алучы. 89. Фөнүн җәдидә — яңа фәннәр. 90. Кәмаләт нәфес — рухны камилләштерү. 91. Тарикат — ишанлык юлы, өйрәтмәсе. 92. Мәхдүм — мулла улы. 93. Голум исламия — ислам фәннәре. 94. Тәхсил — гыйлем алу. 95. Сәмәраи гайрәт — гайрәт җимеше. 96. Монкарыйз — беткән, юкка чыккан. 97. Гоҗебле — масаючан.

Рус газеталарында да мөселманнар тарафыннан язылган мәкаләләр күренә башлады. Һәммәсе Русиядә булган мөселманнар белән русларның иттихадына[100] хезмәт итә иде. Рус мәктәпләрендә көннән-көн укучылар күбәя башлады. Казан, Оренбург халкы арасында да рус мәктәпләренә кереп тәхсил итү[101] (хәзрәт фатиха бирсә) бик зарарлы түгеллеге сөйләнә башланды. Алай булса да, тиҗарәт[102] вә һөнәр мәктәпләрендә ислам баласының аяк басканы юк иде. Хатын-кызны укыту, хатыннардан мөгаллимәләр җитештерү унтугызынчы гасырда ук башланган булса да, бу гасырда чынлап сөйләнә башлады. Билгеле, бу мәсьәлә дә әүвәл муллалар тарафыннан бик каты уклар белән атылды. Ләкин озакламады, уклары файда итмәгәнне, порохлары начар икәнлекне аңладылар. Гомум халыкта боларның кычкырган сүзләре буш, юк сүз, аткан уклары, туплары халыкны куркытыр өчен генә икәнлеген һәм шарт иткәннән башка әсәре[103] калмавын белделәр. Кызлар өчен мәктәпләр ясый башладылар. Яшьтән тол калып, ничә еллар... эштә гомерен кичергәннән соң эш таба алмаенча, сабак кызлары укытырга тотынган карчыкларга кадер бетә башлады. Кызларны мөгаллимнәрдән укыттыруны да бик чит күрми башладылар. Рус мәктәпләрендә аз-аз гына булса да, бу көнгә кадәр укучыларыннан һич файда булмаса да, ислам кызлары күренә башлады. Бер милләтне тәрәккый иттерер өчен, иң әүвәл «ана» җитештерү кирәклеге фикерлеләр тарафыннан язылган рисаләләрдә күренә башлады. Кызлар язу белсәләр, егетләргә хат язалар мәсьәләсе яңадан башыннан аягына кадәр мөхәкәмә кылына башлады. Һәммә җирдә дә укыган кеше берлән укымаган кешенең бер түгеллеге беленә башлады, хатын-кызларның кеше идекләре, аларның да дөньяда булган һәрбер нәрсәдән файдаланырга хокуклары булдыклары, аларның кәнизәк[104] түгеллекләре һәм ирләрне кувәи шәһванияләрен[105] ифадә[106] кылыр өчен генә яратылмадыклары, нинди ризаләтне[107] җигәргә дә ярый торган бер бәддога[108] төшкән, чәчләре озын, гакыллары кыска бер хайваннар гына түгеллекләре һәммә җирдә сөйләнә башланды. Алай булса да, аларның шул хәлләреннән файдаланып, үзләре коруне вәсата[109] патшалары төсле, һәрвакыт кадерләнеп кенә торасы килгән кешеләр бу эшкә бер дә разый булмадылар. Хосусан, голәмалар: «Әйе, шәргъ[110] шәриф хатын-кызны укыту заләл[111] дип әйтә инде мәсәлән» сүзләре берлән бик каты могарәзәләр[112] кылсалар да, аларның халык арасында рәтләп игътибарлары юккамы, әллә замана шуны үзе теләгәнгәме, хатын-кызда уку көннән-көн арта иде. Һәр милләтнең яртысы — хатыннар, һәр милләтнең рухын саклаучылар — хатыннар, һәр милләтнең теленең хосуси тәләффызларын[113], шивәсен[114] саклаучылар — хатыннар, киләчәктәге ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия кылучылар — хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер мәсьәлә булгач, минемчә, аларны тәрбия кылырга кирәкме, юкмы мәсьәләсе һәркемгә җавап бирерлек бер нәрсәдер. Һәм шул кадәр тамаклар авырттырып кычкырышырлык, укыса, егетләргә хат язар, фәлән итәр, икенчеләре укымаса, егетләргә хатын барыбер язар да, үзе язу белмәгәч, кешедән яздырыр да, гыйффәте[115] дә югалыр, сере дә чыгар кебек низагларга һич урын калмыйдыр. Яхшы ананың баласы яхшы, койты ананың баласы эшәке булуында һичкемнең шөбһәсе юктыр. Һәммәмезнең белгән кешеләремездән генә

---

98. Ислах — реформа. 99. Бәнд — мәкалә. 100. Иттихад — бердәмлек. 101. Тәхсил итү — гыйлем алу. 102. Тиҗарәт — сәүдә. 103. Әсәр — эз, билге. 104. Кәнизәк — кол сөяркә. 105. Кувәи шәһвания — җенси куәт. 106. Ифадә — аңлату. 107. Ризаләт — хурлык, яманлык. 108. Бәддога — каргыш. 109. Коруне вәсәта — урта гасырлар. 110. Шәргъ шәриф — изге шәригать. 111. Заләл — туры юлдан язу. 112. Могарәзә — каршы килү. 113. Тәләффыз — әйтелеш. 114. Шивә — җирле сөйләм, диалект.

гыйбрәт алырга кирәк. Әдәпле Миһринең кызы һәрвакыт әдәпле булдыгы кеби, оятсыз Мәрфуганың Әсмасы да һәрвакыт ирдәүкә кыз булдыгы һәммәмезнең мәгълүмедер. Әгәр тәрбияле ана булса, баланың киләчәктә кем булачагын уйлый ала торган хатын булса, ул билгеле, баласына ашату, эчертү, иренә ачуланса, сандык өстенә күтәреп бәрү белән генә канәгать кылмаенча, аның холкының яхшы булуы, сәламәтлегенең саклануы, мәгълүматының артуы, күзенең ачылуы өчен дә тырышачаклар. Билгеле, бу аналар милләт вә дин ноктаи назарыннан[116] һәм җәмгыяте бәшәрия[117] ноктаи назарыннан (күз карашыннан) бик мөкатдәс затлар булачаклардыр. Һәм дә милләт, дин, җәмгыяте бәшәриягә зур хезмәт итәчәкләрдер. Әмма укымаган, тәрбия алмаган, ирләрне дә шул яз көнендә сыерлар үгезләрне ни өчен телиләр, шуның өчен генә кирәк дип белгән хатыннардан һәм балаларга да «б... чүлмәге» дип караган кызлардан балалары өчен, ирләре өчен, җәмгыяте бәшәрия өчен ни файда көтәргә кирәк?! Сезнеңчә, ни файда булыр?! Шөбһә юк, болар гөнаһсыз балаларны бозудан бүтәнгә ярамыйлар. Шул балалар безнең милләтнең әгъзалары булганга, алар милләткә зарар итәләр һәм динемезнең дә әфрады[118] булганга, кирле-морлы аңлап, дингә зарар итәләр. Болар җәмгыяте бәшәриянең бөртекләре булганга, аңарга да зарар итәләр. Шул эшләргә сәбәп булган аналар, аларның шулай калуларына сәбәп булган голәмаларны сез милләткә файда итүчеләр дип әйтер идеңезме? Әллә юкмы? Сезне мин белмим. Әмма мин үзем зарар итүчеләр, дим. Кыямәт көнне шуның өчен бик зур газапка мөстәхикъ[119] булачакларын да, һәр көнне мең мәртәбә әйткән тәһлилләре[120] дә, иртә, кич укыган вирдләре[121] дә боларны бу мәсъүлияттән коткармавында һич шөбһәм юктыр. Һәр нә исә, башланган эш — беткән эш, дигән кебек, хатын-кызның бервакыт кеше булуларында зур өметләр бар иде, ләкин бу өметләр дә корыга чыкты. Без теләгән ана җитештерә торган кызлар мәктәбендә укыла торган фәннәрнең берсе итәк санау, икенчесе фәлән абзыйның килененең хәлен тикшерү, өченчесе укый торган китапның чыгарга ничә бит калганын санап беткәннән соң, баштан бет карау иде. Шуның өчен бу кызлар шул фәләннәрдән бик яхшы белсәләр дә, безгә кирәкле тәрбия фәненнән бихәбәр иделәр. Нә исә егерменче гасырның егерменче гасыр идеке бездә дә билгеле иде. Европа халкы чыбыксыз телеграфлар, телефоннар эшләтүне кәшеф[122] кылдылар. Әмма без аннан да зур нәрсә кәшеф иттек. Ул нәрсә дисеңме? Ул ышанлык!! Шундый нәрсә ул, әгәр ул бер кешедә булса, дөньяның һәммә тәрәккыяте бер якта торсын! Ул сиңа дәүләт бирә! Ул сиңа дәрәҗә бирә! Ул сиңа кирәксә фатиха, алырга теләүчеләргә гүзәл-гүзәл хатыннар бирә! Хасыйле[123], җаның ни тели, шуны бирә! Европа голәмасы безнең шәрык халкын хәйләкәр, үткен таифә[124] дигән сүзләренә мин моңарчы ышанмый идем. Моннан соң ышандым, ышанмый хәл дә юк. Телеграф ярдәмендә халык берлән сөйләшеп кенә була. Моның берлән бөтен халыкны үзеңә кол итеп була. Моннан зур тагы ни эш бар?!!

Бу яктан эшләр шулай барса да, әдәбият аз гына булса да тәрәккый итә башлады. Болгарлар арасында «мөхәррир» исемен күтәрерлек кешеләр күренә башлады. Бик оста язылган бик матур гына гыйбрәтле хикәяләр яисә бик оста язылмаса да, бик яхшы

115. Гыйффәт — кызлык. 116. Ноктаи назар — караш ноктасы. 117. Җәмгыять бәшәрия — кешелек җәмгыяте. 118. Әфрад — затлар. 119. Мөстәхикъ — лаеклы. 120. Тәһлил — «бер алладан башка алла юк», дигән җөмләне гарәпчә әйтү. 121. Вирд — билгеле бер вакытта укыла торган дога, аятьләр. 122. Кәшеф — ачыш ясау. 123. Хасыйле — кыскасы. 124. Таифә — төркем, халык.

нечкә калепләрдән чыккан романнар күренә башлады. Китап нәшер кылу, китап белән сату итү милләт өчен, бөтен җәмгыяте бәшәрия өчен бик файдалы эш икәнлеге сизелә башлады. Әүвәлдә ит сатып бер вакытны ит кибетен китап кибетенә алыштырган кешеләрдән башка, китапчылар мәйданга атылды. Фәзаил әш-шөһүр, каранча бөтие, касырган догасы, фалнамә, татлы тамыр, гатырша мае, дарчин кайрысы, тәсбих, шомырт оны, күкерт вә шуның шикелләләр белән сату итү китап сәүдәсе түгеллеге беленде. Халык арасында, аз булса да, яңа әдәбият мәйдан ала башлады. Ләкин мулла тасвир кылынган хикәя булса, муллалар, байлар тасвир кылынган хикәя булса, байлар арасында — яздырмаска кирәк, шуларны бетерергә кирәк, городскуй галавага әйтик! (Безнең халыкта ике зур мәхкәмә — городская дума, иң зур хаким шәһәр башлыгыдыр. Хәтта Кытай белән Япония сугышы вакытында думаның бу сугышны туктатмавы халыкка бик гаҗәп тоелды), шулай итик, болай итик, кебек сүзләр шапыралар-шапыралар иде дә икенче яңа китап чыкканчы туктыйлар иде. Һәр нә исә язучылар һаман язалар иде, китаплар чыга иде, безнең абзыйлар шулай голованы күрә алмаенча торалар иде. Әхлак җәһәтеннән Казан халкы тагы артка калдылар. Бик күп кешеләр тәһзиб әхлак (әхлак төзәтү) өчен дип, төрле тарикатларга керсәләр дә, әхлак көннән-көн бетүдә иде. Моның да сәбәбе — һәр начарлык намаз укыгач бетә, ишаннар — оҗмах юлын күрсәтүчеләр, мәсьәләләренә бик каты ышанып, ишанга кергән кеше ни кадәр начарлыклар кылса да, кыямәт көнендә котыладыр игътикады[125] урынлашты гыннан, һәр кеше оҗмах юлын үзем беләм дигән кебек, теләсә ни кылanудан иде. Һәм дә халыкта һөнәр булмаганга, байлар эшсезлектән начарлыкка салышалар иде. Фәкыйрьләре, шундый кеше арасына төшеп, үзләрен-үзләре белмәенчә, начарлыкта изеләләр иде. Печән базары хатын-кыздан вак-төяк нәрсә эшләтеп кәсеп иткәнгә, кәләпүш, калфак алганга, шул кәсепкә төшкән бер хатынны ирекле-ирексез фәхеш юлына тарталар иде. Болар шәһәр хатыннарының йөздән егерме бишенче бүлеге булганга, шәһәр халкы арасында фәхеш ниһаять дәрәҗәгә җиткән иде. Моннан йөз ел элек ирләре эчмәгән бер милләтнең хатыннары да эчә башлаган иде. Сыра заводлары, гостиницаларның күбесе Казан мөселманнарының акчасы белән байый иде. Шул елларда сала халкы арасында артык яңа бер эш булмаса да, аларда да инкыйраз[126] галәмәтләре көннән-көн күбәя иде. Җирләре кысылганнан һәм дә зирагать[127] гыйлемен белмәүдән, тамакларын туйдырыр өчен ирләре шәһәрләргә төрлесе төрле кара кәсепкә тарала башлаганнар иде. Хатын-кызлары, Казанга вә башка шәһәргә китеп, асрау булып тора башласалар да, бара-тора аларның да күбесе фәхеш юлына китәләр иде. Оренбург, Троицк, Орск, Ханкирмән[128] мөселманнарының хәлләре бу гасырда күп алда иде. Оренбург, Троицк, Орскилар казакъ белән эш иткәнгә, алар белән эш итүгә артык белү кирәк булмаганга, ханкирмәннәр искедән руслар белән сәүдә итеп, сәүдә хакында яхшы гына мәгълүматлары булганга, бирелмәенчәрәк баралар иде. Ләкин алай булса да, Оренбург, Троицк, Орск халыклары арасында ялкаулык, эшләмәенчә тамак туйдыру уе бик тәрәккый иткән иде. Бу шәһәр халыклары бер катлырак булсалар да, боларда да Казан бүләге — фәхеш бик тәрәккый итүдә иде. Тиҗарәт[129] җәһәте дәхи артка калды. Чөнки сатуларымызның күбесе үз арамызда үтә торган әйберләр белән генә булганга, үземез Европа модаларына ияргәнгә, фәкыйрьләремез руслардан калган толчок киемнәре кия башлаганга, эшләгән эшләремез

---

125. Игътикад — ышану, инану. 126. Инкыйраз — бету, сүнү. 127. Зирагать — игенчелек, авыл хуҗалыгы. 128. Ханкирмән — Касыйм шәһәре.

бик аз үтә башлады. Файдамыз ни кадәр кимесә, расходымыз шул кадәр артканга, көннән-көн фәкыйрьләнә бара идек. Егерменче гасырның урталарында ирекле-ирексез мөфлислек[130] күбәйгәнгә, мөселман урамнарында мөселман йортлары сатылып бетмәсә дә, һәммәсенең өстенә хатыннары исеме язылган иде. Бер йортта Әхмәтҗанова, икенче йортта Мөхәммәтҗанова, өченчесендә Абдуллина фамилияләре ялтырап яталар иде. Хәтта шул хосуста Европадан килгән мөстәшрикъ[131] үзенең Казан мөселманнары хакында язган сәяхәтнамәсендә: «Мондый мөселманнар хатыннарга башка шәрык халыклары кебек карамыйлар. Һәммә эшләрендә хатыннар, кәсепләрендә хатыннардыр. Һәм дә Казанда мөселман ягы диган бер җирдә ничә мәхәлләдә һәммә йорт мөселман хатыннарыныңдыр. Болар ирләреннән мөстәкыйлән йортлар бина кылдырып, сатулар иттереп торалар»,— сүзләре язылган иде. Ләкин мөстәшрикъ зәваллы[132] сәяхәтнамәсенең һичбер җирендә: «Бу мөселманнарның ирләренең эшләре кая, йортлары кая, кәсепләре кая?» — мәсьәләләрен карамаган да, уйламаган да иде.

Бу елларда русча укыганнардан яисә читтә гыйлем алганнардан шактый эшләр чыкты. Төрле фәнни, әдәби, тарихи китаплар мәйданга атылды. Бәгъзе яшьләр милләтне инкыйраздан коткарыр өчен, бар куәтләре берлән төрлесе төрле эшкә тотындылар. Авылларга китеп, халыкларны укыта башладылар. Шәһәрләрдә фәкыйрьләрне тәрбия кылыр өчен җәмгыятьләр ачтылар. Аларга акча күбәйтер өчен әдәбият ахшамнары, театрлар уйный башладылар. Хәтта бара-тора Казаннан Оренбургка, Оренбургтан Троицк, Орск, Самара, Әстерхан вә башка мөселман шәһәрләренә йөри торган театр компаниясе дә вөҗүдкә[133] чыкты. Үз мәгыйшәтемездән[134] бик гыйбрәтле уеннар уйнала башлады. Ләкин моннан да акча җыеп булса да, театрдан максуды биззат[135] булган әхлак төзәтү мәсьәләсе бер дә алга китмәде. Чөнки олырак мөселманнар барсалар да, бара-тора шәрык мәгыйшәтен күрәсе килгән руслар театрны тутыра башладылар. Русча белгәннәре рус театрына, белмәгәне ат кәмитләренә баралар иде. Бу гасырларның башында ук болгарча гәзиткә ихтыяҗ бик яхшы аңланган иде. Шуның өчен аңлаганнары, аңлыйм дип йөргәннәре — һәммәсе гәзитә турысыннан уйлыйлар иде. Хәтта бервакытны бер мәҗлестә аштан соң гәзитә турысыннан күп сүз сөйләнгәч, берничә абзыйлар головадан сорамакчы да булганнар иде. Ул да шулай әллә нишләп калды. Рус гәзитәләрендә милли лисанда[136] гәзитәгә ихтыяҗ мөхәкәмә[137] кылына башланды. Ниһаять, гәзитә сорый да башладылар. Почта берлән килгән акчаны үзе кулын куеп ала торган Габделшәмси хәлфәгә бирмәделәр. Хәтта хәлфәнең күптән балалар укытуы мәгълүм, Казан мәдрәсәләренең берсендә тәхсил кылуы билгеле булса да, бер урында тәхсиле гыйлем кылмаган кешегә андый эш бирелми, дип каты җавап кайтарылган иде. Яңа гына Алат юлыннан күчеп килгән, читек-кәвеш белән сату итүче Шаһвәли дә сорады (?!!). Аңарга да, белмим, ни өчендер бирмәделәр. Хәтта бу хосуста агай-эне тагы головага менмәкче дә булганнар иде дә, сайланган кешеләрдән берсенең эче бик авырта башлагач, изгеләр тотты бугай дип, Касыйм шәехкә әтәч җибәреп кенә котылды. Бара-тора чибәррәк

129. Тиҗарәт — сәүдә. 130. Мөфлислек — бөлү, банкрот булу. 131. Мөстәшрикъ — көнчыгышны өйрәнүче. 132. Зәваллы — бичара. 133. Вөҗүд — барлыкка килү. 134. Мәгыйшәт — тормыш. 135. Максуды биззат — төп максат. 136. Лисан — тел. 137. Мөхәкәмә — тикшерү, хөкем чыгару.

кешеләр дә сорый башладылар. Ахырында фәкыйрь генә, яңа гына университет бетергән бер мөселман рөхсәт алды. Казанда «Кабан» исемендә әдәби, фәнни, мәгыйшәт мәсьәләләрен мөзакәрә[138] кыла торган атналык бер газитә мәйданга чыкты. Халык акрынлап кына газитә укырга өйрәнә башлады. Озак үтмәде, шуннан әллә кайдан бер шәкерт чыкты да «агай-эне»дән бик күлеп яза башлады. Хәтта корсакларына чикле, атасыннан калган доха, толыпларына чикле каләмнән үткәрә башлады. «Бу — мөселман гаебен ачу, мөселман гаебен ачу!» — дип, харчевникларда ике дә өч чәй алып, харчевникчының үзен дә утыртып, бикләтергә кирәклеген бик сөйләсәләр дә, иртәгесен икенче газитәдә шул сүзләр үк чыккач, бөтенләй кул селтәделәр. Озак үтмәде, «Игенче вә һөнәр» исемендә бик садә бер телдә гавам[139] өчен тагы бер газитә чыга башлады. Бу газитәне алучы бик аз булса да, бер аңлаган бай малае, атасының халыкны талап җыйган акчасы халыкка китсен дип, газитәне бушлай да бик күп тараттырды. Казан халкын бер милләт диярлгә ярый иде. Үзләренең газитәләре бар, театрлары бар, хатыннарының йортлары бар иде. Шунысы бик яман: мәктәпләр, мәдрәсәләр бер дә юк иде...

Әдәби лисан мәсьәләсе бетә башлагач, лисанның рәсме хаты[140] хакында озын мәсьәлә башланган иде. Бәгъзеләре ни тавыш ишетелде, шулай язылсын, иске язу әсас[141] тотылмасын, диләр иде. Икенчеләре, безнең телемездә әдәбиятымызның иске әдәбияттан килүе югалмасын, иске китапларымыз, иске әдәбиятымыз ул вакытта бер нигә ярамаячак, шуның өчен аларга карарга кирәк, диләр иде. Язалар иде, сөйлиләр иде, кычкырышалар иде, үз юлларында эшлиләр иде. Әдәбиятымыз хакында озын-озын мәкаләләр, мөхәррирләремезгә ачы-ачы, ләкин хакканый[142] тәнкыйтьләр, театрымызга юл күрсәтә торган сүзләр языла иде, укыла иде. Бөтен халык арасында мөхәкәмәгә тотыла иде. Газитәләремездә тиҗарәт[143] мәсьәләләре ачык-ачык мөхәкәмә кылына башлаган иде. Һәммә җирдә, тиҗарәт мәктәбе тәэсис[144] кылу хосусында сүзләр ачылган иде. Болгарлар арасында көннән-көн яңа фикер арта, көннән-көн халык төрле фикерләргә китеп, ноктаи интизагдан[145] еракланалар иде. Газитә, рисаләләр, авыздан авызга сөйләгән сүзләр ни кадәр хәмият,[146] хаккы пәрвәр,[147] мәхәббәте миллиядән чыккан фөрьяде фиганнар[148] булса да, ни кадәр аңлашылыр тарызда[149] язылса да, аңлаучыларның да гададе[150] көннән-көн артса да, базарларда, җәмгыять урыннарында һәммә кешенең авызында «милләт» булса да, эшчеләр бер дә күренмәгәнлеккә, билфигыль[151] эш тә юк иде. Шуның өчен җиддирәк кешеләр бу сүзләр, бу кычкырышлар, бу язулардан бер нәрсә чыкмаганга, тагы яңа «курчак» уены, ләкин актыккы курчак уены, саубуллашу манзарасы[152] дип, эчләреннән күеп торалар иде. Сөйләнгән саен сүз күбәя, уйлаган саен уй күбәя, үлем хәленә килгән милләтне караган саен яңа авырулар табыла, авыру турында мөхәкәмәләргә керешелә, кычкырышыла, бакырышыла иде. Нидән бу мәсьәлә чыкканлыгы, ничек хәл кылынганлыгы, авыруга дару кирәклеге тәмам хәтердән чыга иде дә: мескен, хәлсез, актык сулусындагы болгар бабайның башын авырттырудан башка эш булмый иде. Ул мескен: «Җитәр инде; зинһар җитәр, актык көннәрем, актык сәгатьләремне генә тыныч куеңыз! Сүзеңезне ишеттем, мине бик кызганасыз, имеш, бик рәхмәт, моңарчы сезнең шулай мине кызганамыз дип йөрүеңезгә

---

138. Мөзәкарә — фикер алышу. 139. Гавам — масса, халык. 140. Рәсме хат — язу, почерк. 141. Әсас — нигез. 142. Хакканый — дөрес, гадел. 143. Тиҗарәт — сәүдә. 144. Тәэсис — нигезләү. 145. Ноктаи интизаг — каршылык, бәхәснең асылы. 146. Хәмият — саклану. 147. Хаккы пәрвәр — хаклык тарафдары. 148. Фөрьяде фиган — елау, ялвару. 149. Тарыз — рәвеш. 150. Гадәд — сан. 151. Билфигыль — чынлыкта. 152. Манзара — күренеш.

ышанып, минә тереләм, минә тереләм, дип тордым. Тордым дияргә ярамый, сез алдап тоттыңыз, сез булмасаңыз, бәлки мин икенче докторга күренер идем. Күренмәсәм, авыру икәнемне белмәенчә, акыртын-акыртын гына картая-картая үлеп китәр идем. Ни кадәр вакыттан бирле чирле, фәлән дару итәргә кирәк, дисез. Үзегез дару итмисез, яисә дару дип, әллә нинди агулар бирәсез, бусында бу файда бар, бусында бусы бар, дисез, сез алдыйсыз! Алдыйсыз! Сезнең даруларыгыз берлән бөтен тәнем җәрәхәтләнеп бетте, сезнең файда була дип биргән нәрсәңез һәммәсе зарарга булды. Сез минем тәнемне генә җәрәхәтләндереп бетермәдеңез! Бигрәк яхшы булдыңыз! Рухымны да төзәтмәкче булдыңыз! «Тәһзиб әхлак»[153] дип минем өстемә әллә нинди кортлар җибәрдеңез! Ул кортлар бөтен тәнемне ашап бетерделәр, караңыз, әнә хәзер йөрәгемә җиткәләр, миңа һаман, түз, әхлакың төзәлә, дисез. Мин үзем бу дәрәҗәгә килгәч, сезнең сүзеңезне тагын тыңлыйммы? Йөрәгемне дә ашап бетерсеннәрме?.. Гаеп итмәңез инде, анысы булмый!.. Бу кортларыңыз бетәргә ярамый, имеш, элгәре боларга бер дә ирек юк иде дә, бик яхшы тора идек. Әхлаклы идекме, түгелме, ләкин, сезнең кебек, бусы тәнгә файдалы, бусы әхлакка файдалы дип, фәхеш, зина, ишанлык агуларын эчми идек! Гаеп итмәңез! Бу кортлар бик күп ашадылар. Минем әхлакым да төзәлгәндер инде, мин ул кортларны үтермәкче булам, тәнемә бераз яшь ит таратмасмы! «Алай да үләрмен инде, үлсәм дә, азрак күңелем тынычлап, картлыгымда алдаганнарымнан үч алып үләрмен» дип, кортларны куарга тотынса да, бабайның әгъзасын ашап бетергәнгә, һичбер әгъзасы кортларга каршы хәрәкәт кылырлык калмаган иде. Шуның өчен, бабай селеккән саен, кортлар ябыша баралар иде. Йөрәгенә кадәр җиткәннәр иде. Бабайның бу сүзен күп кеше картлыктан дип, күп кеше авыру кеше шулай сөйләүчән була дип, аның ул сүзенә карамаенча, аны коткарырга дип озын киңәшләр, озын сүзләргә тагы китәләр иде. Ләкин эш һаман юк иде, әдәбиятымыз шулай барганда, башка эшләремез тагы үз көенчә килгәндә, безнең болгар бабайның яшь вакытында, «тәһзиб әхлак» өчен истигъмаль[154] кыла торган музыкасы ни дәрәҗәдә иде дисезме? Әллә (саут әл-мәлаһи фискын вә әттәлазе биһ көфрен)* дисезме, сез теләсәңез, бабай аны бик ярата иде. Һәм бабайга яшь вакытында да, картая башлагач та, ул бик файда иткән иде. Бабайның үзенеке булганга күрә, аңарга аның бер уенын, аның Волга буйлап Ефрат, Дәҗлә буйларына кадәр озыннның-озын көйләрен көйләп, сатуга йөрүләрен, Дунай буйларында кубызын чылтыратып, халыкны исен китереп, алардан мал җыеп йөрүен исенә төшерә иде дә — мин шул болгармыни?! Шул микәнни?!! Ул вакытта һәммә җирдә минем тазалыгым, өстем-башымның яхшылыгына, кайтсам, өемнең тынычлыгына исе китмәгән кеше юк иде. Хәзер нинди булганмын — өстемә әллә нинди сәләмә кеше киемен киенгәнмен, элгәреге кызыл йөзләр урынында саргайган битләр булган; уйнап тора торган күзләр урынында өмитсез-өмитсез карый торган тирән-тирән чокырлар булган, озын юллардан кайткач, хәл итәргә ята торган тыныч өйләрем кандала базы, корт оясы булган, аның да һәр көнне бер агачы сына, һәр көнне өстемә җимерелергә якынлаша, һәр көнне шуларга карап, яшь вакытларны искә төшерәм. Картайдым, фәкыйрьләндем, авыруга сабыштым, дип үзенең хәзерге хәле белән иске хәле арасын чагыштырып карарга сәбәп була иде. Бу музыка хәкыйкатән әхлак мөгаллиме була торган нәрсә булса да, хакыйкый, «әхлакны тәһзиб» өчен шул музыка җитсә дә, музыкага халкымызның нәзары[155] башкарганга, ягъни аның әхлак төзәтүче икәнлегенә

153. Тәһзиб — төзәтү. 154. Истигъмаль — куллану. 155. Нәзар — караш.
* Музыка тавышы — бозыклык, аның белән ләззәтләнү — көфер.

ышанып, шуның белән файдалану урынына, аны үзен «әхлак бозучы» дип каралганга һәм әхлакка хезмәт итә торган кеше арасында аны мәкруһ[156] күрелгәнгә, аны әхлаксыз кешеләр кулына төшергән иде.

Һәммә җирдә музыканы фәхеш, исерткечнең гаебен капларга истигмаль кылу халык арасында тарала башлаган иде. Музыканың бу эшен күргәч, ягъни әхлакка файда итәр урында, әхлаксызлыкка тарта башлагач, музыка мотлак[157] зарарлы хөкеме чыгарылды. Шуның өчен музыка үзе дә фәхеш хезмәтчесе булды. Болгар музыкасы шул кадәр пычракланган, болгар җырлары шул кадәр әхлаксызланган иде, аларны бер минут тыңлау бик авыр була иде. Шул сәбәптән милли тел, милли әдәбият, милли театр мәсьәләләре арасына милли музыка мәсьәләсе керә алмаган иде. Шул мәсьәләләр белән мәшгуль кешеләр дә милләтнең тәрәккыйсенә милли музыкаларның кирәклеген, милли рухны саклау милли музыка эше икәнлеген хәтергә дә кертми кебек үтеп баралар иде. Болгар халкы никадәр музыка сөя торган милләт булсалар да, аңарга кирәгенчә каралмаганга һәм аларны белү җинаять итеп саналганга, ул дивар артларында гына калган иде. Хатын-кызларымызда моңарга мәхәббәт тагы артык булса да, алар да изелеп кенә калганнар иде. Ниһаять, унтугызынчы гасыр ахырларында музыканың җинаять түгеллеге сөйләнмәсә дә, акыртын-акыртын гына рәтләнә башлады. Казанда Минкин Гариф исемендә бер кеше болгар музыкаларын нотага сала башлады, ниһаять, никадәр иске вә яңа көйләрне рәткә салды. Бу кеше бәлки яхшы түгелдер, бәлки яхшыдыр, бәлки моны голәмалар яратмый торганнардыр — мин анысын белмим, ләкин бу кеше милләткә шул кадәр хезмәт итте, моның хезмәте мотлакан кыямәткә кадәр онытылмаячактыр.

«Яшәсен Гариф Минкин!! Яшәсен милләт!» — тавышлары бездин балаларымызга, балаларымыздан аларның балаларына кадәр, хасыйле,[158] иң актыккы болгарга кадәр авыздан төшмәячәк, аннан соң да шундый гүзәл музыка калдырдыгы өчен, европалылар арасында да онытылмаячактыр. Моннан соң болгарлар арасында музыка машиналары күренә башланды. Болгарларның залында «Сакмар суы», «Тәфкилев», «Әллүки», «Казан алган көй» вә башка көйләр ишетелә башлады. Ирләремез, кызларымыз — һәммәсе йөз,мең елдан бирле бабайларымыз тарафыннан эшләнгән музыканың, бабайларымызга уйлаткан уйларны, бабайларымызга биргән хисләрне балаларына бирә башлады. Бу да байларга гына махсус булганга, гавам халкы арасында, һәр кыз мунчага төшеп биергә, кубыз уйнарга тырышса да, иркенлек булмаганга, аларның бик аз гынасы халык арасында «азган», муллалар каршысында «ахмак» сүзе берлән тәгъбир кылына торганнары гына файдаланалар. Искедәге бабайлар хисләрен аңлый алалар, үзләренең кайгыларын тарата алалар иде. Әдәбият берлән музыка милләтнең атасы берлән анасы икәнлеге һәркемгә мәгълүм бер эш, тарих берлән мөсбәт[159] бер хакыйкать булса да, ата никадәр сәламәт булса да, анасыз бала тумавы мәгълүм булса да, атасыз — анасыз бала да зинадан туган икәнлеге ышанычлы эш булса да, милләтнең атасы берлән анасы булган музыка берлән әдәбиятны бергә торырга никах укытырга, берсенә-берсе файда итешергә, берсен-берсе саклашырга вәгъдә кыйлышуларын алырга теләмиләр дә иде, алмыйлар да иде. Шуның өчен безнең көткән баламыз яисә тумаячак, туса, зинадан туачак иде дә, безнең йөземезне генә кызартачак иде. Егерменче гасырның башларында, унтугызынчы гасырда Казанда

156. Мәкруһ — начар күрелгән, сөйкемсез. 157. Мотлак — бөтенләе белән, абсолют. 158. Хасыйле — кыскасы. 159. Мөсбәт — исбат ителгән. * Гизле — яшерен.

музыка гизлечә* тәрәккый итсә дә, гомум файдалана торган җирләр юк иде.

Болгарча музыка ахшамнары, концертлар һич ишетелми иде, шуның өчен андый музыка ишетергә теләгән кеше, музыка берлән үзенең кайгыларын таратырга тырышкан кеше, үзен кайгылар, мәшәкатьләрдән аерып алып, үзен генә карарга теләгән кешеләр музыка тыңлый торган урын юкка, кайсылары фәхеш җиренә баралар иде, кайсылары икенче халык музыкасын тыңлыйлар иде, кайсылары кайгыларын йотып өйдә утырып калалар иде.

Егерменче гасыр башында ук музыка вә әдәбият ахшамнары ачылуы мөляхәзә[160] кылына башлады һәм бер музыкант тарафыннан иң әүвәл Казанда, аннан башка шәһәрләрдә музыка ахшамнары тәэсис[161] ителә башлады. Ләкин халык моңарга элекке нәзарын үзгәртмәгәнгә, голәма бик тирес[162] торганга, бу эш тәрәккый итә алмады. Башлаган кешенең акчасы юкка, дәвам итәргә акча кирәк булганга, күп үтмәенчә бетеп һәм, гомерләр үтә-үтә, тарих берлән күмелеп, «элгәре бездә дә музыка ахшамнары булган икән», дип сөйләргә генә калган иде. Шул вакыйгадан соң музыкага артык әһәмият бирүче дә чыкмаган иде, һәм музыка үзе дә мәйданга чыгып эшкә тотынмаган иде. Шуның өчен музыка тагы фәхеш эченә чумган, тагы үзенең ләтафәт тәбигыясен[163] югалткан иде. Гәзитәләрдә ахырга таба музыка хакында язылган мәкаләләр күренә башласа да, алар да музыка кешеләре тарафыннан язылмаенча, музыка хакында мәгълүматлары бар кешеләр генә язган булганга, калебтән чыкмаганга, халыкка ул дәрәҗә тәэсир кылмый иде.

Халык арасында музыкадан гармунны, скрипка-фәләнне шыгырдату бетмәсә дә, аларны нәзафәт[164] табигыяләренә кайтаручылар күренми иде. Шуның өчен музыкамыз көннән-көн тәдәнни[165] итә, көннән-көн миллилеген югалта, көннән-көн халык арасында әһәмияте бетә иде.

Рәссамлык безнең халыкта булганы да юк иде, беткәне дә юк иде. Динемезгә тәрсим[166] мәмнүгъ[167] булгангамы, әллә үземездә рәсемнәрдән мәгънә алырлык хис булмагангамы, рәссамнар юк иде. Рәссамнарымызга вак-төяк мәсҗет сурәтләре, хәрәм шәриф[168] сурәтләре — Мәккә, Мәдинә манзаралары гына булганга, алар да фотография берлән алынудан башка, төрекләр яисә гарәпләр тарафыннан эшләнгәннәр иде.

Китап кибетләремездә башмак шәриф, гасаи мөбарәк,* комган һәм дә, «Йаһу[169]-йаминһу»[170] дип аһлар белән яна торган, күзләреннән дәрья кебек яшьләр ага торган, сулаган саен авызыннан ут чыга торган «Мөэмин күңеле» исемендә вә шуның кебекләр мәйданга чыкса да, болар рәсемнәр бирә торган файданы, хис арттыруны бирү урынына, үзләрен тупаслата, дөнья хакында, тормыш хакында ялган уйлар белән гавамның[171] башын гына тутыра иде. Егерменче гасыр башларында рус рәссамнары болгар мәгыйшәтеннән[172] рәсемнәр ясый башладылар һәм Русиядә вә хәтта Европада рәсемнәренең мәгънәлеге, үзенә бер төсле оригинальлеге (оригинальный) белән бик могтәбәр[173] булдылар. Хосусан,[174] «Өрпәк сарган болгар карчыгының кунак сыйлавы», бер болгар картының сату сәфәренә

---

160. Мөләхәзә — фикер йөртү. 161. Тәэсис — төзү, кору. 162. Тирес (диал.) — кире. 163. Ләтафәт табигыя — табигый гүзәллек. 164. Нәзафәт — ару, пакьлек. 165. Тәдәнни — түбән төшү. 166. Тәрсим — рәсем ясау. 167. Мәмнугъ — тыелган. 168. Хәрәм шәриф — изге Мәккә шәһәре дигәнне аңлата. 169. Йаһу — и алла, я алла. 170. Йаминһу — ант итү, каргану. 171. Гавам — халык. 172. Мәгыйшәт — тормыш. 173. Могтәбәр,— хөрмәтле. 174. Хосусан — бигрәк тә. 175. Хазир — хәзер, шушы вакыт. 176. Моталага — уку, өйрәнү.

* Гасаи мөбарәк — алла тарафыннан Мусага бирелгән тылсымлы таяк.

китәр алдыннан, юл киемнәре берлән балалары, хатыны хазир[175] булган бер мәҗлестә «Дога кыйлуы», «Бер болгар шәкертенең мәдрәсә почмагында ялтырый торган ут яктысында күлмәк өстеннән генә юрганын салып казый моталага[176] кылуы», «Бер мулла кызының чаршау артыннан гына үзенең иптәшләре берлән аталарыннан качып язу өйрәнүе» рәсемнәре табигыйләр иде, дөресләр иде. Бу рәсемнәр әүвәлләре һәммәмезгә дә үземезнең, тормышымызны күрсәтә башладыклары кебек, арамызда шундый эшкә кабилиятлеләремезнең[177] дәртен уяндырырга да сәбәп булган иде. Шуның өчен егерменче гасыр урталарында болгарлардан рәссамнар чыга башлаган иде. Һәм дә мәйданга болгар рәсемнәре атыла башлаган иде. Бу рәсемнәр арасында болгар кызларының киндер агартуы, болгар егетләренең тау башында, яз көне су ташуында музыкада уйнаулары, ат ашата торган малайларның бәрәңге пешерүләре халык арасында могтәбәр булган һәм дә рәсемнәрен дә игътибарга керткән иде. Моңарга башка әхлак галәменнән, әхлаксызлык манзараларыннан бик күп рәсемнәр ясалган иде. Кара халык, замана фикеренә авышкан халык, болардан зарар булуны һич уйламаенча, өйләренә тага, балаларына мәгънәләрен сөйләп күрсәтә башласалар да, голәма таифәсе тагы бик каты аякланып, рәсемнең хәрамлыгы хакында, диварларга элү ярамавы хакында, рәсемнең күңел каралтуы, фәрештә качыруы хакында күп сүзләр сөйләнеп кенә калмаенча, мәсҗетләрдә вәгазьләр сөйләнеп, шул хосуста китаплар, рисаләләр дә язылды. Голәмалар арасында ярый диючеләр дә булганга, тагы бер низаг купты. Дин мәсьәләсе мөзакәрә[178] кылыр өчен мәҗлесләр ясала башлады. Яңа курчак туена мәйдан тагы ачылды. Язылды, укылды, сөйләнде, кычкырышылды, тагы берни чыкмады, мәсьәлә шул көенчә калды. Ләкин бу тавыш рәсемнәргә шактый гына зарар булды. Рәсемнәре аз үтә башлады, үзләренә халыкның нәзары башкарды. Рәссамлыкка хәзерләнә торган яшьләрнең күбесен атасы-анасы, карендәш-кабиләсе туктата башладылар. Туктамаганнарына тагы «бозылган» дип карый башладылар. Озак үтмәде, рәссамнарымыз кайсылары үлделәр, кайсылары тамак туйдырыр өчен рәссамлыкны икенче дәрәҗәгә калдырдылар. Ни булса да булды, бер вакытны мәдрәсәләр, мәктәпләр беткән кебек, музыкамыз әхлаксызлыкка чумган кебек, рәссамнарымыз да беттеләр. Сез шул вакытта фәннәр ни дәрәҗә иде, аларга игътибар бар идеме, фәнни китап бар идеме, диярсез. Бар иде. Унтугызынчы гасырның башында фәнни әдәбият мәйданга чыккан иде. Чыгуы берлән бик олылап каршы алынмаса да, акыртын гына тәрәккый иткән иде. Һәр фәннән мохтасар,[179] мөкәммәл[180] китаплар бар иде. Һәр фәннең әһеле[181] бар иде. Һәр фән азмы-күпме укыла иде, фәнни мәсьәләләр хакында мөхәккәмәләр кылына иде. Ләкин бу фәннәр мәктәпләрдә, мәдрәсәләрдә тәхсил кылынмаенча, романнар кебек, һәр кешенең үзе тарафыннан гына укылганга, төбенә төшеп җителми иде, һәм дә фән белүчеләре дә фәннең кагыйдәләрен генә беләләр иде, аны эшкә татбикъ[182] кыла алмыйлар иде. Шуның өчен фәннең тәрәккый итүе күз ачылуга гына сәбәп була иде. Милләткә матди файда итә алмый иде. Булмавына караганда монысына да шатланырга ярый әле. Ләкин шулай булса да, бу фәннең дә алга китүенә, аның милли булуына бик күп кешеләр, бик күп гайрәтләр, бик күп хезмәтләр сарыф кылсалар да, моннан да дингә зарар күргән голәмаларымыз монда да бик зур низаглар чыгарганнар иде. Болар әүвәлдә һәйәт[183] мәсьәләсеннән генә чыкса да,

---

177. Кабилият — сәләтлелек. 178. Мөзакәрә — фикер алышу. 179. Мохтасар — кыска, кыскача. 180. Мөкәммәл — тулыландырган, камилләштергән. 181. Әһел — кеше. 182. Татбикъ — яраштыру, килештерү. 183. Һәйәт — астрономия. 184. Хикмәте табигыя — физика, гомумән, табигать белеме 185. Мохаләфәт — каршы килү.

бара-тора голәмаларымыз тарих, җәгърәфия, хикмәте табигыя[184] фәннәренә дә барып җиттеләр. Һәммәсендә дә дингә мохаләфәт,[185] шәригатькә сыймаулар китереп чыгаралар иде. Үз дәлилләрен куәтләр өчен Коръәннән, хәдистән тирес-мерес мәгънәләр чыгарып, әллә ниләр кыландырып бетерәләр иде. Бу да үзенчә бер курчак туе иде, бу низаглар гәзитәләремезгә, журналларымызга, хәтта календарьларымызга да кергән иде, монда да актыккы хөкем «тәкфир»[186] иде. Фән әрбабы[187] никадәр фәнне яратсалар да, никадәр фәнгә хезмәт итсәләр дә, хезмәтләре әсаслы[188] булмаганга, фәнне дошманнан саклар өчен бер кальга (крепость) — фән мәктәбе бина кыйлынмаганга, бу фәнемез дә бервакытны музыкамыз, рәсемнәремез кебек һәлак булачагында шөбһә юк иде. Ел үткән саен фәнни китаплар арта барса да укучылары азая иде. Һәм дә әүвәлдәге кебек, фән фидаиләре[189] бер дә кренми иде. Шуның өчен бу да озакламаенча бетәчәк иде. Голүм[190] исламия хакында сөйләргә дә юк. Чөнки бездә аның тәрәккый иткәне дә юк иде, тәдәнни[191] иткәне дә юк иде. Нинди зур мәдрәсәләремез, нинди шөһрәт тапкан голәмаларымыз булса да, Һәммәсе исламның ни икәнен, исламның рухын аңламаганнар вә диннең фәлсәфәсеннән хәбәр ала алмаганнар иде. Безнең голәмаларымызның гыйльме һәрвакыт бер хөкемне төрлечә моляхәзә кылып, бер тарикъча[192] аңлау булмаенча, диннең гадәтләрен белүгә генә мөнхәсыйр[193] иде. Шуның өчен бездә истинҗа[194] мәсьәләсен, хәез,[195] нифас[196] мәсьәләсен белгән кешеләр пигамбәремез галиәссәламның кая туганлыгын белмәсәләр дә, һичбер шәргый[197] мәсьәләнең фәлсәфәсен белмәсәләр дә, голәма итлак[198] кылына иде. Шуның өчен болар нинди генә файдалы яңа мәсьәлә чыкса да, үзләренең «китабел-истинҗа»ларына карарга тотыналар иде, анда булмагач, хәрәмлеге белән хөкем кылалар иде.

Мәдрәсәләргә карасак, аларда да өмет юк иде. Иске мәдрәсәләр заман үтә-үтә искереп, хәрабә хәленә килгәннәр иде. Банилары[199] әллә кайчан үлеп беткәнгә, мәдрәсәнең кирәгенә вакыфлар[200] калдырмаганга, мәдрәсәләр әлгәре торырлык булса да, бара-тора олы тәрәзәләре гамәлдән чыгып, аннан соң ашханәләре яраксызланып, гомер үтә-үтә түшәмнәре, диварлары да бозылып, торырлыктан чыккан иде. Шуның өчен теләр-теләмәс бәгъзе мәдрәсәләр ябылган, бәгъзеләре ябылмаса да, мәдрәсәләрнең бер башында гына тора башлаганнар иде. Аңарга башка да, ул мәдрәсәләрнең дәрес ислах кылынмаганга күрә, ысулы тәгълим бик начар булганга һәм аннан тәхсил күргән кешеләр бер нәрсәгә дә ярамаганга, ул мәдрәсәләргә керүчеләр көннән-көн азаюда иде. Бәгъзе мәдрәсәләрдә егерменче гасыр башларында ислах-фәлән диган сүзне ишеткәләгән булсалар да, бу сүзләрне әйтүчеләр үзләре дә ислах ни диган сүз, мәдрәсә ни диган сүз икәнне белмәгән кешеләр булганга, фәкать фонограф[201] төсле, кешедән ишеткәнне сөйләгәнгә, яисә шулай сөйләү модада булганга, «Менә, ийе, ислах кирәк, ахрысы, без ысулы җәдидне инкяр кылмыймыз, голәмаларны гына сүкмәскә кирәк»,— дип сөйләнсәләр дә, берни дә чыкмаенча калган иде. Яңа байлар, җәмгыятьләр бу мәдрәсәләрне төзәтергә, ислах кылырга акча да таба алмыйлар һәм черегән фикерле голәмаларга да сүз дә аңлата алмыйлар иде. Алар һаман шул коруне

186. Тәкфир — көфер дип белдерү. 187. Әрбаб — ияләр. 188. Әсаслы — нигезле. 189. Фидаи — үзен-үзе аямаучы. 190. Голүм — фәннәр. 191. Тәдәнни — түбән төшү. 192. Тарикъ — юл, юнәлеш. 193. Мөнхәсыйр — чикләнү. 194. Истинҗа — тәһараттән соң пакьләнү. 195. Хәез — күрем. 196. Нифас — бала тудыру. 197. Шәргый — шәригатькә бәйле. 198. Итлак — аталу. 199. Бани — нигез салучы. 200. Вакыф — изге эшкә бирелгән мал. 201. Фонограф — авазларны язып ала торган прибор. 202. Коруне васата — урта гасырлар.

вәсата[202] гадәтенчә, китап күтәреп «дәрескә кердем» дип йөрүне бик зурга саныйлар иде. Яңа кешеләр кыяматтән бигрәк белем кирәклеген дә сөйләп, бер-берсен аңлаша алмаганга, икесе дә берсенә-берсе кул селтәгәннәр иде, шуның өчен голәмалар аларны кяфер дип, тегеләре голәмаларны дин кортлары, дин бетерүчеләр, дип йөриләр иде. Мәктәпләр әүвәлрәк ысулы җәдид яңа чыкканда шактый гына ачылган булса да, алар да әсассыз булганга, бани үлү берлән, яисә мөгаллиме китүе берлән, яисә хәзрәтнең сарык бәрәннәре бу ел күбәюе сәбәпле, абыстай бәрәннәрне шунда яптыра башлавы берлән беткән иде. Кызлар абыстайларда укып йөрсәләр дә, мәктәп исеме бирергә яраклы кызлар мәктәпләре булганы да юк иде, беткәне дә юк иде. Шул сәбәптән бөтен Русиясендә бер-ике мәдрәсәдән башка һәм дә җәмгыятьләр идарәсендә укыла торган дүрт-биш мәктәптән башка укыр җирләр юк иде. Хөкүмәт мәктәпләрендә тәхсил итүчеләр бик аз иде. Күбесе иске тәгассепләреннән[203] котыла алмаган иде, бәгъзеләре балаларын укытырга теләсәләр дә, акча юк иде. Шуның өчен русча уку интеллигентныйларга гына махсус иде. Алар да бәрәмләп яисә унлап кына саналганга, укучылар шул саннарыннан күп узмыйлар иде. Егерменче гасырның яртылары җитте. Болгарлар һаман акрын гына, кая барганнарын белмәенчә генә, ни эшләгәннәрен дә уйламаенча гына, инкыйраз юлы белән баралар иде. Милләтнең иң күбесе булган авыл халкы, бәгъзесе җир җитмәүдән, бәгъзесе җир җитсә дә, шәһәрләрдә торуга кызыгудан, төрлесе төрле якка бәхет эзләргә таралганнар иде һәм көннән-көн таралуда иделәр. Болар, билгеле, әүвәлдә кара эштән башлап, миллионщик булачаклар иде, шуның өчен һәммәсенең дә башта ук миллионнар белән эш башларга әлегә акча булмаганга, заводларда аена сигез тәңкәгә эшләп, шул миллионнарны җыярга башлыйлар иде. Мондый җирләрдә бердән һавасы булмаганга, икенчедән сигез сумга җәмәгатьне тәрбия кыйлу икмәк белән судан артмаганга, боларның миллионщик булуы һаман артка кала барса да, сәламәтлекләре көннән-көн кимеп, ахырыннан вакытлы-вакытсыз бер эшкә ярамый торган картлар яисә үзләрен дә тәрбия кыла алмый торган гариплләр булып калалар иде. Мондый җирләрдә шундый киләчәктәге миллионщиклар бик күп булганга һәм фатирлар-фәләннәр дә бергә булганга, андый җәмгыятьле җирләрдә таралуы табигый булган фәхеш болар арасында бик тәрәккый итүдә иде. Бу фәхешнең таралуы һәммә рәзаләтнең[204] башы булып, әхлакның бөтенләй югалуына сәбәп булдыгы кебек, мондый баракларда фаҗигалар да бик күп булуына башчы була иде. Алар белән генә дә калмаенча, фәхеш баласы булган йогышлы чирләрдән сифилис (җөзам) таралып, ул кешеләрдән балаларына, кардәшләренә, ашташларына җәелеп, һәм дә, авылларга кунакка кайтканда, авыл халыклары арасында «бүләк»ләр калдырып, бөтен милләтне сифилискә вә башка йогышлы чирләргә ияртеп бетерәләр иде. Вакытында докторларга мөрәҗәгать кылынса, аларның киңәшләре белән дарулансалар, бәлки бу авырулар да ул дәрәҗәдә бөтен халыкка җәелмәс иде. Бердән, докторларымыз юктан, икенче, даруларымыз юклыктан, өченче, акча юклыктан, дүртенчедән, тыйбка[205] ышанмавымыздан, һич аларга каршы чарасы каралмаенча, «алла сакласа, берни булмас әле», сүзләре берлән генә торалар иде. Һәм көннән-көн инкыйраз орлыгын чәчә баралар иде.

Моңарга башка да әүвәлләре киң һавада тамак туйдырып, күп ит ашарга өйрәнгән бер халык булып, бердән һавасыз бүлмәләрдә ит урнына каткан икмәкләргә керешкәнгә, табигатьләре күтәрә алмаенча, чахотка, катар, белмим тагы ни кебек авырулар белән

---

203 Тәгассеп — фанатизм. 204 Рәзаләт — хурлык, яманлык. 205 Тыйб — медицина. 206 Мөбтәлә — дучар булу. 207 Гадәд — сан.

мөбтәләләнеп,[206] көннән-көн үлүнең гадәде[207] күбәюдә иде.

Бер яктан, җәмәгать тәрбия кылырга җитәрлек эш эшләү бик авыр булганга, икенче яктан, кирәк вакытта хәйванлык өчен хатын-нар табу бик җиңел булганга, өйләнү, кияүгә бару бик сирәкләнгән иде. Гомере буенча өйләнмәенчә сакалы агарган картлар һәм дә кияүгә китмәенчә керче, ашчы, тегүче яисә бөтенләй сатучы[208] булып гомер үткәргән карчыклар һәм дә шуларның юлы берлән бара торган хатыннар, шулар юлы берлән барырга сабак алып килә торган кызлар, егетләрнең исәбе-хисабы юк иде. Бу эшнең бик күбәюенә никах-талак мәсьәләләренә кирәге кадәр әһәмият бирелмәдегә, аларга бер уенчык кына иттереп каралдыгы да бик зур сәбәп булган иде. Шуның өчен булган өйләнү дә, кияүгә бару да икесенең бергә торыр өчен кылган вәгъдәләре булмаенча, бер төрле мәҗүсилек[209] гадәтләреннән генә иттерелгән бер эш төсле генә карала иде. Һәм дә фамилия тормышының дәвамында да сәбәп булмый иде. Никахның, талакның бу төрлесен хәзер дә бетерү мөмкин түгел иде. Чөнки алар хәзер бөтенләй урнашып бетеп, безнең генә арамызда милли гадәтләрдән саналган иде. Бу эшләрнең башлануы унтугызынчы гасырда гына булса да, ул гасырның голәмасы, идарәи руханисе моңарга әһәмият бирмәдекләреннән, бу эш җәрәхәткә кунган микроб кебек, тиз гомердә бик күбәеп, бөтенләй канымызга кадәр кушылып киткән иде. Шул сәбәптән бала табу, бала тәрбия кылу бик сирәк иде. Чөнки андый балаларны табу да аналарына, бердән, табу мәшәкате, икенчедән, тәрбия кылу мәшәкате булачак булганга, ике мәшәкатьтән дә бер юлы котылыр өчен, тапмас өчен әллә нинди агулар эчәләр иде. Бу агулар күп вакытта үзләренә дә бик каты тәэсир кылып, шундый хатыннар арасында үлеп һәм гарип булып калуның исәбе-хисабы юк иде. Бәгъзе яшьрәкләре, үзенең йөкле булуын белми калганнары, яисә эчкән дарулары файдалы булмаганнары тапкаласалар да, балаларның күбесе зәгыйфь туа иде. Һәм дә тагы да тәрбиягә җай булмагач, я суларга ташлана яисә (үземездә андый йортлар салу харам булганга!) руслар тарафыннан ясалган йортларга ыргытылына иде. Шул эшләр сәбәпле, көннән-көн үлүчеләрнең саны күп булса да, туучыларның гадәде кимүдә иде. Бу эшләр безнең инкыйразымызның сәбәбе идеген белгән кешеләр аз булмасалар да, алар да берни эшли алмыйлар иде. «Бетәмез» дип фөрьядлар[210] язып халык арасында тараталар иде. Ләкин укымаган халыкка, укыган булса да, шул дәрәҗә әхлаксызланган халыкка шундый рисаләләр белән генә тәэсир итүнең һич имканы юк иде. Тагы да тәэсирләнсәләр һәм мөхәррирләрнең[211] сүзләренә ышансалар, ни эшләсеннәр?! Һәммәсе дә ташласыннар да китсеннәрмени? Кая китсен? Ни эшләсен? Ни белән тамак туйдырсын? Икенче заводка китсенме? Әллә тагы бер-бер шәһәргә дворник булып керсенме? Әллә бер рус авылында хезмәтче, көтүче булсынмы?! Болай итсә, ни чыгар соң?! Шул үлүләр, шул авырулар, шул изелүләр бетәрме? Һәйһат! Һәйһат![212] Унтугызынчы гасырда күз яшьләре берлән елый-елый әйткән кешеләрне һәм дә халыкка шул хакыйкатьне белдерергә тырышкан мөхәррирләрне голәмаларымыз: «Тәкъдиргә ышанмыйлар, кяфер»,— дип, байларымыз алар артыннан барып, яр якасына килеп җиткән милләтемезне тегеләр сүзе берлән тотып алмаенча, яр астына төртеп төшерделәр. Ярның төбе юк икәнен белгәч, төшүчеләр төшмәскә димләгән кешеләрнең күзе дөрес икәнен белсәләр дә, кире кайтырга юл таба алмагач, һәм дә яр башыннан карап тора торган кешеләр арасында боларны кызганып күз яшьләре белән елаучы теге кешеләрне, һәм

208. Тәннәрен сату күздә тотылса кирәк. 209. Мәҗүсилек — төрле нәрсәләргә табыну. 210. Фөрьяд — ялвару. 211. Мөхәррир — язучы. 212. Һәйһат — үкенечне, өзгәләнүне белдерү сүзе (ымлык).

дә боларның мәталли-мәталли китүләреннән көлеп тора торган чалмалы әфәнделәрне күргәч, түбән таба киткән саен, ләгънәт укысалар да, үлгәч тәүбә кабул булмый дигәнчә, бер егылгач тору фикере дә уй көенчә генә калганга күрә, менә алмаенча түбән китүгә дәвам иткәннәр иде. Бу егылучыларның күбесе мәталлимәталли башлары әйләнеп беткәнгә, үзләренең кая икәнлекләрен күрергә күзләре томаланганга, кая барачакларын, анда ни булачагын уйларга зиһеннәре чуалганга, гүя, туйга барган төсле, көлә-көлә баралар иде. Бәгъзеләре барган саен юллары караңгыланачакларын, ниһаять, бөтенләй күзгә төртсәң күренмәслек бер караңгыга барып чыгачакларын белсәләр дә, алар да кире кайта алмыйлар, үзләре генә кайта алсалар да, башкаларны кайтара алмыйлар иде. Шулай киткәннәр иде. Баралар иде. Очына чыкканчы барачаклар иде.

Егерменче гасырның ахыры җитә башлады. Бу гасыр берлән безнең дә бик күп нәрсәмез бетте. Гәзитләремез бетте, мөхәррирләремез бетте, бетмәсә дә, егерменче гасырның башларындагы кебек кабилият дәрт берлән язганнары калмадылар.

Башка халыкларда һәр җирдә алга бару күренә иде, һәммә халык шуның өчен гаед[213] ясыйлар иде. Әмма без ни эшли идек? Ни өчен гаед ясый идек? Белмим, әллә башымыз тыныч калды инде, йоклаган як белән тик йоклыйк диптер. Ни булса да, безнең эшләремез һаман артка бара иде. Бу гасырның башында бездә бер дә яңа эш булмады. Халык һаман тарала бара иде. Сала халыклары заводлар, фабрикаларга күчә баралар, шәһәр халкы да вак-төяк толчок кәсебе белән кара эшкә генә кала баралар иде.

Менә тагы бер бәхетсезлек. Казанда бер мөселман хәрчәүнәсеннән бер авыру чыкты. Бу шундагы бер шәкерт белән ияреп мәдрәсәгә күчте һәм дә номердагы кешеләр аркылы авылларга һәм шунда заводларда эшли торган кешеләр артыннан завод-фабрика мөселманнарына да таралды.

Бу әллә нинди бер чир иде. Йогышлы иде, бик тиз үтерә иде.

Тагы гаҗәп шунсы, бу мөселманнар арасында чыккан иде һәм шулар арасында гына патшалык сөрә иде. Бер Казанда гына һәр көнне йөзәр мөселман үлә иде. Болай гына калмады, Оренбург, Әстерхан, Уфа мөселманнары арасына да күчте. Һәммә җирдә дә шул булды, һәммә җирдән хәбәр, төрле-төрле куркынычлы сүзләр китерделәр.

Хөкүмәт моны бетерергә бик иҗтиһад[214] кыла башлады. Әллә никадәр докторлар чыгарылды. Больницалар ачылды. Ләкин авыруга һаман чара юк иде. Чөнки авыруның ни икәнлеге һаман кәшеф[215] кылынганы юк иде. Аңарга каршы чарасы да табылганы юк иде, әллә ни кадәр җирдә әллә ни кадәр җәмгыяте тыйббияләр[216] булсалар да, әллә ни кадәр профессорлар шул мәсьәлә белән мәшгуль булсалар да, һич файда чыкканы юк иде. Мөселманнарның үлүе һаман кимеми иде.

Ниһаять, бер болгар докторы бу көнгәчә тыйбта мәгълүм булмаган бер йогышлы авыру икәнлеген исбат кылды. Һәм дә безнең мәгыйшәтемез аның микробларына бик файдалы булганга, мөселманнар арасында гына шул кадәр тәрәккый итүен белдерде. Һәм озак үтмәде, әллә нинди иске восточный дарулар кебек бер дару кәшеф кылды, авыруны азайта башлады. Һәммә җирдә моның дәвасы истигъмаль[217] кылына башланды. Ләкин бу бик озак үткәч булганга, болгарлардагы үлемнең исәбе-хисабы юк иде. Авыру яз көне башланып җәй буе патшалык сөргәнгә, болгар халкының яртысын үтереп бетергән иде. Моның калган яртысының утыз фаизы[218] ата-

213. Гаед — бәйрәм. 214. Иҗтиһад — тырышлык. 215. Кәшеф — ачу. 216. Җәмгыяте тыйббия — медицина җәмгыяте. 217. Истигъмаль — куллану. 218. Фаиз — процент.

сыз-анасыз, кардәш-кабиләсез калган ятим балалар яртысы эшкә ярамый торган карт-коры иде. Болгар халкы шул кадәр беткән иде, һич әйтеп бетерерлек түгел иде. Моннан өч ай элек гөрләп торган авыллар, заводларның баракларын тутырган болгарлар, шәһәрләрнең дворник, извозчик, швейцар вазыйфаларын ифа[219] кылган мөселманнар беткән иде. Базарлар, ярминкәләрдә вак-төяк, саяксандрак, иске-москы берлән сату иткән халыклар бердән, җир упкан кебек, булганнар да беткәннәр иде. Авылларда ябылган өйләр, атасыз-анасыз калган балалар, угылсыз гарип карчыклар, ирсез калган хатыннар, хатынсыз калган ирләрнең исәбе-хисабы юк иде. Болгар халкы арасында һичбер авыру кермәгән йорт юк иде. Һичбер кайгы кермәгән өй дә юк иде.

Казанда, Оренбургта, Уфада, Әстерханда, Семипалатта, Орск, Троицкиларда һәм башка болгар булган шәһәрләрдә, авылда урамнар буш алган. Мәсҗетләр мәхәлләсез калганнар, мәдрәсәләр мөдәрриссез, шәкертсез калган иде. Казан, Оренбург вә башка бәгъзе шәһәрләрдә халык булмаганга, бәгъзе мәсҗетләрдә намазлар укылмый башлаган иде.

Шуның өчен ул мәсҗетләрнең бара-тора бер харап булуында һич шөбһә юк иде. Бу авыру, бу бәла халыкның куәтен алганга, бик күбесенең тормыштан бөтенләй гайрәтен кайтарган иде. Бик күбесенең иң якын кешеләрен — хатыннарын, ирләрен, балаларын, ата-аналарын, дусларын алып киткәнгә, алар белән бергә фамилия сәгадәте, тормыш кызыклары да беткән дә киткән иде. Шуның өчен һәрбер болгар авыр табигатьле, һәр нәрсәгә биәһәмиятәнә[220] карый торган, дөньядан бөтенләй өмет өзгән иде. Һәрберсе, «үлмәгәнгә торабыз инде», дигән кебек кенә яши башлаганнар иде.

Шуның өстенә һәммә җирдә купкан мирас мәсьәләсе калган бер уч болгар халкын да кырыкка ярып бетергән иде. Туганнар туганнары берлән, аталар балалары берлән, хатыннар ирләре берлән мирас өчен тартышалар иде.

Боларның мираслары да никадәр кечкенә булса, низагы шулкадәр зур иде. Бер самавыр мәсьәләсенең тавышы күккә чыга, бер тун тавышы да мәхкәмәдән[221] мәхкәмәгә күчеп, әллә ни кадәр халыкның башын әйләндерә иде. Бер кәҗә дәгъвасы да ни кадәр кешеләрнең авызларын-борыннарын кан ясый иде. Тавышның, кычкырышның исәбе-хисабы юк иде. Мәхкәмәләргә бирелгән гаризаларның, хөкемнәрнең иге-чиге юк иде. Һәр кешенең мәхкәмәдә эше бар иде. Һәр кешенең берсендә аласы бар иде, һәр кешенең икенчесенә бирәсе бар иде. Хөкүмәт бу эшләрне карарга хосуси хаким,[222] хосуси мәхкәмәләр ачса да, эшнең чамасы да юк иде, рәте дә юк иде. Әхлак бозылганга, ялган шаһитның исәбе-хисабы юк иде. Ике як та дәгъваларын ялган шаһитлар белән, антлар белән исбат кылалар иде. Һәр кеше үзенең мөхалифенең[223] шаһитларының ялган гуаһлыкларын[224] икенче гуаһлар берлән исбат кыла иде. Тегесе бу гуаһларның акчага сатылуын, акча алган вакытта булган кешеләр берлән бәян кылалар иде. Һич очына чыгу мөмкин түгел иде. Хөкүмәт мәэмурлары,[225] хакимнәр никадәр рәтләргә теләсәләр дә, һич файда итә алмаганнар иде. Өч елдан соң да шул мирас низаглары дәгъва көенчә калган иде. Ахырда хөкүмәт Духовное собраниегә бу эшләрне карарга кушты. Ул бер дә вакыт үткәрмәенчә, бер циркуляр таратып, Духовное собраниенең мирас низагларын карарга мәэзүн[226] икәнлеген белгертте. Һәм бик тиз эшләрне карарга башлап,

219. Ифа кылу — үтәү. 220. Биәһәмиятәнә — әһәмиятсез. 221. Мәхкәмә — суд. 222. Хаким — судья. 223. Мөхалиф — каршы як. 224. Гуаһлык — таныклык. 225. Мәэмур — чиновник. 226. Мәэзүн — рөхсәт ителгән. 227. Нәфел руза — өстәмә ураза.

мирас дәгъвачыларының бәгъзесенә бер атна, бәгъзесенә ике-өч атна, алты атнага кадәр нәфел руза[227] берлән җәза бирде. Үлемнән калган муллаларга, ахуннарга собраниенең әмерен тотарга бик каты боерды. Низаглар тагы күбәйде, «ураза тотты, ураза тотмады, мулла аны тоттырмады, фәләнне тоттырды» низаглары кушылды. Собрание һич курыкмаенча, муллалар, ахуннарны руза белән җәза кыла башлады. Бу эштән соң мирас мәсьәләләре тагы әһәмият берлән тикшерелә башласа да, ул вакыт собраниенең идарәсендә булган сиксән мең атна руза таралып беткәнгә, нишләргә белмәенчә, ул да аптырап калган иде. Бу мәсьәләләр шулай йөреп бер төрле дә хәл кылынмаган иде. Бусы шулай булса да, халыкта тагы зур мәсьәлә бар иде. Шулкадәр атасыз-анасыз, тәрбиячесез калган балаларны ашатырга, киендерергә кирәк иде. Бу мәсьәлә бик авыр булып, һәр кешенең авызына кергән иде. Ләкин ничек ярдәм кылырга, ничек аларны тәрбия кылырга мәсьәләләре һич хәл кылынганы юк һәм хәл кылыначак та түгел иде. Чөнки боларны тәрбия кылырга әллә никадәр байлык, әллә никадәр гайрәт, әллә никадәр урын кирәк иде. Бездә берсе дә юк иде. Хөкүмәт тарафыннан вә хосуси тәэсис кылынган җәмгыятьләр карасалар да, болгарлар аларга бирәсе килми иде. Шуның өчен яза белгәне язу белән, сөйли белгәне сүз белән, эшли белгәне эш белән шул мәсьәләгә хезмәт итә башладылар. Яңадан хәмият[228] уянды. Яңадан гәзитәләр, журналлар, әдәбият нәшер кылына башлады. Фәкыйрьләр файдасына театрлар, музыка ахшамнары бирелә башлады. Җәмгыятьләр тәэсис кылынды. Һәммә җирдә шул мәсьәлә, һәммә җирдә ярдәм тавышлары иде. Озак үтмәде, Оренбург, Казан кебек шәһәрләрдә гаҗизханә, ятимханәләр ачылды, һәммә җирдән кирәргә теләүчеләр, гаризалар-үтенечләр берлән мөнәҗат[229] кыла башланды. Озак үтмәде, зур җәмгыятьләр ясап ачтылар. Речьләр сөйләделәр, ашадылар-эчтеләр, берсен-берсе макташтылар, ахырдан бу елга дүрт бала алырга хөкем иттеләр!!! Шул мәҗлестә үк рәис җәмгыятьнең дворнигының улы белән секретарьның ерак кына бер кардәш баласына башка икесен сайлап алдылар. Меңнәр, йөз меңнәр мохтаҗларга урын кирәкләге беленде. Кычкырышылды, бакырышылды, сүгешелде, макташылды, ахырдан дүрт бала алынды! Ярабби, бу ни эш? Ник без болай? Моңарга сәбәп нәрсә? Белмим, белмим!! Шуның өчен ирекле-ирексез меңнәрчә балалар русларга кушылып китәргә вә меңнәрчә ир балалар саилче, жулик булырга, меңнәрчә болгар кызлары кара чәчләре, майлы күзләре, кибари[230] кыяфәтләре берлән тамакларын туйдырыр өчен гыйрызларын,[231] намусларын, гыйффәтләрен[232] сатарга мәҗбүр булдылар. Һәммә җирдә шундый кешеләр булды. Гәзитәләрдә мөляхәзәләр язылa башланды, шуларны коткарырга әллә ни кадәр җәмгыятьләр ачылды. Ләкин ни чыкты? Ике-өч, ниһаяте, унга кадәр кешеләрне тәрбиядән яисә коткарудан узмый иде. Бу сан, бу ярдәм мохтаҗлар санына караганда диңгездәге тамчы кебек булганга, һич тәэсире юк иде. Ахырдан моңардан да ардылар. Гәзитәләр башка мәсьәләгә борылдылар. Тегеләй халык авызында да ул сүз бетә башлады. Халык ул эшкә шул кадәр ияләште — ул гаепкә дә саналмый башлады. Андый кызлар, андый егетләр һәрвакыт андый түгелләре белән катышканга, боларның ачкан җәмгыятьләре булмаса да, бик күп кешене үз мәсләкләренә[233] кертәләр иде. Шуның өчен фәхеш гадәт хөкемен алган, йогышлы чирләр дә калган ярты халкымызны каплаган иде.

Егерме беренче гасырның егерме бишенче елларыннан халкымызда тагын артык бер хәмият, артык гайрәт мәйданга чыккан иде.

---

228. Хәмият — зарар китерүдән саклау. 229. Мөнәҗат — аллага ялвару. 230. Кибари — горур. 231. Гыйрыз — абруй. 232. Гыйффәт — кызлык. 233. Мәсләкләренә — карашларына.

Әллә никадәр мәктәпләр, мәдрәсәләр ясалган. Халык арасында халык аңларлык дәрәҗәдә китаплар, гәзитәләр нәшер кылына башлаган иде, хәтта моның белән генә калмаенча, унтугызынчы гасыр, егерменче гасырның олугларына һәйкәл кую да мөляхәзә кылына башлаган иде. Бу тавыш тагы бик зур итеп иганәләр җыюга кадәр җиткән иде...

Ләкин калган халык та көннән-көн кими барганга, көннән-көн ярлылана барганга, боларның бу гайрәтләре, бу хәмиятләре дә вакытлы килгән бер бизгәк авыруы гына булганга, аның бетүенә дә вакыт җитә башлаганга, гәзитәләр бу мәсьәләне сирәкләтә башлаганнар, халыклар да ул кадәр сөйләми башлаганнар иде. Бара-тора акыртын гына бетә-бетә бөтенләй беткән иде. Баягы гайрәтдәр, баягы хәмиятләр илле елга кадәр «милләт, милләт» дип әйткәләп торсалар да, шул елларда дөм сүнгәннәр иде. Яңадан мәдрәсәләр ябылган иде, яңадан мәктәпләр беткән иде, яңадан гәзитәләр, журналлар туктаган иде. Һәммә җирдә бер сөкүнәт,[234] һәммә җирдә бер моңлык сөрә башлаган иде. Хәтта шул елларда чыккан болгар көйләре соң дәрәҗәдә моң, кайгылы, әллә нинди өметне бетерә торган иде. Иртәгә үләсен сизенгән хәстә кебек, як-ягына моң-моң карый башлаган иде. Әдипләр, мөхәррирләр күбесе үлеп, үлмәгәннәре рухан бетеп, милләтемез җансыз дәрәҗәсенә җиткән иде. Фәкать шул елларны гына чыккан Җәгъфәр исемле мөәррих[235] һич арымый иде. Тарихи хикәяләр, тарих китаплары язып мәйданга китерә иде. Ләкин бу да боларның әүвәлге рәхәт гомерләрен исенә төшереп бу көнге зәгыйфь, авыру, кызганыч, аяныч хәлләрен чагыштырып кайгырышудан башкага, үзенең хәленең өметсезлеген белдерүдән башкага бармый иде. Җәгъфәр никадәр әдәбиятка хезмәт итсә дә, никадәр үлеп бара торган хәмиятне уятырга тырышса да, иске әдипләрнең рәсемнәрен таратып, тәрҗемәи хәлләрен язып, халыкта милләт фикерен бетермәскә тырышса да, мәктәпләр, мәдрәсәләр беткәнгә, балаларның тууы соң дәрәҗәдә булганга һәм тәрбияләренә һич әһәмият бирерлек гайрәт калмаганга, халыкның кимүенең һич исәбе юк иде. Әмраз сария[236] шул дәрәҗә таралган иде, нинди пакь кешегә дә аңардан котылу бик авыр иде.

Чөнки варисы булуы да күп булдыгы кебек, дусларыннан иптәшләренә, иптәшләреннән иптәшләренә иярүеннән һич сакланырга имкяны[238] юк иде. Хөкүмәт боларны бетермәк өчен җәмгыятьләр ачып, больницалар ачса да, һаман файда юк иде. Чөнки туган бер бала авыру туа иде. Авыру тумаса, атасыннан иярә иде, агасыннан, тутасыннан иярә иде. Шуның өчен хөкүмәтнең, хосуси кешеләренең гаҗизханәләре бу авырудан әгъзалары чери торган картлар, карчыклар, яшьләр, балалар берлән тулган иде. Авыл халкы бик аз калганга, аларда шул авыру бик таралганга, алар да акыртын гына шәм кебек тик торганда эреп бетәләр иде. Фәхешханә болгар кызларыннан, хәбесханәләр[239] болгар егетләреннән бушана бара иде.

Ниһаять, егерме беренче гасырның ахырына җитә башлады. Җәгъфәр һаман язса да, һаман әлгәреге әхлакымызны, гадәтләремезне югалтмаска тырышса да, халыкның гадәте генә түгел, үзләре дә бетә иде. Егерме беренче гасырның 98 нче елында булган гомуми тәхрир нөфүстә[240] Җәгъфәр Россиядә 3800 болгар барлыгын белде...

Руслар шул эшләрне эшләгән вакытта безнең Җәгъфәр абзый да һәрвакыт үз эшендә иде. Ул болгар халкының мөнкарыйз[241] булуына тәмам ышанганга, аларның калдырган әсәрләрен җыярга тотын-

---

234. Сөкүнәт — тынып калу. 235. Мөәррих — тарихчы. 236—237 Әмраз сария — ячерен чирләр. 238. Имкян — мөмкинлек. 239. Хәбесханә — төрмә. 240. Тәхрир нөфүс — халык саный алу. 241. Мөнкарыйз — сүнгән, беткән.

ган иде. Шуның өчен ул Идел буйлап, Казаннан алып Әстерханга кадәр киткән иде. Әстерханның хәрабә мәсҗетләрен тарих җәмгыятьләре үз идарәләренә алып, өсләренә кайвакыт салынганлыгын, кемнәр бина кылганлыгын, ничә гасырлар гыйбадәтханә булганлыгын, кайсы елда халкы бетеп ташландыгын — һәммәсен язганнар иде.

Мәдрәсәләр төрлесе төрле нәрсәгә әверелгән иде. Бәгъзеләре ятимханә, бәгъзеләре гаҗизханә, бәгъзеләре ночлежный домнар булганнар иде. Әстерханның мәшһүр зиарәтләре, зиарәт өстендәге чардуганнары, ихатасы, һәммәсе тарих җәмгыяте тарафыннан карала иде. Боларга махсус каравылчылар куйганнар, зур зиарәтләргә кем зиарәте икәнлеген, кайвакыт тууын, кайвакыт үлүен, нинди хезмәттә булуын, нинди яхшылыклар кылуын язып куйганнар иде. Җәгъфәр әфәнде һәммәсен карады, һәммәсен күрде, һәммәсе берлән кальбән[242] сөйләште, һәммәсенең күз яшьләренең агуын үз күзеннән яшьләр агыза-агыза тыңлады. Мәсҗетләр: «Ник болай иттегез! Болай калырга булсак, безне салмау кирәк иде, әйе, сез безне кирәклегемез өчен салмаган идеңез, кайсыңыз — үзеңезнең мулла булмаса, тамак туйдыра алмаслык улымызга урын өчен иде, кайсыңыз — сукыр, чулак, гарип, эшкә ярамаган, кияү чыкмаган кызымызны остазбикә итәр өчен иде. Безгә кереп гыйбадәт кылган булып йөрдеңез. Кальбән гыйбадәт кирәк дип, яисә гыйбадәтне файдалы дип түгел иде, фәкать шундагы Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан агайларга күренеп, берсенең кызын алырга, икенчесенең акчасын алыр өчен иде. Безне шундый начарлык кыла торган урын ясасагыз да, чыдадык, ник болай иттегез! Әллә голәмаларыңыз никадәр халык җыеп, вәгазь дип, башларын чуалтып, малларын алырга корган тозакларына урын булмадыкмы? Һәммәсенә бер сүз әйтмәдек. Ниһаять, ни белән кайтардыңыз! Ташладыңыз да киттегез!» — дигән кебек була иде. Җәгъфәр әфәнде бу сүзләрне үзенә хитап[243] кебек уйлап, шул биналарга җавап бирер өчен, болгар тарафыннан куелган дәгъва вәкиле кебек сүз эзләсә дә, бер нәрсә таба алмаенча, тегеләрнең сүзләренә тәсдыйкан[244] баш иеп кала иде. Мәдрәсәләр, мәдрәсәләрнең ташлары Җәгъфәр әфәндегә үзләренең хәлләреннән зарланган кебек күренәләр иде. Алар, гүя, аңарга: «Безне мәдрәсә дип исем бирдеңез! Безгә, мәдрәсә дип, гөнаһсыз, гыйлемгә дәртле балалар тутырдыңыз! Безнең илә каплап шул балаларга сез нинди золымнар кылмадыңыз! Укырга килгән баланы, дөньяга торыр өчен туган баланы, укыткан булып, дөньясыннан, ахирәтеннән биздердеңез! Аларны эшкә ярамаслык иттереп, тамак туйдырыр өчен сәфил,[245] кабәхәт, надан кешеләреңезгә кол иттерү дәрәҗәсенә төшердеңез! Укыйм, белим, дөньяда торыйм, башкалар торганны карыйм, бергә торабыз дип ыжгырып тора торган балаларны дөньяга, ахирәткә дошман итүеңез белән генә калмадыңыз, алардан башка кешеләрне дә шулай зәһәрләргә агу иттеңез! Диварларымыз буенда көнеңез-төнеңезне кирәкле нәрсәләр уку, өйрәнү урынына, тәсәлсел,[246] дәвер иҗтимагыль нәкъзайн[247] тавышлары белән үткәрдеңез! Кая тәсәлсел? Кая дәвер? Һәммәсе бетте, һәммәсе бетте. Сезне дә бетерделәр! Безне дә бетерделәр! Безне мәдрәсә дип ачып, балалар җыеп, бездән әхлаксызлар мәркәзе ясадыңыз! Халык күзенә кызыл яулыкларга төргән зур катыргылы китабыңыз берлән күзләрен сихерләп, «дәрес әйтәмез» дип, милләтемезнең булачак кешеләрен харап иттеңез! Шундый зур начарлык иттеңез! Безнең нинди дошманыбыз да безгә ул кадәр зарар итә алмас иде.

*Ахыры киләсе санда.*

---

242. Кальбән — күңелдән. 243. Хитап — эндәшү. 244. Тәсдыйкан — раслап. 245. Сәфил — түбән, хур кеше. 246. Тәсәлсел — дәвер (әверелү). 247. Иҗтимагыль нәкъзайн — ике каршылыкның бергә җыелуы (формаль логика атамаларыннан).

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәрит Бәширов

# ТУРГАЙСЫЗ ЯШӘП БУЛАМЫ?!

Исегездәме? Балачактан ук күңелгә сеңеп калган, һич тә онытылмаслык якты бер моң булып йөрәк түрендә яшәп килүче җырны хәтерлисезме?

*Яфраклары яшел ак каенның,*
*Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.*
*Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,*
*Шаулап тора һәркөн тау ягы.*

Нәрсәсе белән шулай якын, кадерле, нәрсәсе белән үзенә тарта соң әле безне «Ак каен» җыры? Бер җөмлә белән әйткәндә, «Ак каен» — безне туган як, туган җир кебек изге төшенчәләр белән тоташтырып торучы күпер дә, хәтерсезгә әйләнә башласак, зыңлап аваз бирә, сискәндерә торган кыл да ул.

Төп нигез — әти йорты, авылның үзенә генә хас табигате: урман-сулары, чишмәләре, уйсулыклары, аланнары, ермаклары, тау-калкулыклары һәм тагын әллә нинди, әллә никадәр, шул төбәктә туып үскән кеше генә аңларлык сизелер-сизелмәс билгеләре белән кадерле бит ул безгә туган җир.

«...дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар инде күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында, торналар төшкән җирдә берүзем басып торам. Бу — минем туган җирем...»

Язучы М. Мәһдиевнең туган ягы бу. Шул ук вакытта ул — барыбызныкы да. Талантлы иҗат белән тудырылган туган як образы меңләгән, күп меңләгән, укучының әйтергә, сөйләргә теләгән уй-хисләрен чагылдырган якты сурәт ул. Авыл һәм табигать! Табигать һәм туган як! Болар аерылгысыз төшенчәләр. Берсеннән башка икенчесе яши алмый. «Әй, авыл, син мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш»,— дип язып чыккан С. Рәмиевләр чорыннан алып, бүгенгә кадәр ничә буын әдипләр олы бер сөенеч катыш горурлык хисе белән туган якка, аның табигатенә булган мәхәббәтләрен укучыга җиткерә килделәр.

Ләкин әлеге мәңгелек темага без инде бүген хәвеф катыш борчылу белән дә мөрәҗәгать итәбез. Чынлап та, соңгы унбиш-егерме елда барган зур техник процесслар, нефть чыгару, химия промышленностеның гаҗәеп тизлек белән үсеше һәм шуларга мөнәсәбәттә яңа зур калалар барлыкка килү Татарстанның йөзен нык үзгәртте. Республикабыз ил күләмендә генә түгел, дөнья масштабында әһәмиятле төбәкләрнең берсенә әверелде. Сибгат Хәким язганча:

*Кирәк булса, дөнья картасыннан*
*Кырык илне эзләп табармын.*
*Мин яшәгән Татарстан анә,*
*Күр, кайларга илтә товарын...*
*Керосины да юк, көндездән ул*
*Телеп куя нидә чырасын.*
*Кем юрады икән нефть төяп*
*Океаннарга аның чыгасын?.*

Әдәбиятка яңа тема килде, яңа төр һөнәр кешеләре әсәр каһарманына әверелде. Нефтьчеләр, төзүчеләрнең фидакарь батырлыгына, «Бишьеллык планны дүрт елда» башкарып чыккан, исемнәре «илебез тарихына тутыкмас алтын хәрефләр» белән язылган хезмәт иясләренең дәрт-кечәнә дан җырлаган повесть-романнар, шигырь-поэмалар, драмалар, мәкалә-очерклар ташкыныннан, алардагы пафостан укучы бермәлгә каушап калды. Бераз вакыт сөенечтән һәм ис китүдән зиһенен җыя алмый торгач, безнең замандаш фән-техника казанышларының илебез үсешендәге роленә тамам иманы камил

булып һәм үзен дә шул зур хәрәкәтнең бер вәкиле итеп күрү теләге белән, нефть чыккан төбәкләргә, машина төзелеше, химия промышленносте чәчәк аткан үзәкләргә юл алды. Бу — фәнни телдә «урбанизация» дип аталучы шәһәрләшү процессы иде. Әлеге күренешнең уңай яклары турында күп язылды, күп сөйләнде. Әйтергә кирәк, әдәбият һәм вакытлы матбугат мәсьәләнең нәкъ менә шул ягына гына басым ясады. Үлчәүнең ике тәлинкәдән торуы игътибарга алынмады... Нәтиҗәдә, яшәешнең иң мөһим бер өлеше — гармония бозылды. Бу бозылу беренче чиратта үзен «табигать һәм кеше» бәйләнешендә нык сиздерде. Адәм баласы тарафыннан хәрәкәткә китерелгән әлеге куәтле тәгәрмәч-механизм, өзлексез рәвештә әйләнешен арттыра барып, кешелекне бүген без чаң каккан экологик проблемага китереп чыгарды. Хәзергесе көндә бу процесс үзенең киеренке ноктасына җитте... һәм без, чүлмәкченең үзе тарафыннан ук чыгарылган гыйфритнең кыланмышларына бер чарасызлык, гаҗизлек белән карап торучы фәкыйрь карт кебек, кабат-кабат үзебезгә үзебез сорау бирәбез: «Бу проблеманы булдырмый калу мөмкин идеме соң? Бу хәлгә килеп җитмәү өчен без барысын да эшләдекме?» Мөмкин иде... Кызганычка каршы, эшләмәдек. Авыруны башлангыч чорында дәвалау җиңелрәк, дигән гаҗәеп гади бер хакыйкатьне оныттык. Хәзер инде үтә киеренке халәткә җиттек, шанслар да кимеде. Үлчәү тәлинкәләре «яки-яки» дип тирбәлә башлады. «Яки үлем, яки яшәү» дип...

Иң әүвәл шагыйрьләр сискәнде бугай. Г. Афзал әйткәнчә:

> *Шагыйрь җаны барометр кебек.*
> *Җил иссә дә,*
> *Яфрак төшсә дә,*
> *Һаваларның үзгәрүен сизеп,*
> *Сискәнә.*

Шырпы каплары кебек тыгыз-үндүрт катлы игезәк йортларның «интенсив үсеше» вакытында, «торак йортлар белән тәэмин итүдә глобаль процесслар» баруы турында газеталар һәм радио-телевидение шаулап хәбәр иткәндә Зөлфәтнең кисәтүле авазы яңгырады:

> *Таш пулатлар җитми кешеләргә,*
> *Тыгыз туфрак җитми,*
> *Җитми азык —*
> *Мин китәргә, мин кибәргә тиеш,*
> *Юл бирергә тиеш,—*
> *Бу мин — Сазлык.*
> *— Бәхил булыгыз!*

Юк, Зөлфәт «Казан шәһәренең 39 нчы кварталы янындагы сазлыкның төнге бәхилләшүе» дигән әлеге шигырендә һич тә йортлар төзүгә каршы килми (бу бик кирәкле эшне кем инде инкарь итсен!). Шул ук вакытта табигатьнең кул тимәгән кыргый матурлыгын сагынып лаф ору да түгел бу. Шагыйрь биредә табигать белән кеше арасындагы гармоник мөнәсәбәтнең бозылырга тиеш түгеллеген искәртә. Гармония сакланырга тиеш, юкса тигезлек бозылу төзәтеп булмаслык зур хатага, һәлакәткә алып киләчәк. Шагыйрь шуны кисәтә:

> *...Тыңлады төн. Биектәге йолдыз*
> *Тетрәп-тетрәп серле төнгә дәшә:*
> *— Әйтче, Төнем, әйтче: Нәрсә булды?*
> *Нәрсә булды?*
> *Ник җир бәхилләшә?..*

...Үлчәү тәлинкәләре чайкалалар. Аска... өскә...

Шулай да табигатькә иң зур тәэсирне ясаучы «гигант адымнар» белән үскән таш пулатлар түгел, ә шул ук табигать тарафыннан дәверләр буе тудырылып, сакланып, тупланып килгән «җир асты байлыгы» — нефть булды. Нефть, «кәҗүнни» сүзләр белән әйткәндә, Татарстанның ландшафтын үзгәртүдәге хәлиткеч чараларның берсе һәм беренчесе иде. Үзгәрде... Табигать үзгәрде... Авыллар үзгәрде. Кешеләр үзгәрде... Дөньякүләм әһәмияткә ия булган нефть турында гөр килгәндә нинди дер «Ак каен» турында фәлсәфә сату көлке һәм буш мәшәкать белән булышу (авыз еруны читкә куйсак, «корткычлык») түгелме? Һәм кирәк идеме соң ул? Кирәк иде...

...Үлчәү тәлинкәләре кисәк тартылып куйды. Берсе аска... Берсе өскә...

Хәер, табигатькә булган «сугышчан» мөнәсәбәт Татарстан җирендә нефть табыл-

ганчы ук башланган иде инде. Хәтерлисезме, «Туган тел» өйрәнеп йөргән чактан ук таныш булган, класс стеналарындагы пыяла эченнән төз хәрефләре белән һәрдаим күзгә керәп, ихтыярыбыздан тыш хәтергә сеңеп калган сүзләрне: «Без табигатьтән мәрхәмәт көтеп торырга тиеш түгелбез, аннан алу — безнең бурычыбыз!» һәм ничек кенә алдык әле! Ләкин бер нәрсәне оныттык. Кеше нинди генә фән-техника казанышларына ия булмасын, нинди генә катлаулы машиналар уйлап чыгарып үзенә хезмәт иттермәсен — беренче чиратта ул барыбер табигать баласы. Аның карынында яралып, ул өргән сулыштан яшәп киткән, җан, кан алган йөрәк парәсе. Акыл көче белән тудырылган роботлар теләсә нинди шартларда да яши алсалар, кеше өчен, гомумән, терелек өчен Җир, Су, Һава, Кояш кирәк. Без менә шул үтә гади хакыйкатьне истән чыгардык. Табигать-анабызның баласына булган ышанычыннан вәхшиләрчә файдаландык. Ә бу адымыбызның бумеранг кебек кире кайтып, үзебезгә икеләтә сугачагын уйламадык. Ана каргышы каты була. Оныттык...

Кызганычка каршы, әдәбият бу өлкәдә коточкыч сукырлык, битарафлык, үшәнлек күрсәтте. Әгәр дә яшәешебезнең рухи өлкәсен тәшкил иткән язучы сүзе халыкны вакытында искәртә алган булса, ышанып әйтәм, бүген «яшәү-яшәмәү» мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән безнең алга килеп басмас иде. Ә бит хәзер экология проблемасы атом сугышының янавы белән бер дәрәҗәдә!

Хәзер нефтьчеләр турында язылган проза әсәрләренә килик әле. Барысына да тукталмыйча, үз чорында җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән һәм әдәбиятыбызның зур казанышы итеп танылган романнарга мөрәҗәгать итү картинаны күз алдына ачык китерергә булышыр дип уйлыйм. Бу җәһәттән мин Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар», Ш. Бикчуринның «Каты токым» романнарын күздә тотам. «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» дилогиясендә без Татарстан нефтьчеләренең эштәге, тормыштагы сокланырлык батырлыклары, крестьян психологиясенә заман рухының йогынтысы белән танышабыз. Гади нефтьчедән идарә начальнигы булу дәрәҗәсенә үскән Арслан Гобәйдуллин, карт нефтьче Социалистик Хезмәт Герое Лотфулла Диаров, эшчән, кыю, мәхәббәтендә дә икеләнүсез Фәйрүзә һәм башка күп төрле образ-характерлар белән очрашабыз. Хәер, биредә безнең максатыбыз тәнкыйтьтә инде үз урынын алган бу әсәрләргә төпле анализ ясау түгел, шуңа күрә язучы иҗатына әтрафлы мәкалә (сүз башы) белән чыккан Х. Хәйри фикерен генә тыңлап үтик: «Язучы кешеләр турында кайгыртучанлык күрсәтү фикерен, хезмәт процессында, коллективта кешеләрнең үсүләрен, нефтьчеләрнең авылга уңай йогынты ясауларын, авылның йөзе үзгәрүен киң планда һәм сәнгатьчә көчле эшләнгән картиналар, образлар аркылы ышандырырлык итеп дөрес ачып бирә. ...Язучы геройларның шәхси тормышлары белән производство эшләрен табигый тыгыз бәйләнештә чагылдырып, кешеләрнең язмышларын, перспективаларын халык байлыгы һәм бәхете өчен көрәш идеясе яктылыгында хәл итә».

«Каты токым» романы да чоры өчен зур вакыйга итеп кабул ителде. «Әсәрдә без кешеләрнең,— дип яза С. Шакир,— шәхси интереслардан арынып, җәмгыять, халык интересларын беренче планга куя баруларын күрәбез. ...Аларның омтылышлары, максатлары бер — илгә күбрәк нефть бирү, яңа нефть ятмаларын табу» («Татарстан яшьләре». 1976 ел, 3 апрель).

Менә М. Садри фикере: «Каты токым» романы нефтьче разведчикларга, аларның фидакарь батырлыкларына, авыр, каты токымны җиңеп, үзләре дә үсә, чыныга барган алтын кешеләргә — совет кешеләренә дан җырлаган әсәр булып, проза белән язылган поэма, яңа җыр булып яңгырый». («Социалистик Татарстан». 1976 ел, 16 апрель).

Әйе, барысы да бар бу романнарда. Тик бер генә сорау җавапсыз калды: ни бәрабәренә яуланды ул уңышлар? Нәрсә хисабына?!

Кызганычка каршы, әдәбият та һәм гаделлек үлчәвен кулында нык тотарга, һәрвакыт уяу булырга тиешле тәнкыйть тә иңгә-иң терәлеп бер үк сүзне кабатладылар: «Күбрәк, тизрәк, планнан тыш, фәләненче датага!..»

Шампан бөкеләре атылган тавыш табигатьнең сыкранган авазын ишетергә мөмкинлек бирмәде. Хуҗалар, хәзинәнең үз янындагы, мөлдерәп күзгә карап торган өлешен күрә алмадылар. Бу аларның батырлык үрнәге күрсәтүдәге миссияләренә керми иде. «Күбрәк!», «Шәбрәк!» лозунглары астында тупаслана барган күңелләргә язучы сүзе барып җитмәде. Бу «каты токым»ны әйләнеп үтү хәерлерәк саналды.

Ләкин укучыны алдап булмый! Газета укучыларның хатларыннан төзелгән өзек-өзек мәкаләләрдә дә элек-электән туган җир, табигать өчен никадәрле сызлану, борчылу, әйтеп бетерә алмаган хәвефләнү ята!

Актарып ташланган сөрүлек җирләре, пычранган елгалар, кипкән инешләр, юкка чыккан чишмәләр, корыган әрәмәлекләр — болар берсе дә нефтьчеләр батырлыгына дан җырлаган язучылар күзенә чалынмады микәнни? Монда нефтьнең гаебе юк, шулай ук биредә нефть тик зарар гына алып килде дигән фикер дә үткәрелми. Болай әйтү зур ахмаклык, яки инде рәсми тел белән әйткәндә «политик сукырлык» булыр иде.

Нефтьнең илебез, гомумән, дөнья тарихында үсешендә тоткан тиңсез ролен кем инкарь итсен? Биредә бары тик акыл белән, табигатьнең яшәү законнарына хилафлык китермәскә тырышып, тирә-юньнең экологик чисталыгы өчен зур җаваплылык хисе тоеп, гармонияне кискен тайпылышлардан саклап эш итү турында сүз бара.

«Нефтьче иң мактаулы профессия! Аңа дан һәм хөрмәт! — дип кычкыра, гелгел мәдхия генә укый торгач, без Т. Миңнуллинның «Монда тудык, монда үстек» драмасындагы Илфат ише куркыныч типларны да тәрбияләдек бугай. Җир-суның пычрануы хакында борчылучыларга аның җавабы әзер: «Җир, имеш! Мең-мең ярым гектар әрәм була икән, нигә каравыл кычкырырга!» Мондыйларның асылын драма героинясы менә ничек ачып бирә: «Сез — җир талаучылар, ил байлыгын талаучылар. Җир астына бөтен проектлардан узып су кудырасыз. Нефть катламын су баса. Бер тонна нефть алып, өч тоннаны җир астында калдырасыз... Илгә нефть кирәк, имеш. Сезгә нефть түгел, дан кирәк».

«Нефть һәм кеше» мөнәсәбәтенә генә басым ясау һәм «табигать — нефть — кеше» бәйләнешен игътибардан читтә калдыру — нефтьчеләр турында язылган романнарны, йомшак кына әйткәндә, бик тә берьяклылыкка алып килде.

«Хуҗалар», «Хәзинә» романнарының авторын әле аңлыйк та, ди. Болар 1963—1968 елларда язылган әсәрләр. Ул чакта «атмосфера» да, яшәү һәм иҗат итү алымнары да бүгенгедән үзгәрәк булды дип таныйк, ди. Ә менә «Тирән катлам» романында Ш. Бикчуринга куркыныч ноктага якынлашып килүче табигать һәлакәтен күрми калырга нәрсә комачаулык итте? Гомумән, нефть шау-шуы басыла төшкәч, язучыларыбыз исләренә килеп, бу мәсьәләгә һичшиксез әйләнеп кайтырлар дип көтелгән иде. Ләкин безнең нефтьче героебыз, Татарстанда алыш-бирешен бетергәч, Себер ягына чыкты да китте. «Тирән катлам» (1987) һәм Җ. Рәхимовның табадан яңа төшкән «Кыядагы чәчәкләр» («Казан утлары», 1988 ел, 6—7 саннар) романнарында ул инде тайгада җир маен суыртып йөри.

Үзебезнең Татарстаныбызга кайтыйк. Ни әйтсәк тә, шушында туып-үскән һәм «язмыш шушы туфрактан аермасын иде» дип гомер сөрүчеләр бит әле без. Йә, ни хәлләрдә син, Табигать-Анабыз?

*Төтен исле җилләр исте,*
*Нефть тулып ага елга.*
*. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .*
*Елгаларга төшсәң — бер балык юк,*
*Алар, бәлки, нефть эчкәннәрдер.*

Бу юллар — Гамил Афзалның «Офыкларга карап» (1987) исемле шигырьләр җыентыгыннан. Татарстан нефтенең үзәге Әлмәттә торып иҗат итүче өлкән шагыйребез, прозаиклардан аермалы буларак, табигать фаҗигасен бөтен тетрәндергеч халәтендә күрә һәм ачыну катыш нәфрәт хисе белән үзенең иҗатында чагылдыра алды.

Сарман якларында туып үскән шагыйрь Н. Акмаловка сүз бирик:

*...«Разведчиклар нефть эзли монда!..»*
*Аттан шабрак чапты бу хәбәр.*
*Безнең өчен диңгез була иде,*
*Инештәге суны бусалар.*

*Без бу якка килгәч, нича тапкыр*
*Ат көтүе китте таралып.*

*Ә аннан соң... күлдә балык бетте,*
*Казлар кайтты судан каралып.*

*...Туган якка кайтсам — онытылам,*
*Кайтам кебек малай чакларга.*
*Безнең якта хәзер атлар түгел,*
*Бәбкә дә юк инде сакларга...*

Гарәй Рәхим:

*Ташусыз, дулаусыз гына*
*Килә тактичный язлар.*
*Ак булып туып, нефтьтән*
*Карала монда казлар.*

Һәм, шушы фаҗигале күренешләрне бер фокуска туплаган кебек, З. Мансуровның кисәтүле, ачулы сүзләре яңгырады:

*...Чу!*
*Җан өзгеч тавыш ишетелде*
*Үлеп барган кара таллыкта...*

*Һәлакәтле чакта,*
*SOS биргәндәй,*
*Бер кычкырып куя балык та!*

Житәрдер? Эшнең күптән инде уеннан узганы аңлашылса кирәктер, шәт?! Әгәр шагыйрьләрне эмоциядә, аерым моментларны күпертүдә гаепләсәк, белгечләр фикеренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

«Безнең нәтиҗәләр шуны күрсәтәләр: нефтьнең табигатькә ясаган зыяны елга 25—30 миллиард сум тәшкил итә.

Бүген инде илнең тоташ бер өлкәләрендә экологик фәкыйрьлек зонасы (зона бедственного экологического положения) барлыкка килде. Аерым алганда, болар — Сырдәрья һәм Амудәрья елгаларының түбәнге агымы, Курск магнит аномалиясе, Идел бассейны, Калмык АССР, Уралның промышленность районнары. Бу төбәкләрдә яшәү шартлары начарлана, авырулар көчәя — менә боларны инде бернинди материаль байлык белән дә алмаштырып, аклап булмый». (Экономика фәннәре докторы М. Я. Лемешев һәм юридик фәннәр докторы И. А. Иконицкий әңгәмәсеннән. «Литературная газета». 1988 ел, 41 сан).

...Сүз башыбыз «яфраклары яшел ак каен» гына иде. Туган якны сагыну җырын бүген хәвеф һәм борчылу белән искә алырбыз дип уйламаган да идек...

Ачы булса да бер хакыйкатьне танырга кирәк: дәүләтебез авыл, аның кешеләре алдында түләп бетергесез бурычлы. Авыл — ул табигать һәм кешенең аерылгысыз биргәлеген гәүдәләндерүче бердәнбер һәм абсолют күрсәткеч булып тора. Башка альтернатив төшенчәләрне мин атый алмыйм. Безнең бүгенге шәһәрләребез нәкъ менә авылдан сыгып, суырып алган көчләр хисабына көчәйделәр. Тарихка борылып карасаң, исең китәрлек: авыллар баш әйләнгеч нинди генә тәҗрибәләргә дучар ителмәде! Бу глобаль экспериментлар җир кешесенең гасырлар буе тупланып, чарланып килгән карашларын, гореф-гадәтләрен, традицияләрен искә алмыйча, «тизрәк», «әйдә-әйдә» принцибыннан гына чыгып җәмгыятьнең үсеш законнарына көчләп тагылды. Алдын-артын уйламыйча кизәнергә ярату методының ачы җимешләрен крестьян гомер буе татып килергә мәҗбүр булды. Кизәндек, «иске тормышны нигезеннән җимерәбез!» дигән рухлану белән суктык, ордык, мәш килдек. Җиңел генә «яңа тормыш» төзербез кебек иде. Җиребезне «гөл-чәчәкле бакча итәрбез», сыйлы-нигъмәтле оҗмахка әвереңдерербез сыман иде...

Кизәнергә генә маһир осталар булып чыктык бугай без...

Иң әүвәл без дингә кизәндек. Мең елдан артык тарихы булган, буыннан-буынга тапшырылып кешенең аңына, рухына, канына, карашларына сеңгән, яшәү принципларын, көн күрү рәвешләрен билгеләп торган бу катлаулы өлкәнең үзенчәлекләрен белми, асылына төшенми торып, үзебезгә «ахыр нәтиҗәсе нәрсә булыр» дигән сорауны бирел мәшәкатьләнми генә «ура» кычкырып һөҗүмгә бардык.

Югыйсә, максатыбыз ачык иде — атеистлар тәрбияләү иде. Әмма атеизм ул — җәмгыятьнең диалектик законнарын тирәнтен өйрәнә һәм аңлата торган тулы бер карашлар системасы. «Җимерүчеләр» иң әүвәл шуны аңлап, шуның белән коралланып эш итәргә тиешләр иде. Чынлыкта, дингә каршы көрәш муллаларны — авылның могътәбәр кешеләрен мыскыллап такмак чыгару, аларны эзәрлекләү, Коръән сүзе кергән китапларны яндыру, мәчет манарасын кисүләргә кайтып калды. Шуның белән халык көче тудырган ни кадәрле культура һәм архитектура истәлекләре юкка чыкты, яндырылды, җимерелде. Кешенең иманы тартып алынды, ә алмашка бер нәрсә дә бирелмәде диярлек. Нәтиҗәдә, без атеистларны түгел, ә «алласызлар»ны, «имансызлар»ны, ышанычын югалткан кешеләрне тәрбияләп үстердек. Әхлак өлкәсендәге тайпылышлар шул чорда башланды да бугай инде...

Бик тиз, гаять кыска срокларда үткәрелгән тоташ коллективлаштыру да авылларны дер селкетеп алды. Крестьян аңышмый да, төшенми дә калды, ул арада аның тирәлегеннән «корткычлар»ны, «кулак элементлар»ын эзли башладылар. Күпләр өчен бу процесс «Себергә сөрү» фаҗигасе белән тәмамланды. Аннары — сугыш! Авыр еллар. Каһәрле еллар. Исәпсез-хисапсыз налоглар, заемнар... Крестьянга «бир!» дип әйтү генә гадәткә керде, «мә!» дигән сүз аңа карата кулланылмады.

Һәм, монысы инде безнең көннәрдә, җир кешесенең сабырлык савытын тәмам чайпалдырып җибәргәне — кечкенә авылларны перспективасыз дип игълан итү булды. Кычыткан баскан нигезләре генә, кыр уртасындагы зиратлары гына кайчандыр авыл булганлыгын хәтерләтә торган урыннар әнә шулай барлыкка килде. Бу җәһәттән Р. Газизовның «Монда авыл булган...» дигән шигыренә тукталасым килә. Тигәнәкләр баскан нигезләргә карап, шагыйрь авыр хисләр кичерә дә, авылны ташлап киткәннәргә нәфрәт яудыра башлый:

> Бу авылдан качкан кешеләрнең
> Тигәнәкләр баскан бәгырен.

Тәнкыйтьче Ф. Зөлкарнәев бу шигырьгә зур бәя бирел, аны «туган җирен, туган халкын өзелеп яратучы, шулар язмышы өчен борчылучы гражданин-шагыйрьнең йөрәк

авазы...» дип билгели. Сүз дә юк, бик аянычлы хәлләрне, әйтергә кирәк, чорыбызның иң трагик күренешен сурәтли Р. Газизов. Ләкин гаепләү җиңел, иң әүвәл ул «тигәнәкле» бәгырьләрне» аңларга кирәк. Исеме республикабызда яхшы таныш булган колхоз председателе Нәҗип Зыятдинов турында күптән түгел генә документаль повесть басылып чыкты. Җирне, игенчене яхшы белгән, дөньяның бөтен ачы-төчесен, уңышын-хәсрәтен җаны аша үткәргән герой менә нәрсә ди: «Соңгы вакытта авыл халкы авылдан кача, яшьләр авылда калмый. Нигә алай? дип лаф орабыз. Тирәндә түгел аның серләре, өстә генә ята, әнә шул мыскыллаулар, ничәмә-ничә еллар крестьяннан көлү, мәсхәрәләү аның канын катырды».

Тагын да аянычрагы, «каны каткан» крестьян — элеккеге, җиргә табынучы кеше түгел инде ул. Моңысы хәтәррәк; күпкә куркынычрак нәтиҗә бу! Бәгыре катканнар әнисенә төзәп ук аткан манкортларны хәтерләтә башлый. Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романында Алтынбикә түгаен сөрдерткән Ризванны, Фәүзия Бәйрәмованың «Болын» повестенда чәчәкле болынны сукалап, актарып ташлаган Алмазны хәтерлисезме? Болар бит үзләре тәгәрәп үскән «туган ягы — яшел бишекләрен» җимергән, яндырган кешеләр! Алар бит күктән төшкән явызлар түгел, шушы җир кешеләре. Хәзер без, шагыйрь К. Сибгатуллин әйткәнчә, «каян килде болар, кемнәр бу? — дип үзебезгә үзебез карыйбыз». Манкортларның кылган эшләре дә аяныч була... Ф. Бәйрәмовага сүз бирик әле: «...үлән-чәчәкләрнең мәңгегә өзелгән тамырлары, җәрәхәттән ачылган нерв җепселләре кебек, таралып, җиргә китәсе тармакларын ачык күккә төбәп, җан бирел яталар. Кантар араларына әллә яңгыр суы, әллә җирнең күз яше җыелган... Бередә... үлем тынлыгы. Меңләгән бөҗәк-кортлары, чикерткәләре гөжләп-җырлап, йөзләгән кошлары сайрап торган болын тавыш-тынсыз гына, моңсу гына дөнья белән хушлаша».

Табигать экологиясе котылгысыз рәвештә безне әхлак экологиясенә китереп чыгарды... Кечкенә авылларны бетерү шаукымы табигатькә гаять зур зыян ясады. Менә Удмурт дәүләт университетының удмурт әдәбияты һәм СССР халыклары әдәбияты кафедрасы мөдире А. Г. Шкляев китергән фактлар: 1941—1985 еллар арасында Удмурт АССРда 2541 авыл яшәүдән туктады. Шул чорда 2000 гә якын инеш һәм елга юкка чыга. («Молот», 1988 ел, 3 сан).

Ярый, инде җире сөрелгән-сукаланган «перспективасыз» авылдан китеп шәһәргә килеп урнашкан татар крестьянын алыйк. Әле аңарда авыл моңы яши, гореф-гадәтләр, тел, халык культурасы яши. Ләкин шәһәр мохите башка булу, милли сыйфатларның саклануы өчен төп шарт — милли мәктәпләр юклыгы (булса да, алар формаль гына, бары тик отчетларда гына «яшиләр») икенче, өченче буында традицияләрнең өзелүенә китерә. Нәтиҗәдә, үз халкының җирлегеннән аерылган, шул ук вакытта башка, яңа этносның традицияләрен (бу очракта рус культурасын) үзләштерә алмый ике арада калган буын — төркем барлыкка килә. Фәндә мондый арадаш буынны «маргиналь халәт» дип атыйлар. Фин галиме, этнолог һәм демограф Сеппо Лаллука фикеренчә («Вечерняя Казань», 1988 ел, 14 сентябрь саны) маргиналлар — этика, әхлак мәсьәләләрендә иң сай һәм түбән фикер йөртүчеләр, шуңа күрә аларның үз-үзләрен тотышында кискен читкә тайпылулар аеруча көчле була. Мәрхәмәтсезлек, явызлык, таш бәгырьлелек белән аерылып торучы мондый типлар үз ишләре арасында да шундый мохит хасил итәләр... Чаллыда, аеруча Казанда, җәмәгатьчелекне борчуга салган күренеш — яшүсмерләрнең төркемнәргә тупланып урам сугышлары оештырулары һәм бу бәрелешләрдә гадәттән тыш кансызлык, вәхшилек хөкем сөрү сәбәпләрен әнә шуннан да эзләргә кирәк. Зур ялгышларыбыз, бумеранг кебек кире кайтып, үзебезгә суга.

Авыллар... Җир хуҗасы — игенчеләр, терлекчеләр.... Рәсми тел белән әйткәндә, колхозчылар, совхоз эшчеләре. Кемнәр алар, ничек яшиләр, нинди максатлар белән көн итәләр? Ул өметләрнең кайсысы тормышка ашкан да, кайсысы хыял булып кына калган һәм ни өчен? Сораулар, сораулар... Аларга җавапны әдәбиятыбыз, кызганычка каршы, әлегә бик юаш, як-ягына карана-карана гына эзли.

...Сүз башыбыз «яфраклары яшел ак каен» гына иде. Бу сагыну җырын борчылу белән искә алырбыз дип уйламаган да идек...

Бүген экология проблемасы бөтен илләрне дә борчый торган төп мәсьәләгә әверелде. Бу кискен шартларда язучыдан икеләтә, өчләтә җаваплылык хисе таләп итела. Әдәбият гомер-гомергә халыкны уятучы, авырлыкларны хәл итү юлында берләштерүче көч булды.

Бүгенгә әле без — экологик катастрофага дучар булмаган буын... Бүгенгә әле безнең баш өстебездә кояш балкый, йолдызлар җемелди... Җиде кат диңгез кичеп килгән тымызык җил салмак кына куенга сыена... Иксез-чиксез илебезнең җәйрәп яткан урмансулары күзләребезне иркәли...

Җиребезне иртәгә дә ак каенлы, тургайлы килеш, исән-имин килеш кояш тирәли әйләндерә алырбызмы?

Алырбызмы?!

## Сәгыйть Хафизов

# ПОЛИТИКА ҺӘМ ШИГЫРЬ

Бүгенге күп милләтле совет әдәбиятында политик роман, политик драма, политик җыр, шигырь кебек жанрлар активлашып китте. Шуның белән бергә сәяси башлангыч лирик, философик пландагы әсәрләрдә дә көчлерәк сизелә бара.

Әлеге күренешләр турында уйланганда, әлбәттә, хәзерге татар әдәбияты да гомум үсеш тенденцияләреннән чыгарылма булып тормый, анда да политик факторларның роле көчәя. Әмма бүгенге татар поэзиясенә караган тәнкыйть чыгышларына колак салганда бу гөман итү һич тә теләктәшлек тапмый. Нил Юзиевның соңгы еллар татар тезмә иҗатына йомгак ясаган бер докладында хәтта бу өлкәдә тирән парадокс барлыгы ук күрсәтелә: «Хәзерге тормышта заман кешесе политикага, җир шарындагы һәр төрле вакыйгаларга тагын да ныграк якынайды, ә безнең әдәбиятта, киресенчә, политик һәм гадәти конкрет тормыш Такташ, Җәлилләр чоры белән чагыштырганда шигырьдән читләшә төште... Поэзиянең традицион мәңгелек темаларына ныграк ябышу, шуларны калкан итеп, алар артына посу тенденциясе сизелә...»

Әйе, безнең хәзерге шагыйрьләрнең политик шигырь жанрындагы эшчәнлекләрен егерменче, утызынчы еллар, шулай ук, сугыш арты әдипләренең сәяси әсәрләр язудагы активлыгы белән һич тә тиңләп булмый. Әмма жанр бүген сан, күләм нисбәтендә нык кына оттырса, аның сыйфат ягыннан тирән үзгәрешләр кичерүе, камилләшүе дә хак бит.

Безнең карашыбызча, элекке шигырьдә дөньядагы теге яки бу политик вакыйганы, сәяси күренешне кайнар эздән килеп тасвирлап, аларга карата публицистик пафослы сүз әйтү, ачык тенденциозлы фаш итү яки яклап чыгу позициясе характерлы иде. Бүген исә байтак шагыйрьләр сәясәттә оперативлыкка йөз тотмыйлар, бәлки иң элек политик процессларның үз күңелләрендә фәлсәфи, әхлакый, этик аспектларда яңгырашларын табарга омтылалар. Шул ук вакытта шагыйрьләр аңында сәнгатьчә идея, образ, деталь кебек төшенчәләргә бәйле поэтик ситуация дә ныграк актуальләшә. Политик фикерләү белән художество фикерләве бергә кушылганда, гармония тапканда гына әдәби җәмәгатьчелек һәм укучылар кабул итәрлек әсәр туа бүген.

Кыскача әйткәндә, әлеге аерымлыкларны болай дип характерларга мөмкин булыр иде: безнең көннәрдә политик шигырь интенсив тестә лириклашу процессы кичерә. Объектив дөнья сурәтләре шагыйрьнең шәхси йөрәгенә ныграк үтеп кереп, тойгыларына мулрак төренә. Бүгенге политик шигырь шагыйрьдән көчлерәк януны һәм газаплырак эзләнүләрне сорый, шуңа күрә элекке еллар белән чагыштырганда ул сирәгәя төште.

Политик шигырьнең лириклашу тенденциясе, чишмәләр, инешләр бергә кушылып елга ясаган сыман, илленче елларның бер төркем шагыйрьләре Ә. Фәйзи, Г. Хуҗиев, Ш. Мөдәррис, З. Мансур иҗатларыннан юл ярып, Әнвәр Давыдов поэзиясендә инде ачык сиземләнә. Шагыйрьнең «Күмер көйри» әсәрендә утлы күмер образы башта турыдан-туры Җир йөзендәге афәтне, янгыннарны искәртә:

*Вьетнамда кисеәлә мең-мең гомер,*
*Чаткыланып көйри күмер...*

*Пентагоннан,*
*Тагын Боннан*
*Килгән җилләрдән ул көйри.*

Ләкин алга таба күмернең гади күмер генә булмыйча, кызыклы метафорик образ икәнлеге ачылып китә:

*Күкрәгемдә*
*Зәңгәр ялкын булып кабынырга торган*
*Кара күмер йөри...*

Күмер-йөрәк ерак дөньялардагы гарасат, ут-ялкыннар өчен генә көйрәми, бәлки үзебездәге ямьсезлек, гамьсезлекләр өчен дә эрнеп яна.

*Урамда*
*Кайбер яшьләр (кызлар да бар!)*
*Көнбатышка охшарга теләп,*
*Әрсез шаулап, акырып йөри...*
*Күмер көйри...*

Хәрәкәттәге планета һәм шагыйрь йөрәге концепциясе Хәсән Туфан иҗатында тагын да үсте, конкретлашты. Юкка гына шагыйрь «Гасыр уртасына хатлар» исемле политик шигырьләр циклын лирикага мөнәсәбәтле итеп санамый. Ул: «Сөя, ләкин минем шагыйрь илем һәр темада лирик булуны», дип фикерләп рационалистик политик шигырьне дә йөрәк белән җылыту кирәклеген әйтә. Һәм Туфан иҗаты шул мөһим омтылышта кыю үсеп, гаҗәп соклангыч табышларга ирешә:

*Кил әле, кил...*
*Үбим үзеңне бер!*
*Яратам мин сиңе, Җир шарым!*
*Кочагыма минем сыймасаң да,*
*Җаныма бит сыясың, җаным!*

Шагыйрь җанына Җир шарын сыйдырткан шигырь үзенең гиперболасы белән түгел, ә принцибы белән ныграк әһәмиятле иде әлбәттә.

Сәяси дөньяга киереп йөрәк ачуны алтмышынчы елларда мәйданга чыккан яшь шагыйрьләребез кайнар хуплыйлар һәм политик шигырьдә лирик башлангычның үсүе үзен әдәбияттагы уңай тенденция буларак сиздерә башлый. Политик үткенлек, югары граҗданлык, художество өлгергәнлеге белән сокландырган заман шигырьләре әллә нинди катлаулы вакыйгаларны ачу яисә сенсацион фактларга корылуга карап түгел, ә башлыча шагыйрьнең үз җирлегенә, кичерешләренә таянып язылулары белән алдыралар иде.

Әйтик, Роберт Әхмәтҗановның «Хиросима шагыйрьләренә» шигырендә лирик геройның кояш иленә афәт килгән август иртәсендә яланаяклы малай булып болынга бозау куу факты, бер караганда, бик сәер кебек. Җитмәсә малай кешелекне тетрәндергән политик вакыйгадан аз гына хәбәрдар да булмаган. Әмма хәзер аңа кордашы Сасаки фаҗигасе килеп ирешә:

*Атом корбаны нәни Сасаки*
*кайда да еллар аша*
*атом көйдергән күзләрен эзләп,*
*Кояш сорый нәни учына...*

Һәм шагыйрь җирдә һаман саркып торган атом ярасына әрнеп, япон шагыйрьләренә эндәшә: «Нигә күтәрмисез тавышыгызны?..» Әрнүле эндәш белән тулган шигырь укучыны тойгыларның чынлыгы, ихласлыгы белән тәэсирләндерә. Алар, һичшиксез, яшел болын буйлап яланаяк кызыл бозау куган малай образыннан башлана.

Р. Гатауллин «Европада татар шагыйрьләре» циклы белән халыкара масштабта үз халкын һәм үз «мин»ен яхшы ук уңышлы сурәтли белгән шагыйрь итеп танылган иде. Европа урамнарыннан, Эйфель манарасыннан торып аның лирик герое үз язмышының бөтенлегенә ышанды. «Йокы юк шагыйрьгә» шигырендә дә «тату, дус гаилә без илдә — Татарстанлы» дип хөр, политик тигез хокуклы кеше булуына горурлана ул. Ләкин дөньяда җәбер-золым кичергән, кыерсытылган халыклар да күп әле.

*Кыйныйлар негрны, индеец,*
*ирландны.*
*Димәк ки, мине дә,*
*димәк ки — татарны,*

дип шагыйрь шул халыклар өчен үз тәнендә дә физик авырту тоя. Укучысына да шул авырту килеп ирешә.

М. Әгъләмовның «Онытма, Европа!» әсәрендә дөньяның кайнар нокталары, әллә кайда Каф тавы артларында булмыйча, «Татарстанның урта бер җирендә» сызлану төбәкләре булып ята. Сонгми — Вьетнам авылы — лирик геройның үз авылы да ул. Ә кешеләре — аның авылдашлары:

*Сонгмида үтерелгән карт —*
*авылдашым Шәйхи.*
*Үтерелгән карчык — авылдашым Шәрифә.*

*Сонгмида үлгән әби — минем авылдашым —*
*Минем бавыр ташым.*

Ерак чит ил кешесен үз мөхитендә итеп күрү осталыгы Р. Миңнуллинда да бар. «Дуамал егет турында баллада» сында ул:

*Нәкъ шул чакта дөрли иде Чили*
*Үтергәннәр иде Хараны.*
*Шул кайгыдан ул уйнаган икән*
*Аермыйча акны-караны,*

— дип яза. Егет моннан гына җанына тынычлану тапмыйча, удар төзелешкә — Себергә китә. Анда ул батырлык эшли, үлә. Һәм шагыйрь образга бик әһәмиятле деталь өсти:

*Кыяфәте, йөзе белән дә ул*
*Бик охшаган иде Харага.*

Чилинең патриоты, соклангыч гражданины да дуамал егет сурәте аша конкрет һәм реаль булып укучы каршына баса.

Ләкин безнең ышануыбызча, шигырьдәге шәхси, лирик башлангыч әсәрнең эмоциональ көчен, тормышчанлыгын көчәйтүче фактор гына түгел ул. Мондый башлангыч катлаулы, чуалчык дөнья хәлләрендә адашмас, буталмас өчен, кеше хәленә үзеңне куеп, тәҗрибәдән чыгып карап, дөрес ориентир алу өчен дә бик кирәк.

Өлкән шагыйребез Н. Арслановның «Корваланнар кайта» шигыре Чилидәге канлы вакыйгалар уңае белән дөньяга килгән иде. Шагыйрь бу илдәге фашистлар өеренең тузынуын нәфрәтләнеп сурәтли дә, ничектер җиңеләеп, кинәнеп мондый фикер әйтеп куя:

*Кул-аягы арынып тышавыннан*
*Чыга камалганнар.*
*Төп иленә, үлем кочагыннан*
*Кайта Корваланнар.*

Әйе, Чили коммунистлар партиясенең җитәкчесе Луис Корваланга безнең ил политик ышык бирде, халкыбыз шатланып аны үз гаиләсенә алды. Ләкин Корвалан шәхсән эмигрантлыкны ничек кабул иткән соң? Ул үзе вәхшәттән котылса да, аның иле, халкы ут эчендә кала бит! Шагыйрь әйткәнчә, кайту микән әле бу? Бәлки үлемне адаштырып безгә вакытлыча килү, көрәш урынын, чараларын гына алмаштырудыр бу?.. Кыскасы, Корвалан хәленә күпне кичергән шагыйрьнең катлаулы тойгылар аша каравы кирәк иде.

Гомумән, безнең аерым шагыйрьләр иҗатындагы сәяси темадагы сүрәнлек һәм кызыксызлык авторларның рационалистик, үтә бертөрле, стереотип фикерләү колы булуларыннан килә. Ягъни дөнья хәлләренә карата шәхси позицияне билгели алмау дигән сүз бу. Яшь шагыйрьләребезнең берсе Г. Моратов бер шигырендә болай ди:

*Бу хәвефле планетаның*
*Газиз миңа һәр ягы.*
*Ультракыска дулкыннарда*
*Тыңлап ятам дөньяны.*

Ул җир ямьшы өчен ничаклы гына тирән борчылуларын белдермәсен, үзенең түгәрәк тормышы, тыныч табигыйлыгы белән бу хисне укучыга җиткерә алмый, әлбәттә. Җан кәвефлеген коры сүзләр белән түгел, ә дулкынландыргыч сурәтләр, чын шәхси кичерешләр ярдәмендә генә биреп була.

Политик шигырь ул дөньядагы мөһим сәяси фактларны тасвирлап шуларга карата укучының тойгыларын формалаштырып кына калмый, ә бәлки аның сәяси аңын үстерүдә дә актив катнаша. Шулар арасында, мәсәлән, халкыңны, туган җиреңне, Ватаныңны сөю; тынычлыкны яклау яки сугышны булдырмау өчен көрәшү; кешене хөрмәт итү, ярату; интернациональ солидарлык һәм башкалар аеруча әһәмиятлеләр. Мәгълүм идеяләрне гәүдәләндерүгә татар совет шагыйрьләре һәрчак зур игътибар биреп килделәр. Әмма сугышка чаклы һәм сугыштан соң да алар безнең поэзиядә шактый декларатив сурәтләнделәр, ә кайбер шагыйрьләр исә политик фразалар, лозунглар кычкырудан да тайчынмадылар.

Алтмышынчы елларда исә политик шигырь бу мөнәсәбәттә дә кискен сыйфат үзгәрешләре кичерә. Безнең яшь шагыйрьләр теге яки бу политик идеяне художниклык осталыгы белән сурәтләүгә, рәсемнәргә күчәләр һәм аларның табигый нәкышлы әсәрләрен хәтта политик шигырь жанрына кертеп карау да кыенлашып куя.

Мәгълүм хасиятләр турында уйланганда без иң беренче чиратта Ренат Харис иҗатын күздә тотабыз. Р. Харис һәм дөньяга караш яссылыгында, һәм художестволы фикерләве белән татар политик шигырен яңа югарылыкларга күтәрә. «Безнең гасыр» исемле программ рухлы шигырендә шагыйрь шәхесе үзенең гражданлык активлыгы, сугышчан позициясе, гуманизм игелеклелеге белән сокландыра.

*Безнең гасыр кемнәр гасырымы?*
*Минем өчен минем гасырым.*
*«Кем эше бу?» диеп сорасалар,*
*Икеләнми торып басырмын.*
*Без киләчәк буын каршысында*
*Бер-беребез өчен җаваплы...*
*Яманлыклар өчен без гөнаһлы,*
*Яхшылыклар өчен саваплы.*

Шагыйрьнең сәнгать принципларын билгеләүгә якын килгәндә, ул Һ. Такташның югары идеяләрне халыкның үз тормыш-көнкүрешенә бәйләп сурәтләргә кирәк, дигән акыллы киңәшен үзәккә алып иҗат итә бугай. Чынлап та, әйтик, «Уйнамагыз!» шигыренә игътибар иткәндә, анда: кешелек, атом сугышын булдырмыйк! дигән идея ярылып ята. Әмма шагыйрь укучы алдында арышлар серкә очырып килгән ямьле җәй фасылын сурәтли. Сукмактан чиләк аскан сылу кызлар төркеме төшеп килә. Күпмедер вакыт узгач, кызлар табигать хозурлыгында чыр-чу килеп, рәхәтләнеп ял иткәч, яңадан да үз сукмакларына төшкәннәр:

*Су коеныл*
*Сулар алып,*
*Сылу кызлар менеп килә*
*Күкрәкләре турысында*
*Күлмәкләре юль-юешләр.*
*Мөлдерәмә чиләкләренә*
*Арыш серкәсе коела...*

Шагыйрь шул гади күренешнең тирән ямь, бөтенлек, мәгънә белән тулган булуын яхшы аңлый һәм кайдадыр мәкерле планнар корып яткан сугыш чукмарларын искәртә. Ләкин аның искәртүе дә һәркөн яңгыраган дежур фразалар булмыйча, бары халыкның көнкүреш тәҗрибәсеннән чыккан бик кирәкле эш кылуны хәтерләтә кебек:

*Уйнамагыз —*
*унар чакрым биеклеккә*
*Чөймәгез агулы тузан:*
*Елгаларның,*
*Чишмәләрнең*
*Күлләр,*
*Океан-диңгезләрнең*
*өсте япмаган!*

«Өсте япмаган!» Җәен-кышын кое өстендә капкач тоту аның суын саф, ә яшь балалы гаиләләрне афәттән сакларга мөмкинлек бирә иде. Исегездә тотыгыз, ди шагыйрь, дөньяга капкач юк...

Безнең кайсыбыз машиналарга төялеп яңа фатирга күчүче бәхетле гаиләләрне күрмәгән? Шагыйрьгә дә бу сөенеч китерә:

*Өйдән өйгә, әнә, күченәләр.*
*Шатлык белән дөнья өртелгән —*
*Машинадан, рояль, шкафлардан,*
*Күз, йөзләрдән бәхет бөркелә.*

Әмма күченү хәле шигырьдә икенче ассоциация дә күзгата:

*Бер энәгә, имеш, бер сыер дип,*
*Туган илне ташлап киткәннәр,*

*Кайталмагач*
*Туган илдән килгән*
*Кош эзләрен ятып үпкәннәр...*

Р. Харис поэзиясе өчен менә шулай олы мәгънәләрне табигый суратка, рәсемгә салып гәүдәләндерү хас. Бу, әйтелгәнчә, принцип тәшкил итә. Һәм әлеге принцип белән эш итүдә мәгълүм шагыйрь һич тә ялгыз түгел.

М. Әгъләмов шигырендәге:

*...Безнең бабайларга*
*Кырыс еллар биргән акылны*
*Ой каршына иманнарне түгел*
*Утыртканнар сайлап тупылны,*

— дигән юлларны укыгач та, «Ник тупыл, ә иман ниса каен түгел?» дип фикерләп куясың. Шул ук вакытта күзәтүләрең, тормыш тәҗрибәң тупылның йорт агачы булуын искәртеп куя. Чынлап та халык каршында ни кадере бар соң бу агачның?.. «Ә... тупыллар яшеннәрне яхшы үткәргән»... йортны ут-күздән саклаган.

Шагыйрь менә шулай уңышлы метафорага нигезләнеп Ватаныбыз белән горурлана. Безнең илнең планетада тынычлык терәге һәм кешелек язы икәнен рәссам осталыгы белән ачып сала.

Шагыйрә Флера Гыйззәтуллинаның «Сатин чуклар» әсәрендә сугыш чыгар алдыннан гына гаиләгә үги ана килә. Ата кешенең яуга китүе, илгә килгән кысанлык һәм шуның өстенә үги ана катылыгы балаларның бәгыренә төшә. Ләкин яшәү бит бу! Тамак кайгысы, уен тойгысы йозак-сандыклар вата... Апалы-сеңелле кызларның үги ана киеп килгән затлы күлмәккә күзе төшкән була:

*Күлмәк итәгенә сапкан бәби итәк —*
*Без санадык инде:*
*Туар бәби саны!*

Үги ана эштә чакта шул бала итәкле алсу күлмәктән курчаклар тегелә, чук-чук киселеп матча, түшәм дә бизәлә. Үги ана бу эштән гаҗиз булса да, ярсынса да, балалар бизәгенә кагылмый.

*Һәм шул чуклар дүрт ел җилфердәде*
*түрдә*
*Өметләрне биләп,*
*яу тынганны теләп.*

Вакыт үтү белән кызлар үги аналарының фаҗигасенә төшенеп, инде аның өчен үзләре әрни башлыйлар:

*Хыял укенечкә!—*
*Билләр һаман нечкә...*
*Сибелеп үзлегеннән сатин чуклар кими.*
*Бер дә бишек җыры көйләмәгән килеш,*
*Бу яшь ана инде тол да каламыни?*

Шигырьдәге фикер тынгы бирми. Сатин чуклар — сугыш корбаннары!.. Сугышны тагын кем шулай нечкә тойгылар белән каһәрли алыр икән?

Нурия Измайлованың «Табын» шигыре балачактан таныш, шөкрана тойгылар уятучы көнкүреш төшенчәсе турында. Табын икән, димәк, аның тирәсенә туганнар, дуслар, танышлар җыела. Ә шагыйрьнең табынына халыклар, дәүләтләр тупланган:

*Бер табында төрле илләр,*
*Бер үк чәйләр эчелә.*
*Әйткән тостлар туры килә.*
*Укылган китаплар да,*
*Күргән кино, сөйгән җырлар*
*Хәтта анекдотлар да!*

Чынлап та, тизлекләр үсеп, аралашу көчәйгән бер заманда халыкларның тормыш-көнкүрешендә дә гаҗәп уртаклыклар күзәтелә. Алар бер үк җирне «әнкәбез» дип атыйлар. Шулай дус, туган булып җир табынында бергә яшәргә иде! Әмма «табында — кан эзләре, күз яшьләре агыла... Ә табынга таш атканнар табыла да табыла...» Юк, табын түгәрәк,

нурлы булырга тиеш! Дәүләтләрнең үзара тыныч һәм тату яшәү идеясен — заманыбызның иң мөһим таләбен шагыйрь әнә шулай бик табигый итеп сурәтли.

Асия Минһаҗеваның «Кыргый күрәш» шигыре исә исеменнән үк табигатьнең кырыс гадәтләренә ишарәли. Атом заманында акылга, югары әхлакка корылган, яңача фикерләү һәм мөнәсәбәтләргә нигезләнгән политика алып баруны яшәүнең мөһим шарты итеп саный ул:

*Килер заман: Кояш үчен алыр —*
*Калмас ышык, калмас күләгә дә!*
*Уйланырга вакыт: берчак без үзебез*
*Калмабызмы Кызыл Кенәгәдә?*

Поэтик образ иҗат итүдәге аерым казанышлар янәшәсендә кимчелекләр дә ачык күренә.

Соңгы ун-унбиш ел эчендә бездә чәчмә шәрехләүле политик шигырьләр шактый күп языла башлады. Рәфикь Юнысовның «Җирдә яшим» китабындагы «Тагын ни?» шигырен, мәсәлән, без шундый типтагы әсәрләрнең берсе итеп саныйбыз. «Капиталистик илләрдә сак эшенә яңадан-яңа җанварлар тартыла» дип хәбәр бирә автор һәм укучыга шул уңай белән дүртьюллык тезмәсен тәкъдим итә:

*Овчарка, юлбарыс, тәвәләр,*
*Кобралар безнең «дус сафлар»да.*
*Тагын ни чакырыйк ярдәмгә —*
*Кешене — кешедән сакларга?*

Шигырь сарказмга корыла булса кирәк. Әмма көлке тумый, чөнки четерекле хәбәрдән арынып булмый, башваткыч ситуация килеп туа.

Х. Хөснуллин исә үзенең бер политик шигыре өчен теманы «Вакыт» программасыннан ала: «Израиль агрессиясе нәтиҗәсендә Палестина халкының алтмыш проценты иленнән китәргә мәҗбүр булды»...

«БМО мәгълүматлары буенча җирдәге һәрбер кешегә фәлән кадәрле урман һәм үтергеч корал туры килә» дип шәрехләү бирә З. Мансуров та «Өлеш» шигырендә. Аның «Йөз суы» (1983) исемле кечкенә күләмле китабындагы дистә ярымлап шигырендә зурзур аңлатмалар бирелгән. Ә «Шөгыль» кебек шигырьләрне аңлатмадар күплеге белән гыйльми текстны хәтерләтә.

Г. Тукай да үзенең «Китмибез!» шигырендә, мәсәлән, тәфсилле шәрехләү яза алган булыр иде. Ләкин ул моны эшләмәгән бит! Информацияне дә хис-тойгы аша бирүне кирәк тапкан.

Шагыйрь ни кадәр генә интим хисләр җырчысы булмасын, барыбер, иҗтимагый яшәешкә карата билгеле бер мөнәсәбәтне, идеяне алга сөрә ул. Моны үз замандашларыбызны күздә тотып кына әйтмибез. Киләчәк буын кешеләренең ничек яшәүләре безнең конкрет эшләребезгә генә түгел, бәлки уй-кичерешләребезгә, омтылыш һәм үкенечләребезгә дә бик бәйле бит. Димәк, тойгылар нәрсәнедер яклый, нәрсәдәндер искәртә.

Хәзерге татар шигырь сәнгате, конкрет әйткәндә, фәлсәфи, мәхәббәт, табигать яисә пейзаж һәм социаль юнәлешләр белән тармакланган лирика традицион тойгыларны үстерү белән бергә, укучыларга яңа иҗтимагый эчтәлекле хисләр тәрбияләүдә дә казанышлар яулый. Әйтик табигатьне саклау, кадерләү тойгысын уятуда безнең поэзиянең бәхәссез табышлары бар. Шагыйрьләр табигатьне үз йөрәгендә тоя, аның фаҗигасен үзендә кичерә башладылар:

*Һәрбер сынган ботак ыңгыраша,*
*Һәр тапталган үлән сызлана.*
*Һәрбер чишмә көлә челтерәп,*
*Әйтерсең лә, наян кыз бала.*

З. Насыйбуллинда табигатьне кешеләштерү булса, Р. Вәлиевта, киресенчә кеше табигать булып гәүдәләнә:

*Мин мин түгел әле — мин уйламыйм,*
*Минем аша Җир бу, җир уйлый.*

Шулай, безнең поэзиядә кеше белән табигать берлеген, яшәү дигән бөек төшенчә тәшкил итүен аңлау көчәйде.

Тәнкыйть яшь шагыйрьләрдәге халкыбыз тарихына карата «Еракка китеп карау»

позициясен шактый гына каршылыклы бәяләсә дә, аның да укучыда кирәкле, файдалы тойгылар формалаштыруын шикләнми әйтергә мөмкин. Ул яшәеш хакында, рухи тамырлар мәсьәләсендә фәлсәфи фикерләүләрне киңәйтте, киләчәккә карашларны яктыртты. Нәтиҗәдә кеше заты өстенә төшкән бурычлар, яшәүнең олы мәгънәләре турында уйланулар күпкә тирәнәйде.

Хәер, болар гына микән әле. Яшьләрдә тарихның хәвефле чакларына игътибар итеп язган байтак шигырьләр бар. Әмма шунысы кызык: гарасатлар курку-дулкынлану белән түгел, ә бүгенгенең бик гадәти фонында, гаҗәпләнү катыш сурәтләнә. Менә Зөлфәттә ничек:

*Монда, имеш, яулар җир селкеткән,*
*Юк ителгән, имеш, халыклар.*
*Шушы кырдан мәгърур ханнар үткән,*
*Кабиләләр үткән күченеп...*

Шагыйрь хыялында канлы зилзиләләр уйнап ала да, реаль күренеш яктыра: «бүген анда «Алга» колхозының ат көтүе йөри чемченеп...» Шулай аңарда үз чорына сөенү тойгысы кузгала:

*Мин ял итәм*
*— яңа гасыр улы*
*Болонь плащ җәеп болынга.*

Р. Миңнуллинның лирик герое исә «Хан тавында» басып тора:

*Очрый монда кылыч сыныклары,*
*Юлыгасың сөнге йә укка:*
*Заманында монда яу булгандыр,*
*Охшап калгандыр тау тамугка.*

Аны туган ягының тыныч күге, хыялый зәңгәрлекләре әсир итә, тынычлыгы, иминлеге шатландыра.

Р. Низамиевның «Музейда» шигырендәге лирик герой, шулай ук яңа гасыр улы. Ул дәһшәтле сугыш коралларын кабул итә алмый. Лирик герой сугышларның урыны музейда гына дип фикерли.

Ф. Сафин, З. Насыйбуллин, Я. Игәнәй, М. Шәйхи кебек шагыйрьләрнең әсәрләрен укыганда да әлеге мотив — кешелекнең гарасатлы үткәненә ихлас гаҗәпләнү тоясың. Аны Х. Әюповның түбәндәге юллары шактый конкретлаштырып күрсәтә:

*Дәверләрне бер кичмәкче идем —*
*Яулар белән челтәрләнеп беткән.*
*Ис китәрлек:*
*Кеше бу көннәргә*
*Ничек үтеп чыга алды икән?*

Яшь буында тарихи гаделлек, мәгънәле яшәүгә омтылыш көчле. Ул тарихтагы изгыштылаш, кан коюларны кыргыйлык, варварлык нәтиҗәләре итеп санап, шулар өчен ихлас әрни, хәтта аяла һәм аларның кабатлану мөмкинлеген уена да кертеп карарга җөрьәт итми. Сугыш — аларча тарихи логикасызлык, кешелек хатасы. Тарих дилбегәсен кулларында ышанычлы тоткан яшь шагыйрьләр, шулай итеп, сугышны инкарь итүдә, яшәүне раслауда үз юллары белән киләләр.

Тагын шунысын да өстәргә кирәк. Кайбер яшьләрдә, мәсәлән, А. Минһаҗевада «прессланган илләр ята, прессланган кешелек» өчен «үкси-үкси елыйсы» килү тойгысы сизелә дә, тарихи концепция тиз арада оптимизм, дәртле акыл белән сугарыла.

*Тарих үзе чорлар чылбыры ул,*
*Ә бүгенге син, мин, һәр кеше —*
*Шул чылбырның*
*Үткәнен һәм бөтен киләчәген*
*Тоташтыра торган өлеше.*

З. Насыйбуллин «чылбыр»ның конкрет әһәмиятен дә ачып күрсәтә:

*Кешелекнең киләчәге бәйле*
*Синең белән минем нык лыкка...*

Ләкин яшәеш мәгънәләрен ачуда хәзерге татар поэзиясе уңышлардан гына тормый. Әмма шунысы аяныч, моны аерым талантларның, бигрәк тә яшьләрнең иҗатта күтәрелү-төшү нисә урында таптанулары өчен борчылудан бигрәк, тулаем хәзерге поэзиянең үсеш дәрәҗәсенә карата әйтергә туры килә. Хәер, шигырь тәнкыйте бу турыда инде күптәннән тукып тора. Тик без тегеләй яки бу шигырьдәге, геройдагы нисә поэтик концепцияләрдәге йомшаклыкларны төрле сәбәпләргә аударып калдырмыйча, аларның төп, үзәк ноктада — кеше концепциясендә тамырлануларын күрсәтергә кирәк санлыйбыз.

Безнең шагыйрьләр, бигрәк тә җитмешенче елларда формалашкан яшьләр иҗатында кешегә карата шактый каршылыклы фикерләр чагылыш таба. Бер яктан, бигрәк тә карашларны декларатив белдергән очракларда, кеше турында шагыйрьләр бик оптимистик фикерлиләр. Әйтик, «Мин Галәмдә микронокта түгел, мин Галәмнең гражданины» (Г. Рәхим). Яки «Кемнәр генә безгә таянмыйлар, таяналар… димәк, без зур инде» (Рәшит Әхмәтҗанов). Янсә «Җир язмышы хәзер безнең кулда, без гадиләр түгел, без — галиләр» (З. Насыйбуллин) кебек раслауларда кешенең чынбарлыктан килгән көч-куәтен тану, горурлану ята. Әмма, икенче яктан, фәлсәфи, интим уйлануларына ныграк бирелгән саен, безнең шагыйрьләрдә кешенең вакыт, дөнья каршында гаҗизлегенә карап сызлану өстенлек ала:

*Калкансыз яши кеше,*
*Ак күлмәк киеп кенә.*
*Тәнендә тормыш уты —*
*Шәм уты кебек кенә.*

*Аны таптап сүндерү*
*Берни тормый көчлегә.*
*Кызган, зинһар, кагылма!*
*Кеше, тимә кешегә!*

Кеше турында шөбһәле уйланулы Р. Юнысовның лирик герое үзенең әйләнә-тирәсенә дә куркып-шикләнеп карый.

*Куркам, җирем, синең өчен*
*Гүя карчык — ана син:*
*Торган саен кечерәя,*
*Көчсезләнә барасың.*

Шөбһәләнү шундый дәрәҗәгә җитә ки, хәтта Г. Рәхим: «Вакыт җиле кисә гомерләрне, балки яшәү кирәк тә түгел?!» дип Гамлет соравын кабартып куя.

Әйе, бу сораулар атом, космос заманы өчен актуаль. XX гасырның диннән, мифологиядән арынган реалистик, ялангач материализмы, дәһшәтле атом энергиясе, серле кибернетика, катлаулы техника куәтләре, шулай ук, хаотик миграция, урбанизация хәрәкәтләре — барысы да рухи үзгәрешләр, кешегә карата заманча фикерләүгә ия булуны сорый. Шәхестән социаль һәм интеллектуаль активлык таләп итә. Әмма, кызганычка каршы, байтак шагыйрьләр үз инертлыклары белән катлаулы чынбарлык агышыннан читтә калалар. Шул хәл аларда кешегә карата каршылыклы мөнәсәбәтләр формалашуга китерә. Ягъни искечә хыял иткән кеше моделе белән гамәлдәге кеше яраша алмый.

Каршылык — алдагы киртә инде ул. Безнең поэзиядә нинди генә чагылышлар алмый ул! Берәүләр: «Гомер уза. Мин язмыштан, үзем исән чакта үзем коеп утырткан бакыр баганамнан риза» (Р. Гатауллин) ди. Икенчеләре: «Мәңгелекнең кай төше бу? Кышмы, җәйме? Кайсы ай?» (Г. Моратов) дип вакытта ориентирын югалткан. «Ага гомер, ятам шулай яшел болын кочагында. Якындагы шәһәр шавы таптап үтә кайчагында» (Х. Гайнетдинов) дип, өченчеләре тормыш агышыннан читләшкәннәр. Ә дүртенчеләре өчен вакыт та, хәрәкәт тә туктап калган кебек: «Чорлар белән чорлар арасында уйга талып тора кешелек» (М. Галиев).

Тагын кайберәүләрдә, мәсәлән, Р. Зәйдуллинда: «көз артыннан язмы, кышмы?» — дип, уйнапмы-чынлапмы, билгеле хакыйкатьләрдә дә буталу шаукымы бар:

*Нарасый өзгән алмада*
*Яңа ике теш эзе.*
*Безме соң бу, безме?..*

Әмма тагын да ныграк борчыганы шул: безнең байтак яшь авторлар киләчәккә куркынып карыйлар. «Якынлашып килә һәлакәт!..», «Упкын аста!..», «Дөнья кыл өстендә!..» дип урынлы-урынсыз чаң сугалар, сөрән салалар. Иҗтимагый яшәешкә карата мондый шикләнүле, хәтта өметсез караш, шул нигездәге социаль пассивлык, конкрет тормыш мәсьәләләренә битарафлык — зур традицияләргә нигезләнгән һәм анык иҗтимагый политик йөзе белән горурланган татар поэзиясенә килешми торган сыйфатлар. Безнең яшь шагыйрьләр үзләренең үсү юлындагы каршылыкларны, киртәләрне ачып, татар шигырь сәнгатен яңа югарылыкка күтәрергә бурычлылар. Кем киртәләрне атлап үтәр, кем чорыбызга лаек идея-эстетик концепцияләрне раслый алыр?..

Дениза Ибәтуллина

# БЕРЕНЧЕ БУРАЗНАЛАР

## ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫ

„Күп уйлыйсың, фикер йөртәсең. Бөтен эпоха турында, бөтен кешелек турында уйлыйсың. Язучы бит ул үз мәнфәгате өчен генә яши торган кеше булырга тиеш түгел, язучы бит ул кешеләр бәхетле булган вакытта гына... ниндидер якты, изге идеяләр белән сугарылса гына язучы була ала, шунсыз ул яза да алмый, язучы да була алмый».

Утызынчы елларда, Татарстан совет язучыларының шәһәр күләмендәге җыелышында яшь Әмирхан Еники үзенең иҗат позициясен нәкъ шулай билгели. Журналист Сафа Гыйлфан, билгеле бер чорда Ә. Еникигә карата тискәре карашта булса да, чынында исә ул да иҗатчының фәлсәфи-эстетик позициясен уңай яктан телгә ала:

«Ә. Еники болай ди: менә, күрәсез, иптәшләр, чишмә — табигатьнең көче, ул тау тишекләреннән, тау араларыннан бәреп чыгып тора. Менә шушы чишмәне никадәр генә таш кисәкләре белән күмсәң дә, ул туктамый, тагын бәреп чыга». (ТАССР Дәүләт архивы, 7083 ф., 1 тасв., 55 эш, 53 док.)

Ә. Еникинең иҗади эшчәнлеген егерменче еллардан башлап «Безнең юл», «Совет әдәбияты» журналларында басылып чыккан хикәя-нәсерләр, 1929 елда аерым китап булып дөнья күргән «Дус кеше» повесте күрсәтеп тора. Шул елларда язучының иҗади агымында, киләчәк иҗатына оеткы буларак, төрле-төрле идеяләр, образлар туа. Мәсәлән, 1933 елның январь аенда Татарстан Язучылар союзын оештыру комитетының беренче пленумында катнашучы делегатлар өчен анкета тутырганда, Ә. Еники «Нинди әсәрләр өстендә эшлисез?» дигән сорауга: «Яза башлаган нәрсәм «Безнең авторитетлар» (типлар сериясе)», дип җавап яза.

Казанга 1925 елда гына килгән Ә. Еники, озак та үтми, яшь язучылар Сәгыйть Агиш, Мирсәй Әмир, Фатих Кәрим, Габдрахман Минский, Демьян Фәтхи һ. б. белән дуслашып, аралашып китә, әдәбият дөньясына аяк баса. Ул язучы яки рәссам булырга хыялланган була. Балачактан ук китаплар укырга ярата. Күренекле шагыйрь, Г. Тукайның замандашы һәм дусты Сәгыйть Сүнчәләй Әмирханга ике китап (берсе Г. Тукайның «Су анасы») бүләк итә. Әмирхан ул чакта укый белми әле, әмма китапларны кулдан төшерми, битләрен кат-кат актарып чыга, рәсемнәрне кызыксынып карый. Һәм тора-бара хәрефләрнең мәгънәләренә төшенеп, алардан сүзләр, җөмләләр төзергә керешә. Көз көне мәктәпкә йөри башлаганда, ул инде укый-яза белә. Шулай итеп, Тукай әсәре Әмирханның белемгә сусавын арттыра, ана теленең матурлыгына сокландыра.

Еникиевләр яшәгән Дәүләкәндә татар китапханәсе була. Ундүрт-унбиш яшьләрендә Әмирхан шактый гына китаплар укып чыга, Г. Ибраһимовның булган бар әсәрләре белән таныша. Аның китапка булган ихтирамы көннән-көн арта бара.

Иҗат эшенә омтылыш яшүсмер агымында үз вакытын көтеп яши. Һәм Әмирхан бер көн «Кызыл Татарстан»да Архумаска (рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыймарәтчелек мастерскойлары) кабул итү турындагы игъланны күрү белән, Казанга укырга китәргә дип карар итә. Үзенең истәлекләрендә Ә. Еники 1925 елда Казанны беренче мәртәбә күреп соклануын тасвирлый. Казан! Күпме өмет, күпме дулкынлану уятты яшь йөрәктә бу исем. Казан шәһәрендә дагы Тукай яшәгән, урамнарында Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирханнар йөргән!

Шәһәргә килү белән Ә. Еники кайнап-ташып торган әдәбият дөньясына чума. Яшь әдәбиятчылар еш кына комклубта җыелышып шигырь, хикәя укыйлар. Тартыну юк, бәхәс башлана. Бу әдәби кичәләрдә хөкем сөргән рухи атмосфера, һ. Такташ, Х. Туфан, Г. Кутуйларның чыгыш һәм киңәшләре Ә. Еникине рухландыра, аны үз иҗатына җитди карарга өйрәтә. Шуннан да яхшырак мәктәпне тап әле! «Минем әдәбияттагы беренче адымнарым әнә шундый елларга туры килде, — дип яза Ә. Еники. — Беренче адымны җиңел генә ясасам да, әллә ни ерак китә алмадым... Аннары тәҗрибә бик бәләкәй иде бит әле, еш кына күңелдә туганны ничек итеп язарга белмичә, азапланып бетә торган идем. Шигырь бөтенләй чыкмый, мин моны башта ук белдем, шуңа күрә «нәсер» дигән чәчмә парчалар язгалап карадым. Хикәяләр язуга 1928 елдан башлап кына керештем». («Соңгы китап».)

Егерменче елларда татар әдәбиятындагы художество өлгеләре эзләү шаукымы Ә. Еникига да тәэсир итми калмый. Ул кайбер киңәшләргә колак сала, төрле карашларны чагыштыра, кайберләрен кабул итә (мәсәлән, Гомәр Галинең художество-эстетик прин-

циплары, журналлар битләрендә басыла барган иҗат психологиясенә караган аерым мәкаләләр һ. б.). Әмма ни генә булмасын, ул үз стилен, индивидуаль йөзен сакларга, югалтмаска тырыша.

Яшь иҗатчыга иң көчле йогынты, һичшиксез, Галимҗан Ибраһимов һәм Лев Толстой әсәрләре аша була. Беренчесе ана теленең образлылык куәтен раслап, татар әдәбиятында катлаулы характерлар, киң панорамалы тарихи-социаль, тарихи-фәлсәфи, социаль-психологик тормышны гәүдәләндерү мөмкин икәнлеген исбатлый. Икенчесе әдәбиятта катлаулы рухи дөнья, «күңел диалектикасы» барлыгын искә төшереп тора.

Ә. Еники нәсер, хикәя, повесть формасын еш куллана. «Дус кеше» повестенда Салих исемле бер бәндә кайчандыр бергә укыган шәриге Лотфины кунакка чакырып, үзенең кылган махинацияләрен каплап калу нияте белән тегенең дәрәҗәсеннән, дуслык бәйләнешләреннән файдаланмакчы була. Автор Салихның икейөзлелеген актыга куя, укучы күз алдына бу кешене төрле кыяфәтләрдә китереп бастыра: беренче кыяфәт — дуслык, ачыклык, кунакчыллык битлеге, икенчесе — аның чын йөзе, асылы.

«Ул йөзләрен җыерды. Тешләрен кысты. Кулларын көч белән йомарлады: «Шушы адәм имгәге, итләч бит тә, акыллы баш була торып, кешенең кызганыч хәленә керү, ярдәм итү түгел... менә бу кадәр хөрмәтләргә ихтирам йөзеннән генә дә ичмасам, яхшы, ягымлы сүз әйтү, түбәнчелек күрсәтү дә юк... Ә мин, ә мин җүләр, ахмак, шыр тиле, ярдәм дим. Шушы адәм имгәгеннән, кеше хатынына хайван шәһвәте белән янып, шашып утырган бер эттән ярдәм сорыйм: ярдәм кәтәм...» («Дус кеше». Татиздат. 1929 ел.)

Автор реалистик образлар бирергә тырыша, көн үзәгендәге конфликтларны тормыштан ала, ләкин повесть берникадәр схемачылыктан азат түгел. Әсәрдә төп герой урынын яулаган Лотфи характер буларак тәссез чыккан, Салих исә күп очракта туры сызыклар ярдәмендә тасвирлана. Дустының хәлсезлегенә төшенгәч, ул аны артык дорфа рәвештә куып чыгара (бу исә характерның социаль һәм милли сыйфатларына ятышып бетми).

Ә. Еники замандашлары бу әсәргә төрлечә бәя бирәләр. Гадел Кутуй авторны художник талантына ия дип саный, повестьны идеологик проблемалылык һәм сәнгатьлелек эретмәсе дип күрә. Г. Кутуй фикеренчә, авторның бу әсәре кайбер язучыларның «идеология белән сәнгать бергә була алмый, идеология тулы булса, сәнгать ягыннан аксый, сәнгать тулы булса, идеология ягы аксый» дигән ялгыш карашларын кире кага. Бу повестьта, ди Г. Кутуй, сурәтләү объекты дөрес тотып алынган, чөнки «хәзерге вакытта авылларда партия билеты астына ышыренеп, авылны бутап ятучы чит элементлар юк түгел, бар. Алар төрле юллар белән партия билетыннан файдаланып, кулакларны үз канатлары астына алып, алар белән бергә кулга-кул тотынышып эшлиләр. Алар белән баҗалаша, кияүләшәләр». («Кызыл Татарстан». 1929 ел, 17 сентябрь.)

Ә Гомәр Толымбайский повестька карата башкачарак караштa тора. «Матур әдәбиятта сыйнфый юлсызлык» дигән мәкаләсендә Г. Толымбайский авторның җитешсезлеген шунда күрә: «64 битле хикәя, авылдагы череп таралган коммунистның Лотфига сөйләгән монологлары, авылны хурлый торган сүзләре белән тулган». («Кызыл Татарстан». 1929 ел, 18 сентябрь.)

Г. Толымбайский Лотфины төп герой итеп алуга шик белдерә. Әсәр илдәге сыйнфый каршылыкларны чагылдырмый, партиянең роле күрсәтелмәгән, ди ул.

Икейөзле кеше тибы язучы иҗатында сугыштан соң чорда, «Саз чәчәге», «Рәшә» исемле повестьларда аеруча тулы булып формалаша.

Кыска жанр формасын Ә. Еники күбесенчә геройның лирик халәтен сурәтләү, дөньяны философик аңлау өчен куллана. Бу очракта язучыга И. С. Тургеневның «Стихотворения в прозе» циклы йогынты ясаган кебек. Ә. Еники үзе дә кайбер мәкаләләрдә бу язучының лирик прозасын телгә ала. Әгәр «Дус кеше»дә мәгълүм социаль-психологик типларга тартым сизелсә, «Кар шатлыгы» нәсерендә укучы инде лирика дулкынында коена, киләчәккә өмет өзмәскә, бәхеткә ышанырга кирәк дигән фәлсәфи-эстетик карашны очрата:

«Аңлыйсызмы?!

Яшәргә теләү шундый көчле.

Яңа шатлык, яңа матурлыклар сорау шундый чиксез, киләчәк көннәремне сагынып сөенгән күңелем шундый-шундый керсез...

— Көннәрем, таңнарым, беренче кар шатлыгыдай яңа шатлык белән, салкын кар һавасыдай саф, таза хисләр белән юсыннар!!!

— Ак мамык карлар җиргә яусыннар!..

Яусыннар!.. Яусыннар!..» («Безнең юл». 1929 ел, 1 сан.)

Шул ук аһәң: бәхеткә, яктылыкның җиңүенә ышану Ә. Еникинең соңрак, 1944 елда язылган «Мәк чәчәге» нәсерендә дә яңгырый:

«— Кеше, сез китәргә җыенасыз!.. Сезне анда канлы сугышлар көтә булыр, һәр адымыгызны, бәлки, үлек гәүдәләр, кара кисәүләр аша атлап үтәргә туры килер. Ләкин мин дөньяның матурлыгыннан туймаган, һаман да аны матур итәргә теләгән ялгыз мәк — сезнең һәр үткән адымыгыз артыннан чәчәкләр үсеп калуын телар идем... Кәл һәм каннан

яралган чәчәкләрнең рәхмәте сезне мәңгелек дан һәм бәхеткә илтсен! Хуш, Кеше, хуш! Ак юл сезгә!»

Әмма нәсер кысаларында да Ә. Еники конкрет социаль типлар урнаштыра. Ягъни ул фәлсәфи уйланулар һәм гомумиләштерүләргә социаль планны да кушмакчы, әсәрнең эмоциональ-идея куәтен арттырмакчы була. Мисал өчен «Бүгенге яз» исемле нәсерне алыйк: «Көмеш бикле портфельны кул очына гына эләктергән, киң җилкәле, яхшы драп пальтолы, каракүл бүрекле симез нэпман әфәнде корсагын киергән килеш тротуардан акрын гына атлый. Ул әле яңа гына беренче номерлы ашханәдән кыйммәтле ашлар, яхшы эчемлекләр белән сыйланып чыккан...»

Ә менә икенче бер тип: «Юка гына пальтодан, иске штиблеттан, сулган арык йөзле, ләкин тирән янар күзле студент китеп бара.

Аның йөзләре нинди дер күңел рәхәтлеге белән ихтыярсыздан елмайганнар. Аның да күзләре бүгенге язның хушлыгына, бүгенге язның ямьлелегенә, бүгенге кояш нурларының шундый йөрәккә керерлек үткен булуларына сокланып карыйлар». («Безнең юл». 1927 ел, 4—5 саннар.)

Бу очракта типларның икесе дә турыдан-туры конфликтка керми, ләкин язучының иҗади тойгысы гүя киләчәктә туасы киеренке конфликтларны алдан ук сиземли. Андый конфликтлар соңыннан бигрәк тә «Рәшә», «Шаяру» кебек әсәрләрдә дөньяга килә.

Ә. Еникинең башлангыч чор иҗаты тематик яктан да игътибарга лаек. Язучы персонажларның хәрәкәт даирәсен бертөсле җирлек белән чикләп куймый, ул авыл тормышын да читләтми, шәһәрдәге завод-фабрикалар тормышына да күз йөртә. Характерлар һәм вакыйгалар төрле ракурсларда укучы күз алдына килеп баса. Әйтик, «Мидхәт» хикәясендә үзәктә бер генә кеше, аның эчке монологы. «Никуличева һәм аның иптәшләре» хикәясендә исә эшче коллектив һәм җитәкчелек арасындагы мөнәсәбәтләр тасвирлана...

Без биредә танылган әдип иҗатының кайбер чыганакларына гына күз ташладык. Ул чыганаклар соңга таба язучының искиткеч бай, катлаулы, планетабыз әдәбияты үлчәүләре белән үлчәнергә лаеклы художестволы дөньясын барлыкка китерде.

**Яхъя Абдуллин,**

философия фәннәре докторы

# ДУМАВИНЫҢ ДӨНЬЯВИ УЙЛАРЫ



Татар әдәбияты тарихында егерменче гасырның башы аерым бер урын, үзенчәлекле урын алып тора. Бу хәл 1905—07 еллар революциясе тәэсире белән аңлатыла. Нәкъ менә шушы чорда татар халкының озак еллар дәвамында җыйнала, туплана килгән куәтле рухи энергиясе тышка бәреп чыгу мөмкинлеге ала. Нәкъ менә шушы елларда татар халкының иҗтимагый аңында, фәлсәфи һәм социаль-политик карашларында, әхлакый-этик, эстетик фикерләвендә тирән сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә. Күп санлы татарча газета-журналлар пәйда була, татар китабының саны һәм тиражы нык арта. Мәктәп-мәдрәсәләр тормышында да зур үзгәрешләр күренә, программаларга дөньяви фәннәр кертү буенча яңа адымнар ясала, әдәбият, татар һәм рус телләрен укытуда яңалыклар була. Милләтнең күп санлы прогрессив культура эшлеклеләре, журналистлар, педагоглар пәйда булу һәм милли театрның барлыкка килүе татар иҗтимагый тормышында гаять мөһим роль уйный.

Соңгы елларда бездә гасыр башы культура мирасын өйрәнү буенча шактый гына эшләнә башлады. Ул чорның тарихи вакыйгаларын һәм әдәби процессын яктыртучы күренекле шәхесләрнең тормышына, эшчәнлегенә һәм алар калдырган мираска багышланган мөһим монографияләр басылып чыкты. Шулай ук Г. Тукай биш томлыгының, Г. Ибрагимов сигез томлыгының, Ф. Әмирхан һәм М. Гафури дүрт томлыкларының, Г. Камал өч томлыгының басылып чыгуы да гасыр башындагы культура үрнәкләрен пропагандалау өчен мөһим күренеш булды. Дәрдемәнд белән С. Рәмиев әсәрләренең дөнья күрүен җәмәгатьчелек шулай ук җылы кабул итте. Ниһаять, без кулыбызга Нәҗип Думавиның сайланма әсәрләрен дә алдык. (Думави Нәҗип. Тормыш сәхифәләре. Шигъри әсәрләр һәм проза. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1985. Төзүчеләре Зөфәр Рәмиев һәм Резеда Ганиева).

Н. Думави әсәрләренең сирәк басылуын без инде беләбез. Алар сугыштан соң беренче мәртәбә 1960 елда дөнья күргән булса, бусы — икенче шундый вакыйга. Яңа басмага тегесендә булмаган 50 шигырь кертелү белән бергә проза әсәрләре дә тәкъдим ителгән. Шуңа күрә безнең алда Н. Думавиның дөньяга карашларын һәм әдәби-эстетик фикерләү рәвешен аңлау өчен материал, күбрәк. Алар Н. Думавиның татар әдәбияты тарихындагы ролен тагын да ачыграк аңларга булышалар.

Егерменче гасыр башы татар әдәбиятында Н. Думави бик тә үзенчәлекле фигура. Аның иҗат юлы вакыт ягыннан алганда әллә ни күп елны колачламаса да, ул юлда мөһим борылышлар һәм көтелмәгән үзгәрешләр шактый күп. Иҗатында нинди генә яңа тенденцияләр чагылса да, барыбер халык, милләт һәм аның киләчәге турында

---

АБДУЛЛИН Яхъя Габдулла улы *(1920 елда туган) — философия фәннәре докторы, профессор, РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, татар иҗтимагый фикер тарихы мәсьәләләренә багышланган берничә монография һәм күп санлы мәкаләләр авторы. Казанда яши. Бу айда Яхъя ага Абдуллинга 70 яшь тула. Шул уңайдан күренекле галимебезне журналның күп санлы укучылар исеменнән тәбрик итәбез, сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телибез.*

уйлану шагыйрь өчен иң төп мотивлардан булып кала. Әдипнең андый уйлары иң калку булып «Замана хәле шулай» исемле шигырьдә чагыла:

*Адәмнең кирәкләре хәддин ашкан,*
*Мәшәкать (нужа) илә тулып ташкан;*
*Сугышкач табигатьле гадәләтсез,*
*Золымлык гадәләтне бөгеп баскан.*
*Күрә алмый хәкаикъны ачык итеп,*
*Хакыйкать аның өчен ерак качкан.*
*Никадәр күрмәсә дә гаҗәп түгел,*
*Өйрәнгәч караңгыга кече яшьтән.*
*Шулкадәр авыр хәзер — гомер итү,*
*Уңаймас тәзәтмичә яңабаштан.*

1905-07 еллар революциясен Н. Думави шатланып каршылый. Бу чорда ул изелгән хезмәт кешесен яклап, патша самодержавиесенә каршы күп кенә шигырьләр яза. Шагыйрьнең яңа китабын ачып җибәргән «Революция заманы» шигырендә ул болай яза:

*Дулкынланды океаннар бу көннәрдә,*
*Болганадыр күңелләр һәм бу көйләрдә;*
*Талпыналар мәмләкәтнең кораблары, —*
*Сизенмәсәң, батып китәр бөтенләй дә.*
*Үзлегеннән күтәрелде ачы җилләр,*
*Атып бәрә корабларны ничә милләр.*

Алга таба китсәк, «Без дә файдаланыйк» дигән шигырь белән очрашырбыз. Анда шагыйрь үзенең милләттәшләренә мөрәҗәгать итә, аларны башка халыклардан калышмаска өнди, беренче революция биргән мөмкинлекләрдән файдаланып калырга чакыра, гомум кешелек хокукларыннан файдалану кирәклеген искәртә. «Яз. Күзне ачып карыйк әле» дигән шигырьнең идея эчтәлеге дә әнә шундый.

Революцион вакыйгалар куера башлаган елларда шагыйрь, Чистайдагы мөгаллимлеген калдырып, Урал ягына китә. Ләкин изге эшен биредә дә ташламый, шахтерларның балаларын укыта. Яңа мохит шагыйрьнең үзенә дә нык тәэсир ясый, аның социаль яктан өлгерүенә булыша. Тормыш тәҗрибәсе арту ачык чагылган шигырьләрнең берсе — «Җир күмере казучылар».

*Ничә сажин җир астында пәриләр күк бәреп-ватып,*
*Казыймыз ташкүмер, руда, чүгеп һәм түш илә ятып...*
*Белеп булмый: бу базларны казыймыз без бәхеткәме,*
*Яхуд үз гәүдәмез өчен чыгалмаслык ләхеткәме?..*
*Атнаның алты көнендә күренми безгә көн йөзе*
*Керәмез таң илә бергә, чыгамыз кич кышын-көзе...*

Әнә шундый төгәл тасвирланган социаль күренешләр шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә еш очрый башлый. Мисал өчен «Бер бай», «Байлар җире», «Заман хәлен...» дигән әсәрләрне атап күрсәтергә мөмкин.

Гуманист шагыйрь буларак, Н. Думави авыр хәлдәге хезмәт кешесен чын күңелдән кызгана. Ләкин ул моның белән генә дә канәгатьләнеп кала алмый. Үз әсәрләрендә шагыйрь катгый килешмәүчәнлеген дә белдерә. «Эч поша, күңел болгана», «Замана хәле шулай», «Җәй дә бетте, көз дә җитте» әнә шундыйлардан.

«Гарьлек» дип аталган шигырьдә ярлы кешенең тормышы, язмышы психологик яктан бик төгәл табылган сүзләр аша укучыга җиткерелә. Искиткеч түбәнлеккә төшкән хезмәт кешесен кызгану шигъри әсәрләрдә генә түгел, чәчмә әсәрләрдә дә төп тема булып бара. «Габдулла» һәм «Ике мәхәббәт» дигән хикәяләр әнә шундыйлар.

Ул чор тормышын чагылдырырга теләп, Н. Думавиның тоткынлык темасына, тоткын образына мөрәҗәгать итүе бер дә юкка түгел. Яңа китапта дистәдән артык әсәр менә шушы гайре табигый хәлне төрле яклап ачуга, күрсәтүгә багышланган. Шагыйрь кол булуның, коллыкның нәрсә икәнен бик яхшы белеп яза. Чөнки В. И. Ленин тарафыннан «халыклар төрмәсе» дип йөртелгән Россиядә тоткынлык, коллык тойгысы бик күп халыкларга хас иде. Н. Думавиның шигырьләре бу хисне бик ачык гәүдәләндерә:

*Давыл, кар, боз, суык-салкын һавасы,*
*Ябык, хур, кайгылы һәрбер баласы.*
*Хәбес (төрмә), богаулар һәм богаулар,*
*Кылыч, мылтык, револьверлы кагаулар.*
*Караңгы, һәр кеше монда бәхетсез,*
*Бәхетсезлек малик монда тәхетсез.*

Ул чордагы татар әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләре арасында Россиядәге политик стройны, патша властеның деспотизмын, дәүләт думасының көчсезлеген, аның хезмәтчел халык өчен нәрсә дә булса эшли алуы мөмкин түгеллеген Н. Думави сыман ачы итеп тәнкыйтьләүчеләр күп булмый. Бу яктан бигрәк тә шагыйрьнең «Государственная думага хитап» дигән шигыре һәм «Безләр нишлибез?» исемле публицистик мәкаләсе аерылып тора. Шулай ук «Үтте, үтте...», «Тавыш» һ. б. шигырьләрдә дә политик мотивлар өстенлек итә, хезмәт халкын һәртөрле җәберләүләр өчен, меңләгән кешеләрне каторгага сөрүләр өчен, гаепсезгә коелган кан өчен, гөнаһсызларның күз яшьләре өчен патша хакимиятенең гаепле икәнлеге раслана.

Ләкин шагыйрь монда патшаның үзен генә гаепләп калмый. Ул капиталны гаепләүгә кадәр барып җитә. «Эч поша, күңел болгана» шигырендә әлеге фикер мондый юллар аша белдерелә:

*Кая баксаң, җылап ага*
*Фәкыйрь кардәшләрем каны.*
*Атылмышлар, киселмешләр, —*
*Һаман бер туктамый шул хәл;*
*Исең китәр хисапласаң,*
*Ниһаятьсез моның саны!*
*Түгел бер патшада бу хәл,*
*Бөтен дөнья тулып Дәҗҗал;*
*Икенче сүз илә: ошбу —*
*Капитал дәүренең җае.*

Гади кешеләрнең тырышып һәм намус белән хезмәт итеп тә, гаять авыр хәлдә яшәүләре өчен капиталның һәм патша властеның гаепле икәнлеге әсәрдә бик ачык әйтелгән. Ә инде «Мәхәббәтме, рәхәт, шатлыкмы кирәк?» дигән икенче бер шигырьдә автор шул фикерен тагын да ныграк үстерә: капитал һәм акча хакимияте кеше тормышының кадерен киметә, аның тәнен һәм җанын сату-сатылу объекты итә, дип белдерә. Патша Россиясенең политик строен һәм капиталистик мөнәсәбәтләрне гаепләгән әсәрләр Н. Думавиның бу китабында һәм, гомумән, иҗатында шактый урын били. Шагыйрь иҗтимагый стройны тулаем гаепләү белән генә канәгатьләнми, аның максаты — үз халкын, татар милләтен бәхетле итеп күрү. Европаның алдынгы халыклары кебек үсештә итеп күрү. Ә моның өчен иң беренче чиратта актив эшчәнлек һәм көрәш соралганын яхшы белә шагыйрь. «Иҗтиһад», «Тырышмак», «Ник йоклыйсың син, агай» һ. б. байтак шигырьләрнең эчтәлеге әнә шул хакта сөйли.

Ул чорда үсешне тоткарлаучы иҗтимагый тәртипләр Г. Тукай белән Ф. Әмирхан һәм башка алдынгы фикерле иҗатчылар әсәрләрендә дә тәнкыйть ителә. Искелеккә каршы көрәш кирәклеге дә актив рәвештә раслана. Н. Думавиның да күп кенә әсәрләре алар фикеренә авазадаш. Бигрәк тә «Иделгә» һәм «Күңел белән бәдән» шигырьләрен күрсәтергә була. Ләкин, яшәп килүче җәмгыятькә карата байтак кына тәнкыйть фикерләре булса да, иҗтимагый үзгәртеп кору мәсьәләсенә килгәндә шагыйрь әле мәгърифәтчелек карашларында тора. Милләт алдындагы мөһим мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләгәндә исә XIX гасырда яшәгән мәгърифәтче галим Шиһабетдин Мәрҗани образы аның өчен юл күрсәтүче маяк булып хезмәт итә. Рухи остазына багышлап, шагыйрь «Шиһабетдин Мәрҗани кабере янында» дигән шигырь дә яза.

Бүтән мәгърифәтчеләр кебек үк, Н. Думави да кешенең акылына һәм белеменә дан җырлый. Укыган кеше җәмгыятьнең кысан шартларында да үзен иркле сизә алачак, азатлык идеалларыннан үзенә көч табачак. Иң куркыныч төрмә — таш капчык түгел, ә наданлык, караңгылык. Халыкның начар хәле турында борчылмау, уйланмау — шулай ук коллык галәмәте.

Бу хакта шагыйрь «Гафильнең» дип аталган шигырендә җитди сүз алып бара. Биредә татар халкын изеп торучы деспотлык һәм караңгылык кискен гаепләнә.

Караңгылыктан һәм артталыктан чыгу юллары турында уйлану шагыйрьне кабат-кабат шуңа алып килә: моның өчен татар халкының заман культурасына һәм заманча белемгә ия булуы сорала. «Бер вәлидәнең балаларга нәсихәте», «Карлыгачның балаларга әйткән сүзләре» дигән әсәрләр укучыга нәкъ әнә шул фикерне сеңдерә. Ләкин биредә дә, аң-белем кирәклеге турында сүз алып барганда, шагыйрь тормыш чынбарлыгыннан аерылмый. Ул чорның мәктәп-мәдрәсәләрендәге реаль хәлне дөрес аңлый. Кадими мәдрәсәләрне «Кемнәр ничек», «Иске мәдрәсә җимеше», «Мулла булам, мулла булам», «Сихерле тамчылар» әсәрләрендә тәнкыйть утына тота. Кайбер әсәрләрендә исә шагыйрь татарның белем бирү системасын камилләштерү, аны тормышка ныграк якынайту турында уйлана. Чорның, милләтнең рухи һәм гамәли ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә мәктәп һәм мәдрәсәләрне мөһим бер баскыч итеп саный. Дөнья культурасының алдынгы сафлары белән тигезләшү юлында шагыйрь милләт улларына берләшү кирәклеген дә искәртә.

Н. Думави иҗатын бәяләүдә төрле тенденцияләр яши һәм бер-берсенә каршы килүче фикерләр әйтелә. Ә элеккерәк елларда исә бу иҗат тулысынча кара төстә генә яктыртыла иде. Кайбер тикшеренүчеләр шагыйрь язганнарны халыкка каршы эш дип күрсәтергә тырыштылар.

Әлбәттә, Н. Думави иҗатының үзендә дә каршылыклы урыннар бар. Бу аның дөньяга карашы шундый булу белән һәм шагыйрьнең шәхси язмышының борылышлары белән аңлатыла. Чөнки 1905-07 еллар революциясен зур өметләр һәм куаныч белән каршылаган Н. Думави реакция чорын бик авыр кичерә, еш кына күңел төшенкелегенә бирелә. Аның бу чорда язылган әсәрләрендә ышаныч югалу һәм өметсезлек авазлары да мул яңгырый. 1908-10 елларда язылган әсәрләрдән, мәсәлән, «Яз үтеп, җәйнең башы...», «Дөньяга ачык хат», «Мәхбүс. Дөньяда төннәр узып...», «Себер төрмәсендә тәрәзә рәшәткәсенә кунган кошны күреп...», «Юану», «Бу да бер киңәш»ләрдә андый мотив көчле чагыла. Хәтта әле мондый күңел төшенкелеге бераз соңрак язылган шигырьләрдә дә күренә. («Караңгы, кап-кара болыт» — 1908 ел, «Мотлак фарыз, мотлак фарыз» — 1912 ел, «Үтә яшьлек» — 1913 ел һ. б.) Әсәрләрнең кайберләрендә чынбарлыктан качарга тырышу мотивлары да чагыла.

Ләкин шагыйрь үз күңелен биләп алган мондый халәттән котылырга тырыша, тирән рухи эзләнүләр белән яши. Шул чорда марксистик әдәбият һәм Ленин хезмәтләре белән танышу аңа терәлештән чыгу юлын табарга булыша. 1911 елда төрмәдә утырган чагында ул К. Маркстың экономик теориясе белән таныша һәм Г. В. Плеханов хезмәтләрен укый. Ләкин вак буржуа даирәсеннән чыккан шагыйрь бу тәгълиматны барыбер тулысынча кабул итә алмый.

Үзенә рухи маяк эзләп, шагыйрь дөнья әдәбияты классикларын һәм рус язучылары әсәрләрен укый, көнбатыш илләрен биләгән фәлсәфи агымнар белән мавыга. Аның әсәрләрендә еш кына очраган Н. Гоголь, А. Пушкин, М. Лермонтов, Ф. Достоевский, А. Чехов, Л. Андреев һәм башкаларның исемнәре әнә шул хакта сөйли. Шулай ук аңа Л. Толстой белән М. Горькийның да билгеле бер тәэсире була. «Дөнья кайчан ислак булыр?» һ. б. әсәрләре шуңа мисал. Үткән чор фикер ияләреннән шагыйрьгә Сократ, Бэкон, Локк, Декарт, Руссо, Кант, Дарвин өйрәтмәләре дә якын һәм таныш була. Дөрес юл эзләп, ул Шопенгауэр белән Ницше фәлсәфәләренә дә мөрәҗәгать итә. Ләкин шагыйрь боларның берсеннән генә дә үзенең рухи канәгать тулы җаваплар таба алмый. Ул икеләнү һәм шик тулы эзләнүләрен дәвам итә. Бу китапта урын алган «Серле тамчылар» хикәясе сыман әсәрләр шундый рухи эзләнүләр нәтиҗәсе булып тора.

Иҗатының башлангыч чорында Н. Думави да, замандашлары Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан кебек, кадими рухтагы мөселман руханиларын кискен рәвештә тәнкыйтьләп чыга. Аларның дин турында кайгыртмауларын, ә үз мәнфәгатьләрен генә алга сөрүләрен камчылый. Биредә сүз бара торган китапта әнә шундый эчтәлектәге «Вөҗдан», «Хөррият булмаса», «Ишан» һ. б. шигырьләр бар. Ләкин шунысы игътибарга лаек: беренче рус революциясе җиңелеп, илдә реакция чоры башлангач, шагыйрь иҗатында шактый сизелерлек борылыш була. Ул элекке позицияләреннән китеп, алла һәм кеше тәкъдире, язмыш хакында дини уйлануларга якыная. «Мәэюскә», «Коръән», «Үзгәрү», «Сәҗдә» һәм «Җир кортлары» дигән шигырьләрне әнә шулар рәтенә кертергә мөмкин. Шул ук вакытта шагыйрь андый уйлар кысасыннан чыгу кирәклеге хакында да шактый нык уйлана. 1912 елда язылган «Газраил яки оҗмах көткәндә» шикелле әсәрләрендә инде ул үзенең элеккеге антиклерикаль идеяләренә кайтып төшә дияргә була. «Хәзерге заман» белән «Газраил»дә бу тенденция тагын да көчләрәк.

Н. Думавиның иҗади мирасында кеше проблемасы төп урыннарның берсен алып тора. Ләкин әлеге проблеманың иң мөһим өлеше — кеше белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсе шагыйрь иҗатында үзенә дөрес чишелеш таба алмый. Н. Думави өчен кеше шәхесе үзе генә, ялгызы гына яши. Иҗтимагый тормышның стихияле көчләренә каршы кеше бер ялгызы гына каршы тора. Кешене адым саен явызлык, гаделсезлек сагалый. Ләкин алар барысы да иҗтимагый мөнәсәбәтләр җимеше итеп түгел, ә аерым-аерым кешеләрнең аерым эш-хәрәкәтләре итеп карала. Мисал өчен 1912 елда язылган «Кем гаепле?» хикәясен алыйк. Әсәрнең төп образы итеп тасвирланган Нәгыймә — көчле рухлы һәм тормыш, яшәү турында ныклы үз фикере булган кеше. Ләкин әхлакый бозык бер кеше тарафыннан аңа карата ясалган әшәкелек Нәгыймәнең бөтен тормышын боза. Әле тагын шунысы бик мөһим: үзенә килгән бәла белән Нәгыймә бер ялгызы кала. Тора-бара үз язмышын бозган кешедән үч алырга карар кыла. Ул аңа күңеленнән үлем карары чыгара. Һәм үзе үк моны чынга да ашыра.

Зур тормыш күренешләре арасында кешене ялгыз итеп тасвирлау «Мортый илә Мукәй» хикәясендә дә күзгә бәрелә. Бу инде индивидуализм фәлсәфәсен алга сөрү. «Яшь күңелгә» шигыре андый нәтиҗәне тагын бер кат раслый. «Җир йөзендәге тәртипләрне кешелеклерәк итү турында хыяллану — буш хыял», — ди төсле безгә шагыйрь. Кеше бары тик үзенең холкын, табигатен үзгәртү турында гына уйлый ала. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: шагыйрьнең моңа охшаш фикерләре элеккерәк еллар иҗатында да күзгә ташлана иде. Мәсәлән, 1906 елда язылган «Вөҗдан» шигырендә шагыйрь шундыйрак фикер үткәрә — кеше иҗтимагый тормыш кануннары буенча яшәргә тиеш түгел, аңа үз вөҗданы юнәлеш күрсәтергә тиеш.

Н. Думавиның нык ышануынча, вөҗдан — кешенең бердәнбер хакиме һәм юл күрсәтүчесе, рухи юлдашы. Менә мондый уйлары шагыйрьне тора-бара Лев Толстой идеяләренә алып килә. Ягъни, дөньяны камилләштерү өчен иң элек кешенең үзен яхшыртырга кирәк, дигән фикергә. Думавиның андый уйлары 1912 елда язылган «Дөнья кайчан ислах булыр?» исемле шигырьдә ачык чагыла.

Унынчы еллардагы Н. Думави иҗатына күз салсак, без анда романтизм агымының нык кына көчәеп китүен күрербез. Бу чорда шагыйрьнең «Юкка үлде», «Алла тигезли», «Болгар кызы Тойгы туташ» дигән романтик рухлы шигырьләре языла. Ул елларның байтак кына хикәяләре дә шул рухта иҗат ителгәннәр. Шагыйрь ул чорда үз халкының үткәнен дә күбрәк романтик буяулар аша, романтик төстә күрә. Шәрыкның идеалистик фәлсәфәсендә ул юл күрсәткеч маяк булырдай көч күрә, көнчыгыш халыкларының Чыңгыз хан шикелле шәхесләрен зурлый. Шундый омтылыштагы әсәрләрдән шагыйрьнең «Бер мөляхәзә», «Шәрыктән Гарәпкә мөнәсәбәте белән» һәм «Шәрык даһие» дигән шигырьләрен күрсәтергә мөмкин. Н. Думавиның бу шигырьләрендә алга сөрелгән андый идеяләр үз вакытында Җамал Вәлиди тарафыннан хаклы рәвештә тәнкыйть ителделәр.

Шагыйрьнең дөньяга карашлары системасында кешенең табигать белән мөнәсәбәте аерым урын алып тора. Н. Думави җәмгыятьне камилләштерү, аны яхшы якка үзгәртү ысуллары хакында сүз барганда сыйнфый көрәштә һәм революциядә әллә ни өмет күрми. Халык алдына килеп баскан проблемаларны хәл итү юлларын ул табигатьтә һәм аның кануннарын үзләштерүдә күрә. Ә җәмгыятьтәге тигезсезлекне ничек бетерергә? Шагыйрь уйлавынча, табигать моңа бик яхшы җавап бирә — анда гармония, камиллек. Менә шушындый идеяне раслаучы шигырьләр дип түбәндәгеләрне күрсәтергә була: «Акчарлак» (1913), «Бездә җәйге таң», «Җәйге айлы төн», «Айлы төн» (1914), «Чишмә», «Җәйге төндә» (1915), «Җәйге таң» (1916). Чәчмә әсәрләрдән «Юкка үлде» һәм «Дөнья китабы» хикәяләрендә дә Н. Думави табигатьтәге камиллекне кешелек җәмгыятендәге начарлыкларга каршы куя, ә «Хәрибә» дигән әсәрендә исә гомумән дә кешелек җәмгыятен вакытлы гына бер күренеш дип саный, аннан үзгә буларак, табигатьтәге мәңгелек гүзәллеккә дан җырлый. Кеше табигать кануннарын аңларга һәм шуларны истә тотып эш итәргә тиеш, дигән фәлсәфәне тагын да ныгыта.

Үз иҗатында кеше проблемасын язганда Н. Думави антропологик фәлсәфәгә тартым фикерләр үткәрә. Әлбәттә, табигать матурлыгын гына алга сөргәндә, аңа гына табынып яшәгәндә моның шулай буласы алдан ук билгеле иде. Үзенең байтак кына әсәрләрендә шагыйрь табигый мәхәббәт тойгысын бик югары күтәрә, аны кешеләргә яктылык һәм яшәү чыганагы бирүче буларак данлый, мәхәббәтне тормыш пычрагыннан азат булган илаһи бер башлангыч итеп күрә. 1914-16 елларда язылган «Мәхәббәт», «Син кая, әй, син кая...» һәм «Шәркыям» әсәрләре әнә шуның гүзәл үрнәкләре.

Табигый гармониягә һәм кешедәге табигый башлангычларга, әлбәттә, татар демократик культурасының башка әһелләре дә зур әһәмият бирәләр иде. Ләкин Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм М. Гафури кебек әдипләр, шагыйрьләр бу мөнәсәбәттә ары таба китеп, үзләренең карашларын социаль күренешләргә таба юнәлтәләр һәм революцион-демократик нәтиҗәләргә киләләр.

Н. Думави исә еш кына очракларда көчле шәхесне данлауга, индивидуализмга һәм иррационализмга килеп чыга. Бу яктан караганда аның «Хакыйкать эзләгәндә» исемле хикәясе кызыклы. (Әлеге хикәя инглиз язучысының әсәре нигезендә иҗат ителгән). Әсәр герое итеп алынган егет танышлары белән конфликтка керә дә, алар тарафыннан эзәрлекләнә башлагач, гаиләсе белән бергә джунглига кача, шунда яши башлый. Ул кыргый шартларда яшәп, табигый гармониягә ирешеп, үз күңеленә канәгатьләнү һәм тынычлык таба. Н. Думави уйлавынча да шулай: табигать белән дус һәм тату яшәү — кеше өчен иң зур бәхет. Һәм хакыйкатьне дә бары тик табигатьтән генә эзләргә кирәк. Кешеләр арасында дөреслек юк. Анда бирәүләр икенчеләр өстеннән хакимлек итә, кеше һәм бөтен нәрсә сатыла. Анда уйлап чыгарылган абруйларга сукырларча ышану яши һәм бүтән төрле җитешсезлекләр күп. Шуның өчен тормыш дөреслегенә бары тик табигатьтән генә өйрәнергә мөмкин. Ләкин табигать серенә акыл белән дә, хисләр аша да ирешеп булмый. Хисләр безне алдый, ә акылга субъектив хаталанулар хас. Һәр кеше үзенә ошаган әйберне генә дөрес дип санарга күнеккән... Шулай итеп, Н. Думави иррационализм ясссылыгына килеп чыга. Кеше үзенең әйләнә-тирәсен интуитив рәвештә генә тоярга мөмкин, дигән фикергә килә. Аның уйлавынча, кеше аңына һәм акылына буйсынмый торган көчләр генә хакыйкатькә таба алып бара ала, бирәдә кешенең пычранмаган эчке дөньясы, тойгылары гына ярдәм итә ала. «Алла тигезли» дигән хикәясендә Н. Думави иррациональ көчләрне явызлык тудыруда төп гаепле итеп аңлата. Янәсе, кешеләргә бөтен бәхетсезлекне алар алып килә... Шундый карашлар әдипнең мәкаләләрендә дә алга сөрелә.

Н. Думави иҗатын шушы кыска гына мәкалә аша күзалларга тырышканда да

аның катлаулы һәм каршылыклы иҗат юлы, эзләнүләрендәге фәлсәфи һәм эстетик борылышлар ачык гәүдәләнә. Аның карашларына тотрыклык һәм эзлеклелек җитми. Бу Н. Думавиның вак буржуаз демократка хас карашларыннан килеп чыга. Ләкин, шул ук вакытта, мондый хәл татар милләтенең үзенең ул чактагы халәте белән дә аңлатыла иде. Беренче революция нәтиҗәсендә әле генә уянган халык массалары арасында рухи һәм фәлсәфи эзләнү юллары туры гына булмаган кешеләрнең күплеге гаҗәп түгел. Н. Думави да әнә шундый эзләнүчеләрнең берсе иде.

Ләкин, иҗади юлы ничек кенә катлаулы һәм каршылыклы булмасын, Н. Думави халкы белән һәрчак бергә атлады, үз әсәрләрендә аның уйларын һәм хис-кичерешләрен чагылдырды. Н. Думави әсәрләрендә без авыр хәлдә яшәүче хезмәт кешесенең аһзар авазын да, яшәп килгән тәртипләрне кире кагуны да, караңгылыкка һәм арттапыкка каршы чыгуны да күрәбез. Икенче төрле итеп әйткәндә, аның иҗади эзләнүләре һәм рухи омтылышлары татар халкының социаль һәм милли изүдән котылырга теләү омтылышлары белән тәңгәл килә иде. Бу — халыкның һәм аның бер улының алдынгы халыклар, культура ягыннан югары үскән милләтләр белән тигезләшергә теләве иде. Экономикада, фәндә һәм культурада алар белән бер сафка басарга теләү иде бу.

Н. Думави үз халкының бәхетле киләчәгенә ышанып иҗат итә. Аның бу ышанычы 1906 елда язылган «Замана хәле шулай» һәм «Китәчәк иске дөньяга яңа дөньяның сүзләре» шигырьләрендә генә түгел, ә соңгы елларда язылган, хәтта күңел төшенкелеге чорында язылган әсәрләрендә дә чагыла. 1915 елда иҗат ителгән «Әкрен-әкрен сүнә кичке шәфәкъ» шигырендә ул мәсьәләне болай ди:

*Күпкә бармас тарлык, сабыр ит, җан!*
*Ләгънәт орма, бизмә дөньядан!*
*Уйнар күктә матур энҗе-мәрҗән,*
*Калкып чыгар матур тулган ай!*
*Шунда инде менә бетте коллык*
*Күзе ачык һәрбер җаннарга;*
*Әтраф ачык, чиксез киң бер тынлык —*
*Ник очмыйсың әллә кайларга!..*

1915 һәм 1916 елларда басылып чыккан «Җәйге айлы таң» шигырендә дә шуңа тартым оптимистик аһәңнәр яңгырый.

Әйе, Н. Думавиның иҗат юлы сикәлтәле була. Ләкин берничә сикәлтә дә, төкә борылыш та аны кешегә ышанудан, аның рухи көченә инанудан ваз кичтерә алмый. Үзенең иҗади юл башында ул кешегә һәм аның көченә дан җырлаудан, аның мөмкинлекләренә сокланудан башлаган булса, бу ышанычын ул гомер ахырына кадәр саклап калды. Хәтта шагыйрь өчен иң авыр булган 1914 һәм 1915 елларда иҗат ителгән «Тормыш һәм мәхәббәт» белән «Бир яшен — тел, әй фәләк!» шигырьләрендә дә шагыйрь һаман да кешегә ышана, аның бетмәс-төкәнмәс көч чыганагына ия булуын әйтә. 1916 елда Н. Думави хәтта турыдан-туры «Син кеше» дип исемләнгән шигырь дә иҗат итә.

*Бирмә серне, бул гали — типсен йөрәк зурлык белән!*
*Булма мәхзун — сынма төшенкелек белән, хурлык белән!*

*Бирмә тезгенне кара көчләргә — булма кол кеше!*
*Бул — батыр! Бул — нык кеше! Бул — ир кеше! Бул — хөр кеше!*

*Син беләмсең синдә күпме көч барын, куәт барын?*
*Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!*

*Син — бөек! Салган ходай күктән сиңа үз орлыгын.*
*Бул — гали! Таптама зинһар шул «ходайлык» зурлыгын!*

Үзе дә рус-япон сугышында һәм империалистик сугышта катнашкан Н. Думави андый явызлык күренешләрен җаны-тәне белән кабул итә алмый, сугышны кара көчләр ихтыяры дип саный. 1908 елда язылган «Сугыш» шигырендә шагыйрь сугышны — халык өчен кан һәм үлем, ә армиядәге түрәләр өчен дан һәм дәрәҗә алу чарасы дип бара. Шул ук вакытта Н. Думави сугышны алла һәм дин исеме белән акларга теләгән поплар һәм муллалардан ачы көлә. Кешелекнең бер өлешен юк итәргә чакыручы «фәнни» теорияләргә дә гуманист шагыйрь каршы чыга. 1916 елда язылган «Агач аяк» хикәясе кешене рухи һәм физик гарипләндерүче, юк итүче сугышка көчле нәфрәт белән сугарылган. Шул ук елны язылган «Сугыш тәэссораты» шигырендә исә яу кырында ныклыкка, кыюлыкка чакыручы юллар да бар. Бер үк вакытта әсәрдә сугышларның

мәгънәсез кан кою икәнлеге дә ачык һәм тәэсирле итеп әйтеп бирелә. Чөнки анда бер гаепсез кешеләрнең җаны кырыла, каны коела.

*Кычкырмачы, карга, баш янымда,*
*Китче, зинһар, миннән арырак!*
*Күрмисеңме канны як-ягымда,*
*Куллар мәҗрух, тездән юк аяк?*

Н. Думави иҗаты яңа чор татар әдәби телен үстерүдә дә зур роль уйный. Билгеле булганча, бу эшкә узган XIX гасырда Габделҗаббар Кандалый мөһим өлеш керткән иде. Һәркем аңлый ала торган телдә язылган шигъри әсәрләр ул чорда татар шигъриятен чынбарлыкка якынайттылар. Аннан соңгы чорда әлеге тенденция К. Насыйри, Г. Ильяси, Ф. Халиди иҗатлары аша тагын да үстерелде. Ә инде XX гасыр башында халык шагыйре Габдулла Тукай иҗаты белән бу юлда яңа һәм зур адым ясала. Аның чордашлары Г. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларның да әлеге процесстагы өлеше әйтеп бетергесез зур. Бирәдә С. Рәмиев, Ш. Камал, Ш. Мөхәммәдев исемнәрен дә онытa алмыйбыз.

Хәзер без тикшерә торган шагыйрь дә үз иҗаты белән татар әдәби телен формалаштыруда, аны халыкның тормышчан сөйләм чынбарлыгына якынайтуда зур эш башкарды. Әлбәттә, Н. Думави әсәрләрендә кайчак җирле сөйләш үрнәкләре очрый, ләкин тулаем алганда алар XX гасыр башында әдәби норма буларак кабул ителгән һәм хәзер дә кулланылышта булган телдә язылганнар.

Үзенең иҗат юлындагы һәм язмышындагы күп төрле борылмалар аша булса да Н. Думави совет чынбарлыгын тануга килә алды. Иҗатының бөтен тамырлары аша гади халык белән нык бәйләнештә яшәгән һәм язган шагыйрь язмышы, әлбәттә, бүтәнчә була да алмый иде. Чөнки ул моңа кадәр гел халык бәхете хакында хыялланып яшәде, аның иң якты уйлары шул булды.

Революциядән соң 1917-1921 елларда Н. Думави Чистай шәһәрендәге мәктәптә балалар укыта, өяз мәгариф бүлегендә инспектор булып эшли, «Берлек» газетасында хезмәттәшлек итә. Ачлык елларында шагыйрь ачыгучыларга ярдәм оештыру белән шөгыльләнә. Халык кичерә торган бу фаҗига турында ул газеталарда шигырьләр бастыра. Әлеге чорда язылган әсәрләрнең кайберләре бу китапка да кертелгән. Шигырьләр халыкны күңел төшермәскә өнди, бәланең тиздән үтәчәгенә ышандыра. Гомеренең соңгы чорында да Н. Думави җәмәгать эшләрендә катнаша, яшьләрне рабфакларга әзерләүдә һәм наданлыкны бетерү курсларында эшли.

Шагыйрьнең совет чоры иҗатын күзаллау өчен 1923 елда «Безнең юл» журналында басылган «Кеше» дигән нәсер кызыклы. Н. Думави анда кыю, горур һәм көчле кеше образын тудыра. Бу — күп киртәләр, кыенлыклар аша үзенең якты киләчәгенә бара торган шәхес. 1928 елда шагыйрь «Соңгы манара» исемле шигырь дә бастыра. Бирәдә манара образы аша иске дөньяның җимерелүе тасвир ителә.

1927 елдан алып үзенең вафатына кадәр (1933) Н. Думави Үзбәкстанда яши, культура-агарту эше алып бара. 1929 елда Казанда «Хәзерге татар руханилары һәм аларның эшләре» дигән китап бастыра. Шулай ук Үзбәкстанда чыккан атеистик журналда мәкаләләр белән катнаша.

Егерменче гасыр башында яшәп иҗат иткән әдипләрнең мирасын халыкка, укучыларга җиткерү буенча Татарстан китап нәшрияты, әлбәттә, яхшы эшли. Н. Думави әсәрләре белән дә без бик шатланып таныштык. Ләкин, шул ук вакытта, әдипнең әлеге китапка керми калган әсәрләренең шактый икәнлеген дә әйтергә туры килә. Кайбер шигырь һәм хикәяләрнең яңа китапка кермәве исә әдипнең иҗади эзләнүләр юлын тулы күзалларга комачаулый. Н. Думави иҗатында эстетик һәм социаль-фәлсәфи каршылыкларны, аларның чын табигатен аңлау да авырлаша. Игътибарга лаек булып та, басылмаган әсәрләр рәтенә «Хаклык эзләгәндә» дигән хикәяне, шулай ук «Кизел», «Без нишлибез» h. б. исемнәр астында дөнья күргән публицистик мәкаләләрне кертергә мөмкин. Алар беренче революция чорында татар милләте алдына килеп баскан иң үткен мәсьәләләргә багышланган. 1911 елда М. Горький җитәкчелегендә нәшер ителгән «Современник» журналында басылып чыккан «Россия татарларының уянуы һәм аларның әдәбияты» дигән мәкалә дә игътибарга лаек. Шулай ук шагыйрьнең 20-30 елларда басылган публицистик һәм фәнни мәкаләләре дә ул чорны тулырак аңларга ярдәм итәрләр иде. Киләчәктә әдипнең әсәрләрен тулы күләмдә бастырып чыгару турында уйларга кирәк.

**Әбрар Кәримуллин,**
филология фәннәре докторы

# АМЕРИКА ТАТАРЛАРЫ ТАРИХЫННАН

Соңгы елларда илдә барган үзгәрешләр — хәбәрдарлык һәм демократиянең торгызыла башлавы — туган телебез һәм милли мәктәбебез, рухи мирасыбыз һәм мәдәниятебез, халкыбызның язмышы һәм киләчәге турында иркенләп сүз алып барырга юл ачты. Халкыбызның килеп чыгышы, аның этник һәм гражданлык тарихы белән кызыксынуга да этәргеч ясады. Татарстаннан читтәге республика һәм өлкәләрдә яшәүче милләттәшләребезнең теле, мәктәбе, мәгарифе катастрофик хәлгә барып җитүен күрсәтте, аларга ярдәм итү юлларын көн тәртибенә китереп бастырды. Илдә барган үзгәртеп коруның шифалы җилләре халкыбыз язмышының моңа хәтле шактый четерекле саналган мәсьәләләре турында да ачыграк сөйләшергә юл ача башлады. Шул исәптән, төрле тарихи сәбәпләр аркасында чит илләргә таралган милләттәшләребезнең язмышы белән кызыксынуга да игътибар көчәйде.

Дөрес, чит илләрдә яшәүче татарлар турында беренче хәбәрләр моннан 25-30 еллар элек күренгәли башлады. Ул елларда Казан университетында Румыниядән килгән бер төркем румын татарлары укып китте. Шул уңайдан матбугат битләрендә хәбәрләр күренде. Алар артыннан Казанга Бухарест университетының татар теле һәм әдәбияты укытучысы Али Җафар килеп китте. Ул галим генә түгел, оста җырчы да булып чыкты. Аның башкаруындагы румын татарлары җырлары берничә ел татар радиосы дулкыннарында яңгырап алды. Моннан егерме ел чамасы элек Казанга Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир килеп чыкты. Без аннан Финляндиядә меңгә якын татар яшәвен, аларның тормышы, милли мәктәпләре, гореф-гадәтләре турында ишеттек. Шушы вакыттан башлап Финляндиядә яшәүче татарлар белән фәнни, мәдәни элемтәләр урнашты: татар галимнәре һәм артистлары берничә мәртәбә Суоми иленә барып кайттылар, ә фин татарлары Казанга еш килә башлады, татар әдәбияты һәм сәнгатенә багышланган фәнни конференцияләрдә катнашты, ә узган ел бер төркем һәвәскәр артистлар, музыкантлар килеп концертлар куеп китте.

Бу элемтәне үстерү, киңәйтүгә күп көч куйган фольклорчы галимебез И. Надировның мәкаләләре аркылы без фин җирендә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы, сәнгате, мәдәнияте белән шактый таныш инде. Узган ел Финляндиягә барып, язучыбыз Р. Батулла белән университет галиме Җ. Зәйнуллин халкыбызның теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате турында Оривеси институтында укучыларга лекцияләр укып кайттылар.

Соңгы елларда халкыбызның мәгарифе, культурасына багышланган кайбер мәкаләләрдә милләттәшләребезнең башка илләрдә дә яшәве турында искә алына. Дөрес, без татарларның Кытай, Төркиядә яшәүләрен революциягә хәтле чыккан материаллардан да белә идек.

Революциягә хәтле эш эзләп туган җирләрен ташлап киткән татарлар шахталарга күмер чабучы булып Россиянең кайсы гына якларына барып чыкмаганнар. Куркып тормаганнар, татар шахтерлары революциягә хәтле үк инде Франциягә дә барып чыкканнар, аның көньягындагы шахталарда күмер чапканнар. Антанта союзына кергән Россия Франциядә беркадәре гаскәр тоткан. Октябрьдә царизм бәрелеп төшерелгәч, бу армия таркалган, аның шактый өлешен тәшкил иткән татар солдатлары Франциядә тупланеп калганнар. Утызынчы елларның ахырында аларның күп өлеше Франциядә шахталарда эшли, бер өлеше крестьян эше белән шөгыльләнә. Алар бер-беренә булышып, бергә оешып яшәргә тырышканнар. Аларның язмышы Казан университеты профессоры М. Корбутны да кызыксындырган.

Соңгы елларда басылган материаллар арасында татарларның АКШ, Канада, Австралия, Бразилия, Корея, Португалия, ГФР, Япониядә яшәүләре турында искә алына. Әгәр без Кы-

тай, Төркия, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез турында шактый гына хәбәрдар булсак та, ә менә искә алынган илләрдәге татарлар турында мәгълүматларыбыз гаять аз һәм сай. Әйтик, менә Бразилия, Канада, ГФР, Португалия, Австралиядә күпме татар яши, алар анда кайчан килеп чыкканнар, ничек яшиләр — аларның теле, культурасы турында без бер нәрсә дә белмибез диярлек. Мондый очракта, фәлән илдә, төгән җирдә дә татарлар яши, дип сөйләп торуның кызыгы каламы соң? Татарлар Дания, Швеция, Норвегия, Кения, Австрия, Алжир, Израиль, Италия, Согуд Гарәбстаны һәм башка илләрдә дә очрыйлар. Бу һәм башка илләргә барып чыккан берничә татар кешесе бар икән, шуннан чыгып кына, менә татарлар шундый-шундый илләрдә дә яши, дип сөйләп торуның мәгънәсе аз.

Теге яки бу илдә милләттәшләребез яши дип сүз алып бару өчен, миңа калса, ул илләрдәге татарларның саны шактый зур булуы, үзара тыгыз бәйләнештә булып, үзләренең кем икәнлекләрен нык аңлап, тел, моң, мәдәният турында кайгыртып яшәүләре кирәк дип саныйм. Әйтик, Бразилиядә бер татар кешесенең ит эшкәртү заводы тотуыннан, бер татар кызының Согуд Гарәбстанындагы бер гарәпкә кияүгә чыгып анда күчеп китүенә карап кына бу илләрдә татарлар яши, дип сүз куйгату урынсыз.

Мине инде күптән кайда, кайсы илләрдә татарлар яшәве, аларның язмышы кызыксындырып килә. Бөек Ватан сугышы елларында Румыниядә вакытта бер татар авылында булганым бар. Венгриягә барып чыккач, татар сүзен исем итеп алган Сакал, Чишмә, Алма атлары кебек хутор һәм авылларны күрдем. «Бу венгр авыллары ничек итеп татарча аталган?» диген сорау миңа озак еллар тынгылык бирмәде. Япон милитаристларына каршы сугышта Кытайның Харбин шәһәрендә мәчет күреп шаккаткан идем. Мәчетне саклаучы бер татар картын очратып сораша торгач, бередә күп кенә татарларның яшәвен, мәктәпләре булуын белдем. Инде сугыш бетеп, университетны тәмамлап Казан университетының фәнни китапханәсендә эшли башлагач, татар матбугаты битләрен актарганда татарларның Маньчжурия, Синь-цзян, Япониядә яшәүләренә караган мәгълүматларга тап була башладым. Менә шундый хәбәрләр арасында аерым татар кешеләренең Англия, Америкага да барып чыгулары турындагы хәбәрләргә дә юлыктым. Кайларда гына сәүдә итеп, хаҗ кылып, мосафир булып йөрмәгән безнең бабаларыбыз. Төньяк Африка, гарәп илләре, бөтен Азия диярлек алар өчен шактый таныш булган. Европасы да ят булмаган. Ә менә Америкага безнең милләттәшләребез кайчан барып чыкканнар һәм кайчан анда урнаша башлаганнар. Бу турыда мәгълүматлар аз. Һәрхәлдә, XIX йөзнең ахырында һәм XX йөзнең башында безнең бабаларыбыз Америкага сукмак сала башлаганнар дияргә мөмкин. Бу елларда Истанбул, Бәйрут, Каһирә кебек шәрыкъ шәһәрләрендә мөселман яшьләре өчен Америка уку йортлары ачыла башлый. Анда укучылар арасында Идел-Урал буеннан барып чыккан татар яшьләре дә күренгәли. Революциягә хәтле үк матбугатта Америка Кушма Штатларының уку йортларында укучы татар яшьләре турында искә алына, аларның бер өлеше әнә шул шәрыкъ шәһәрләрендә укый башлаган яшьләр булуы мөмкин. XX йөз башында татар яшьләренең Германия, Франция, Япония югары уку йортларына барып укырга керүләре ачык билгеле. Шулай булгач, белем алу өчен аларның Америкага махсус барып чыгучылары да булган дип уйлый алабыз. Миңа калса, татарларның Америкага күчеп урнашуы XX йөз башларында көчәя булса кирәк. Шушы фикерне куәтләп, бер хәлне искә алып үтмәкче булам. 1965 елны тарихчы Миркасыйм Госманов белән Рязань өлкәсенең Касыйм районы татар авылларында археографик экспедиция вакытында бер кызык хәлгә тап булдык. Шушы районның Ширин авылында канцелярия каравылчысы белән төн буе сөйләшеп утырдык. (Ул кешенең исемен онытканмын, Ватан сугышыннан аягын калдырып кайткан инвалид татар иде). Мин шунда революциягә хәтле бу яктагы татарларның сәүдә белән эш итүләрен, тимер юл рестораннарында эшләүләрен, җәен авылга кайтып иген игүләрен, хәзер инде авылларын ташлап Мәскәү, Ленинград һәм башка шәһәрләргә күчеп китүләрен, шулай итеп, күп кенә татар авылларының юкка чыгуын ишеттем. Сөйләшә торгач бу фронтовик Вашингтонда әтисенең абыйсы торуын, сугыштан соңгы елларда Ибраһим исемле бу туганыннан посылкалар килүен әйтте. Минем бик үк ышанып бетмәүне сизеп булса кирәк, өенә чыгып (йорты канцелярия белән рәттән иде) бер төргәк кәгазьләр алып керде. Бу кәгазьләр арасында Вашингтон почта мөһере һәм Америка маркалары ябыштырылган конвертлар, европача киенгән бизнесмен Ибраһим аганың фоторәсеме, уллары, гаиләсе рәсемнәре бар иде. Ибраһим әфәнденең кибетләре урнашкан һәм кунакханәсе булган 27 катлы небоскреб фотосы да килеп чыкты.

Аннан миңа Ибраһим әфәнденең «одиссея»сен сөйләде. Ул революциягә хәтле авылдан чыгып киткән була, рестораннарда эшли. Ул вакытта Россия составында булган Польшага барып чыга, Варшавада татар кызына гашыйк булып, шуңа өйләнә. Кызның әтисе ярдәмендә Ибраһим Варшавадагы бер тимер юл ресторанының хуҗасына әйләнә. Революциядән соң Польша мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыккач, Польша өчен авыр бу елларда күп кенә поляклар Америкага күчеп китәләр. Алар арасында Ибраһим да була. Америкага барып чыккач алар ниләр күргәндер, анысын Ибраһимның Ширин авылында яшәүче туганы белми иде...

1917 елгы революцияләр һәм гражданнар сугышы бәхет эзләп Россиянең төрле төбәкләренә таралган татарларның чит илләргә күченүенә шактый зур этәргеч булган. Әйтик, Россиядән аерылып чыккан Эстония, Литва, Латвия, Финляндия, Польшада яшәгән татарлар шул илләрдә калганнар, шул рәвешле чит ил татарына әверелгәннәр. Революциягә хәтле Кытайда, Маньчжуриядә татарлар шактый күп була: сәүдәгәрләр, Кытай-Россия тимер юлы эшчеләре... Колчак армиясе составында чигенгән татар байлары, руханилар, өлешчә татар солдатлары да Маньчжуриядә утырып кала, элек монда яшәгән татар җәмәгатен арттыра. Маньчжуриядә яшәүче татарларның бер өлеше тора-бара Япониягә күчеп утыра башлый. 1904-1905 еллардагы рус-япон сугышында патша армиясе хурлыклы рәвештә җиңелә. Гаскәрнең шактый өлеше әсирлеккә эләгә. Әсирләр арасында татарлар да аз булмый. Әнә шуларның бер өлеше Японияда нигезләнеп кала. 1908 ел ахырында Габдрәшит Ибраһим (1857-1944) дигән бер татар зыялысы һәм җәмәгать эшлеклесенең Японияга барып чыгуы биредә татарларның яшәве белән бәйләнгән. Габдрәшит Ибраһим Кояш чыгыш илендә берничә ай яши, Япониянең премьер-министры Хиробуми Ито, чит илләр эше буенча министр Шигиминобу Окума һәм башка күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән очраша. Габдрәшит казыйның Япониягә килеп чыгуы, аның властьлар тарафыннан яхшы кабул ителүе андагы татарлар тормышы өчен шактый гына уңайлыклар тудыра. Миллионга якын япон кешесе ислам диненә чыга, япон мәктәпләрендә гарәп теле укытыла башлый, Токио, Киото шәһәрләрендә мәчетләр, мәктәпләр ачыла, татар телендә китап басу башлана, концерт кичәләре оештыру активлаша. Биредә яшәүче татарлар Америкада яшәүче милләттәшләре белән элемтәгә керә башлый, алар арасында Америкага күчеп китә башлаучылар да күренә.

Гражданнар сугышы елларында Россиядән аерылып чыккан дәүләтләр составында калган татарларның бер өлеше Төркиягә, Кытайга, Америкага күчеп килә. Менә шундый шартларда бу чит илләрдә Бөек Ватан сугышына хәтле үк татар җәмәгатьләре барлыкка килгән була. Америка татар җәмәгатенең ныклап торып формалашуы икенче бөтендөнья сугышыннан соң башлана диярга мөмкин. Америкага татарларның күчеп утырулары бу чорда төрле юллар белән бара.

Бөек Ватан сугышыннан соң безгә япон милитаристлары белән сугышырга туры килде. Шушы сугыштан соң Кытай территориясе японнардан азат ителде. Кытайда яңа тормыш төзү шартларында бу илдә яшәүче башка халыкларга карата күп кенә гаделсезлекләр эшләнде. Бу гаделсезлекләр Кытайда яшәп килүче татарларны да читләп узмады. Менә шул сәбәпле Кытайның Маньчжурия генә түгел, Синьцзян районнарында яшәүче татарлар да, кытайлаштыру политикасыннан котылу өчен, Кытайны ташлап китә башлый. Аларның бер өлеше СССРга кайтты, калганнары Япония, Төркия, Америка Кушма Штатларына юл тотты. «Америкада этнографик группалар» исемендәге Гарвард университеты чыгарган энциклопедиядә (Кембридж), АКШта яшәүче татарларның 20 проценты Кытайдан күчеп килгән, диелә. Утыз процентын Бөек Ватан сугышы елларында әсирлеккә эләккән солдатлар тәшкил итә. 1960 елда Төркиядә экономик кризис башлана. Монда яшәүче татарлар бу кризис елларында Төркияне ташлап Австралия, АКШ һәм башка илләргә күчә башлый. Менә шул елларда Төркиядән килгән татарлар АКШтагы милләттәшләребезнең яртысын диярлек тәшкил итәләр. 1980 елда чыккан энциклопедиядә Америкага татарларның кайчан күчеп килә башлавы турында бернинди информация юк. Бу энциклопедиядә 1976 елда АКШта 250 гаиләдән торган меңгә якын татар яшәве турында мәгълүмат бар. Хәзер бу санның шактый арта төшүен күрсәтергә кирәк. Хәзер Нью-Йоркта һәм аның тирәләрендә генә яшәүче татарларның саны да бер меңгә якынлаша.

АКШта татарлар, нигездә, ике урында күп урнашкан. Берсе Нью-Йорк төбәгендә, Атлантик океаны буенда, икенчесе — Сан-Франциско шәһәре һәм аның тирәләрендә, Тын океан буенда. Менә шушы ике җирдә татар культура үзәкләре оешкан. Болардан тыш милләттәшләребез Нью-Джерси, Коннектикут, Вашингтон шәһәрләрендә дә яши. Биредә сүз татарлар күбрәк булып яши торган җирләр турында гына бара. 1988 елда АКШта булган вакытта без аерым татар гаиләләрен Детройт, Висконсин, Бостон, Кембридж шәһәрләрендә дә очраттык, АКШның башка шәһәрләрендә яшәүче татарлар да бар, әлбәттә.

АКШта безнең милләттәшләребез кем булып эшли соң? Чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә Америкага күчеп килгән татарлар аякка шактый нык басканнар диярга була. Аларның күпчелеге — врачлар, сәнгать эшлеклеләре, банкирлар, кунакханә хуҗалары, шактый өлеше — сәүдәгәрләр? Арада фән дөньясына керүчеләр дә юк түгел. Кыска гына вакыт эчендә без Көньяк Калифорния институтында тарих профессоры Азад Гайшә Рорлих, Нью-Йорк технология институты профессоры Рифат Таби, Коннектикут университетында тарих укытучысы Шәфика Дәүләт, Висконсин университетының Урал-Алтайны өйрәнү фәнни тарихчысы Юлай Шамил угылы белән таныштык. Башка югары уку йортларында, фәнни оешмаларда эшләүче татар галимнәре барлыгын да беләбез. Америка татар яшьләрен үзебез булган Мэдисон-Висконсин, Бостон, Гарвард университетларында да очраттык.

Нью-Йоркта вакытта без профессор Я. Абдуллин белән биредә эшләп килүче татар җәмгыятенең аерым әгъзалары белән очраштык. Бу очрашу безгә АКШта яшәүче татарлар-

ның тормышы турында шактый нәрсәләрне ачыкларга мөмкинлек бирде. Нью-Йорктагы татар җәмгыяте һәр елның апрель аенда Габдулла Тукайның туган көне уңае белән бәйрәм кичәсе оештыра икән. Анда Тукайның тормышы, иҗаты турында доклад, халкыбызның тарихы, культурасы турында лекцияләр укыла, һәр бәйрәмдә татарча концерт куела, җыр-биюләр оештырыла, кичә татар аш-сулары белән дәвам итә. Бу җәмгыятьнең Нью-Йоркта (Манхеттинда) аерым заллары бар. Тукай кичәләре белән рәттән анда гает, рамазан, корбан бәйрәмнәре дә билгеләнеп үтелә. Бу мәҗлесләргә, кичә һәм концертларга олысы-кечесе бик теләп йөри. Бу җәмгыять каршында дини эшләр, яшьләр белән эшләү, хатын-кызлар, чит илләрдәге милләттәшләр белән элемтә комиссияләре бар. Җәмгыять Төркия, Австралия, Финляндия, Япониядәге татарлар белән тыгыз элемтә тота, бер-берләренә барып килеп йөриләр. Күптән түгел алар бер төркем булып Японияга барганнар, анда Татарстан Җыр һәм бию ансамбле концертларын карап, видеомагнитофоннарга язып алып кайтканнар. 1988 елда Финляндиядә яшәүче татарлар белән Казанга килеп атна-ун көн кунак булып, татар театры, концертларын карап, милләттәшләре белән аралашып, китап, татарча пластинкалар алып кайтып киттеләр.

Җәй айларында Нью-Йоркның көньягында, Атлантик океан дулкыннары шаулап торган яр буендагы зур, матур бер болында, ай саен татарларның җыен кебек бәйрәмнәре һәм Сабантуе үткәрелә. Балалары белән машиналарга төялеп, Нью-Йорк һәм аның тирәсендә яшәүче татарлар бергә ял итәргә киләләр. һәр очрашу төрле уеннар, җыр-бию, концертлар белән дәвам итә: өлкәннәр төрле мәсьәләләр турында киңәшләшә, балалар төрле уеннар уйный, яшьләр танышa, аралаша, уйный, бии, җырлый.

Америкада яшәүче татарлардан якынча 90 процентының хатыннары — Казан,Идел буе татар хатын-кызлары, өлешчә төрек, литва татарлары хатын-кызлары. Калган ун проценты — рус, немец милләтеннән. Америкадагы милләттәшләребезнең балалары инглиз телендәге мәктәпләрдә укый. Шул ук вакытта ата-аналар балаларны туган телгә, халыкның җыр-моңына, мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләүгә зур игътибар бирәләр. Җәй көне үткәрелә торган Сабантуе, җыен кебек бәйрәм-очрашулардан тыш, балалар өчен атна саен бәйрәм кебек очрашулар үткәрелә. Анда аларны җырларга, биергә, төрле уеннарга өйрәтәләр. Бу эш белән аерым кешеләр — тәрбияче укытучылар шөгыльләнә.

Бирeдә аларга әкиятләр укыйлар, шигырьләр өйрәтәләр —— барлык уеннар, җырлар, сөйләшүләр туган телдә алып барыла. Бу эшләрне алып бару өчен укытучыларны ата-аналар үз хисабыннан яллый. Бу үзенә күрә атнага бер үткәрелә торган балалар бакчасын хәтерләтә. 1950 елдан алып 60 елларның башына хәтле Нью-Йоркта татар мәктәбе дә эшләп килә, хәзер аны менә шундый кичәләр, клублар, сабантуйлары, җыеннар алыштыра. 1960 елдан башлап Америка татарлары латин графикасы нигезендә «Америка татар җәмгыяте бюллетене» дигән журнал чыгара. Аның битләрендә Америкада яшәүче милләттәшләребез тормыш кирәк-ярагына кагылышлы материаллар, киңәшләрен бастыралар. Алар өчен бу бюллетень аралашу, хәбәрләшү, киңәшләшү органы булып та тора.

Америка татарлары оешу ягыннан әле аякка басып кына килә. Монда инде татарларның өченче буыны үсә. Культура, мәгариф, өлкәсендә ныклап торып эш алып барырга аларның әле матди хәлләре зур мөмкинлек бирми дип уйлыйм. Әгәр бергә күптән күчеп килеп яшәүче руслар, украинлылар, поляклар, литвалылар, эстоннар үз телләрендә газета чыгара, китап баса, милли мәктәпләр тота, махсус фәнни тикшеренү институтлары ачкан икән, милли мәнфәгатьләрен киң планда алып баралар икән, аларның монда инде зур матди мөмкинлекләре һәм кадрлары бар дигән сүз. Әйтергә кирәк, АКШта яшәүче русларның саны алты миллионнан артык, әле искә алып үтелгән халыклар саны йөзәр меңләп санала. Шуңа күрә аларның милли культура өлкәсендәге эшчәнлеген әле күптән түгел Америкага барып чыккан һәм нибары ике меңне тәшкил иткән татарлар эшчәнлеге белән чагыштыру дөрес булмас иде.

Туган телебезнең илдә абруе түбәнәю, яшьләр арасында туган телне белмәүчеләрнең тиз артуын соңгы елларда безнең үзебезнең туган телгә гамьсезлегебез белән аңлатырга тырышучылар табыла башлады. Янәсе, Америка татарлары чит җирләрдә яшәсәләр дә, әнә, ана телләрен ничек яхшы беләләр, балалары да яхшы белә, бу аларның ата-аналары тырышлыгыннан килә. Янәсе, илебездә татар теленең мондый хәлгә калуына без, татарлар, үзебез генә гаепле, илебездә милли телләрне, культураларны үстерү өчен бөтен мөмкинлекләр бар, имеш. Илебездә милли телебез, милли культурабызның шундый авыр хәлгә килеп җитүен үзебезгә генә бәйләп калдыру, Америка һәм Финляндия татарлары тормышына ишарә ясап «аңлатырга» тырышу урынсыз. Анда да татар яшьләренең бер өлеше инглизләшә, финләшә бара. Моңа шаккатыр урын юк. Анда бит бөтенләй икенче этник мохит. Ә туган илебездә, туган телебезнең казаны булган җирдә телебезне оныту, аңа хөрмәтнең кимүе Америка янсә Финляндиядәге татарлар арасындагыга караганда ун, йөз мәртәбә тизрәк бара. Туган телебезнең, милли культурабыз һәм мәктәпләребезнең мондый авыр хәле өчен татар халкы үзе түгел, ә бәлки социализм исеме астында барган сталинизм политикасының вәхши, канлы милли сәясәте гаепле. Америка татарлары белән чагыштырып татар-

ларның теленә, мәдәниятенә карашын бозып күрсәтү, аларны милли нигилизмда гаепләргә тырышу әнә шул сталинизм политикасының үзгәртеп кору шартларында демагогик юллар белән татарларга яла ягарга тырышу ысулы ул.

Америкада яшәүче татарлар телебезнең язмышы, әдәбият, мәктәп, сәнгатебезнең торышы белән бик тә кызыксыналар. Алар халкыбыз тормышын «Казан утлары», «Азат хатын» журналлары аша белеп, күзәтеп торалар. Төрле юллар белән татар китапларын, татар җырлары язылган пластинкалар алырга тырышалар. Татар әдәбияты, театры, сәнгате турында шактый хәбәрдарлар, күп кенә татар композиторларының җырларын яхшы беләләр. Аларга күп кенә татар артистлары һәм язучыларының исемнәре, әсәрләре таныш. Алар безгә өзелеп-өзелеп татар язучыларын, артистларын күрәселәре, тыңлыйсылары килүе турында сөйләделәр. Мәскәү оешмаларына татар артистларын, язучыларын Америкага чакырып үтенеч бирүләрен әйттеләр. Бар үтенечләр дә җавапсыз калган. Татарстан тормышы, татар мәдәнияте белән тулырак һәм вакытында танышу өчен инде озак еллар Казанда чыга торган газеталарга язылырга тырышалар, ни сәбәптәндер, безнең газеталарга язылa алмыйлар икән. Күрәсең, аларның Бөтенсоюз каталогына кертелмәвеннән киләдер бу нәрсә. Китаплар сатып алу өчен Татарстан китап нәшриятына дә мөрәҗәгать итеп караганнар, аннан да китаплар килмәгән. Менә шундый нәрсәләрне алар бик борчылып сөйләделәр.

Америкада яшәүче милләттәшләребез өзелеп-өзелеп туган җирләрен сагыналар. Әнә шулай тырыша-тырыша очрашулар, җыр-бию кичәләре оештыру, сабан туе һәм җыен кебек бәйрәмнәр, аралашулар үткәрү юлы белән алар туган җиргә, туган телгә, бабалары җиренә булган сагынуларын басарга тырышалар. Инде Америкада үзләренең матди хәлләрен шактый ныгытсалар да, безгә караганда яхшырак яшәсәләр дә, аларның күңелләре китек, аларның йөзендә, җанында илгә булган зур сагыну, сагыш яши. Алар күңелен кан тарта, туган җир, туган халкы тарта. Без аерылышканда бу сагынуларның аларның йөзләрендә ничек тирән чагылуын күрдек, күзләреннән мөлдерәп яшь агардай итеп карауларыннан йөрәгебез тетрәнде. Бу сагышлардан таш та эрер иде, мөгаен.

Америкада яшәүче милләттәшләребезнең хәлләре менә шулайрак. Алар — татар халкының аерылмас бер өлеше. Менә шуннан чыгып, Татар иҗтимагый Үзәге чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәгә керү, алар белән эшләү буенча махсус комиссия төзеде. Бу комиссиянең изге максаты кәгазьдә генә калмасын иде диясе килә.

Америкада безнең милләттәшләребезне Казан яки Идел буе татарлары дип атыйлар. Анда безнең халыкның Идел буенда, Урал якларында яшәвен яхшы беләләр. Безнең халыкның элек болгар исеме астында билгеле булуын да язалар. Америка галимнәре кайсы халыкның кем булуын яхшы беләләр, исем охшашлыгыннан чыгып кына бер этносны икенче этнос белән бутамыйлар. Әйтик, югарыда искә алынган энциклопедиядә Кырым татарлары һәм Литва (Польша, Белоруссия) татарлары турында да языла һәм аларның һәрберсе турында аерым мәкаләләр бирелгән. 1976 елгы мәгълүматлар буенча, Америкада 800 гаилә Кырым татарлары яши. Аларның саны безнең татарлардан 3-4 мәртәбә күбрәк. Үз җәмгыятьләре бар, аның үзәге Нью-Йоркның Бруклин өлешендә урнашкан. «Кырым төрекләренең Америка берлеге» дигән махсус органнары чыга. Кайчандыр Кырым һәм Казан татарлары бер җәмгыять төзегәннәр, ләкин озак та тормый бер-берсеннән аерылып чыкканнар.

Америкада безнең милләттәшләребездән һәм Кырым татарларыннан тыш тагын бер төрле татарлар яши. Аларны Польша яки Литва, яисә Белоруссия татарлары диләр. Кырым татарлары кебек, алар да аерым халык. Һәрхәлдә, Казан татары түгел. Дөрес, үзләренең бик борынгы чыгышлары белән алар Идел буеннан, аның түбән өлешеннән бу якларга килеп чыкканнар. Дөресрәге, Литваның бөек кнәзе Витовт аларны үзенә ярдәмгә чакырган. 1410 елда Тевтон рыцарьларына каршы сугышта бу татарлар литвалыларга зур ярдәм күрсәткән, немец рыцарьларын җиңеп, Витовтка үз иленең мөстәкыйльлеген саклап калуда зур көч, корбан биргәннәр. Шул вакыттан башлап, аларның бу ярдәменә хөрмәт һәм җавап билгесе итеп, бу татарларга Литва җирендә мәңгелеккә урын бирелгән, алар налоглардан азат ителгән. Соңыннан Бөек Литва төрле сәбәпләр аркасында төрле илләргә бүленгәч, аларның бер өлеше Польша, бер өлеше Белоруссия, бер өлеше Литва җирендә кала. Алар әле дә шул илләрдә яшиләр, Белоруссиядәге бу татарларны хәзер белорус милләтенә кертә башладылар.

Литвадан калган татарлар тора-бара телләрен югалталар, поляк, литва, белорус телләрендә сөйләшә башлыйлар. Ә менә диннәрен саклыйлар, бигрәк тә Польшада һәм Литвада. Бирегә аларның мәчетләре дә эшли, гает, корбан бәйрәмнәрен үткәреп киләләр. Аларның бер өлеше инде поляклашып, литвалашып киткән. Бөек поляк язучысы Генрих Сенкевич һәм күренекле поляк җәмәгать эшлеклесе һәм әдибе Леон Кручковскийның чыгышлары — әнә шул татарлардан. Октябрь революциясеннән соң поляк татарларының бер өлеше Идел буйларына килеп чыга, гражданнар сугышында Кызыл Армия командирлары булып катнаша, Татарстан республикасы төзү юлында эш күрсәтә.

Октябрь революциясеннән соң Польша, Россия империясе таркалуы нәтиҗәсендә,

аннан аерылып чыга, бу авыр елларда поляклар АКШка күпләп күчеп китә. Инде югарыда әйтеп үтелгәнчә, алар белән Польша татарларының бер өлеше дә Океан артына күчеп урнаша. Америкада аларның да үз милли җәмгыятьләре бар. Алар Нью-Йорк, Нью-Джерси, Массачусетс, Коннектикут шәһәрләре тирәсендә яши, Флоридада зур булмаган бер колония булып та яшиләр. Поляк татарлары җәмгыяте үз милләттәшләре арасында төрле культура эшләре алып бара, яшьләрне үзләренең милли традицияләрендә тәрбияләүгә зур әһәмият бирә. «Аннур» исемле бюллетень чыгарып килә. Чыгышлары белән татар булган бу халык инде үзенең борынгы этник сыйфатларыннан шактый ераклашкан. Әмма үзенең кан чыгышын барыбер онытмаган. Бу аларның, Америкада яшәүче поляклар белән аралашып яшәүләренә карамастан, Идел-Урал буе татарларына тартылуларында да, үзләренә хатын итеп татар, мөселман кызларына өйләнергә тырышуларында да чагыла.

Без биредә Америкада яшәүче милләттәшләребез турында, нигездә, информацион, күзәтү характерында гына сүз алып барабыз. Аларның Океан артына килеп чыгу тарихы, җирле шартларга җайлашуы, хәяты, мәгарифе, экономик хәле турында, әлбәттә, күбрәк беләсебез килә. Шул исәптән, башка илләрдә яшәүче татарларның тарихы турында кызыксыну да арта. Халкыбызның гражданлык һәм этник тарихына игътибар арта башласа — үзгәртеп кору шартларында ул нәкъ шулай булыр дип ышанасы килә,— бу өлкәдә дә эш активлашыр. Дөнья буйлап таралган милләттәшләребезнең чит илләрдәге хәле, тормышы, язмышы — ул халкыбыз тарихының аерылмас өлеше. Алар тудырган рухи байлык та безнең гомум культурабыз җимешләре булып саналырга тиешле. Без моның шулай икәнен чит илләрдә яшәп иҗат иткән рус язучылары, галимнәре тудырган байлыкка рус халкының ихтирамы, хөрмәте, югары бәя бирүе аркылы да ачык күрә алабыз.

---

## *Бер сорауга бер җавап*

**— Туган әдәбиятыбызның халыкара бәйләнешләрен ныгыту өчен сез нинди эшлисез!**

— 1986-1987 елларда венгр телен, мәдәниятен өйрәнер өчен Будапештта яшәдем, шул дәвердә байтак күренекле венгр язучылары, культура эшлеклеләре белән аралаштым. Табигый ки, сүзебез бик еш кына татар әдәбиятына килеп кагыла иде. Мин аларны мәшһүр шагыйрьләребезнең әсәрләре белән таныштыруга аеруча әһәмият бирдем. Кыска гына вакыт эчендә венгр телен үзләштерүем һәм хәтта шул телдә шигырьләр дә яза башлавым хуҗаларның Татарстан белән кызыксынуын тагын да көчәйтеп җибәрде. Дөрес, Венгриядә, татар дөньясын танып-белергә омтылу элек-электән килә. Вамбери, Балинт һәм башка галимнәр тарихыбызны, фольклорыбызны өйрәнүгә мәгълүм өлеш керткәннәр. Алар эшен хәзер Штефан Мандоки (Коңгыр) кебек яшьләр дәвам итә. Якын арада Будапештның «Европа» нәшрияты «Татар шигърияте антологиясе»н бастырырга әзерләнә. Мин шул җыентыкны төзүдә һәм татарчадан турыдан-туры венгрчага тәрҗемә кылуда катнашам.

Лондон шәһәрендә бүгенге татар әдәбияты һәм публицистикасы җыентыгын чыгаруда да катнашым бар. Бабаларыбызның ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулу тантаналарына Англиядән танылган галимә Мария Броксап ханым килгән иде. Без аның белән булачак китап хакында киңәштек. Шундыйрак эшне ГФРның Франкфурт шәһәрендәге «Дагәле» нәшрияте белән дә тормышка ашырырга җыенам — татар прозасы антологиясен немец теленә турыдан-туры тәрҗемә итәргә вәгъдә бирдем.

Татар телен һәм әдәбиятын башка халыкларга таныту кыюлык, тәвәккәллек, әзләнүчәнлек, туган мәдәниятебезгә бирелгәнлекне сорый. Мин бу җәһәттән бер мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмаска тырышам. ГФРга баргач, «Азатлык» радиостанциясе миңа татарча тапшыруларында катнашырга тәкъдим итте. Риза булдым — Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен, татарчадан тыш, алман (немец), инглиз, испан, мәҗар (венгр), рус телләрендә дә сөйләдем.

Мәскәүнең «Искусство» нәшрияты исә татар суфый шагыйрьләре антологиясен чыгарырга ниятли. Мин шул җыентыкны төзүне һәм тәрҗемә итүне дә өстемә алдым. Бу китапны соңрак чит илләрдә дә бастырырга исәп бар.

**Равил БОХАРАЕВ,**
Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты.

## Габделхак Зәбиров

# АТА САЛИХ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР

*Бу очерк-истәлек һәр яктан игътибарга лаек. Беренчедән, ул — татар һәм төрекмән халкының дуслыгын, хезмәттәшлеген раслаучы дәлил. Икенчедән, бу истәлекләрдәге геройларның берсе — Ата Салих азактан Төрекмәнстанның күренекле шагыйре булып үсеп җитә. Өченчедән, язмаларның авторы Габделхак Гариф улы Зәбиров — хезмәт ветераны, аңа 80 яшь тулып узды инде. Ул 1908 елның 26 августында Татарстанның Биектау районы Әсән авылында крестьян гаиләсендә туган. Егерме беренче елның ачлыгы аны туган-үскән авылыннан Казанга китәргә мәҗбүр итә. 13 яшьлек үсмер Балалар йортына урнаша. Бераздан ул педагогия техникумы интернатына күчерелә. 1923 елны Габделхакның олы абыйсы Габделбәр Зәбиров, Кызыл Армия сафларыннан авылга кайтып, Арча контонында финансист булып эшли башлый, энесен үз тәрбиясенә ала.*

*Габделхак Арчада 1928 елга кадәр яши, Арча мәктәбендә укый. Ә 1928 елны ул, 20 яшьлек егет, Төрекмәнстанга агротехник итеп җибәрелә. Зур һәм катлаулы тормышы шунда башлана Габделхакның. Егерме яшьлек егет өч мәртәбә басмачылар кулына эләгә. Берсендә ул, атарга алып барган чакта, ат өстеннән елгага сикереп котыла. Икенчесендә аны басмачылардан кышлак дехканнары саклап алып кала. Өченче мәртәбәсендә басмачы пычагы аның күкрәгенә кадала. Фаҗигале үлемнән күкрәк кесәсендәге катыргы тышлы блокнот кына коткара.*

*Бу озын гомерендә Габделхак агай Төрекмәнстан, Үзбәкстан һәм Татарстанда күп төрле эшләрдә эшли. Агротехник, укытучы, зоотехник, экономист, колхоз председателе-утызмеңче, райплан председателе... 80 елның 45 елы — Коммунистлар партиясе сафында.*

*Бу агайның, аның гаиләсенең тормышы миңа яхшы таныш. Казанның Зур урамындагы гадәти генә бер йортның ике бүлмәле фатирында ифрат мөлаем табигатьле, кунакчыл хуҗалар — карт белән карчык яши. Габделхак ага белән Камилә җиңги өч бала үстергәннәр. Кызлары Сурия — Казанның Совет районы дәүләт банкында өлкән хисапчы, уртанчы балалары Фоат — Татарстанның эчке эшләр министрлыгында политбүлек инструкторы, офицер; өлкән уллары Марат КамАЗда эшли.*

*Укучыга тәкъдим ителә торган әлеге очерк-истәлекне мин Габделхак Зәбировның Төрекмәнстанда күргән-кичергәннәре хакындагы кулъязма китабыннан алдым. Язма гомумиләштерелгән, Габделхак ага үзе күргәннәрне Зәбир Хикмәтов образы аша тасвирлаган.*

**Гариф АХУНОВ**



1930 елның мартында Зәбир Хикмәтов, ерак юллар узып, Төрекмәнстанның Шортеп участогына агротехник булып килде. Аны Агаҗан агай белән Фатыйма җиңги йортына өйдәш итеп керттеләр.

Авылга беренче аяк басканда мәдрәсә янына җыелып утырган малайларны күрде Зәбир. Мәдрәсә бик борынгы, малайлар бик яшь иде. Алар арасында буй җиткән бер егет тә бар. Өстенә ак күлмәк, ак чалбар кигән, билен пута белән буган, путасының чугы да бар. Аягындагы чәпәге, төшеп калмасын өчен, бау белән бәйләп куелган, ә ул чәпәк, аның табаннары Төрекмәнстанның уттай кызу комташыннан саклый торгандыр, мөгаен. Башында — түбәтәй, ул да кояштан саклану өчен. Матур гына җәлпәк борынлы, көлгән чакта ап-ак тап-таза тешләре балкып китә торган бу егетнең күзләре ярым

йомык. Ул күрми иде. Янында кызгылт төстәге озын таяк ята, аңа капшанып йөрү өчен кирәк, билгеле.

Беренче очрашкан чакта, Зәбир килгәнне күреп, малайлар аяк өсте бастылар, бик борынгыдан килгән матур гадәт буенча, олы кешене барысы бердәм рәвештә:

— Әссәламәгаләйкем, арма! — дип сәламләп каршы алды.

Зәбир аларның сәламен алды:

— Вәгаләйкем әссәлам, бар болың, огланнар, әй бәрәкалла!

Ата Салих — баягы сукыр егет дигәнебез — урыныннан кузгалмаган килеш кенә малайларның үз янына әйләнеп килүен көтеп торды.

— Кемгә сәлам бирдегез? — дип сорады.

— Аграмун килде, Агаҗан агаларда торачак, — диделәр.

— Исеме ничек? — Ата Салих, таягына таянып, торып басты.

— Исемен белмибез, сорамадык.

Ата Салих энесен, тагын ике малайны белешергә җибәрде.

— Аграмун, синең адың нәмә? (Агроном, синең исемең ничек?)

— Хә-хә... — диде Зәбир, — исемем Зәбир минем.

Малайлар кире йөгерделәр.

Икенче көнне иртән Зәбир, атка атланып, Каушутбентка җир эшләрен башкарырга дип бара иде, мәдрәсә янында таягына таянып утырган Ата Салихны күрде. Зәбир якынлашкач, ул аягүрә басты да кычкырып сәлам бирде:

— Әссәламәгаләйкем, Зәбир!

— Ай, вәгаләйкемәссәлам, егет! Кәефең әйбәтме?

— Ай, бар бол, Зәбир (Исән бул, Зәбир), — диде Ата Салих.

## Беренче әңгәмә

Тагын берничә көн узды. Зәбир эштән кайтып, атын йорт буена бәйләмәкче иде, Ата Салихны күреп алды.

— Сәлам, Ата Карый! — диде Зәбир.

Ата Салих аны аңламады бугай.

— Фатыйма дайза, Зәбир кемне сәламли? — дип сорады.

— Сине, Ата Салих, сине!

— Ә? Ул «Атагарры» дип әйткәч, мин бүтәнгә дәшә дип торам. Мин бит карт кеше түгел, яшь кеше.

— Зәбир! Ата Салих синең белән сөйләшергә дип килде. Вакытың булыр микән? — диде Фатыйма җиңги.

— Булыр. Вакыт табарбыз, — диде Зәбир һәм үсмер егетне кулыннан җитәкләп өйгә алып керде.

Ата Салих бүлмәдә урындыкка утырырга теләмәде, идәнгә киез өстенә аяк бөкләп утырды. Таягын янына куйды. Зәбирнең ул каян килгәнен, нинди һөнәр белүен, ата-аналарын сораштырды.

Зәбир Идел буйлары, анда калган әти-әниләре хакында сөйләгән арада йорт хуҗасы Агаҗан ага, тастымалга төреп, тәбикмәк алып керде. Дөя йонынннан тукыган эскәтерне идәнгә, кунаклар алдына җәеп, тәбикмәкләрен шуның өстенә куйды да аш алырга икенче бүлмәгә чыкты. Кунакларга зур кәсәләргә салынган аш бирделәр.

Тавыш-тынсыз гына тамак ялгадылар, Салих сүз башлады.

— Син мине Каррый дип атадың? Карт күрендеммени?

Зәбир аңлатып бирде:

— Мин сиңа «каррый» димәдем, «карый» дидем. Каррый — карт дигән сүз, ә карый — укучы дигән сүз. Гарәп теленнән кергән сүз ул. Татар халкының бөек шагыйре Тукай үзенең «Шүрәле» дигән әсәрендә, укучыларына «И карием, туктале!» — дип дәшә. Үзбәкләр белән таҗикларның барлык сукырлары, хәер сораганда, дога укыйлар. «Карый» сүзе алар өчен үз исемнәреннән дә якынрак булып китә. Мин сине дә шундый карый дип белдем, син гел мәдрәсә янында утырасың. Әгәр минем сиңа «карый» дип дәшүем ошамый икән, гафу ит...

— Менә хәзер аңлашылды. Үпкәләмим, — диде Ата Салих.

— Юк, юк, Ата Салих, син бик яшь, бик күңелле кеше. Ничә яшь инде сиңа, Ата?

— Мамык җыйганда егерме ике яшь тула.

— Без, димәк, яшьтәшләр. Димәк, син дә 1908 елны тугансың. Без туган көннәребезне бәйрәм итәрбез. Минем туган көнем синекеннән алдарак — август аенда. Мин сине чакырырмын, аз гына шәрап эчәрбез. Ризамы син шуңа, Ата?

— Риза түгел... Мин бит шәрап эчмим, бераз папирос кына тартам.

— Ярый, Ата, без сине папирос белән, чәй белән, пылау белән сыйларбыз.

— Ярар, бәрәкалла, шулай булсын. Тик мин аңламадым, син минем изге догалар ятлавымны, карый булуымны телисеңмени?

— Мин сиңа, Ата, укырга киңәш итәм. Күрмәүчеләр өчен махсус әлифба һәм китаплар чыга. Казанда сукырлар өчен типография бар. Безнең илдә әле ул бераү генә. Ул әлифбадагы хәрефләр күзләләр укый торган хәреф төсле түгел. Алар каты кәгазьгә бөз белән тишеп язылә. Күрмәүчеләр аларны бармаклары белән капшап укыйлар.

Сукырлар арасында галимнәр, шагыйрьләр, артистлар, музыкантлар бар. Мин, мәсәлән, 1925 елны Арчада бер сукыр адвокат та очраттым. Исеме тирә-якка танылган адвокат. Суд ун көнгә сузылды, ун көн буена ул үзенә кирәкле сүзләрне бөзе белән катыргыга төшерә барды, азактан шул язулардан бик оста файдаланды. Мин аның зирәклегенә таң калдым. Дүрт яшеннән сукырайган булган ул. Әмма тырышып укыгач, дәрәҗәле кеше булып җиткән. Мин тагын бер атаклы кешене беләм, Ата, мин әле ул хакта сиңа сөйләрмен. Көрәшче ул. Безнең авыл кешесе, минем күршем. Бүген инде соң, икенче очрашканда сөйләрмен, һәме?!

— Рәхмәт, Зәбир. Мин тыңлармын. Ул кешенең исеме кем соң?

— Зариф аның исеме. Фамилиясе — Вахитов. Үзе югында аны «Сукыр Зариф» дип йөртәләр иде. Төрекмәнчә — «Кер Зариф».

— Сау бул, Зәбир, озак яшә. Сый-хөрмәтең өчен дә, әңгәмәң өчен дә бик зур рәхмәт. Сиңа да рәхмәт, Агаҗан ага. Зәбир! Мин шигырьләр беләм, икенче юлы җырлап күрсәтермен.

— Бик яхшы, Ата. Өеңә үзең кайта аласыңмы? Этләр тимиме сиңа? Озатып куйыйммы әллә?

— Юк, Зәбир. Этләр тими миңа. Сау бул, арыма!

## Икенче әңгәмә

Зәбир Хикмәтов яшәгән йортка Ата Салих икенче мәртәбә ял алдыннан кичен килде. Исәнләштеләр, хәл-әхвәл сораштылар.

Күрми торган егет бу юлы бүлмәгә Зәбиргә тотынмыйча үзе керде. Моннан биш көн элек утырган урынына идәнгә урнашты. Таягын артына куйды:

— Минем юлдашым бу, — диде.

Озакламый Агаҗан ага да керде бүлмәгә. Ул Ата Салихның шигырь сөйләвен үтенде. Зәбир дә Ата Салихның шигырьләрен төн уртасы җиткәнче тыңларга әзер иде. Үтенечне Ата Салих кына кабул итмәде.

— Мин шигырьне теләсә кайчан сөйли алам, аның өчен вакыт күп кирәкми, бүген Сукыр Зариф хакындагы сүзне тыңлыйсым килә, — диде.

— Ярый алай булгач, — диде Зәбир һәм Сукыр Зариф турындагы хикәясен башлады. — Зариф Вахитов 1855 елны туган. Ярлы, бик ярлы гаиләдә. Өч яшеннән сукыр калган. Чәчәк авыруыннан. Өч яшькә җиткәнче ул әнисенең йөзен, кулындагы ипи сыныгын талап алган кызыл әтәчне, әнисе су буена куып барган үрдәкләрне күреп, хәтерләп калган. Әнисе, аңа, баш түбәсенә күтәреп, мәчет манарасын һәм манара башындагы айны күрсәткән. Монысын ул бик томанлы гына исендә калдырган.

Зариф абзыйлар йорты безнең каршыда гына иде. Мин, малай гына булсам да, аның белән бик теләп очраша торган идем. Ул үз тормышыннан бик тә кызыклы вакыйгаларны сөйли иде. Миңа ун яшь тулганда, аңа алтмыштан артыграк иде инде. Җирән сакаллы. Кечкенәдән татарча көрәшләрдә катнашканга күрәдер, базык гәүдәле, таза беләкле иде. Биш бала үстереп, аларның барын кеше итте ул.

Сөйләвенә караганда, балачагында эч пошудан аптырап йөрмәгән. Әтисе аңа шәрә таяклары, агач атлар ясап биргән. Агач шарлар белән санарга өйрәткән. Уңга бер шар, сулга бер шар: бер, ике, өч... Әнисе малайны киндер сүсеннән, йоннан җеп эрләргә өйрәткән. Күзе күрми торган Зариф оеклар, оекбаш һәм бияләйләр бәйләгән. Күршеләре аңа заказны яудырып кына торган. Малай нарат пүләненнән чыра теләргә яраткан. Ул чагында бит коросин лампасы да сирәк кешедә була иде. Һәрбер йортта чыраны кочагы-кочагы белән телеп куялар иде. Аз булса да якты кирәк. Кышкы көннәр кыска, төннәр дилбегә буе — бергәләшеп оек бәйләп, йон эрләп яки чабата ясап кич утырганнар. Сукыр Зариф малай чагыннан ук чабата үрергә дә өйрәнеп алган. Юкәне аңа әтисе әзерләп биргән. Авылда нинди эш эшләсәләр, Зариф шуларның барысын да булдырган — печән чапкан, урак урган. Әмма бала чагыннан ук аның бик тә теләгәне — татарча көрәш булган. Сигез-тугыз яшеннән үзеише малайлар белән көрәшә башлап, кырык-кырык биш яшенә җиткәнче мәйдан тоткан. Сабантуйларның уртасында булган ул! Зариф көрәшнең алымнарын да белә, беләкләре дә чуен кебек. Минем әтине дә көрәшергә өйрәткән. Язларын ул унсигезәр сабантуйда булырга, күп кенә бүләкләр алырга өлгергән. Ул заманнарда үтә дә ярлы, хәерче дәрәҗәсендәге гаилә өчен Зариф көрәшеп алган бүләкләр гаиләне

киендереп тотарга ярдәм иткән. Казанда да көрәшкән, тик анда майдан тоткан батыр булып бик сирәк калган. Казан бит ул! Идел буйларының данлы каласы. Казанга әллә ниткән яклардан чуен беләкле ирләр җыела торган була. Бар, егып кара син аларны!

Сукыр Зарифның даны шундый да таралган, аны тирә-як авыллардан ат белән килеп ала торган булганнар. Җиңүче булып калган чакларда, аның ходай тәгалә тарафыннан кимсетелгән булуын, күзе күрмәвен дә истә тотып, нечкә күңелле авыл картлары сабан туена җыелган барлык мал-мөлкәтнең көрәшчеләргә өләшүдән калганын йөге белән Сукыр Зарифка биреп җибәрә торган булганнар.

Зариф унбиш яшеннән Мозаффар байда ат караучы булып эшли. Көне-төне атлар янында ул. Бай аны сабантуйга да җибәрмәскә тырыша. Бу вакытта Зарифка утыз яшьләр. Бер төнне бай йортына ат караклары керә. Зариф каравыл кычкыра башлый. Каракларның берсе Зариф янына йөгереп килеп, муеныннан эләктереп ала, бишмәт якасыннан күтәреп, аны кычкыруыннан туктатмакчы! Зарифмы соң бирешә торган адәм?! Ул ат карагының касыгына чуен гер төсле йодрыгы белән берне генә тондыра, теге шундук тынсыз ава. Зариф аның кул-аякларын бәйли. Ярдәмгә кешеләр чакыра башлый. Ул арада ат каракларының икенчесе Зарифка балта белән ташлана, байның кибетчесе Сәгыйть ат карагының кулыннан балтаны сугып төшерә.

— Тимә Зарифка, хатыны, балалары ятим кала бит, — ди.

Ат караклары чанага иң яхшы атны җигеп өлгерәләр. Алар белән бергә Сәгыйть тә юкка чыга. Баксаң-күрсәң, сүз куешкан булганнар икән. Мозаффар бай Сукыр Зарифны бер көн тотмыйча куып чыгара. Имеш, ул караклар белән сүз куешкан, атны аларга үзе биреп җибәргән.

— И каргадым да соң Мозаффар байны! — диде миңа Зариф абзый. — Очраклы туры килгәнмедер, нәрсә булса да булган — шул елны Мозаффар байның һәммә эше кирегә китте. Сәүдәсе бетте. Казаннан кайтышлый кулларын, борынын өшетте, гомер буе борын урынына ике тишек кенә күренгән чырай белән йөрде. Өстәвенә, хатыны Хәбибә аңардан мыскыл итеп көлеп яшәде.

Хәбибә-убырлы Сукыр Зарифны да аз мыскылламады, чеметә, ямьсез сүзләр әйтә иде. Өстәвенә, Казаннан килә торган бер энесен — унтугыз яшьлек бер «утын агачын», котыртып, Зарифның битен кычыткан белән чактырган, аның өстенә вак таш аттыра торган булган. Әмма Зариф та аңардан бер мәртәбә үч алган! Теге ни акыллы, ни җүләр егет бер көнне кулына чыбыркы тотып чыккан. Суга бу Зарифка, суга да кача. Зариф тегенең чыбыркы очыннан эләктереп ала да кинәт үзенә тарта. Чыбыркы сабындагы элмәкне теге егет кулына кигән булган, тиз генә ычкындыра алмый. Тартып китерә моны Зариф, чуендай йодрыгы белән берне генә тондыра тегенең касыгына — бөгәрләнеп кенә төшә теге бандит! Бай исә Зарифны мактый, чөнки ул байга җен булып күренгән Хәбибәнең энесен кыйнаган ич.

Менә шул, Ата Салих, бүгенгә әңгәмәбез бетте. Вакыт инде төнге бер. Агаҗан ага йоклый инде. Сүзне йә иртәгә, йә шимбә көнне дәвам итәрбез.

## Өченче әңгәмә

Икенче көнне Зәбиргә кунаклар килде. Алар барысы бергә Миргаб елгасына балыкка барып кайттылар. Кичкырын Зәбирнең хикәясен тыңларга җыелдылар. Зәбир Фатыйма җиңгинең кызын Ата Салихны алырга җибәрде. Сукыр Зариф турындагы хикәянең азагын ишетмәсә, аның үпкәләве мөмкин иде.

— Әссәламәгаләйкем, Зәбир, мин килдем, — диде егет.

Яхшы булган, Ата. Кил, утыр, хәзер Зариф хакындагы хикәяне дәвам итәбез... Зариф егерме тугыз яшендә күзләре яхшы күрә торган сау-сәламәт кызга, ике генә яшькә яшьрәк Латифага өйләнә. Бер елдан аларның Садыйк исемле уллары туа. Ике елдан — Гариф, тагын җиде-сигез ел узгач, кызлары туа. Аңа Гарифә дип исем кушалар. Озак та тормый, Салих исемле малай дөньяга килә. Төпчек туганнан соң бер ел тулар-тулмаста әнисе дөнья куя. Бу 1889 ел була. Балаларын кайгыртып, тәрбияләп яшәгән уңган ананың котмәгәндә үлүе гаиләгә бик зур кайгы китерә. Зариф абзый кая барып бәрелергә белмичә йөри беренче көннәрне. Өлкән улына — унбер, аңардан соң туганына — тугыз яшь, калган икесе гел дә сабыйлар. Тормышны ничек алып барырга? Беренче мәлгә ятим балаларны карашырга Зарифның кияүдәге сеңелләре Хәмидә белән Газизә килеп булышалар. Ләкин алар гел монда гына яши алмыйлар шул — аларның үз гаиләләре, үз балалары бар.

1890 елның язы җитә. Кояш көннән-көн иртәрәк чыга, көннән-көн ныграк җылыта. Карлар эри, кар сулары шаулап йөгерә. Җылы яклардан кошлар кайта. Хәллерәк агайлар язгы чәчүгә әзерләнә. Яз хәлсезләрне, ярлы-ябагайны хәсрәткә сала. Кайдан ат алырга, каян чәчүлек табарга?

Улларын чакырып киңәшә Зариф. Олы улы Садыйкка әйтә: «Син, балам, җәмәгать

кетүен кетәргә чыкмый булдыра алмассың инде быел, — ди. — Староста белән сөйләшермен...» Икенче улы Гарифка сеңлесе белән энесен карап-багып торуны тапшыра. Үзе балтага тотына, көрәк сапларын, балта сапларын ясый. Чабата да үрә. Сабантуйларын көтеп, өмет белән яши.

Сабан туенда башка еллардагыдан да тырышыбрак көрәшә. Авыл картлары, аның хәлен аңлап, ярдәм итәргә әзер торалар. Көрәштә өстен чыкканлыгын да, тол ир булып калганлыгын да истә тотып, сабантуй мөлкәтенең артык өлешен дә аңа биреп җибәрәләр.

Халык канатландырып җибәргәннән соң Зариф кабат өйләнә. Нужа авылыннан, Мари ягыннан бу юлы ул Галимә исемле хатынны алып кайта. Галимә апа үги балаларына да мәрхәмәтле ана булып чыга. Ярлы крестьян тормышының барлык авырлыкларын бергә күтәрешә. Берничә елдан соң ул кыз бала таба, аңа Хәбирә дип исем кушалар. Җорлыгы, ягымлы холкы өчен аны авыл халкы да үз итә. Балалары мәдрәсә белеме алалар. Нык хәтерле ата (күрми торган кешеләрдә хәтер шәп була!) балаларының белемен тикшереп тора. Бар нәрсә дә көйләнеп, үз тәртибенә салына: олы балалары Казанга китеп урнашалар. Берсе заводка, берсе кызыл мал кибетенә эшкә керә. Кечеләре дә аякка басалар.

Малайлар як-яктан тәрәү булгангадыр, Сукыр Зариф атлы-туннлы була, иркен генә өй дә салып җибәрә. Инде матур гына, чүкердәшеп кенә яшибез дигәндә...

## Дүртенче әңгәмә

1914 елның җәендә империалистик сугыш башлана. Зариф агайның берьюлы өч улын сугышка алалар. Садыйк белән Гарифның хатыннары елашып кала, Салих әле өйләнмәгән була.

Крестьян тормышының бөтен авырлыгы Сукыр Зарифка һәм аның кызы Гарифә җилкәсенә төшә. Гарифә ат җигеп сука сукалый, тырма тырмалый, муенына тубал асып, чәчү чәчә. Өйне тәртиптә тоту, ашарга пешерү, мал-туар карау да аның өстендә. Сугыш башланганның икенче елында Гариф яраланып бик озак госпитальләрдә ята, тазару өчен дип әтисе янына кайта, бер елдан гүр иясе була.

— Дөньялар яңарыр, сугышлар бетәр, мин генә булмам, — дип үләр алдыннан үзәкләре өзелеп әйтә ул әтисенә. Солдатларның салкын окопларда ятып арыганлыкларын, фронтта болганышлар башланганын, тиздән азат көннәр киләчәген сөйли. Улы әйткәннәрнең дөреска чыгуын Зариф абзый шатланып көтеп ала. Озак та тормый, патшаны төшерәләр. Аннары Октябрь революциясе була. Зариф абзыйның уллары Садыйк та, Салих та большевиклар ягына чыга. Себер якларыннан томырылып килгән ак генералларга — Колчак бандаларына каршы көрәшеп, икенче улы да корбан була.

Революция килгәндә миңа тугыз яшь иде. Власть халык кулына күчте.

Казаннан килгән өндәмәләрне таратып йөрделәр. Минем әти өндәмәнең татарчасын укыгач, әнигә әйтте:

— Менә бу кәгазьләрне Ювас авылына илтеп, Саттаров Мусага тапшырырга кирәк. Зариф агайга ялынырга туры килер. Минем улым белән икәү илтерләр, хәвефсезрәк булыр, сукыр бер абзый белән бәләкәй малайдан шикләнмәсләр.

Зариф агайны әти янына чакырып алып кайттым. Ул эшнең нәрсәдә икәненә бик тиз төшенде. Өндәмәләр төргәген арбага печән астына яшердек тә юлга чыктык. Ювас<br>ка хәвеф-хәтәрсез барып җиттек. Өндәмәләрне тиешле кешесенә тапшырдык. Әмма авылдан чыккан чакта басу капкасы төбендә безне алама киемле, шикле бер кеше туктатты:

— Сез каян кайтасыз? Кемдә булдыгыз? — ди бу.

Зариф агай каушап калмады:

— Син иң әүвәл миңа шуны әйт әле: кем син, кайдан син,ник чыктың син безнең каршыга? Син мине таларга телисең мәллә? Син уйлыйсыңдыр, арбада Сукыр Зариф утыра икән, аны таларга да була дип. Ул әшәке эшең барып чыкмас! Мин сине җир астыннан эзләп табармын!

Теге әле бурлаттай кызарды, әмма китәргә һаман да комачаулады: бер кулы белән тарантаска тотынган, икенче кулы белән дилбегәгә ябышкан. Мин куркудан кычкырып елый башладым. Тавышка күрше йортлардан йөгерешеп кешеләр чыкты. Алар теге адәмнең кулын тарантастан кубарып алдылар, дилбегәне Зариф агайга тоттырдылар.

Икенче көнне Зариф агай өндәмәләрнең үзебездә калган бер данәсен каравыл өенә илтеп стенага ябыштырып куйды.

— Зәбир! Синең әтинең ярлы кешеме, әллә түгелме? — диде Ата Салих кетмәгәндә.

— Юк, Ата. Минем әтием ярлы кеше түгел, ул урта хәлле. Бабай гына бик тә мескен вә ярлы, җиде балалы бер рухани булган. Үзе чахотка белән авырган. Балалары аңардан берәр нәрсә сорый башласалар:

— Берәм-берәм бәреп үтерергәме соң сезне? Тәмам теңкәмә тидегез бит инде! — дип ачуланган.

Әтием шул гаиләдә иң олы бала була. Кече яшьтән аңа әтисенә булышырга туры килә. Шуңа күрә ул балта эше, пыяла кую, мич чыгару кебек һөнәрләрнең барын да белгән. Җир эшенә дә кулы яткан аның: сука сукалаган, печән чапкан, иген иккән. Алма бакчасы да үстергән, умарта асраган. Мин үзем дә балта эшен беләм. Бакчачы, умартачы, игеннәр белгече мин. Татарлар: «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз», — диләр.

Әтием большевиклар ягында булды, аларга булышты. Син, Ата Салих, бәлки ул вакыйгаларны ишетмәгәнсеңдер, син дә минем кебек үк яшь әле, ул чорда малай гына булгансың. 1918 елны ак чехлар корпусы һәм башка акгвардиячеләр Идел буена басып керә. Кызыл Армиянең, эшчеләр отрядларының тиңсез батырлыклар эшләп сугышуына карамастан, дошман 6 августта Казанны ала. Палачлар кулыннан күп каһарманнар һәлак була: Шейнкман, Комлев, Вахитов. Мулланур Вахитов — Ленинның көрәштәше.

Казанны коткару — Советлар ватанын коткаруга тиң була ул чакта. Казан — Урал — Самара фронтында чехословакларны җиңү — революция язмышын хәл итәчәк, ди Владимир Ильич Ленин. Казанны коткарыр өчен Мәскәү, Петроград гаскәрләре, Азин дивизиясе, Идел флотилиясе, яшь Советлар иленең беренче авиация көчләре сугыша. 1918 елның 10 сентябрендә Казан дошманнардан азат ителә. Казанны коткаручыларны котлап, Ленин телеграмма суга.

Ләкин әле көрәш бетми. Тагын бер елдан, 1919 елның язында минем туган якларым Татарстан янә дә көрәш, бәрелеш, кырылыш мәйданына әйләнә.

## Бишенче әңгәмә

Гражданнар сугышы чорында коммунистларга, авыл активистларына хәвефсезрәк урыннарга китеп торырга туры килде. Бервакыт большевиклардан дүрт кеше безнең авыл аркылы да узды. Алар Мари ягындагы пыяла заводына бармакчы булганнар. Ләкин Зур Битаман авылы аркылы узганда дошман кулына эләккәннәр. Дошманнар белән Насыйбулла дигән нык хуҗалыклы, хәлле кеше җитәкчелек иткән. Большевикларны шыр калганчы чишендереп, хәлдән тайганчы кыйнап, ялангач көе җибәргәннәр. Уникe кеше катнаша кыйнауга. Большевикларның берсе юлда ук үлеп кала.

Бу шомлы вакыйгадан соң Зариф абзыйларга Казан ягыннан, иртән иртүк, җиде кызылгвардияче килде. Кулларында винтовка, өсләрендә яшел гимнастерка, аякларында — чолгау чорнап кигән ботинкалар. Алар килеп кергәндә, Зариф абзый ишегалдында көрәк саплары ясап азаплана. Кызылгвардиячеләрнең берсе Сукыр Зариф белән танышкач, аңа кәгазь бирә. Зариф абзый кәгазьне безнең әтигә китерде. Анда татарчалап мондый сүзләр язылган иде:

«Хөрмәтле Гариф абзый! Бу иптәшләргә мөмкин булган барлык ярдәмне күрсәтергә тырышыгыз».

Кәгазьне укыгач әти:

— Барысы да безгә килсеннәр! — диде. — Әйт үзләренә, Зариф.

Кызылгвардиячеләр бездә тамак ялгадылар, чәй эчтеләр, аннары мин аларны Упкын чокырына хәтле озатып куйдым.

Мин өйгә әйләнеп кайтуга, әти мине күршебез Хәсән абый Мусиннарга җибәрде: «Кетү кайткач та ул безгә керсен, кысыр зур сарыкны суеп бирер», — диде. Әнигә ул ике мәртәбә, мич тутырып уникешәр ипи салырга кушты. Сарыкның итен тулысынча пешереп бирерсең, диде. Боларның нигә шулай эшләнгәнен безгә, малайларга, әйтмәделәр. Ләкин мин бераз чамаларлык идем инде.

Кич җитте, караңгы төште, күктә ай калыкты. Әти атны җикте, арбага чиләк сыешлы мичкә куйды. «Улым, син йоклама, без синең белән икәү суга барырбыз», — диде. Җигүле атны ул чолан янына китереп куйды. Без, Әминә апа белән Хәлимә апа һәм мин, көндезен пешереп куйган ипиләрне арбага ташыдык, әти аларны мичкәгә тутыра барды, пешкән итләрне дә мичкә эченә куйды.

Аннары әти миңа арбаның артына, мичкәгә тотынып басарга кушты, үзе мичкә өстенә алга утырды. Киттек. Күлгә җиткәндә аучы Хәким абый очрады. Әти белән исәнләшкәннән соң шыпырт кына:

— Кояш баегач та күл буендагы тауда ике кеше күренде, — диде. — Кулларында әллә мылтык, әллә күсәк. Җиргә чүмәшеп утырдылар да беркая китмиләр. Мин курка калдым. Сезгә әйтәм, әллә кире кайтасызмы?..

— Кара син, ә? — диде әти, башын селеккәләп. — Ярар, Хәким туган, әйтүеңә рәхмәт. Ходай тәгалә саклар әле...

Күл буена җитүгә безнең янга Хәким агай әйткән ике кеше килеп җитте. Аннары каяндыр — тагын өчәү. Аркаларында капчык, кулларында балык җәтмәсе иде. Әти мичкәдән

итне, ипиларне алып, аларның җәтмәләренә тутыра башлады. Азаккы әйбер итеп әти мичкәдән зур кара чәйнек алды. Ә ул чәйнеккә кәгазьгә төреп тоз, такта чәй салынган иде.

Тиз генә саубуллаштык. Әти мичкәгә күлдән су тутырды.

Әкрен кайттык. Инде ашыгасы юк иде. Юлда мин әтигә:

— Алар бит безгә кергән кешеләр, — дидем. — Авылда калсалар ни булган? Нигә әле без аларны кайгыртабыз, алар әллә безгә туганнармы?

— Әйе, улым, алар безгә туган. Акларга каршы сугышка киткән абыең төсле үк туганнар алар безгә, — диде әти. — Кара аны, бу хакта берәүгә дә әйтә күрмә, йәме!..

## Алтынчы әңгәмә

Ата Салих Казан ягыннан Төрекмәнстанга килгән кунакның сүзләрен отыры бирелебрәк тыңлый, вакыт инде соң булса да, арыдым, кирәкми, дип әйтми. Аңа Идел буйларында барган дәһшәтле вакыйгалар ошый. Ихтимал, ул хәлләр егетнең яшь йөрәген дулкынландырадыр, һәлак булган каһарманнар өчен ут йотып утырырга мәҗбүр итәдер.

— Совет иле дошманнары минем туган якларымнан алып ташлангач, Упкын чокыры кебек тирән чокырларга себереп түгелгәч, Битаман авылына кызыллар килде, — дип башлады яңа әңгәмәсен агротехник Зәбир. — Егерменче кеше иде. Барлык ир-атка җыенга, каравыл өе янына барырга боердылар. Җыелган халыкка җиргә утырырга куштылар.

— Кем дә кем урыныннан тора, үзенә үпкәләсен, газиз гомерен кыярга бер пуля җитә, — диде аларның башлыклары.

Шуннан соң бер кәгазь алып, исемлек укырга кереште. Исемлектә большевикларны кыйнауда катнашкан кешеләр иде. Алар уникә булырга тиеш, унберe монда, уникенчесе — иң явызы, боларны котыртучы Насыйбулла дигәннәре юк.

Кызылармеецлар арасында каратут битле, уртача буйлы берсе торды, күе кара кашларын җыерып, уйланып торгач әйтте:

— Юк икән палач. Юк икән җирән сакал. Нәкъ менә ул минем эугазымнан буды. Пычрак бармаклары белән колак төбемә басып торды. Мин аңымны җуеп егыла яздым. Табарга кирәк аны, табарга!

Исемлектә фамилияләре чыккан кешеләрне кызылармеецлар ягына чыгара бардылар. Эшләгән явызлыкларын, буржуйларга сатылганлыкларь н үз телләре белән әйтеп бирергә куштылар. «Сез явызлыкны халык алдында эшләдегез, гаебегезне дә халык алдында әйтегез!» — диделәр.

Тиешле беркетмә язылып, аны халыкка кычкырып укыгач, совет дошманнарын җәзалаучы отряд әлеге унбер кешегә койма буена тезелергә команда бирде. Сатлык җаннарны коймага терәп аттылар.

Аннары отряд күршедәге Казаклар авылына юл тотты. Анда гаепле алты кеше җәзасын ала, берсе койма аша сикереп чыгып, Ашыт елгасына ташлана — анысын таба алмадылар.

Бу вакыйгалардан соң инде ун елдан артык вакыт узды, әмма авылыбыз халкы әтинең, большевикларга кагылмагыз, дип теге вакытта аерым кешеләрне үгетләп алып калуын әле дә онытмый. Шул сәбәпле исән-имин калуларына сөенәләр.

Сукыр Зарифның өлкән улы Садыйк акгвардиячеләргә каршы гражданнар сугышы беткәнче сугышты. Ул Украинада хезмәт иткән җиреннән демобилизацияләнә. 1921—1922 елның кышында Идел буйларында ачлык котырынганны белеп, ул үзе белән ике пот он ала. Казанга кайта. Әсән авылына — әтисенә тикле кайту мәшәкатe килеп туа. Ат юк, безнең якларга кайтучы күренми.

Мин ул елны Казан педагогия техникумының интернатында укый идем, миңа инде ундүрт тулган иде. Ял көнне безнең авыл кешесе Бутузов Җиһанша карамагындагы постоялый дворга барасы иттем. Садыйк абый белән мин нәкъ менә шунда очраштым инде. Мине күреп ул сөенде, әтисенең, сеңелләренең хәл-әхвәлен сорашты. Аннары әтисенә кайтарып җиткерергә кирәкле ярты капчык онын күрсәтте. Ат юклыктан зарланды, бәләкәй чана белән тартып кайтырга туры килмәгәе, диде.

— Ат табарга тырышыгыз, Садыйк абый, — дидем мин аңа. — Әтиегезне ике пот он белән куандырырга теләвегез бик тә әйбәт, әмма бу байлык белән юлга чыгу куркыныч. Халык ач. Бер телем ипи өчен бер-берсенә ташлана. Юлда сезне талаулары ихтимал.

— Ярар, уйлармын, — диде Садыйк абый. — Синең өйдән чыкканыңа күптәнме? Безнекеләрне күрдеңме?

— Мин киткәндә, Зариф абзый исән-сау иде. Ике кул тегермәне ясады. Берсе — бөртек, берсе иман чикләвеге өчен; бик әйбәт тарттыралар... Зариф абзый югала торган кеше түгел, ганләсен ачтан үтермәскә тырыша.

Садыйк абый белән без менә шулай аерылыштык. Ул чакта урамда 20 градусы

гыйнвар суыгы иде. Иртәгесен ул чана тартып юлга чыгып киткән. Тик... кайтарып җиткерә алмаган ул әтисенә онны. Юкка чыкты Садыйк абыебыз. Беренче империалистик сугышын, гражданнар сугышын узып исән калган каһарман Казан белән Әсән арасында югалды. Менә шулай, туганым Ата Салих.

## Җиденче әңгәмә

Шулай итеп, авыр елларда Зариф абзыйның өч улы да гүр иясе булды. Шул елларны язмыш аны икенче хатынынан — Галимә ападан да мәхрүм итте: ул грипптан вафат булды. Өлкән кызы Гарифә кияүгә чыкты. Зариф агай карамагында аның бердәнбер кызы — икенче хатыны Галимә ападан туган кызы Хәбирә генә торып калды. Ул, туганкай, синең белән минем кордаш. 1922 елны аңа 14 яшь тулды. Аның гомере өзелмәүгә бердәнбер сәбәп әтисе Сукыр Зарифның тырышлыгы булды.

Сукыр Зариф белән Хәбирә сеңелкәш ачлык белән көрәшеп, үлем тырнагыннан исән чыктылар. Июль башында арыш өлгерде. Бу инде исән калу дигән сүз иде. Үлгәннәрнең каберенә үлән үсте.

Ошыймы сиңа минем сөйләгәннәрем, Ата Салих? Сукыр Зариф абзый тормышыннан гыйбрәт алырдай нәрсәләр бармы?

Ата Салих, йомыла төшкән күзләрен ачмаган хәлдә, башын алга суза төшеп, ике кулы белән таягына таянып әйтте:

— Мин сине колакларымны шыңкайтып тыңладым, Зәбир. Әле тагын, күпме сөйләсәң дә, тыңларга әзермен. Син сөйләгән Зариф ага — каһарма-. Герой. Нинди акыллы ул, зирәк, көчле, кыю. Нинди кайгы-хәсрәтләрне, тешен кысып, уздырып җибәрә. Син сөйләгәннәрдән мин менә нәрсәне аңладым бит әле: Зариф ага үзенең сукыр булуыннан кимсенми, ник дигәндә, аны авылдашлары кимсетмиләр. Болар миңа көч бирә. Димәк, ярлы-ябагай өчен дә ялынычлы заманнар узган. Һәркем иркле. Минем беләсем килә: сезнең якларда, Идел буйларында авыллар бездәге кебек кечкенәме? Хуторлар гы-чамы?

— Юк, Ата Салих. Бездә, Идел буенда, хуторлар түгел, бездә 150-200 йортлы авыллар. Бу әле уртача авыллар. 500 йортлы авыллар да бар. Кечерәк авылларда 15-20 йорт. Урамнар туры, йортлар бүрәнәдән. Җирне бездә 12-15 ел саен бү торалар иде. Революциягә кадәр җир ир-атларга гына бирелә иде, хатын-кызга юк. Җир хәзер җан башыннан тигез бүленә.

Җир бүлгәннән соң кишәрлеген таба алмый йөрүчеләр дә була торган иде. Андый чакта Сукыр Зариф агайга баралар, аның хәтер шәп. Ул, менә монда булырга тиеш, дип, урман буйларын, Убырлы чокыры тирәләрен, ындыр артларын хәтереннән барлый. Кешеләр аңа таң калалар, кишәрлек, чыннан да, ул әйткән төштә булып чыга иде. Зариф агай авыл буендагы барлык юлларны белә, япа-ялгызы күрше авылларга йөри, атнага бер мәртәбә базарга чыга, көмеш һәм бакыр тиеннәрне генә түгел, кәгазь акчаны да зурлыгына, кәгазенең шомалыгына карап аера, чутлый белә иде.

— Син киткәндә исән идеме әле ул? — дип әкрен генә сорап куйды Ата Салих.

— Исән иде әле. Аңа җитмештән күбрәк иде бугай инде. Сау-сәламәт калды миннән. Авылда театр уйнаганны карарга ярата иде. Мин Төрекмәнстанга китәр алдыннан Әсәндә булдым, Зариф агай белән сөйләшеп утырдым, авылда күмәк тормыш корырга йөриләр, ул колхозга керергә риза, мин анда камыт тегүче булып файда китерә алам бит әле, дигән иде. Мин киткәнгә генә борчылды. «Кемнәр куяр инде, син киткәч, театрларны?» — диде...

• • •

Ата Салих агротехник Зәбир Хикмәтов яшәгән йортка атна саен килүдән туктамады. Идел буйларында яшәгән Сукыр Зариф турындагы чын хикәя аны әсәрләндергән, хәер эстәп яшәү турындагы уйлары юкка чыккан, ул үзенә өлге-үрнәк итеп ерак-еракта, татарлар яшәгән якларда көн күргән, гомер буе гаделлекне яклаган, уңган Сукыр Зарифны сайлаган иде...

— Рәхмәт сиңа, Зәбир, син кәттә кеше, мин сиңа бүгеннән башлап төрекмән җырларын җырлармын, үзем белгән шигырьләрне укып күрсәтермен. Агаҗан ага белән Фатыйма дәйзә миңа рөхсәт итәр. Кунак ашы — кара каршы була бит, — диде.

# БИШЕНЧЕ ДӘРЕС

*Бөтен дөнья ап-ак булып кар яуганда,*
*Ишек алды, урам, түбә агарганда,*
*Ап-ак булып кайтып килә безнең бабай*
*Безгә төрле-төрле уенчык алган да.*

Габдулла Тукай.

Бала белән татарча җөмләләр төзеп сөйләшә башлаганда, аларның фигыльләрне дөрес куллануына аерым игътибар итәргә кирәк. Татар теленең грамматик төзелеше рус теленнән шактый нык аерыла, бу бигрәк тә фигыльләр өлкәсенә карый. Русча «Кукла упала» дигән җөмләне, мәсәлән, татарча төрлечә әйтеп була:

*Курчак егылды. Курчак егылган. Курчак егылган иде.*

Беренче очракта хәрәкәт баланың күз алдында була: курчак **егылды.** Икенче очракта бала курчакны егылган хәлдә (ягъни эшнең нәтиҗәсен) күрә: курчак **егылган.** Өченче очракта үткәннең билгеле бер моментында булган эш хәбәр ителә: курчак **егылган иде** (аягы сынды).

Әйтик, иртән балалар бакчасына барырга чыккач, яңа яуган карга карап бала: **«Кар яуды»**,— дип әйтә икән, аны, һичшиксез **«кар яуган»** дип төзәтергә кирәк була. Яки:
Әби кунакка килде — Бабушка пришла в гости.
Әби кунакка килгән — (Оказывается) бабушка пришла в гости.
Әби кунакка килә иде — Бабушка приходила к нам в гости.

**Авазларның дөрес әйтелеше.**

Татар телендә **в** хәрефе белән бирелгән аваз рус теленнән кергән сүзләрдә бер төрлерәк, ә татарча сүзләрдә башкачарак әйтелә. Мәсәлән, **вакыт, Вәли, давыл** кебек сүзләрдә ул иреннәрне бөрә төшеп, ике ирен катнашында, ә **вагон, вышка** кебек сүзләр иреннән һәм тешләр катнашында ясала. Бу авазларны үзара буташтырып әйтергә ярамый. Татарча сүзләрдә урыны белән **в** авазы **у, ү** хәрефләре белән дә күрсәтелә. Мәсәлән, тау, дәү. Түбәндәге шигырьдә ассызыкланган урыннарда сез татарча **в** авазын ишетәсез.

Бари Рәхмәт

## УРАМДА ЙӨРҮ

*Чыгабыз урамга*
*Һавага уйнарга.*
*Чуарлап өсләрне*
*Ябалак кар ява.*
*Ябалак кар яу, яу!*

*Без ясыйбыз кардан тау.*
*Ак мамыктай тузгып яу!*
*Бик дәү булсын безнең тау*
*Яу, яу, мамык кар!*
*Яз җиткәнче явып кал!*

Бүгенге дәресне «Гаилә» темасына үткәрәбез. Балаларга **эти**, **әни** (**әткәй**, **әнкәй**), **абый**, **апа**, **кызым**, **әби**, **бабай**, **дәү әни** (дәвәни түгел!), **дәү әти** сүзләрен дөрес әйтергә, дөрес кулланырга өйрәтү максатын куйыйк.

1. Башта гаилә тасвирланган теләсә нинди рәсем, картина буенча әңгәмә үткәрелә.

Бу — гаилә. Бу кем? Бу — әни. Бу кем? Бу — әти. Ә бу кем? Бу — дәү әни. Сүзләрнең мәгънәләре төшендерелә. Сүзләр кат-кат әйтелә. Әни нишли? Әни укый. Әби нишли? Әби бәйли. Әңгәмә нигезендә кечкенә хикәя төзелә.

Бу зур гаилә. Аларның этисе, әнисе, дәү этиләре, дәү әниләре, балалары бар. Алар дус яшиләр.

2. Габдулла Тукайның «Безнең гаилә» шигырен укыгыз (Яттан өйрәнергә дә мөмкин).

*Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —*
*Безнең өйдә без җидәү: безнең песи җиденчесе.*
*Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә[1] бергә йоклый ул,*
*Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.*

3. Курчак белән әңгәмә.

Менә, кызым (улым), Айсылу үзләренең гаиләсе турында сөйләргә тели.

«Мин — курчак. Минем исемем Айсылу. Минем әтием һәм әнием бар. Минем абыем да бар. Безнең матур уенчыкларыбыз бар.»

4. «Бармак уены».

*Бу бармак — бабай*
*Бу бармак — әби,*
*Бу бармак — әти,*
*Бу бармак — әни.*
*Бу бармак — бәби,*
*Аның исеме — чәнти.*

Абдулла Алиш

## ӘКИЯТ

Бер соры куянның үзе төсле зур колаклы бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик ярата икән.

Көннәрдән бер көнне куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайткан.

— Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын,— дигән.

Кызы бу бүләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәт әйткән. Хәзер инде ул яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин куян кызы җылы киез итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнием тапмасын дип, аларны яшереп куйган.

Яланаяк кар өстеннән дә, боз өстеннән дә йөгерә икән. Бер

[1] Безнеңлә — безнең белән.

көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән. Өченче көнне инде әнисе янына килгән.

— Әни, әни, минем аягым бик авырта! — дигән. Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

— Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич,— дигән. Инде нишләргә? Куян кызын күтәргән дә Айболит доктор янына киткән. Барып җитсәләр, доктор Айболитның эше бик күп икән, «Балаларны чиратсыз карыйм мин»,— дигән доктор Айболит. Доктор Айболит куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм әйткән:

— Аягың, төзәлгәч, киез итекләреңне инде бер дә салма, сүземне тыңла, тагын начар хәлгә калма,— дигән.

Доктор Айболитка алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.

Әкиятне укыгыз, эчтәлеген балага аңлатыгыз. Кыскача эчтәлеген баладан сөйләтеп карагыз.

Муса Җәлилнең «Суык бабай» шигырен укыгыз.

*Суык бабай, кил безгә*
*Яңа ел бәйрәменә.*
*Чыршы әйләнәсендә*
*Җыр җырлап әйләнергә.*

*Ефәк кушак билендә,*
*Көмеш балта кулында.*
*Зифа буйлы бер чыршы*
*Үсеп утыра юлында.*

*Балтаң белән чыршыны*
*Кисеп аудар чанаңа.*
*Ул киенеп, ясанып*
*Килсен безнең арага.*

*Уенчыклар, бүләкләр*
*Безгә тагын алып кил,*
*Соңга калма, бабакай,*
*Атлап түгел, чабып кил!*

**Фәһимә ХИСАМОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

**Рәшидә БОРҺАНОВА,**
методист.

## *Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре*

### Казандагы мәдрәсәләр

1. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия», Тихвинский урамында, үз йорты.
2. «Мәдрәсәи Мәрҗания», Захарьевский урам почмагында, үз йорты.
3. «Мәдрәсәи Касыймия», Кабан күле буенда.
4. «Мәдрәсәи Госмания», Тихвинский урам белән Мочальный площадь почмагында.
5. Әҗем мәдрәсәсе, Мыловарный урамда.
6. Закир хәзрәт мәдрәсәсе, Малый Мещанский урамда.
7. Казаков мәдрәсәсе, Печән үлчәве урамында.
8. Зариф хәзрәт мәдрәсәсе, Яңа бистәдә.
9. Салихҗан хәзрәт мәдрәсәсе, ———•————•————
10. Садыйк хәзрәт мәдрәсәсе, ————•————•————

### Ибтидаи (башлангыч) мәктәпләр

1. Русча-татарча кызлар мәктәбе, Екатеринский урам, Алкин йортында.
2. «Әл-иҗтиһад» мәктәбе кызлар өчен, Печән базарында, Мозаффария йортында.
3. «Җәмгыяте хәйрия» мәктәбе, Әрмәнский урамда, үз йортында.
4. «Мәктәп хосусия» Сираҗ хәлфә идарәсендә, Захарьевский урамда, Апанаева йортында.
5. «Ләбибә ханым» мәктәбе, Мещанский урамда, үз йортында.
6. «Ятимнәр мәктәбе», Аркылы Захарьевский урамда, «Мәдрәсәи Мәрҗания» йортында.
7. Яңа ачылачак кызлар мәктәбе «Исмәгыйлия», Екатеринский урамда, үз йортында.

## Дәрдемәнд

### Бер хәзинә

Карт бер игенче, гомеренең актык көннәрендә балаларын янына чакырып әйтте: «Балаларым! Басуыбызның эчендә бер хәзинә бар. Әмма кай җиренә күмелгән икәнен белә алмадым. Мин үлгәннән соң, вакыт заигъ итми, басуыбызга барыгыз, һәр җирен яхшылап казып актарыгыз. Әгәр тапсагыз, ул хәзинә гомерегез буенча тотынсагыз да бетмәс һәм сезне бераүгә дә мохтаҗ итмәс, атадан балага мирас кала килгән бу басуны, сак булыгыз, сата күрмәгез. Чөнки, бердән, киләчәктәге балаларыгызга хыянәт иткән булырсыз, икенчедән, эчендәге хәзинә кулыгыздан ычкыныр».

Карт игенче вафат иткәннән соң, ике кардәш кем узардан басуга йөгерделәр. Казылмаган җир, чукылмаган урын калдырмадылар. Актардылар, эзләделәр — хәзинә юк!

Басуның өсте тоташ казылган, туфраклары тетелеп ватылган иде. Ике кардәш, бу кадәр имгәкләре бушка калмасын өчен, богъдай чәчтеләр. Хәзинәнең табылмаганына бик кайгырыштылар.

Көннәр үтте. Игеннәр пешеп өлгерде. Кардәшләрнең игене күрше игеннәрдән кат-кат артык иде. Урак урылды. Ындыр басылды... Ике кардәш, ындыр табагында өем-өем яткан богъдайны күргәч, аталары әйткән хәзинәнең «тырышып эшләү» икәнен менә шул вакытта гына аңладылар. Шулай итеп, тәҗрибә күргән гакыллы игенче, үзенең уллары алдында, тырышып эшләүнең төкәнмәс бер хәзинә хөкемендә икәнлеген балаларына киная белән аңлаткан иде.

Дәрдемәнд. Исә җилләр. Казан, 1980, 199—200 битләр.

# مدرسه‌لر

۱. «مدرسهٔ محمّدیه» تیخوٚیسکی اورامده، اوز یورتی.
۲. «مدرسهٔ مرجانیه» زاخاریۋسکی اورام پوچماعنده، اوز یورتی.
۳. «مدرسهٔ قاسمیه» قبان کولی بوینده.
۴. «مدرسهٔ عثمانیه» تیخوٚینسکی اورام بله‌ن ماچالنی پلوشچاد پوچماعنده.
۵. اجم مدرسه‌سی میلوۋارنی اورامده.
۶. ذاکر حضرت مدرسه‌سی مالی میشچانسکی اورامده.
۷. کازاکوف مدرسه‌سی پچه‌ن ئولچه‌وی اورامنده.
۸. ظریف حضرت مدرسه‌سی یاڭی بیسته‌ده.
۹. صالحجان حضرت مدرسه‌سی -"-"-"-.
۱۰. صادق حضرت مدرسه‌سی -"-"-"-.

## ابتدائی مکتبلر

روسچا تاتارچا قزلار مکتبی، یکاترینسکی اورام، آلکین یورتنده.
«الاجتهاد» مکتبی قزلار ایچون، پچه‌ن بازارنده، مظفریه یورتنده.
«جمعیت خیریه» مکتبی ئه‌رمیانسکی اورامده، اوز یورتنده.
«مکتب خصوصیه» صراج خلفه اداره‌سنده، زاخاریۋسکی اورامده آپانایۋا یورتنده.
«لبیبه خانم» مکتبی میشچانسکی اورامده، اوز یورتنده.
«یتیملر مکتبی» آرقلی زاخاریۋسکی اورامده، «مدرسهٔ مرجانیه» یورتنده.
یاڭی آچیلاچق قزلار مکتبی «اسماعلیه»، یکاترینسکی اورامده، اوز یورتنده.

قارت بر ایگنچی، عمرینڭ آقتق کونلرنده بالالرین یانینا چاقروب
ایتدی: «بالالریم! باسوویبزنڭ آچنده برخزینه بار. ئه مما قای جیرینه
کوملگه ن ایکه نن بله آلمادم. مین اولگه ندن سوڭ، وقت زایع ایتمی،
باسوویبزغا باریغز، هم جیرین یاخشیلاپ قازوپ آقتاریغز. اگر
تاپساغز، اول خزینه عمریگز بوینچه توتونساغز دا بتمه س هم سز-
نی بره وگه ده مختاج ایتمه س، آتادن بالاغا میراث قالا کیلگه ن بو
باسونی، ساق بولیغز، ساتا کورمه گز. چونکی، بردن، کیله چه کته گی
بالالریغزغا خیانت ایتکه ن بولرسز، ایکنچیدن، آچنده گی خزینه
قولیغزدن اچقنر

قارت ایگنچی وفات ایتکه ندن سوڭ، ایکی قاردش کم اوزار-
دن باسوغا یوگوردیلر. قازلماغان جیر، چوقلماغان اورین قالدرمادیلر.
آقتاردیلر، آزله دیلر- خزینه یوق!

باسونڭ اوستی توتاش قازلغان، توفراقلری تتیلوپ واتلغان
ایدی. ایکی قاردش، بوقدر ایگه کلری بوشقا قالماسن ایچون، بغدای
چه چتیلر. خزینه نڭ تابلماغانینا بیک قایغیرشتیلار.

کونلر اوتتی. ایگنلر پشوب اولگوردی. قاردشلرنڭ ایگینی
کورشی ایگنلردن قات - قات آرتق ایدی. اوراق اورلدی. اندر با-
سلدی... ایکی قاردش، اندرتاباغندا اویوم - اویوم یاتقان بغداینی کور-
گه چ، آتالری ئه یتکه ن خزینه نڭ «تریشوپ آشله و» ایکه نن منه
شول وقتدا غنا آڭلادیلر. شولای ایتوپ تجربه کورگه ن غاقللی
ایگنچی اوزینڭ اوللاری آلدنده. تریشوپ آشله ونڭ توکه نمه س بر
خزینه حکمنده ایکه نلگین بالالرینا کینایه بله ن آڭلاتقان ایدی.

Тихвинский — хәзерге Тукай урамының колхоз базары белән Татарстан урамы арасындагы өлеше. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» — хәзерге Г. Тукай урамы, 34 йорт.
Екатерининская — хәзерге Г. Тукай урамы.
«Мәдрәсәи Касыймия» — хәзерге Комсомольская урамы, 28 йорт.
«Мәдрәсәи Мәрҗания» — хәзерге З. Солтан урамы, 4 йорт.
«Мәдрәсәи Госмания» — хәзерге Нариман һәм Татарстан урамнары почмагында.
Захарьевский — хәзерге К. Насыйри урамы.
Әрмәнский — хәзерге Спартаковская урамы.
Яңа Бистә — Казанның көньягында урнашкан бистә, хәзер шәһәрнең Идел Буе районына керә.
Печән базары — иске Казандагы зур базар, хәзерге Киров һәм Париж коммунасы урамнары чатында урнашкан.

*Текст 1910—1912 елларда Казанда басылган «Татар» исемле юл күрсәткечтән алынды (35—36 битләр).*

*Журнал өчен текстны Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

---

## Котлыйбыз!

## Диләрә Зөбәеровага 60 яшь



Диләрә Гази кызы Зөбәерова 1930 елның 9 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Күтәмәле авылында туган. Җидееллык мәктәпне авылда тәмамлап, Алабуга педагогия училищесында, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган. Аннары ул Татарстан китап нәшриятында редактор булып, республикабызның төрле районнарында укытучы булып эшли, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә хезмәт итә. 1962—1985 елларда Диләрә Зөбәерова — «Азат хатын» журналының бүлек мөдире.

Укучыларыбызга язучының күп санлы әдәби-публицистик язмалары, «Куш өянкеләр шаһит», «Кыр чәчәге» кебек повестьлары, җылы лирика белән сугарылган хикәяләре яхшы таныш.

Ул —1971 елдан СССР Язучылар союзы члены.

## Барлас Камаловка 60 яшь



Барлас Хәмит улы Камалов 1930 елның 17 гыйнварында Татарстанның Чистай шәһәрендә укытучы гаиләсендә туган. Казанга килеп, педагогия институтының тарих-филология факультетында югары белем ала, 1953—1956 елларда шул ук институтның татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурада укый. 1959 елда «Гомер иткәндә» дип исемләнгән беренче китабы дөнья күрә.

Барлас Камалов, күп еллар төрле газета һәм журнал редакцияләрендә эшләгәннән соң, алтмышынчы еллар ахырыннан башлап — профессиональ язучылык хезмәтендә. Шул вакыт эчендә аның бик күп санда хикәя, ике дистәгә якын повесть һәм роман, күпләгән очерк һәм публицистик язмалары, мәкалә һәм рецензияләре басылып чыкты. Авторның иҗат кыйбласы — бүгенге тормыш, аның кискен проблемалары. Ул үзенең күп кенә геройлары аша югары әхлак, ватандарлык идеалларын раслый. «Күңел кыңгыраулары», «Сыналыр чак», «Ялыкмаслар», «Китәрсеңме?», «Канатлы кырмыска», «Сарсаз кызы Сәрия», «Узган гомер бигрәк җәл» повестьлары, «Өметең өзелмәсен» романы һәм башка күпләгән әсәрләре әнә шуның ачык мисалы.

Ул — 1961 елдан СССР Язучылар союзы члены.

## Фәрит Хатиповка 60 яшь



Фәрит Миргалим улы Хатипов 1930 елның 1 гыйнварында Татарстан АССРның Актаныш районы Пучы авылында туган. 1947 елда Ф. Хатипов Казанга килеп, университетка укырга керә. Соңгы курсларда укыганда матбугатта язышa башлый, беренче рецензияләрен һәм тәнкыйть мәкаләләрен бастыра. 1955 елда ул М. Әмир иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклый. 1955—59 елларда Түмән өлкәсенең Тобол педагогия институтында укыта, «Ленин юлы» исемле татарча өлкә газетасын оештыруда катнаша, анда җаваплы секретарь булып эшли.

1959—72 елларда Ф. Хатипов Башкорт дәүләт университетында укыта. Күренекле татар язучылары иҗатына багышланган мәкаләләр бастыра, «Эпик жанрлар» исемле хезмәтен яза. 1972 елдан бирле ул Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы мөдире.

Ф. Хатипов үзәк газета-журналларда, Татарстан һәм Башкортстан матбугатында басылган күп санлы әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм китаплар авторы. 1982 елдан СССР Язучылар союзы члены. Ул — филология фәннәре докторы.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярларны кайнар котлый, аларга сәламәтлек һәм иҗат уңышлары тели.

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

13—15 ноябрьдә Мәскәүдә РСФСР Язучылар союзы идарәсенең чираттагы VI пленумы булып узды. Пленумда Россия Федерациясе карамагындагы нәшриятләр һәм журналларның эшчәнлеген тагын да яхшырту мәсьәләләре каралды. Махсус докладлар белән РСФСР Госкомиздат рәисе урынбасары Л. Шапкин һәм РСФСР Язучылар идарәсе секретаре М. Шевченко чыкты. Пленум эшендә ТАССР Язучылар союзы идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, рәис урынбасары М. Маликова, РСФСР Язучылар идарәсе члены Р. Фәйзуллин, Ревизия комиссиясе члены Ә. Гаффар иптәшләр катнашты. Фикер алышуларда Р. Мөхәммәдиев чыгыш ясады. Шул ук көннәрдә РСФСР Язучылар союзы секретариатының Язучылар союзына яңа әгъзалар кабул итүгә багышланган утырышы да булды. Ул утырышта Татарстанның яшь язучылары Р. Гыйззәтуллин, Ә. Мостафин, Ф. Зыятдинова, Н. Вәлитова, М. Зарецкий, В. Лавришко, С. Малышев иптәшләр СССР Язучылар союзына кабул ителделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

5 октябрьдә шигърият секциясенең оештыру җыелышы булып узды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе урынбасары М. Маликова ачып, секция алдында торган җаваплы эшләр турында сөйләде. Аннан соң секция җитәкчесе итеп сайланган шагыйрь З. Мансуров киләчәктәге планнар, яңа тәкъдимнәр белән таныштырды. Соңыннан секциянең яңа бюросы сайланды.

●

18 октябрьдә тәнкыйтьчеләр секциясенең отчет-сайлау җыелышы узды. Отчет докладды белән әдәбият галиме Ф. Мусин чыкты. Яңа бюро һәм секция җитәкчесе итеп тәнкыйтьче Ф. Зөлкарнәев сайланды. Бүгенге тәнкыйть һәм аның иҗтимагый аңны күтәрүдәге роле турында зур сөйләшүдә тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре Г. Халит, А. Әхмәдуллин, Г. Гыйлманов, А. Яхин, И. Илялова, М. Вәлиев, Р. Кукушкин, Ә. Мәхмүдов, М. Гайнетдинов, Н. Ханзафаров һ. б. катнашты.

●

Чәчмә әсәрләр секциясенең 18 октябрьдә узган җыелышында «Дөнья мәдәнияте һәм татар әдәбияты» дигән зур сөйләшү булды. Анда аксакал әдип Г. Бәширов, Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, язучылар Б. Камалов, Р. Хафизова, С. Шәмси һ. б. чыгыш ясады.

Секциянең яңа бюросын һәм җитәкчесен сайлау уздырылды. Секция җитәкчесе итеп язучы Ә. Гаффар сайланды.

## БАЛАЛАР ӨЧЕН ТАТАРЧА ЯҢА ЖУРНАЛ

29 сентябрьдә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретариаты нәниләр өчен татар телендә «Салават күпере» дип аталган яңа журнал чыгара башлау турында карар кабул итте.

13 октябрьдә ТАССР Язучылар союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты органы булган бу журналның баш редакторы итеп, Язучылар союзы идарәсе президиумы тәкъдиме белән, З. Хөснетдинов (Зиннур Хөснияр) сайланды.

Әлеге журнал 1990 елдан сатуга чыга башлаячак.

## АКАДЕМИК БЕЗДӘ КУНАКТА

Ноябрь аенда якташыбыз, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, СССР халык депутаты Роальд Зиннур улы Сәгъдиев Казанда кунакта булды. Ул Казан дәүләт университетында студентлар, галимнәр, Татар иҗтимагый үзәге вәкилләре, журналистлар белән очрашты. Бу кызыклы очрашу вакытында сүз җәмгыятебезне үзгәртеп кору процессы, космонавтиканы үстерү, милли проблемаларны хәл итү һәм Татарстан АЭСы төзелешен туктату турында да барды.

## ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 70 ЕЛ

10 ноябрьдә В. И. Ленин исемендәге Үзәк музейның Казан филиалында, Татарстан китап нәшрияты оештырылуга 70 ел тулу уңаеннан, республика китап бәйрәме үткәрелде.

В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе хезмәткәрләре тарафыннан оештырылган китап күргәзмәсе Татарстан китап нәшрияты үткән катлаулы һәм мактаулы юлны күзалларга ярдәм итә. Анда гарәп, латин һәм хәзерге алфавит белән дөнья күргән күп санлы хезмәтләр урын алган.

70 ел эчендә (1919—1989) Татарстан китап нәшрияты 31 мең 498 исемдә 375 миллион данә китап, брошюра һәм башка төрле продукция чыгарды. Хәзерге вакытта нәшрият ел саен 8 миллионга якын данә тираж белән 340 китап, брошюра һәм башка төрле продукция бастырып чыгара.

Татарстан китап нәшрияты директоры

Х. Әшрәфҗанов тантанага килгән күп санлы китап сөючеләргә, язучыларга китап сәнгатенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында мавыктыргыч итеп сөйләде.

## ТОКТОГУЛ ЮБИЛЕЕ

Октябрь аенда атаклы кыргыз акыны Токтогулның (Токтогул Сатылганов) тууына 125 ел тулуга багышланган юбилей Кыргызстанда зур тантана белән билгеләп үтелде. Фрунзе шәһәренә илебезнең күренекле шагыйрьләре, чит ил кунаклары җыелдылар. Кыргызстан Язучылар Союзы председателе Ч. Айтматов чакыруы буенча бу әдәби бәйрәмгә Казаннан шагыйрь Равил Фәйзуллин барды. Ул тантаналы җыелышта чыгыш ясады һәм Токтогулның туган җире Чолпан-Атада булды, акынның яңа ачылган музеена Токтогулның татар телендә чыккан шигырьләр китабын бүләк итте.

## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ҮЗӘКЛӘРЕ ХӘБӘРЛӘРЕ

### Таллинн

Эстония башкаласында «Татар культура берлеге» җәмгыятенең оешуына октябрь аенда бер ел тулды. Шушы кыска гына вакыт эчендә милләттәшләребез белән сигез очрашу үткәрелде. Очрашуга килүче татарларның саны арткannан-арта бара. Сабан туе үткәрү, видеофильмнар карау, әкиятләр уку, балаларның җыр-биюләре һәркем күңеленә хуш килә. Хәзерге вакытта Р. Низаметдинова тырышлыгы белән Шимбә көн мәктәбенең эше җайга салына башлады. Балалар татарча сөйләшергә, укырга өйрәнәләр, әмма дәреслекләр, әдәби китаплар җитешмәве, программалар юклыгы хәзергә үзен нык сиздереп тора.

### Куйбышев

Ноябрь аенда КПССның Куйбышев өлкә комитеты политик мәгариф йортында «Идел-Кама Болгар иленең тарихы һәм культурасы. Халыклар дуслыгын ныгытуда тарихи фәннәрнең өлеше» дигән темага кызыклы сөйләшү булды. Милләттәшләребез алдында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты галимнәре А. Халиков, Ф. Хуҗин, Г. Дәүләтшин, И. Якимов, Р. Вәлиев, Куйбышев университеты доценты Г. Матвеева, профессор П. С. Кабытов һ. б. чыгыш ясады.

Болгар бабаларыбызның ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулу уңаеннан Куйбышев шәһәрендә яңа мәчеткә нигез салынды.

### Пенза

Пензада «Якташлар» исемле татар мәдәнияте җәмгыяте оешты. Җыелышта җәмгыятьнең Уставы, эмблемасы һәм советы сайланды. Җәмгыять рәисе итеп Пенза врачы Әсият Умярович Дашкин сайланды.

Татар яшьләре исә вокаль-инструменталь ансамбль оештыра. Аның да исеме — «Якташлар».

### Оренбург

Узган елның 17 маенда татар әдәбияты классигы Дәрдемәнд хөрмәтенә мемориаль такта ачылды (Ленин урамы, 31 йорт). Хатирә тактасы ачу уңае белән оештырылган митингта Оренбург халкы, шәһәр советы хезмәткәрләре катнашты. Митингта татар иҗтимагый үзәге вәкиле З. Шакиров, Мәскәүдән шагыйрь Р. Бохараев, СССР География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, хезмәт ветераны М. Рәхимкулова чыгыш ясады.

Митингтан соң Х. Ямашев исемендәге китапханәдә Дәрдемәнднең тормышы һәм иҗатына багышланган конференция үткәрелде.

### Әндиҗан

Әндиҗандагы 2 нче Культура йорты каршында пенсионерка Х. Хөснетдинова тырышлыгы белән «Идел» исемле татар-башкорт һәвәскәрләр ансамбле оештырылды. Август аенда Әндиҗанның Нәваи исемендәге культура һәм ял паркында ансамбльнең концертлары булып узды.

### Уфа

Октябрь аенда Уфада Нефтьчеләр культура сараенда рәсми төстә татар җәмәгатьчелеге җыелышы булып узды. Җыелышны әзерләү һәм үткәрүдә Г. Ибраһимов исемендәге татар мәдәнияте сөючеләр клубы тырышлык күрсәтте. Җыелышта сүз Башкортстан АССРда яшәүче татар милләтенең хәзерге хәле һәм киләчәге турында барды.

Җыелыш илнең һәм республиканың югары партия һәм совет органнарына җибәреләчәк резолюцияләр кабул итте. Аларда, КПССның Милли мәсьәләләр буенча платформасына нигезләнеп, башлыча шундый таләпләр куела (кыскартып бәян ителә):

республикада, башкорт һәм рус телләре белән беррәттән, рәсми тел буларак, татар теленең конституцион статусын яңадан торгызырга;

«БАССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр турында»гы Закон проектындагы 99 статьяны 1937 елдагы БАССР Конституциясенең 24 статьясы редакциясендә яңадан торгызырга, ягъни анда: «Башкорт АССР Законнары, БАССР Верховный Советы карарлары һәм башка актлары башкорт, татар һәм рус телләрендә басылып чыга» дип язылырга тиеш;

мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә һәм мәктәпләрдә туган телдә укыту мөмкинлекләрен киңәйтергә һәм формаларын үстерергә, шәһәрләрдә татар балалар бакчалары һәм мәктәпләр челтәрен арттырырга;

БАССР Язучылар союзы каршында татар секциясе оештырырга;

Уфада татар телендәге китаплар чыгаруны яңадан җайга салырга;

татар телендә иҗтимагый-политик журнал чыгаруны юлга салырга;

сәнгать институтында һәм училищесында, педагогия институтында татар бүлекләре булдырырга;

республика тапшыруларының вакытын озайту исәбенә, радио һәм телевидениедә татар телендә тапшыруларны яңадан торгызырга;

Уфада 1912—1922 елларда эшләп килгән Татар дәүләт театрының яңадан эшли башлавына ирешергә;

элекке «Галия» мәдрәсәсе бинасында үрнәк татар мәктәбе ачарга.

### Тобол

Шәһәрдәге типография күптән түгел Татар мәдәнияте үзәге өчен беренче басма продукция чыгарды. Анда афишалар, чакыру кәгазьләре, буклетлар бар. Киләчәктә шәһәрдә һәм районда узачак һәртөрле кичәләр, концертлар, бәйрәмнәрнең рекламасын, программасын күпләп бастырып чыгару күздә тотыла.

Шәһәр радиосы татар телендә тапшырулар башлап җибәрде. Аның программасында татарча соңгы хәбәрләр бирелә, сораулар буенча җырлар тапшырыла.

### Туймазы

Татар иҗтимагый үзәгенең Туймазы бүлеге, узган ел гына оештырылуына карамастан, шәһәр һәм район авыллары мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын яңадан укыта башлау, татар сәнгатен һәм әдәбиятын пропагандалау, милли гореф-гадәтләрне халыкка кире кайтару өлкәсендә максатчан эшләп килә. Туймазыда татар халык театры, «Ләйсән» татар театр студиясе, «Алтын башак» әдәби берләшмәсе эшләп килә. З. Низаметдинов җитәкчелегендәге Туймазы татар иҗтимагый үзәге бүлеге республиканың иҗади көчләре белән тыгыз элемтәдә эшли, төрле кичәләр, очрашулар уздыра. Туймазыда профессиональ театр — татар дәүләт театры ачуга һәм мәчет төзүгә әзерлек бара.

### Бәләбәй

Татар иҗтимагый үзәгенең Бәләбәй бүлекчәсе тырышлыгы белән, «Автонормаль» заводының бакчасында татар-рус бүлеге ачылды. Ике урта мәктәптә татар телен өйрәнү буенча бәрәр башлангыч класслар булдырылды. Татар милләтенең барлыкка килүенә һәм аның тарихына багышланган лекция укылды.

«Автонормаль» заводының Техника йортында «Туган тел» бәйрәме уздырылды, халык иҗатыннан торган концерт булды.

### Кемерово өлкәсе

1989 елның 16—21 октябрендә Кемерово өлкәсенең Ижмор районы Җылы елга авылында урнашкан урта мәктәптә, татар теле укыта башлауга әзерлек уңаеннан, өлкә укытучылары семинары үткәрелде. Семинарны үткәрүдә Халык мәгарифе идарәсе начальнигы урынбасары Н. Неворатова, Кемерово укытучылар белемен күтәрү институты методисты Г. Белорыбкина, Ижмор районы Халык мәгарифе бүлеге мөдире В. Савильева активлык күрсәттеләр. Гөлшат Биккулова җитәкчелегендәге мәктәп коллективы семинарда катнашучылар өчен барлык шартларны тудырганнар иде.

Атна буена татарча дәвам иткән семинар эшендә РСФСР Халык мәгарифе Милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы мөдире, филология фәннәре докторы Ф. Юсупов, филология фәннәре кандидаты Г. Әдһәмова, халык мәгарифе отличнигы С. Мөхәммәтшина катнашты.

Ике ярым гасыр артык яшәгән авылда рәсми рәвештә татарча сөйләшү, әлбәттә, мәктәп стеналарына гына сыймады. «Азат Себер» колхозы партком секретаре К. Сабиров һәм колхоз председателе З. Алтынбаев инициативасы белән семинарның дәвамы культура сараена күчте, әдәби-музыкаль кичә белән тәгәлләнде.

### Түбән Кама

Мәскәүдә яшәүче татар язучысы, дингезче Миргазиян Юныс, «Түбән Каманың «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе чакыруы буенча, Татарстанда булып китте. Иң әүвәл ул туган районы Баулы авылларында чыгыш ясады. 31 октябрьдә, «Җидегән чишмә» коллективы белән берлектә, Баулының үзендә М. Юнысның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

Андый кичәләр 4—5 ноябрьдә Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрендә дә уздырылды. Зур әдәби бәйрәмгә әверелгән кичәләрне Чаллы язучылар оешмасы җаваплы секретаре Рахмай Хисмәтуллин алып барды.

## «ТАҢ АТА» АНСАМБЛЕ — КАЗАНДА

Ноябрь ахыры һәм декабрь башында Казан, Яр Чаллы шәһәрләрендә Төркиядә яшәүче татарлардан төзелгән «Таң ата» фольклор ансамбле концертлары булып узды. Казанны сагынып килгән Төркиядә яшәүче милләттәшләребез Казан Кремле, Сөембикә манарасы белән таныштылар, Казан дәүләт университетында булдылар, Татарстан әдипләре белән очраштылар. «Таң ата» фольклор ансамбле, Татарстанга килгәнче, дөньяның бик күп илләрендә — шул исәптән Япония, АКШ, Франция, Австралия, Кытайда булып кайткан.

Ансамбльдә кырыкка якын кеше исәпләнә. Татарлардан тыш, аның составында казакълар, үзбәкләр, кыргызлар да бар. Казанга ансамбль биш кешелек составта килгән иде. Ансамбль җитәкчесе Истанбул университеты галиме Рахми Өрч Гүвәнч һәм аның юлдашлары Яшәр Гүвәнч, Айгөл Гүвән, Гүлтән Ураллы һәм Кадыйр Пүчәкләрнең максаты — борынгы төрки-татар җырларын җыю, саклау һәм халыкка җиткерү.

## Кече манара

Чалт аяз көн. Акрын гына искән талгын җилдә тузганаклар тирбәлә. Тирә-як иниңдәр бер моңсу тынлыкка чумган. Әйләнәдә — җырларда җырланган, риваятьләрдә макталган, даны ерак илләргә таралган борынгы Болгар шәһәре хәрабәләре. Әнә, болгар бабаларыбызның дәүләт корып яшәгән заманнарының якты бер истәлеге булып, манара басып тора. Аны Кече манара дип атыйлар. Ак ташлардан салынган манараның ишек яңаклары, тәрәзә уемнары таштан «үреп» ясалган нәфис бизәкләр белән нәкышләнгән. Ничә гасырлар килеп китүгә карамастан, алар әле дә билгесез болгар остасының кул җылысын саклый шикелле.

Кече манара — шәһре Болгарның хәзерге вакытта чагыштырмача яхшы сакланган тарихи-архитектура истәлеге. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, манара «изге болгарлар» җирләнгән урында төзелгән һәм тирә-юньдәге төрбә-мавзолейлар белән бербөтен корылмалар комплексын тәшкил иткән. Манара янындагы каберлек татар риваятьләрендә «Хан зираты» дип тә йөртелә. Кече манараның төзелүен археологлар XIV гасырның икенче яртысына нисбәт итәләр һәм җәмигъ мәчетнең Олы манарасы үрнәгендә төзелгән дип раслыйлар. Биеклеге унбиш метр чамасы булган бу манара өскә таба нечкәрә барган цилиндрик каүсә һәм аның өстендәге конус түбәле галереядән гыйбарәт. Үзенең төзелеше, бизәк мотивлары белән ул Кавказ аръягы, Кече Азия һәм Кырым манараларына охшаш. Берьяктан хәрби манараны да хәтерләткән әлеге корылма Азәрбайҗанның каравыл манараларына да якын тора дип әйтергә була.

Заманында Болгарда тагын бер манара — Олы манара да була. Әмма ул 1841 елның бер төнендә күршедәге Болгар авылын гына түгел, янәшә тирәдәге авылларның халкын да тәмле йокысыннан уятып гөрселдәп авып төшә. Олы туганын югалтуга сыкранса да, Кече манара, заманнар узуга артык исе китмәгәндәй, галибанә кыяфәттә басып торуын дәвам итә. Узган гасырларның телсез шаһиты булган манара кемнәрне генә үзенә җәлеп итмәгән, кемнәрне генә тирән уйга, кайгы-хәсрәткә салмаган. XVIII йөзнең билгесез бер татар шагыйре әнә нәрсә ди:

*Шәһре Болгар манарасы*
*Сиксән баскыч һәм арасы.*
*Анда менгән ирәнләрнең*
*Сил тик агар күздин яше.*

Дөрес, бу очракта шагыйрь Олы манараны күздә тоткан, күрәсең. Чөнки Кече манараның өске катына алып менүче әйләнеч таш баскычның басмалары кырык биш. Әмма безнең өчен басма саны түгел, ә шагыйрьнең тарихыбызга мөнәсәбәте, күңел түреннән чыккан ихлас сүзе кадерле. Әйе, Кече манара кешеләр тарафыннан игътибарсызлыкка үпкәли алмый.

1722 елда Иран сугышына барышлый император Петр I Болгарда туктала. Кече манарага менеп болгарларның кала төзү өчен уңайлы урынын сайлый белүләренә соклана һәм истәлек өчен аның диварына исемен дә язып куя. Болгарда бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани дә еш була. 1860 елда ул Кече манарага менеп исемен түгел, ә буыннар эстафетасы турында гаҗәпчә тирән эчтәлекле шигырь яза. 1830 ел азагында шәһре Болгарга сәяхәт кылган Эдуард Турнерелли болай ди: «Заманында бу диварлар менә хәзер безнең кебек тормыш белән кайнап торганнар, ә хәзер келгә әйләнгән, онытылган, ташланган». Юк, онытылмады алар, онытырга бик тырышсалар да, онытылмады. Заманалар узу белән Кече манара бәет-риваятьләрдән фәнни монографияләргә, китапларга, рәсем-фотоларга күчте, Болгар тарих-архитектура тыюлыгының күркенә әверелде, кино-телевидение экраннарына чыкты, календарь белән диварларга эленде, значок-билге булып күкрәкләребезгә менде. Ә шулай да манарага карап уйга калган вакытларда еш кына күңелдә Шәһре болгар бәетенең түбәндәге юллары яңара:

*Җиһанны тетрәтмеш иде синең олуг шәүкәтең,*
*Кайда милкең, кайда гыйльмең, кайда бөек дәүләтең?*

Җәүдәт **МИҢНУЛЛИН**,
тарих фәннәре кандидаты.

**Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле татар әдибе Салих Баттал.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосы.

# *Китаплар дөньясында*

**Татарстан китап нәшрияты 1988—1989 елларда түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:**

**Ак чәчәк атар идем.** Хәсән Туфан турында истәлекләр. 368 бит. Б. 1 с. 60 т.

Гамил АФЗАЛ. **Коянкка карап.** Сайланма лирика, шигырьләр. 272 бит. Б. 1 с. 20 т.

Әхсәт БАЯНОВ. **Алтын кашбау.** Шигъри трагедия. 80 бит, рәсем белән. Б. 25 т.

Клара БУЛАТОВА. **Хәтер тәрәзәләре.** Шигырьләр. 80 бит. Б. 30 т.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. **Сәнгать дөньясына сәяхәт.** Болгар иле турында истәлек язмалар. 48 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

Кол ГАЛИ. **Кыйссаи Йосыф.** Матур Йосыфның гүзәл Зөләйхага мәхәббәте, аның тормыш маҗаралары турында дастан. 224 бит. Б. 1 с. 40 т.

Мәсгуд ГАЙНЕТДИНОВ. **Давылларда, җилләрдә.** Хәсән Туфанның тормыш һәм иҗат сәхифәләре. 280 бит. Б. 1 с. 20 т.

Аркадий ГАЙДАР. **Повестьлар һәм хикәяләр.** 272 бит. Б. 80 т.

Нәби ДӘҮЛИ. **Әйтмичә булмый, булмый.** Әдәби парчалар. 184 бит. Б. 80 т.

Евгений ЕВТУШЕНКО. **Казан университеты. Әни һәм нейтрон бомбасы.** Поэмалар. 152 бит. Б. 80 т.

Анатолий ИВАНОВ. **Повестьлар.** 328 бит. Б. 1 с. 40 т.

**ИДЕЛ.** Яшьләрнең әдәби альманахы. 1989 ел. Хикәяләр, шигырьләр, мәкаләләр. 96 бит. Б. 25 т.

**Иртешкә сәяхәт.** Мөхәммәт Садри Себердәге халкыбыз арасыннан җыйган әкиятләр, җырлар. 160 бит. Б. 70 т.

Рафис КОРБАНОВ. **Җиде төстә кунакта.** Балалар өчен шигырьләр. 32 бит. Б. 5 т.

Александр КУПРИН. **Повестьлар.** 496 бит. Б. 2 с. 50 т.

**Ленин турында хикәяләр.** 112 бит. Б. 40 т.

Зиннур МАНСУРОВ. **Юлын белгән арымас.** Тормыш, әдәбият һәм сәнгать турында уйланулар. 166 бит. Б. 60 т.

Туфан МИҢНУЛЛИН. **Өмет.** Повесть, хикәяләр, юморескалар, уйланулар. 256 бит. Б. 1 с. 10 т.

Зәет МӘҖИТОВ. **Татар шигърияте Бөек Ватан сугышы елларында.** 144 бит. Б. 50 т.

Шәрәф МӨДӘРРИС. **Тупчы Вәһап.** Шигырьләр, поэмалар, сонетлар. 192 бит. Б. 45 т.

Илдар НИЗАМОВ. **Бер карадым.** Парчалар бәйләменнән повесть. 192 бит. Б. 50 т.

Вакыйф НУРУЛЛИН. **Шинельсез солдатлар.** Повестьлар. 256 бит. Б. 1 с. 10 т.

Владимир ОБРУЧЕВ. **Санников җире.** Роман. 272 бит. Б. 80 т.

Александр ПУШКИН. **Балыкчы һәм балык турында әкият.** 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 25 т.

Софья РАДЗИЕВСКАЯ. **Урман әкияте.** Хикәяләр. 168 бит. Б. 25 т.

Майн РИД. **Башсыз җайдак.** Роман. Икенче басма. 496 бит. Б. 2 с. 50 т.

Шамил РӘКЫЙПОВ. **Йолдызлы төннәр.** Роман-дилогия. 544 бит. Б. 1 с. 30 т.

**Салам Торхан.** Татар халык әкияте. 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 40 т.

Җәвад ТӘРҖЕМАНОВ. **Әтәчкәй.** Әкияти хикәят. 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.

Шамил УСМАНОВ. **Кичеккән фәрман.** Повесть һәм пьеса. «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән. 272 бит. Б. 65 т.

Мәрзия ФӘЙЗУЛЛИНА. **Салават күпере.** Шигырьләр. 24 бит. Б. 50 т.

Хәкимҗан ХАЛИКОВ. **Канатлы мәче.** Балалар өчен шигырьләр, әкиятләр, арифметик табышмаклар. 64 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.

Шәриф ХӨСӘЕНОВ. **Мәхәббәт сагышы.** Повесть, драмалар, хикәя. 352 бит. Б. 1 с. 40 т.

Марс ШАБАЕВ. **Гомер уты.** Шигырьләр һәм поэмалар. 142 бит. Б. 75 т.

Сәет ШӘКҮРОВ. **Артист.** Повесть. 256 бит. Б. 1 с. 10 т.

Солтан ШӘМСИ. **Җаяүле буран.** Повесть һәм хикәяләр. 160 бит. Б. 75 т.

Илдар ЮЗЕЕВ. **Сандугачлар килгән безгә.** Комедияләр, драмалар. 352 бит. Б. 1 с. 50 т.

Муса ҖӘЛИЛ. **Кечкенә дусларга.** Балалар өчен шигырьләр, поэма. 160 бит, портрет белән. Б. 45 т.

Шамсия ҖИҺАНГИРОВА. **Балачак кая китә.** Шигырьләр. 32 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга-почтой». 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1, отдел «Книга-почтой».

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)